КАЗАН ДӘҮЛӘТ УНИВЕРСИТЕТЫ
ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕ ҺӘМ ТАРИХЫ ФАКУЛЬТЕТЫ

ФӘННИ ЯЗМАЛАР – 2007

Казан
2008

Китап Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы "Татарстан Республикасы халыклары телләре турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру Комитеты ярдәмендә нәшер ителде.

Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультеты Гыйльми Советы карары нигезендә басыла.

Фәнни мөхәррир – проф. Гыйләҗев И. А.

Җаваплы мөхәррир һәм төзүче – доцент Юсупова Ә. Ш.

Мәкаләләрдәге орфографик һәм фактик хаталар, төгәлсезлекләр өчен җыентык төзүчеләр җавап бирми.

Җыентыкта факультет укытучыларының өр-яңа фәнни мәкаләләре урын алды. Бу мәкаләләрдә татар теленең иң актуаль мәсьәләләре, татар әдәбиятының мөһим проблемалары, тарих, мәдәният өлкәсенә караган темалар күтәрелә.

Җыетык филологларга, аспирантларга һәм студентларга адреслана.

Эчтәлек

Абдулвәлиева Л.Ш.
Рабит Батулла драматургиясендә тарихи шәхесләр образлары
Аминева В.Р.
Проблема характера в рассказах Ф.Амирхана «Праздники» и «Блаженный день»
Әнвәрова М.Х.
Татар телендә “задә” антропонимик берәмлеге
Әхмәдуллин А.Г.
Бүгенге татар драматургиясендә яңалык сулышы
Батталова А.Д.
Т.Миңнуллинның “Без бит авыл малае” комедиясендә йорт образы
Батыршина А.Н.
XX йөз ахыры – XXI гасыр башы прозасында яңа тенденцияләр: дискурс мәсьәләсе
Бәдертдинова Л.Ш.
Гази Кашшаф һәм татар театр тәнкыйте
Бурсаков И.С.
Становление Российской Федерации в период 1917 – 1922 гг.
Вәлиева Л.Ә.
Автомобиль терминологиясендә фигыль тезмәләр
Габидуллин Р.Р.
Ирекле шәхесләр илгә нигә кирәкми?
Гали Г.Ф.
Принцип преемственности в обучении английскому языку
Гараева Л. Ф.
Татарская периодическая печать начала XX века и ее роль в функциональном развитии татарского языка.
Гәрәева Л.З.
Татар телендә исем фигыльнең килеш белән төрләнүе.
Гобәйдуллин Л.И.
«Икътисад» журналында (1908-1913) авыл халкының социаль - көнкүреш проблемаларының чагылышы
Гыйлаҗев Т.Ш.
Тәнкыйди-гыйльми фикердә Тукайның әдәби абруе мәсьәләсе (XX гасырның беренче чиреге)

Гыймранова Г.Ш.
XX гасыр башы татар шигъриятендә аваз кабатлауларның эстетик вазифасы
Даутова Г.И.
Сөйләм күнекмәләрен үстерү чарасы буларак текст
Денмөхәммәтова Э.Н.
Балалар фольклорында лексик синонимия
Егоров А.Н.
Литературный процесс «оттепели» в формировании нового поколения татарской творческой интеллигенции
Закирҗанов Ә.М.
Хәзерге татар әдәбият белеме проблемалары
Йосыпов А.Ф.
XIX гасыр татар поэзиясе телендә гарәп-фарсы элементлары
Йосыпова Н.М.
Хәзерге татар драматургиясендә интеллектуаль тенденция: М.Гыйләҗев
Калимуллина А.Г.
Уровень смертности в Казанском уезде Казанской губернии
за 1865-1870 годы и ее причины.(статистические данные)
Кашфиева Л.
Илдус Гыйләҗевнең мәхәббәт лирикасында шәхес гәүдәләнеше
Кириллова З.Н.
XX гасыр башы татар әдәби телендә аныклаучы теркәгечләр
Кузьмина Х.Х.
Матур әдәбият телендә темпоральлекне белдерү чаралары.
Маннапова Л. М.
Хәзерге татар әдәби телендә парлы сүзләр ясалышының фонетик закончалыклары
Миннегулов Х.Ю.
Еще раз о турецко-татарских взаимосвязях
Минегулова А.Р.
Об употреблении этнонима «татары» в «Полном собрании русских летописей»
Мирсиязпова Т.И.
Мөхәммәт Хәнәфи – философ. (“Хәят вә фәлсәфә” исемле мәкаләләр циклы мисалында)

Мөгътәсимова Г.Р.
Татар халык табышмакларында фигыльләр
Мусина Г.Ф.
Морфологический способ образования технических терминов в татарском языке от именных основ
Мустафина Д.А
Одна из страниц истории включения литовских татар в российское правовое пространство в первой половине XIX века
Нәбиуллина Г.Ә.
Поэзиядә номинатив җөмләләрнең мәгънәви-стилистик кулланылыш үзенчәлекләре
Нуриева Ф.Ш.
Региональные особенности в языке памятников золотоордынского периода
Сабиров Р.Р.
К.Тинчуринның “Мәрҗәннәр” әсәрендә шәхес һәм дәвер каршылыгы
Садыкова Л.Р.
Глагольное словообразование в трудах Шигапа Рамазанова
Сайхунов М.Р.
Ритмическая структура татарской разговорной речи
Сафиуллина Ф. С.
Татар телендә парлы сүзләр
Сәлахова Э.К.
Хәйрияче Хәкимовлар
Сәлимҗанова Ф.С.
Татарстан республикасының антропотопонимик системасы
Сибгаева Ф.Р.
Хәзерге татар әдәби телендә поэтик фразеологик антонимнарны өйрәнү мәсьәләсе
Усманова Г.С.
А. Троянский сүзлегендә сүзләрнең кулланылыш сферасы ягыннан тасвирлануы
Фазуллина Л. Х.
Язучы-прозаик буларак Газиз Гобәйдуллин
Фәтхуллова К.С.

Телара аралашу ысулы буларак тәрҗемә

Хаков В.Х.

Татар әдәби теле тарихында хәл ителәсе кайбер мәсьәләләр

Харрасова Р.Ф.

Текстта җөмләара бәйләнешләрне тикшерү

Хәбибуллина Л.Р.

XX йөз башы татар поэмаларында мифологиянең урыны

Хәкимов Б.Э.

Русча-татарча икетеллелек шартларында профессиональ телдән тәрҗемә һәм аңа өйрәтүнең кайбер мәсьәләләре

Хәкимуллина Х.Р.

“Баласы бар кошның күңеле ояда була” (Р.Мингалимнең “Өченче бүлмәдә эт яши” (1980) драмасы буенча)

Хәмидуллина Г.Н.

Тел белемендә реклама феномены

Хәсәнова А.М.

Әдәбият белемендә жанрлар төрлелеге мәсьәләсе

Хисамова Л.А.

Хәзерге татар вакытлы матбугатында варваризмнар

Хөрмәтуллина Р.Ш.

Гамил Афзал әсәрләрендә эндәш сүзләрнең роле

Хузина Э.С.

Понятие «гендер» в языкознании

Хурматуллин А.К.

Понятие «дискурс» в современной лингвистике

Шакирова Г.М.

Гаяз Исхакыйның проза әсәрләрендә портрет бирелеше

Шәйдуллина Р.Р.

Бертуган Хөсәеневләрнең татар мәгърифәте өлкәсендәге эшчәнлекләре (XIX йөз ахыры-XX йөз башы)

Шәкүрова М.М., Шәехов М.Р.

Г.Гыйльмановның “Фронтовик” парчасына лингвистик анализ ясау

Шәмсетдинова Р.Р.

Фәнни-техник әдәбиятны тәрҗемә итүгә кагылышлы кайбер мәсьәләләр

Юсупов А.Ф.

Верования в тюрко-монгольском мире до образования Золотой Орды

Юсупов Ф.Ю., Хәмидова Ф.Ф.

Минзәлә сөйләшенең формалашу һәм өйрәнелү тарихы

Юсупова А.Ш.

Отражение субъективных факторов в татарско-русских и русско-татарских словарях XIX века

Юсупова А.Ш., Ситдыкова А.Ф.

Тематические группы «Посуда» в татарско-русских и русско-татарских словарях XIX века

Янсаева Л. А.

Татар теле диалекталь синтаксисында җөмлә кисәкләренә кагылышлы аермалыклар.

Абдулвәлиева Л.Ш.

Рабит Батулла драматургиясендә тарихи шәхесләр образлары.

Әдәбиятның төп бурычларыннан берсе – барыннан да элек, үз заманын, хәзергене иҗади чагылдыру, үз чорының мөһим бурычлары белән яшәү һәм халыкны кызыксындырган беренче бурычларга сәнгать сүзе белән җавап бирү. Әмма җәмгыятьнең хәзерге яшәеш мәгънәсен, сынын үткәндәге көннәрдән, еллардан, элекке үсеш тарихыннан башка тирәнтен аңлау мөмкин түгел. Һәр язучының иҗатында тарих сизелми калмый, чөнки ансыз халык характерен тирәнтен аңлап һәм дөрес сурәтләп булмый.Үткәндәге тарихи вакыйгаларны, атаклы тарихи шәхесләрне, гомумән, бик борынгы заманнарда яки чагыштырмача якын чорларда халык һәм дәүләт кичергән тарихи вакыйгаларны, фактларны, әлбәттә, барыннан да элек тарихчылар өйрәнә, документлар нигезендә ачып салалар,теге яки бу дәвернең тарихи үсеш закончалыкларын фәнни нигезләп бирәләр. Монда сәнгать һәм әдәбиятның да роле кечкенә түгел.
[4, 152-159б.]

Рабит Батулла тарихи темаларга күптәннән бирле мөрәҗәгать итеп килә. Аның игътибары борынгы чорларга да, чагыштырмача якын вакытка да юнәлә. Шуның өстенә төрле төрләрдә, төрле жанрларда иҗат итә. “Сөембикә” романы укучылар тарафыннан да, әдәбиятчылар тарафыннанда уңай кабул ителде. Бөек шагыйребез Г.Тукайга ике жанрда әсәр багышлап язды.(“Сират күпере”, “Кылычтан үткен, кылдан нечкә”)

1986 нчы елда язылган һәм 1987 нче елда Драма һәм комедия театры тарафыннан сәхнәләштерелгән “Сират күпере” драмасы укучыларның һәм тамашачыларның күңелен яулап алды.

Татар әдәбиятында, аеруча шигъриятендә һәм драматургиясендә Тукай образы шактый тудырылган. Әле 1930 – 1950 нче елларда ук Әхмәт Фәйзи “Тукай”, “Тукай Җаекта” пьесаларын, соңрак “Тукай” романын, 60 нчы елларда И. Нуруллин “Тукай Петербургта” драмасын иҗат итәләр. Бу әсәрләрдә шагыйрь образын тарихи фонда ачуга, чынлап та

булган тарихи фактлар ярдәмендә сурәтләүгә ныклы игьтибар бирелә.

Соңгы елларда да драматурглар бу образга кат-кат мөрәҗәгать итәләр. Габдулла Тукайның тууына 100 тулу уңаеннан берничә сәхнә әсәре язылды. Риза Ишморатның “И мөкатдәс моңлы сазым”, Туфан Миңнуллинның “Без китәбез, сез каласыз”, Илдар Юзеевның “Очты дөнья читлегенннән”, Әхәт Гаффарның “Соңгы сәгать” исемле пьесалары дөнья күрде.

Күп кабатланган тема кебек булса да һәр каләм иясе Тукай шәхесен ачуга төрлечә якын килә. Бу аларның шагыйрь тормышыннан хәбәрдарлык дәрәҗәсе, әсәрнең үзәк мотивы, образны тудыруның алдан куелган ачык максатлары белән бәйле. Рабит Батулла шагыйрь образын калкуландырган пьесасы башка әсәрләрдән шактый аерылып тора. Ул үлем алдындагы шагыйрьгә бәйле һәм чынлыкта да булырга мөмкин фаразларын күз алдына бастыра. Автор үз фантазиясен мул куллана. Ләкин моның белән тарихи әсәр үз кыйммәтен югалтмый.

Алда әйтелгәнчә, драмада төп каһарман булып Тукай образы тора. Инде ул җитлеккән шагыйрь, гомеренең сонгы көннәрен кичерә. Шагыйрьгә хас сыйфатлар төрле ситуацияләрдә ачыла. Пьесаның беренче битләреннән үк аның тугры сүзле, намуслы, мохтаҗларга ярдәм итүче булуы күренә.

Белгәнебезчә, драманың нигезендә конфликт ята.Тукай Шәүлә белән җитди конфликтка керә. Шәүлә артында “ике башлы зур каракош” тора. Каракош – турыдан-туры Рәсәй хөкүмәте символы. Шәүлә һәм Тукай арасындагы конфликтның сәбәбе шагыйрьнең шәхси сыйфатлары белән дә бәйле. Ул – милләтпәрвәр, үз халкының бәхете өчен көрәшүче каһарман. Ул бу юлда хәтта үзенең шәхси бәхетеннән дә ваз кичә. “Минем өчен түгел андый тормыш, - ди ул дусты Агабәккә. – Мин тулаем халыкныкы! Башым, иҗатым, авыруым мин халыкка кире кайтарып алмаска тапшырылган. Мин гаиләдә вакланып бетсәм, халыкка ни калыр? Шуңа күрә өйләнмәскә уйладым”.

Әйе, монда Тукай берьяклырак караштa тора, дип әйтергә була.Ләкин бит ул үзенең каты авыру икәнен белә. Шуңа күрә изге ялганга барырга мәҗбүр була.

Әсәрнең төенләнеше дип “Тукай каты авырый” дигән ялган телеграмма сугуны әйтеп була. Вакыйгалар үстерелешендә

каршылык хәрәкәт итә башлый, катнашучы яклар турында мәгълүматлар арта, тирәнәя. Телеграммадан соң, Тукайның охранкадан яшеренеп йөргән дуслары берәм – берәм аның янына хәл белергә киләләр. Бу - дошманнар өчен менә дигән вакыт. Мәсәлән, күпме эзәрлекләп тә, эзләп тә таба алмаган Ядкәр Хөрмәтовны (революционер Хөсәен Ямашев) Тукай янында булганнан соң тиз генә эләктереп алалар.

Әйе, Тукай ялгыз түгел, аның җан дуслары бар. Күршесендәге Агабәк (прототибы Фатих Әмирхан) кенә дә ни тора. Шагыйрьнең кайгысын да шатлыгын да уртаклаша, киләсе көнгә көч бирә. Сагышлы, Бикчура исемле дуслары да Тукайның хәлен белеп торалар.

Алар һәммәсе шагыйрьнең иҗтимагый тормышындагы, милләт язмышындагы урынын ачыкларга, аның әдәбиятка карашын, иҗат кешесенең җәмгыять тормышында биләгән урынын күзаллавына төшенергә, шагыйрьнең нинди граждан һәм патриот икәнлеген гәүдәләндерергә булышалар. [2, 147б.] Гомумән алып әйткәндә, “Сират күпере”нең үзәгенә драматик шәхес язмышы куелган. Бу язмыш халык язмышы белән тиңләштерелә. Ядкәрнең “Татарның ютәленә дәва юк, Тукай”, - дип әйтүе генә дә милләтебезне ютәлләп ятучы Тукайга җирлек итә.

Драмадагы Тукайның тагын бер сыйфатын күрсәтми китеп булмый. Ул аның шәхси тормышына, мәхәббәтенә кагыла. Алдарак язылган әсәрләрдә Тукай берьяклырак, күбесенчә көрәшче генә итеп, үз милләте өчен җан атучы гына итеп сурәтләнгән булса, Рабит Батулла Туташ һәм Ханым образлары ярдәмендә Тукайны үз рухи дөньясы булган шәхес итеп тә тасвирлый. Моның белән автор шагыйрьне тулы канлы итеп күзаллата. Бу әсәрдә Тукай - җир шарындагы һәрбер кешегә хас сөю хисенә ия булган олы җанлы кеше. Ул мәхәббәт шигырьләре язырга илһамландыручы Туташны чын күңеле белән ярата. Аның белән аралашкан күренешләр тирән лиризм белән сугарылган, тамашачыны да, укучыны да тетрәндерергә мәҗбүр итә. Бу авторның зур уңышы дип әйтергә була.Үзенең терелә алмаслык авыру икәнен белгәнгә күрә, шагыйрь Туташның мәхәббәтен кире кага. “Мин сезне сөймим” дип, изге ялганга бара. “Тукай: (үзалдына). Хуш, бәгырем, мәңгегә бәхилләә бу ялганымны!

Мәхәббәт шигырьләремнең илһамчысы, хуш, Бәхил бул! Әльаман, туташ, әльаман.Әлвидаг, туташ, әлвидаг!”

Ханым белән сөйләшкән өлештә Тукайның тагын берничә сыйфаты ачыла. Ул –горур, кеше акчасына, бигрәк тә, хатын – кыз акчасына үлсә дә яшәмәячәк. Ул- акыллы, ханымны үпкәләтмичә генә ярдәмен кире кага.

Кульминацион ноктада Шәүлә үзенең бөтен серен, пычрак эшләрен Тукайга сөйләп бирә. Шунысы игътибарга лаек, Рабит Батулла Тукайга багышланган башка әсәрләрдә кебек Шәүлә образын берьяклы гына сурәтләми. Дөрес, ул – көчле, мәкерле, астан гына эш йөртүче.Ялган телеграмманы да ул суга. Шул хәбәргә ышанып Ядкәр Казанга кайта.Ялган хәбәр Сагышлы һәм Бикчураның да башына җитә. Ләкин Шәүләдә дә хаклык бар. Аның революция турында үз фикере бар:

“Шәүлә. …Революция ясаучыларның туксан проценты надан була. Биш – ун хыялыйның идеясенә котырып, наданнар баш күтәрә. Баш күтәрү вакытында үлеп бетә. Революция юлы уртасында шыр наданнар гына торып кала. Баралар наданнар, кая барганнарын белмиләр. Кая барабыз соң без, барабыз да барабыз, дип сораганнарны әлеге наданнар революция исеме белән кырып ташлыйлар. Интеллигенция бетә, аек фикерлеләр атыла, шиклеләрне аталар. Алай-болай булмагае дип, һич гаепсезләрне дә төрмәләргә тыгып бетерәчәкләр. Илне шом, деспотизм шаукымы басачак. Һәр палач гөнаһсыз башны чапканда бисмилла урынына: “Яшәсен революция!” дип акырачак. Менә нәрсә ул әзерлексез революция. Хөрмәтов Ядкәр хыялланган революция – ул революция түгел, ул ирексезләү, көчләү хәрәкәте генә булып калачак. Әгәр Ядкәрләр җиңә калса, Россияне “грядущий хам” – тупаслык, әдәпсезлек басачак. Россия әле чын революциягә әзер түгел. Мин менә шуннан куркам, Тукай. Әнә шундыйлар Россия халыкларын ялгыш юлдан алып китмәгәе дип, бөтен көчемне, талантымны биреп көрәшәм.”

Чыннан да, 1917 нче елдагы инкыйлабтан соң көткән хыяллар тормышка ашмый. Киресенчә, рус булмаган милләтләрне юкка чыгару сәясәте тагын да көчәя, шәхес культы һәм башка репрессияләр башлана.

Драманың азагында Тукай үлемгә дучар ителгән булса да җиңүче булып кала. Аның эшләрен башкалар дәвам итәчәк. Шәүлә җиңелә, моны үзе дә таный:

“Шәүлә. Синең һәр бәйрәмеңне олылап бөтен Россия, бөтен Европа күләмендә уздырачаклар… Синнән кала Әмирханнар, Рәмиевлар, Кариевлар, Сәхипҗамаллар, Камаллар даһи саналачак.”

Соңгы елларда да Рабит Батулла тарихи әсәрләр иҗат итүен дәвам итә. 2004 нче елда уздырылган “яңа татар пьесасы ” дип аталган конкурста катнашкан “Җимерелгән бәхет” пьесасы бу өлкәдә аерым бер урын алып тора. Монда авторның бу әсәрне язу алдыннан күпме материал җыюы соккландыра. Чыннан да, олы язмышлы шәхесләрне тасвирлаганда драматург аларның бөтен нечкәлекләренә кадәр күз уңыннан ычкындырмый. Әлбәттә, болар автор фантазиясе белән бергә үрелеп бара. Автор Әхмәров, Алкин, Тинчурин гаиләләрен, Г.Кариев, Г.Исхакыйларны җентекләп һәм яратып сурәтли. Болар - авторның олы табышы. Укучыга, тамашачыга күпме кызыклы һәм мөһим фактларны, вакыйгаларны китерә, тарихтан билгеле булган шәхесләрнең холык-фигыльләрен ача. Ул елларның картинасын күз алдына бастыра. Дөрес, бу әсәрне сәхнәгә кую авыр булыр. Бу - пьесаның композицион төзелешенә дә, монологларның артык озын булуына да бәйле.

Төп герой – олы яшьтәге Заһидә ханым Тинчурина. Пьесада аның яшь чагы хатирәләр төсендә дә, параллель рәвештә дә бирелә. Ул – статский советник Шаһбазгәрәй Әхмәров һәм зыялы нәселдән булган Хадичә Алкина кызы. Алар балаларына яхшы тәрбия, төпле белем биргәннәр. Заһидә дә рус, Аурупа әдипләрен өйрәнә, алар язган әсәрләрнед өзекләрен яттан сөйли. Аларның тормыш фәлсәфәсен үрнәк итеп саный. Гомумән, ул елларда, күрәсең, зыялы яшьләр шул ук фикердә, шул ук караштa торганнар. Бигрәк тә бөек язучыбыз, милләтпәрвәр Г.Исхакый Заһидәгә тирән йогынты ясый. Аның бөтенләй үзгә фикере бар.Ул үз милләтен инкыйраздан саклап калу өчен соңарып булсада татарларны берләштерү уе белән яши. Язучы Көнчыгыш һәм Көнбатыш әдәбияты фәлсәфәсен тигез күрү ягында тора. Күренә, драма авторы позициясе шул ук якта. Драматург, чигенеш ясап булсада, Заһидә ханым сүзләре белән бүгенге

тормышка, тел мәсьәләсенә үз фикерен белгертеп бара. Бу ханым - мөселман хатын кызына хас булганча исктикеч сабыр. Күпме авырлыклар күреп тә, үз милләтенә хезмәт итүдән туктамаган. Гомере буе балалар укыткан. Ире Кәрим белән араларны бозу өчен күпме коткы салмасыннар, барыбер акыллы эш йөртә белгән, иренә ышанган, кирәкмәгәнгә тавыш куптармаган. Шуның белән ул дошманнар алдында җиңүче булып кала белгән.

"Җимерелгән бәхет" пьесасындагы тарихи образлар бик күп. Алар арасында характер булып оешканары да, эпозодик һәм атап кына үтелүче геройлар да бар. Алда әйтелеп үтелгән Гаяз Исхакый образы шактый тулы ачылган. Ул үзенең туры сүзле булуы белән башкалардан аерылып тора. Аның язмышы сокландыргыч та, кызганыч та. Бөтен гомерен татар халкына багышлаган шәхес чит илгә китеп үләргә мәҗбүр була. Шунысы да мөһим: монда бөек шәхесебез Гаяз Исхакый образы татар драматургиясендә беренче мәртәбә урын ала. Пьесадагы һәрбер геройның олы язмышы аша автор илдә барган сәясәткә үзенең тискәре мөнәсәбәтен белгертә. Күпме талант ияләре сугышта үлеп калган, шәхес культы корбаннары булган. Аеруча бу афәтләр татар башына төшкән. Рабит Батулла моны ассызыклап күрсәтүе белән бик тә хаклы. Әсәрдәге геройларга төшкән бәлалар белән автор тулаем милләтнең киләчәк язмышының уртаклыгы проблемасын куя. Аны уңай чишү күбесенчә үзебездән торуын күрсәтә. Олы шәхесләрне тиешенчә бәяли алмавыбыз хакында Рабит Батулла әсәрдә генә түгел, ә үзенең әңгәмәләрендә дә ачынып сөйли.

Авторның башка әсәрләрендә дә кабатланган Шәүлә образын күрсәтми китү мөмкин түгел. Ул кагылган кешеләр берәм-берәм үлеп баралар.Сәхнәгә Шәүлә дүрт төрле кием киеп чыга.Мәсәлән, беренче бөтендөнья сугышында катнашып, гарип булып кайткан Заһидәнең абыйсы Ильяс кызыл армеецлар тарафыннан үтерелгән вакытта Кара Шәүлә кызыл бөркәвечтән була. Бу – символик мәгънәгә ия "Теткәләнеп беткән Илъяс абыемны - ватан өчен кан койган каһарманны да...Мең үлемне кичкән, әҗәлне үзе эзләп йөргән мәһабәт ир Ильяс Әхмәров яшисе килеп, савыгып йөргәндә шулай һәлак булды. Аны патша армиясе офицеры, суелып бетмәгән татар морзасы дип, кызыл иблисләр харап итте, "- дип сөйли Заһидә. Драматург кеше

гомерен кисеп ”гадел” хөкүмәт төзүчеләрне “кызыл иблисләр” дип атый.”Сират күпере” драмасыннан аермалы буларак бу әсәрдә Шәүлә образы бары тик кара буяулар белән генә бирелә.

Тарихыбызны белү - бүгенгебезгә, кичәгебезгә дөрес итеп карау. Тарихи үткәннәрдән дөрес мәгълүматлы булу - милли үз-аң тәрбияләүдә мөһим шарт. Алдагы көннәрдә “узгандагылар” кабатланмас өчен кирәк, “үткәннәрне белеп гыйбрәт ал” ди халкыбыз.

Әдәбият

1. Әдәбият белеме сүзлеге / Төз-ред. А.Г. Әхмәдуллин. – Казан кит. нәшр., 1990.
2. Әхмәдуллин А.Г. Күңелләрне уятыр: Хәзерге татар драматургиясе: Монография. – Казан: Мәгариф, 2007.
3. Заһидуллина Д.Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Яңадан эшләнелгән һәм тулыландырылган икенче басма. – Казан: Мәгариф, 2004.
4. Хатипов Ф. Романнарда Сөембикә образы // Казан утлары. – 1993. - №12. – 152-159 б.
5.

Аминева В.Р.

Проблема характера в рассказах Ф.Амирхана «Праздники» и «Блаженный день»

Установлено, что отношения между планом выражения, планом содержания и планом референции в европейских литературах подчиняются родо-видовой семантической логике, в соответствии с которой происходит уточнение общего родового понятия за счет видовых спецификаций, вписывание видового значения внутрь уже намеченной родовой области, сопровождаемое сужением смысловой сферы за счет наполнения ее большим количеством содержательных характеристик. Родо-видовой организации смысловых единиц альтернативна процедура нахождения смысла, которая требует, как доказывает А.В.Смирнов, не абстрагирующего *очищения* от специфицирующих признаков, а перехода от отдельных явлений к той области, которая лежит вне их и в которой они *совпадают*. [Смирнов 2001: 308-309]. Родо-видовые механизмы осмысления

содержания понятий и изложения материала блокируются художественным сознанием мусульманского Востока с его столь же фундаментальной и универсально признаваемой теорией «указания на смысл». Родового расширения и видового сужения слова, которое благодаря этому начинает включать и дополнительные значения, здесь не происходит, как не происходит и приращения смысла. Но достигается большая «подтвержденность» указания на тот смысл, который служит последним основанием всякого разъяснения.

Описанную логику смыслопорождения демонстрируют способы создания характера в прозе татарских писателей I трети XX в. Так, в рассказах Ф.Амирхана «Праздники» (1908), «Блаженный день» (1910) и др. характеристика внешнего облика человека строится таким образом, что между типическим и индивидуальным устанавливаются отношения соответствия, совпадения, взаимоперехода друг в друга. А.Сайганов, исследуя соотношение общего и индивидуального в структуре характеров, созданных Ф.Амирханом, приходит к выводу: «Жизненный тип видится Ф.Амирхану в его неповторимом индивидуальном своеобразии. Он – одновременно и тип, и конкретная живая личность. Не случайно *сима* (тип) употребляется татарским писателем в двух значениях. Так, в характеристиках Ш.Марджани, З.Бахтиярова, Э.Аппаковой он прилагается в одних случаях к типическому лицу, в других – к отдельной личности. Более того, нередко характеристика существенных свойств жизненного типа сопровождается указанием на его индивидуальные, личностные качества, типическое воспринимается в свете этих индивидуальных качеств» [Сайганов 1982: 64].

Доминирующие в психологии представителей старого мира черты: устойчивость, известный стереотип привычек и чувствований, - выявляют тщательно выписанные детали одежды, интерьера, поведения героев. В рассказе «Праздники» подробно перечисляются элементы одежды Вали-абзыя, собирающегося в мечеть. Такие же точные и конкретные детали используются при описании внешности его сына Габдельгалляма. Добросовестная обстоятельность, пристальное внимание к

малейшим подробностям вызваны стремлением запечатлеть как можно полнее конкретику мусульманского быта и жизни, формирующей социально-психологические типы.

Подчеркивается повторяемость, воспроизводимость одних и тех же событий, действий, слов, что передает ощущение однообразия, монотонности жизни, отсутствия перемен, создает образ «застывшего» времени. Каждое действие или событие сопровождается словами «как всегда», «как обычно», «все так же, как в прошлые годы», «так же, как и тогда» и т.д. С таким течением времени, свойственным старому, патриархальному миру, связано мироощущение, поведение людей, ритм их жизни. Не изменение, а повторение – определяющий момент их сознания.

Но выполняющие сатирическую функцию приемы внешней изобразительности смягчаются точкой зрения «изнутри»: «в повествование вводится мотив стариковской тоски» [Валеев 1985: 50]. Праздник в честь окончания поста вызывает у Вали-абзыя грустные раздумья о скоротечности жизни, быстро уходящей молодости, неизбежности смерти. Благодаря мотиву щемящей тоски персонаж воспринимается не только в социальном, бытовом, но и родовом общенациональном масштабе. Понимание исчерпанности и обреченности традиционных отношений и форм быта, сознание того, что старый мир гибнет, приводит Вали-абзыя в отчаяние. Он искренен в своем возмущении не только новым строем жизни, но и непочтительностью, подчеркнуто пренебрежительным отношением молодого поколения к мнению «отцов». Таким образом, преданный старым устоям и порядкам, правоверный мусульманин Вали-абзый дается в двойственном освещении: «изнутри» и «извне», глазами другого, что определяет живую объемность, объективную полноту его портрета.

Ф.Амирхана более всего интересуют мысли, чувства, душевный склад, моральный облик человека, оказавшегося перед выбором между двумя типами жизни – старой и новой. В рассказе проявляется характерное для татарской прозы первой трети XX в. изображение объективного мира согласно формам его восприятия и осмысления героями: домашняя обстановка Габдельмажита, литературный вечер даются глазами

Габдельгалляма, т.е. в субъектной соотнесенности и мотивированности тем видением жизни, которое присуще этому герою. Такой способ повествования, сюжетно-ситуативно сближающий субъекта речи и активное персонажное присутствие в событии рассказывания, позволяет передать эмоционально-оценочную, личностно заинтересованную точку зрения наблюдателя.

Конфликт старого и нового переносится во внутренний мир героя, в душе которого сталкиваются противоположные стремления: с одной стороны, он стихийно тянется к новой жизни, ему очень хочется пойти на литературный вечер, но с другой стороны, герой не уверен в себе, боится нарушить общепринятые нормы поведения, в его сознании живучи традиционные представления. Борьбу взаимоисключающих начал: разумного и желаемого, мысли и чувства, - писатель воспроизводит с помощью внутреннего монолога. Решение героя «заглянуть ненадолго» на литературный вечер сопровождают переживания, которые передает суммарно-обозначающая форма психологического изображения, типизирующая и обобщающая психологические процессы и переживания. Исследуя психологическую природу власти общепризнанных, освященных законом норм и обычаев над человеком, Ф.Амирхан показывает, что она оказывается сильнее стремления к новому, желания познать неведомое. Психологический анализ, обращенный к отдельно взятой человеческой личности и ориентированный на очень важную и актуальную для того времени общую социально-психологическую проблему, является и средством выявления индивидуального склада души, и способом социальной типизации образов.

В рассказе «Блаженный день» Ф.Амирхан показывает несовместимость естественных человеческих чувств, запросов и потребностей личности с существующими устоями и порядками. Описывается один из немногих счастливых дней в девичьей жизни Гайниджамал: посещение долгожданной весенней ярмарки. Это событие ненадолго разрывает замкнутый круг жизни, подчиняющий человека обыденно-житейскому, бытовому, циклическому времени и изолирующий его от большого мира, обрекающий на пребывание в закрытом

пространстве обыденности. Выделяя значимый с психологической точки зрения момент, писатель ставит вопросы этико-философского характера: о закономерностях судьбы, свободе и выборе, об истинном и ложном в человеческом существовании и др.

Внутреннюю несвободу героини, ее подчинение традициям, стереотипным жизненным программам и ориентирам выявляют детали внешнего вида и поведения. Изобилует выразительными подробностями описание одежды, походки Гайниджамал, ее манеры держаться. Но Гайниджамал, как и Габдельгаллям, не является персонажем только «овнешненным», мотивированным и исчерпывающимся материально-бытовой сферой жизни. Писателя интересует внутренний мир человека, который погружен в поток повседневности бытия: его психологические реакции, внутренний ход мыслей и чувств.

Динамика переходного состояния жизни способствует пробуждению сознания Гайниджамал, что определяет своеобразие повествовательной формы рассказа: значимыми становятся точка зрения героини, ее восприятие и оценка тех или иных явлений. Решающую роль в этом процессе, как показывает писатель, принадлежит эмоциональной сфере, накоплению однородных впечатлений. Так, Гайниджамал невольно загляделась на счастливцев, катающихся в этот теплый ясный день на лодках. Увидев знакомого студента Закира с русской девушкой, она испытала глухую ревность. Автор фиксирует психологический процесс, который сам герой не понимает и не может объяснить: многоточия передают сложное, смутное, противоречивое состояние души, указывают на неясные, неосознаваемые душевные движения, неподдающиеся художественному воспроизведению и анализу пласты внутренней жизни, а также на те чувства, в которых героиня не может признаться даже себе самой.

Ревность с новой силой вспыхивает в душе Гайниджамал, когда она увидела Закира и его спутницу в кондитерской. Предлагаемое писателем психологическое описание не детализирует эмоциональную жизнь героя, а дает ее целостное, синтетическое воспроизведение: щемящую боль сменяет поднявшаяся в сердце Гайниджамал бессильная злоба.

Суммарно-обозначающая форма психологического изображения используется Ф.Амирханом для того, чтобы раскрыть психологию человека, воспитанного в старотатарских патриархальных традициях, но с интересом присматривающегося к новым веяниям, новым отношениям между людьми, психологию, отмеченную некоторыми индивидуальными особенностями и соотнесенную с оппозицией естественного и противоестественного, которая лежит в основе трактовки как персонажей, так и состояния мира.

Состояние покоя, ощущение устойчивости и стабильности постепенно сменяется неясной тревогой, сомнением в прочности сложившегося уклада жизни и отношений. Возникающие в душе героини тоска, непонятный страх и досада отражают стремление к освобождению от старых форм быта и символизируют пробуждение в ней сущностных начал. В чувствах, которые испытывает человек, оказавшийся на грани двух миров (старого и нового), проявляется мера его индивидуального сдвига от стереотипа общей социальной судьбы. Таким образом, Ф.Амирхан вступает в диалог с европейской традицией, обнаруживая «выход» к «предельным основаниям рациональности», характерным для этой культуры.

Литература

Валеев Н.М. В мире нравственных исканий: Исследование / Н.Валеев. – Казань: татарское кн. Изд-во, 1985. – 120 с.

Сайганов А. У истоков эстетики реализма. Эстетика Ф. Амирхана и ее место в развитии татарской реалистической литературы / А. Сайганов. – Казань: Татарское книжное изд-во, 1982. – 168 с.

Смирнов А.В. Номинальность и содержательность: почему некритическое исследование «универсалий культуры» грозит заблуждением // Универсалии восточных культур. - М.: Издательская фирма «Восточная литература» РАН, 2001. - С.290-317.

Әнвәрова М.Х.

Татар телендә “задә” антропонимик берәмлеге

Билгеле булганча, күпчелек төрки халыкларда, шул исәптән татар халкында, төрле-иҗтимагый, икътисадый-мәдәни багланышлар нәтиҗәсендә, аеруча ислам дине йогынтысында гарәп һәм фарсы телләреннән сүзләр кабул ителгән. Алар язма әдәбият белән, дини-рухани тәгълиматларда, кеше исемнәре аша килеп кергәннәр һәм татар теленең лексик системасында гаять бай катлам тәшкил итәләр.

Татар теленең антропонимик системасында сан ягыннан иң зур күпчелекне алып торган гарәп-фарсы чыгышлы кеше исемнәре (КИ), кызганычка каршы, монографик планда махсус аерып алып тикшерелмәгән. Шуңа карамастан, алар татар антропонимиясен тикшерүгә багышланган фәнни хезмәтләрдә, генетик катламнарны арып чыгаруга бәйле, шактый тирәнтен яктыртылган.

Татар теленең аңлатмалы сүзлекләрендә *задә* лексик берәмлеге исем сүз төркеменә кергән фарсы чыгышлы искергән сүз итеп бирелә һәм түбәндәгечә аңлатыла: а) ЗАДӘ *и. иск.* Ир бала, (кемнең дә булса) улы – *Синең кыяфәтең, синең сөйләшүең бер асыл задә икәнлегеңә дәлаләт кыладыр. Ш. Мөхәммәдиев* [6, 1979: 339]; б) **ЗАДӘ** *ис. иск. фар***.** Ир бала, ул, углан ◊ **Хәләл задә** Законлы туган бала. **Хәрәм задә** Законсыз туган бала. [7, 2005: 161]. Соңгы сүзлектә урын алган “Татар халкында кеше исемнәре һәм аларның мәгънәләре турында” дигән кушымтада (төзүчесе Р.Г.Әхмәтьянов) *задә* сүзе хатын-кыз исемнәренә нисбәтле исем компоненты буларак: **Задә** *фар.* “Кызы” мәгънәсендәге исем компоненты: Гөлзадә, Нурзадә [7, 2005: 836], ә ирләр исемнәренә бәйле бары тик постпозитив формант итеп: **-задә** *фар.* “Углы” мәгънәсендәге исем компоненты: Ханзадә, Шәехзадә, Әшрафзадә һ.б. [7, 2005: 842] теркәлгән.

Р. Г. Әхмәтьянов үзенең татар теленең кыскача тарихи этимологик сүзлегендә *задә* сүзен *зат* сүзенә нисбәттә аңлата, һәр ике берәмлекне фарсы чыгышлы итеп күрсәтә: **ЗАТ** «род, потомство» - фарсы. *зад* «зат» сүзеннән, зан «туу, тумыш, нәсел, ул» тамырыннан (һинд-евр.*ghen «туу, нәсел» иск. әд. *задә* «улы яки кызы»: *маликзадә* «малик улы (кызы)», *шаһзадә* «шаһ улы

(кызы)» шулай ук фарсы теленнән һәм *зат* сүзе белән тамырдаш. [8, 2001: 74]

Зәйнуллин Җ.Г. тарафыннан төзелгән “Шәрык алынмалары сүзлегендә” *задә* гарәби чыгышлы сүз: **Задә** *г.* Бала; затлы, зыялы гаиләдә туган бала.[3, 1994:47], ә гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлегендә фарсы чыгышлы исем [2, 1993:123] буларак бирелә. Татар исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлекләрендә [4, 1981: 81; 1998:102; 2006:127] *Задә* фарсы теленә нисбәтле, “угыл; аксөяк малае, патша улы” мәгънәсен белдергән ир-ат исеме буларак теркәлгән һәм күпсанлы кушма нигезле һәм ир-ат, һәм хатын-кыз кыз исемнәре составында табыла.

Югарыда әйтелгәнчә, төрле төрдәге сүзлекләрдә исем сүз төркеменә кергән, фарсы чыгышлы, мөстәкыйль кулланылышка ия сүз буларак урын алуына карамастан, татар теле сүз ясалышы өлкәсендә зур фәнни эшчәнлек күрсәтүче күренекле галим Ф.Ә.Ганиев үзенең кушымчалау ысулы белән сүз ясалышына кагылышлы монографик хезмәтләрендә (1974, 2005) һәм татар грамматикасында *задә* берәмлеген исем ясагыч алынма кушымча итеп тикшерә: **Нигез + -задә** кушымчасы. Бу модель татар телендә сирәк очрый: *шаһзадә, ханзадә*. Бары *ханзадә* сүзе генә татар теле ясалышына керә, чөнки аның ясаучы нигезе татар теленеке. Бу кушымча белән килгән исем атасының титулы белән белдерелгән улны тәгъбир итә.[5, 1998: 285] Дөрес, галим үзенең 1982 нче елда дөнья күргән кушма сүзләр ясалышына багышланган монографик хезмәтендә *ханә, намә*, *стан, тараш* сүзләре белән беррәттән *задә* сүзен матди структурасы ягыннан мөстәкыйль сүз төркеменә кергән сүзгә, ә белдергән мәгънәләре буенча кушымчаларга якын тора торган берәмлекләр итеп билгели һәм аларны, күпмедер дәрәҗәдә кушымча дип түгел, ә “ярымсүз” термины белән атау ягында тора. Ф Ә.Ганиев бу “ярымсүз”ләр катнашында ясалган сүз типларын кушма сүзләргә кертергә һәм аларны кушымчалау юлы белән ясалган сүзләр итеп түгел, ә сүзләрне кушу ысулына бәйле тикшерү фәнни дөреслеккә якынрак булуына басым ясый. Без бу фикерләрне хезмәтнең тулыландырылган икенче басмасына нигезләнеп тәкъдим итәбез [1, 2002: 20]

XX гасырның 90 нчы елларыннан башлап татар кеше исемнәрен тикшерүгә багышланган хезмәтләрнең барысында да диярлек *задә* фарсы чыгышлы кушымча итеп бирелеп килә. Безнең фикеребезчә, татар теленең антропонимик системасында бу берәмлек, аерым ир-ат исеме буларак кулланылышын да исәпкә алсак, һичшиксез кушма төзелешле кеше исемнәре составында антропнимик лексик берәмлек, ягъни антрополексема итеп каралырга тиеш.

Татар исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлегендә [4, Гомәр Саттар-Мулилле, 1998] ~59 (38 ир-ат, 21 хатын-кыз) КИ исеме теркәлгән. Һәрвакыт постпозитив компонент.

Төрки-татар антрополексемар белән 6 КИ ясалган: баланың бәхетле булуын теләп кушылган, уртак кулланылышка ия (һәм ир-ат, һәм хатын-кыз) *Миңлезадә* исеме; баланың матур-чибәр, якты-нурлы йөзле булуын теләп кушылган *Акзадә* дигән ир-ат, *Айзадә, Илзадә* кебек хатын-кыз исемнәре; баланың көчле, батыр-гайрәтле булуын теләп кушылган *Арсланзадә* исеме.

Саф фарсы *Мирзадә* ‘әмир баласы’, *Шаһзадә* ‘шаһ баласы’, *Ширзадә* ‘арысландай бала’ кебек ир-ат һәм *Бибизадә, Гөлзадә, Гөлемзадә*, *Хөршидәзадә>Хөршизадә, Маһизадә, Миһризадә* хатын-кыз КИ исемнәре табыла.

Югарыда билгеләп үткәнчә, *задә* исем компоненты гарәби антрополексамаларга кушылып ~43 КИ ясаган һәм бу антропонимик берәмлекләр, безнең фикеребезчә, татар теленә әзер килеш кабул ителгәннәр һәм аларда да исем кушу мотивларлары баланың затлы, зыялы, галим, батыр, бәхетле, сөекле һ.б. булуын теләү белән бәйле. Уртак кулланылышка ия *Гыйльмезадә, Мәхбүбзадә~ Мәхүбзадә>Хубзадә* ‘сөекле бала’, *Хөснизадә* ‘матур, күркәм бала’, *Хөббизадә* ‘мәхәббәтле бала’, *Хәбибзадә* ‘сөекле бала’, *Хәйрезадә* ‘хәерле, игелекле бала’, *Фәрхезадә* ‘шатлык, бәхет китерүче бала’, *Шәмсезадә* ‘кояштай чибәр бала’ кебек күркәм исемнәр бар. Бары тик кыз балаларга кушыла торган *Өммезадә* ‘кыз бала анасы’, *Нурзадә* исемнәре билгеле. Ир-ат исеме буларак теркәлгән КИ зур күпчелеге ир баланың дәрәҗәле, затлы-зыялы, батыр, асыл, мәрхәмәтле һ.б. шундый ир-егетләргә хас күркәм сыйфатларга ия булып үсүен теләп кушылганнар: *Исламзадә, Асылзадә Солтанзадә, Хакимзадә, Гализадә, Рәхимзадә*, *Лотфыйзадә* “шәфкатьле бала”,

Мәгъруфзадә ‘атаклы, шөһрәтле бала’, *Сәетзадә* ‘Мөхәммәт пәйгамбәр нәселеннән килгән бала’, *Сәлимзадә* ‘исән-сау бала’, *Сәхипзадә* ‘дус, сердәш яки хуҗа, әфәнде бала’, *Рахманзадә* ‘рәхимле, шәфкатьле бала’ һ.б.

Әдәбият

1. Ганиев Ф.А. Образование сложных слов в татарском языке / Ф.А.Ганиев. – Казань: «Печатный двор», 2002. - 192 с.
2. Мәхмүтов М.И. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге Т.1. / М.И.Мәхмүтов, К.З.Хәмзин, Г.Ш.Сәйфуллин. – Казан: “Иман” нәшр., 1993. – 448 б.
3. Зәйнуллин Җ. Г. Шәрык алынмалары сүзлеге / Җ.Г.Зәйнуллин. – Казан: Мәгариф, 1994. – 143 б.
4. Саттаров Г.Ф. Татар исемнәре сүзлеге / Г.Ф.Саттаров. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1981. – 256 б.; Гомәр Саттар-Мулилле. Татар исемнәре ни сөйли? / Г.Ф.Саттаров. – Казан: “Раннур” нәшр., 1998. – 285 б.; Гомәр Саттар-Мулилле. Исемең матур, кемнәр куйган? / Г.Ф.Саттаров. – Казан: “Академия познания”, 2006- 544 б.
5. Татар грамматикасы Т. 1. – М.: “Инсан”, Казан: “Фикер”, 1998. – 512 б.
6. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. Т. 1. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1979. – 725 б.
7. Татар телененең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: “Матбугат йорты” нәшр., 2005. – 848 б.
8. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге / Р.Г.Әхмәтьянов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2001. – 272 б.

Әхмәдуллин А.Г.

Бүгенге татар драматургиясендә яңалык сулышы

Татар драматургиясенең асыл үсеш юлы – реализмда. Вакыт-вакыт драматурглар шартлы алымнарга, әкият чараларына, аллегорик һәм романтик, мифик һәм метафорик образларга мөрәҗәгать итеп, реалистик сурәтләүне баеталар. Ләкин боларның һәммәсе өстендә, иң беренче, «тормышчан

булсын», «тормыш дөреслегенеә хыянәт итмәсен» дигән материалистик таләп хакимлек итте.

Узган гасырның «хрущёв җепшеклеге», соңрак «торгынлык чоры» дип аталган елларында драматургия сүз-сурәтләү алымнарын тизлек белән баета башлады. Иң беренче, бу процесс 1960-70 нче елларда иҗатка килгән буын белән бәйле иде. Сәхнәгә шартлы метафорика торган саен күбрәк чыкты. Татар сәхнә әдәбиятының уңышларын чагылдырган «Үлемнең үлеме», «Әлдермештән Әлмәндәр», «Ай булмаса, йолдыз бар», «Моңлы бер җыр» кебек шартлы-фәлсәфи әсәрләр барлыкка килде. Мондый әсәрләрне классик булмаган, традицион сәнгатьне киңәйтергә-баетырга омтылыш юнәлешендәге постмодернизмның беренче карлыгычлары дип тә кабул итәргә мөмкин.

Шулай да болар – реалистик иҗат методы кысаларында ирешелгән уңышлар иде. Үзгәртеп корулар чорында да драматурглар зур күпчелектә шул сызыкны дәвам иттеләр, дөньяның галимнәр «беренчел художестволы моделе» дип атаган картинасын тудыру юлында тордылар һәм торалар.

Шуның белән бергә сәхнәдә тормышны чагылдыру-сурәтләүнең башка төрле – әдәбият һәм театр белемнәрендә «икенчел художестволы моделе» дип аталган – формасына мөрәҗәгать итү дә урын ала һәм жанлана барды. Аның иң ачык мисалы – Г.Камал театрында уңыш белән бара торган «Кара чикмән» исемле спектакль. Моңар драматургия дә йөз белән борылды. Монда күбрәк иҗатчыларның яшьрәк буыны алда. Сәхнә әдәбиятыбызда гайре табигый характерлы геройлар, һәртөрле мифик, экияти һәм төштә генә күрүе мөмкин булган персонажлар – җен-пәриләр, шүрәлеләр, су иярләре, албастылар, өрәкләр, бичуралар, кеше ашаучылар, персонаштырылган Җир, Ай, йолдызлар, роботлар һ.б. төрле образлар күбәйде. Кешеләр уйланма ситуацияләрдә, чынлыктан ерак булган хәлләр эчендә хәрәкәт итәләр. Җәртөрле җанлы һәм җансыз табигать вәкилләре һәм күренешләр үзара мөнәсәбәткә керәләр. Мондый әсәрләрдә барысы да бер хис яки фикергә хезмәт итәләр, эчке кичерешләр, психологик халәтләр юк дәрәҗәсендә.

Мондый характердагы драматургиянең беренче тәҗрибәләрен Айдар Хәлим әсәрләрендә күрәбез. 1981 нче елда

язучы «Җанчишмә» исемле, үзе жанрын «хикәят» дип билгеләгән пьесасын яза һәм ул «1983-1984 ел сезонында Мәҗит Гафури исемендәге Башкорт дәүләт Академия драма театры сәхнәсендә зур уңыш белән барды, әмма «антисовет, партиягә каршы тенденциозлыкта» гаепләнеп, каты тәнкыйтькә дучар булды, сәхнәдән алып ташланды» (Хәлим, Айдар. Пьесалар. – Казан, 2004. – 6 нчы бит). Пьесада персонажлаштырылган Чишмә, халыкның битарафлыгын, ваемсыз яшәү, ягъни торгынлык чорын гәүдәләндергән Йоклаган кеше, үз туган җире өчен үзен җаваплы булуын соңарып аңлаган Сагындык образлары ярдәмендә кешелекнең яшәеше өчен табигатьнең никадәр кирәклеге, экологик чисталык өчен һәркемнең җаваплылыгы мәсьәләсе куела. Табигатькә саксыз карау, алай гына да түгел, табигать кануннарына каршы бару, табигатьне «матурлауга, төзәтергә» омтылыш нинди аяныч нәтиҗәләргә китерергә мөмкинлеге хакнида Айдар Хәлим сәхнәдән беренчеләрдән булып чаң сукты. «Кешенең беренчел Анасы – табигать, - дип яза ул. – Милләт-Табигать Табигатьне көчләү, хәтта Аллаһудан килгән тере табигатьне дә ихтыярсыз итеп, аның тере заты булган Адәм баласын – кеше шәхесен ихтыярсыз итеп, робот ясау, аны йоклату, рухи үтерү – җинаять. Кешедә табигатькә карата кешелеклелекне бетерсәк, кеше үзеннән-үзе үләчәк» (шунда ук, 174 бит).

Кешелеккә хас булган аерым сыйфатларны, җәмгыять тормышындагы аерым күренешләрне, процессларны үзендә туплаган абстрак һәм метафорик образларны Айдар Хәлим икенче пьесасында – абсурд театрының яраткан жанры булган трагифарста тагын бер тапкыр сәхнәгә күтәрә. Дөрес, «Кияү урлау» әсәрен автор үзе «фантастик трагикомедия» дип атый. Ләкин үзенең бөтен компонентлары, фитуацияләренең оештырылуы белән бу – трагифарс, гротексттан иркен файдаланган, аллегорик образлардан, фарс элементларыннан оештырылган, авангардизмның бер гәүдәләнеше булган пьеса.

Әсәр 1985 нче елны язылып, «1989-90 нчы еллар сезонында Мәҗит Гафури исемендәге Башкорт Академия драма театрында сәхнәләштерелде һәм сигез тамашадан соң туктатылды» югарыды искә алынган китаптан, 86 нчы бит). Бу пьесасында да

автор кешелек өчен мөһим проблеманы күтәрә. Ул моның асылын үзе болай аңлата:

«Унтугызынчы гасырның азагы – егерменче гасырның башында дөньяның сионизм, троцкизм кебек агымнарында җим тапкан экстремистик, бигрәк тә фенимистик оешмалар «хатын-кызга ир-ат белән тигезлек» дигән шигарь уйлап табып, җирдәге тормыш тотрыклылыгын какшатырга тотындылар. (...) Мин хатын-кызның лидерлык теориясен алга сөргән масоннар һәм, «җенси тигезлек» өчен көрәшкән булып, җиңел генә шуларның тозагына төшкән, бик тә беркатлы рәвештә аларның апологетына әверелгән «тигезлек» көрәшчеләре – коммунистларның хатын-кызның эмоциональ акылы-фигыле аша барлык Җир Шарын кулга төшерү теориясен өйрәндем. Хатын-кызның аңлы рәвештә ир-атка каршы җибәрелгән экспансиясенең татар язмышындагы урыны мине коточкыч уйларга салды. Минем икенче пьесам нәкъ шушы темага багышланырга тиеш иде» (шунда ук, 175 бит).

...Фантастик киләчәк дөньясындагы ситуация «кызтәкәләр» Зилә, Дилә һәм Виләнең Карфаген (соңыннан Камил) исемле егетне үз коллары итү өчен урлап алып кайтулары белән башлана. Бу кызлар «стериль мөнәсәбәтләрдән» торган җәмгыять төзүне максат иткәннәр. Декларацияләре: «...Без, татар хатын-кызларының социаль азатлыгы өчен көрәшчеләр, мең ел буе хокуксыз яшәгән әбиләребезнең үчен кайтарабыз. Хәзер без ирләрне үзебез сайлыйбыз. Долой ирләр изүен! Долой никах! Долой – бала бишеге! Хатын-кызны аналык хорәфәтеннән азат итү – безнең төп бурыч! Тоталь конфронтация! Конфронтация! Конфронтация!»

фәлсәфә фәннәре докторы Рамазан Галиевич, качып йөрүче юрист Сервилад, кызтәкәләрнең атасы – игенче нәби, аның хатыны Зәкия, Камилнең әнисе Даимә, бүлмә роботы Айзек катнашындагы вакыйгаларда бк декларациянең нигезсезлеге фаш ителеп, персонажлаштырылган-шәхсиләштерелгән Мәхәббәт хисе җиңә. Үз дигәннәрен булдыра алмау үченнән җир шарын шартлатып юк итәргә уйлаган Зиләләрнең кара ниятеннән аңарчы аларга карусыз хезмәт иткән, инде Мәхәббәт ярдәмендә кешегә әйләнгән Айзек коткарып кала. Ә кызтәкәләр корган йорт, шуның белән алар хыялланган яшәү рәвеше шартлап юкка чыга. Кызлар

үзләренең мондый юлга кереп китүләренә әниләре Зәкияне дә гаеплиләр:

«Зәкия (артларыннан барып). Балаларым! Балаларым!..

Виләә (борылып). Бала чагыбызда бер тапкыр да әкият сөйләмәдең!

Диләә. Бер тапкыр да җыр җырламадың!

Зилә. Бер тапкыр китап укымадың!..»

Кешелекнең алга барышында мөһим роль уйнаган, кызганычка каршы, хәзер әһәмиятләрен җуя, төссезләнә баручы фикерләрне алга сөргән трагифарс милли драматургия тарихында бу жанр формасында беренчеләрдән булды.

Соңгы еллар татар драматургиясе фарсның башка формаларына да мөрәҗәгать итте. Шуларның күренеклеләреннән берсе – Зөлфәт Хәкимнең «Җен бутады» исемле трагикомик фарсы (1991). Монда да, Айдар Хәлим әсәрендәге кебек үк иркен булмаса да, абсурд театрының төп алымы булган гротесктан файдаланыла.

Трагикомик фарста мифик образ Җенне автор традицион кабул итеп өйрәнелгән явыз итеп сурәтләми. Ул асылда мәрхәмәтле, үзе белән аралашкан адәми затларга ярдәм итә башлый. Шул яктан бу – яңамифик образ. Әнә ул, хатыны хыянәт итеп үзенә тамчы да ошамаган малай алып кайткан, дип аңардан аерылган, шул чит кеше малае өчен алимент түләүдән качып йөрергә ниятләгән сәлмәнне, аның бик нык ялваруларын тыңлап, Ай ярдәмендә башка планетага күчерергә ярдәм итә. Алиментщик анда кеше ашаучы аборигеннар кулына эләгә. Бәхетенә монда тагын ике татар бар икән. Җирдә вакытта партия обкомы вәкилен кыйнаган өчен төрмәгә утыртачакларын белеп, качып йөрүче Камил аны кеше ашаучылар кулыннан коткара. Һәм алар шундый ук качкын жулик Гали белән берләшеп, үзләренә «җәмгыять» төзеп, яши башлыйлар. Ләкин җирдәге яшәү законнарын үтәүдән качкан бу затлар законсыз-кагыйдәсез яшәештә үзара ызгышып-талашып бетәләр, мондый тормыштан тиз туялар. Инде Җен тагын бер кат аларның зар-үтенечләрен тыңлый, Айдан үтенеп, аларның җиргә кайтуларына булыша.

Гомумән, сюжет төзелешен оештыруда да, авторның төп фикер-идеясен уздыруда да әсәрдә мөһим рольне Җен образы уйный. Дөрес, сюжетны Сәлмәннең алимент түләүдән качып

йөрүе, чит планетага эләгүе, андагы маҗаралары, кире җиргә кайтуы, соңыннан акылга утырып Саимәсе һәм улы Рәшит белән кушылуы вакыйгалары тотып тора. Ләкин әсәрне фикерен укучы һәм тамашачыга җиткерүдә төп йөк нәкъ менә Җен-Хатыйп образына салынган. Инде 2084 яшь яшәгән, башта кешеләргә күп зыян күрсәткән Җен хәзер яхшы күңелле җан иясенә әйләнеп бара. Дөрес, бүген дә ул әле кайберәүләрне җәфалый: алкашларны «белая горячка» вакытында саташтыру – аның төп гамәле. Шулай да, Сәлмән белән очрашкач, ул күзгә күренеп үзгәрә. Аның бу метаморфоза кичерүендә, иң әүвәл, фәнни-техник революция чорына килеп кергән җәмгыять һәм торган саен бозыла баручы кешеләр гаепле. Җеннәр яши торган күлне заводтан чыккан шакшы отход белән агулыйлар. «Хәзер бит заманалар шулкадәрле үзгәрде ки, хәтта без, җеннәр, үзебез кешеләрдән курка башладык, - дип сөйли ул. – Бик күпләребез авырыйлар хәзер. Шул химия тәэсиредер инде – без, Җеннәр, соңгы вакытта бик юашландык».

Узган гасырның 90 нчы елларындагы илдәге вәзгыятькә, кешелекнең инкыйразга баруын да автор Җен авызыннан әйттерә. Шулай да, аның фикеренчә заманның бозылуында, иң беренче, кешеләр үзләре гаепле: «... кешеләр бөтен әшәкелекләрне үзләре үйлап чыгарган яман көчләрдән күрә. Кеше һаман гаепне үз өстенә алмый. Кеше һаман гөнаһлары өчен җавап бирүдән качмакчы була». Мисалга ул Сәлмәннәрнең чит планетадагы тормышын китерә. Барысы да үз кулыгызда иде бит, ди ул, ник кешеләрчә яши алмадыгыз?! Һәм нәтиҗә ясый: кешеләрчә яшәү өчен җәмгыять булып оешу кирәк, аларны үти белергә кирәк. Ә боларның барысы өчен дә үзең чын кеше булырга кирәк! «Һәркем үзендә эзләргә тиеш начарлыкны да, яхшылыкны да. Оеткы аның үзендә». Һәм трагикомик фарстагы вакыйгалар үзләре алдыннан Җеннең, аларны чын кешеләр итәргә ниятләгән, ләкин бернигә карамыйча үзен һәлак итәргә алынган кыргыйларга соңгы сүзләре белән тәмамлана: «Нишлисез сез, кешеләр?!»

Әгәр дә бу әсәрдә мифик көч кешеләргә ярдәм итүне максат иткән булса, авторның 1999 нчы елда язылган «Шайтан куентыгы» исемле фаҗигасендә инде мондый персонажлар җәмгыятьнең караңгы, бозык якларын гәүдәләндерәләр һәм кешеләрне шул юлга сөйриләр.

Балачактан бергә уйнап үскән, бер-берсенә гашыйк булып, гомергә бергә булырга антлар бирешкән фәнзилә белән Разимнең мәхәббәте фаҗига белән тәмамлана. Моңа гаеплеләр – ир кыяфәтендәге Илгиз исемле шайтан һәм кызлар кыяфәтендәге шайтан Илгизә. Ә баш сәбәп – саксыз рәвештә әйтелгән «шайтан алсын!» дигән сүзләр. Аларны беренче тапкыр сөеклесенең шәһәргә укырга киткән җиреннән беркадәр үзгәреп кайтуына эче пошкан Разим, бер-берсенә үпкәләшкән вакытта, ачуланып әйтә. Шуның белән кызны бүгенге яшәешнең яман якларын, байлыкка алданып бозыклыкка бирелү гадәтләрен гәүдәләндергән Илгиз шайтан кочагына ташлый. Икенче вакытта кызының алмашынып китеп авыруга сабышуын күрше егетеннән күргән Мәдинә шул ук сүзләрне Разимга әйтә. Эффект шул ук. Егет беренче мәхәббәтен шайтан кызы Илгизәгә, аңар ияреп бозык тормыш коруга алыштыра, эчкечелек юлына баса.

Шулай да беркадәр вакытларга рәхәтлек бирсә дә, гел күңел ачуга корылган бозык шартлар яшьләрнең изге хисләрен бөтенләй дә җиңә алмый. Алар бер-берсенә тартылудан туктамыйлар. Ләкин шайтани тормыш бик көчле, ул ахыр чиктә ике яшьнең шайтан куентыгында яр убылып төшеп батып үлүләре белән очланган фаҗигагә алып килә. Ә бит бу култыкта яшьләрнең эчкече әтиләре белән дә баткан булган. Димәк, соң чиктә җәмгыятьнең баткаклыгына алып баручы көчләр җиңә булып чыга. Эчкечелек һәм бер-береңә начарлык теләүдән торган көчләр.

Тормышны сәнгатьле чагылдыруның яңадан-яңа формаларын эзләү (бүгенге әдәбият галимнәре тарафыннан бу күренешне я «соңарган модернизм», яки «постмодернизм», яисә «магик реализм» дип атаулар да бар) дәвам итә. Моны без югарыда карап үтелгәннәрдән тыш Туфан Миңнуллинның «Шүрәле-җанкисәгем», «Кулъяулык», «Җен алыштырган», Фәүзия Бәйрәмованың «Аллалар ялгышы», «Вакыйга җүләрләр йортында бара», илдар Юзиевнең «Ахырзамангашыйклары», Рабит Батулланың «Мин Америка ачтым», «Ана каргышы» кебек пьсалар мисалында да күрә алабыз.

Мондый әсәрләр иҗат итүдә соңгы елларда яңа буын драматурглардан Мансур Гыйләҗев уңышларга иреште.

Аның 1989 нчы елда язылып, Г.Камал исемендәге академия театры сәхнәсендә уңыш белән барган «Бичура» исемле, автор үзе жанрын «гыйбрәтле хәлләр» дип кенә билгеләгән пьесасы фикер тирәнлеге, оригинальлеге ягыннан игътибарга лаек. Әсәрдә реалистик һәм мифик образларны аралаштыру ярдәмендә бүгенге яшәештә урын алган проблемалар яктыртыла. Ул да булса – татар авылларының бетә баруы, татар традицияләренең саегуы, онытылуы. Соңгы еллардагы күп кенә татар пьесаларында үзәккә куелган бу проблеманы М.Гыйләҗев художестволылыкның яңа яссылыгында яктыръа.

Проблема реаль шәхес, авыл карты Аксак белән халыкның уй-ышанычында урын алган йорт иясе Бичура арасындагы мөнәсәбәтләр, аларның язмышы ярдәмендә чагылдырыла.

«Пьесадагы хәрәкәтне тәшкил итүче конфликт ике катламда бара, - дип яза тәнкыйтьче Әлфәт Закирҗанов. – Берсе – Аксак күңелендәге Ак һәм Кара як, ягъни Бичура һәм Шәүләләр эшгамәленә барып тоташучы каршылык, ул Бичура дөньясы белән бәйле. Икенчесе исә реаль тормышта Аксак белән әйләнәтирәдәгеләр арасында. Соңгысына бәйле эчкечелекнең артуы, кеше күңеленең катылануы, авылларның бетеү, өлкән буын белән яшь буынның үзара аңлаша алмавы өчен дә тирәнтен борчыла автор» (Закирҗанов, Әлфәт. Заман белән бергә: әдәбитәнкыйть мәкаләләре. –Казан: ТКН, 2004. – 61 нче бит).

Конфликт кара җаннарның җиңүе белән тәмамлана. Аксакның йорты – яшәүне гәүдәләндерүче символик образ. Киләчәккә ышанычны тотып торган Бичура аны ташлап киткәч, ул тәмам таркала, җимерелә. Шунысы да мәгънәле: әлбәттә, аны җимерүдә Шәүләләр – төп көч. Шулай булса да, кайсыдыр моментта бу кара эштә аларга ярдәмгә бүгенге кимчелекле җәмгыятьнең үзенчәлекле вәкилләре булган Киленнәр дә, бу авылга читтән килеп урнашкан, Аксак карт сүзләре белән әйткәндә, авыл өчен «ят кеше» Күрше дә ярдәм итәләр, Шәүләләргә кара эшләрен тәмамлап куярга җирлек хәзерлиләр. Дөрес, аңарчы Аксакның бичура турындагы сүзләренә ышанмаган Күрше соңгы күренештә аны үзе күрүе, бичураның үз чормаларында яшәве турында сөйли, шуның белән традицияләрнең, авылның яшәячәге турында беркадәр оптимистик чаткы тудыра. Ләкин инде моңа Аксак түгел, укучы-

тамашачы да ышанмый... Сүз уңаеннан шунысын әйтергә кирәк. Соңгы елларда пьесаларның жанрын билгеләгәндә авторлар артык иркен эш йөртәләр. Жанр формаларын атауның уңышлы булганнары бар (әйтик, «моңсу комедия», «риваять», кайбер очракларда - «тамаша» һ.б.). Ләкин бу очракта пьесаның билгеләмәсе уңышлы дип әйтеп булмый: «гыйбрәтле хәлләр»... Нәрсәсе гыйбрәтле? Кем өчен гыйбрәтле? Шулай булса, ул хәлләрдән кемдер, ниндидер гыйбрәт алырга тиеш бит инде. Булган хәлләр Аксак карт өчен гыйбрәтлеме, аның хатыны өченме? Аларны Киленнәр өчен гыйбрәтле дип әйтеп булмый. Тамашачы да мондый хәлләрдән гыйбрәт алмый. Әсәр эчтәлегенең гомуми мәгънәсеннән чыгып аны фаҗигагә тартым «драма» дип билгеләү дөресрәк булыр.

Авторның «Баскетболчы» (2002) исемендәге пьесасы аның «икенчел художестволы модель» тудыру юнәлешендә эзләнүләрен киметмичә алып баруын күрсәтә өәм бу юлдагы нәүбәттәге уңышы булып тора.

Әгәр дә алдагы әсәрдә мифик-метафорик образлылык, шартлы-ясалмалылык һәм символика сәнгати эшләнешнең нигезендә ятса, бу комедиядә яңа модернистик шартлылык соң чиккә җиткерелгән. Алда искә алынган китабында Әлфәт Закирҗанов аны «абсурдлык элементлары белән баетылган пьеса» дип атый, режиссёр Марсель Сәлимҗанов аны сәхнәгә куеп, «абсурдлык театры»на нигез сала, ди (шунда ук, 100 нче бит). Моның белән килешәсе килми. Авылның кичәге укытучысы Сократның баскетболчы булырга, команда оештырып, төрле ярышларда җиңеп чыгарга хыяллануын гипербола, хәтта гротекск дип, авылдагы соры, кызыксыз, рухи ярлылыкка алып бара торган тормышка контракст метафора дип карарга мөмкин, ләкин тулы мәгънәсендә абсурд дип әйтеп булмас. Һава шарының сазлыкка барып төшүен, ягъни бу тормыштан котылырга теләүне фантастика, ягъни хыялга ашмас ниятне юкка чыгаруда бер сәнгати чара, ә сазлыкны бүгенге җәмгыять шартларының символы дип, гәзиттәге игълан буенча өйләнергә килгән ике «кияү»нең маҗараларын комедия жанрына хас булган арттыру дип, кайберләрен модернистик элементлар дип карарга була.

Кыскасы, бүгенге татар драматургиясе, рус һәм башка халыклар драматургияләре кебек үк, әдәбиятлардагы

постмодернизм чорының үзенчәлекләрен үзләштерү юлына басты. Билгеле инде, ул моны сәнгати яңалыкларга ирешү өчен генә түгел, ә яшәешнең-тормышның өлгергән мәсьәләләрен, гомумкешелек проблемаларын тәэсирлерәк, кызыклырак итеп сәхнәгә чыгару максатында эшли. Татар драматурглары театр сәнгатендә мондый юнәлешнең инде кызыклы гына нәтиҗәләргә килүенә мөмкинлек бирә торган әсәрләр иҗат иттеләр.

Батталова А.Д.

Т.Миңнуллинның “Без бит авыл малае” комедиясендә йорт образы

1960—70 елларда тулаем әдәбиятта авыл темасының алгы планга чыгуы, авылга милли көнитеш, яшәү рәвеше саклана торган урын буларак карау драматургиядә материалында да күзәтелә. Шартлы рәвештә «авыл реализмы» дигән агым әдәбиятка күп кенә үзенчәлекле проблемалар, алымнар, яңа геройлар алып килә. Моны без Т.Миңнуллинның «Без бит авыл малае» комедиясе, шулай ук йорт образының әсәрнең идея-проблемасы белән гаять тыгыз керешкән әсәрләреннән берсе мисалында күзәтә алабыз. Әлеге әсәр йорт—авыл—туган җир чылбырына бәйле җәмгыятьтәге актуаль, халык һәм милләт киләчәгенә куркыныч яный торган проблемаларны көн тәртибенә куюы белән дә кыйммәтле. Һәм әлеге проблемалар йорт образы ярдәмендә формалаша.

Пьеса үзәгендә — бер йортлы, бер урамлы авыл язмышы: «*Бер урамлы Алпамыш авылының бер өйле урамында яшәүче Иштугановларның капка төбе. Төрле төстәге буяулар белән сырлап буялган капка. Коймасы да капкасына тиң. Өйнең бизәкле тәрәзәсе күренеп тора. Коймага терәп бүрәнәләр өелгән»* [Миңнуллин Т., 1985, -б.143]. Алпамыш авылындагы ялгыз өйне автор бик җентекләп, нечкә штрихлар, вак детальләр ярдәмендә тасвир итә. Ул төрле матур төсләргә буялган, якты. Йорт үзе генә түгел, аның тәрәзәсе, коймасы, капкасы да аллы-гөлле. Болар барысы да, өйнең ялгызлыгына карамастан, оптимистик мөнәсәбәт уята. Автор аның вәкилләре белән дә таныштыра бара. Һәр герой бер урамлы Алпамыш авылының бер өйле урамында яшәүче буларак

характерлана: «*Концертыбызның чираттагы номеры — шигырь. Бер урамлы Алпамыш авылының бер өйле урамында яшәүче Ирбатыр Иштуганов үзе чыгарган шигырен укый. Хорда катнашалар: бер урамлы Алпамыш авылының бер өйле урамында яшәүчеләр — Шамилә Иштуганова, Иртуган Иштуганов, Ирбатыр Иштуганов. Башлап җырлый... Башлап җырлый бер урамлы Алпамыш авылының бер өйле урамында яшәүче атказанган артистка Илсөяр Иштуганова». «Тальян гармунда — бер урамлы Алпамыш авылының бер өйле урамында яшәүче атказанган гармунчы Иршат Иштуганов»* [Миңнуллин Т., 1985, - б.145-146].

Иштугановлар йорты авылда бердәнбер. Бу яктан караганда, ул ялгыз, ләкин шул ук вакытта аның эче гөрләп тора. Бу йортта үзләренең авылларын өзелеп яратучы Иштугановлар гаиләсе яши. Йортның тышкы як кыяфәте дә хуҗаларын хәтерләтә, аннан чиксез рух күтәренкелеге бөрки.

Авылга башка кешеләр күчеп килми, бүтән йортлар юк. Димәк, авыл шушы йорт йөзендә чагыла. Иштугановлар йорты — Алпамыш авылы үзе ул. Бу йорт-авылга, хәтта, туган-тумача да сирәк аяк баса: «*Айтуган. Нәрсә, монда гына сөйләшәбезме, өйгә керәбезме?*

Иртуган. Әллә туган йортыңа да керми китәр идеңме?

Айтуган. Ярый алайса. Җиңги, чәй куя тор әле».

«Иртуган. Бик ашыгычмыни? Ашыкма, болай да елга бер генә күренеп китәсең безнең авылда. Син бит авыл Советы председателе, безнең хәлне белешеп торырга тиеш. Авылда менә клуб юк. Урамда концерт куябыз. Театр, концерт килми безгә, үзебезнең күңелне үзебез ачабыз.

Наилә. Кыртапага барып карагыз,

Иртуган. Кыртапа ерак бит».

«Иртуган. Сөйләп кайтмадым, иптәш председатель, әйтеп-кисәтеп кайттым. Малайны, ягъни мәсәлән, Ирбатыр Иртуганович Иштугановны Кыртапа авылы мәктәбенә бүтән аяк бастырмыйбыз, үзебезнең авылда укыячак, дидек» [Миңнуллин Т., 1985, - б.147-148].

Әсәрдә Алпамыш авылындагы бер йорт язмышы йөзендә авылларның яшәеше, киләчәге проблемасы күтәрелә. Әйтерсең лә драматург бай рухи тормыш белән яшәүче Алпамышны авылларны юк итүгә китергән җәмгыятькә каршы куя. Авыл прозасының да төп

үзенчәлекләреннән берсе итеп «әхлакый дефицит» проблемасын чишү юлларын эзләү күрсәтелә [Лейдерман Н.Л., Липовецкий М.Н., 2001, - с.54]. Әлеге әсәрдә бер йортлы өй илдә югала барган әхлакый дефицитны саклап яшәүче урын булуы белән әһәмиятле.

Үзләрендә татар халкының матур гореф-гадәтләрен, милләтнең асыл сыйфатларын саклаган авыллар язмышында җәмгыятьтәге хәл ителергә тиешле шактый җитди сорау-мәсьәләләр бар:

«Наилә. Күпме әйтергә була сезгә, сезнең авылыгыз юк.

Шамилә. Ничек юк? Ә без?

Айтуган. Бер йортлы авыл булмый.

Иртуган. Мин сиңа йөз дә туксан тугызынчы тапкыр әйтәм, энекәш. Син нәрсә, башыңа тәкәрлек типкән нәрсә. Бар безнең авыл. Бар Алпамыш авылы. Аның бабайлар салган нигезе бар, бабайлар кушкан исеме бар, әллә ничә мең кеше ята торган зираты бар. Кемнәрдер качып киткәнгә без гаепле түгел» [Миңнуллин Т., 1985, - б.148]. Шул рәвешчә, Алпамыш авылының, шул исәптән Иштугановлар йортының да бай тарихын бер генә гаилә вәкиле дә онытырга теләми. Ул моңа кадәр авылдагы соңгы йорт булса, моннан соң беренче йорт булачак һәм авылның яңа тарихи сәхифәләрен башлап җибәрәчәк, дигән фикергә йорт хуҗалары чиксез ышаналар: «*Иртуган. Шулай булгач авылның таралуы турында сөйләнмик, яңарту турында сөйләшик. Бәйләнделәр шул Кыртапага күчмәгән өчен. Ни өчен күчик без? Без бит бу урынга килмешәк булып килеп утырмаган. Бу минем һәм Шамиләнең туган авылы. Кирәкми миңа Кыртапагыз. Кыртапада кыртапа кешеләре яшәсен. Ул аларның туган авылы. Бүген бер йорт, киләсе елга ике йорт булачак, Иршатны өйләндерәбез дә башка чыгарабыз»* [Миңнуллин Т., 1985, - б.149]. Ләкин зиратына ничә мең кеше күмелгән авылдан халыкның китеп бетү факты үзе үк драматург һәм укучы–тамашачының шиген үстерә. Шушы яссылыкта әсәр шартлы кабул ителә башлый. Ул авыл прозасындагы авылларны әхлак кагыйдәләрен саклап, табигать белән гармониядә һәм рухи бай тормыш итүче урын кебек шәрехләгән «авыл Атлантидасы» хакындагы миф кебек [Лейдерман Н.Л., Липовецкий М.Н., 2001, - с.54], бер яктан, туган җир төшенчәсен гомумкешелек кыйммәте дәрәҗәсендә расласа, икенче яктан, җәмгыятьнең бу идиллик

микродөньяны, «кече ватанны» җимерүен «күрмәү», аңа күз йомарга теләү булып тоела.

Дөрес, геройлар Алпамышның ни өчен бер генә йортлы булып калуы хакында уйланалар: «*Шамилә. Мәктәпкә җибәрмибез, дип әйтмәдек. Кыртапа мәктәбенә җибәрмибез, дидек. Үзебезнең авыл мәктәбендә укыр, дидек.*

Наилә. Сезнең авылда мәктәп юк.

Иртуган. Ачыгыз.

Наилә. Бер бала өчен кем сезгә мәктәп ачсын!

Иртуган. Унбиш бала барында нигә яптыгыз? Ябуыгыз булды, авылдан кеше дә китеп бетте.

Наилә. Үткәннәрне казып чыгарма. Шулай кирәк булган.

Иртуган, Кирәк булмаган шул менә, Наилә абыстай. Кирәк булмаганны хәзер әйтәләр. Авылны бетерәм дисәң, син аның мәктәбен яп» [Миңнуллин Т., 1985, - б.149]. Димәк, иң беренче чиратта, йортлар булсын, авыл яшәсен өчен тәрбия, мәгърифәт учагы булган мәктәп кирәк. Ул — йортны нык иткән һәм яшәткән көчле факторларның берсе. Автор әсәрдә авыл яшәсен өчен йортларның ялгыз түгел, ә ишле булуы кирәк, йортлар булсын өчен туган нигезен яратучы кешеләр, мәдәният, мәгърифәт кирәк, дигән нәтиҗәгә килә. Әсәрдә җәмгыятьне, кешеләрнең карашларын үзгәртү мөмкинлеге дә күңел күзе булганнарны авылда калдыруда дигән, заманы өчен бик популяр утопик фикер белдерелә: «*Иртуган. Күңелсездер. Барыр урын юк. Яшьләргә шау-шу кирәк. Аптырама, утыз елдан безнең авыл да гөрләп торыр әле. Аның каравы безнең авылның үз гармунчысы бар. Гармунчысы булган авыл — авыл инде ул. Менә сине дә баяннарда, пианиноларда уйнарга өйрәтергә иде. Көең бар синең, моңлы бала син, улым. Консерваторияләрдә укып чыксаң, композитор булыр идең син. Ачуланма инде миңа. Авылга да бит моңлы кешеләр кирәк. Моңсыз кешене җир яратмый. Икмәк булса, җыр була, диләр...»* [Миңнуллин Т., 1985, - б.154].

Гаилә башлыгы Иртуган балаларында авылны, ата-баба нигезен саклап калучы зур көч барлыгына (*«җыр булмаса, икмәк тә булмый. Күңелендә җыр йөртмәгән кеше иген игә белми»)* ышана, шуңа өмет итә. Алпамыш авылының бетеп баруы шаһиты булган ир-егетнең аның тернәкләнеп китүен дә күрәсе килә, чөнки, аның фикеренчә, кайчандыр гөрләп-шаулап торган авылның моңа тулы хакы бар:

«*Уйна. Дөнья яңгырасын. Без — Алпамыш авылы егетләре. Яле, сиптер әле бию көен. Кычкыртып уйна. Менә шулай була ул. Белмисең син, улым, безнең авыл егетләрен. Сугышка хәтле сабан туйларында безнең авыл егетләре бил бирмәгән. Ике йөз илле хуҗалык булган безнең авылда. Без үзебез дә кимен куймый идек. Өйләр селкенеп кала иде без урамнан җырлап үткәндә. Таралыштык, таралыштык. Зыян юк, җыйналырбыз. Синең йортны менә монда салабыз, янәшәңдә энекәшләрең булыр...*» [Миңнуллин Т., 1985, - б. 155].

Әсәр барышында Иштугановлар йорты үзенә генә хас чалымнарын да ала. Элек-электән бу йортта иминлек-тынычлык, хезмәт һәм уен-көлке аралашып яшәгәннәр. Бу йорт тавыш-гауганы яратмый («*Әкрен, улым. Безнең өйдә, беләсең, алай сөйләшмиләр. Кычкырып көләргә ярый, кычкырып сөйләшергә ярамый»*). Япа-ялгыз утырса да, аның эче бәхет, шатлык белән тулган. Эче шау-гөр килеп торган йорт үзе дә бәхетле язмыш иясе, чөнки анда тереклекнең иң бөек көче — яшәү бар. Бер урамлы Алпамыш авылының бер өйле урамында яшәү — ул әле бәхетсезлек түгел, чөнки йортның эче өмет, киләчәккә якты ышаныч белән сугарылган. Бу йорттан аермалы буларак, кешеләр ташлап киткән җимерек нигезләр, хуҗаларын озак еллар буе көтеп-көтеп тә, аларны күрә алу, үзендә яшәү тамыры тибешен тоюга зар-интизар булган йортлар — менә алар чын бәхетсезләр һәм ятимнәр. Йортсыз кеше — бәхетсез кеше. Шундый җаннарның берсе — Галимҗан. Иртуган һәм Галимҗанның диалогы бу уңайдан бик гыйбрәтле: «*Галимҗан. Сахалиннан кайнише кайтып төшкән, чыраен сыткан була, бурсык! Кыртапалар шундый алар, Иртуган абый. Ул минем өемә килеп төшсәме?*

Иртуган. Өең бармы соң синең?

Галимҗан. Нәрсә ул өй, Иртуган. Хәзерге заманда кая барсаң, шунда өй. Кил монда, иптәш Галимҗан, дип чакырып торалар. Владивостоктан Житомирга хәтле, Норильскидан Пржевальскига чаклы... Ә син Робинзун Крузо кебек, ә, Иртуган дус. Берүзең, ә?» [Миңнуллин М., 1985, - б.159]. Әлеге сөйләшү авылны ташлаганнарның психологиясен, аларга шушы фикерне сеңдергән, «кече ватан»га «олы ватан»ны каршы куйган сәясәтне ача. Чынлыкта Алпамыш авылының бер урамлы авылында яшәүче Иртуган түгел, ә хәзерге заманда кая барсаң — шунда өй дип

яшәгән, шул уй белән үзен юатырга тырышкан Галимҗан ялгыз. Галимҗан сукбай булып гомерен үткәрү аркасында рухи яктан тәмам саеккан, хәтта үзе туып үскән нигезенең кайдалыгын да белми. Кендек каны тамган, гомер кояшының чыгыш урынын да хәтерендә тотмаган кешенең киләчәге булу да бик шикле: «*Галимҗан. Ух!.. Ух!.. Туган авыл. Их, Иртуган браток! Хәтерләмисеңме, Иртуган браток, безнең өй кайда иде ул? Нигезе кайда безнең өйнең? Таба алмадым, Иртуган батько. Ух!.. Ягез әле, егетләр-братлар. Авыл бит сагындыра бит... Яле йотып куй әле, Иртуган абый, бәгырькәем…»* [Миңнуллин Т., 1985, - б.162].

Әсәрдә йорт– нигез символының тагын берничә мәгънәсенә ишарә бар: «*Шамилә. Әллә соң үзебезнең авылга күчеп килсенме кияү кеше?*

Иртуган. Кирәкми. Йортка кергән ирләр куркып яши. Куркак ирнең балалары да куркак була. Алпамышта куркак нәсел үрчетмибез…» [Миңнуллин Т., 1985, - б.174]. Әлеге сөйләшү йортның — таяныч, хөрлек бирүче булуын ачыклый.

Нәтиҗәләр ясасак, Т.Миңнуллиның «Без бит авыл малае» комедиясендә өй туган авыл чикләрен ала. Автор гиперболик шартлы сурәтләү алымына таянып Алпамыш авылының бердәнбер урамында утырган бердәнбер йорты хакында сүз алып бара. Ул авылга бер йорт, аның тиңдәшләре дә, иптәшләре дә юк. Шулай да йорт яши. Алай гына да түгел, йортның киләчәге бар. Язучы йортны җанландыра, авыл белән тигезләшерлек итеп киңәйтә. Ягъни авыл йортка, йорт авылга әйләнә. Мондый арттыру–киңәйтү комедиядә күтәрелгән проблема, автор идеясен мөмкин кадәр тирәнрәк, үтемлерәк итеп укучыга җиткерүгә хезмәт итә. Йорт туган нигез, туган туфрак категорияләре белән тыгыз бәйләнгән, хәтта аларның символы дәрәҗәсенә күтәрелгән. Әсәрдәге барлык вакыйгалар да йорт тирәсендә кайный. Аның эчке пространствосы авылны яраткан, туган авылларына тугрылыклы булган яшь буын белән тулган. Йортның иминлеген, ныклыгын нәкъ менә алар саклый. Авторның бу әсәрендә Иштугановлар йорты «аңа китерүче сукмаклар белән тыгыз бәйләнгән» [Бугрова Л.В., 2004, – с.13]. Кыртапага кияүгә чыгарга җыенган Илсөярнең дә, чик саклап кайткан Иршатның да, армия сафларында хезмәт итүче ике игезәкнең дә, Казанга укырга киткән Илһамиянең дә, егерме биш ел элек авылын ташлап чыгып киткән Галимҗанның да,

Кыртапа авылында рәислек итүче Айтуганның да сукмаклары, юллары шушы өйгә килә. Ягъни комедиядә «юл» һәм «өй» төшенчәләре үзара гаять тыгыз дәрәҗәдә бәйләнгән. Юл йортны, пространство буларак, тирә-юньгә ача, анда яшәүчеләрне һәм йортның үзен дә гармоник дөньяның бер өлешенә әверелдерә. Өй — вакыйгаларның үзәгендә яткан тирәлек. Өйнең үткәне, бүгенгесе һәм, иң әһәмиятлесе, киләчәге бар. Бер төркем кешеләр өйнең үткәненә хөрмәт белән, бүгенгесен аңлап, киләчәгенә тирән ышаныч белән карыйлар. Икенче берәүләр өйнең бүгенгесен күрмәмешкә салыналар, киләчәге юк дип уйлыйлар. Йорт ялгыз утырырга тиеш түгел, аның кебек эче шау-гөр килеп торган башка йортлар да булырга тиеш. Андый йортлар никадәр күп булса, авылның киләчәге дә шул кадәр ышанычлы. Ил буйлап сукбайлыкта йөргән Галимҗанның: «*Туктале, син нәрсә мине минем авылымнан куасың? Телим икән, тотам да калам шушында — үз авылым. Әнә Кыртапада хуҗа бул. Иртуган, браток, авылдаш, көрәк биреп тор әле, пожаласты... Үзебезнең нигезне эзләп таптым. Бакчасына агачлар утыртып куям, мин кайтып өй салганчы үсә торсыннар*» [Миңнуллин Т., 1985, - б.192] сүзләре дә авторның бу проблемага оптимистларча каравы хакында сөйли.

Әдәбият

1. Бугрова Л.В. Мотив Дома в русской романтической прозе 20-х – 30-х годов Х1Х века: Автореф.дис. … канд.фил.наук/Л.В.Бугрова; Тверский гос.университет. – Тверь, 2004. – 24 с.
2. Лейдерман Н.Л., Липовецкий М.Н. Современная русская литература: В 3-х кн. Кн.: 2: Семидесятые годы (1968-1986) / Н.Л.Лейдерман, М.Н.Липовецкий. – М.: Эдиториал УРСС, 2001. - 424 с.
3. Миңнуллин Т.А. Монда тудык, монда үстек / Т.А.Миңнуллин. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1985. –350 б.

Батыршина А.Н.

XX йөз ахыры – XXI гасыр башы прозасында яңа тенденцияләр: дискурс мәсьәләсе

Гасырлар чигендә югары кыйммәтләрнең үзгәреше, дөньяның бөтенлекле картинасы таркалу әдәбиятка да турыдан-туры тәэсир ясый: герой концепциясе үзгәреш кичерә; традицион жанр кануннары актив рәвештә җимерелә; сәнгать стильләре арасындагы чикләр югала, аларның бер-берсе белән керешеп китүе, якынаюы сиземләнә.

Татар әдәбияты да XX йөз ахырында үзенчәлекле үзгәреш чоры кичерә. Җәмгыятьтәге үзгәрешләр әдәбиятны көчешкә этәрә. Реализм һәм романтизмның яңа башлангычлар, яңа төсмерләр белән баюы күзәтелә. Бер үк вакытта, рус һәм чит ил әдәбиятларында өстенлек алган тенденциягә ияреп, әдәби әсәрләрне махсус рәвештә билге-кодлар белән катлауландыру, шартлы сурәт мөмкинлекләрен файдалануга омтылыш үзен нык сиздерә.

Әдәбияттагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә татар әдәбият белеме фәне дә үз үсешендә яңа баскычка күтәрелә. Әдәби әсәрдә кулланылган яңа алымнарны постмодернистик ноктадан шәрехләү, әдәбиятка төрле структур катламнарны берләштергән катлаулы система буларак якын килү, бу системаның элементларын төрле дәрәҗәдәге яссылыкларда чишү-шәрехләү – болар заман тарафыннан әдәбият белеме фәне алдына куелган бурычлар.

70 нче еллардан төрле милли-әдәби мәктәпләрдә актив рәвештә кулланылып килгән дискурс төшенчәсе дә татар әдәбиятына мөнәсәбәтле рәвештә яктыртылуны сорый. Гомуми лингвистикада һәм әдәбият белемендә инде урнашып җиткән, шактый тулы дәрәҗәдә ачыкланган бу күренеш безнең фән өчен әле чагыштырмача яңа, таныш түгел.

Дискурс төшенчәсе лингвистик категория буларак шактый катлаулы һәм күпкырлы тикшерү объекты булып тора. Терминны билгеләүдә фикер төрлелеге яшәп килә, дискурсны бәйләнешле текст [Harris, 1963], катлаулы коммуникатив берәмлек [Van Dijk, 1997] яисә социаль-тарихи мәгълүмат чыганагы [Чернявская, 2003] буларак карау әлеге төрлелекнең нигезендә ята. Без үз

тикшеренүләребездә текстларны аерым «социаль белем» чыганагы буларак карадык һәм бу белемнәрне тарихи тәэсир, идеология йогынтысы һәм үзенчәлекле «чор рухы»ның чагылышы белән бәйләргә тырыштык. Дискурс төшенчәсен без әсәр эчендә җемелдәгән хакыйкатьләр берлеге буларак билгеләдек.

Дискурс төшенчәсен анализлау тәнкыйди һәм романтик башлангыч алган әсәрләр җирлегендә башкарылды. Тәнкыйди башлангыч алган әсәрләрдә автор позициясе әсәрдәге чынбарлык дискурсын билгели. Амур Фәләхнең “Таш бәгырь” [Фәләх, 2004] повестенда өй һәм армия тормышларына ясалган деконструкция бүгенге тормышка яңа күзлектән карарга ярдәм итә, тәнкыйди дискурсны формалаштыра. Симуляциягә корылган өй һәм армия тормышы гиперреальлек формасын ала. Бу гиперреальлектә җәмгыять белән акча идарә итә, кеше гомере кемнәрнеңдер баюы өчен корбан була; җәмгыять үзе ялганга корылган; хакыйкатьне ачарга омтылу исә үлемгә китерә. Болар деконструкция ярдәмендә ачыкланган закончалыклар.

Ясалма чынбарлык белән эш итү әсәрдәге невротик дискурс турында сүз йөртергә мөмкинлек бирә. Кешеләр аңында яши торган гиперреальлек – уйдырма, һәм ул чын реальлекне алыштыра, нәтиҗәдә, повестьта тәнкыйди дискурс белән янәшә һәм аның белән бәйләнештә невротик дискурс пәйда була.

Әлеге гиперреальлектә яши алуның бердәнбер юлы – таш шикелле нык булу. Таш кебек ныкларга киләчәктә үз хакыйкатьләрен әйтергә мөмкинлек тә булыр, бәлки. Шуңа күрә кеше өмет белән яшәргә тиеш. Бу әсәрдә сурәтләнгән чынбарлык алып килгән төп идея.

Зөлфәт Хәкимнең “Агымсуда ни булмас” һәм “Кишер басуы” повестьларында [Хәким, 1997] исә уйдырма сатира объектына әверелә, һәм ул ике төрле рәвеш ала: совет чынбарлыгы һәм бүгенге чынбарлык. Беренче әсәрдән аермалы буларак, монда бербөтен миф, шуны җимерү өчен уен бар, эстетик яктан бөтенлекле. Әмма З.Хәким әсәрләрен дә бер-берсенә тәңгәл куеп булмый: икенче повестьта реаль конкрет чишелеш тәкъдим ителә, һәм ул геройлар тарафыннан әйттерелә: халыкның берләшүе һәм намуслы, якты күңелле кешеләр артыннан иярүе. Шул рәвешле, бу повестьларда постреалистик

дискурс хасил була, ул автор уены рәвешен ала. Постреалистик дискурс социалистик реализм юнәлеше нигезендә барлыкка килә, әмма аны тәнкыйтьләүче, фаш итүче буларак чыгыш ясый. Постреалистик дискурста уен объекты – совет идеологиясе тудырган миф, символик дискурс. Автор сатирасы шушы мифка каршы юнәлтелгән.

Шул рәвешле, тәнкыйди башлангыч алган әсәрләрдә автор позициясе әсәрдәге чынбарлык дискурсын билгели. Ул яшәргә хаклы бердәнбер һәм төп хакыйкать булып реальләшә. Дискурс характеры автор позициясе һәм чынбарлыкны тәнкыйть юлының сайланышы белән билгеләнә.

Романтик әсәрләргә якын килгәндә исә, биредә дискурс шактый тармаклана, ул геройлар дискурсы, автор дискурсы һәм чынбарлык дискурсы рәвешен ала.

Амур Фәләхнең “Татлы газап” [Фәләх, 2004] новелласын карап үтик. Әсәр алып килгән төп дискурсив информация новелла чынбарлыгының сурәтләнү характерына бәйле. Ул кешеләрнең мәхәббәт дип исемләнгән хис-тойгыга мөнәсәбәтенә барып тоташа. Текст эчендә өч төрле дискурс хасил була: Артур дискурсы (романтик, невротик): «Мәхәббәт – бәхет ул»; автор дискурсы (реалистик): «Мәхәббәт - абсурд»; чынбарлык дискурсы: «Кешеләр төрле булган җәмгыятьтә мәхәббәткә төрле мөнәсәбәт яшәргә хаклы».

Артур хыялы тудырган мәхәббәт аның реальлеген алыштыра алган икән – димәк, биредә романтик (яисә невротик) дискурс турында сүз йөртәбез. Ә менә автор дискурсы башка информация алып килә - мәхәббәтнең абсурд буларак бәяләнүе векторларны капма-каршы юнәлешкә бора: уйдырмадан – реальлеккә таба, димәк чынбарлык биредә уйдырманы алыштыра һәм реалистик дискурсны хасил итә. Әмма әсәр эчендәге төп хакыйкать чынбарлык дискурсы булып формалаша: Мәхәббәтнең кешеләр тарафыннан уйлап табылган төшенчә булуы ачыкланса да, шушы уйдырмага ышану кемнедер бәхетле итә икән – димәк, бу ышаныч яшәргә тиеш.

Яңа алымнар җәһәтеннән якын килгәндә, әсәрнең постмодернизм таләпләренә җавап бирүен сиземләргә мөмкин. Повесть, рус әдәбиятындагы яңа тенденцияләргә ияреп, авторның үлеме концепциясенә корылган. Бу концепциянең эчтәлеге

авторның әсәр тукымасына килеп керүеннән, үзе дә геройларның берсенә әверелүеннән гыйбарәт. Повесть ахырында пәйда булган өйләнгән Артур гади укучыга шул ук төп герой булып аңлашылырга мөмкин, әмма зәвыклы укучы аның ялгыз Артур вакыйгалары белән бәйле текстның авторы булуын аңлый (Артурның Рәшит белән сөйләшүләре вакытында аның өйләнмәгәнлегенә басым ясала). Димәк, әсәр эчендә ике төрле текст сиземләнә: Артур-Диана тарихы һәм өйләнгән Артур тарихы. Артур-Диана тарихы, ялгыз Артур тарихы – текст эчендәге текст ул, өйләнгән Артур хыялы тудырган текст.

Югарыда сүз булган өч төрле дискурс Рәшит Бәшәр әсәрләрендә дә («Адашкан кош тавышы», «Минем әтиемне сугышта үтерделәр», «Акбалык») [Бәшәр, 2004] табыла. Беренче төр дискурс каһарманнарның тормышны романтик күзаллавына барып тоташа һәм әсәрләрнең иҗат юнәлешен дә билгели. Бу төр дискурсны романтик дискурс дип билгели алабыз, векторлар чынбарлыктан уйдырмага, хыялыйга таба юнәлгән, геройлар үзләре тудырган яңа чынбарлыкта яшиләр. Автор дискурсы башка төрле, ул автор позициясенең дөньяны реалистларча күзаллау рәвешендә формалашуы нәтиҗәсендә оеша. Язучы тарафыннан кешелеклелек һәм кешелексезлек модельләре тәкъдим ителә, нәкъ менә шушы модельләр авторның дөнья турындагы күзаллавын, автор хакыйкатен билгели. Чынбарлык дискурсына килгәндә исә, ул Амур Фәләх новелласы белән аваздаш. Биредә дә кешеләрнең шактый төрле булуы һәм аларны бәяләгән вакытта да «яхшы-начар» моделенә сыешып бетә алмавы мөһим. Мисалга Минневәли образын («Адашкан кош тавышы») алыйк. Аны кайсы полюска кертеп карыйк? Әсәр башында укучыда бары тик тискәре мөнәсәбәт уяткан герой алга таба башка яклары белән ачыла, һәм без инде аны яхшымы-начармы дип, кистереп кенә әйтә дә алмыйбыз. Шулай, кеше характерлары шактый төрле һәм катлаулы булган кебек, тормыш үзе дә бертөрле генә түгел. Нәкъ менә шушы дөреслек әсәрдәге чынбарлык дискурсын тәшкил итә һәм ул төп хакыйкать булып реальләшә.

Шул рәвешле, романтик әсәрләрдә дискурс шактый тармаклана, ул геройлар дискурсы, автор дискурсы һәм чынбарлык дискурсы рәвешен ала. Шунысы игътибарга лаек:

анализланган әсәрләрдә автор һәм төп герой хакыйкатьләре тәңгәл килмәсә дә, чынбарлык дискурсы бер үк, һәм ул бүгенге «чор рухы»н билгеләргә мөмкинлек бирә: безнең дәвердә кешеләрнең төрлелеге, һәрберсенең үз сукмагы, дөньяга үз карашы булу һәм тормыш юлын да нәкъ менә үзе салуы, үз язмышын үзе хәл итүе мөһим. Бу дөреслек әсәрләрдә доминанта була алмый, доминантаны автор позициясе билгели, әмма бу – тормыш хакыйкате.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар әдәбиятында дискурс төшенчәсенең реальләшүе үзенчәлекле рәвеш ала. Тәнкыйди башлангыч алган әсәрләрдә ул автор дискурсының бердәнбер хакыйкать буларак тәкъдим ителүе рәвешен алса, романтик әсәрләрдә төрле хакыйкать-позицияләрнең синкретик берлеге кебек реальләшә. Терминның алга таба өйрәнелешен фәлсәфи башлангыч алган әсәрләр җирлегендә башкару да кызыклы нәтиҗәләргә китерергә мөмкин.

Әдәбият

1. Бәшәр Р. Ачык капка: Хикәя, повестьлар / Р.Бәшәр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2004. – 255 б.

2. Фәләх А. Таш бәгырь: Повесть, новелла, хикәяләр / А.Фәләх. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2004. – 127 б.

3. Хәким З. Сайланма әсәрләр, II том. Повестьлар, хикәяләр / З.Хәким. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1997. –383 б.

4. Заһидуллина Д.Ф. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы / Д.Ф.Заһидуллина. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2003. – 255 б.

5. Заһидуллина Д.Ф. Яңа дулкында (1980 – 2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык) / Д.Ф.Заһидуллина. – Казан: Мәгариф, 2006. – 255 б.

6. Fairclough N.L. Language and power / N.L.Fairclough. – London; New York, 1989. – 224 p.

7. Harris Z.S. Discourse analysis / Z.S.Harris. – Mouton, 1963. – 428 p.

8. Van Dijk T.A. The study of discourse / T.A. van Dijk. // Discourse as structure and process. Discourse studies: A multidisciplinary introduction. – London; New Delhi, 1997. – P.1 – 3.

9. Ван Дейк Т.А. Язык. Познание. Коммуникация / Т.А. ван Дейк. – М., 1989. – 325 с.

10. Венедиктова Т. Между языком и дискурсом: Кризис коммуникаций / Т.Венедиктова. // Новое литературное обозрение. – Б.м. – 2001. - № 50. – С.89 – 96.

11. Ильин И.П. Постмодернизм. Словарь терминов / И.П.Ильин. – М.: ИНИОН РАН – INTRADA, 2001. – 384 с.

12. Кадырова А.И. О понятии «дискурс» в лингвистической литературе / А.И.Кадырова. // Язык и методика его преподавания: Сб. ст. – Казань, 2000. - С.14 – 15.

13. Квадратура смысла: Французская школа анализа дискурса. – М., 1999. – 414 с.

14. Литературная энциклопедия терминов и понятий. (Гл ред. и сост. А.Н.Николюкин.) – М.: НПК «Интелвак», 2001. – С.38 – 39.

15. Петрова Н.В. Текст и дискурс / Н.В.Петрова. // Вопросы языкознания. – Б.м… - 2003. - № 6. – С.123 – 131.

16. Руднев В.П. Психотический дискурс. Электронный ресурс: http: // ihtik.libru.ru/htm.

17. Фуко М. Слова и вещи: Археология гуманитарных наук / М.Фуко. – М., 1994. – 518 с.

18. Чернявская В.Е. От анализа текста к анализу дискурса: немецкая школа дискурсивного анализа / В.Е.Чернявская. // Филологические науки. – Б.м… - 2003. - № 3. – С.68 – 76.

Бәдертдинова Л.Ш.

Гази Кашшаф һәм татар театр тәнкыйте.

Танылган тәнкыйтьче, әдәбият галиме, педагог Гази Кашшаф (1907-1975) театр тәнкыйтендә дә үз сүзен әйтеп калдырган. Озак еллар дәвамында әдәби тәнкыйть белән бергә, әдипнең бу өлкәдә эзләнүләре, казанышлары матбугат битләрендә еш басылып килә. Н.Юзиев «Фидакарьлек» дип исемләнгән мәкаләсендә болай дип язып калдырган: «Гази Кашшафның театр тәнкыйтьчесе буларак формалашуында квартирасының театрга якынлыгы нинди роль уйнагандыр, әйтүе кыен. Әмма шунысы ачык – Гази агага театр үз йорты кебек якын булды. Соңгы елларда үзенең фәнни һәм әдәби тәнкыйть эшчәнлеген йомгаклаган китаплар чыгару уе тугач, бу эшен ул театр һәм драматургия турындагы мәкаләләрен туплаган

җыентык төзүдән башлады. Ул аны нәшриятка да тапшырды. Тик «Күңел көзгесе» исемендә чыккан әлеге китабын үзенә генә күрергә насыйп булмады... » [3,131] 1975 елда чыккан «Күңел көзгесе» әдипнең вафатыннан соң гына дөнья күрә.

Г.Кашшафның нәкъ менә театр тәнкыйтенә караган мәкаләләрен бастырырга теләве юктан гына булмаган. Басылып чыккан хезмәтләре арасында үз әсәрләре, тәнкыйть мәкаләре җыентыгы белән беррәттән, ул театрны да читтә калдырмаган. Әдип уенча, вакытлар узу, заманалар үзгәрү белән аның төрле газета һәм журнал битләрендә чәчелеп яткан язмалары тарихка кереп югалачак. Ә китап, җыентык бу юлда ярдәм күрсәтә ала. Г.Кашшафның үзе тарафыннан бәяләнеп, «Күңел көзгесе»нә сайланып алынган мәкаләләре чынлап та аның иң кадерле сүзләрен, төпле фикерләрен дә җиткереп киләләр, заманның рухи агымын тоярга булышалар.

Г.Кашшаф өчен театр аерым бер дөнья, мохит буларак күзаллана: «Гаҗәп тылсымлы сәнгать бит ул театр. Минем тормышымда ул зур урын алды, кече яшьтән үк мин аның тәэсиренә бирелеп киттем һәм ул минем күңелемә нур өсти барды. Бу җыентыкны «Күңел көзгесе» дип билгеләүнең мәгънәсе дә шунда. Театр, зур мәктәп буларак, минем өчен генә әһәмиятле түгел. Ул барыбыз өчен дә изге сәнгать бинасы. Ул сине көлдерә һәм сөендерә, уйланырга һәм борчылырга мәҗбүр итә, кеше рухының тирән диңгезләрендә йөздерә, күңел кылларыңны тибрәндереп төрле моңнарга чумдыра, нәфрәтләндерә һәм көрәш уты кабызып җибәрә» [1,3]. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: Гази Кашшафның балачак, яшьлек еллары татар театрының барлыкка килүе һәм үсеше чорына туры килә. Барлык халык күңеленә үтеп кергән театр яшь тәнкыйтьченең дә күңелен битараф калдыра алмаган. Әмма Г.Кашшаф бу сихри дөньяның көченә йотылып, буйсынып яшәми. Аның үз кыйбласы, үткен каләме бар. Театр постановкаларына бәя биреп, ул беренче чиратта аның үсешен күздә тота, аңа ярдәм итәргә тели. Тегеяки бу спектакльгә билгеләмә бирү җиңел эшләрдән түгел. Моның өчен үз фикерең булу, аны төгәл җиткерә белү сәләте дә кирәк. Сәхнәгә куелган әсәрләр дә тәнкыйтьче тарафыннан башта «әдәби тәнкыйть» уза.

Шуннан соң гына ул спектакльнең сәхнәдә башкарылуын тикшерү бурычын үз өстенә ала.

«Мин актер да, режиссер да, драматург та түгел, ләкин драматик әсәрләргә килеп тотынуга мин актер да, режиссер да, драматург та булам. Мин аны үземчә хәрәкәтләр, характерлар көрәше эчендә сиземли башлыйм. Кайчак, ул сәхнәдән башкача яңгырый, кайчак, әсәр минем зәүкыма ярашып бетми, кайчак тирән канәгатьләнү белән кайтасың һәм театрның тылсымлы көчен сизеп рәхәтлеккә биреләсең... » [2,4] – дип яза Г.Кашшаф. Шундый хисләр аның һәр мәкаләсендә диярлек сизелеп тора.

«Күңел көзгесе» җыентыгында театр тәнкыйтенә караган барлыгы егерме алты мәкалә тупланган. Алар 1940 елдан алып 1974 елга кадәр төрле журнал һәм газета битләрендә басылып чыкканнар. Әгәр шушы утыз елдан артыкка сузылган чорда якынча утыз спектакль генә тикшерелгән дип күз алдына китерсәк тә, театр тарихы, аның үсеш-үзгәреше турында гомумән мәгълүматы булмаган кеше дә күренеп торган нәтиҗәләр чыгара алыр иде. Г.Кашшаф исә: «... Сезгә тәкъдим ителгән бу материаллар мин язганнарның бик аз өлеше генә, алар – татар театры тарихының бер этабын да яктыртуны дәгъва итмиләр», – дип яза [2,5]. Ягъни әле моның белән аның эшчәнлеге чикләнми. Ә без аның бер үк вакытта тагын күп кенә башка эшләр белән шөгыльләнүен дә беләбез. Шундый затлар, һичшиксез, үз чорының башка шәхесләрен дә эшкә өндәгән, үрнәк булып тора алган.

Г.Кашшаф тарафыннан тәнкыйтьләнгән сәхнә әсәрләренең бер өлеше бүгенге театр тамашачысына яхшы таныш: «Галиябану», «Беренче мәхәббәт», «Хуҗа Насретдин», «Әни килде». Кайберләре исә инде үз заманының сәхнә җимеше булып кына калган. Драматурглар арасыннан Г.Кашшаф аеруча Н.Исәнбәт, М.Фәйзи, М.Җәлил, М.Әмир, Т.Гыйззәт, Г.Камал иҗатларын аерып куя, аларның әсәрләрен киң планда, төрле яклап тикшерә.

Мәсәлән, тәнкыйтьче үз игътибарын «Галиябану» операсына юнәлтә: «Галиябану» кебек драманы зур опера полотносына салу (Ә.Ерикәй либреттосы) – мактаулы һәм гаять җаваплы эш. Үлми торган әсәрнең операсы да үлми торган, классик опера булырга тиеш. Бу − табигый хәл,» – дип яза автор [2,6]. Алга таба

композитор М.Мозаффаровның уңышка ирешүе турында сүз бара. Гази Кашшаф Галиябануны Сара Садыйкова һәм Галия Кайбицкая башкаруында чагыштырып карый, һәр артистканың бу рольне башкаруда үзенчәлеген билгеләп үтә. Биредә шунысы да ачыклана: Г.Кашшаф театр постановкаларының һәрберсенә берничәшәр тапкыр йөргән, артистларны да яхшы ук белгән. Бу тәнкыйтьчегә югары дәрәҗәләргә ирешергә мөмкинлек тә биргән.

Мәкаләләр арасында күләме белән Нәкый Исәнбәткә багышланганнары аерылып тора. Алар драматургның 70 еллык юбилеена атап язылган. Гази Кашшаф биредә «Мәрьям», «Муса Җәлил», «Һиҗрәт», «Хуҗа Насретдин», «Рәйхан» һ. б. сәхнә әсәрләренә туктала, авторның иҗат уңышларын барлый: «Нәкый Исәнбәт халыкның тарихын иңләп ала торган талантлы язучылар рәтеннән исәпләнергә тиеш. Иҗаты белән бер эзгә салыну белән үк ул үзенә шундый кыю иҗат максаты куя: татар халкының күп гасырлы тарихын әдәби әсәрләрдә чагылдыру идеалы аның яшәү һәм иҗат максатына әверелә» [2,132]. Н.Исәнбәткә, аның иҗатына ихтирамын тәнкыйтьче шулай ук «Социалистик Татарстан», «Татарстан яшьләре», «Совет әдәбияты» укучыларына да җиткергән.

Татар драматурглары белән бергә, Г.Кашшаф үз китабында рус, башкорт талантларына да урын тапкан. «Сәхнәдә Островский», «Халыкчан һәм тормышчан», «Салават», «Күрше күзе аша» дигән бүлекләр моны безгә раслап тора.

Әгәр соңгы өчесе Башкорт дәүләт театрының Казанга килеп куелган яисә Г.Кашшафның Уфада карап кайткан әсәрләр постановкасын яктыртса, «Сәхнәдә Островский» дигәне аерым урын алып тора. Билгеле инде, биредә сүз аның татарчага тәрҗемә ителгән постановкасы турында бара. Бу Наил Дунаев тарафыннан «Агай-эне ак мыек» дигән исем белән тәрҗемә ителгән «Свои люди − сочтемся» дигән Н.Островский комедиясе. Күләме ягыннан бу тәнкыйди язма зур булмаса да, актерлар уенын шактый тулы яктырта, рәссам М.Сутюшевның да эшчәнлеге Г.Кашшаф тарафыннан югары бәяләнә.

«Башкорт дәүләт академия драма театрының Казанда гастроль спектакльләрен шагыйрь Кадыйр Даянның «Таңчулпан» драмасы белән башлап җибәрү бик уңышлы һәм мәгънәле, чөнки нәкъ шушы спектакльдә башкорт халкы характерын аңларга

мөмкин», – дип яза тәнкыйтьче «Халыкчан һәм тормышчан» дигән мәкаләсендә [2,65]. Г.Кашшафның кардәш башкорт театрына битараф булмавы нәкъ менә шушы мәкаләсендә ачык күренә. Китапта авторның: «Кардәш театр коллективы белән очрашу һәрвакыт бәйрәм. Елдан-елга күреп, профессиональ осталыкларын тәкъдир иткән тамашачы быелгы беренче очрашуны да бәйрәм кебек каршылады. Артистлар... Халыкның рухи бизәкләрен асраучы сәнгать әһелләре, без тагын очраштык... Тик бу очрашуда сагыш та бар, чөнки безнең яраткан дусларыбызның кайберләре инде килә алмаячак икән... Ләкин шунысы куанычлы – картлар урынын талантлы, җитез һәм темпераментлы яшьләр алган. Димәк, театр хәрәкәттә, ул үсештә, матур традицияләрне баетып баруында дәвам итә», – дигән юллар чын күңелдән әйтелгән сүзләр буларак яңгырый [2,188]. Г.Кашшаф чын-чынлап театр дөньясының иң югары казанышларын белүче, аларны хөрмәт итүче буларак күз алдына килеп баса.

Шулай да тәнкыйтьченең драматургиягә кагылышлы язма мирасы аерым авторларның сәхнә әсәрләрен тикшерү, постановкаларына бәя бирү белән генә чикләнми. Театр тәнкыйтьчесен «Татар операсының үсүе», «Бүгенге драма турында» кебек мәсьәләләр кызыксындыра. Мәсәлән, аның Татарстан язучыларының дүртенче съездында сөйләгән докладына игътибар итәргә кирәк. 1958 елда басылып чыккан бу язмада автор татар драматургиясенең артталыгы турында борчыла. Мәскәүдә үткән декада да бу мәсьәләнең ачык чагылуын күрсәтә. Егерменче-утызынчы елларда куелган спектакльләрнең илленче елларда сәхнәдә урын алуы Гази Кашшафны канәгатьләндерми. Ул драматургларны эшкә өнди, аларны иҗат итәргә чакырып кала.

Алда билгеләп узганыбызча, Г.Кашшафның һәр язмасы актерлар эшчәнлеген яктыртуга да юнәлтелгән. Шуларның берсе турында ул аерым китап булып басылып чыгарлык очерк та иҗат итә. Әлеге артистка – Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская.

1958 елда басылып чыккан бу китап күләме ягыннан да, басмасы ягыннан да зур түгел. Әмма эчтәлеге бик бай. Хезмәт танылган артистканың тормыш фактларын теркәп бару белән генә чикләнми, ә бәлки аны тормышчан, гади бер хатын-кыз итеп

сурәтләүгә багышланган. Бу истәлекне язып чыгуда ярдәм итүчеләрне дә Г.Кашшаф читтә калдырмый: «Волжская белән байтак еллар бергә хезмәт иткән талантлы артист Шакир Шамильский миңа бик күп истәлекләр сөйләгән иде,» – дип яза автор [1, 22]. С.Волжскаяның үзе белән очрашу исә Г.Кашшафта бу талантлы артисткага карата чын соклану хисен уята. Артистканың әңгәмәдәшче сорауларына туры җавап бирүе дә тәнкыйтьче тарафыннан билгеләнми калмый. Режиссер буларак аның артистларга рольләрне үзе бүлеп бирүе дә, «Сәйяр»не ташлап, татарларда тагын бер труппа булдырырга омтылуы да Гази Кашшаф сорауларына җавап булып яңгырый.

Алда билгеләп үткәнебезчә, Гази Кашшафның эшчәнлеге күпкырлы. Шуның белән бергә, ул татар театр сәнгатенә дә битараф калмаган, театр дөньясын да үз иткән. Бу фикерне әдипнең китаплары, басылып чыккан мәкаләләре дәлилләп тора. Гази Кашшаф театр тәнкыйтендәге эшчәнлеген киң планда алып барган. Ул сәхнә әсәрләрен, аларның постановкаларын тикшергән, актерлар, режиссерлар, рәссамнар, композиторларның эшчәнлегенә үз бәясен биреп барган. Вакытлар үтү белән, һичшиксез, татар театры да үзгәрешләр кичергән. Шуңа да карамастан, алга бару, яңа үрләр яулау өчен, театр сәнгате белән кызыксынучылар аның тарихын да белергә тиеш. Бу юнәлештә Гази Кашшафның китаплары, аның басылып чыккан язмалары, билгеле бер дәрәҗәдә, чыганак булып тора.

Әдәбият

1. Кашшаф Г. Беренче артистка / Г.Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. – 50 б.
2. Кашшаф Г. Күңел көзгесе / Г.Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – 206 б.
3. Юзиев Н. Фидакарьлек / Н.Юзиев // Әдәбият хәзинәләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 324 б.

Бурсаков И.С.

Становление Российской Федерации в период 1917 - 1922гг.

Становление российской федерации происходило в 1917 - 1922 гг., как известно, под непосредственным руководством вождя российского пролетариата В. И. Ленина. 12 января 1918 года III Всероссийский съезд Советов рабочих и солдатских депутат утвердил выработанную именно В. И. Лениным «Декларацию прав трудящегося и эксплуатируемого народа». В соответствии с этим документом Россия объявлялась республикой Советов рабочих, солдатских и крестьянских депутат на основе свободного союза свободных наций как федерация советских национальных республик. Этому факту предшествовала следующая историческая обстановка: «загнивающий», как его часто называют в учебниках, царизм, затем февральская буржуазная революция и временное правительство, затем, подготовленное опять же В.И. Лениным вооруженное восстание против временного правительства и установление диктатуры пролетариата. Историческое решение о практическом проведении вооруженного восстания в октябре 1917 года было принято на расширенном заседании ЦК РСДРП (б) 10 октября 1917 года также по предложению В.И. Ленина.

Анализ исторических событий с точки зрения современного человека показывает, что В.И. Ленин был сторонником «теории элит». Будучи образованным человеком и мудрым политиком, В.И. Ленин понимал, что на смену царизму придет капитализм. Этот строй при весьма скромном социальном положении В.И. Ленина не сулил ему особо блестящих перспектив, поэтому необходимо было правильно воспользоваться существующей политической ситуацией в стране и самому оказаться у власти. И он ею воспользовался. Овладеть сознанием народных масс В.И. Ленину помогла утопическая идея коммунизма, взятая из учения Маркса и Энгельса, которую Маркс и Энгельс выдвигали как некий совершенный идеал, который, как известно, недостижим. Преподнесенная народу в адаптированном виде - все обобщить и поделить поровну - эта идея вполне отвечала чаяниям трудящихся и обеспечила их массовое участие в вооруженном

восстании и приход к власти партии большевиков. Теперь надо было приложить усилия к тому, чтобы удержать эту власть. Самым слабым местом политики многонациональной царской России был национальный вопрос. Как пишет О.И. Чистяков, царское правительство «...принимало все меры к тому, чтобы истребить всякие следы государственности у тех народов, которые обладали ею ранее». Следовательно, первым пунктом большевистской национальной политики стало дарование народам страны права на свободное самоопределение вплоть до отделения и образования самостоятельного государства. Однако на практике для большинства народов подобное отделение было невозможно, и В.И. Ленин это прекрасно понимал. «Провозглашение Советской властью права наций на самоопределение создавало возможность для изменения», формы ее государственного единства в сторону усложнения, в сторону федерации. В январе 1918 года двумя основополагающими документами III ВСС РЕЗОЛЮЦИЕЙ О ФЕДЕРАЛЬНЫХ УЧРЕЖДЕНИЯХ И ДЕКЛАРАЦИЕЙ ПРАВ ТРУДЯЩЕГОСЯ И ЭКСПЛУАТИРУЕМОГО НАРОДА Россия была провозглашена федерацией. Съезд решил вопрос о федерации, только в принципе, так как вопрос о форме федерации в резолюции и декларации оставался открытым. Термин федерация произошел от латинского слова «фэдус», что означает союз. В юридической литературе по проблемам федерализма широко используется понятие «федеративное государство». В большинстве случаев его содержание совпадает со значением понятия «федерация». Существует много точек зрения данного понятия, однако понятие федеративного государства как союзного государства является наиболее распространенным.

Для РСФСР был свойствен специфический способ возникновения федеративных отношений, отличный от порядка образования союзного государства. Для союзного государства характерен договорный способ оформления. В основе образования РСФСР лежал не договор, а закон. РСФСР была провозглашена законами, принятыми III Всероссийским съездом Советов. В.И. Ленин подчеркивал, что образование автономных единиц законами, издаваемыми органами центральной власти, не только не исключают, но наоборот предполагают волеизъявление

народов, получающих автономию. Народы России получали автономию в различных формах: Автономная Советская Социалистическая Республика (АССР), Автономная Область (АО) и Трудовая Коммуна (ТК).

Российская Федерация была построена исключительно по национально-территориальному принципу, хотя были и другие предложения. Однако именно национально-территориальный принцип был удобен как для хозяйственного, так и для идеологического управления людским субстратом на территории страны посредством местных Советов. В ходе событий Великого Октября была разрушена бюрократическая централизация управления местами и стала строиться новая система местного управления, основанная на принципе демократического централизма, на сочетании широких прав местных органов власти и управления с подчинением их центру. Однако широкие права местных органов власти и вовсе не могли не сочетаться с центром, так как целиком и полностью следовали по коммунистическому пути, проложенному большевистской партией.

Из этого следует, что национально-государственное строительство в РСФСР проходило под руководством партийных государственных органов. Таким образом, РСФСР сложилась как своеобразная форма федерации. Она возникла не в результате объединения равнозначных суверенных государств, а в силу выделения отдельных территорий из уже существующего государства - Российской Советской Республики - и предоставлении им статуса автономных единиц. В тот период Российская Федерация сложилась не как союзное государство, а как государство с автономными включениями находящимися в полном подчинении центру. Как видим, октябрьский переворот и установившаяся в его результате форма государственности России - это практическая реализация теории элит, т.е. такого государственного строя, при котором подавляющее большинство населения обслуживает некую верхушку, «элиту». В данном случае элита — это компартия во главе с В.И. Лениным и с ЦК. Следовательно страной руководила хотя и не династия, но все равно конкретный узкий круг людей - В.И. Ленин и его

сторонники - и никто другой в этот круг не допускался, власть должна была передаваться из рук в руки в пределах этого круга. Таким образом, фактически это была та же монархия, которая была свергнута лишь в 1993 году.

Вәлиева Л.Ә.

Автомобиль терминологиясендә фигыль тезмәләр

Татар техник терминологиясенең шактый өлешен төп компоненты фигыль булган аналитик атамалар тәшкил итә. Мондый тезмә атамаларның асылын ачыклаганда, аларга күчүче башлангыч сүзтезмәдә булган синтаксик мөнәсәбәтләрне игътибарга алмыйча булмый. Тезмә компонентларының лексик-грамматик үзлекләре, мәгънә белдерү дәрәҗәләре төрлечә булуы мөмкин, бу исә аналитик терминның лексик-семантик үзенчәлегендә чагылмый калмый. Әмма тезмә атамаларербөтен техник төшенчәне белдерүче лексик берәмлек булганга, аларны шартлы рәвештә генә синтаксик ысул белән ясалган дип кабул итәргә була.

Түбәндә, тезмә терминнарның төркемнәрен атау өчен, ирекле сүзтезмә атамаларының үзгәртелгән формасы кулланыла. Мисал өчен, «исемле фигыль тезмә» атамасы – «беренче компоненты исем, икенче компоненты фигыль булган тезмә термин» дигән мәгънәгә ия. Аналитик терминнарның төзелеше башлангыч сүзтезмәнең синтаксисын чагылдыручы калып белән шартлы билгеләр аша сурәтләнә: {Сүз төркеме (бәйләүче чара) → Сүз төркеме (бәйләүче чара)}. Сүз төркемнәре хәреф белән (И – исем, Ф – фигыль, С – сыйфат, Р – рәвеш, Сн – сан) тамгалана. Бәйләүче чара гади җәяләр эчендә бирелә, кушу тамгасы (+) булу аның кушымча икәнен аңлата. Сүз төркеменең ясагыч кушымчасы игътибарга лаек булган очракта, ул сызыкча (-) аша аерылып, җәяләрсез күрсәтелә. Авыш сызык (/) «яки» мәгънәсен бирә, ук (→) иярткүле бәйләнешне билгели.

Фигыль тезмә рәвешен алган техник атамаларда төп компонент булып исем фигыль килә, шуңа күрә бу терминнарның төзелеше исем тезмәләргә охшаш була. Монда исем фигыльне конверсия нәтиҗәсендә исемгә күчкән дип карарга да булыр иде [4]. Әмма төп компоненты исем фигыль булган тезмәләрнең

семантикасы аерым бер үзенчәлеккә ия: монда икенче компонент нинди дә булса эш-хәрәкәтне, процессны ачыклый. Шуңа күрә синтаксик ысул белән барлыкка килгән техник тезмә атамаларны тәшкил итүче сүзләр арасындагы бәйләнешне синтактика һәм семантика күзлегеннән өйрәнгәндә, төп компоненты исем фигыль булган тезмәне төп компоненты исем булган тезмәдән аерып карау уңышлырак. Төп компоненты фигыль булган техник тезмә терминнарны синтаксик караштан исемле, сыйфатлы, рәвешле, фигыльле, санлы фигыль тезмәләргә бүлергә була.

Исемле фигыль тезмәләр

А) Тезмә атама хасил итүче сүзтезмәдә исем фигыльгә янәшә тору яки лексик мәгънә аша ияргән очракта {И→Ф}, исем билгесез килештә килә һәм ул фигыльдән аңлашылган процессны төрлечә ачыклый.

Хәбәрлекле (предикатив) тезмә терминнар составындагы сүзләр ия-хәбәр (субъект – предикат) бәйләнешенә кергәндәй күренә: *күчәр күчү* (осевое смещение), *ягулык бөркелү* (вспрыск распыление топлива), *аккумулятор корылу* (заряд аккумулятора), *аккумулятор бушану* (разряд аккумулятора), *клапан ачылу* (открытие клапана), *клапан ябылу* (закрытие клапана), *компрессия кимү* (снижение компрессии), *очкын булмау* (отсутствие искры), *очкын булу* (наличие искры).

Тезмә атамага конверсияләнүче сүзтезмәдә исем процессның объектын да белдерергә мөмкин: *йөк ташу* (грузоперевозка), *ягулык тоту* (расход топлива), *газ бүлү* (газораспределение), *газ алмаштыру* (газообмен).

Б) Исемнең фигыльгә килеш аша иярүеннән ясалган сүзтезмәләрнең дә, лексикалашып, тезмә терминга күчү мөмкинлеге бар. Башлангыч сүзтезмәдә түбәндәге очраклар очрый:

Туры объектны белдерүче сүзләрне күчемле фигыльләр +ны/+не кушымчасы аша ияртәләр. Бу төр терминнар {И(+ны/+не)→Ф} калыбы буенча хасил булалар: *двигательне карау* (осмотр двигателя), *картерны җилләтү* (вентиляция картера), *карбюраторны көйләү* (регулировка карбюратора).

Физик хәрәкәтнең юнәлеш ноктасын белдергән очракта, тезмә фигыль термин {И(+га/+гә/+ка/+кә)→Ф} калыбына салына: *ияргә утыру* (посадка на седло). Юнәлеш килеше

кушымчасы ярдәмендә физик хәрәкәтнең максатын да белдереп була: *очкынга тикшерү* (проверка на искру), *разгонга тикшерү* (проверка на разгон), *выбегка тикшерү* (проверка на выбег).

Физик хәрәкәтне белдерми торган процессның кыек объектын күрсәтү өчен {И(+дан/+дән/+тан/+тән)→Ф} калыбы файдаланыла: *җылыдан саклау* (теплозащитная) аслыгы.

Башлангыч сүзтезмәдә бәйләүче чара +да/+дә/+та/+тә кушымчалары булганда, ияртүче кисәк урын-вакыт килешендә була һәм ияртүчедән аңлашылган процессның урынын белдерә. Мондый сүзтезмәләр тезмә атамага {И(+да/+дә/+та/+тә)→Ф} калыбы буенча күчә: *карбюраторда кабыну* (зажигание в карбюраторе), *глушительдә шартлаулар* (хлопки в глушителе), *двигательдә шакылдаулар* (стуки в двигателе).

Тезмә терминнарга әверелүче сүзтезмәләрдә фигыльгә исем иялек килеше аша да ияргә мөмкин, бу хәл фигыльгә тартым кушымчасы ялгануга китерә. Мондый тезмәләрдә {И(+ның/+нең)→Ф(+ы/+е)} процесс үзенең үтәүчесенә яки объектына каратыла: *тәгәрмәчләрнең җәелүе* (развал колес), *тәгәрмәчләрнең якынаюы* (схождение колес).

В) Тезмә атамаларга конверсияләнүче сүзтезмәләрдә фигыль исемне төрле ярдәмлекләр аша да ияртергә мөмкин.

Бу процесс нәтиҗәсендә ясалган тезмә терминнарда (*белән)* бәйлеге иң еш очрый {И→(белән)→Ф}. Биредә компонентлар арасында төрле мәгънә мөнәсәбәтләре урнашырга мөмкин: төп компонент процессны белдерсә, икенче компонент (исем) аны төрле яклап аныклый. Еш кына исем процесс үтәүче, аны башкаручы коралны яки материалны белдерә: *су белән суыту* (водяное охлаждение), *һава белән суыту* (воздушное охлаждение), *очкын белән кабызу* (зажигание искрой). Кайвакыт исем процессның объектын күрсәтә: *һава белән туендыру* (питание воздухом), *ягулык белән туендыру* (питание топливом). Исем ярдәмендә процессның үтәлү рәвешен белдерү өчен дә шушы ук калып кулланыла: *өзеклек белән эшләү* (работа с перебоями), *үзагым белән майлау* (смазка самотеком).

Икенче компонент (исем), нинди дә булса ярдәмлек исем янында килеп, шулай ук исемле фигыль тезмәләр хасил итәргә мөмкин {И→(аст)→Ф}: *басым астында майлау* (смазка под давлением). Бу тезмәдә эш-хәрәкәтнең үтәлү рәвеше белдерелә.

Рәвешле һәм сыйфатлы фигыль тезмәләр

А) Сыйфатлар, саф рәвешләр фигыльгә янәшә тору һәм лексик мәгънә аркылы бәйләнүе нәтиҗәсендә ясалган тезмәләрдә процессның үтәлү рәвешен белдерелә {С/Р→Ф}: *мәҗбүри суыту* (принудительное охлаждение), *пөхтә чистарту* (тонкая очистка), *тупас чистарту* (грубая очистка), *түбән тапшыру* (низшая передача), *югары тапшыру* (высшая передача), *кинәт кушу* (резкое включение), *артык җылыну* (перегрев), *артык суыну* (переохлаждение).

Күренгәнчә, рәвешле һәм сыйфатлы фигыль тезмә еш кына каршы мәгънәле төрдәш терминнар хасил итәләр. Кайбер очракларда мондый антонимнар инкарьлы тезмә белән биреләләр: *тигез әйләнү – әйләнмәү* (равномерное – неравномерное вращение), *тулысынча ачылу – ачылмау* (полное – неполное открытие), *тыгыз ябылу – ябылмау* (плотное – неплотное закрытие), *тыгыз утыру – утырмау* (плотная – неплотная посадка), *тыгыз яту – ятмау* (плотное – неплотное прилегание).

Башлангыч сүзтезмәдә сыйфатны фигыль чыгыш яки юнәлеш килеше кушымчасы аша ияртүендә, тезмәдә шулай ук үтәлү рәвешен белдерелә {С(+дан/+дән/+тан/+тән/+нан/+нән)→Ф}: *үзлегеннән кушылу* (самовключение), *үзлегеннән аерылу* (самоотключение) яки {С(+га/+гә/+ка/+кә)→Ф}: *бушка эшләү* (работа вхолостую), *турыга тоташтыру* (прямое соединение), *турыга тапшыру* (прямая передача).

Рәвешләр, фигыльгә янәшә тору чарасы белән ияргәндә, процессны төрле яклап (күләм, вакыт, урын, сәбәп-максатын күзлегеннән) ачыкларга мөмкин. Мисал өчен, *элегрәк ачылу* (раннее открытие), *соңрак ачылу* (позднее открытие), *элегрәк ябылу* (раннее закрытие), *соңрак ябылу* (позднее закрытие), *иртә кабыну* (раннее зажигание), *соң кабыну* (позднее зажигание).

Б) Ясалма сыйфатлар һәм ясалма рәвешләр дә, фигыльгә ияреп, аны шулай ук төрле яклап ачыклап киләләр. Бу очракта ясагыч кушымчалар бер үк вакытта иярүчене фигыльгә бәйләү хезмәтен дә үтиләр, һәм шул бәйләү барышында сыйфат яки рәвеш ясала. Бу тезмәләр {С/Р-кушымча→Ф} калыбы белән

биреләләр, һәм аларда төп компоненттан аңлашылган процессны ачыклана.

Техник тезмә терминнарда процесс шул процесста катнашкан әйбер аркылы ачыкланырга мөмкин. Биредә сыйфат -лы/-ле кушымчалары ярдәмендә ясала һәм тезмә атама {С-лы/-ле→Ф} калыбы белән бирелә: *тупсалы тоташтыру* (шарнирное соединение), *тешле тоташтыру* (зубчатое соединение), *сырлы тоташтыру* (резьбовое соединение), *каешлы тапшыру* (ременная передача), *чылбырлы тапшыру* (цепная передача). Бу мисалларда фигыль белән бирелгән ияртүченең иярүче аңлаткан әйбер ярдәмендә эшләгәне ачыклана.

Ясалма сыйфатлы фигыль тезмәләр ярдәмендә процессны шул процесста катнашмаган, булмаган әйбер яки төшенчә аркылы да ачыклап була. Биредә сыйфат -сыз/-сез кушымчалары ярдәмендә ясала һәм тезмә атама {С-сыз/-сез→Ф} калыбы белән бирелә: *кузгалышсыз утырту* (неподвижная посадка), *аергысыз тоташтыру* (неразъемное соединение).

Кайвакыт фигыль тезмәләрне хасил итүче сүзтезмәдә иярүче кисәк фигыльдән ясалган сыйфат ярдәмендә дә бирелә. Бу очракта төп компонентның нинди дә булса эш-хәрәкәткә әвәслеге *йөзүчән тоташтыру* (плавающее соединение) яки үтәлү рәвеше *җитәрлек тарттырылмау* (недостаточная затяжка) билгеләнергә мөмкин.

В) Фигыль тезмәләрдә аныклаучы компонент алынма сыйфат та булырга мөмкин. Мондый сыйфат чыганак телдән үзенең нигезе һәм кушымчасы (тулы килеш яки кыскартылып) белән күчә [2], шуңа алынма сыйфатлы фигыль тезмәләрдә компонентлар янәшә тору чарасы аша бәйләнгән дип карарга була. Бу тезмәләрне {$С_А$→Ф} калыбы белән бирергә була, һәм аларда фигыльдән аңлашылган процессның үтәлү рәвеше билгеләнә. Европа телләреннән татар теленә күчкән алынма сыйфатлар тезмә техник терминнар төзүдә актив катнаша: *техник карау* (технический осмотр), *герметик ябылу* (герметическое закрытие), *контроль карау* (контрольный осмотр), *инерцион чистарту* (инерционная очистка), *фрикцион тоташтыру* (фрикционное соединение).

Г) Сыйфатлы һәм рәвешле фигыль тезмәләрдә төп компонент булып сыйфат фигыль дә килергә мөмкин.

Компонентлар арасында урнашкан мәгънә мөнәсәбәтләре кызыксындырганга, монда да адъективизациягә аерым игътибар бирмәскә була. Бу тезмәләр {С/Р→Ф} калыбы белән бирелә, һәм аларда компонентлар янәшә тору һәм лексик мәгънә аркылы бәйләнә: *даими тоташтырылган* (постоянно включенный), *даими аерылган* (постоянно выключенный), *кузгалышсыз утыртылган* (неподвижно посаженный), *бик ярлыландырылган* (сильно обедненная), *бик баетылган* (сильно обогащенная), *аз көчәйтелгән* (низкофорсированный), *уртача көчәйтелгән* (среднефорсированный), *күп көчәйтелгән* (высокофорсированный), *артык корылган* (перезаряженный).

Фигыльле фигыль тезмәләр

А) Фигыльләрнең үзара хәл фигыль формалары аша бәйләнешеннән ясалган тезмә терминнарда бер фигыльдән аңлашылган процессны икенче фигыль төрле яктан ачыклый.

Татар грамматикасында [4], -п белән яки -а, -ә, -й белән тәмамланган хәл фигыльләргә ярдәмче (модификацияләүче) фигыльләр кушылып, татар телендә, гомумән, нинди дә булса фәнни терминологиягә бәйсез рәвештә, тезмә фигыльләр ясала дип кабул ителгән. Гадәттә, мондый тезмә фигыльнең төп мәгънәсе беренче компонент (хәл фигыль) белән белдерелә, ә ярдәмче фигыль өстәмә мәгънә бирә, беренче фигыльнең мәгънәсен конкретлаштыра. Автомобильгә бәйле тезмә атамалар {Ф(+п/+ып/+еп/+а/+ә/+й)→Ф} калыбы ярдәмендә төрле мәгънәләр белдерергә мөмкин: эш-хәрәкәтнең гомумән башлануын *кабызып җибәрү* (пуск), *әйләнеп китү* (проворачивание), *эшләтә башлау* (пуск) яки эш-хәрәкәтнең өзлексез, чагыштырмача даими булуын *тартып йөртү* (буксировка).

Төп компонентның үзенчәлекле билгесен процесс аша белдерү өчен, кайбер очракларда фигыль тезмәләрдә ярдәмче фигыль сыйфат фигыль формасын ала. Мондый тезмәләрдә гадәти, үзгәрешсез, регуляр эш-хәрәкәтне яки нинди дә булса эш-хәрәкәткә әвәслекне белдерү өчен *тору* ярдәмче фигыле еш кулланыла: *катмый торган* (незамерзающий), *алмаштырыла торган* (заменяемый), *шплинтлана торган* (шплинтуемый), *үзе кысыла торган* (самоподжимной), *күтәрелә торган* (восходящий), *төшә торган* (нисходящий).

Хәл фигыльле фигыль сүзтезмә буларак барлыкка килеп, терминга әверелгән тезмәләрдә бер процесс икенче процесс аша ачыклана, эш-хәрәкәтнең үтәлү рәвешен белдерелә {Ф(+ып/+еп)→Ф}: *чәчрәтеп майлау* (смазывание разбрызгиванием), *янып тузу* (прогорание), *күчереп тоташтыру* (переключение), *эретеп ябыштыру* (сварка).

Күренгәнчә, хәл фигыльле фигыль тезмә терминнарны хасил итүче сүзтезмәләрдә иярүче, башлыча, татар сүзләренә кушымчалар ялганып, ияртүчегә бәйләнгән. Әмма техник фигыль тезмәләр алынма нигезле хәл фигыльләр катнашып та ясалырга мөмкин {Ф-лап/-ләп→Ф}: *пресслап утырту* (посадка прессованием), *шарнирлап тоташтыру* (шарнирное соединение), *щлицалап тоташтыру* (щлицовое), *шпонкалап тоташтыру* (шпоночное соединение), *клепкалап тоташтыру* (заклепочное соединение), *фланецлап тоташтыру* (фланцевое соединение), *балансирлап асу* (балансирная подвеска), *эмульсияләп бирү* (подача эмульсией), *вулканизацияләп ябыштыру* (вулканизация). Мондый тезмәләрдә дә төп компоненттан аңлашылган процессның үтәлү рәвешен ачыклана.

Төп компоненты сыйфат фигыль булган очракта да хәл фигыль процессның үтәлү рәвешен белдерә: *коеп ясалган* (литой), *чүкеп ясалган* (кованый), *эретелеп ябыштырылган* (сварной), *кисеп ясалган* (изготовленный резанием), *тишеп ясалган* (изготовленный сверлением).

Б) Исем фигыльле фигыль техник тезмәләр сирәк очрый. Еш кына мондый тезмәләргә конверсияләнүче сүзтезмәдә бәйләүче чара булып кушымчалар тора. Туры объектны белдерүче фигыльне төп компонент +ны/+не кушымчасы белә бәйли, һәм бу төр терминнар {Ф(+ны/+не)→Ф} калыбы буенча хасил булалар: *кабызуны көйләү* (регулировка зажигания). Физик хәрәкәтне белдерми торган процессның кыек объектын күрсәтү {Ф(+дан/+дән/+тан/+тән)→Ф} калыбы аша башкарылырга мөмкин: *кызудан кабыну* (калильное зажигание).

В) Сыйфат фигыльле фигыль тезмәләр шулай ук сирәк очрый. Сыйфат фигыльнең барлык формалары да, фигыльгә ияреп, ирекле сүзтезмәләр ясый алса да, техник тезмәләрдә үткән заман сыйфат фигыльләре генә катнаша. Мондый фигыль тезмәләрдә, гадәттә, процесс үзе өстендә башкарылган башка эш-

хәрәкәт аша билгеләнә {Ф-ган/-гән/-кан/-кән→Ф}: *юнәлдерелгән чәчрәтү* (направленное разбрызгивание), *түбәнәйтелгән тапшыру* (пониженная передача), *күтәрелгән тапшыру* (повышенная передача).

Санлы фигыль тезмәләр

Санлы фигыль тезмәләрне хасил итүче башлангыч сүзтезмәдә сан исем фигыльгә (исемгә күчкән фигыльгә) янәшә тору чарасы аша иярә. Мондый техник терминнарда, гадәттә, сан процессның тәртип ягыннан ничәнче урында торуын белдерә {Сн-нчы/-нче→Ф}: *беренче тапшыру* (первая передача), *икенче тапшыру* (вторая передача).

Шулай итеп, тезмә терминнарның ясалу мөмкинлеге аны тәшкил итүчеләрнең грамматик табигатенә һәм лексик эчтәлегенә бәйле, ягъни сүзләрнең грамматик яки лексик каршылыгы нәтиҗәсендә теләсә нинди сүз тезмә сүзнең компоненты була алмый. Автомобиль тармагына караган терминологиядә фигыль тезмәләрнең төп компоненты булып исем фигыль тора. Мондый тезмәнең, башлыча, төп өч төре кулланыла: исемле, сыйфатлы һәм фигыльле. Исемле һәм сыйфатлы фигыль тезмәләргә күчүче башлангыч сүзтезмәләрдә компонентлар янәшә тору һәм лексик мәгънә аша гына түгел, ә бәлки килеш кушымчалары ярдәмендә дә актив бәйләнәләр һәм ачыкланалар.

Сыйфатлы фигыль тезмәләр еш кына ясалма сыйфатлар хасил булу аркылы бара. Фигыльле фигыль тезмәләрне хасил итүдә исә хәл фигыль актив роль уйный. Төп компоненты фигыль булган тезмә атама ясалу башлангыч сүзтезмәнең гади конверсиясе аша башкарыла, ә аның кушымча алып лексикалашуы бу очракта күзәтелми.

Әдәбият

1. Ганиев Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби телендә сүзьясалышы/ Ф.Ә. Ганиев. – Казан: «Мәгариф», 2006. – 271 б.
2. Карягин А.В., Соловьев Г.М. Автомобильләрнең төзелеше, аларны карау һәм йөртү кагыйдәләре/ А.В. Карягин, Г.М. Соловьев. – Казан: ТКН, 1963. – 500 б.
3. Юлдашев А.К., Җомагылов Ә.Х. Тракторлар һәм автомобильләр/ А.К. Юлдашев, Ә.Х. Җомагылов. – Казан: «Мәгариф», 1999. – 335 б.

4. Татар грамматикасы. – Т. I. – М.: «Инсан», Казан: «Фикер». 1998. – 512 б.
5. Фасеев Ф.С. Татар телендә терминология нигезләре / Ф.С. Фасеев. – Казан, 1969. – 200 б.

Габидуллин Р.Р.

Ирекле шәхесләр илгә нигә кирәкми?

Мең еллык тарихы булган татар әдәбиятында шәхес ireгeн кысу, аны көчләп рухыннан аеру, шәхес буларак кешене сындыруны сурәтләгән әсәрләр шактый күп. Кайсы чорда язылуларына карамастан, аларның барысы да сәясәт, тормыштагы үзгәрешләр һәм дини кануннарның сакланмавы белән бәйле. Шунысын да искәртеп үтү мөһим: бары тик рухи һәм сәяси әзерлекле әдипләр генә мондый әсәрләрне иҗат итә ала. Алар арасында “хөрлек богаулаган чорны, шул замандагы каршылыкларны, эчке көрәшне үзенчә чагылдыручы катлаулы мирас калдырган, үзе дә озак еллар дәвамында эзәрлекләнгән, кимсетелгән, бары гомеренең соңгы чорында гына Татарстанның халык язучысы дигән исемгә лаек булган әдип Аяз Гыйләҗев” [2, б.4]ның да лаеклы урыны бар. Гаделлек, гуманизм принциплары, гади халыкны ярату А.Гыйләҗев әсәрләренең төп мотивы булып тора. Р.Фәизов хаклы рәвештә билгеләп үткәнчә, “әдәбиятта халыкларның тарихи үткән юлы һәм киләчәккә булган өметләре дә, уй-хыяллары, киләчәккә нинди юл белән атларга исәп тотулары да бик ачык төсмерләнә” [4, б.160]. Аяз Гыйләҗевның “Йәгез, бер дога!” дип исемләнгән роман-хатирәсе шундый әсәрләрнең бер үрнәге булып тора. Әсәрдә тулысы белән әдипнең күргән-кичергәннәре тормышындагы явыз вакыйгалар белән үрелеп бирелә. 20 яшьлек студент егетнең төрмәгә килеп эләгүе шул чордагы кешеләрне генә түгел, бүгенге укучыны да сагаерга мәҗбүр итә. Бернинди кануннарга да, киртәләргә дә сыймаган эш-гамәлләрне кылырга рөхсәт ителгән чорның нинди булуы турындагы фикер, әлбәттә, әдипнең үзен дә уйландыра. Ул бу турыда әсәрендә берничә мәртәбә искә ала. Чыннан да XX гасырның 40 нчы еллар ахыры нинди тарихи, сәяси вакыйгалар белән бәйләнешле соң? Бу чорда кемнәрне кулга алганнар, әдип нинди шәхесләр белән бер камерада утырган?

Шушы караңгы һәм катлаулы чорда төрмә үз эченә меңләгән генә түгел, хәтта миллионлаган гаепсез кешеләрне җыя. Анда тоткыннарның ни өчен китерүләрен аңлау бүгенге көндә дә чишәргә авыр булган табышмак булып кала бирә.

Әлеге сорауга җавап табу максатыннан, әсәргә мөрәҗәгать итик.

Әдипнең камерадашы Кәбир Мөхәммәтшин-авыл егете, аның бар гаебе сугышта исән калуында. Рәсәй ягыннан немецларга биш миллион җиде йөз мең кеше әсир булып төшкән. Кәбир-шул миллионнар арасында исән калганнарның берсе.

Ә Казан арты, Арча ягы татарын көлтә керткән җиреннән, басудан тотып алганнар. “Җирнең хыянәтсез улы-татар крестьянының эшен трибуналга җиткергәннәр” [3, б.17]. Автор әйткәнчә, русча ипи-тозлык та белмәгән, Рәсәйне, ярты Европаны түше белән шуып гизсә дә, тарихны да, географияне дә аңламаган надан татарга: “Совет властен тамырдан җимерергә Англия, Франция, Белгия дәүләтләреннән задание алып кайткан шпион”,-дип аяусыз хөкем чыгарганнар.[3, б.17]. Шулай итеп, риясыз табигать баласына, көнен төнгә ялгап ялны белмичә эшләп тә, бер кайчан да тамагы туймаган крестьянга 25 ел каты режимлы төрмә, 5 ел сөрген, тагын 5 ел хокуклардан мәхрүм итү турында приговор чыгарган офицерлар, тикшерүчеләр акчалата бүләкләнә, паеклары арта, абруйлары тагын да югарыга күтәрелә.

Нәтиҗәдә, легионерларны гына түгел, гап-гади кешеләрне, бары тик дошманга әсир төшкән кызылармеецларны да төрмәгә ташый башлыйлар.

Пленда булган, иленә хыянәт итмәгән әсир солдатларның төп гаепләре, югарыда билгеләп үтелгәнчә, бары исән калуларында. Ике тапкыр фашистлар лагерыннан ычкынган, өченчесендә качып котыла ук алган, аннан соң да фашистларга каршы сугышкан Минзәлә егетен Татарстанга исән-сау әйләнеп кайткач: “Пленда булганнар арасында гаепсезләр юк, аны ачарга гына кирәк!” [3, б.14]-дип тотып япканнар.

Черек күлдә тагын бер ишле төркем җыела. “Революциянең канлы тырнагыннан чыгып ычкына алып, чит җирләргә барып урнашкан, гаилә корып, бала-чага үстереп яшәп яткан Рәсәй кешеләрен-мөһәҗирләрне нәкъ кырык сигездә төрмәләргә тутырырга тотынганнар” [3, б.14].

Шулай ук, бу чорда утызынчы-кырыгынчы елларда бер тапкыр утырып чыккан тотннарны да кабат җыя башлыйлар. Икенче тапкыр төрмәгә алынганнар арасында инженер Кулешов Аяз Гыйләҗевка аеруча тәэсир ясый. “Бер тапкыр җәһәннәмне кичеп, икенче кат төрмәгә эләккән кешенең шундый сабырлыгы, үз-үзен тотышы, горурлыгы, олысымаклыгы” [3, б.11] әдипне сокландыра. Элек утырып чыккан тоткыннарны ни өчен җыюлары студент егетне кызыксындырса да, ул әлеге сорауга җавап ала алмый. Инженер җавап урынына: “Монда нидер бар, студент! Моның тирән сере булырга тиеш!”-дип кабатлый [3, б.12].

“Ул җәйдә камера саен студент егет ябылган иде дисәм дә хак” [3, 23-24 б.], ди автор. Студентларның данлысы һәм мактаулысы Адлер Тимергалин була. Совет властеның явызлыгы, Сталинның кансызлыгы турындагы фикерләрен курыкмыйча тикшерүчеләрнең чырайларына бәреп әйткән өчен аны Арча кырындагы юләрләр йортына тикшерергә йөртәләр.

Мәшһүр тоткынарның икенчесе университетның юридик факультеты студенты Фролов була. Шулай ук әдип утыз алтынчы камерада университетның биофак студенты Михаил Хошәбәне дә очрата.

Бу коточкыч заманда югары мәктәпләрдә укучы, зиһеннәре, алдынгы фикерләре белән бүтәннәрдән әзме-күпме өстенрәк торган Гурий Тавлин, кебек яшьләрне дә “халык дошманнары” дип җәмгыятьтән аерганнар. Бүген дә зиһенне чуалта торган явыз табышмакның җавабы тирәндә, узган гасыр башындагы тарих сандыгында бикләнгән иде, тарихи документлар шуны раслый.

Коммунистларның тарихи XX съездында канлы тиран Сталинның кылган җинаятьләре фаш була башлагач, большевиклар хакимиятенең канлы Октябрьдән башлап санга-исәпкә сыймаслык явызлыклар эшләгәнлеге ачыкланырга тиеш булса да, тарихны бозып күрсәтү, тарихи җепнең өзек-өзек рәвештә бары тик фактларга гына кайтып калуы кешелек җәмгыятен бүгенге явызлыкка китереп җиткерде. Америка Президенты Рональд Рейган хаклы рәвештә Рәсәйне “Явызлык империясе” дип тамгалый. Әлбәттә, Рейганның тарихи гадел бәя бирүе белән күпләр, ягъни коммунистлар килешми. Чөнки, бу сүзләр аша большевиклар партиясенең, асылда, караклар,

ришвәтчеләр, талаучылар, үтерүчеләр, шымчылар һәм җәзалаучылар фиркасе икәнлеге ачык аңлашыла иде. Большевикларның планлы рәвештә террор куллануларының нигезен Ленинның бик күп хезмәтләрендә табарга була. Шул рәвешле, югарыда куелган күпсанлы сорауларның җаваплары да "бөек юлбашчының" томнарына һәм хатларына яшеренгән икәне һәркем өчен мәгълүм. XX гасырның 90 елларына кадәр Ленин хезмәтләре урта мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында мәҗбүри рәвештә үзләштерелде. Хәзерге көндә шушы томнарга салынган белем һәм тәрбияне алган буын ил белән җитәкчелек итә, яшь буынга белем бирә, күбесе үткән тормышның гаделлеген һәм рәхәтлеген сагынып искә ала. Документлар белән танышканда тагын бер гаҗәп сорау туа, аларда бит кешеләрне асарга, үтерергә, бер бөртек икмәкләрен калдырмыйча талап алырга, көч кулланырга боерылган үтә мәрхәмәтсез фикерләр әйтелгән. Ни өчен илнең зыялылары шуның белән килешеп яшәгәннәр икән? Димәк, моны ачык аңлаган кешеләрне төрмәләргә япканнар, ә укымышлыларны илдән куганнар. 1922 елның 19 маенда хәлләрне төрле яктан исәпләп язган хатында Ленин болай ди: "Һәммәсен төрле яктан үлчәп, профессорларның, язучы-әдипләрнең эш стажларына кагылышлы белешмәләр җитәрлек тупланганнан соңында гына илдән куу хакында карар кабул итргә" [3, 45 б.]. Шул рәвешле илне чистарту эшләре башлана. Акыллылар, тәрбиялеләр, эшлеклеләр илдән куылып китәргә тиеш, ә хөкүмәт башына, урыннардагы хакимият идарәләренә аз белемле, надан дөнья күрмәгән ярым ахмаклар, ялкаулар кереп урнаша. Шулай итеп, Рәсәй халыклар төрмәсенә әверелә. Автор утырган камераларның, тоткыннар ябылган башка читлекләрнең төрмә эчендәге төрмә икәнлеген исбатларга тулы мөмкинлек бар. Белемле, көчле шәхесләрнең ирекләрен чикләсәләр дә, ә менә надан крестьянның, совет власте дигәндә тезләнә торган, Ленинны, Сталинны, совет властен мактап йөзләрчә шигырь язган Мәҗит Рәфиков кебекләрнең дә төрмәдә булуы кабат фикер каршылыгы тудыра. Үзе белән крестьяннарның мул тормышта, Сталин биргән бәхеткә чумып яшәүләре турында бәхәс алып барган Мәҗит Рәфиковның төрмәдә булуына, әлбәттә, автор башта ышанмый. Ни өчен шушылай бер-берләренә капма-каршы фикер йөртүче һәм яшәү

рәвешләре, дөньяга карашлары белән дә бер-берсеннән нык аерылган кешеләрнең кулга алынулары турындагы сорауга да тарихи документлар аша җавап табарга мөмкин. Ленинның 1918 елның 11 августында Пенза коммунистларына язган хатыннан түбәндәгеләрне китерергә мөмкин: “Кулаклардан, байгуралардан һәм кан эчүчеләрдән иң кимендә 100 кешене асарга. Халык алдында асарга: күрсеннәр! Асылганнарың исемнәрен гәзитләрдә басарга! Асылганнарның бер бөртек икмәкләрен калдырмыйча алырга! Шулай эшләргә кирәк ки, йөз чакырымдагы тирә-юньдә халык дәһшәтеннән куркып дер калтырасын, коты чыксын, белсен һәм бугазын киереп акырсын: канэчкеч кулакларны буалар һәм буачаклар.

Ошбуның үтәлешен телеграф аша белдерегез.

Нык, каты куллы кешеләр табыгыз!” [3, б.44] Димәк, җитәкче өчен кемнең үлүе бөтенләй әһәмиятле түгел, ул бары тик саннар белән генә эш итә. Ләкин шул саннарның эчендә тере шәхес, җан булуы юлбашчыны да, аның фикерен дәвам итүчеләрне дә кызыксындырмый. Тарихны барлаганда бүгенге көнгә кадәр вакыйгаларның түгел, ә фактларның гына өстенлек итүе дә шуннан килә икәнлеге дә хәзер ачык аңлашыла.

Әсәр авторы соңгы вакытларда ачылган тагын бер гыйбрәтле документка туктала. 1940 елның җәендә Катынь урманында һәм якын-тирәләрдә НКВД әһелләре 21857 поляк офицерын атып үтерәләр. Поляк милләтенең каймагын кыралар һәм сатлык академик Бурденко белән аның яраннары “Поляк офицерларын немецлар атып үтерде”, дигән ялган нәтиҗә ясыйлар” [3, б.46]. Сәбәбе исә, “Полякларны юк итәргә!” дигән Политбюро карарына Сталин артыннан ук Калинин кул куйган һәм боерык тормышка ашырылган.

Хәзер инде Черек күл төрмәсенең ни өчен немец төрмәсеннән дә катырак булуы аңлашыла. Әлеге аяусыз дөреслекне автор түбәндәгечә аңлата. “Тентүчеләр шулкадәр остарган ки, дивардагы черки боты хәтле сызык та, ясмык бөртеге хәтле тап та алар күзеннән китми. Алар камераның астын-өстен ялап чыгалар. Мин укыган китапларда төрмә стенасында тулы бер архив саклана иде, шигырьләр язылган була анда, васыятьләр һ.б. Черек күл төрмәсендә мондый хәлнең булуы мөмкин түгел. Шәхси тентү шулкадәр мыскыллау белән үтә ки, чәч төпләреңне

аралыйлар, чүгәләргә боералар, артыңны туңкайтып, ярымшарларыңны аерып ыштан төбеңнән бүтән берни күрмәгән тирәнлекләрдә казыналар. Муса Җәлил Моабит төрмәсендә җәфа-газап чиккән. Шпандауда интеккән. Әгәр Муса Черек күлдә утырган булса, без аның сыңар шигырен дә эзләп таба алмас идек” [3, б.20-21]. Автор төрмәдәге мәрхәмәтсезлек аша, совет иле кешеләренең бер-берсенә карата булган вәхшилегенең фашизм явызлыгыннан да көчле булуын исбатлый. “Немец төрмәчеләре безнекеләр янәшәсендә сабый, өйрәнчек булып кына калалар түгелме соң? ... Кемдер, мактанырга теләп, Черек күл төрмә диварлары аша шакылдатып, борынгы алфавит белән хәбәрләр алыштык, дисә, ышанмагыз! Ялган! Черек күл-өч катлы, шактый зур төрмә. Ул кара төндә йөзеп барган караңгы кораб сыман, анда шалт иткән тавыш ишетелми, шакып кара бар! Төрмәнең юеш, салкын, кыргаяклы подвалларына очып төшүеңне сизми дә калырсың!..” [3, б.21]. Туганнары, абыйлары, балалары, ирләре төрмәдә бер гаепсез шушындый каты, газаплы җәфа чиккән вакытта, барлык совет кешеләре белән беррәттән, аларның якыннары да үзләренең “иң бәхетле совет илендә яшәүләре”, “Ленин сызган якты юлдан барулары”, “якты киләчәккә-коммунизмга барулары” турында “зур горурлык” белән “югары рухта” җырлап яшәделәр. Кешеләргә якты киләчәк вәгъдә иткән коммунизмның гаделсезлеген раслап, тарих фәннәре докторы Ә.Борһанов түбәндәгеләрне яза: “Илне, дәүләтне яулап алмаса, коммунизм-җәмгыять үсешенең тарихи закончалыкларына каршы килә торган, фәнни нигезләнмәгән буш хыял, “җирдәге оҗмах” хыялы гына. Ә инде, диктатура урнаштырып, ил-дәүләтне үзенә буйсындырган коммунистик режим-ул “җирдәге тәмуг”! Аның юлы гына игелекле ниятләр белән түшәлгән була. Иң зур куркыныч та әнә шунда. Кешеләр арасында һәрвакыт бу хыялны тормышка ашырырга тырышучы шәхесләр табылып торачак. Алар халыкны коммунизмга бару юлында мөмкин булган хаталар өчен борчылмаска үгетләячәкләр, “бер эш-гамәл кылмаганнар гына ялгышмый”, диячәкләр. Ә ул “хаталар” кан кою, төрмә-лагерьлар була икән, Бухарин әйтмешли, “яңа кеше” бары тик шулай гына тәрбияләнә ала да!” [1, б. 95]

Әлеге әсәрдә автор тагын бер аянычлы хәлне-ил күлмендә булган ачлыкны тетрәнеп сурәтли. “Илдә совет хакимияте урнашканнан бирле ачлык крестьян белән гел кочаклашып йөрде, үз тырнагыннан ычкындырмады ачлык авыл халкын” [3, б.61],- дип әрни ул. Кырда урылмыйча калган бер арыш, яисә бодай сабагын уып алган өчен хатын-кызларны төрмәгә озаткан җитәкчеләрнең җаннары гына түгел, фикерли, уйлый белү сәләтләре дә булмавын роман-хатирәдән ачык аңлыйбыз. Бер-бөртек ризык калдырмыйча, әзмәвердәй ирләрне, гүзәл затлар булып туган хатын-кызларны, киләчәкнең ышанычы булган гөнаһсыз, газиз балаларны бәрәңге сабагын боламык итеп ашарга мәҗбүр иткән дәүләткә ышану өчен акылның нинди булуы мөһим? А.Гыйләҗев язганнар шушы рәвешле уйланырга мәҗбүр итә. Әсәрдән аерылып, чынбарлыкка әйләнеп кайткач та, илгә ирекле шәхесләрнең кирәге булмау турындагы фикер рухны яралый. Нәтиҗәдә, югарыда әйтелгәнчә, тарихны бары тик фактик мәгълүмат чарасы итеп кенә өйрәнү һәм шуңа күнегү гасырлар буе сузылып килгән тарихи җепне өзек-өзек итеп кенә күзаллау кешелек җәмгыятен бер кайчан да гафу итәргә мөмкин булмаслык фаҗигаларга алып бара түгелме? Авторны да шушы сорау борчый. А.Гыйләҗевның төрмәдә күргәннәренә тирәнтен тукталмыйча, төрмәгә эләгүнең сәбәпләрен ачып биргән әлеге мәкаләдә кулланылган тарихи документлар да әсәрнең үзеннән алынды.

Фикерне йомгаклап әйткәндә, авторның “Йәгез, бер дога!” дигән роман-хатирәсе А.Гыйләҗевның әдәбиятыбызда һичкемгә охшамаган катлаулы әдип һәм көчле шәхес икәнлеген тагын бер кабат раслый.

Әдәбият

1. Борһанов Ә. Кем гаепле? Нәрсә эшләргә? / Ә.Борһанов // Казан утлары, 1998. - №6.- 93-111 б.

2. Госманов М. Аяз әкә сабаклары / М.Госманов // Татарстан яшьләре, 2003. – 16 январь. – 4 б.

3. Гыйләҗев А. Йәгез, бер дога! Роман-хатирә / А.Гыйләҗев. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1997. – 448 б.

4. Фәизов Р. Алда яктылык күренә / Р.Фәизов // Казан утлары, 1993. - №6. – 160-163 б.

Гали Г.Ф.

Принцип преемственности в обучении английскому языку.

Образование является одним из важнейших факторов развития человечества. Совершенствование способностей человека, повышение уровня профессиональной квалификации, воспитание культуры человека приобретает все большую значимость в современном мире. Поэтому на повестку дня поставлен вопрос, касающийся не только количественного, но и качественного образования. Нельзя не отметить, что знание языков становится все больше востребованным на данном этапе развития современного общества. Отмечается тенденция повышения общественной потребности в изучении иностранного языка. На наш взгляд это можно объяснить глобальными процессами, происходящими в мире: открытый европейский рынок предоставляет новые перспективы для образовательных предложений в изучении иностранного языка, а также, появился большой спрос на специалистов, владеющих иностранным языком. Понятно, что при этом качество процесса обучения должно улучшиться [1]. Но, как показывает педагогический опыт, важность реализации принципа преемственности в процессе преподавания иностранного языка в системе «школа-вуз» не осознана в полной мере. Педагогическая практика свидетельствует, что нарушение преемственных связей в обучении приводит к нерациональным затратам учебного времени, а также вызывает трудности в адаптации учащихся к вузовской системе обучения. Для системы народного образования важным является укрепление связей между отдельными ее звеньями, прежде всего, между средней и высшей школой. В связи с этим, необходимо отметить, что проблема преемственности в обучении очень актуальна в наши дни. *Перспективность и преемственность* – вот те черты, которые во многом определяют эффективность учебного процесса. Именно поэтому, в последние годы в образовательных учреждениях этой проблеме уделяется большое внимание. Как справедливо отмечал С.М.Годник: «Преемственность позволяет осуществлять обучение на высшем уровне трудности, не обрывая его ассоциативных связей. Она – профилактика таких разрывов. В этом заключается

важный конструктивный смысл преемственности, ее созидательный характер» [2, с.89].

Преемственность в обучении прослеживается в содержании, в формах и методах обучения, но мы будем рассматривать только преемственность в содержании учебного процесса. Попытаемся сформулировать основные пробелы учащихся в изучении английского языка. Для этого необходимо изучить уровень знаний учащихся. Нам кажется, что здесь целесообразно применять метод тестирования, как метод изучения. В связи с этим, нами было проведено тестирование в средних школах с углубленным изучением английского языка в 11-х классах. Научный интерес вызывают проблемы, связанные с выявлением типичных ошибок. Тест по английскому языку включал в себя такие разделы языка как орфография, лексикология, использование языка, грамматика. Приведем один из вариантов данного теста (примеры приводятся в сокращенном виде).

B - level

Test A

Spelling

1. Plural forms. Which 5 words in the list below have spelling mistakes?

knives mothers-in-law videos thiefs tomatos

leafs postmans heroes oxes carrots

2. The two words that are written after each sentence sound alike, but have different meanings and spellings (homophones). Fill in the blanks with the correct words to complete each sentence.

1) The…………..on a ………..is called fur.

a) hare b) hair

2) It is not…………if some people do not pay their bus……………

a) fair b) fare

3. the verb + ing. Choose the correct spelling.

1) to lie

a) lieing b) lying c) liying

4. Degrees of comparison. Choose the correct spelling.

1) late

a) later latest   b) latter latterest   c) latier latiest   d) laterer laterest

2) good

a) gooder best   b) gooder goodest   c) better best   d) goodier goodiest

5. Double the letter where necessary.

1) Why are you shout..ing at me?

2) Stop quarrel..ing about nothing!

6. Silent letters. Complete the spelling of the words by adding the silent letters.

1) An ..onest man never tells lies.

2) ..hose spectacles are these?

7. There is one spelling mistake in each line in the following text. Write the correct spelling in the space provided at the end of the line.

Have you ever thought that a person's apearance ___________________________

revels more than we realize? According to some ___________________________

experts, a persons' face, head, and body can ________________________________

reveal a great deal about personallity____

Vocabulary

1. Which one of the four answers has most nearly the same meaning as the word in bold. Circle the correct answer.

1) pretty **blossoms**

a) pictures   b) clothes   c)ribbons   d) flowers

2) measured **precisely**

a) easily   b) before   c) exactly   d) on all sides

2. Read each group of words. Cross out the word that does not belong with the others.

1) a) customer   b) complain   c) assistant   d) manager   e) cashier

2) a) seagull   b) pigeon   c) shark   d) eagle   e) peacock

3. "Do" or "make"?

a) do - b) make -

1. money
2. the garden
3. an effort

4. Synonyms. Match the words.

1. seashore a) simply
2. annual b) coast
3. merely c) coming once a year

5. Opposites. Match the pairs with opposite meaning.

1. bull a) innocent
2. grief b) joy
3. guilty c) cow

6. Definitions. Match the definitions and the words.

1. witness a) person who buys and sells wholesale or on a large scale;
2. currency b) a person or a thing able to give evidence;
3. merchant c) money in actual use in a country.

Use of English

1. Complete the passages using the words.

a) poisonous b) mysterious c) safety
d) glorious-looking e) dangerous f) thoughtful g) worse

Sometimes beautiful flowers might be (1) __________. You should be careful not to pick (2) _________ flowers when you go to a (3) _________ field or garden. Be (4) ________ and always think of your (5) __________.

A (6) ____________flower could be ninety times (7) __________than you think.

Grammar

1. Tenses. Put the verb in brackets into the correct tense.

1. Stamps ……in Post-offices. (sell)
2. When I ….the house yesterday, I ….some old love letters. (clean, find)
4. He …….tomorrow. (not come)
6. I …..never…..to Russia. (be)
7. He felt sick because he …….too much. (eat)
8. He ………letters since morning. (write)
9. We haven't decided yet, but we …………..of moving house. (think)

2. Give the degrees of comparison.
1. big
2. famous

3. Put some, any, much, or many into each gap.
1. Have you got ………brothers or sisters?
2. How ………money have you got?
3. There isn't…….petrol in the car.

4. Write questions to the following answers.
1. We were watching a football match at 9 o'clock.
2. I advise you to stop eating chocolate.
3. They gave Sandy a present.

5. Put in the right preposition. Some times no preposition is necessary.
1. I'm going to Madrid ……the afternoon.
2. I'm waiting …..you.
3. What are you doing ……this evening?
4. He's interested …. languages.

6. Put in a, an, the , or nothing.
1. Where's ….nearest shop?
2. Do you often listen to …radio?
3. ….sky is very clear tonight.
4. Last year we had …..wonderful holiday.

7. Complete the following sentences.
1. If it rains this afternoon, we …….. . (stay at home)
2. If I ………to Egypt I will see the pyramids. (go)

8. Write reported speech.
1. "I don't like people shouting at me." (He said)
2. "Are you a doctor?" (She asked)
3. "What do you have for dinner?" (He asked)

9. Put must, have to, can, could, may, might or should.
1. …..you tell me the time, please?
2. Where will he go on holiday? I don't know. He ……go to Italy.
3. He ………to go to work five days a week.

Интересно анализировать количество ошибок по разделам. Приведем некоторые данные исследования по количеству ошибок в следующих явлениях: орфография - 52%; лексикология - 54%; использование языка – 71%; грамматика – 66%.

Данный анализ помогает нам сделать вывод о некоторых типичных ошибках, допускаемых учащимися в процессе изучения английского языка. Среди них можно выделить следующие группы: орфографические, логические и грамматические ошибки. Например, к наиболее распространенным речевым ошибкам можно отнести непонимание значения слова, в употреблении синонимов, фразеологизмов. Грамматические ошибки – это несоблюдение норм слово- и формообразования, норм синтаксической связи между словами в словосочетании и предложении, неправильное употребление времен. Например, учащиеся неправильно подбирают синонимы, неточно выбирают дефиниции к предложенным словам, ошибаются в формировании и употреблении времен и т.д.

Как показывает анализ тестов, выпускники средних школ недостаточно владеют как навыками правильной устной речи, так и нормами английского языка. Очевидно, что необходимо составление дополнительных методических пособий по английскому языку для студентов первого курса, которые помогут преодолеть трудности в изучении языка.

Литература:

1. Митрюхина М.С. Преемственность формирования коммуникативной культуры в процессе преподавания иностранного языка (в системе «школа- ссуз-вуз): дис. …канд.пед.наук./М.С.Митрюхина.-Казань, 2005.-170с.

2. Годник С.М. Процесс преемственности высшей и средней школы. – Воронеж: Изд-во Воронежского университета, 1981. - 208с.

3. И.И.Кошманова. English. Tests. – М.: «Издат-Школа», 1998. – 224с.

Гараева Л. Ф.

Татарская периодическая печать начала XX века и ее роль в функциональном развитии татарского языка.

Начиная с 1905 г. появляется большое число газет и журналов на татарском, язык которых все больше приближается к разговорному. Упрощенный «тюрки» постепенно входивший, прежде всего, в обиход начальной школы, называясь в некоторых

учебных хрестоматиях «материнским» языком, применяется все в большей степени и в газетных статьях.

Газеты и журналы предъявляют к языку прежде всего требование понятности. Рубрики татарских печатных изданий, их лексика, тематика отражают существенные черты развития татарского языка.

Проводимые различные культурные и общественные мероприятия, находя свой отклик на страницах периодической печати, способствовали укреплению позиций собственно татарского языка. Например, единственным требованием организованных в 1908-1910 годах журналом «Шура» языковых соревнований - «тел ярышы», было «...писать о чем угодно, но только на чисто татарском (төрки телдә) языке» Подобные соревнования организовывались и на страницах таких газет, как «Нур» [1905.—№8], «Йолдыз» [1906.—15, 22 фев.], «Ахбар» [1907.—№6-8].

Сближение литературного языка с народно-разговорным для всех выдающихся представителей татарской культуры начала XX века, среди которых следует назвать Г.Тукая, Г.Исхаки, М.Бигиева, братьев Максуди, М.Гафури, Ф.Амирхана, Г.Ибрагимова, Ш.Камала, С.Рамиева, Дж.Валиди и мн. др., было стратегической целью и они своими научно-публицистическими заметками и статьями всячески в этом участвовали.

Периодическая печать стала также решительным толчком в развитии татарской литературы. На страницах газет и журналов наряду с известными писателями выступают и молодые силы, которые, набирая опыт и мастерство, в скором времени начинают играть ведущую роль в литературном процессе. В своей первой газете «Эль-ислах» («Реформа»), выходившую с 29 ноября 1905 года (до 3 октября 1907 года они выпускали газету нелегально), шакирды размещали серьезные работы по изучению истории татарской литературы, например, большую статью-исследование Ф.Амирхана «Әдәбиятка гаид» («Имеющий отношение к литературе»). Здесь были напечатаны первые рассказы Г.Ибрагимова—такие, как «Зәки шәкертнец мәдрәсәдән куылуы» («Изгнание Заки-шакирда из медресе»). От внимания газеты не ускользала ни одна новая книга, ни одно значительное событие культурной жизни татар. Не обходила она и женский вопрос,

сильно волновавший в то время татарскую общественность. На ее страницах велся постоянный отдел «Хатын-кыз галәме» («Мир женщин»), где систематически публиковались письма читательниц. Редакция широко пропагандировала передовую русскую культуру и классическую литературу.

Писатели и поэты, работавшие или сотрудничавшие в редакциях журнала «Шура» и газеты «Вакыт», внесли большой вклад в развитие татарской литературы, публицистики и литературной критики. Среди них весьма интересно творчество Дердмэнда, все стихотворения которого печатались на страницах «Шура». В этом журнале сделали свои первые литературные шаги Мирхайдар Файзи, Зия Ярмаки, Ибрагим Башмаков, Хабиб Исхаки, Зайнаб Сагиди, Абрар Сагиди, Шайхзада Бабич и многие другие.

В журнале «Шура» и газете «Вакыт» публиковались талантливые произведения, общественно-политические и публицистические статья Ш.Камала и Г.Ибрагимова, созданные в годы реакция и нового революционного подъема. Среди них можно отметить рассказы «Уяну» («Пробуждение»), «Буранда» («В буран»), «Бәхет эзләгәндә» («В поисках счастья»), «Кычкырыш» («Ссора») Ш. Камала; «Карт ялчы» («Старый батрак»), «Диңгездә» («В море»), «Йөз ел элек» («Сто лет тому назад»), «Уты сњнгән җәһәннәм» («Потухший ад») Г.Ибрагимова. Рассказы и стихотворения других авторов также значительны актуальностью тематики и реалистическим изображением характерных сторон жизни татарского народа. Среди подобных материалов следует назвать стихотворения «Татар хатыны» («Татарская женщина») С.Сунчаляя с эпиграфом из Н.А.Некрасове и «Ятимә» («Сирота»), напечатанное за подписью «Чала татар» [*Гайнуллин* ,1983, с.75-77].

Редактором журнала «Шура» состоит известный татарский писатель Р.Фахретдинов; издатели - братья Рамиевы, собственники газеты «Вакыт». «Шура» размещает исключительно научно-популярные по педагогике, истории статьи. Как бы извиняясь перед некоторой частью читателей за возможную степень сложности для их восприятия, редактор журнала в конце одной из своей статей «Инсанның шаны гали булуы хакында» («О величии достоинства человека») [Шура.—

1914.—№23.—719] обращает их внимание на другие, более доступные для их уровня, публикации: «"Шура" укучылар арасында бик сәламәт вә һәрнәрсәне сеңдерелек дәрәҗәдә көчле мигъдәге малик адәмнәр бар. Шул кешеләргә бу мәкаләне һәдия итәмез. Мигъдәләре зәгыйфь булган адәмнәр моның урынына башка бер жиңелрәк ләзем кылына торган мәкаләләрне укырлар» [*Мәрданов* ,2001, с.29].

Журнал «Эль-гаср-эль-джадид», во главе которого во все время его деятельности стоял видный татарский издатель Камиль Мутыги-Тухватуллин, широко также публиковал и художественную прозу, отдавая предпочтение рассказам. Среди этих материалов можно назвать рассказ «Явызлык» («Злость») (№ 6, 1906 г.), вторую часть книги «Тутам» («Моя тетя»), «Мокаясэ» («Сравнение»), «Гузәл тәрбия» («Прекрасное воспитание») и ряд других. Эти произведения стоят в преддверии татарской реалистической прозы, и потому знакомство с ними представляет определенный интерес. Кроме «Эль-гаср-эль-джадид» представитель прогрессивной татарской общественности К.Мутыги-Тухватуллин сумел в те тяжелые годы, не владея большими материальными средствами, организовать издание еще одного журнала «Уклар» («Стрелы») и двух газет «Фикер» («Мысль») и «Уралец», одновременно являясь их ответственным редактором. Его энергичная деятельность в области журналистики способствовала развитию татарской поэзии, прозы, литературной критики. Но Г.Тукаю и другим демократическим деятелям, сотрудничавшим в журнале, недолго пришлось издавать «Эль-гаср-эль-джадид». Пятый номер журнала, вышедший 25 мая 1907 года, оказался и последним.

Первые шаги в создании сатирико-юмористического издания сделал и Г.Тукай. Вместе с Камилем Мутыги-Тухватуллиным поэт начинает издавать иллюстрированный сатирический журнал «Уклар» («Стрелы»), который в известной мере можно считать сборником сатирических произведений Тукая, так как большая часть помещенных в нем материалов принадлежала поэту. Первый номер его вышел в свет в июне 1906 года в Уральске.

Традиции «Уклар» продолжил журнал «Карчыга» («Ястреб»), начавший выходить с сентября 1906 года в Оренбурге. Издание его было организовано известным татарским писателем и публицистом Ш.Мухамедовым. Задачи журнала были определены так: «Карчыга» ставит своей целью защиту интересов рабочего народа, приказчиков и конторщиков, живущих своим трудом, и непримиримую борьбу против капитализма» [*Гайнуллин,* 1983, с.53].

Вскоре после того, как появились первые газеты на татарском языке, под названием «Нур» («Луч») и «Казан мөхбире» («Казанский вестник»), выходившие с сентября и октября 1905 года в Петербурге и в Казани соответственно, этот процесс приобретает большой размах и периодические издания начинают выходить во всех регионах, где компактно проживают татары. По данным И.Рамиева, количество названий газет и журналов, печатавшихся до революции 1917 года, достигает до ста [*Рәмиев,* 1926].

С целью пропаганды нового метода преподавания, обновления общественной жизни и повышения самосознания народа, а также для обеспечения более быстрого и широкого распространения реформаторских идей в школьном деле Г.Баруди основывает журнал «Ад-дин вә аль-әдәб» («Религия и этика», 1906-1908, 1913-1917). Кроме педагогических вопросов, автор журнала стремился поставить и решить целый комплекс проблем, связанных с духовным возрождением татарского народа. Это вопросы экономического развития народа, равноправия женщин, женского образования, задачи создания единого общетюркского языка и др. [*Юсупов* ,2003, с.52].

Татарскую периодическую печать тех лет М.Гайнуллин условно разделяет на демократическую, либерально-умеренную и буржуазно-консервативную. В первую группу причисляет газеты «Азат», «Азат халык», «Фикер», «Эль-ислах»; во вторую — газеты «Казан мөхбире», «Йолдыз», «Вакыт», «Идель», журнал «Шура» и др.; в третью — газеты «Нур», «Иль», «Сњз», журнал «Дин вә мәгишат» и другие [Гайнуллин,1983, с.89].

Еженедельное издание «Казан-Мөхбире» («Казанский Вестник») существует исключительно перепечатками из других газет и журналов, внося свой вклад в развитие татарского языка в

сфере переводческой деятельности. Газета в подборе материала, так же как и «Йолдыз» («Звезда»), стойко выдерживала татаро-тюркскую направленность. Основная идея Х.Максуди, редактора газеты «Йолдыз», заключавшаяся в том, что в авангарде единения тюркских народов должны идти казанские татары с «их» языком «заказанского» наречия, отражалась и в публикуемых на страницах его газеты материалах.

Список периодической печати на татарском языке:

Бәянелхак, 1906—1911 гг.

Вакыт, 1906 гг.

Йолдыз, 1907, 1915 гг.

Казан мөхбире, 1906—1911 гг.

Кояш, 1915 г.

Милләт, 1913—1915 гг.

Шура, 1909—1911 гг.

Литература:

Гайнуллин 1983 — *Гайнуллин М.Х* Татарская литература и публицистика начала XX в. — Казань:

Мәрданов 2001 — *Мәрданов Р.Ф.* «Шура» журналы (1908-1917): әдәбият мәсьәләләре. — Казан: Рухият, 2001. — 152 б.

Рәмиев 1926 — *Рәмиев И.* Вакытлы татар матбугаты. — Казан: «Гажур», 1926. — 331 б.

Юсупов 2003 — *Юсупов М.Х.* Галимджан Баруди. — Казань: Тат. кн.изд-во, 2003. — 208 с.

Гәрәева Л.З.

Татар телендә исем фигыльнең килеш белән төрләнүе.

Хәзерге татар әдәби телендә фигыльләрнең үзенчәлекле категориясенең берсен исем һәм фигыль билгеләренә ия булган форма – **исем фигыль** тәшкил итә. Исем фигыльнең семантикасында иң мөһиме – наклонениягә һәм заманга бәйләнмәгән эш-хәрәкәтне, халәтне, процессны белдерү. [Татар грамматикасы. – Т. 2, 115 б.]. Татар телендә исем фигыльнең берничә формасы бар: **-у/-ү, -ганлык/-гәнлек, -ш, -ыш/-еш** һәм **-мак/-мәк** кушымчалары ярдәмендә ясалган формалар.

Исем фигыльләрнең грамматик категорияләренә мөрәҗәгать итсәк, алар үзләрендә фигыль үзенчәлекләрен дә, исем билгеләрен дә берләштерәләр. Фигыль билгеләреннән юклык һәм эшнең үтәлеш дәрәҗәсен белдерә торган кушымчаларны алалар, юнәлеш категориясе белән төрләнәләр; исем билгеләреннән килеш, сан, тартым категориясе белән төрләнәләр.

Килешләр сүзләрне бәйләп, аларны үзара төрле синтаксик мөнәсәбәткә куялар. Килешнең бу үзенчәлеге исем фигыльләрдә дә чагылыш таба. Килеш тартым категориясе белән тыгыз бәйләнештә тора. Тартым кушымчасын алган исем фигыльләр еш кына килеш белән төрләнәләр.

I. -у/-ү формалы исем фигыльнең килеш белән төрләнүе

-у/-ү формалы исем фигыль барлык килешләр белән дә төрләнә һәм җөмләдә төрле функцияләр үти ала.

1. **Баш килештә** ул түбәндәге функцияләрне башкара:

- Тартым кушымчаларыннан башка килеп, субъекттан аерылган эш-хәлнең, процессның, халәтнең атамасын белдерә һәм җөмләдә ия булып килә:
- Тартым кушымчалары белән килеп, билгеле бер субъектка бәйле эш-хәлнең, процессның, халәтнең исемен атый һәм җөмләдә, шулай ук, ия булып килә.
- Җөмләдә аергыч функциясен үти. Исем фигыль изафә конструкциясенең беренче компоненты булып килә, ә аерылмыш исә тартым кушымчасын ала. Бу очракта исем фигыль предмет яки затны эш-хәл яки халәт буенча характерлый: *Адәм баласын **кырыкка төрләндерү ысуллары** бар Черек күл хөкемдарлары кулында [А. Гыйләҗев, 22 б.].*
- Кайбер очракларда предикатив функцияне үтәп, җөмләдә хәбәр булып килә: *Аның исәбе гаепләнүче белән шаһитны күзгә-күз **сөйләштерү иде** [Г. Ибраһимов, 63б.].*
- -у/-ү формалы исем фигыль *бар, юк* модаль сүзләре белән бергә килеп, эш-хәлнең, процессның, халәтнең булу-булмавын белдерә.

2. **Иялек килешендәге** -у/-ү формалы исем фигыль түбәндәге функцияләрне башкара:

- Җөмләдә аергыч ролендә килә ала. Бу очракта ул аерылмышның тартым белән төрләнүен таләп итә.
- Объект мәгънәсен белдереп, җөмләдә тәмамлык булып килә: *Бер тапкыр да кычкырып **көлүнең** ни икәнен белмәгән, дөньяда менә шушындый туганнары да булмаган ул бала ни эшләр икән тормышта? [Ф. Амирхан, 147 б.].*

3. **Юнәлеш килеше** белән төрләнгән исем фигыль түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

- Тартым кушымчасыннан башка килгәндә, ул субъекттан аерылган объект мәгънәсен белдереп, җөмләдә тәмамлык булып килә: *Икенче мәртәбә карады: үзенең әнисенең кодагые шул **булуга** ышанмады [Г. Исхакый, 258 б.].*
- Юнәлеш килешендәге исем фигыль, тартым белән төрләнеп, субъектка бәйле объект мәгънәсен белдерә ала һәм җөмләдә тәмамлык функциясендә килә.
- Сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен белдереп, җөмләдә сәбәп хәле булып килә: *Боларның һау-һаулап **йөрүләренә** хуҗа үзе дә уянды [М. Мәһдиев, 35 б.].*
- Төп фигыльгә кадәр үтәлгән эш-хәлне, процессны, халәтне белдереп, җөмләдә вакыт хәле булып килә: *Спектакль **бетүгә**, артисларның баш ияргә чыгуларын да көтеп тормыйча, ул тизрәк ишеккә ташланды [Г. Кутуй, 100 б.].*

4. **Төшем килешендәге** исем фигыль түбәндәге функцияләрне башкара:

- Тартым белән төрләнмәгән очракта, субъектка карамаган туры объект мәгънәсен белдереп, җөмләдә тәмамлык булып килә.
- Төшем килешендәге исем фигыль, тартым белән төрләнеп, субъектка бәйле булган туры объект мәгънәсен белдерә. Җөмләдә тәмамлык булып килә.

5. **Чыгыш килешендәге** исем фигыль түбәндәге функцияләрне үти:

- Тартым кушымчасыннан башка, субъектка бәйле булмаган объект мәгънәсен белдереп, җөмләдә кыек тәмамлык функциясендә килә: *Бу йортта тел **яшерүдән** файда юк [А. Гыйләҗев, 9 б.].*

- Тартым кушымчалары алып, субъектка караган объектны белдерә һәм җөмләдә кыек тәмамлык булып килә.
- Сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен белдереп, җөмләдә сәбәп хәле булып килә: *Сәгыйдә, ата-анасыннан **оялудан**, күзен итәгеннән күтәрмәде [Г. Исхакый, 261 б.].*

6. **Урын-вакыт килешендәге** исем фигыль түбәндәге функцияләрне башкара:

- Эш-хәлнең үтәлү вакытын белдереп, җөмләдә вакыт хәле була: *Хатларны бер **күрүдә** барысын да аңлады, агарынып, күгәренеп китте [Г. Бәширов, 95 б.].*
- Объект мәгънәсен белдереп, җөмләдә кыек тәмамлык ролен үти.

II. -ыш/-еш формалы исем фигыльнең килеш белән төрләнүе

-ыш/-еш формалы исем фигыль килешләрдән, күпчелек очракларда, баш, юнәлеш килешләре белән, сирәгрәк – чыгыш һәм урын-вакыт килешләре белән төрләнә.

1. **Баш килештә** -ыш/-еш формалы исем фигыль түбәндәге функцияләрне башкара:

- Тартым белән төрләнмичә, субъекттан аерылган эш-хәлнең, процессның, халәтнең атамасын белдерә һәм җөмләдә ия булып килә: *Алгач, ялгыз-ялгыз эшләүдә **табыш** юк, дим [Г. Ибраһимов, 91 б.].*
- тартым белән төрләнеп, субъектка бәйле эш яки хәлнең атамасын белдерә, җөмләдә ия функциясен башкара.

2. **Юнәлеш килешендә** килеп, -ыш формалы исем фигыль түбәндәге функцияләрдә кулланыла:

- Объект мәгънәсен белдерә һәм җөмләдә кыек тәмамлык булып килә: *Кара керфекле коңгырт күзләренең чәчеп **карашында** дуслык һәм мәхәббәт билгеләрен күреп була иде [Ф. Әмирхан, 59 б.].*
- Вакыт мәгънәсен белдереп, җөмләдә вакыт хәле функциясендә килә: *Капкадан **чыгышка**, конвойның күзе кисешкән мәйданчыкта бишәр-бишәр тезелдек без [А. Гыйләҗев, 215 б.].*

3. -ыш формалы исем фигыль **урын-вакыт килешендә** килеп, объект мәгънәсен белдерә һәм җөмләдә кыек тәмамлык функциясен башкара: *Кояшның болай алланып* ***чыгышында*** *ул үзенә ниндидер юану тапты [Ә. Еники, 67 б.].*

III. –мак/-мәк формалы исем фигыльнең килеш белән төрләнүе

-мак/-мәк формасы татар телендә киң кулланылмаган. Килешләрдән ул, күпчелек очракта, баш һәм чыгыш килешләре белән төрләнә, иялек килеше белән төрләнүе күзәтелмәде.

1**. Баш килештә** килеп, -мак/-мәк формалы исем фигыль түбәндәге функцияләрне башкара:

- Эш-хәлнең, процессның, халәтнең атамасын белдерә һәм җөмләдә ия булып килә: *Лязем түгел инсаф, вөҗдан – бер данә дә, Һич кирәкми гайрәт итмәк, мәрданә дә [Г. Тукай, 45 б.].*
- Предикатив функцияне үтәп, җөмләдә хәбәр була.
- Объект мәгънәсен белдереп, җөмләдә кыек тәмамлык функциясендә килә.
- Предмет яки затны эш-хәл яки халәт буенча характерлый һәм җөмләдә аергыч ролендә килә.

2. **Юнәлеш килешендә** –мак/-мәк формалы исем фигыль инфинитив функциясен үти.

3. **Төшем килеше** белән төрләнеп, -мак/-мәк формалы исем фигыль туры объект мәгънәсен белдерә һәм җөмләдә туры тәмамлык функциясен үти.

4. **Чыгыш килеше** белән төрләнгән –мак/-мәк формалы исем фигыль түбәндәге функцияләрне башкара:

- объект мәгънәсен белдерә һәм җөмләдә кыек тәмамлык булып килә: *Йөзәдер аркылы, буйга, - котылмактан өмид өзми [Г. Тукай, 54 б.].*
- Сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен белдереп, җөмләдә сәбәп хәле була.

5. Урын-вакыт килешендәге –мак/-мәк формалы исем фигыль объект мәгънәсен белдереп, җөмләдә кыек тәмамлык була.

IV. -ганлык/-гәнлек формалы исем фигыльнең килеш белән төрләнүе

-ганлык/-гәнлек формалы исем фигыльләр, урын-вакыт килешеннән тыш, барлык килешләр белән төрләнә ала һәм киләсе мәгънәләрне белдерә:

1. Баш килештә тартым белән төрләнмичә, субъекттан аерылган процессны атый.

Баш килештә, тартым белән төрләнеп, субъектка бәйле процессны атап килә ала*: Бу иптәшнең шатлыгы зур **булганлыгы** әллә кайдан күренеп тора [Г. Бәширов, 98 б.].*

2. Иялек һәм **юнәлеш килешләрендә** дә -лык кушымчасы процессны ныграк предметлаштырып, объект мәгънәсен белдерә*: Ул үзенең улы Әхмәтне миссионер дип белеп шулкадәр кайгырган һәм **елаганлыгына** гаҗәпләнергә дә, гаҗәпләнмәскә дә белмәде [Ф. Әмирхан, 125 б.].*

3. Төшем килешендә объект мәгънәсен белдерә һәм җөмләдә туры тәмамлык булып килә*: Якуб үзенең нинди максат белән килгәнлеген әйтеп, үткән хәлләрне сораштырырга тотынды [И. Гази, 125 б.].*

4. Чыгыш килешендә -ганлык формасы, кагыйдә буларак, сәбәпне белдерә*: Ир-ат булмаганлыктан, Рахмановлар гаиләсе иманадан бөтенләй төшерелеп калдырылды [Ф. Хөсни, 145 б.].*

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: –мак/-мәк һәм –ыш/-еш формалы исем фигыльләр хәзерге татар әдәби телендә аз кулланылу сәбәпле, килешләр белән дә сирәк төрләнәләр. Ә телдә актив кулланылышта йөргән –у/-ү һәм –ганлык/-гәнлек формалы исем фигыльләр килеш категориясе белән актив төрләнеп, төрле мәгънәләр белдерәләр. Шул рәвешле телне баетуга һәм камилләштерүгә үз өлешен кертәләр.

Әдәбият

1. Татар грамматикасы: 3 томда. – Т. 2: Морфология. – М.: Инсан; Казан: Фикер, 2002. – 448 б.
2. Татар грамматикасы: 3 томда. – Т. 3: Синтаксис. – М.: Инсан; Казан: Фикер, 2002. – 451 б.
3. Ганиев Ф. А. Вопросы морфологии татарского языка / Ф. А. Ганиев. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. – 81 с.

4. Тумашева Д. Г. Татарский глагол: Опыт функионально-семантических исследований грамматических категорий: Учеб. пособие / Д. Г. Тумашева. – Казань: Изд-во КГУ, 1986. – 189 с.
5. Юсупов Ф. Ю. Изучение татарского глагола / Ф. Ю. Юсупов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. – 286 с.
6. Юсупов Ф. Ю. Морфология татарского диалектного языка: категории глагола / Ф. Ю. Юсупов. – Казань: Фэн, 2004. – 592 с.
7. Юсупов Ф. Ю. Неличые формы глагола в диалектах татарского языка / Ф. Ю. Юсупов. – Казань: Изд-во КГУ, 1985. – 320 с.

Гобәйдуллин Л.И.

«Икътисад» журналында (1908-1913) авыл халкының социаль -көнкүреш проблемаларының чагылышы

ХХ йөз башы татар иҗтимагый һәм икътисади фикерендә төп чыганак, матди база итеп табигать һәм җир, аны хәрәкәткә китерүче көч итеп кеше акылы, дөньяга карашлары үзәк урынны алып тора. Авылларда җир, игенчелек, терлекчелек, бакчачылык, һөнәрчелек һәм умартачылык проблемаларын хәл итү белән бергә авыл халкының башка төр социаль проблемаларын хәл итү һәм авылларны киң планда үстерү проблемалары турында да уйланыла. Чөнки татар халкының күпчелек өлеше авылда яшәгәнлектән, авылларның социаль-көнкүреше турында уйлау, татар халкы, аның киләчәген кайгырту дигән сүз. «Икътисад» журналы авторлары бу проблеманы хәл итүдә ике юнәлештә эшлиләр: аның беренчесе шул чордагы авыл кимчелекләрен күрү һәм тәнкыйтьләү, анализлау; икенчесе шушы проблемаларны хәл итү юлларын күрсәтү, халыкны мәгълүматлаштыру.

ХХ йөз башы татар иҗтимагый фикерендә тәнкыйди реализм үсеш ала. Бу әдипләр, журналист-публицистлар, җәмәгать эшлеклеләре мәкаләләрендә, әсәрләрендә чагылыш таба. Татар халкы көнкүреше, хуҗалыгында барган күренешләр дә тәнкыйть утыннан читтә калмый. Бу очракта авыл халкы өчен хас булган социаль проблемлар бөтен милләт контекстына куела. Иҗтимагый фикер үз халкына җәмгыятьнең социаль-икътисадый торышын күзгедән күрсәтергә тиеш була. Халык хуҗалыгына, аның икътисади әхвәленә нисбәтле авыл, милләт юкка чыгу этаплары,

сәбәпләре өйрәнелә, шул ук вакытта килеп туган ситуациядән ничек чыгарга дигән сорау куела һәм җавап эзләнелә.

Авыл халкының артта калуына йогынты ясаган беренче иң зур фактор, милекнең булу-булмау мәсьәләсе. Аллаһы Тәгаләнең нигъмәте булган мал, милек бөтен тормыш-көнкүрешнең нигезе, тереклекнең сихәте буларак анализлана.[1] Халыкны инкыйразга, авыл халкының бетүенә төп сәбәпләрнең берсе булып икътисад кагыйдәләрен белмәү тора.[2] Милләтнең ихтыяҗын канәгатьләндерерлек продукцияне читтән алмыйча, үзенекен куллану, икътисадның, матди җитештерүнең нигезен тәшкил итә. Нәкъ менә шуның өчен «Икътисад» журналы авторлары авылларның икътисадын үстерүне максат иткәндә аның эчке потенциаль мөмкинлекләрен, егәрен күздә тота һәм шуңа таянырга чакыралар.

Өченче төп сәбәп - авыл халкының фәкыйрьлеге. Фәкыйрьлек Русия мөселман авыллары арасында бик киң таралган була. Нәкъ менә фәкыйрьлек аркасында наданлык, исереклек, бозыклык, зиначылык кебек гамәлләр авылларда тарала. Журналда фәкыйрьлек таралуның сәбәпләре өйрәнелә. Ул сәбәпләр түбәндәгеләр: 1) авыл халкы арасында исереклек һәм отыш уены кебек гамәлләрнең күп таралуы. Авыл ярминкәләрендә, сабантуйларында, отыш уены уйный торган җирләрдә өелеп уйнаулары; 2) авыл халкында киләчәкне кайгыртуның булмавы, халык иген яхшы уңса, киләсе елга орлык калдырмыйча сатып бетергән, аннан кергән акчага кәсеп итеп, аны арттыру турында уйламаган; 3) авыл халкында һөнәрчелекнең начар үскән булуы; 4) безнең халыкта ике карендәш, хәтта ата белән угыл да бергә тора алмавы. Моның сәбәбе күбрәк ике килен яки килен белән каен ана аралары бозылуда чагыла. Туй үткәрү өчен атамы ул, угылмы, әллә никадәр мал сарыф итеп, бөтен игеннәрен сата яки бурычка керә торган булган, я булмаса, бер кешегә әллә ничә айлар эшләрлек эш алган. Шуңа бүрә бүленү һәр ике тарафның фәкыйрьләнүенә сәбәп булган.[3]

Авыл халкының фәкыйрьлеге этнографик детальләрдә дә чагылыш таба. Кайчандыр күчмә шартларда яшәп, соңыннана утрак тормышка күчеп, чит халык тарафыннан яулап алынган халык өчен аякка чабата кию, сыер һәм бозауны өйләргә кертеп, шулар нәҗесе арасында ашау-эчү, өйләрнең түбәләре салам белән

ябылу кебек күренешләр гаҗәп тоела.[4] Бу күренешләр татар халкы арасында төрле тарихи шартларда туган. Ул рус культурасы йогынтысында аякка чабата кию, терлекчелек-малчылык традицияләреннән ераклашу, тире сәүдәсе һәм аны эшкәртүдәге проблемаларның кискенләшүе, урман һәм җир проблемалары турында сөйли. Йортларның кечкенә булуы, салам белән ябылуы, араннарның булмавы урманга хокук проблемасының актуальлегенә мисал булып тора.

Дүртенче төп сәбәп милекне тота белмәү һәм аны исраф итү. Бу саналып үтелгән сәбәпләрнең беренче һәм икенче пунктлары белән берникадәр охшаш. Алда ул игенчелек һәм гореф-гадәтләргә бәйләнештә каралса, монда татар халкының этник сыйфаты - кунакчыллыкка бәйле. Әлбәттә, бу борынгыдан килүче, татар халкының этник йөзен билгеләүче сыйфат. Әмма ул чамадан тыш артып киткәндә икътисад һәм ислам дине кануннарына каршы килә. «Икътисад» журналы битләрендә Түнтәр авылыннан Габделбари Үтәви язып җибәргән хатка анализ ясала. Мөхтәбәр кешеләр килгәндә, бәйрәм көннәрендә авылларда көнгә унлап, хаттә кырыклап җирдә аш хәзерләнеп һәр кайсында кунак төшә, бер авылда гына дүрт көн эчендә 200 ләп өйгә кереп чыккан кешеләр барлыгы языла. Кунаклар хөрмәтенә биш-ун мәчет-мәдрәсә салынырлык акча тотылганлыгы тәнкыйтьләнә. Журнал редколлегиясе фикеренчә, моның кадәр акчаны җыеп яртысын хөрмәтле кешегә бирелсә, яртысы мәгариф юлына сарыф ителсә, ике якка да файдалы булыр иде.[5]

Бишенче сәбәп – авыл халкына төрле шәхесләрнең тискәре йогынтысы. Бер шәкерт читкә чыгып йөри башласа, авылда көнкүреш эшен башкаруны үзенә кабәхәт эш дип санавы тәнкыйтьләнә. Халык арасында файдалы нәрсәләр сөйләсе урында ул тискәре якларны күпертеп күрсәтә. «Алар кулында курчак кебек уйнаган авыл халкы ничек фәкыйрьлектән котылсын, ничек баю юлын күзәтсеннәр!»- дип авыл эшен кайгыртучы вәкилләр тәнкыйтьләнә, аларның авыл үсешен тоткарлаулары риторик өндәү җөмләләрдә күрсәтелә. Авылларда халык, милләт өчен хезмәт итә торган кешеләрнең җитмәгәнлегенә басым ясала. «Эшләр фәкать берничә кешенең хәтере өчен яки эшләүченең шәхси мәнфәгатьләре өчен эшләнәдер, арада гаиләләренең ихтыяҗын әйтә алмаган, эчеп-исереп йөрүчеләр, сабый балаларны

хезмәт итәргә алучылар, хаттә аларны теләнчелеккә мәҗбүр итүчеләр дә бар»,-дип языла.[6] Нәтиҗәдә, авыл үсешен тоткарлаучы факторлар итеп социаль-икътисади, психологик, әхлакый һәм шәхес факторлары күрсәтелә.

«Икътисад» журналы авторлары авылларны ничек үстерергә дигән сорауга да җавап эзлиләр. Моның өчен иң беренче эш итеп халыкны тәрбияләргә, аларга юл күрсәтүче шәхесләрне хәзерләргә кирәклеге әйтелә.[7] Инсан бер эшне башлап җибәрсә, ул максатына ирешәчәк. Иң мөһиме фикер кузгалту, нәсихәт сөйләү, тормышны тәнкыйтьләү кебек эшләргә аерым кешеләрнең алынуы кирәклегенә басым ясала. Иген игү, хайван асрау, кошлар тәрбияләү, бакча үстерү, болыннарны яхшырту, балык тоту, сөтханә ачу, янмаслык биналар салу, җир сукалау, кул һөнәрләрен авыл халкына өйрәтүче, башлап эшләп күрсәтүче шәхесләр кирәк. Авыл халкына элеккеге традицион эш-гамәлләрен заманча итеп яңартырга, авыл халкында булмаган әйберләрне халыкка, табигать шартларына яраклаштырып кертү мөһим.[8] «Икътисад» журналында икътисадта һәм авыл хуҗалыгында шәхес проблемасына шактый зур урын бирелә. Авыл көнкүрешенә нисбәтле гыйлемнәрне башлап йөрүче шәкертләрнең генә түгел, ә халыкның белүе кирәк.[9] Журналда шәхси эш һәм җәмгыять (масса) эше, шәхеснең җәмгыятьтә үз өлеше кебек мәсьәләләр турында да уйланыла. Инсанның эше, аның матди мөмкинлекләреннән, сәләтеннән чыгып гаилә эше, мәхәллә эше, карья эше, дүртенчесе милләт яки кабилә эше, бишенчесе мәмләкәт эше, алтынчысы инсаният эше, җиденчесе хайванат эше дәрәҗәләренә бүлеп йөртелә.[10] Карья, милләт эшләре белән шөгыльләнү, аларның тормышын яхшырту өчен чаралар эзләү, фикер алышу максатыннан фикерле кешеләргә җәмгыятьләр булып оешырга кирәк. «Икътисад» журналы авторлары җәмгыятьләр эшчәнлегендә уку йортлары ачуны, тормыш яхшырту ысулларын тәҗрибә итүне, үрнәк кораллар ясауны, корал складлары булдыруны, файдалы машиналар, яхшы нәселле үгез һәм айгырлар сатып алуны, халыктан иген җыеп аны тиешле бәягә урнаштыруны һ.б. күздә тота.[11]

Халыкны авыл тормышы эшләрендә катнаштыру, үзидарәне булдыру өчен авыл җыеннары үткәрелә. Ләкин бу җыеннар XX гасыр башында үз максатларына ирешә алмый. Җыеннарның

оештыручы үзәге булмау сәбәпле дәрәҗәсе төшә, авылның яхшы кешеләре анда бармый, имамнар анда нотык тотуны гаеп эш дип саный башлыйлар, җыенда эшне оештыру оятсыз, телчән кешеләр кулына кала, җыеннар ызгыш-талаш формасында гына узалар.[12] Авыл җыеннарын камилләштерү өчен редколлегия түбәндәгеләрне тәкъдим итә:

1) авыл старосталарын мәгълүматлы кешеләрдән сайларга кирәк. Безнең мөселманнар арасында мәдрәсәдә яхшы гына укып мулла булмыйча авылда торып калган кешеләр күп. Алар башкаларга караганда күбрәк мәгълүматлы булалар. Муллага укыган кешеләр кирәк булган кебек рәислеккә дә укыган кешеләр бик кирәк.

2) авыл җыеннарының әһәмиятен халыкка яхшы аңлатырга кирәк. Аны җиңел эшкә яки анда баруны кимчелек санап, авылның яхшы кешеләре анда бармый калу ярамаганлыгын һәркемгә бертигез аңлатырга кирәк.

3) җыенның рәисе махсус бер җыен ясап җыенда сөйләшүнең тәртипләрен эәләп, карарга кертергә, җыенда старостадан рөхсәт алмыйча, беркем дә сөйләмәсен, сөйләүчеләр нәүбәт белнә сөйләсеннәр, кычкырышу, сүгенү, кешенең йөзен кызартуларга юл куелмасын. Мондый эшләрне кылган кешеләргә бер җәза кылырга кирәк, мисал өчен ике тәүлек буена ябып тоту.

4) зуррак мәсьәләләрдә бөтен авылга файда вә зарур булачак мәсьәләләрдә яшерен тавыш белән мәсьәләне өзәргә кирәк. Юкса күп кеше куштаннарның соңыннан җәбер вә золым итүләреннән куркып алар әйткәнгә кушылалар. Үзләренең күңелләре риза булмаса да куштаннар теләгенә хилаф булган урында без алай теләмибез дип әйтә алмыйлар. Әгәр мәсьәлә яшерен тавышка куелса, болай итәргә урын калмаячак. Яшерен тавышка куелганда җыенда булган кешеләрнең һәммәсенә ак вә кара шар өләшеп чыгалар да шуны үзенең теләгенә карап бер ящикка салырга кушалар. Бу шәрыкътә бар эш, фикъһе китапларында бәян ителгән.

5) староста канун каршында үзенең нинди хокук, вазыйфалары бар икәнен белеп, шуларның һәммәсеннән файдаланырга вә һәммәсен җиренә җиткерергә тиеш.

6) авыл җыенының эшли торган эшләре канун белән билгеләнгән. Старостага ул эшләрне белергә кирәк, һәммәсен башкарырга кирәк. Авылның эшли торган эшләрен бер программа ясап

халыкка күрсәтергә кирәк. Алар: а) авыл идарәсенең чыгымнарын кайгырту; ә) авыл халкының сәламәтлеген кайгырту, йогышлы авыруларны тикшерү; б) ачлык ел өчен саклык иген хәзерләү; в) авылның юлларын төзәтү, җир мижаларын төзек тоту, авылга җитәрлек суны кайгырту; г) төнге каравылчылар тоту; д) авылның эштән чыккан картларын вә ятимнәрен кардәшләре булмаганда тәрбияләү; е) пожарга каршы тәдбирләр итү.

Авылда нинди дә булса җәмәгать өчен зур эш эшләгәндә халыкка юл күрсәтүче шәхес халык көченә таянырга тиеш. Мәхәлләдә булган яше-карты, бае-ярлысы - һәммәсе дә үзләренең фикерләрен һәм көчләрен шул эшкә сарыф итәргә тиешләр. Монда, аеруча, мәктәп-мәчет, балалар бакчасы, уку йортлары, китапханә, җәмәгать кибетләре булдыру кебек эшләр беренче планга куела. Бай булмаган бер авыл халкы таштан мәчет салганда, халыкның бер өлешенең кирпеч сугуы, берничә дистә җиргә мәчет өчен иген чәчүләре, аның акчасын мәчет файдасына бирүләре, Иске Котлымбәт авылында җәмәгать тегермәне буасын буаларга авыруларга кадәр хезмәт куюы язылa.[13] Кизләү мәдрәсәсе өчен якын-тирә авыллардан иганә җыелганлыгы, Чынлы авылында мәктәп-мәдрәсә чыгымнарын авыл халкыннан салым белән бергә җыеп алырга карар бирелгәнлеге турында мәгүлүмат бар.[14] Татар мәгарифе, мәчет-мәдрәсә эшчәнлеге өчен татар халкына, гәрчә ул дәүләткә салым түләп торса да, бер тиен дә акча бирелмәгән. Шуңа күрә дә ул халыкның үз көченә таянырга мәҗбүр булган.

Ачлык вакытларында авыл халкына ярдәм итү максатыннан ике төрле вариант тәкъдим ителә. Беренчесе, татар авыллары халкын җәмәгать эшләрендә, авыл өчен күлләр, коелар казу, буа буу, күперләр салу, юлларга таш түшәү эшендә эшләтеп акча түләү; икенчесе, земстводан ярдәмгә иген бирү. Моның беренчесе дәүләт тарафыннан үткәрелгән сәясәт була һәм автор шуны пропагандалый.[15] Икенче бер мәкаләдә бу хезмәтләрнең уңай нәтиҗәләрен күргән автор Русия МС рәисе П.А.Столыпинга үзенең рәхмәтен белдерә.

Халыкка юл күрсәтүче шәхесләрнең халык белән бергә хезмәт итүләре һәм үзидарәләре татар авыллары халкының тормыш-көнкүрешен үзгәрткән. Бер авылда ел ярлы булса да, атларның көчле булулары, юлларга таш түшәлгән булуы, елгалар

аркылы күперләр салынуы, күлгә яраклы җирләрдә күлләр казылуы, йортлар эчләрендәге җиһазларның яхшыруы, мөселман сәнгать мәктәбе укучылары ясаган шкаф, гардероб, өстәлләр, урындыклар булуы, кызлар мәктәбендә укучы кызлар теккән челтәрле җәймәләр, аларның төрле рәсемнәр белән бизәлүе, бакчада алмагачлар, умарталар булуы тасвирлана.[16]

«Икътисад» журналында авыл-шәһәр мөнәсәбәтләре дә тикшерелә. XX йөз башында Самара шәһәрендә мөселманнар туу кимегән, ә аларның саны авылдан килгән мөселманнар хисабына тулыланып торган.[17] Шулай ук, үсүеп килүче шәһәрләрне авыл халкы ихтыяҗларына яраклаштыру һәм андагы авыл эшмәкәрләренең санын арттыру проблемасы да күтәрелә.[18] Кондитер фабрикасы, ашханә-чәйханәләр ачарга тәкъдим ителә. Шәһәр янындагы авыллар икътисадын шәһәрләр өчен яраклаштыру шул авылда яшәүче халык өчен мөһим. Игенчелек белән шөгыльләнмичә бакча үстереп, бер-ике сыер асраса, шуның җимешләрен һәм сөтен калага илтеп сатсалар ике як өчен дә файдалы булачак.[19]

Авылларны билгеле бер план кысасына гына салып алга җибәреп булмый, чөнки һәрбер авыл табигый, тарихи, икътисади яктан үзенчәлеккә ия. Авылга статистик анализ ясау мөһим. Бер авылның җәмәгать керемен барлау, аның кайларга сарыф ителешен тикшерү астында тоту кирәк. Авылда керем китерерлек урыннарны барлау, аларны буш яткырмау мәсьәләсе карала. Авылдагы берәр төрле кәсепне тагын да үстерү мәсьәләсе, яңаларын өйрәнү турында уйланыланыла. Болары авыл халкы үзе финанслап хәл итә торган проблемалар. Икенче төркем проблемалар земстводан файдаланып хәл ителә торган эшләр: янгыннан саклау, юл, күпер, базар, почтаханә, хастаханә, кулланучылар җәмгыяте ачу һ.б. «Авыл халкы ни өчен акчаны читкә җибәрә?»,-дигән сорауга да җавап эзләнә. Башка авыллардан акчаны үз хуҗалыгыңа китерү өчен икътисадның төп төшенчәсе – тәкъдимне үстерү шарт. Моның өчен һөнәрчелекне үстерергә кирәк.[20]

Авылда өйләрнең салам түбә белән ябылуы, пожар сүндерә торган коралларның начар булуы, авыл халкының янгын сүндерү ысулларын белмәүләре сәбәпле янгыннарның күп булуы традицион күренеш була.[21] Чыганакларга караганда алар

шактый зур һәм куркыныч булып, гадәттә бер янгыннан йөзләрчә йорт янган. Журналның шул темага нисбәтле мәкаләләрдә йортларны янмый торган әйберләрдән салу, пожар сүндерү өчен кирәкле кораллар алу, авыл янгыннары дружиналарын татар авылларында да булдыру проблемалары турында уйланыла.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк: журнал авторлар авыл халкының социаль-көнкүреш проблемаларын төрле өлкәдә колачлыйлар. Проблемаларны анализлыйлар һәм аны чишү юлларын күрсәтәр.

Чыганаклар

1. Мал // Икътисад.- 1908.-№1.- Б.2-3.
2. Русия мөселманнарында фәкыйрь вә зилләтнею сәбәпләре // Икътисад.- 1909. - № 1. – Б.8-9.
3.Хәлили Ә. Бездә фәкыйрьлек һәм аның сәбәпләре/ Ә.Хәлили// Икътисад.- 1912. - № 3. – Б. 65-67.
4. Карьяләребез // Икътисад. – 1911. - № 7. – Б. 192-194.
5. Исрафтан шикаят // Икътисад. – 1909. - № 12. – Б. 355-356.
6. Гомуми эшләр // Икътисад. – 1910. - № 10. – Б. 289-291.
7. Әхвәлебез // Икътисад. – 1910. -№ 7. – Б.195.
8. Карьяләребез // Икътисад. – 1911. - № 7. – Б. 192-194.
9. Шунда ук.
10. Гомуми эшләр // Икътисад. – 1910. - № 10. – Б. 289-291.
11. Әхмәдфатыйх. Авыл җәмгыятьләре /Әхмәдфатыйх // Икътисад. - 1912.- № 3. – Б. 67-69.
12.Авыл идарәләре. // Икътисад. – 1912. - № 2. – Б. 36-39.
13. Җәмәгать иттифагы // Икътисад. – 1910. - №7. – Б. 194-195.
14. Гүзәл хәбәрләр // Икътисад. - 1909 .-№ 3. – Б. 92.
15. Ил хезмәтләре // Икътисад. – 1911. - № 7. – Б.196-198.
16. Сәяхәт хәтирәләре// Икътисад. - 1911 - № 6. – Б. 162-164.
17. Карья мәгыйшәте // Икътисад. – 1908. -№ 4. – Б.113-114.
18. Мәктүпләр. Әлмәт карьясеннән // Икътисад. – 1910. - № 7. – Б. 217-218.
19. Фәхри Ф.Карь хаҗәтләре. Шәһәр янындагы авылларга /Ф.Фәхри// Икътисад. - 1912. - №7. – Б. 213-214.
20. Авылны ничек тәрәккый итәргә? // Икътисад. – 1913. - № 4. – Б.82-85.

21. Мирзагабдрахман Ш. Авыл пожарлары / Ш.Мирзагабдрахман // Икътисад. – 1911. - № 7. – Б. 215-218.

Библиографик әдәбият“Икътисад” журналының библиографик күрсәткече / Төз. Г.Н. Хисмәтова // Гасырлар авазы-Эхо веков. – 2001. - №1-2. – Б. 284 – 320.

Гыйлаҗев Т.Ш.

Тәнкыйди-гыйльми фикердә Тукайның әдәби абруе мәсьәләсе (XX гасырның беренче чиреге)

XX гасырның ахыры – XXI гасыр башларында гыйльми-тәнкыйди фикер Тукай шәхесен, аның бай һәм кабатланмас әдәби мирасын яңача аңлау юлында җитди адымнар ясый. Бу уңайдан Тукай фәненең яңа аспектлары, мәсьәләләре, шагыйрь иҗатын шәрехләүнең үзгә юнәлешләре билгеләнә. Әдәби абруй, әлбәттә, Тукай шәхесе һәм шигърияте хакындагы тәнкыйди бәя-хөкемнәргә, карашларга нигезләнә. Әмма ул шагыйрь-җәмгыять, шагыйрь-халык, шагыйрьнең әдәбиятта тоткан урыны кебек традицион үзәк мәсьәләләрдән тыш талант, сәләт, әдәби шөһрәт, дуслык-дошманлык, әдипнең шәхси һәм әдәби йөзе кебек төсмерләр, детальләр белән тирәнәйтелә, баетыла.

Шагыйрьнең әдәби репутациясе Тукай фәненең үсеш тарихында төрле максатлардан чыгып өйрәнелде һәм бәяләнде. Бу проблеманың асылы, табигате ук ниндидер шаблонлыкка, схемалылыкка ия булса да, аны яктыртуда берьяклылык, аеруча 1920-50 нче елларда үзенең иң югары ноктасына җитте. Күренә ки, Тукай поэзиясе турындагы гыйльми-нәзари күзаллауларның ђлеге аспектын яңартасы, яңарыш күзлегеннән бәялисе бар. Аның яктыртылышында 1910 нчы еллар төрле тенденцияләр, карашлар кисешкән, әдәби бәхәсләргә, идея-эстетик фикер көрәшенә юл ачкан иң бай чор булып тора.

XXI гасырга чыкканда, Тукай фәне алдында торган бурычларны, бу өлкәдәге перспектив эзләнүләрне ачыклап, Ф.Мусин: “Г.Исхакый, Ф.Әмирхан һәм Г.Ибраһимов кебек олы әдипләрнең озак вакытлар күләгәдә калдырылган фикерләре Тукайның шагыйрьлек асылын һәм дәрәҗәсен ачыклауда

принципиаль әһәмияткә ия”, - (1, 33 б.) дип язды. Чыннан да, шагыйрьнең әдәби абруе мәсьәләсе беренчеләрдән булып Ф.Әмирханның Тукай җыентыклары дөнья күрү уңаеннан язылган рецензияләрендә, публицистик мәкаләләрендә, истәлек-хатирәләрендә көн тәртибенә куела башлый. Алар Тукай шәхесенә олы ихтирам, җылы мөнәсәбәт, зурлау хисләре белән сугарылган. Мәкаләләренең беренчесендә үк Ф.Әмирхан, шагыйрь иҗатын Пушкин поэзиясенең рус әдәбиятында тоткан урынына параллель куеп, башка милләтләр арасында татар халкын дөнья күләмендә танытачак, аны югары күтәрәчәк иҗат төсендә бәяли: “Шушы тәэсирләр арасында Тукаев шигырьләрендә хис ителгән хосуси татарлык рухының аңкуы безгә Тукаевның озакламый камил мөстәкыйль татар шагыйре булачак икәнлеген күрсәтәдер. Мөстәкыйль шагыйре булган бер әдәбият – бәхетле әдәбияттыр. Ләкин мәдәни яктан алга киткән милләтләрдән башка бик аерым бәхетлесе генә бу шәрәфкә ирешә аладыр” (2, 93 б.).

Моңа кадәр салмак кына көн тәртибенә куелып, тикшерелеп киленгән мәсьәлә 1913 нче елда кискен борылыш ала, үзенең агышын киңәйтә һәм тизләтә, ургылып, ташкынланып аккан елганы хәтерләтә башлый. Моның сәбәпләре мәгълүм: аның беренчесе – шагыйрьнең вакытсыз үлеме. Икенчесе – бер гасырлык өйрәнелү тарихы булган һәм аңа бүгенге көндә дә нокта куелмаган Г.Ибраһимовның “Татар шагыйрьләре” китабының дөнья күрүе. Мәсьәләнең бу ягына тукайчы галим Җ.Вәлиди дә игътибар иткән: “Тукай үлгәннән соң аңар мөнәсәбәт бераз башкарды, аңа тәнкыйть күзе белән карау башланды. Хәтта “Тукай шагыйрьме?” дигән сөальләр туды. Хәзердә дә Тукай хакында мондый сөальне бирүчеләр күренгәли. Ләкин элек заманда Тукайның дуслары эчендә аңа сукыр көенчә табынучылар күп булган кебек, соңгы вакытта аның турысында “уптым гына” уйлап, “Тукай шагыйрь түгел иде” кебек сүзләрне сөйләүчеләр дә күп” (6, 264 б.). Тукайның вакытсыз үлеме Россия татарлары арасында гына түгел, төрки-мөселман дөньясында зур яңгыраш ала.

Шагыйрьнең әдәби абруе, шагыйрьлек дәрәҗәсе турында фикер алышканда, әлбәттә, Г.Ибраһимов исемен телисеңме, теләмисеңме - урап үтеп булмый. Әдипнең тәнкыйди

эшчәнлегендә “бисмилласы” булган “Татар матбугаты” (1910) мәкаләсендә бу вакытка инде индивидуаль стиле булган, талантлы шагыйрьләр С.Рәмиев, Дәрдемәнд, Н.Думави һ.б. арасыннан Тукайны шагыйрьлек тәхетенә утырта. Ә инде өч ел үткәч, “Татар шагыйрьләре” китабында аның шагыйрьлеген шик астына ала. Менә шушы хезмәт шагыйрьнең әдәби абруе мәкаләсенә карашны ике төркемгә аера. Ибраһимовка оппозиция төсендә Җ.Вәлиди бәясен күрсәтергә кирәк. 1913 нче елдан алып 1925 нче елларга кадәр әдәби тәнкыйди фикер шушы ике якның карашын яклау яки кире кагу рухында яши. Шагыйрь иҗатына, шәхесенә нинди мөнәсәбәттә булуларына карамастан, аларның тәнкыйди фикерләре маяк ролен үти. “Татар шагыйрьләре” китабын тикшерүгә багышланган хезмәтләрдә шагыйрь белән тәнкыйтьнең каршылыгын “шомартырга” омтылу, мәсьәләне бары тик Ибраһимовның әдәби эстетик карашлары белән бәйләп карарга тырышу тенденциясе сизелә. Х.Госман, Г.Халит, И.Нуруллин, Р.Ганиевалар әдипнең эстетик концепциясен романтизмга нисбәтле шәрехлиләр. Ә М.Хәсәнов Ибраһимовның Тукайга мөнәсәбәтен аның җитди ялгышы төсендә бәяләп, “саф сәнгать” йогынтысына бирелүенең нәтиҗәсе итеп карый. Шушы фикер марксистик-ленинчыл идеология, Октябрь инкыйлабы икегә бүлгән дөньяның теге ягында яшәгән Г.Исхакыйның “Шагыйрь Габдулла Тукай (Г.Тукайның вафатына 25 ел тулу мөнәсәбәте илә) мәкаләсендә сәбәпләрнең берсе итеп күрсәтелә.

Г.Ибраһимовның “Татар шагыйрьләре” (1913), “Талант трагедиясе” (1914), “Актык сәлам” (1915) хезмәтләре Тукайның әдәби абруе, әдәби даны мәсьәләсен аңлауда яңа сызыклар, штрихлар барлыкка китерә. Моңа кадәр тәнкыйтьтә шагыйрь иҗатындагы уңай яклар турында гына хөкем ителә. Ә иҗатының кимчелекләре, Тукайның индивидуаль, шәхси йөзе күләгәдә кала килә. Совет чоры тәнкыйди фикере читләтеп узарга тырышкан, Тукайның “дошманнары” мәсьәләсе дә шушы елларда калкып чыга. Бу факт 1 Ф.Әмирханның язмаларында төркәлеп калган: “Тукайның шәхси дошманнары да аның шигырьләрендәге халык рухын, халык аһәңен, халык музыкасын инкарь итә алмадылар” (2, 176 б.).

Ф.Әмирхан әйткән шәхси дошманнар кемнәр? Г.Ибраһимовмы? Әллә бер кичәдә Тукайны “тиз үләчәк кеше” дип хурлаучы Тимерша Соловьевмы? Әлбәттә, боларга хәзер өздереп җавап бирүе кыен. Безнең карашыбызча, аерым мәсьәләләргә ачыклык кертү Тукайның тукайлыгына зыян китермәс иде.

Тукай белән гомеренең күп өлешен үткәргән Ф.Әмирхан аерым язмаларында шагыйрьнең шәхси сыйфатларыннан дөрес сүзлелек, гадилек, хис кешесе булу турында сүз алып бара. Аннан соң ул билгеләгән тагын бер сыйфаты Ибраһимов белән ике арадагы киеренке мөнәсәбәтне аңлауга ачыклык та кертә кебек: “Бу соңгы сәбәпне тикшергәндә, Тукайның ике сыйфатын башлыча хәтердән чыгармаска тиеш буладыр: ул гаять үз-үзен сөя торган бер кеше иде ки, үзенә нинди дә булса бер яктан кимсетелеп карауны вә хәтта шул карау ихтималын гына күтәрә алмый иде” (2, 163 б.).

Тукайның тәнкыйтьне күтәрә алмавы, әдәби дошманлык белән шәхси дуслыкны аермавы Г.Ибраһимовта кат-катраслана. Шул ук вакытта аерым мәгълүматларга караганда, Г.Ибраһимов үзе дә кимчелекләрсез кеше булмаган. Тукай шәхесе, иҗатына мөнәсәбәте уңаеннан Г.Исхакыйның бер язмасына күз салыйк: “Г.Ибраһимов, Габдулла Тукайның үзен танымавыннан бераз үпкәләп, тиз көндә шулкадәр сөелүеннән бер көнчеләп, Тукайны үзенең дәрәҗәсеннән төшерергә маташа... (4, 9 б.). Аннан соң “Мөгаллимә” драмасы басылып чыккач, Ибраһимовның Г.Исхакыйның тулы иҗатына кискен мөнәсәбәте, 1922 нче елларда Җ.Вәлиди белән әдәби бәхәс алда әйтелгәннәрнең нигезсез түгеллеген раслый.

Тәнкыйтьче “Татар шагыйрьләре” китабында Тукайның шигъриятенә этрафлы анализ ясау белән бергә, алда әйтелгәнчә, аның абруе, даны-шәһрәте мәсьәләсенә махсус туктала. Татар дөньясында Тукайның мәртәбә алуының берничә сәбәбен билгели. Беренчедән, аны шагыйрь иҗатының милли характерына, гадилегенә, табигыйлегенә таянып аңлата, чыгармалар ясаса да, Тукайның сәләтен, шигъри талантын тану юлына баса. Икенчесе – иҗтимагый-мәдәни хәл һәм очраклылык: “Әдип вә шагыйрьләрнең халык вә матбугат каршында торган мәртәбәсе – һәрвакыт аның талантына туры килә, дип уйлау

беркатлылыктыр. Монда очраклылыкның, әхвальнең, күп вакыт берәр мәнфәгать вә интригаларның тәэсире бик зур эш кыйлырга, бик гади кабилиятне күккә күтәрергә мөмкин... Әхваль һәм очраклылык Тукаевның ярдәменә бик вакытында җитеште" (5, 133 б.). Әдип поэзиясенең халыкчынлыгын, халыкның уй-теләкләре, моң-зарлары белән бәйләнешен шагыйрьлек дәрәҗәсе күтәрелүнең чираттагы сәбәбе итеп күрсәтә.

Тукайның әдәби репутациясе хакында Ибраһимов тарафыннан тәкъдим ителгән билгеләр 1925 нче елларга кадәр дөнья күргән мәкаләләрнең, язмаларның темасын, проблемасын билгели, үзәк мәгънәви мотивлары булып тора. Күпләре Г.Ибраһимов белән бәхәскә, бәя-хөкемнәрнең бәрелешенә корылган. Язмаларда үзмаксатка әверелгән, файдасыз шагыйрьлек дәрәҗәсе турында сүз бармый. Тәнкыйтьчеләр милләт язмышы, аның киләчәге белән бәйләнгән дәрәҗәгә ирешүне ассызыклыйлар: "Тукай үз гомерендә халык тарафыннан күтәрелеп, татар кебек халыкта шагыйрьләрнең ирешүе мөмкин булган мәгънәви дәрәҗәләрнең иң югарысына ирешә" (6, 264 б.).

Г.Ибраһимов гади халыкның, әдәби иҗатны дөрес аңлап, объектив бәяли алуына, аның эстетик зәвыгенә шик белән карый. Бу шагыйрь поэзиясенә шушы өлкәдә махсус шөгыльләнүче галимнәр, фикер ияләре генә хөкем чыгара ала дигән карашның чагылышы да булып тора, ягъни ул халык биргән бәядән генә чыгып, теге яки бу әдип-мөхәррирнең урынын, шагыйрьлек дәрәҗәсен билгеләп була дигән караштан ерак тора.

Г.Ибраһимов шагыйрь Габдулла Тукаев иҗаты мөнәсәбәте белән язылган хезмәтләрендә әдәби дан, шөһрәт мәсьәләсенең тагын бер аспектына – талант, сәләт аспектына барып чыга. Әдәби талантның кешегә тумыштан бирелүе, табигатьтән бүләк ителүе турындагы фәлсәфи карашлары белән уртаклаша. Шигырь-шагыйрь, нәзым-назыйм мәсьәләләренә нисбәтле Г.Ибраһимов болай дип яза: "Кеше үзе тырышып, көчләнеп назыйм булырга, нәзым мәҗмугаларе чыгарырга мөмкин, әмма чын мәгънәсе белән шагыйрь булу өчен анаңнан шагыйрь булып туарга кирәк. Кеше үзе теләп шагыйрь була алмый, аны табигать ясый (5, 81 б.). Әдәби сәләт, талант мәсьәләсе нәкъ шушы юнәлештә, фәлсәфи яссылыкта Г.Исхакыйның "Милли фаҗига" мәкаләсендә шәрехләнә. Ә әдәби талантны үстерү, тормышка

ашыру шартлары, җирлеге аның “Талант трагедиясе”ндә ачыклана. Ә ул аларны Тукай талантының язмышы тирәсендә уйланулары төсендә шәрехли, бер системага сала. Культура-тарих мәктәп кануннары, кагыйдәләреннән чыгып аңлата. Г.Ибраһимов, тумыштан бирелгән сәләте ачылмыйча, Тукай вафат булды дигән фикер үткәрә. Аны гүргә кертүче сәбәп төсендә татар мохите, милләт, аның яшәү рәвеше, тирәлек күрсәтелә. Тукайның вакытсыз үлемен милли фаҗига дәрәҗәсенә җиткереп, ачынып сурәтләгән Г.Исхакый да шагыйрьгә тирәлек, заман тәэсирен билгели (10).

Тукайның табигатьтән бирелгән сәләтенең ачылмыйча калуында тәнкыйтьче тагын түбәндәге сәбәпләрне күрсәтә: табигать белән дус булмау, язучылар, дөнья әдәбияты белән аз танышлык. Шушы уңайдан Ибраһимов шагыйрьнең шәхси сыйфатларына да туктала. Хезмәт авторы карашынча, ул үзе хакында югары фикердә була, шушы аның “беренче трагедиясен тудыра”. Тукайның үз-үзен яратуы, үз дәрәҗәсен белүе Шәһер Шәрәф истәлегендә дә теркәлеп калган: “Тукай үзенең табгань (табигате белән) шагыйрь булып яратылуына, үзендә шагыйрьлек таланты фәүкыльгадә куәтле булуына бик нык иманлы иде. Бервакыт 1909 нчы ел “Вакыт” газетының бер номерында Сәгъди имзасы берлә Тукайның шигырьләре вә шагыйрьлеге хакында озын бер фельетон язылган иде. “Мин: “Бу фельетонны укыгач, берәр вершок үсеп киткәнсең”, - диюемә каршы Тукай бер дә исәпләп тормаенча гына: “Балыкка “син йөзәргә оста” дисәләр, күтәрелеп китәр идеме? – диде (6, 106 б.).

Дөрес, Тукай горур, шәхес булган, үз дәрәҗәсен, урынын яхшы белгән, халкының мәхәббәтен тоеп, сизеп яшәгән. Мәсәлән, ул “Җавап” (1909) шигырендә үзеп Лермонтов, Пушкиннар белән бер рәткә куя.

Шигъре Лермонтов вә Пушкин – олугъ саф диңгез ул,
Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов, Тукай - өч йолдыз ул.

Ә инде үз шигырьләренең халык тарафыннан сөелеп укылачагына зур өметләр баглый: Бервакыт онтыр җиһан Пушкинны һәм “Евгениен”

Яуме мәхшәрсез онытмаслар бәрәңгемне минем”

(“Пушкин һәм мин”).

Ибраһимов шагыйрьнең шигъри горурлыгына нисбәтле “әдәби дуслар”, “әдәби дошманнар” аспектын ачыклауга күчә. Ул урынсыз мактаулар шагыйрьнең кимчелеген, җитешсезлекләрен тану, үзенә тәнкыйть күзе белән карау юлын япты дигән фикерне яклый.

Ә “әдәби дошманнар”, киресенчә, кешенең аяк басуына, ныгыуна җирлек әзерли. Чыдамлылык, тырышлык, көч, җитдилегеңне камилләштерү теләген үстерә. Ихтыяри көчле кешеләр акыллы дошманнары булуга сөенәләр дигән караштa тора Ибраһимов. Р.Фәхреддин үзенең 1916 нчы елда “Шура” журналының берничә санында бастырган “Интикад вә тәган” мәкаләсендә шушы фикергә аваздаш уйлануларын тәкъдим итә: “Адәм углы үзе хакында мәдех кенә түгел, бәлки мәдех белән берлектә косурлары (кимчелекләре) сөйләнүен дә ишетергә тиеш. Мәдех кенә ишетеп тору инсаннар өчен иң зарарлы нәрсәдер. Әгәр дә “мәдех”нең зарары яхшы аңлашылып җитсә иде, дошманнар үз дошманнарыны зәмм (орышу) итәчәк урынса мәдех кенә итеп торырлар иде” (11, 392 б.). Бу яктан да, Г.Ибраһимов уйлавынча, Тукайга бәхет елмаймый.

Тукай үз әдәби дошманнарының барлыгын, аның иҗаты, шәхесе, татар шигърияте күгендә тоткан урынына нисбәтле капма-каршы бәяләр яшәве, вакыты белән нахак сүзләр әйтелүе турында белгән. Зур горурлык белән, шактый кискен, үткен, усал тел белән аларга үз мөнәсәбәтен, җавабын “Җавап” (1909), “Дошманнар” (1912), “Мөнтәкыйд” (1912), “Интигадка мөтәгалликъ (тәнкыйтькә бәйләнешле) (1912) әсәрләрендә шагыйрәнә белдергән. Һәм аның бу рухтагы шигырьләре 1910 нчы елларда майданга килә. Әйтергә мөмкин, дуслык, дошманлык мотив сыйфатында гәүдәләнеш таба. Р.Фәхретдиннең тәнкыйть, аның шартлары, тәган тирәсендә уйлануларын белдергән мәкаләсендә “матбугат этләре” дигән гыйбарә килеп керә. Бу мәсьәләдә “эт”, “эт өрү” шагыйрьнең яраткан образына әверелә.

Кит хәзер, ләкин китәрдә сал колак бу сүзгә бер:
Барчы, эт, гомрең буе шул күктә льч йолдызга ьр!
(«Җавап»)

Күренә ки, Тукай үзенә язылган мәкаләләрне, рецензияләрне кеше шәхесен сүгү, кимсетү, әдәбият

мәйданында аның дәрәҗәсен тљшерү максаты белән язылган тәнкыйтьнең бер төре – тәган кысаларында карый.

Г.Тукай кебек олы талант иясен, милли шигърияттә үз әдәби мәктәбен, юнәлешен, тудырган шагыйрьне бер калыпка салу ҹич тә мөмкин түгел. Тормыш яшәеш кануннарыннан чыгып хөкем иткәндә бу күренеш табигый хәлләрдән исәпләнә. Әдәби дуслык, әдәби дошманлык мәсьәләсенә фәлсәфи якын килергә тырышканнар. Татар хатын-кызларыннан беренче булып Казан император университетында укучы, Сталин шәхес культы елларында фаҗигале язмышка дучар ителүче Ә.Мөхетдиния карашы игътибарга лаек: «Шулай дөнья белән сугышырга тотынгач, ҹәрнәрсәнең барышын тикшереп, халыкның гаебен үзенә ачып биргәч, әлбәттә шагыйрьнең дусты да, дошманы да күп булуы бик табигый, аның кеше сүзенә исе китми, ул «кул кулны юа, икесе дә пакъ тора» дигән кагыйдәдән югары» (6, 283 б.).

Соңгы елларда Ибраһимов белән Тукай каршылыгын ачыклау юлында кызыклы һәм дәлилле фикерләр күп яңгырады. Аларның барысын бер үзәк тирәсенә җыйганда, укучыны ышандырырлык концепция калыплаша. Ә Г.Тукайга татар халкының олы шәхесләреннән энциклопедик галим Р.Фәхретдин, М.Бигиевләрнең каршылыклы мөнәсәбәте нәрсә белән аңлатыла? Сәбәп нәрсәдә?

Мәгълүм булганча, Р.Фәхретдин “Вакыт” газетасының 1906 нчы елгы бер санында Тукайны гарәп шагыйре Мәгарри белән чагыштыра. Җамал Вәлиди шагыйрьнең сайланма әсәрләре җыентыгына зур күләмле монографик кереш мәкалә яза. Тукай тормыш юлы һәм иҗатының татар, төрек матбугатларында яктыртылышына күзәтү ясаганда, шушы фактны да үз язмасына терки. Әлеге язма Р.Фәхретдинне кулына каләм алырга этәрә һәм ул, әлеге мәсьәлә буенча үз фикерләрен җыйнап, “Шура” журналының 1914 нче ел 22 нче санында “Мәсамәрә” (Мәшрикъ илә мәгъриб йолдызлары) исеме астында мәкалә бастырып чыгара. Әйтергә кирәк, мәкаләнең икенче кисәге Тукай шәхесе, шигъриятенең идея-эстетик үзенчәлекләре, шагыйрьлек баскычы турында уйланулар белән сугарылган.

Р.Фәхретдин Тукайны Мәгарри белән чагыштыруны үзенең татар дөньясында да Мәгарри кебек олы шагыйрь күрү теләге белән эшләнгәнлеген әйтә. Тукай шигырьләре һәм Мәгарри җыентыклары белән танышып чыкканнан соң аларны янәшә кую, Тукайны "шагыйрьләр философы һәм философлар шагыйре", гыйлем диңгезе вә гакыл хәзинәсе Мәгарригә тиңләү мөмкин түгеллекне кистереп куя.

Аннан соң шушы фикерен шәрехләүгә күчә, укучы белән үз уйлануларын бүлешә. Бу кисәктә шигырьне ауропача аңлаган Г.Ибраһимов белән шәрыкче Р.Фәхретдиннең карашлары кисешә.

Р.Фәхретдин Тукайны соңгы юлга озаткан көннәрдә, көндәлек матбугаттагы активлыкка салкын мөнәсәбәт белдерә һәм шул уңайдан Тукайның шагыйрьлек сәләтенең моннан берничә ел элек күмелүе турында искәртә. Аның табигатьтән, тумыштан бирелгән талантының ачылмыйча калуының сәбәпләре төсендә Тукай яшәгән мохит, тиешле тәрбия алмау, мәхәббәт дөньясы белән бәйләнеш булмау күрсәтелә.

Г.Ибраһимов, Р.Фәхретдиннең хөкемнәре, уйланулары бүгенге көндә берьяклылык, бер тарафлык дип бәяләнсәләр дә, алар Ф.Әмирхан, Җ.Вәлидине битараф калдырмый. Шунысы игътибарга лаек: Тукайны татар халкы язмышыннан, үзе яшәгән мохитеннән, Казаныннан аерып алып, шәрекъ һәм гареб әдәби-эстетик фикер казанышлары ноктасыннан бәяләүне Җ.Вәлиди тәнкыйтьләп чыга. Әмма Ф.Әмирханның "Күпме какканны вә сукканны күтәрде бу ятим" (1923), Җ.Вәлидинең "Тукайның шагыйрьлеге" (1923) мәкаләләрендә шагыйрьнең әдәби репутациясе, шагыйрьлек дәрәҗәсе мәсьәләсе Г.Ибраһимов, Р.Фәхретдин карашлары йогынтысында шәрехләнә. "Тукай философ шагыйрь түгел: монда, әлбәттә, ике төрле караш булмас. Тукай томрап тора торган диңгез түгел. Тукайда тирәнлек юк", (6, 264-265 б.) - дигән юлларда Р.Фәхретдиннең Мәгарри белән Тукай дәрәҗәсе турындагы хөкемнәренең күләгәсе чагыла. Ә Ф.Әмирхан оппонентларының мәкаләләрендә күрсәтелгән дүрт сәбәпне саный, үзе дә сизмәстән, үз карашларын Г.Ибраһимов һәм Ф.Фәхретдиннәрнең сукмагына сала.

Теге яки бу әдипнең әдәби абруе югары күтәрелүдә, дәрәҗәсенә зыян килүдә вакытлы матбугат зур роль уйный. Тукаевның әдәби даны, шагыйрьлек миссиясе хакындагы бәхәс,

фикер, бәя-хөкем бәрелешләре газета-журнал сәхифәләрендә бара. Үз иҗтимагый-сәяси эшчәнлегендә халыкның милли үз аның үстерүдә көндәлек матбугатның ролен тирән аңлаган Г.Исхакый "Тукай – матбугат" мәсьәләсенә зур игътибар бирә. Тукайны пропагандалауда, аның иҗатын шәрехләүдә, милли асылын ачуда матбугатка зур вазыйфа йөкли: "Бу фикергә каршы килүче юк иде вә шул фикерне матурландыру, мәрхүм Тукайның – бәхетсез Тукайның ач, мохтаҗ тормышын бизәп, матур итеп күрсәтү, Тукай хакында милли бер шагыйрь исемене һәм каһарман, һәм пакъ, һәм матур иттерү матбугатымыз, әдәбиятымызның бурычы, киләчәк буын алдында вазифасы иде" (12, 83 б.). Бу вазыйфа Исхакый тарафыннан матбугатның көчен, чисталыгын, сыйфатын билгеләүче бер үлчәү төсендә тәкъдим ителә, әмма ул бу яктан әдипне канәгатьләндерми. Аеруча Исхакыйны Тукайның кыйммәтен төшерә торган, аны ихтирам хисенә зарар китерә торган язмаларның басылуы борчый. Ул аерым бер мәсьәләләрдә бик сакланып каләм йөртергә чакыра. Тукай хакында аз гына булса да шөбһә уята торган сүзләр сөйләүне, төрле уйларга сәбәп булган мәкаләләр язуны милли тәрбия җәһәтеннән җинаятькә тиңли.

Кайчакта гомуми тенденциягә бирелеп, татар мәктәп-мәррәсәләрендәге Тукайның әдәби мохитен, Җаек, Казан шәһәрләрендәге әдәби-мәдәни хәятен кечерәйтеп күрсәтү күзәтелә. Шагыйрьнең әдәби абруен, шагыйрьлек дәрәҗәсен күтәрүдә "Мотыйгыя" мәдрәсәсендәге әдәби мәҗлесләр, Казандагы әдәби кичәләр, Шәрык клубы әһәмиятле роль уйнаган. Г.Шәрәф, Ф.Әмирхан һ.б.ларның язмаларында әдәбиятны сөючеләр түгәрәге, мәҗлес әгъзаларының Тукай әсәрләрен яратып тыңлаулары, кабул итүләре турында фактлар теркәлеп калган: "Түгәрәк" дәвам иткән вакытларда байтак әсәрләр укылды. ...Шулай да "түгәрәк"тә Тукайның "Печән базары" кадәр иптәшләргә куәтле тәэсир калдырган әсәрне хәтерли алмыйм" (6, 102 б.).

Күзәтүләргә нәтиҗә ясап, шуларны әйтергә мөмкин. XX гасырның беренче чирегендә Г.Тукайның шагыйрьлек дәрәҗәсе, әдәби абруе мәсьәләсе гыйльми-нәзари, әдәби-тәнкыйди фикердә кызыл җеп булып сузыла. Ул 1906 нчы елларда көн тәртибенә

куелып 1920 нче елларның урталарына кадәр кызыклы үсеш кичерә. Бер фикер икенчесе тууга юл ача, өченче төрле караш үзеннән алдагысын инкарь итә. Тукай шәхесе, әдәби шөһрәт тирәсендә барлыкка килгән бәя-хөкемнәр, үлчәүләр бер-берсенә бәйләнеп, үрелеп үсеп, бер буын, фикерләр чылбырын тәшкил итә. Шунысы кызык: 1925 нче елларга кадәр дә Тукай өчен көрәш бара. Югыйсә, Тукай иҗатын, шәхесен марксистик-ленинчыл идеологиягә буйсындыру, социалистик төзелешкә хезмәт иттерү максаты куелмый, сәяси басым юк. Әмма гасыр башында галимнәрне, әдипләрне башка ориентирлар борчый. Тукай шагыйрьлеге, аның даны, әдәби шөһрәте өчен фикер бәрелеше милли сүз сәнгате, яңа әдәбиятның үсеш юнәлеше өчен көрәшү белән бәйле була. Шагыйрьнең әдәби абруе мәсьәләсенең үзәгендә, иң беренче чиратта, Тукай иҗатының асыл сыйфатлары – халыкчанлык, миллилек турында әдәби-эстетик карашлар ята. Тукай иҗаты өчен көрәш халыкчан, реалистик әдәбият өчен көрәшкә барып тоташа.

Әдәбият

1. Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте. Шагыйрьнең 110 еллыгына багышланган халыкара конференция материаллары. – Казан, 1997. – 322 б.

2. Әмирхан Ф. Әсәрләр: 4 томда. 4-т. / Әдәбият – сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар / Ф.Әмирхан. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1986. – 389 б.

3. Мәхмүтов Һ. Замандашлар бәяли / Һ.Мәхмүтов // Мирас. – 1992. - № 4. – 79-88 б.

4. Исхакый Г. Шагыйрь Габдулла Тукай / Г.Исхакый // Татарстан. – 1998. – № 2. – 7-12 б.

5. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. 5-т. / Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910-1933) / Г.Ибраһимов. – Казан: Татар.кит.нәшр. 1978. – 614 б.

6. Тукай турында замандашлары: Истәлекләр, мәкаләләр һәм әдәби әсәрләр җыентыгы. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1960. – 294 б.

7. Фәхретдинов Р. Мөсамәрә / Р.Фәхретдинов // Шура. – 1914. – 22. – 701-704 б.

8. Ибраһимов Г. Актык сәлам / Г.Ибраһимов // Татарстан хәбәрләре. – 1992. – 10 июль.

9. Ибраһимов Г. Талант трагедиясе / Г.Ибраһимов // Мирас. – 1992. - № 4. – 84-86 б.

10. Исхакый Г. Милли фаҗига / Г.Исхакый // Мирас. – 1992. - № 4. – 80-82 б.

11. Фәхретдинов Р. Интикад вә тагын: Интикадмы? Тәнкыйтьме? Интикадның фаидәсе / Р.Фәхретдинов // Шура. – 1916. - № 17. – 391-193 б.

12. Исхакый Г. Тукай мәхәббәте / Г.Исхакый // Мирас. – 1992. - № 4. – 82-84 б.

Гыймранова Г.Ш.

XX гасыр башы татар шигъриятендә аваз кабатлауларның эстетик вазифасы

Шигъри сөйләм теле, беренче чиратта, авазлар составы ягыннан оеша. Фонетик элементларның билгеле бер тәртипкә салынган булуы шигъри әсәрдәге сәнгати уйланмага буйсынган үзенчәлекле мәгънәне барлыкка китерә. Шигъри текстны авазлар ягыннан оештыруда төп принцип булып, кабатлау принцибы тора. Әлеге күренеш еш кына халык авыз иҗатында, матур әдәбиятта, аерым алганда, шигърияттә сурәт тудыру, әсәрнең аһәңлелеген, укучыга тәэсир көчен арттыру өчен кулланыла.

Аваз кабатлауларның берничә төре бар: иң киң таралганы – **аллитерация** – әдәби нәфис сөйләмдә һәм халык телендә сәнгатьлелекне, сурәтлелекне көчәйтү максатында бер үк яисә охшаш тартыкларның кабатланып килүе. Әдәби әсәрнең тәэсир көчен арттыруда сузык авазларның еш кулланылуы – **ассонанс** күренеше дип атала. **Эвфония** – бер үк төрле сузык яки тартык аваз тезмәләренең күбрәк кулланылуы нәтиҗәсендә, сөйләмнең югары һәм экспрессив яңгырашы барлыкка килү [Хаков, 1999, 168-169].

Курбатов Х.Р. фонетик-стилистик алымнарның татар шигырь төзелешендә әһәмиятле роль уйнавын күрсәтә һәм аларны кулланганда чаманы белергә, теге яки бу авазны кабатлауның күңелдә нинди тәэсир уятуын яхшы тоярга

кирәклекне искәртә [Курбатов, 1971, 185]. Чөнки авазлар кабатлану билгеле бер стилистик максатлардан чыгып эшләнмәгән очракта, аларның урынсыз кулланылуы ямьсез яңгыраш – какофония күренеше барлыкка килүгә сәбәпче була.

Хаков В.Х. сәнгатьле сөйләм тудыручы фонетик-стилистик алымнарның татар халык авыз иҗатында зур урын тотуын күрсәтә: *Тел очы татлы, тел төбе татлы* (*т* авазы), *туган телен кадерләгән халык кадерле булыр* (*л* авазы), *аз сүз – үз сүз, күп сүз – чүп сүз* (*ү* авазы), *ачу дошман, акыл дус, ачуыңа акыл куш* (*а, у* авазлары), *кырда бер алачык, алачык эчендә капчык, капчык эчендә карчык* (*кы-ка, че-чы*) [Хаков, 1999, 168-170].

Сүзләрнең әйтелешенә (яңгырашына) нигезләнгән сурәтләү алымнарының гүзәл үрнәкләрен XX гасыр башы татар шигъриятендә, аеруча халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай иҗатында күрергә мөмкин. Х.Х. Кузьмина Г. Тукай шигырьләрендә аллитерация барлыкка китерүдә төп рольне *т, д, р* һәм *с, з, ш* тартыклары уйнавы турында билгеләп үтә [Кузьмина, 2006, 55].

Г. Тукай иҗатында авазлар кабатлануның иң ачык үрнәге – “Пар ат” шигыре. Әлеге әсәрдә *к, т, п, р* авазлары актив кулланылып, ат тояклары тавышы ишетелгәндәй була, әлеге тартыклар шигырьгә күңелле моң, шатлык өсти:

Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап;
Чаптыра атларны кучер, суккалап та тарткалап.

“Шагыйрь” исемле шигырьдә исә, *к, р* һәм *т* тартыклары күп кулланылу фикергә кискенлек, катгыйлык бирә:

Булмамын, юк, картайсам да, чын карт кеби,
Утырмам тик, юк-бар теләк тели-тели.

Гомумән, *т* авазы – Г. Тукай шигъриятендә иң зур тасвирый мәгънәгә ия булган авазларның берсе. Мисалга барыбыз да яттан белә торган “Туган тел” шигырен генә китерик:

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

С, ч һәм *ш* тартыклары да шагыйрь иҗатында сурәт тудыру, мәгънә һәм форма берлеге оешуга китерә:

Сач та җиткән, алдырырга куркыныч, бик куркыныч:
Тотса баштан сачтараш, шылтыр да шылтыр җон ага.
(“Саташкан”).

Әлеге шигырьдә билгеле бер авазларның актив кулланылышы сурәтнең тәэсир көчен тагын да арттыру, кеше күңеленә шом салуга китерә.

“Бәйрәм бүген” шигырендә исә, *б* тартыгы иң зур урынны алып тора:

Бар күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген.
Нәрсәдән бу? – Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Күргәнебезчә, шигъри әсәрдә билгеле бер авазларның еш кулланылуы аңа аһәңлелек, сурәтлелек өсти. Мондый шигырьләр үзләреннән-үзләре “җырлап”, көй сорап тора. Шуңа да Г. Тукайның күп кенә шигырьләре көйгә салыну гаҗәп түгел. Галим К.Миңнуллин да хәзерге җыр жанрында авазлар аһәңдәшлеген булдыру өчен актив кулланыла торган фонетик чараларны автор җырларына Г.Тукайның “Бәйрәм бүген”, “Пар ат”, “Милли моңнар” әсәрләре алып килүен билгеләп үтә [Миңнуллин, 1998, 117].

С. Рәмиев исә шигъри әсәрләрендә *н* һәм *р* авазларын бик яратып куллана:

Нинди иркен, нинди рәхәт,
Нинди бар җир гөл генә;
Синдә төн дә юк, төнең дә
Бер болытлы көн генә.
(“Авыл”).

Дәрдмәнд шигырьләрендә дә билгеле бер мәгънәгә ия булган аваз кабатлаулар еш очрый:

Шаулый диңгез...
Җил өрәдер...
Җилкәнен киргән кораб!
(“Кораб”).

Җ, *ш* һәм *р* авазлары чиратлашып, җил, диңгез тавышлары ассоциациясен тудыралар.

Күргәнебезчә, тартык авазларны кабатлау ярдәмендә әсәргә тирән мәгънә салырга мөмкин. Сузык авазлар да әлеге өлкәдә зур әһәмияткә ия.

Г. Тукайның күп кенә шигырьләрендә без аллитерация белән беррәттән, ассонанс күренешен дә очратабыз:

Әлли-бәлли итәр бу,

Мәдрәсәгә китәр бу...

“Бишек җыруы” шигырендәге *ә* һәм *и* авазларының салмак кына күчеше тынлык, тынычлык, рәхәтлек ассоциациясе тудыра.

“Г. Тукайның мәхәббәт турында язылган шигырьләрендә мондый салмак агышлы, көйгә салынган юллар юк диярлек. Мәхәббәт, сөю, ярату – дулкынландыргыч хисләр, шуңа күрә шагыйрь аны тигез ритмга салмыйча, калын һәм нечкә сузыкларны аралаштырып бара:

Җир яшәрмәс, гөл ачылмас, - төшми яңгыр тамчысы,
Кайдан алсын шигъре шагыйрь, булмаса илһамчысы?!
(“Мәхәббәт”)” [Кузьмина, 2006, 56].

С. Рәмиев иҗатында да сузыклар чиратлашуга корылган юллар очрый:

Мине утка аткан ул – син,
Мине суга салган да – син,
Утка янсам, суга батсам,
Тартып алган Аллам да – син!

“Син” шигырендәге *а, у* һәм *и* авазлары чиратлашу контекст белән тыгыз бәйләнешкә кереп, лирик геройның сөйгәнен билгеле бер югарылыкка күтәрә.

Шагыйрьләр эвфония күренешенә дә еш мөрәҗәгать итәләр. Г. Тукай күп кенә шигырьләрендә бер үк сүзләрне кабатлау ярдәмендә дә югары яңгырашка, сәнгатьлелеккә ирешә:

Татар бәхте өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын.
(“Үз-үземә”).

Әлеге күренеш С. Рәмиевнең шигырьләренә дә хас, үзенең фикерләрен укучыга үтемле итеп җиткерү өчен ул еш кына авазлар, сүзләр кабатлануга мөрәҗәгать итә:

Сызла, сызла, сызла, күңлем!
Сызла бер туктамыйча,
Сызла айлар, сызла еллар,
Сызла төн йокламыйча!
(“Сызла, күңлем!”).

“Мин” шигырендә “мин” сүзе еш кабатлану сәбәпле, беренче зат алмашлык мәгънәсе контексттан калкып чыгып, фикер тулылыгына ирешүгә ярдәм итә:

“Мин!” димен мин, яшәсен “мин!”
“Мин” минемчөн Алла ул.

Дәрдмәнд бер үк сүзләрне кабатлауны үзенчәлекле куллана, строфаның һәр юлын бер үк сүзгә башлап, анафора алымы тудыра:

Илдә бер дуст булмаса гәр,
Ил бөтен – дошман түгел!

Бер үк сүзләр кабатлану рифма тууга да хезмәт итә:

Күңелемнең әзрәк кенә кинәсе бар,
Телемнең дә зәһәр очлы инәсе бар.

Димәк, фонетик чаралар әдәби сөйләм телен нәфис, аһәңле, матур яңгырашлы итүдә зур әһәмияткә ия, һәм аларны урынлы куллану шагыйрьләрнең осталыгын, зәвыгын күрсәтеп тора.

Әдәбият

1. Кузьмина Х.Х. Фонетик стилистика мәсьәләләре / Х.Х.Кузьмина. – Милли мәдәният, 2006. - № 11. – 55-57 б.
2. Курбатов Х.Р. Хәзерге татар әдәби теленең стилистик системасы. / Х.Р.Курбатов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. – 185 б.
3. Миңнуллин К. Шигърият һәм җыр. / Миңнуллин К. – Казан: Мәгариф, 1998. – 287 б.
4. Хаков В.Х. Татар әдәби теле (стилистика) / В.Х.Хаков. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 303 б.

Даутова Г.И.

Сөйләм күнекмәләрен үстерү чарасы буларак текст

Хәзерге вакытта татар телен укыту киң юнәлештә алып барыла, төрледән-төрле дәреслекләр, укыту әсбаплары һәм методик ярдәмлекләр бастырыла, укыту методикасы камилләшә бара. Рус телле балаларга икетелле мохиттә татар телен укыту алымнарын, шул исәптән текст белән эшләүнең үзенчәлекләрен өйрәнү актуаль мәсьәләләренең берсе булып тора. Мәктәп программасында әйтелгәнчә, рус телле балаларга, татар телен аралашу чарасы буларак үзләштерү өчен, тел берәмлекләрен гамәли үзләштерү сорала.

Лингвометодикада тел берәмлекләре дип аерым авазларны, сүзләрне, сүзтезмәләрне һәм җөмлә калыпларын атыйлар. Тел һәм сөйләм берәмлекләре функциональ якын килеп сайлана һәм билгеле бер тәртиптә өйрәтелә. Укучылар сөйләм күнекмәләренә ия булсыннар һәм тел берәмлекләрен аңлы рәвештә үзләштерсеннәр өчен, текстка нигезләнеп эшләү бик мөһим. Текст бик күп гуманитар фәннәрнең өйрәнү предметы булып тора, ләкин һәрбер фән аны үз формасына яраклаштырып, үз мөмкинлекләреннән чыгып өйрәнә. Галимнәр фикеренчә, текст мәктәп укучыларының сөйләмен үстерү чарасы булып тора, ягъни текст сөйләмне бер логик эзлеклелектә алып барырга, аралашуны иркенәйтергә ярдәм итә.

В.Ф.Габдулхаков әйтүенчә, текстларга бәйле рәвештә укучыларның сөйләм күнекмәләрен камилләштерергә мөмкин. Дәресләрдә текстны төрле яклап тикшерү, анализлау алга таба укучыларның лингвистик компетенциясен үстерү дә әһәмияткә ия. Монда монологик сөйләмгә дә игътибар бирү мөһим. [2]

Бүгенге көндә гомуми белем бирүдә когнитивистик алым кулланып укытуга аерым игътибар бирелә. Әлеге алымнан файдаланганда, укучыны, бигрәк тә башлангыч сыйныф укучыларын шәхес буларак үстерү күздә тотыла. Димәк, укучының яшь үзенчәлекләрен истә тотып, аны кызыксындырырлык, игътибарын җәлеп итәрдәй эш төрләрен сайларга, психологик шартларны булдырырга кирәк.

Укучыларның белем дәрәҗәсен арттыру юнәлешендә эшчәнлек алып барганда, текст белән эшләүне методик яктан уңышлы оештыру шарт. Әйтик, башлангыч сыйныф укучылары өчен текст сайлаганда, аның эчтәлегенә, төзелешенә игътибар итү татар теленә өйрәтүнең нәтиҗәлелеген арттырырга мөмкинлек бирә. Беренчедән, сайланган текстлар укучы өчен бай мәгълүмат чыганагы булып тора. Алар аша укучылар татар мәдәниятенә хас үзенчәлекләр, татар халкына хас сыйфатлар, тарихи мәгълүмат белән танышалар. Икенчедән, уку барышында әлеге текстта кулланылган сүзләрне, җөмлә калыпларын, сөйләм гыйбарәләрен гамәли үзләштерәләр, ягъни лексик-грамматик материал аша җиткерелә һәм ныгытыла.

Текст белән эшләгәндә, аның эчтәлеге укучыларга алаешлы булсын өчен, укучы тексттагы һәр сүзгә, һәр гыйбарәгә аңлатма

бирергә яисә аңлау өчен аралашу мохите тудырырга тиеш. Шулай ук рус телле балаларга тексттагы кайбер күчерелмә мәгънәле сүзләр яисә фразеологик әйтелмәләр аңлашылмаска мөмкин. Шуңа бирелгән сүзләрнең татар телендәге синонимнарын яисә рус телендәге эквивалентларын күрсәтү зарур.

Танылган галимә И.Л.Бим фикеренчә, туган телдән кала башка телне өйрәнү укучының фикерләү сәләтен һәм коммуникатив мөмкинлекләрен үстерә, аралашу аша башка халыкларның тарихын, рухи казанышларын өйрәнергә ярдәм итә.

И.Г.Сорокина үзенең хезмәтендә бигеләп үткәнчә, укыту барышында башлангыч сыйныф укучыларының фикерләү осталыгын үстерү мөһим, чөнки фикерләү – белем һәм осталыкның бердәмлеге. [3] Гомумән, дәреслекләрдә укучыларның фикерләвен үстерүгә юнәлдерелгән күнегүләр күпчелекне тәшкил итәргә тиеш. Шуңа күрә текст белән эшләгәндә дә, укучы эзлекле фикерләүгә таянып, тел күренешләрен анализлый алырга, төрле чагыштырулар, гомумиләштерүләр алып барырга, текст буенча нәтиҗәләр ясый белергә тиеш.

Алда әйтеп кителгәнчә, икетелле мохитә рус балаларына татар телен укыту барышында иң мөһим мәсьәләләрнең берсе булып коммуникатив эшчәнлекне булдыру санала. Рус балаларының татар милләтеннән булган яшьтәшләре белән аралашу коммуникатив эшчәнлекне булдыруга ярдәм итә. Коммуникатив эшчәнлек турыдан-туры төрле текстлар төзү, аларның эчтәлеген сөйләүгә, шулай ук диалоглар төзеп, бер-берсе белән аралашуга кайтып кала. Әлеге алым укчыларда бер-берсен тыңларга, сөләмне дөрес төзергә өйрәтә. Шулай ук төрле текстлар төзү укучының татар телендә дөрес язу күнекмәләрен дә формалаштырырга ярдәм итә. Диалог формасындагы сорау-җавапка корылган текстлар да укучыларның коммуникативлыгын арттыруга китерә. Әлеге чараның отышлы булуын психологик һәм психолингвистик тикшеренүләр дә күрсәтә. [3]

Чит телле баланы татар теленә өйрәтү барышында коммуникатив һәм шул ук вакытта сөйләмне үстерергә ярдәм итә торган кайбер башка биремнәр дә кулланыла ала. Аларны, танып белү һәм коммуникатив мөмкинлекләренә карап, гадәттә өч төркемгә бүлеп йөртәләр.

1) Телне өйрәнгәндә барлыкка килә торган барьерны бетерергә ярдәм итүче күнегүләр. Мәсәлән, хикәя сөйләү, сурәтләү, чагыштырулар күрсәтү. Әлеге күнегүләр ярдәмендә укучының коммуникатив мөмкинчелекләре формалашырга тиеш.

2) Танып белү мөмкинлекләрен үстерергә ярдәм итүче күнегүләр (уку, укып аңлау, сөйләү).

3) Коммуникатив һәм танып белү функцияләренең синтезын тәшкил итүче күнегүләр.

Боларга аңлату, билгеләмәләр бирү, белгәнеңне исбатлап сөйләү кирә. [5]

Икетелле мохиттә чит телне өйрәнү өлкәсендә төрле фәнни экспериментлар үткәрелә. Шундыйларның берсе булып эмпирик метод санала. Әлеге метод, вербаль текстларны кулланып, укучының үзаңын үстерү, шулай ук дәреслекләрдә бирелгән махсус текстлар ярдәмендә укучыларның чынбарлыкны танып белү күнекмәләрен үстерү, тормыштагы охшаш күренешләр белән чагыштыруны үз эченә ала. Шулай ук телне практик яктан камилләштерү дә күз уңында тотыла. Әлеге методлар барысы да укучыларның линвистик компетенциясен үстерү максатыннан алып барыла.

Татар теле дәресләрендә текст белән эшләгәндә, тагын шунысын да истә тотарга кирәк: ул сөйләм эшчәнлегенә өйрәтүнең бер тармагы булып тора һәм аның рецептив төренә карый, ягъни текстны тыңлап аңлау яки уку. Шулай ук продуктив төрләр дә (сөйләү һәм язма сөйләм) текст төзүгә кайтып кала.

Текст белән эшләү методикасы психология, психолингвстика, коммуникация теориясе һ.б. фәннәр белән тыгыз бәйләнештә тора һәм аларның казанышларына нигезләнеп үсеш ала.

Бу юнәлештә алга таба да тикшеренүләр, эзләнүләр алып бару, алдынгы педагогик тәҗрибәне өйрәнү, яңа идеяләр тәкъдим итү, эш алымнарын төрләндерү икенче телгә өйрәтүне, шул исәптән рус телле балаларга татар телен укытуны тагын да баета ала.

Әдәбият

1) Вислогузова М.А. Структура базового блока педагогического образования и технология его диагностики / М.А. Вислогузова. – М., 2001. – 197с.

2) Габдулхаков В.Ф. Современная языковая коммуникация и технология развития речевой деятельности в условиях билингвизма / В.Ф. Габдулхаков. – Казань, 1999. – 208 с.

3) Сорокина И.Г. Развитие умений интерпретации художественного текста / И.Г. Сорокина. – М., 2001. – 102с.

4) Стрелкова Г.В. Общеевропейские компетенции владения иностранными языками / Г.В. Стрелкова. – М., 2001. – 135с.

5) Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре / Ф.Ф. Харисов. – Казан: Мәгариф, 2002. – 536б.

Денмөхәммәтова Э.Н.

Балалар фольклорында лексик синонимия

Балалар фольклоры өлкәннәр тарафыннан бәбиләр өчен башкарыла торган һәм нәниләрнең үз мохитендә яшәп килгән егермеләп жанрдагы халык авыз иҗаты әсәрләрен берләштерә. Бу әсәрләр халык иҗатында шартлы рәвештә аерым бер төркемгә бүленеп йөртелсә дә, “балалар фольклоры “ белән “ зурлар фольклоры “ арасында зур чик сызыгы юк, дип санала. Ул халкыбыз поэтик мирасының аергысыз өлеше. Бу төркемгә кергән әсәрләр үзләренең тематикасы белән бала күңеленә якын, аларның шигъри тукымасына балалык рухы сеңгән булуы хас.

Рус фольклорчылары бу жанрга XIX гасыр да ук игътиб итәләр. А.Глаголев – балалар җырларын җыя, И.П.Сахаров - уен һәм такмак-такмазаларны өйрәнә, А.Терещенко – уен, бишек җырларын туплый, өйрәнә, Е.Авдеева – санамыш, әйтешләргә игътибар итә. Соңрак Г.Н.Потанин. М.Ф.Кривошапкин, А.Ф.Можарский, П.А.Бессонов, Д.Н.Садовникова, Ф.Д.Нефедов, Я.Ф.Головицкий, В.Ф. Кудрявцев, Е.А.Покровский, К.И.Чуковский, О.Копица, Г.С.Виноградов һ.б. бу җәүһәрләрне туплау һәм аларны фәнни тикшерүгә үзләреннән зур өлеш кертәләр.

Татар халык авыз иҗатын өйрәнүчеләр тарафыннан “балалар фольклоры” төшенчәсе ХХгасырның 20еллары ахырында гына фәнни кулланылышка кертелсә дә, халык иҗаты әсәрләренең бик борынгыдан яшәп килүе шиксез. Шунлыктан бу ядкярләрне М.Кашгари хезмәтендә үк күзәтүләр мәгълүм. Соңрак С.Күкләшев, К.Насыйри, Т.Яхин, К.Гали, Т.Ченәкәй, Х.Бәдигый, Г.Толымбаев, Г.Хуҗи, С.Әхтәмова, Н.Исәнбәт, И.Надиров, Ә.Абдуллин, М.Нигъмәтҗанов, Э.Галиев, Х.Курбатов, Р.Кукушкин, Р.Ягъфәров һ.б. тарафыннан җыелып, тупланып бастырылулары һәм әдәбият, халык педагогикасы һәм музыкасы, фольклор, этнография һәм тел материалы буларак фәнни өйрәнелүләре дә билгеле.

Балалар фольклоры, функцияләре һәм поэтик үзенчәлекләре ягыннан, күп төрле жанрларны эченә ала. Кайберләре кечкенә баланы йоклату өчен, зурлар тарафыннаан башкарылса, икенчеләре исә хәрәкәтле уеннар белән бәйле рәвештә, балаларның үзләре тарафыннан башкарыла, өченчеләре балаларның күңел ачуларын, җорлану вакытында уен сүзләре буларак кулланыла. Шуны искә алып, фольклор галимнәре балалар фольклоры жанрларын “Багу поэзиясе” (бишек җырлары, юаткычлар, мавыктыргычлар), “Күңел ачу фольклоры” (нәүрүзләр, яңа ел теләкләре, сөрән салулар, эндәшләр, әйтенүләр, иярмешләр, үртәвечләр, такмаклар, такмазалар, тел көрмәкләндергечләр, алдавыч әкиятләр. әкиятләр, мәзәкләр), “Уен фольклоры” (уеннар, шобага әйтешләр, санамышлар, әйтешләр, алдавычлар) дигән төркемнәргә бүлеп карыйлар. Бу жанрлар функцияләре белән төрле булган кебек, төзелешләре ягыннан да аерылалар: алар арасында чәчмә характердагылары да, тезмә төзелешкә ия әсәрләр дә, сүзсез, хәрәкәтләр ярдәмендә башкарыла торганнары гына да бар.

Тикшерү объекты буларак “Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры” хезмәтенә тупланган һәм Рәшит Ягъфәров тарафыннан бастырып чыгарылган “Татар балалар фольклоры” китабында теркәлгән тезмә әсәрләр алынды. Шуны искәртеп үтү кирәктер: балалар фольклоры буларак тупланган әсәрләрнең теле тел- сурәтләү чаралары ягыннан фольклорның башка жанрларыныкыннан һич кенә дә калышмый. Мондый чаралар

исәбенә мәгънәдәш сүзләрнең кулланышын да кертеп карау зарур.

Синонимнар - телнең байлыгын күрсәтә торган чара булып саналалар, һәм аларның сөйләмдә кулланылуы бары уңай яктан гына бәяләнә ала. Галимнәр, мәгънәдәш сүзләр контекстта я амплификация (тезеп китү), яки каршы кую, яисә төрле тезмәдә яки җөмләдә әле берсен, әле икенчесен файдалану рәвешендә кулланылалар һәм төрле максатлардан файдаланыла алалар, дип исәплиләр.

Тезмә характерда булган балалар фольклоры әсәрләреннән – бишек җырлары, юаткычлар,мавыктыргычлар, күңел ачу һәм уен фольклоры әсәрләрендә кулланылган синоним берәмлекләрне тикшереп чыкканнан соң, түбәндәге нәтиҗәләргә килергә мөмкин:

1. Балалар фольклоры әсәрләрендә барысында да диярлек мәгънәдәш сүзләр кулланыла. Әмма үртәвечләр – теге яки бу уңай белән бер-берсеннән көлеп төзелгән тезмәләр. Алар бик кыска булалар һәм мәгънәдәш сүзләрне куллану мөмкинлекләре юк. Башка жанрлар исә, аеруча бишек җырлары, такмак һәм такмазаларларда синонимнар еш урын алалар. Мәсәлән, <u>Әлли итәр</u> бу бала, <u>Бәлли итәр</u> бу бала; Илебезгә тырышып, хезмәт итәр бу бала.

2. Бишек җырлары һәм юаткычларда синонимнарны бер үк контекстта тезеп китеп куллану еш очрый. Бу күренеш нигездә, түбәндәге максатлардан башкарыла: а) сүз аңлата торган күренешкә тулырак, күләмлерәк характеристика бирү өчен кулланыла. Мәсәлән, <u>Әлли-бәлли итәр</u> бу

<u>Йокыларга китәр</u> бу,
<u>Бәү-бәү итеп күз йомып,</u>
<u>Изрәп кенә</u> китәр бу.

ә) Сүзнең аерым төсмерен күпертеп күрсәтү өчен файдаланылалар:

Аю баласын чабам,
Бүре баласын чабам,
Бәхетле бул. <u>Тәүфикълы бул</u>
Ата-анаңа <u>ихтирамлы бул</u>, тәмле телле бул диң.

б) Бер үк мәгънәдәге сүзләр төрле мәгънәдәге сүзләр кебек кулланыла:

Исәнлеккә, саулыкка,
Тазалыкка, байлыкка,
Бакаларга ярлыкка,
Үзебезгә байлыкка (69)

в) Вакыйга күренешләргә биргән характеристика сүзнең мәгънә төсмерен төрлечәрәк куллану мөмкинлеген тудырганлыктан киләләр:

Әгузе билләһи, мин шалтыратыйм
Син дә дөбердәт!
Бисмилләһи рахманиррахман.
Төрткәләмә әле , Габдерахман! 93)

Шунысы кызыклы: бу мисалларда сүз уйнату ритм, рифма төгәллеген сакларга тырышу максаты белән бик уңышлы кулланыла, әмма тотрыклы гыйбарәләрнең төгәллегенә зыян килә.

3. Балалар фольклор әсәрләрендә дә, әдәби телдәге кебек үк, төрле тел берәмлекләре ярдәмендә барлыкка килгән мәгънәдәш сүзләр күпчелекне тәшкил итә. Алар арасында гарәп, фарсы, рус һәм төрки-татар сүзләреннән торган синоним парлар бик актив. Мәсәлән, мәктәп – мәдрәсә, Армия – Хәрби хезмәт, сандугач – былбыл, кайгы – хәсрәт, җен – пәри, сүз – кәлимә һ.б. кебек берәмлекләр еш кулланыла. Мәсәлән,

Такмакка да мин оста
Шакмакка да мин оста
Әти-әни эшкә кушса,
Мин авыру , мин хаста

Сөйләм такмаклары арасында исә, бары сүзләрне тәрҗемә итү характерында булган берәмлекләр генә дә очрый. Алар сөйләм телендә генә кулланыла торган гыйбарәләрне чагылдыру өчен дә, шул ук вакытта бары сүз уйнату, шаяру максатыннан да файдаланылганнар: *Ипи- хлеб, мука –он; Кафтан – чикмән, шуба – тун.* яки *Рано утром – иртә белән,Пошли – киттек базарга. Надо – кирәк бидрә- чиләк скорее – тизрәк.*

4. Сүзләр арасында мәгънәдәшлек бер контекст эчендә дә, төрле контекст җирлегендә дә күзәтелә. Беренче төр синонимнар контекстта тезеп китү характерында бирелсәләр, икенчеләре исә шул ук мәгънәнең җирле сөйләмдәге бирелешен күрсәтү өчен, яки

әдәби телдә кулланыла торган башка төсмерен белдерү өчен дә файдаланылалар. Мәсәлән,

Миндә гайрәт, миндә көч,
Миннән курка үрмәкүч,
Мич башына менгән идем.
Тараканга җитми көч.
Яисә
Иртән торып тышка чыксам,
Кәҗә көтү төшерә,
Табаларын кыра-кыра
әтәс коймак пешерә.

Ике тавык җырлап йөри
Кучат гармун уйната,
Шул тавышка чыдый алмый
Ата каз елап ята.

Яки әнә килә автомобиль
Төягәннәр өтерге
Куначага менгән идем
Әтәч тибеп төшерде.

Мисаллардан күренгәнчә, әдәби телдә кулланылышта булган әтәч сүзе – такмакларда фонетик һәм лексик диалектизмнары белән теркәлгән.

Песи, песи, пыстыр хан
Артына салам кыстырган
Саламына ут капкан
Йөгереп чыгып юл чапкан.

Безнең дә бар мәчебез
Сезнең дә бар мәчегез
Безнең мәче сезгә килсә
Зинһар, ишек ачыгыз.

Әргәдин, мәргәдин
Песәй йөри елгадан
Ул песәйне тотыгыз
Койрык астын ертыгыз.

Әлеге мисалларда исә *мәче* сүзенең мәгънәдәш берәмлекләре бирелә. Бу берәмлекнең “Синонимнар сүзлеге”нә теркәлгән *мачы, миябикә, мыраубикә* вариантлары да такмакларда урын ала.

5. Иярмешләр – кошлар тавышына охшатып авазлар чыгару , җәнлек булып сөйләшү, шулай итеп аларның холыкларыннан, тышкы кыяфәтләреннән көлеп, кеше сөйләменең аерым гыйбарәләреннән көлеп кызык табуны белдерә торган гыйбарәләр саналалар. Алар күбрәк шәкертләр тарафыннан чыгарылганлыктан, алынма гыйбарәләргә бай булалар. Шул ук вакытта, сүзнең мәгънә төсмерен арттыру максатыннан, синоним берәмлекләне дә еш кулланалар. Мәсәлән,

Мөһиммәтел мөслимин
Тавыктан да <u>көчлемен</u>
әтәчтән дә <u>батырмын</u>
кабыргаңны ватармын .

6. Синонимнар мондый әсәрләрдә техник максатлардан (рифмага туры китерү өчен; күләм һәм гармонияне саклау өчен; бер үк сүзне кабатламас өчен, сүз уйнату, кызыклык тудыру өчен), аеруча күп кулланылуы мәгълүм булды.

Гомумиләштереп шуны әйтергә мөмкин: балалар фольклоры халкыбызның поэтик һәм педагогик мирасы ул. Анда тәрбия, зирәклек, фәлсәфә һәм тел җорлыгы тигез дәрәҗәдә урын алып, гасырлар дәвамында яшь буынны тәрбияләп килә. Шуңа күрә алар тел байлыгының матурлыгын күрсәтүдә,аларны саклап калып өйрәтүдә, мәгънәдәшлек вариантларын тәкъдим итүдә дә зур вазифа үтиләр.

Әдәбият

Горбочевич К.С. Вариативность слова и языковая норма (на материале современного русского языка) / К.С. Горбочевич. – Л: Наука, 1978. -321 с.

Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры/ төз. Р.Ягъфәров. – Казан: Тат. китап. нәшр., 1993. – 336 б.

Уфимцева А.А. Роль л ексики в познании человеком действительности и в формировании языковой картины мира / А.А. Уфимцева//Роль языкового фактора в языке. – М.: Наука, 1988. -231с.

Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф.С. Синонимнар сүзлеге / Ш.С.Ханбикова, Ф.С.Сафиуллина . – Казан: Хәтер, 1999. -256 б.

Егоров А.Н.

Литературный процесс «оттепели» в формировании нового поколения татарской творческой интеллигенции

Последние годы правления И.В. Сталина прошли под знаменем борьбы с космополитизмом и проявлениями национального самосознания в культуре. Данная тенденция негативным образом сказалась на состоянии всей отечественной литературы. Установка на пропаганду советского патриотизма привела к устранению из творческого процесса остатков критического отношения к советской действительности, внедрению в учебную программу филологических отделений вузов произведений официозной направленности. Тем не менее, ущерб, нанесённый русской литературе сталинизмом, несопоставим с потерями татарской писательской среды. Проповедуемая высшим руководством страны идеология великодержавного шовинизма отказывала татарам в праве на историческую память. Под строжайшим запретом находилось изучение памятника средневековой поэзии дастана «Идегей», произведения Дэрдменда, Г. Исхаки, Ш. Бабича и ряда других основоположников новой татарской литературы. В годы большого террора в тюрьмах НКВД погибли такие талантливые писатели как Ш. Усманов, Г. Нигмати, Дж. Валиди и С. Сунчелей.

От дальнейшего упадка татарскую литературу спасла начавшаяся вскоре после смерти И.В. Сталина либерализация общественно-политической жизни страны. Параллельно с кампанией по борьбе с последствиями культа личности, полным ходом шёл реабилитационный процесс. К читателям вернулись произведения К. Наджми, М. Крымова, И. Рами и других репрессированных в сталинские годы авторов. В декабре 1956 года в журнале «Совет эдэбияты» после мн6оголетнего перерыва были опубликованы стихи Х. Туфана. Свидетельством активизации литературной жизни республики явилось становление нового поколения татарских писателей, представленного такими яркими именами как Р.А. Мустафин, Н.Ш. Хисамов, Р.К. Закиев и Р.А. Файзуллин. Почти все они учились на отделении татарского языка и литературы историко-

филологического факультета КГУ, ставшего в 1950 – 1960-е годы главной кузницей кадров национальной творческой интеллигенции.

Цель работы заключается в комплексном исследовании влияния литературного процесса «оттепели» на умонастроения студентов филологических специальностей Казанского университета. В процессе достижения поставленной цели необходимо ответить на ряд вопросов: Какое значение в формировании политических убеждений студентов-филологов играл социальный фактор? Как учащиеся отделения татарской филологии оценивали советскую национальную политику? Каким было отношение «русских филологов» из числа татар к своей национальной идентичности?

Методология проведённого исследования основана на принципах качественной социологии. Качественный подход направлен на «изучение социальных явлений и процессов, прежде всего, с точки зрения действующего индивида как начала любой социальности, интерпретирующего мир вместе с другими людьми, действующего в соответствии со своими интерпретациями». [1, 81] Применительно к нашей исследовательской ситуации речь идёт о реконструкции политического мировосприятия студентов-филологов в контексте литературного процесса «оттепели». С этой целью были опрошены 10 выпускников Казанского университета – по 5 респондентов от каждого из отделений филологического профиля. В процессе интервьюирования им задавались вопросы, затрагивающие проблему влияния политики на культурную жизнь общества.

К числу наиболее актуальных тем «оттепельной» литературы относится проблема плачевного состояния советской деревни в послевоенные годы. Её постановка в русской прозе связана с публикацией в журнале «Новый мир» рассказа А. Солженицына «Матрёнин двор». В татарской литературе настоящим откровением для читателя стали «Три аршина земли» (1962) А. Гилязова. Повесть имела огромный резонанс среди учащихся отделения татарской филологии.

> *«Народ читал, потому что он критиковал политику партии в 30-е годы. Раскулаченные – люди без вины*

виноватые. У героя умирает жена, и в предсмертном состоянии она просит мужа, что она хочет вернуться на Родину, а он нет. Это очень трогательное, сильное произведение». (М., 68 лет)

В известной степени, популярность произведения А. Гилязова на отделении объяснялась тем, что основную массу местного студенчества составляли выходцы из сельской местности. Многие из них на себе испытали последствия коллективизации и последующих мероприятии аграрной политики И.В. Сталина.

«Ещё до революции отец матери был деревенским купцом. Нас после революции и по отцовской линии, и по материнской линии раскулачили. Даже из дома выселяли, но потом вернули, потому что отец отказался от своих земельных владений». (Ж., 70 лет)

Проблема сохранения национального самосознания в условиях проводимой властью политики культурной ассимиляции на протяжении всего советского периода беспокоила лучших представителей творческой интеллигенции республики. По идеологическим соображениям эта тема не могла быть поднята в печати. Это на практике доказал С. Баттал. В 1970 году он попытался опубликовать повесть «Я отрекаюсь» – сатирическое изложение русификаторских устремлений ЦК КПСС. Вопреки стараниям автора, рукопись оказалась доступной широкой общественности, только в наши дни. [2, 201 – 202] Тем не менее, национальная проблематика в той или иной мере присутствует в творчестве большинства татарских писателей-«шестидесятников». Свою роль в формировании гражданского самосознания Н. Хисамова, Р. Файзуллина, Р. Гатташа и других современных авторов сыграл научно-исследовательский и творческий кружок при кафедре татарской литературы КГУ. Его руководителями в 1950 – 1960-е годы были такие университетские преподаватели, как М. Закиев, И. Нуруллин и З. Мазитов. По воспоминаниям выпускников на заседаниях литературного кружка преподаватели и приглашённые писатели часто говорили об исторических традициях национальной культуры, утраченных за годы советской власти.

«Запомнился Накый Исанбет. Я помню, в 70-е годы мы организовали по своему отделению в общежитии встречу. И он

нам рассказывал, какое у нас богатое наследие. Но из-за смены алфавита, закрытия татарских школ мы его почти лишились. Тогда это слово ещё не употреблялось, «монкырт». Мы уже не помним свою богатую историю. Вот такой состоялся разговор». (М., 68 лет).

Ярким событием культурной жизни Советского Союза стало проведение в Москве декады татарской литературы (1957). В рамках этого мероприятия в ряде столичных театрах с успехом прошли постановки пьес К. Тинчурина, Н. Исанбета и других ведущих драматургов Татарстана. Наконец, в разговоре о политических убеждениях студентов татарского отделения не будем забывать о новых веяниях в политике партии, произошедших после смерти И.В. Сталина. Именно в годы «оттепели» были отменены несправедливые оценки сталинского времени в отношении эпоса «Едигер» и других памятников средневековой татарской литературы. В 1960 г. на отделении Татарской филологии университета была создана самостоятельная кафедра Татарского языка, положившая начало возрождению тюркологии в республике.

Частичная реабилитация культурного наследия татарского народа способствовала пробуждению национального самосознания у студентов отделения. Данная тенденция, в частности, нашла отражение в неприятии местной молодёжью официального прочтения обстоятельств присоединения территории Казанского ханства к России. По сложившейся в советской историографии традиции, события более чем 500-летней давности оценивались исключительно с точки зрения победившей стороны. Альтернативное мнение студенты имели возможность свободно высказать только на заседаниях научно-исследовательского кружка, функционировавшего на кафедре татарской литературы. Выпускница отделения татарского языка и литературы 1960 года выпуска вспоминает, как один из её однокурсников, будущий известный поэт Н.Ш. Хисамов написал стихотворение-размышление, посвящённое памятнику воинам Ивана Грозного. В нём автор справедливо заметил, что в войне 1552 года были жертвы не только с русской, но и татарской стороны, и об этом нужно помнить. Для того времени это было равносильно пропаганде национализма. Тем не менее, в роли

добровольных критиков молодого поэта выступили ведущие преподаватели историко-филологического факультета И.З.Нуруллин и Р.И. Нафиков.

«Существует легенда, что под памятником войнам Ивана Грозного 400 татарских голов лежат. Про это Нурмухамет (Н.Ш. Хисамов – примечание А.Е.) написал стихотворение, и прочитал его нашим преподавателям, Рафику Измайловичу Нафикову и Ибрагиму Нуруллину. Они послушали и сказали: «Ты нигде больше это не читай». (Ж., 70 лет).

Из приведённого отрывка интервью видно, что в формировании нового поколения национальной творческой интеллигенции трудно переоценить роль университетских преподавателей. Среди них нужно отметить не только специалистов в области татарской словесности, но и отдельных представителей партийной науки. На рубеже 1950 – 1960-х годов сотрудники кафедры истории КПСС Р.И. Нафиков и А.Х. Бурганов фактически стали основоположниками нового направления в изучении проблемы формирования и развития национальной политики большевиков. К примеру, в 1957 г., тогда ещё начинающий учёный, Р.И. Нафигов представил на обсуждение кафедры статью «О деятельности М. Вахитова и руководимого им МСК». В подготовленной на статью рецензии А.А. Шишкиным содержится ряд замечаний, наглядно показывающей смелость и новизну авторского подхода. В частности, серьёзные нарекания рецензента вызвала фраза Р.И. Нафигова о том, что «Вахитов М.Н. стоял за государственную культурно-национальную автономию во главе с рабочим классом, с общими вооружёнными силами пролетариев различных национальностей». [3, 50 – 51] Учитывая, что В.И. Ленин являлся сторонником национал-федерализма, тезис Р.И. Нафигова ставил под сомнение официальную картину взаимоотношений ЦК РКП(б) и социалистов-мусульман после Октябрьской революции.

О несоответствии учебной программы интеллектуальным запросам студентов татфака говорят и материалы архивных фондов. К примеру, на заседании партийного комитета КГУ от 20 декабря 1954 г. было отмечено, что успевающие студенты на кафедре Татарского языка и литературы игнорируют работу преподавателей общественных дисциплин. [4, 151]

Отличная от той, что была на отделении татарского языка и литературы обстановка сложилась на других подразделениях университета, в особенности на отделении русского языка и литературы. Не случайно, что крупнейший представитель русскоязычной словесности республики Р.А. Кутуй в студенческие годы принадлежал к сообществу «русских филологов». Представители местного национального студенчества в качестве главного достоинства своего поколения назвали отсутствие этно-конфессиональных различий. Одна из выпускниц геологического факультета призналась, что в студенческие годы она даже не задумывалась о своей принадлежности к татарской нации.

Я мыслила по-русски. То есть мы обрусевшие все. И я считаю, что в моём случае это позитивно. Нам это не дано, ни в семье, ни в государстве. Родственники наши, по-русски говорили. И потребности главное не было». (Ж., 70 лет)

В большей степени, чем их коллеги с татарского отделения, «русские филологи» интересовались литературными дискуссиями периода «оттепели». Этому способствовала известная свобода слова, установившаяся в творческих союзах в преддверии и непосредственно во время работы 2-о II Всесоюзного съезда советских писателей (декабрь 1954 г.). В это время в печати появился ряд публикаций, в которых впервые за долгие годы было сказано, что творчество современных писателей часто грешит приукрашиванием действительности. Специфика филологического образования побуждала студентов находиться в курсе происходящих в литературе процессов. На факультете регулярно устраивались обсуждения нашумевших произведений и критических статей. Вопреки стараниям преподавателей убедить студентов в заблуждении оппозиционных авторов, мероприятия не всегда шли по сценарию. К примеру, на заседании партийного комитета КГУ от 13 сентября 1954 г. была высказана жёсткая критика в адрес коллектива кафедры Русской литературы. На диспуте посвящённом статье Померанцева «Об искренности в литературе» сотрудники кафедры «не смогли дать отпор в корне неправильным выступлениям студентов Царегородцева, Мустафина, Золотусского, Волошина, Чебаева». О серьёзности

инцидента говорит тот факт, что он получил освещение на страницах «Советской Татарии». Ректор Казанского университета К.П. Ситников вынужден был поставить вопрос «о неправильной расстановке кадров на кафедре». [4, 96 – 97]

Таким образом, новые веяния в литературной жизни Республики Татарстан периода «оттепели» соответствовали умонастроениям основной массы студентов татарского отделения. Актуальные проблемы послевоенной деревни и недостатки советской национальной политики неоднократно обсуждались на заседаниях научно-исследовательского и творческого кружка под руководством доцентов И. Нуруллина и М. Закиева. При поддержке ряда ведущих писателей, таких как Х. Туфан, Г. Кашшаф и Р. Тухватуллин на отделении было организовано издание стенной газеты «Эдэби суз» и студенческого литературного альманаха (с апреля 1962 года). Данные издания познакомили писательскую общественность республики с творчеством тогда ещё совсем молодых авторов – Н. Хисамова, Р. Гатташа, Р. Файзуллина. Они же стали первым опытом журналистской деятельности для А. Яхина и Р. Закиева. Благодаря этим институциям, профессорско-преподавательский корпус татфака сыграл роль посредника идей и традиций между двумя поколениями национальной творческой интеллигенции – поколением 1930 – 1940-х годов и так называемыми «шестидесятниками». На этом фоне вклад отделения русского языка и литературы в культурную жизнь татарского народа выглядит более скромным. Отсутствие творческих контактов с представителями татарской интеллигенции не способствовало развитию у студентов-татар национального самосознания.

Примечание: При написании статьи, автор использовал выдержки из интервью выпускников отделения татарского языка и литературы Ф.М. Хисамовой, Х.Ю. Миннегулова, Р.К. Закиева, выпускницы геологического факультета Д.Г. Насыровой.

Литература и источники

1. Готлиб А.С. Введение в социологическое исследование: Качественный и количественный подходы. Методология. Исследовательские практики: Учебное пособие. / А.С. Готлиб;

Под ред. Т.И. Кузнецовой. – Самара: Изд-во Самар. ун-та, 2002. – 424 с.
2. Мустафин Р.А. Силуэты: Литературные портреты писателей Татарстана. / Р.А. Мустафин. – Казань: Таткнигоиздат, 2006. – 354 с.
3. НАРТ. Ф. 1337. Оп. 44. Д. 138/
4. ЦГАИПД РТ. Ф. 624. Оп. 1. Д. 291. Л. 151

Закирҗанов Ә.М.

Хәзерге татар әдәбият белеме проблемалары

Җәмгыятьтәге социаль-мәдәни һәм идеологик үзгәрешләр татар әдәбият белеменә зур йогынты ясый. Әлеге фәннең һәр тармагында җитди эзләнүләр башланып, әдәбият тарихы, әдәбият теориясе, әдәби тәнкыйтьнең барлыкка килү алшартларын, формалашуын ачыклау, төп этапларын, татар галимнәре таянган нигез концепцияләрне, методларны билгеләү һәм үсеш-үзгәреш юлларын барлау белән бәйле. Үткән мираска тәнкыйди караш, аны яңача бәяләү дә мөһим сорауларның берсе буларак куела. Шуның белән бергә, рус һәм Көнбатыш Европа әдәбият белеме казанышларын үзләштерү, татар әдәбият белеменең дөньякүләм процесстагы урынын, үзара бәйләнеш-йогынтыны ачыклау мәсьәләсе дә калкып чыга.

Әлеге сораулар белән янәшә фәннең үз методологиясен эшләү кирәклеге дә көн тәртибенә куела. Татар әдәбият белеме методологиясе буенча әлегә махсус хезмәтләр юк. Әмма бу мәсьәлә гомумән эшләнмәгән дигән сүз түгел. Методологик сораулар конкрет тикшеренүләрдә, аеруча әдәбият тарихына һәм теориясенә караган хезмәтләрдә билгеле бер дәрәҗәдә чагылыш тапты. Шулай да озак вакытлар дәвамында фәнни эзләнүләрнең анализланып системага салынмавы яңа тикшеренүләргә тоткарлык ясый. Болар барысы да XX гасыр ахырында татар әдәбият белеме методологиясенә караган берничә сорауның көн тәртибенә куелуына һәм эзләнүләр башлануына китерә. Берсе – алдагы чорларда өстенлек иткән идеология белән бәйле булып, фәнни тикшеренүләрне марксизм-ленинизм тәгълиматыннан арындыруга кайтып кала. Каршылык-бәхәсләр аша “әдәбият теориясенең эчке закончалыклары, әдәби-тарихи барышны

өйрәнү принциплары”[1.14] эзләнүләр нигезе булырга тиешлеге ачыклана.

Икенче сорау әдәбият теориясен һәм әдәбият турындагы фәннең методологиясен аерып карау белән бәйле. Үзара тыгыз бәйләнештә булган әлеге төшенчәләрнең өйрәнү объектлары төрле: әдәбият теориясе әдәби иҗатның закончалыклары һәм категорияләре белән эш итсә, әдәбият белеме методологиясе әлеге закончалыкларны һәм категорияләрне фәнни тикшерү принципларын билгели[2.17]. Ф.Мусин, Ф.Хатипов, Й.Нигъмәтуллина, Д.Заһидуллина хезмәтләрендә бу сорауларга шактый тулы ачыклык кертелеп, өйрәнү өлкәләре аерып куела.

Методологиягә караган мөһим сорауларның тагын берсе – татар әдәбият белеменең үзенә хас принципларын булдыру. Билгеле инде, үзара якын әдәби-мәдәни мохиттә яшәгәнлектән, татар әдәбият белеме рус һәм башка тугандаш халыклардагы фәнни казанышларны үзләштерә, аларга таяна. Әдәбият теориясенә, әдәбият тарихына, әдәби тәнкыйтькә караган хезмәтләрдә характерлы билге-күренешләрне билгеләү, тенденцияләрне аерып чыгару өчен дөньякүләм кабул ителгән методологик принципларга нигезләнү табигый күренеш. Шуның белән бергә, соңгы ике дистә елда татар әдәбият белеменең үзенә хас методологик принципларын ачыклау буенча аерым хезмәтләр дөнья күрде[3]. Алар, нигездә, әдәбият тарихын яңача өйрәнүне күздә тотсалар да, методологик планда бөтен әдәбият белеменең нигезен билгеләүче сыйфатлар булып ачыла. Ф.Мусин болай дип яза: “Инде халыкның иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни-рухи үткәнен милли идея яссылыгында өйрәнүнең төгәлрәк методологик принциплары мәсьәләсенә килсәк, монда, безнең карашча, барыннан да элек тарихилык һәм миллилек турында сүз алып барырга кирәктер”[4.18]. Дөрес, әлеге принциплар яңа түгел. Тарихилык сүз сәнгате тарихына мөнәсәбәттә XX йөз башында ук куела һәм ул әдәбиятне эзлекле үсеп-үзгәреп торучы, җәмгыять тормышы белән тыгыз бәйләнештә булган, билгеле бер закончалыкларга буйсынучы, традицияләрнең яңачалыклар белән үрелеп баруына нигезләнүче күренеш буларак аңлатыла. А.Веселовский, Д.Лихачев, А.Бушмин хезмәтләрендә ул теоретик һәм гамәли ачылышын таба. Ф.Мусин әлеге принципның мәгънәләрен тагы да киңәйтеп, бер яктан, әдәбиятның аерым

чорлары арасындагы үзара бәйләнешнең асылын нигезләсә, икенче яктан, “халкыбыз тарихы белән рухының үзенчәлекле елъязмасы һәм көзгесе булуы сәбәпле, әдәбиятны үзалдына гына карау җитми, аны милли тарих, тел, халык иҗаты, иҗтимагый-фәлсәфи фикер үсеше һәм башкалар белән бәйләнештә дә өйрәнергә кирәк”[4.20] дип саный.

Миллилек принцибы 1917 елга кадәрге әдәбият белемендә киң урын алса да, Совет чорында аның эчтәлеге, гадәттә, соцреализм эстетикасы эчендә генә билгеләнә иде. Шуңа да гаять әһәмиятле принцип булудан бигрәк, теге яки бу халык әдәбиятының бер үзенчәлеге рәвешендә күрсәтелеп киленде. Хәзер исә миллилек принцибы әдәбият турындагы фәнне халык язмышы, аның бүгенгесе һәм киләчәге, менталь сыйфатлары белән тыгыз бәйләнештә һәм милли идеягә нигезләнеп өйрәнүне күздә тота.

XX гасырның 80-90 нчы елларында, идеологик шартлар үзгәрүгә бәйле, чит илләрдәге әдәбият белеме казанышлары белән танышу мөмкинлеге туды. Бигрәк тә Көнбатыш Европада һәм Америкада сүз сәнгате өлкәсендә алып барылган һәм аеруча әдәби мәктәпләр, әдәби концепцияләр, әдәби методлар өлкәсендәге эзләнүләр әдәбият белеменең барлык тармаклары турындагы карашларыбызны, тикшеренү объектларының асылын аңлатуны киңәйтеп җибәрде. Рус әдәбият белеме әлеге яңалык-табышларны кабул итүгә әзер булып, фәнни эзләнүләрнең яңа баскычына күтәрелде.

Татар әдәбияты белеме исә аларга шактый каршылыклы мөнәсәбәттә булды. Моның берничә сәбәбе бар. Берсе – татар әдәбият белеме үзенең традицияләренә турылыгы белән көчле. XX йөз башы әдәби тәнкыйтендә һәм әдәбият теориясендә реализм һәм романтизмның төп сыйфатлары ачыкланып, 1990 нчы елларга кадәр, нигездә, шул юнәлешләргә караган сәнгати фикерләү үзенчәлекләре өйрәнелде, ә инде бу кысалардан чыккан юнәлеш, агым, форма, чаралар я тискәре бәя алды, я күрмәмешкә салынылды. Икенчесе – 1930 еллардан башлап әдәбият белеме марксистик-ленинчыл идеология кысаларына кертелде. Милләтчелектә гаепләнүдән куркып, әдәбиятчылар милли сыйфат-билгеләр, үзенчәлекләр турында гомуми планда гына язарга тырыштылар. Шундый шартларда рус әдәбият белеменең

йогынтысы бик нык үсеп, күп кенә мәьәләләрдә татар әдәбият белеме ияреп бару яисә тәрҗемә итү юлына күчте. 1990 нчы еллар башында, милли идея үсүгә бәйле, читләр тәэсиреннән котылу омтылышы да көчәя. Шул рухта рус һәм чит ил әдәбият белемендәге термин-төшенчәләрне, теоретик караш-фикерләрне кабул итүгә сак килде. Өченчесе – профессиональ әзерлекле кадрлар белән бәйле. Башкаларда урын алган күренеш-билгене яңа җирлеккә турыдан-туры күчереп куярга ярамый. Ул, гадәттә, ясалмалылыкка китерә. Шуның белән бергә, әдәбият белеменең методологиясен һәм аерым тармакларының теориясен эшләү, шул нигездә фәнни тикшеренүләрнең юнәлешләрен билгеләү мөһим мәсьәлә булып калка. Ике гасыр чигендә дөнья күргән хезмәтләрдә билгеле бер нәтиҗәләргә дә ирешелде.

Әдәбият теориясенең асылын билгеләүче фәнни тема-аспектлар (гносеология, онтология, морфология, поэтика, семантика һәм риторика, рецептив эстетика, герменевтика һәм аксиология, тарихи поэтика, культурология) буенча махсус тикшеренүләр бик аз. Әлеге сораулар, нигездә, әдәбият тарихына, аерым әдипләр иҗатына караган хезмәтләрдә теге яки бу дәрәҗәдә чагылыш таба. Әдәбият теориясе белән бәйләнешле китаплар арасында “Әдәбият теориясенә кереш” (1987), “Әдәбият белеме сүзлеге” (1990), Ф.Хатиповның “Әдәбият теориясе” (2000) һәм “Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге” (2007) мөһим урын алып тора. Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы укытучы-галимнәре тарафыннан төзелгән “Әдәбият белеме сүзлеге” “әдәбиятның фәнни-теоретик нигезләрен аңлатучы иң актив атамаларны һәм төшенчәләрне үз эченә ала”. Ул, бер яктан, моңа кадәр чыккан сүзлекләргә, икенче яктан, рус әдәбият белеменә караган сүзлек һәм энциклопедияләргә, өченче яктан, татар әдәбият белеменең соңгы казанышларына нигезләнә. Марксизм идеологиясеннән тулысынча арынып җитмәсә дә, “Сүзлек” иҗтимагый аңның бер төре булган әдәбиятның эчке закончалыкларын, эчтәлек-формасын, традицияләр дәвамчанлыгын, теге яки бу чорга хас яңачалыкларны тулы, эзлекле күзалларга мөмкинлек бирә. Аның методологиясендә төп урынны дөнья әдәбиятындагы уртаклыклар һәм аларның милли әдәбият сыйфатлары белән баюы алып тора. Шуңа да теге яки бу закончалык яисә термин

дөнья әдәбиятына, рус әдәбиятына һәм татар әдәбиятына караган үрнәкләр-мисаллар нигезендә аңлатыла. “Әдәбият белеме сүзлеге”нең җитди яңалыгы булып, бер яктан, рус һәм дөнья әдәбияты белемендәге казанышларны үзләштерү, ягъни озак вакытлар дәвамында тәнкыйди рухта бәяләнеп килгән модернизм юнәлешен, агымнарын аңлаткан төшенчәләрне бай фактик материалга нигезләнеп тәкъдим итү (мәкаләләр авторы – Р.К.Ганиева); икенче яктан, күпгасырлык әдәбиятыбызның бай традицияләренә, Шәрык әдәбиятлары белән бәйләнешенә һәм сүз сәнгатенең аеруча Борынгы, Урта гасырлар дәверенә караган термин-төшенчәләрне күчемле бәйләнештә аңлату (мәкаләләр авторы – Х.Ю.Миңнегулов) тора.

Ф.Хатиповның “Әдәбият теориясе” татар әдәбият белеме ирешкән казанышларны бер системага салуның уңышлы үрнәге булып тора. Студентлар һәм укучылар өчен атап чыгарылган дәреслек булуы эчтәлеккә йогынты ясаган. Профессиональ филологлар әзерләүгә йөз тоту әдәбият теориясенә караган төшенчәләрнең асылын, үзара бәйләнешен аңлатуны, әдәби әсәр, аның компонентларын тикшерүне алгы планга чыгара. Шуңа да әдәбият теориясенең әдәби әсәрнең бөтенлеге, аның төрләре, жанрлары һәм жанр формалары, эчтәлек һәм форма, сюжет һәм композиция, иҗат тибы, стиль, метод кебек төп төшенчәләрне ачыклауга киң урын бирелә.

Хезмәтнең методологик нигезе булып татар, рус, чит ил әдәбият белеме туплаган күпгасырлык традицияләр, әдәби-эстетик, фәлсәфи карашлар системасы тора. Бу исә авторга киң планда Аристотель, Гегель, В.Белинский, Н.Чернышевский кебек классикларга таяну, фикер-карашларын үстерү мөмкинлеге бирә. Икенче төрле, Ф.Хатипов әдәби әсәрне өйрәнүнең киң таралган методларына (биографик, чагыштырма-тарихи, социологик, структур, герменивтика һ.б.) нигезләнә, ягъни ул әдәбият теориясенең комплекслы юлын тәкъдим итә. Шуның белән бергә, автор әдәбият теориясенең бәхәсләр уяткан сорауларын - әдәбиятның яшәү рәвеше, әдәби барыш закончалыклары, әдәби юнәлешләр, агымнар һ.б. – читләтеп үтә. Ә бит алар әдәбиятны системалы рәвештә әдәби-тарихи барыш эчендә өйрәнү, бәяләү мөмкинлеге бирә.

Әдәбият тарихы – алдагы чорда да, хәзер дә игътибар үзәгендә булып, чагыштырмача киңрәк өйрәнелә торган тармак. Тикшеренүләрдә дөнья һәм рус әдәбияты белемендә кабул ителгән методлар (мифологик, чагыштырма-тарихи, биографик, культура-тарих, комплекслы, компаративистика, социаль-эстетик, психологик, герменевтика, формаль, структур, тарихи-генетик һ.б.) нигез булып тора. Мисал өчен, М.Бакиров, Ф.Урманчиев кебек галимнәр үз тикшеренүләрендә мифологик методка нигезләнсә, Х.Миңнегулов чагыштырма-тарихи методны үз итә, Р.Ганиева исә герменевтикага, чагыштырма-тарихи һәм социаль-эстетик методга таяна. Әдәбият тарихын өйрәнүнең җитди нәтиҗәсе булып XX һәм XX1 гасыр чигендә “Средневековая татарская литература”, “История татарской литературы нового времени (X1X-начало XX века)”, “Татар әдәбияты тарихы”ның У1 томы басылып чыгу тора.

Хәзерге әдәби тәнкыйть күп бәхәсләр уяткан һәм тәнкыйтькә дучар булган тармак булып кала. Бу, беренче чиратта, аның үз вазыйфаларын үтәмәве белән аңлатыла. “Китап дөньясы үзе бик чуарланды, художество-эстетик кыйммәте булмаган чүп-чар чын җәүһәрләр белән бер шүрлеккә менде. (...) Критерийларның югалуы, әдәби тәнкыйтьнең юк дәрәҗәсендә булуы, әдәбият белән кызыксынучыларны, бигрәк тә яшьләрне авыр хәлгә куйды”[5.6], - дип яза Р.Фәйзуллин. Икенче яктан, әдәби тәнкыйтьнең әдәби-эстетик югарылыкта кала алмавын күрәбез. Йомшак әсәрне мактау белән мавыгу яисә уңышлы әсәрне күрмәмешкә салышу очраклары да ешаеп китте. Хәзерге әдәби тәнкыйтьнең үсеш-үзгәреш юлына чыгу юлын Д.Заһидуллина “фәнни, академик тәнкыйтьне үстерүдә, һәр шагыйрь, прозаик яки драматургның әдәби барыштагы урынын, нинди иҗат юнәлеше, алымы тарафдары булуын билгеләүдә”[6.149]күрә. Чит ил һәм рус әдәбият белемендә шактый тулы өйрәнелгән тәнкыйть юнәлешләренең (рецептив, психоаналитик, стилистик, импрессионистик, социологик, генетик, мифологик, феминистик, субъектив һ.б.) бездә тиешенчә чагылыш тапмавына китерә. Тәнкыйтьчеләрнең күпчелеге әдәби әсәрнең чынбарлык белән мөнәсәбәтен тема, проблема, идея һ.б. нисбәтле тикшерүне максат итә (М.Вәлиев, Р.Шәрәфиев, Р.Фәизов һ.б.). Сүз сәнгатенә тел ягыннан бәя бирүнең сирәк,

әмма уңышлы үрнәкләрен Ф.Сафиуллина тәкъдим итте. Соңгы елларда Ф.Урманчиев, М.Ибраһимов, Л.Дәүләтшина һ.б. хезмәтләрендә мифологик тәнкыйть белән очрашабыз. Ә менә И.Вәлиулланың мәкалә-язмалары чынбарлыкны танып-белү чарасы буларак әдәби әсәргә эстетик планда якын килүнең, ягъни яңа тәнкыйтьнең бер чагылышы булып тора.

Шулай итеп, иҗтимагый-мәдәни тормыштагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә, татар әдәбият белеме үсешенең яңа этабына керде һәм ул үзенең традицияләрен нигез итеп, рус һәм чит ил сүз сәнгате фәнендәге казанышлардан файдаланып, әдәбият тарихы, теориясе, тәнкыйте тармакларындагы табышларны, проблемаларны ачыклау аша киләчәккә үсеш сукмакларын, яңа тикшерену юлларын билгеләүгә йөз тота.

Әдәбият

1. Заһидуллина Д. Әдәбият кануннары һәм заман /Д.Заһидуллина.- Казан: Татар.кит.нәшр., 2000.- 271 б.
2. Бушмин А.С. Наука о литературе: Проблемы. Суждения. Споры / А.С.Бушмин.- М.: Современник, 1980.- 334 с.
3. Әхмәдуллин А. Татар совет драматургиясен яңача өйрәнү мәсьәләләре /А.Әхмәдуллин // Дөреслеккә ирешү юлында.- Казан: Татар.кит.нәшр., 1993.- 7-16 б.; Хәсәнов М. Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең кайбер методологик мәсьәләләре / М.Хәсәнов // Казан утлары.- 1992.- № 1.- 141-147 б.; Галиуллин Т. Татар поэзиясе тарихын яңача өйрәнү мәсьәләләре / Т.Галиуллин //Шигърият баскычлары.-Казан: Мәгариф, 2002.- 9-19 б.; Мусин Ф. Татар әдәбияты тарихы һәм заман / Ф.Мусин //Мирас.- 1996.- № 1-2.- 18-29 б.
4. Мусин Ф. Татар әдәбияты тарихы һәм заман /Ф.Мусин //Мирас.- 1996.- № 1-2.- 18-29 б.
5. Фәйзуллин Р. Яңа елда яңарган уйлар / Р.Фәйзуллин // Казан утлары.- 2002.- № 1.- 3-6 б.

Йосыпов А.Ф.

XIX гасыр татар поэзиясе телендә гарәп-фарсы элементлары

XIX гасыр татар әдәби теле - тел тарихында үзенчәлекле-кызыклы чорларның берсе. Аның бер үзенчәлеге берничә вариантлы, күпкатламлы булуы белән билгеләнсә, икенчедән, бу чор иске татар әдәби теленнән хәзерге әдәби телгә күчешнең башлангыч ноктасы да булып тора. XIX йөз татар поэзиясе теле тел үсешендәге төп тенденцияләрне һәм каршылыкларны, шушы вакыт аралыгында барган үзгәрешләрне, әдәби нормаларның урнашу юлларын чагылдыруы ягыннан кызыклы. Әлеге чор шигъри вариантларының берсе гарәп-фарсы телләренә хас грамматик категорияләренең кулланылуы белән билгеләнә. Гарәп-фарсы грамматик чараларының активлыгы шагыйрьләрнең көнчыгыш әдәби тел традицияләренә йөз тотуы, аеруча суфи поэзия теле традицияләрен сакларга омтылышлары белән аңлатыла. Әлеге үзенчәлек һәр грамматик категориядә диярлек чагыла.

Тартым категориясе мәгънәсен гарәп-фарсы формалары ярдәмендә белдерү. I затка караган **тартым мәгънәсен** бирүдә фарсы әдәби теле өчен норма булган **кушма алмашлыклар** да катнашырга мөмкин. Иялек мәгънәсен белдерү өчен исемнәргә фарсы телендәге -am, -äm I зат кушма алмашлыклары ялгана. Алар төрки тартым аффиксларыннан бары тик фонетик яклары белән генә аерылып торалар. Мәсәлән: γaribäm, xaqdan üzgä mönisem juq [4, 96] «гарибем, хактан башка тегәнем юк».

-am, -äm I зат фарсы кушма алмашлыклары, татар тартым аффикслары кебек үк, ендәш сүзләр формалаштыруда да катнашалар. Алар затка яратып, иркәләп һәм якын итеп ендәшкән вакытта төрле сүзләргә ялганалар. Бу очракларда тартым мәгънәсе йомшара төшә: xodavändäm, säŋadyr ibtihal [4, 106] «тәңрем, сиңа ялвару (тәңремә ялыну)».

Тартым мәгънәсен тәгъбир итүдә **фарсы изафә тезмәләре** дә катнашырга мөмкин: <u>nuγmät-э</u> <u>xaq</u> dörleder, - alγyl sabaq [4, 125] «хакның нигъмәте төрле, – сабак ал».

Тикшерелә торган шигъри текстларда тартым категориясен **гарәп телендәге изафә тәркибе** белән дә белдерү очраклары бар: belgel, allax wälijü äl-mö′minin [4, 125] «бел, аллах мөэмин-мөселманның яклаучысы».

Шигъри әсәрләр телендә зур күләмдә **«ватык» күплек саны** формасында гарәп лексикасы кулланыла. Гарәп телендә утыздан артык ватык күплек саны ясалу моделе кулланылышта йөри. Шулар арасыннан **äfγäl** «әфгъәл», **fäγani** «фәгани», **äfγilä** «әфгъиләә», **fäγail** «фәгаил», **äfäγil** «әфәгъил» формалары XIX йөз татар поэзиясе телендә урын ала. Тикшерүләр күрсәткәнчә, күплек сандагы исемнәр, нигездә, **äfγäl** «әфгъәл» моделендә ясала. Мәсәлән: äγmäl (әгъмал) [4, 102] «эшләр», ätraf (әтраф) [4, 85] «тирә-як, әйләнә-тирә» һ.б.

Моннан тыш, татар теленә хас күплек мәгънәсен бирүдә “ватык” күплек формасындагы гарәп сүзләренә дә мөрәҗәгать ителә: cömlä ärwaxnyŋ gidasy bondadyr [4, 112] «барлык рухларның да ярлырагы мондадыр».

Тикшерелә торган поэтик әсәрләрдә, нигездә, гарәби һәм фарси чыгышлы алынма лексикага зур урын бирелә. Алынма сүзләр арасында **сыйфатлар** күпчелекне тәшкил итәләр. Шигырьләрдә **fäγil** (фягиль) моделе белән фигыльләрдән ясалган гарәп сыйфатлары кулланыла: bäγid [4, 107] «ерак», γafifä [4, 121] «чиста, бозылмаган» һ.б.

Гарәби чыгышлы сыйфатлар чагыштыру дәрәҗәсендә дә киләләр: äxsan «яхшырак, иң яхшы»: dine islam šöker äxsandyr, I jar [4, 125] «ислам дине шөкер иң яхшыдыр, әй яр».

XIX гасыр поэтик әсәрләрендә төп юнәлештәге гарәби чыгышлы сыйфат фигыльләр дә сыйфат функциясендә кулланылалар: baqyj «калган, мәңгелек»: baqyj γömrem ähle täqwalar ilän kičsen bänem [4, 87] «калган гомерем дини кешеләр белән кичсен минем».

Шигырьләрдә тамыр фарсы сыйфатлары белән бергә ясалма сыйфатлар да актив кулланыла, аеруча **bi (би)** һәм **na (на)** префикслары белән ясалганнары күпчелекне алып торалар: bisäbäb [4, 110] «сәбәпсез», nadan [4, 113] «надан», nabikär [4, 110] «эшсез» һ.б.

Фарсы сыйфатларына төрки телләр өчен хас булган **-raq / -räk** чагыштыру дәрәҗәсе аффиксы да ялганырга мөмкин: bu ikeneŋ arasynda bälki budyr bädrake [4, 111] «между этими двумя это, возможно, хуже».

Тикшерелә торган поэтик әсәрләр телендә гарәби чыгышлы **рәвешләр** дә еш кулланыла. Гарәп телендә түбәндәге сүзләр рәвеш функциясендә йөриләр: misle [4, 111] ошаган, төсле кебек шикелле», aslan [4, 101] «һич, һичбер», cömlätän [4, 125] «бары бергә, барысы да, берьюлы», qaulän [4, 110] «сүздә, сүз белән», fiγlän [4, 110] «чынлыкта, дөреслектә, эш белән», bikulli [4, 85] «тулысынча» һ.б. Кайбер гарәп сүзләре гәрәп телендә рәвеш функциясен башкармасалар да, татар телендә рәвеш булып кулланылалар: mödam [4, 86] «өзлексез, һәрвакыт», daim [4, 95] «өзлексез, һәрвакыт».

XIX гасыр татар поэзиясе телендә гарәп алынма формаларының берсе **исем фигыль – масдарлар** актив кулланылышта йөри. Галимнәр фикеренчә, күпчелек гарәп исем фигыль – масдарлары татар телендә исемләшәләр. Әлеге күренешне М.Мәхмүтов татар теленең үз эчке закончалыклары белән бәйләп аңлата [2, 17].

Шигъри текстлар телендә түбәндәге төр гарәп масдарлары кулланыла: I баб (*tärк* [4, 93] «калдыру, ташлау»), *xäbär* [4, 97] «хәбәр», II баб (*tä'sir* [4, 86] «тәэсир итү»), III баб (*xitab* [4, 82] «мөрәҗәгать итү, сүз тоту», IV баб (*itaγät* [5, 417] «итәгать, буйсыну», *iman* [4, 81] «иман»), VIII баб (*ixtyjar* [4, 94] «ихтыяр», *intizar* [5, 415] «көтү», X баб (*istiqamät* [4, 124] «намуслылык, дөреслек ») һ.б.

Фарсы чыгышлы теркәгечләр өйрәнелә торган әсәрләрнең телендә киң кулланылышка ия. Тектларда алар еш кына төрки-татар чыгышлы теркәгечләрне алыштырып килә. Төзелеше ягыннан аларны *гади* (**кі** «ки», **čön** «чөн», **ägär (gär)** «әгәр», **häm** «һәм», **wäli** «әмма, ләкин») һәм *кушма* (**čönki** «чөнки» (**čön** + **кі**), **bälki** «бәлки» (каршы куючы **bäl** (әмма, ә) теркәгече + **ki** дән тора), **ägärčä (gärčä)** «гәрчә» (**ägär (gär) + če** «нәрсә» алмашлыгы) төрләргә аерырга мөмкин.

häm «һәм» тезүче төркәгече берничә функцияне үти:

1. Җөмләнең тиңдәш кисәкләрен бәйли: älem häm ajaүym baүly [4, 104] «кулым һәм аягым баулы».

2. Күренешләрнең бер-бер артлы килүен күрсәтә: barča ešläremdä bäŋa wirgel fällax, häm nasyjb äjlä bäŋa fäüz, fällax [4, 107] «барча эшләремдә миңа бир уңыш, һәм насыйб ит миңа эшләрне уңышлы тәмамлау, бәхет».

3. Аерым очракларда *-da / -dä* кисәкчәсе урынында килүе күзәтелә: can äzäldä ber-berene sümäsä, dönjada häm ber-beren säwešmäde [4, 100] «мәңгелектә җан бер-берен сөймәсә, дөньяда да бер-берен сөешмәс».

bälki «бәлки» и **wäli** «әмма, ләкин» <u>каршы куючы теркәгечләре</u> бер предметның, күренешнең яки эш-хәрәкәтнең икенчесенә каршылыгын белдереп килә: **bälki** däүwa ähleder – xar-zälil [4, 116] «бәлки дәгъва итүче – түбән кешедер»; äjü süz gärčä canlarүa үazadyr, **wäli** küb süzlämäklekdä xätär war [4, 108] «изге сүз гәрчә җаннарга азык булса да, әмма күп сөйләүдә хәтәр бар».

<u>Ияртүче теркәгечләр</u> аеруча актив һәм алар киң мәгънәви төрлелеккә ия:

čönki «чөнки» теркәгече ияртчен җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен хезмәт итә һәм сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләрен белдереп килә: čönki sadryna jasyldy үyjšqy xat [4, 82] «чөнки йөрәгенә гыйшык хаты язылды». Моннан тыш Ш.Зәки әсәрләре телендә әлеге теркәгечнең кыскартылган **čön** варианты да еш очрый: qasd idärmen canyma, čön susamyšym qanyma [4, 101] «начарлык эшлим җаныма, чөнки сусадым каныма».

ägär «әгәр» теркәгече һәм аның кыскартылган **gär** «әгәр» варианты ияртчен шарт җөмләне баш җөмләгә бәйләүче чара булып хезмәт итә. Өйрәнелә торган текстларда кыскартылган вариантның еш кулланылуы күзәтелә: ägär bän didekeme dota belsäm [4, 90] «әгәр мин сез әйткәнне тота белсәм», gär delärsän kem, dökänmäz däülätä irešäsän [4, 81] «әгәр теләсәң, бетмәс дәүләткә ирешәсең» һ.б.

ägärčä һәм **gärčä** «гәрчә» теркәгечләре ияртчен кире шарт җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла: ägärčä jazyqym čuq, azyүym juq [4, 96] «гәрчә языгым күп, азыгым юк», gärčä bu

bändä xodaγa qyjlmady lajyq γämäl [4, 94] «гәрчә бу бәндә ходага лаек гамәл кылмады» һ.б.

Ияртүче **ki** «ки» теркәгече төрле иярчен җөмләләрне баш җөмләгә бәйли һәм эш-хәрәкәтнең төп мәгънәсен ачыклый: šul jaŋa kitdem ki, andan kilmešem [4, 107] «шул якка киттем ки, аннан киләм».

Билгеле булганча, *ki* теркәгече һәрвакыт баш җөмлә составында килә [3, 339]. Әмма Ш.Зәки әсәрләре телендә аның иярчен җөмлә составында килү очраклары да билгеле. Бу вакытта *ki* теркәгече *čönki* теркәгече функциясендә килеп, сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтен белдерә: äzalät äjlä bändan bu γamany, ki fareq idäm döneme köndezemdän [4, 89] «мине бу кайгыдан (сукырлыктан) коткар, чөнки көнемне төнемнән аерам».

Гарәби чыгышлы теркәгечләр. Төзелешләре ягыннан алар *гади* (**wä** «һәм», **fa** «һәм», **bäs** «бәс, шулай булгач, димәк, нәтиҗәдә», **illä** «әмма, тик, ә инде», **jäγni** «ягъни») һәм *тезмә* (**wä läkin** «вә ләкин, ләкин, тик, бары» (тезүче **wä** «һәм» теркәгече + каршы куючы **läkin** «ләкин» теркәгече), **wä illä** «юкса, югыйсә, башкача булса» (тезүче **wä** «һәм» + каршы куючы **illä** «әмма, тик, ә инде» теркәгечләре) төрләргә аерыла.

wä «һәм» теркәгече, фарсы чыгышлы **häm** теркәгеченең грамматик синонимы буларак, җөмләнең тиңдәш кисәкләрен бәйли: küzlämäz du γälämeŋ qarasyny wä aγyny [4, 92] «бу галәмнең карасын һәм агым күрмәс». Кайбер очракларда *wä* теркәгече кабатланып, көчәйтү төсмерен өсти һәм *-da / -dä* кисәкчәсе мәгънәсен ала: anyŋ qasdy imanyŋda wä canyŋda wä qanyŋda [4, 81] «аның начарлыгы иманында һәм җанында, һәм канында».

Гарәп телендәге [1, 396] кебек үк **fa** «һәм» җыючы теркәгече ике җөмләнең бер-бер артлы бәйләнешен белдерә: fa šökru niγmäti allahi, - dide xaq [4, 125] «Аллахның нигъмәтенә шөкер итегез, - диде Хак».

wä läkin «вә ләкин, ләкин, тик, бары» теркәгече күренеш, эш-хәрәкәт яки предметны икенчесенә каршы куя: mö'minäm dijärsän, wä läkin tabnyrsän näfseŋä [4, 98] «мөэмин (мөселман) дисең, ләкин нәфсеңә табынасың».

illä «әмма, тик, ә инде» теркәгече исә кемнең яисә нәрсәнең дә булса башкарыла торган эш-хәрәкәттән төшеп калуын белдерә:

gärčä rah räüšan doryr, illä säfär wäxšätleder [4, 118] «гәрчә юл йөрү якты булса да, әмма сәфәр хәтәрле».

Гарәп теленә хас төстә [1, 427] **wä illä** «юкса, югыйсә, башкача булса» теркәгече альтернатив шартны белдерә һәм алдагы катгый шартны кире кага. Мәсәлән: äsär kilde bäŋa göl quxusyndan, wä illä tufraγam bän ta äzäldan [4, 107] «әсәрләндем гөл исеннән, югыйсә туфракмын мин мәңгегә».

Аерым очракларда автор каршы куючы теркәгеч функциясендә гарәп теленнән кергән **bäs** «бәс, шулай булгач, димәк, нәтиҗәдә» сүзенә мөрәҗәгать итә: bäs qory däγwalara aldanmaŋyz [4, 117] «шулай булгач, коры дәгъваларга алданмагыз».

Фарсы предлоглары. Поэтик әсәрләр, төрки телләргә хас бәйлекләрдән тыш, фарсы предлогларының актив кулланылуы белән дә үзенчәлекле. Алар арасында **ta** «кадәр», **ba** «белән», **där** «эчендә», **bi** «-сыз / -сез», **na** «-сыз / -сез» чагыштырмача актив. Алынма фарсы предлоглары *вакыт, катнашлык, корал, урын* кебек мәгънә мөнәсәбәтләрен бирә.

ta «кадәр» предлогы урын яки вакыт чиген белдерә: bändan razyj ulγyl ta äbäd [4, 101] «миннән мәңге разый бул».

ba «белән» корал яки катнашлык нисбәтен белдерүдә катнаша: ba safa ilä wiräsän canyŋy [4, 82] «шатлык белән җаныңны бирәсең».

där «эчендә» предлогы урын төшенчәсен бирү өчен кулланыла: där xaqiqät, äxiläreŋ bonlar hämin [4, 125] «хакыйкатьтә болар гына синең туганнарың».

bi «-сыз / -сез», **na** «-сыз / -сез» предмет яки күренешнең юклыгын аңлата. Алар ярдәмендә сыйфатлар актив ясала: tuγmady härgiz anadan bän kebi bi čara qol [4, 89] «минем кебек бичара кол беркайчан да тумады», raxmätendin naömid šajtan toryr [4, 133] «рәхмәтеңнән өмет өзгән (өметсез) шайтандыр» һ.б.

Гарәп предлоглары. Тикшерелә торган әсәрләрдә **fi** «эчендә», **bi** «белән», **käj** «кебек, төсле, сыман», **γajre** «гайре», **bäγdä** «аннан соң» кебек гарәп предлоглары очрый. Алар *урын, катнашлык, охшату-чагыштыру, вакыт* кебек мәгънә төсмерләрен белдерүдә катнашалар.

fi «эчендә» предлогы урын нисбәтенә бәйле рәвештә кулланыла: bel: fäna fi allahi [4, 85] «бел: юкка чыгу (эреп югалу) Аллаһыда».

bi «белән» предлогы катнашлык нисбәтен яки эш-хәрәкәтне башкара торган коралны белдерә: bi külli xaqγa jöz totyb hämišä [4, 85] «һәрвакыт хакка йөз тотып».

käj «кебек, төсле, сыман» предлогы **kebek (kebi)** «кебек» төрки бәйлегенең грамматик синонимы булып тора һәм охшату-чагыштыру мөнәсәбәтен бирү өчен кулланыла: γäciz ašöftäder zar zäγifem käj näxif [4, 91] «зәгыйфьләрем ябык (авыру) кебек гаҗиз, борчулыдыр».

γajre «гайре» предлогы чыгыш килешендәге сүзләр янында килеп, билгеле бер төркемгә кермәгән зат, предмет яисә күренешне белдерә: ta sane belam ki, sändän γajre jarym qalmady [4, 102] «Сине генә беләм, Синнән гайре ярым юк».

bäγdä «аннан соң» вакыт нисбәтенә бәйле рәвештә кулланыла: bäγda, i axel-γaziz γäbdel-qawi… [4, 123] «аннан соң, әй, гаҗиз абыем Габду-ул-Кави…».

Шул рәвешле, XIX гасыр татар поэзиясе телендә иске татар һәм көнчыгыш телләренең диалектик бәйләнеше морфологик яссылыкта ачык чагыла, аерым алганда, күпчелек грамматик категорияләрдә угыз-кыпчак һәм гарәп-фарсы катламнары аерыла. Төрле системадагы телләрнең грамматик чараларын кушып иҗат итү – шул чор язма әдәби теленең бер шигъри варианты.

Әдәбият

1. Гранде Б.М. Курс арабской грамматики в сравнительно-историческом освещении/Б.М.Гранде. –М.: Изд-во вост. лит., 1963. – 594 с.

2. Махмутов М.И. Фонетическое и грамматическое освоение арабских заимствований в татарском литературном языке: Автореф. дис. ... канд. филол. наук / М.И.Махмутов; Казан. гос. ун-та. – Казань, 1966. – 20 с.

3. Современный татарский литературный язык. Лексикология, фонетика, морфология. – М.: Наука, 1969. – 380 с.

4. Шәмсетдин Зәки шигырьләре / Төз. Зиннәтулла Мөхәммәтрәхими (гарәп графикасында). – Башкортстан Фәннәр

академиясенең Уфа тарих, тел һәм әдәбият институты гыйльми архивы, ф.3, т.63, б.47, б.178. (Бу кульязманың фотокопиясе проф. Х.Й.Миңнегуловта саклана).

5. Фәхретдинов Р. Асарь. 13 җөзьә. 2 нче җилд. / Р.Фәхретдинов. –Оренбург, 1907. – 422 б.

Йосыпова Н.М.

Хәзерге татар драматургиясендә интеллектуаль тенденция: М.Гыйләҗев

Сиксәненче елларның икенче яртысы-туксанынчы еллар чигендә драматургия яңа үсеш сукмакларын барлый башлый: Р.Хәмид, Ю.Сафиуллин, Зөлфәт Хәким, Ф.Бәйрәмова, М.Гыйләҗев һ.б. сюжет-композиция бирелеше, образлар төрлелеге, сәнгати алымнар җәһәтеннән яңа эзләнүләр, тәҗрибәләр юлына керә. Шулар аша ачылган субъектив катлам җәмгыятькә хас сыйфат-билгеләрне, система, тоталитар режим, аның шәхескә йогынтысын гына түгел, кешелекнең үзен, яшәеш кануннарын бәяли башлый, тәнкыйди бәя фәлсәфи фикер-карашлар белән кушыла яки фәлсәфә үзе бер катлам-башлангыч төсендә алга чыга. Драма төре тематик яктан байый-төрләнә, психологизм көчәя, проблематик яссылыкта әхлакый мәсьәләләрдән гомумкешелек кыйммәтләрен яктыртуга таба хәрәкәт итә. Өченчедән, драматургиядәге сыйфат үзгәрешләре иҗат юнәлеше, агымнарының, иҗади тенденцияләрнең төрлелегенә тоташа: сүз сәнгатенең бу төрендә романтизм, реализм юнәлешләре, агымнары белән янәшәдә модернистик, постмодернистик алымнар бергә берегеп үсә-үзгәрә, интеллектуаль тенденциянең көчәюе күзгә ташлана, дөнья әдәбиятлары үрнәгендә яңа әдәби юнәлешләр урын ала. Бу үсеш-үзгәреш, бердән, сүз сәнгатенең үз эчке закончалыклары белән бәйләнсә, икенче яктан, үзгәртеп кору сәясәтенә мөнәсәбәтле 1980-90 нчы еллар чигендә башланган иҗтимагый-сәяси, мәдәни фикердәге яңарыш, милли үзаң үсеше йогынтысында формалаша.

Модернистик сәхнә әдәбиятында фәлсәфи башлангычның үзәккә алынуы, шартлылыкның, интеллектуаль тенденциянең көчәюе күзгә ташлана, драматургиядә интелектуаль башлангыч тагын да киңрәк урын ала [2, 67] Мондый әсәрләр тормыш-

яшәешкә бәя бирергә, актуаль проблемаларны, яшәү кануннарының, тәртипләрнең кешегә тәэсирен гәүдәләндерергә омтыла. Үзәккә хакыйкатьне тапкан геройны күтәреп, аның аша ялгызлык фәлсәфәсен үткәрә һәм җәмгыять кешене ялгызлыкка китерә, хәтта шәхес буларак юкка чыгара дигән фикерне ассызыклап бара. Шуның ярдәмендә билгеле бер канун-кагыйдәләрне аерып чыгара, мифологик мәгълүматлар, шартлы-мифологик, символик образлар, метафора, әкияти алымнар ярдәмендә идеаль тормыш моделен төзеп, укучыга тәкъдим итә. Авторның игътибары тормышны, кеше характерларын сурәтләүдән бигрәк, катнашучылар алып барган идеяләр бәхәсенә юнәлә [5, 93], фикерләү дискурсы алга чыга, әйтелеп бетелмәгән мәгънәләр интеллектуаль сюжетның буыннарын тәшкил итә [4, 133].

Мондый әсәрләр чорның рәхимсезлеген, аның кеше тормышына йогынтысын ассызыклап бара, яшәеш кенә түгел, сәяси кыйммәтләрне дә кире кага. Бу үзенчәлекләр хакында М.Гыйләҗевның “Бичура”, “Баскетболист”, З.Хәкимнең “Җүләрләр йорты”, “Кишер басуы”, Д.Салиховның “Алла каргаган йорт” кебек әсәрләре хәбәр итә. Бу юнәлештәге әсәрләрнең бер өлеше милләт язмышы, аның киләчәге, әхлакый кыйммәтләрнең үзгәрүе мәсьәләсе тирәсенә җыела.

“Бичура” драмасы ике катламның - реалистик һәм шартлы-мифологик дөньяның янәшә бирелешеннән гыйбарәт. Реалистик катламдагы вакыйгалар чылбыры Аксак белән Хатынның ике генә гаилә калган авылда көн күрүләре, Аксакның Кара җаннар һәм Бичура белән очрашулары, күршеләре белән мөнәсәбәтләре, киленнәренең авылга кайтып төшүләре, Аксакның аттан, чормадан егылулары, өметен өзүе һ.б. вакыйгаларны, холык-характерларның үзгәрү тарихын бер бәйләмгә җыя. Ирреаль, шартлы-метафорик катлам Бичура һәм Кара җаннар образларына бәйләнештә ачыла. Драмадагы конфликт та ике катламда бара: Аксакның эчке һәм якыннары белән тышкы каршылыгы. Беренчесе Бичура һәм Кара җаннарның эш-гамәленә барып тоташса, икенчесе Аксакның гаиләсендәге мөнәсәбәтләргә, киңрәк алганда, кешеләр арасындагы мөнәсәбәткә кайтып кала. Аксакның эчке конфликты писихик хәрәкәт буларак билгеләнә һәм геройның яшәеш белән күңел, чынбарлык белән намус

арасында бәргәләнүен ачыклый. Моннан тыш Бичура җыры Бичура күңелендәге каршылыкны җиткерә:

Кара бөдрә чәчләремне,

Үрдерәсем килмидер.

Эчем ялкын, тышым салкын,

Белдертәсем килмидер.

Җырның кабатлануы эчке каршылыкны тагын да көчәйтеп, эмоциональ халәтнең үсеш-үзгәрешен күрсәтә.

“Бичура” драмасында тышкы конфликтның *герой белән герой, герой белән яшәеш*, өлешчә *герой белән җәмгыять* каршылыгы кебек традицион төрләре урын ала һәм алар аша бүгенге милләт яшәешенә, чорга хас, татар халкының киләчәгенә кагылышлы проблемалар күтәрелә. Мәсәлән, Аксак белән Хатын арасындагы каршылык авылларның бетә баруы, кешенең киләчәккә өмете өзелү, югалу алдында торуын аңлау, гаилә бөтенлеге проблемаларын күтәрсә, Аксак белән Күрше конфликты өметсезлек, туган нигезгә береккәнлек, туган җирнең кадерен белү һ.б. мәсьәләләрне калкыта. Киленнәрнең үзара, гаиләдәгеләр белән ярдәмче тышкы каршылыгы яшь буынга бәя бирүгә юнәлтелә. Ләкин моннан тыш драмада Бичура һәм Кара көчләр, Аксак һәм Кара җаннар каршылыгы урын ала. Алар милләт яшәешенә, гомумиләшеп кешелек яшәешенә бәя бирүгә юнәлтелә һәм тормышта ямьсезлекнең өстенлек ала баруы, киләчәккә өмет, туган җиргә мөнәсәбәт, үткәннәр алдында җаваплылык кебек мәсьәләләрне көн үзәгенә куя.

М.Гыйләҗев татар авылларының бетүе өчен борчыла, аларны милләтнең җан сакчысы, яшәеш чыганагы дәрәҗәсенә күтәреп, татарның киләчәге нинди булыр дип чаң суга, шуңа бәйләп, авылларның югалу алдында торуы, фаҗигасе мотивын үткәрә. Әлеге мотив төн образы, авыр баскыч, зур капка детальләре аша төгәлләштерелә: *“...Аның кайчандыр гөрләп торган хуҗалыгы инде әкренләп тарала башлаган, нәрсәдер кыйшайган, нидер ишелеп үк төшкән... Капка биек, имән ниргәдән нигез бүрәнәләре, зур чорма – үткәннәрнең шаһитлары әле дә калган. Чорма ишегенә авыр баскыч сөялгән... Төн. Тынлык”.*

“Бичура” драмасында образлар системасының үзенчәлекле булуы да күзгә ташлана: мифологик образлардан Бичура һәм Кара җаннар, бердән, төп образларны ачарга, икенчедән, авторга үз фикерен төгәлләштерергә ярдәм итә, аларда шартлылык сыйфаты гадәттән тыш калку бирелә. Бичура шартлы-символик образы укучы аңында матурлыкка омтылыш, җан сакчысы, рухи яшәеш, иман билгесе, авырлыкларны җиңәргә ярдәм итүче кебек архетипик сыйфатларга ия образ буларак гәүдәләнә һәм символик яссылыкта шундый билгегә әйләнә дә. Кара җаннар исә Бичураның капма-каршысы булып тора. Әсәр тукымасында алар аерым кеше тормышыннан башлап, милләт яшәешендәге ямьсезлек булып күзаллана, Бичура белән каршылыкта кеше күңелендәге, милләт тормышындагы Ак һәм Кара каршылыгын гәүдәләндерә. Әмма талантлы каләм моның белән генә чикләнмичә, субъектив катламда образларның башка мәгънәләрен аңларга да мөмкинлек калдыра. Алар яшәештәге ике чикне тергезеп, фәлсәфи мотивлаша. *“Бичура китә бездән, ташлый. Кемгә таянып яшәрбез кара җаннар арасында... Бүгеннән мине Бичура дип белегез. Бу йорт-җирләрне, бу нигезне, бу табигатьне үзем саклыйм”* (Аксак), *“Шушы яшеңә җиткәч бер бичура белән генә калсаң, аннары ул да юкка чыкса дип, гомерем буе хафаландым ич мин...”* (Хатын). Бичураның Кара җаннар тарафыннан җиңелүе (*“Алар җиңде безне, картлач. Алдагы төндә алар тагын килерләр. Сизәсеңме, алар һаман арта тора, күбәя. Минем андый чирүгә каршы торырлык көчем юк. Көрәшә-көрәшә ардым, хәлдән тайдым. Үткәннәрне оныт, өеңнән чыгып кит. Соңгы киңәшем шул сиңа. Бу дөньяда безгә урын калмаган, без югалырга тиеш”* (Бичура) яшәештә каралыкның, ямьсезлекнең өстенлек алуы булып аңлашыла. Шуңа бәйләнештә әсәргә экзистенциаль фикерләр, өметсезлек мотивлары килеп керә: *“Дөньялар тәмам бозылган, Бичура күренеп тә рәткә сала алмас”* (Күршекәй), *“бу хәрабәләрне кемгә калдырырга җыенасың? Кемгә кирәк бу нигез? Бетсен, тар-мар килсен, аусын”* (Хатын). Өметсезлекнең иң көчле чагылышы булып Аксак сүзләре күтәрелә, ул автор фикере кебек тә гомумиләшә: *“Озак яшәдек... Без күчкәннән соң дөнья йөзендә ни кала? Тормыш каламы? Иман каламы? Юкка яшәгәнбез, күрше, гомерне бушка исраф иткәнбез. Кеше күңелләрендә*

калырлык изгелек кылмадык, тормышны чәнти бармак кадәр дә алга җибәрмәдек".

Ләкин драмада Бичура белән Кара җаннар каршылыгының иҗтимагый мотивлашуы да күзгә ташлана. Бу яссылыкта Бичура милләт сакчысы, Кара җаннар милләтнең нигезен корытучылар (*"Алар сине куарга, йорт-нигезеңне җимерергә, нәселңне корытырга телиләр"* Бичура), милләтне бүлгәләүче сәбәпләр, азайтучы вакыйгалар (*"Кем бездән рәхәтрәк яшәде? Сугышта ятып калганнармы? Әнә исемнәре язылган багана чокырда аунап ята. Бәлки чит җирләргә китеп барганнар бездән бәхетлекрәктер? Юк, юк, мең мәртәбә юк, киткәннәр дә бәхет тапмады"* Хатын), колхозлаштыру сәясәте (*"Ә сарай? Ник каерганнар аның ишеген? Буп-буш икәнен белмиләрмени? Ат колхозга кергәнгә ничә ел үтте?; "...Син дә, мин дә таңнан төнгәчә бил бөгеп кырда тир түктек! Бергәләп колхоз, колхоз дип җенебезне өздек..."* Аксак), идеология, совет системасы (*"Җитмеш ел интектек, тамагыбыз туймады, өс-баш ялангач булды... Җәфаларның җәфасын күрдек"* Хатын; *"Син бу авылның гына түгел, тирә-якның соңгы кешесе. Калганнарны алар берәм-берәм юк иттеләр. Җитмеш ел эчендә аларның ниләр кылганын башка сыйдырырлык башлар калмады инде"* Бичура; *"Иске тормышны җимердек. Яңасына юл таба алмадык, җимерекләр арасында гомеребез үтте"* Хатын) кебек тә укыла һәм Кара җаннарның җиңүе милләт фаҗигасе булып аңлашыла. Автор өмете өзелгән кеше билгесезлек алдында кала дип раслый, авылларның, иманның юкка чыгуы, ямьсезлекнең җиңүе, өметсезлек тормышта, яшәештә гармония югалуга китерә дип тулыландыра.

Эпизодик образлар рәтен киленнәр Руфия, Наилә, Гөлнара һәм Күршекәй образлары тулыландыра. Алар әсәргә өч максаттан чыгып кертелә: Руфия белән Гөлнара авылны яшәтергә тиешле яшь буынга бәя бирү, аның әхлаксызлыкка йөз тотуын гәүдәләндерергә ярдәм итсә, Наилә авторның яшьләргә өметен тергезә, Күршекәй образы олы буын фаҗигасен җиткерә. Аның өзлексез казлар эзләве метафора булып тәгаллашә һәм сугышта югалткан ирен, балаларын сагынуы, табачагына өмет итүе, җан авазы булып ишетелә: *"Аңгыралар ич әле, әнкәләре юк, ата казга тагылып йөриләр. Җиде ятим бәбкә. Җидесе дә матур булып*

үсеп киләләр дигәндә явыз тилгән күтәреп китмәсен дим”. Әсәр ахырында Аксакның сүзләреннән соң (“*Утыз ел тоташ каз эзләп изаланасың, утыз ел! Җиде улың, ирең бер көндә сугышка чыгып киттеләр. Киттеләр дә гаип булдылар., кайтмадылар. Үлеп калдылар, бичаралар! ...Чит җирләрдә аларның каберләре! Ак сөякләре чит җирләрдә таралып ята. Эзләмә син бәбкәләреңне, ата казыңны да эзләмә! Җиде бәбкә белән ата казың юк синең. Эзләмә тилмереп аларны, оныт, тынычлан. Элегрәк моны күзеңә карап әйткән кеше булмады...*”) Күшекәйнең үлеп китүе укучыны “өмете өзелгән кешенең гомере чикле, нәрсәгәдер өметләнеп яшәве генә кешене алга илтә” дигән фикергә алып килә. Бер үк вакытта авторның сугыш идеологиясенә тискәре мөнәсәбәте дә сизелә.

Драмада табигать образларының бирелеше кызыклы, алар персонажларга, тормышка бәя бирү барышында файдаланыла. Әсәр ахырында табигать образлары башка мәгънәләр белән дә баетыла. Ул автор фикерен тагын да көчәйтеп, өмете өзелгән кеше билгесезлек алдында кала дип раслый, аны авылларның, иманның юкка чыгуы, ямьсезлекнең җиңүе, өметсезлек тормышта, яшәештә гармония югалуга китерә дип тулыландыра.

Әсәрдә ялгызлык мотивы Аксак образына бәйләнештә ачыла. Аксак кешелекнең мескен хәлдә яшәвен аңлый, хакыйкатьне таба, ләкин бу хакыйкать бары тик аңа гына билгеле. Икенчедән, ялгызлык фәлсәфәсе күрше карчыгы Хәмдия һәм Аксакның күршесе аркылы җиткерелә. Әлеге өч образ бер фикерне - җәмгыять кешене ялгызлыкка китерә һәм хакыйкатьне тапкан кеше үзенең эчке дөньясы белән ялгыз дигән карашны ныгыта. Ялгызлыкның асыл сәбәбе дә кешеләрнең үзләрендә һәм алар яшәгән җәмгыятьтә дип раслана.

Әдәбият

1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007.

2. Елисеев И.А. Словарь литературоведческих терминов / И.А.Елисеев, Л.Г.Полякова. – Ростов н / Д: Феникс, 2002.

3. Заһидуллина Д.Ф. Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык) / Дания Заһидуллина. – Казан: Мәгариф, 2006.

4. Лейдерман Н.Л. Современная русская литература: В 3-х кн. Кн.2: Семидесятые годы (1968 – 1986): Учебное пособие / Н.Л.Лейдерман, М.Н.Липовецкий.— М.: Эдиториал УРСС, 2001.
5. Русова Н.Ю. От аллегории до ямба: Терминологический словарь-тезаурус по литературоведению / Н.Ю.Русова. – М.: Флинта: Наука, 2004.

Калимуллина А.Г.

**Уровень смертности
в Казанском уезде Казанской губернии
за 1865-1870 годы и ее причины.
(статистические данные)**

Данные переписей населения в Российской империи показывают, что с 1857 по 1897 годы количество татар в Казанском уезде Казанской губернии выросло с 99946 человек до 146730 человек. [1. – 11 с.]

Однако, как показывают метрические Казанского уезда Казанской губернии, уровень рождаемости смертности не позволяет сделать вывод о естественном приросте татарского народа.

В данной работе мы предлагаем статистические данные по уровню смертности и ее причинам за 1865-1870 годы.

Естественное движение татарского народа Казанского уезда Казанской губернии в 1865-1870гг.

Год	Рождаемость	Смертность	Прирост/убыль
1865	3838	3486	+352
1866	3261	3811	-550
1867	4015	3281	+734
1868	5358	4280	+1078
1869	3788	3316	+472
1870	3878	2658	+1220
Итого	**24138**	**20832**	**3306**

Из приведенных ниже диаграмм видно, что в Казанском уезде Казанской губернии в 1865-1870 годы мальчиков рождалось больше, чем девочек. Однако и умирало мальчиков также больше. В отличие от девочек, среди новорожденных мальчиков оказывается большое количество детей мертворожденных.

В целом, детская смертность достигает 50% от общего количества умерших. При этом 40-55% детей умирает, не достигнув годовалого возраста. Основной причиной смерти детей в эти годы является заболевание ветрянкой.

Если говорить об общей смертности, то можно привести следующие цифры по процентам смертности населения относительно количества родившихся детей по годам:

1865 год – 90,83% от общего числа родившихся;
1866 год – 116,87%;
1867 год – 81,72%;
1868 год – 79,89%;
1869 год – 87,54%;
1870 год – 68,54%.

К концу 1870-х годов смертность снижается 61,69 % от общего числа родившихся, а к концу 1880-х годов – 67,84 %. Число рожденных и умерших мужчин и женщин приведено ниже.

Число рожденных и умерших мужчин за 1865-1870 гг.



Число рожденных и умерших женщин за 1865-1870 гг.



Основными причинами смертей являются:

1) у детей:

- мертворожденные (туганда үлгән, үлеп туган, җансыз туган, җитлекми туган),
- ветрянка,
- детская болезнь,
- головная боль,
- боль в животе,
- боль в горле,
- боль в груди,
- высокая температура,
- сыпь на коже,
- опухоли,
- обморожение;

2) у взрослого населения в возрасте от 20 до 60 лет:

- головная боль,
- боль в животе,
- боль в горле,
- боль в груди,
- сердечная боль,
- высокая температура,
- сыпь на коже,
- одышка, удушение,
- сахарный диабет (бирән зәхмәте),
- желудочная болезнь,
- понос,

- судороги,
- чахотка,
- опухоли,
- желтуха,
- сумасшествие (дивана булып, җен зәхмәте, тилчә зәхмәте)
- у женщин в возрасте от 19 до 50 лет – смерть при родах,
- обморожение,
- утопление и др.;

3)В возрасте от 60 лет:

- смерть от старости,
- боли в руках и ногах,
- долгая болезнь и др.

Как видно, причины смерти выявляют, в основном, видимые признаки той или иной болезни. Это свидетельствует о медицинской неграмотности населения середины XIX века.

Однако, нельзя отрицать и отдельные факты долгожительства в определенный нами период. Ниже мы предлагаем список долгожителей, достигших возраста в 100 и более лет.

№ п/п	Имя	Пол	Год и место смерти	Возраст умершего	Причина смерти	Источник
1	Сагидабану Мухаммедовна	ж	1867 год, дер. Кшкар	100	боль в животе	6-85*
2	Фархиназ Нигматулловна	ж	1868 год, дер.Кшкары	100	Боль в животе	8-472об
3	дочь Габдерашита	ж	1867 год, дер.	102	Боль в животе	6-84об

			Кшкар			
4	супруга Габдуллы Нигматеддиновича Килбагида	ж	1866 год, дер. Сенные покосы по речке Ашит	105	болезненность	4-208
5	Баязит Атнагулович	м	1867 год, дер. Большая Атня	110	чахотка	5-413
6	супруга Валида дочь Ахсана	ж	1865 год, дер. Сенные покосы по речке Ашит	117	болезненность	2-382

Таким образом, можно подвести следующие итоги:

1) в середине XIX века в Казанском уезде Казанской губернии уровнем населения управлял так называемый естественный отбор,

2) болезненные и неприспособленные дети умирали, а выжившие могли дожить до преклонного возраста,

3) наиболее здоровыми были молодые люди в возрасте от 20 до 40 лет,

4) умирали, в основном от инфекционных заболеваний,

5) насильственной смерти (убийства) или суицидов не наблюдается.

*в данной графе указывается метрическая книга и номер листа, где №6 – номер дела по списку литературы.

Литература

1.Татары и Татарстан в XX – начале XXI веков (этностатистика). – Казань: Институт истории АН РТ, 2007. – 124 с.

2. Ф. 4, Оп. 177, Д. 135 Метрические книги мечетей Казанского уезда Казанской губернии за 1865 год
3. Ф. 4, Оп. 177, Д.136 Метрические книги мечетей Казанского уезда Казанской губернии за 1866 год
4. Ф. 4, Оп. 177, Д.137 Метрические книги мечетей Казанского уезда Казанской губернии за 1866 год
5. Ф. 4, Оп. 177, Д.138 Метрические книги мечетей Казанского уезда Казанской губернии за 1867 год
6. Ф. 4, Оп. 177, Д.139 Метрические книги мечетей Казанского уезда Казанской губернии за 1867 год
7. Ф. 4, Оп. 177, Д.140 Метрические книги мечетей Казанского уезда Казанской губернии за 1868 год
8. Ф. 4, Оп. 177, Д.141 Метрические книги мечетей Казанского уезда Казанской губернии за 1868 год
9. Ф. 4, Оп. 177, Д.142 Метрические книги мечетей Казанского уезда Казанской губернии за 1869 год
10. Ф. 4, Оп. 177, Д.143 Метрические книги мечетей Казанского уезда Казанской губернии за 1869 год
11. Ф. 4, Оп. 177, Д.144 Метрические книги мечетей Казанского уезда Казанской губернии за 1870 год
12. Ф. 4, Оп. 177, Д.145 Метрические книги мечетей Казанского уезда Казанской губернии за 1870 год
13. Ф. 4, Оп. 177, Д.164 Метрические книги мечетей Казани и Казанского уезда Казанской губернии за 1865 год

Кашфиева Л.

Илдус Гыйләҗевнең мәхәббәт лирикасында шәхес гәүдәләнеше

Һәркем шигърияткә үз сүзен әйтергә килә. Илдус Гыйләҗев диюгә үк, аның турында бер тавыштан "җир шагыйре" диләр. Илдус Гыйләҗевнең һаман тулыланып торган шигъри мирасы барлаганда һәм бәяләгәндә, җыентыклардагы гаҗәеп пөхтә тематик төркемнәргә тап буласың. Туган җир, авыл, игенчелек; әнкәй, гаилә, мәхәббәт, яшәеш һәм иҗат фәлсәфәсе, әхлак, туган тел, милли азатлык, һәм шулар арасындагы башка бик күп тематик катламнарда шагыйрьнең шәхес концепциясе үсеше юл

ала. “Җилкенү” (1990), “Серле мәгарә” (1995), “Хак сүз” (2000) “Чатыртау тылсымы” (2001), “Яратканга күрә” (2005) дип аталган шигырь китапларында шагыйрьнең эстетик идеалы үскәннән үсә, тулы канлылана барганлыгы күренә. Шагыйрь күзаллаган шәхес төрле яктан ачыла һәм камилләшә барып каләм иясенең бердәм художестволы концепциясен тәшкил итә. Һәм Илдус Гыйләҗев иҗатындагы шәхес концепциясе аның иҗатының этәргеч көчен, әйтәсе сүзенең мәгънәви асылын билгели.

Яшәешне һәрдаим үзгәрештә, үсештә күзаллау Илдус Гыйләҗев иҗатындагы шәхес концепциясе үсешенең дә үзәк ызанын хасил итә. Ул тудырган шәхеснең тормыш фәлсәфәсенә һәрдаим яну, әрле-бирле чабу, эзләнү, камилләшү хас. Ул кешеләр бәхете өчен үзен аямыйча егылганчы бара торган мосафир кыяфәтендә дә, башкаларга юлны яктырту өчен күкрәгеннән йөрәген тартып чыгарган Данко ихтыярында да күз алдына баса. Аның максаты – алга, фәкать алга бару. “Мәңгелек хәрәкәт” шигырендәге:

Иртән торсам, чабам әрле-бирле,
Нидер эзлим һаман.
Яктылыгым төшсен кешеләргә! –
Дөрли-дөрли янам,-

дигән юллар шәхес концепциясенең асылын тәшкил итә. Әлеге шигырь - Илдус Гыйләҗев шигърияттендәге **мәхәббәт лирикасының** алтын таҗы. Мәхәббәтнең иң киң һәм тирән мәгънәсен үз эченә алган, яшәешкә, кешелеккә карата ихлас хисләр белән сугарылган бу юллар шагыйрь иҗат иткән эстетик идеалның югары багланышын гәүдәләндерә. И.Гыйләҗевнең мәхәббәт лирикасы үзенең фәлсәфи уйланулары һәм нәтиҗәләре, шуннан килеп туган афоризм дәрәҗәсендәге тыгыз мәгънәле гыйбарәләре, шулай ук җылы юморы, шаярту, төрттерүе белән күпкырлы һәм бай.

Шагыйрь өчен мәхәббәт – ул сагыш әчесе дә, сагыну да, чырагачка калып ябыгу да, көнләшү, шикләнү газабы да, хәйлә кору, моңга чуму, җырлап тилереп йөрү дә.

Шулай булмаганда нигә кирәк
Килеп китеп йөрү, сөйрәлеп.

....Мәхәббәтне зурлап яшәдек без,
Шашып яратырга өйрәнеп, -

дип ул үзенең мәхәббәт концепциясен шәрран ачып сала "Гадиләштермә мәхәббәтне" шигырендә.

Сөю халәтенә фәлсәфи, тылсымлы күзлектән карап, әкияти романтикага юл алу, образлы нәфислеккә йөз тоту мондый шигырьләрнең шагыйранә яңалыгын тәшкил итә. "Икебезнең әҗәт" шигырендә дә лирик герой сөйгәне образына мөрәҗәгать итеп гаҗәеп табигый, нәфис сурәт тудыра.

Гаҗәпләнмә, һава тып-тын чакларда да
Чәч толымың куйса уйнаклап –
Мин йөрим ул... Мыштым гына барып килсәм,
Уем белән сине кочаклап.]

Шигырьдәге үзгә бер моң, авазлар тибрәнеше, ритмнар төгәллеге бу юлы авторның замандашы мәрхүм Наис Гамбәр тавышын ишеттергәндәй була.

Гаҗәпләнмә: бер көн өй каршына

Кошлар җиккән арба туктаса,

Күңел кошлары ул:

Тәкыя үр, Ләйсән,

Кошлар биргән гөлдән чук ясап,-

дип язган иде ул "Күңел кошлары" шигырендә. Н. Гамбәрдә романтиклык хыял югарылыгында тотып алынса, И. Гыйләҗев романтизмы җиргә, чынбарлыкка якынрак халәттә реаль яшәешне нәфис итеп тасвирлау йөкләмәсен ала. Әсәрдә хис-вакыйгалар динамикасына, драматизмга, психологизмга ирешүдә ике шагыйрь дә шигъри калыптан, ритмик мөмкинлекләрдән, урынлы кулланылган паузалардан отышлы файдаланган.

Әлеге шигырьдә И. Гыйләҗев тормышка, мәхәббәткә фәлсәфи караш ягыннан да отышлы ысулга мөрәҗәгать итә. "*Минем алачагым, синең бирәчәгең бармы? Синең янга һаман тартылам*",- дип үзенең мәхәббәтендә, фәлсәфә фәнендәге мөһим закон буларак, сәбәп һәм нәтиҗә бәйләнешен нигез

итеп ала. Алай гына да түгел, сөйгәне белән мөнәсәбәтен аклау өчен ул илаһи кануннарны да сәбәп итеп ала:

... Без, мөгаен, икәү дөнья каршысында,

Хода каршысында әҗәтле...

Тормыш тәҗрибәсенең сөземтәсе буларак туган фикер төгәллеге һәм мәхәббәт лирикасындагы үзгә бер әверелешне күзаллавы ягыннан «Мин божрада» шигыре дә гыйбрәтле. Кеше күңеле гомер буе камиллек, гүзәллек эзли, иң зур табыш еш кына янәшәдә булып чыга. Кеше шушы рәвештә үз асылына кайта, аның аң-фикер үсеше шуны таләп итә.

Синнән башланам да синдә бетәм

Божра сыман.

... Бөгелергә Ходай үзе

Боера сыман...

Әлеге фикер «Шулай булачак», «Җиңелеп җиңү», «Бер фәлсәфә» шигырьләрендә дә төрле яклап ачыла. Мәхәббәт фәнен яхшы үзләштергән, хисләр дөньясында кыйбласын югалтмаган лирик геройның бу юлы да чыгарган нәтиҗәләре илаһи кануннарга нигезләнә. «Бер фәлсәфә», «Түләү» шигырьләрендә дә хисләр дөньясында хакыйкатькә инану, язмыш белән килешү, чын мәхәббәтне, бәхетне тану сөю лирикасының эчке бөтенлеген хасил итә.

Мәхәббәт дөньясында афористик яңгырашлы кануннар булдыру И. Гыйләҗев иҗат иткән шәхеснең әхлакый тормыш принципларын формалаштыра. Мәсәлән, «Бәхетнең бер төре» шигырендә лирик каһарман яшьлеккә, гүзәллеккә сокланган гөнаһсыз һәм ихлас зат буларак күз алдына баса. Һәм үзенең дөньяга карашын аклап, мондый нәтиҗәгә килә:

Чибәр кызлар тулы бу дөньяда

Яшәп китү – үзе бер бәхет.

«Эш узгач» шигыре дә лирик геройның тирән кичерешле, катлаулы хисләр дөньясында күп еллар узгач калкып чыккан хакыйкатьне тануы белән гыйбрәтле. Табыну,

сагыну узган заман яссылыгында «ялгыш» дип бәяләнсә дә, еллар узгач, шул ялгышларның табыш булганлыгына инану калка. Хронотоп, яки вакыт һәм пространство берлеге башка шигырьләрдә дә фәлсәфи нәтиҗәләрнең нигезе булып тора. Ике вакыт яссылыгында барган вакыйга-хәлләрне чагыштыру тыгыз фикерле, эмоциональ тәэсирле, инандыргыч көче булган сөземтәләргә алып килә. «Түләү» шигырендәге җиңгән ханбикәгә шигырь белән ясак түләп торучы әсирнең, «Еллар шәүләсе» шигырендәге еллар хозурында тәмам йончыган лирик геройның күңел халәтен бәяләү ике вакыт яссылыгында бара. Зур тормыш тәҗрибәсе, хисләр дөньясындагы сөземтәләр мәкальгә тиң тезмәләр хасил итә.

Ундүрт яшьтә елап яратмаган

Егермедә чынлап яратмас («Ундүрттә, егермедә»).

Көнләштереп кенә бөгеп була

Баш бирмәгән горур егетне («Хәзер үзем көнләштерәм»).

Мәхәббәттән качып бәхет тапкан

Кеше әле җирдә булмаган («Күрәзәче булмасам да»).

Сөю көче көчсезлектә («Иң бөек көч»).

Ялган сүз дә ышандыра,

Ышанасың килгәндә («Хак шулай»).

Лирик геройның күңелендә яралып, эволюция кичереп, вакыт сынавын үтеп чыныккан хисләр әнә шундый афоризмнар тууына сәбәп булган.

Шагыйрьнең мәхәббәт теориясе төрле парадоксларны эшкә җигү юлы белән дә сөю көченең психологик тирәнлеген ачарга мөмкинлек бирә.

Томаланды ихтыярым

Рисвайлар иттердең.

Хушлашам дип килгән идем,

«Яратам!»,- дип әйттердең… («Үзгәреш»).

Юк, автор лирик геройның ныксызлыгына, ихтыярсызлыгына түгел, ә шәхес белән идарә итүче эчкерсез, саф хисләрнең илаһи көченә ишарәли бу юлы. «Матурлык колы» шигырендә дә мәхәббәтне илаһилаштырып, шагыйрь *«Эреде дә бете менә Гомер буе җыйган акыл...»* дип, рухи, хисси эволюцияне гаҗәеп җыйнак формада ачып бирә.

И.Гыйләҗевнең мәхәббәт шигырьләрендә гыйшыклык халәтенә җиңелчә ирония, җылы юмор белән карау да сиземләнә. "Сөйкемле була белсәң" әсәрендәге кыз чәүкә белән янәшә утырган егет чәүкәнең кыяфәтенә генә карагыз! Берничә юл эчендә автор аның холык-фигылен, килеш-килбәтен җете төсләр белән койган да куйган. Монда халыктагы: "Сылу сылу күренми, сөйгән сылу күренә" дигән мәкальгә ишарә бар. Әнә бит сөйләшергә яратмыйча, төксе генә утырган, каурыйлары тырпаешкан, канатлары ләшперәйгән "егет"кә кыз-чәүкә ничек сөеп карый. Күп шигырьләрдәгечә, биредә дә автор үз морален үзенчә җиткерә: *"Чибәрләр бер читтә тора, Була белсәң сөйкемле"*. Шигъри карикатура тудырганда сүз остасы "янәсе", "мөгаен", "Ярабби", "икән", "шикелле" кебек кереш һәм ярдәмлек сүзләрдән отышлы файдаланган. Автор, гомумән, шигъри сүзнең җегәрен, катлаулы сүзтезмәләрдән, хикмәтле символикадан түгел, ә халык теленең үткенлегеннән таба.

Мәхәббәт призмасы аша хакыйкатьне эзләү, кеше тарафдарының тормыш мәгънәсен шигъри табышларда яктырту фәлсәфи, тормышчан кануннарга алып килә:

Мин – һаман яшь! Яныпшашып
Яратканга күрә,-

дип - вәкарь белән яңгырата ул үз гыйбарәсен. Ярату – шагыйрь өчен тормыш принцибы, дөрес яшәү шарты, картаймау, көчсезләнмәү, бетәшмәү сере булып ачыла.

Кириллова З.Н.

XX гасыр башы татар әдәби телендә аныклаучы теркәгечләр

Барлык төрки телләр өчен дә хас күренеш – теркәгечсез бәйләнгән кушма җөмләләрнең алданрак барлыкка килүе һәм хәзерге вакытта да аларның күбрәк урын алып торуы барлык галимнәр тарафыннан да танылa. Бу, әлбәттә, төрки телләрнең агглютинатив төзелешкә ия булуы белән дә аңлатыла.

Күренекле тюрколог Н.Гаджиева күрсәтүенчә, төрки телләрдә теркәгечләр аша бәйләнгән иярченле кушма җөмләләр хәл фигыльле конструкцияләргә караганда соңрак барлыкка килгән, һәм беренче чиратта алар угыз тибына кергән төрки телләр өчен хас [1, 139].

Һинд-европа телләрендә ияртүле бәйләнешнең төп күрсәткече булган теркәгечләр әкренләп төрки телләрдә дә урын ала башлыйлар, әмма аларның күбесе бик җиңел рәвештә синтетик чаралар белән алыштырыла яки бөтенләй төшереп калдырыла ала. Мәсәлән, хәзерге вакытта әгәр теркәгече күпчелек галимнәр тарафыннан аналитик бәйләүче чара булып танылмый һәм әлеге теркәгеч ярдәмендә бәйләнгән җөмләләр синтетик иярченле җөмлә төренә кертеп каралалар [2, 307]; ки теркәгече күбрәк стилистик чара буларак файдаланыла, җөмләнең мәгънәсенә зыян китермичә төшереп калдырыла ала, бары традициягә нигезләнеп кенә аналитик бәйләүче чара итеп билгеләнә [2, 257]; чөнки теркәгечен күп санлы синтетик бәйләүче чаралар белән алыштыру мөмкинлеге табыла: -га, -ганлыктан, -га күрә, -у сәбәпле, -у аркасында, дип һ.б.

Хәзерге татар әдәби телендә ияртүче һәм аныклаучы теркәгечләрне, шулай ук теркәгеч сүзләрне билгеләүдә төрлелек хөкем сөрә. Мәсәлән, “Татар грамматикасы”ның III томында һәм М.З.Зәкиев хезмәтләрендә ияртүче теркәгечләргә чөнки, гүя, ки, ягъни; ә ияртүче теркәгеч сүзләргә хәтта, хәер, юкса, бигрәк тә, аннан да бигрәк, әйтерсең, башкача, башкача әйткәндә, ул да түгел, җитмәсә, әйтәм (лә), аеруча, һәрхәлдә, димәк бәйләүче чаралары кертелә [2, 257-259; 3, 359-363]. С.М.Ибраһимов хезмәтләрендә һәм “Татар грамматикасы”ның II томында шул ук автор тарафыннан ияртүче теркәгечләргә чөнки, гүя, гүяки, әгәр,

әгәренки, гәрчә, ки, әйтерсең, диярсең, күрәсең, ул да түгел сүзләре кертелә, ә ягъни, мәсәлән, хәтта, бигрәк тә, аеруча, башкача әйткәндә, икенче төрле әйткәндә, җитмәсә, өстәвенә һ.б. аныклаучы теркәгечләр дип санала; сорау алмашлыклары белән бирелгәннәре исә теркәгеч сүз дигән атама ала [4, 95-96; 5, 368-384].

Тикшеренүебезнең максаты – хәзерге тел белемендә төрлечә билгеләнгән аныклаучы теркәгечләрнең XX гасыр башы татар әдәби телендә кулланылыш үзенчәлекләрен ачыклау.

Традиция буенча, XX йөз башы татар әдәбиятына 1905-1917 нче еллар арасында иҗат ителгән әсәрләр кертелә. Бу чор әдәбиятын монографик планда тикшергән Ф.К.Бәширов исә хронологик чикләрне 1901-1918 нче еллар белән билгели [6, 7]. Безнең тарафтан тикшерү объекты итеп алынган язучылар арасыннан З.Һади һәм Ф.Кәрими иҗатлары әлеге бүленешкә туры килә. XX гасыр башы татар әдәби телен тикшерү өчен, шулай ук Г.Исхакый, Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан, Ш.Камал әсәрләре, өлешчә Г.Ибраһимовның публицистик мәкаләләре алынды. Әлеге язучыларның әсәрләрендә аныклаучы теркәгечләрнең кулланылыш үзенчәлекләре буенча без түбәндәге нәтиҗәләргә килдек.

Хәзерге татар әдәби телендәге кебек үк, XX гасыр башында да **ягъни** һәм **мәсәлән** теркәгечләре кулланылыш ешлыклары ягыннан беренче урынны алалар. Мисалларның күпчелеге аныклагыч җөмлә кисәген формалаштыруга тупланды: *Кызларда ике төрле аклык вә пакьлек бардыр: бере заһири, ягъни караганда күренер. Бере батыйни, ягъни уйлаганда беленер...* (З.Һади). *Аларга Шәрык лисаннарын, ягъни күбесе Азиядә булган милләтләрнең телләрен үгрәтәләр. Мәсәлән, безнең Петербургта вә Мәскәүдәге шундаен мәктәпләрдә гарәпчә, фарсыча, госманлы төрекчәсен, азәрбайҗан төрекчәсен, чыгтайча, татарча, һинд вә санскрит, кытай, япон, гыйбрани, сурияни телләре кебек төрле-төрле телләр үгрәтәләр* (Ф.Кәрими). Әлеге теркәгечләрнең иярчен аныклагыч җөмлә хасил итүенә мисаллар: *Бонларның төсләре генә түгел, уйлары да берләшеп беткән иде. Мәсәлән, Сөннәтче бабай: "Карчык, түтәлләргә сибәргә вакыт түгелме?" – дияргә өлгерә алмый иде, Гөлйөзем әби чиләкне күтәреп чыга башлый иде* (Г.Исхакый).

Хәзер сүзләремдә баштагы дорфалыклар сизелми иде, ягъни үзем сизми идем (Ш.Камал). *Бу шәһәрдән килгән кешенең киемнәре вә сөйләшүләре миңа ят тоела иде. Мәсәлән, ул сүз арасында "мин өлкән кеше" дип ычкындырса, мин бу "өлкән" дигән сүзне һич аңлый алмый идем* (Г.Тукай). З.Һади һәм Ш.Камал әсәрләрендә ягъни һәм мәсәлән теркәгечләренең икесе бергә урын алуы да күзәтелә. Мәсәлән, *Бу укытуга Вәлид хәзрәт тә тәхсис итеп: "Әссабакы хәрфен, эттәкрары әлфен, ягъни мәсәлән, сабакны бер хәреф алып, мең мәртәбә тәкрар кыйлырга кирәк", – диеп балаларны нәсихәт кыйла иде* (З.Һади). *Җылы булыр дип уйлыймыз инде, әйе. Ул, ягъни мәсәлән, кыш көне мәктәп салкын булса, әлбәттә, ягъни уңайсыз була, әйе. Менә бу бүлмә инде үзегезгә булыр, ягъни мәсәлән, үзегез инде шул бүлмәдә торырсыз. Бераз кечкенә кечкенәлеген... Әлбәттә инде, ягъни җәмәгатьсез кешегә артык тыгыз булмас дип уйлыймыз, әйе...* (Ш.Камал). Күренгәнчә, һәр ике авторда да әлеге теркәгечләрнең янәшә урын алуы персонажның сөйләм үзенчәлеген чагылдыру максатына җавап бирә.

Хәзерге телдә актив кулланыла торган **хәтта** теркәгече ХХ гасыр башында иҗат ителгән әсәрләрдә дә зур урын били. Әлеге теркәгечнең иярчен аныклагыч җөмлә хасил итүенә мисаллар: *Аның җанында әле хәзергә кадәр үзендә һич күренгәне булмаган бер тойгы – милли тойгы кузгалып китте. Хәтта бу калфаклы кызларның берсенең (Хәятның) шулкадәр матур булучылыгы аның җанында әллә нинди бер милли мактаныш кузгатты* (Ф.Әмирхан). *Саҗидә апай, чахотка белән авырып, хәтта мунчага-фәләнгә барганда, аны әти үзенең аркасында күтәреп йөри торгач, ниһаять, үлде* (Г.Тукай). Түбәндәге җөмләләрдә исә хәтта теркәгече аныклагыч ясауда катнаша: *Шул ялган хикәятләр вә мәкальләр, халыкның игътикадларыны бозып, хәтта фигыльләрене бозарга да сәбәп улалар иде* (З.Һади). *Борыны уртача гына иде, хәтта азрак кечкенәрәк диярргә дә ярый иде* (Г.Исхакый). *Аның өст-башы, чәч, мыегы вә гадәте тәмамән русныкы төсле булып, бу хәле күп кешеләр тарафыннан аның чын мөселман булуында шик кыйлынырга сәбәп булмакта, хәтта кайбер вакыт "чукынган имеш" хәбәрләре дә чыкмакта исә дә, ул вакыйгдә, чын ихласлы бер мөэмин иде* (Г.Ибраһимов). Бары Ф.Кәримидә генә хәтта ролендә килгән **вә лү** теркәгече

табылды: *Белмәгән бер шәһәргә барылдыгы вакыт, вә лү аз да булсын, әүвәлдән беркадәр мәгълүмат алмак иҗап итәр (соралыр – З.К.).*

Узган гасыр башында хәзерге әдәби телдәге “бигрәк тә”, “аеруча” мәгънәләрен белдерә торган **хосусән, бахосус (ба хосус), ба хосус ки, хосусы илә ки, бәлхассән** теркәгечләре кулланылышта йөри. Алар арасында гарәп теленнән алынган **хосусән** теркәгече тикшерелгән барлык язучылар иҗатында да урын ала, күбесенчә иярчен җөмлә төзүдә катнаша. Мәсәлән, *Һәрнәрсә мөмкин булып күренә. Хосусән, “Тәүзыйх”, “Мулла Җәлал” укып та, моназарага осталык илә, яки суфи вә тәкъвалык илә шөһрәт чыгарган шәкертләрнең хыяллары бик куәтле була* (Ф.Кәрими). *Абыстай теләгән вакытта кайнаган каймак, сары май, былтыргы балны кызганмады. Хосусән атналар үтеп китеп, Анна мөәзиннең кызын русча укыта башлагач, яшь мулла хатынына кул һөнәрләренә өйрәтә башлагач, боларның кадере артты* (Г.Исхакый). Хосусән теркәгеченең аныклагыч хасил итүенә түбәндәге мисалларны китерергә мөмкин: *Гәзитәләремезне мөрәттәб (тәртипле рәвештә – З.К.) укып барган кеше бу нәүгъ (төр – З.К.) мәгънәсезлекләргә еш-еш очрар. Хосусән, “Вакыт”ның бу хакта кыйлган юмартлыгын күреп, тәгаҗҗеб вә хәйрәттән (гаҗәпләнү һәм хәйран калудан – З.К.) үзене тыя алмас* (Г.Ибраһимов). *Ысулы кадим хәзрәтләрдән, хосусән үземезнең хәзрәтемездән көлә башладылар* (Г.Исхакый). Ф.Кәрими һәм Ф.Әмирхан әсәрләреннән алынган мисаллар да аныклагычлы гади җөмләне тәшкил итәләр, тик аларда теркәгечнең язылышында бераз аерма күзәтелә: *Һич хисапламаган җирдә үзенең бүлмәсенә бердән бергә буйлә гүзәл бер кыз килеп керүгә безнең депутат бераз шашырып калды вә шул сәбәпле аның әйткән фамилиясен дә аңлый алмады. Хосусан, мондай бер кыз килеп кергән вакытта үзенең камзулчан гына утыруына оялып китте, вә көзгене тизрәк бер читкә – өстәлгә алып куйды* (Ф.Кәрими). *Хәятның рус телен бик яхшы белүе һәм, кечкенәдән үк рус гаиләләренә, вә хосусан, Мясниковларга катышып килеп, рус җәмгыятендәге гореф вә әдәпләрне яхшы ук өйрәнгән булуы да тәрбияләр арасындагы бу зур аерманы каплап тора иде* (Ф.Әмирхан).

Гарәп-фарсы чыгышлы һәм “бигрәк тә” мәгънәсен белдерә торган **бахосус** теркәгеченә мисаллар исә нигездә Ф.Кәримидән тупланды. Мәсәлән, *Һәм дә зурларга вә бахосус, тәгълим вә тәрбия күргән кешеләргә, тәгъзыйм өчен, җәмгы сигасе (күплек формасы – З.К.) белән дә “сез” дип сөйләүнең лазем икәненнән асла хәбәрләре дә юк. Әгәр андаен нәрсәләрне белмәсәң, аларны белгән кешеләр арасына, үзеңне танымыйча, кереп кысылырга, вә бахосус, пароходның өстенә менеп, голама кыяфәте илә бөтен милләтеңне мәсхәрә иттерергә тиеш түгел икән.* Әлеге теркәгечнең аерым язылышлы формасы, шулай ук **ба хосус ки, хосусы илә ки** теркәгечләре Ф.Кәрими әсәрләре җыентыгының астөшермәләрендә “аерым алганда” дип тәрҗемә ителә: *Безнең өяз халкы, бөтен гаиләсе илә ел буенча кичә-көндез эшлиләр дә, алай да тамаклары туймый, өстләре – алама [...]. Ба хосус, бу вакытларда, яңа ашлык өлгермәс борын, бичаралар ачлыктан үләр чиккә җиткән булалар. “Петербургта өйләнсәм, кыш көннәре, Дума вакытларында бонда аның илә торсам, тәгътил (каникул, отпуск – З.К.) вакытларында, җәй көннәре, йортка кайтып, андагы гаиләм илә яшәсәм, боның кай йире фәна улачак? Ба хосус ки, минем күптән бирле берәр укыган кыз илә өйләнергә дәртем бар иде [...]”. Хосусы илә ки, без, шимди, Алманиягә барыюрбыз, ләкин кәндемез нимесчә белмәюрбез.*

Ф.Кәриминең “Кырымга сәяхәт”ендә **бәлхассән** теркәгече очрады. “Гарәпчә-татарча-русча сүзлек”тә билхасса, билхосус рәвешендә тәкъдим ителгән әлеге теркәгеч татар теленә “аеруча” дип тәрҗемә ителә [7, 30]: *Безне тәшйигъка килгән дустларымыз эчрүсендә Мостафа Нури әфәнде намында бере бәңа кәнденең рәсмен һәдия итте. Боңа бәлхассән тәшәккер итәрәм.*

Күренгәнчә, хәзерге телдә актив кулланыла торган бигрәк тә, аеруча, аерым алганда теркәгечләре бу чор әдәбиятында күп санлы алынма теркәгечләр белән бирелә. Бары 1910 еллардан соң гына **бигрәк тә** теркәгече күзәтелә башлый. Аерым алганда, Ф.Әмирханның 1911 нче елда язылган “Хәят” повесте һәм “Фәтхулла хәзрәт” әсәренең 1911-1912 нче елгы икенче басмасыннан түбәндәге мисалларны китерергә мөмкин: *Хәят аны уртача гына егетләрдән берсе саный, бигрәк тә, мыегын бөтенләй кырганлыгын ошатмый, авызы әбиләр авызы шикелле булып тора, ди иде. Яшьләр шул мөнәсәбәт белән, китап*

кибетләренә йөгереп, 20 нче гасыр башындагы татар тормышыннан, бигрәк тә, руханилар тормышыннан язылган комедияләрне алып укырга ашыгалар [...].

Йомгак ясап, шуны әйтергә мөмкин: XX гасыр башы татар әдәби телендә хәзерге вакытта да гаять актив булган ягъни, мәсәлән, хәтта теркәгечләре зур урын ала, “бигрәк тә”, “аеруча”, “аерым алганда” мәгънәләре исә гарәп яки фарсы чыгышлы хосусән (хосусан), бахосус (ба хосус), ба хосус ки, хосусы илә ки, бәлхассән теркәгечләре белән бирелә, хәзерге телдә сорау тудыра торган теркәгечләр XX йөз башы татар әдәби телендә әле актив кулланылышта булмый.

Әдәбият

1. Гаджиева Н.З. Синтаксис сложноподчиненного предложения в азербайджанском языке (в историческом освещении) / Н.З.Гаджиева. – М.: Изд-во АН СССР, 1963. – 220 с.
2. Зәкиев М.З. Татар синтаксисы: Югары уку йортлары өчен д-лек / М.З.Зәкиев. – Казан: Мәгариф, 2005. – 399 б.
3. Татар грамматикасы. Т. III. – М.: Инсан, Казан: Фикер, 1999. – 512 б.
4. Ибраһимов С.М. Татар телендә аналитик төзелмәләр / С.М.Ибраһимов. – Казан: Тат. китап нәшр., 1964. – 131 б.
5. Татар грамматикасы. Т. II. – М.: Инсан, Казан: Фикер, 2002. – 448 б.
6. Бәширов Ф.К. XX йөз башы татар прозасы / Ф.К.Бәширов. – Казан: Фикер, 2002. – 287 б.
7. Хәмзин К.З. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге / К.З.Хәмзин, М.И.Мәхмүтов, Г.Ш.Сәйфуллин. – Казан: Тат. китап нәшр., 1965. – 854 б.

Кузьмина Х.Х.

Матур әдәбият телендә темпоральлекне белдерү чаралары.

Темпоральлек, ягъни Вакыт һәм аны өйрәнү проблемасы бик борынгыдан, антик чордан ук башлап, кешеләрне үзенә тартып торган. Вакыт төшенчәсен аңларга тырышу, аның асылын ачарга омтылу Аристотель, Платон хезмәтләрендә үк күренә.

Вакыт материя төзелешендә роль уйный торган иң әһәмиятле категорияләрдән санала, шуңа күрә дә ул бик күп төрле фәннәрнең (физика, фәлсәфә, математика, психология һ.б.) өйрәнү обьекты булып тора. Шул ук вакытта вакыт төшенчәсе филология, лингвистика фәнендә дә күптәннән өйрәнелеп килә. Яңа фәлсәфә сүзлегендә бирелгән аңлатма буенча, Вакыт кеше субьективлыгының продукты дип билгеләнә (Новый философский словарь, 2000, 452), ягъни вакытның кешегә карата һәрвакыт субьектив булуы ассызыклана. Физика фәнендә вакытның төзелешен, параметрларын ачыкларга омтылганнар, аның аерым константа булуын һәм реаль тормышта һәрвакытта да пространство, ягъни урын, аралык физик зурлыгы белән мөнәсәбәттә булуын ачыклаганнар. Физика кануннары буенча, вакыт һәрвакытта да туры линияле, бары бер тарафка – үткәннән киләчәккә таба хәрәкәт итә торган зурлык. Телгә килеп кергәч, вакыт үзенең саф физик сыйфатларын югалтып, башка сыйфатлар белән байый, тулыландырыла; телнең чынлап та могҗизалы, тылсымлы көч икәне күренә: телдә вакыт кабатлаулы, күптән үткән, билгеле яисә билгесез дә булырга мөмкин.

Тел белемендә вакыт төшенчәсен өйрәнү аспектларына килгәндә, аның ким дигәндә өч аспектта өйрәнелүе турында әйтергә кирәк: XIX нчы гасырның икенче яртысында – XX гасырның беренче яртысында темпоральлек грамматик категория буларак өйрәнелсә, XX гасырның икенче яртысыннан соң темпоральлек төшенчәсенең телдә лексик яктан тәэмин ителүе һәм функциональ-стилистик төсмерләре өйрәнелә башлый. Бу аспектлар беренче чиратта когнитив лингвистика яссылыгында ачыклана. Рус тел белемендә вакыт төшенчәсенең бирелүен ачыклау буенча берничә диссертация язылган, аның концептуаль кыры билгеләнгән. Татар тел белемендә дә бу өлкәдә шактый эш башкарылган. Аерым алганда, “Темпоральность художественного текста на материале английского и татарского языков” дигән диссертацияне күрсәтергә мөмкин.

Татар телендә вакыт төшенчәсенең концептуаль кырын ачыклаганга кадәр, вакыт мәгънәсен белдергән сүзләрне тупларга кирәк. Билгеле булганча, вакыт – абстракт төшенчә, димәк, вакытны белдерә торган сүзләр конкрет мәгънәле сүзләрдән

күпкә соңрак, кешелек цивилизациясенең предметлы фикерләүдән абстракт фикерләүгә күчү дәверендә генә барлыкка килгәннәр, шуңа күрә күпчелек халыкларда вакытны кисәкләргә бүлгәләү, вакытны санау астрономик җисемнәр - кояш һәм ай белән бәйле. Элек-электән вакытны билгеләү өчен халыклар физиологик халәткә, хезмәт итү, көнкүреш, дини ориентирларга таянганнар, телдә әлеге ориентирларга бәйле сүзләр, сүзтезмәләр барлыкка килгән, мәсәлән, ахшам вакыты, сабан, урак өсте һ.б. Татар телендә мондый сүзләр бик күп:

Вакытны белдергән сүзләр: мизгел, секунд, минут, сәгать, таң, иртә, кич, көндез, өйлә, төштән соң, кич, төн, көн, тәүлек, кичә, бүген, өченчекөн, атна, ай, яз, җәй, көз, кыш, ел, быел, былтыр, йөз, чор, гасыр, заман, дәвер, вакыт, мәңгелек. Алардан ясалган сүзләр: бишъеллык, унъеллык, йөзъеллык, меңъеллык.

Кеше гомере белән бәйле сүзләр: сабыйчак, балачак, бала-чага, үсмерчак, яшьлек (яшь чак), яшь-җилкенчәк, егет чак, кыз чак, ир уртасы, картлык, гомер, тормыш.

Әлеге сүзләр татар теленең төп лексик фондын тәшкил иткәнгә күрә, әдәби әсәрләрдә авторлар тарафыннан бик теләп кулланыла. Үзләренең төп мәгънәләреннән тыш, мондый лексик берәмлекләр, әдәби әсәр тукымасына килеп кергәч, күчерелмә мәгънә төсмерләре белән байыйлар, образ барлыкка китерүдә бик әһәмиятле чара булып торалар. Татар әдәбиятының күп әсәрләре белән танышып чыккач, вакыт төшенчәсе Аяз Гыйләҗев әсәрләрендә үзенчәлекле яктыртылганлыгы ачыкланды. Мисал өчен алынган “Өч аршын җир” повесте – вакыт концепты тулырак ачылган әсәрләрнең берсе. Бу повестьнең сюжет линиясе дә кешенең үткән тормышы белән бәйле.

Бер җөмләдә темпоральлекне белдергән берничә сүз булуын очратырга мөмкин:

Дөнья, вакыт, гомер, чор төшенчәләре, **заманның** катлаулы язмышы, каты көрәш-бәрелешләре бу гашыйклардан читтә иде әлегә! (“Ө.а.җ.”, 219). Әлеге җөмләдә д**өнья, вакыт, гомер, чор, заман** сүзләре үзләренең төп лексик мәгънәләрендә килгәннәр һәм информатив лексикага карыйлар. Шул ук әсәрдә аларның һәркайсы өстәмә мәгънә белән баетылган һәм вакытны сурәтләүдә үзенчәлекле образ барлыкка килгән. Мәсәлән, *Ләкин **вакыт-патша**, тормышның астына ут ягып, аны кайнатып*

кына торды ("Ө.а.җ.", 219с). Әлеге җөмләдә вакытның һәрнәрсәдән өстен булуы аны патша белән чагыштыруга нигезләнә, шул ук вакытта бу җөмләдә вакыт һәм тормыш төшенчәләре бер-берсеннән аерылып бирелә. Әйтергә кирәк, *гомер* һәм *тормыш* төшенчәләре, темпоральлек аспектыннан караганда, беркадәр бәхәсле: галимнәр бу лексемаларны аерым концепт барлыкка китерә торган төп концептологик төш (ядро) буларак күрсәтәләр һәм вакыт мәгънәсен әлеге концептларның тирәлегендә урнашкан, перифериядәге мәгънә буларак билгелиләр. Чыннан да, тормыш лексемасында беренче планга вакыт мәгънәсе түгел, ә гомуми көнкүреш мәгънәсе чыга, темпоральлек исә өстәмә мәгънә буларак кулланыла, ләкин моңда без физик закончалык чагылуын күрәбез: вакыт һәм пространство һәрвакыт бер-берсенә бәйле. ***Гомерең*** *буе шуны сагынып, шуңа талпынып яшәгәнсең икән лә син! ("Ө.а.җ.", 230)*

Түбәндәге өзектә дә *тормыш* сүзе вакыт терминнары белән янәшә килгән: ***Сәгать*** *ничә? Кесәсендә* ***сәгате*** *бар иде инде барын, тик дүртенче* ***көн*** *борганы гына юк.* ***Тормыш җебе*** *кулыңнан ычкынганда,* ***атна, көн, сәгать*** *дигән вак-төяк төшенчәләрнең әһәмияте югала икән.* ("Ө.а.җ.", 230). Гомумән, А. Гыйләҗев *тормыш* концептын бик актив куллана һәм төрле метафоралар ясый:

Нык селкетте сине ***тормыш*** ***<u>җиле</u>****, кайгы-хәсрәт дулкыннары нык чайкалтты... ("Ө.а.җ.", 230)*

Үзең сукыр килеш ***тормыш*** ***<u>тәгәрмәче</u>*** *астына килеп кереп, аксак чеби хәлендә калуыңны хатыныңа ничек танасың! ("Ө.а.җ.", 238)*

Әгәр мин авылдашлар белән бергә булып, ***тормыш*** ***<u>казанында</u>*** *кайнасам, эшләсәм, эшемнән тәм тапсам, көршсәм, мондый газаплы уйлар белән җанымны интектермәс идем! ("Ө.а.җ.", 242)*

Мин үлгән булсам да, ***тормыш*** *шулай ук* ***<u>кайнап</u>*** *торыр иде. Барысы да искечә яшәрләр, шаярырлар, көлешерләр, эшләрләр иде. Димәк, мин бик кечкенә, әһәмиятсез зат микәнни?("Ө.а.җ.", 241)*

Вакытны тасвирлаганда, аның хәрәкәт итүен чынбарлыктагы предмет- күренешләрнең хәрәкәте белән чагыштырып күрсәтәләр. Гадәттә, дөнья халыклары телендә

вакыт су кебек ага, ком кебек коела, җил кебек исә, болыт кебек ага. Бу үзенчәлек татар әдәбиятына да хас:

***Замана** **дулкыннары** олы юллардан читтә, аулак бер куентыкта яткан Карачурага да килеп бәрелделәр ("Ө.а.җ.", 219).*

*Син, мин күр дип тормаган **тормыш**, алга аккан икән ("Ө.а.җ.", 241)*

*Син урасы арышларны **күзге** җилләр койдымы икән? ("Ө.а.җ.", 231)*

***Вакытка** нәфис чәчәкләр генә түгел, кешеләр дә чыдамыйлар... ("Ө.а.җ.", 231)*

Лексик-грамматик аспект – рәвешләр, бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр белән вакыт мәгънәсе бирелә.

Шулай итеп, татар әдәби телендә темпоральлек грамматик чаралар белән беррәттән, лексик-грамматик, лексик, лексик-стилистик чаралар белән белдерелә.

Әдәбият исемлеге:

Л.Г. Бабенко, Ю.В. Казарин. Лингвистический анализ художественного текста. – М., 2006.

Барт Р. Текстовой анализ// Новое в зарубежной лингвистике. Вып.9. – М., 1980.

Бахтин М.М. Формы времени и хронотопа в романе // Вопросы языкознания, 1974.- №3.

Маннапова Л. М.

Хәзерге татар әдәби телендә парлы сүзләр ясалышының фонетик закончалыклары

Парлы сүзләр ясалышында фонетик закончалыклар барлыгына галимнәр парлы сүзләрне өйрәнә башлау чорында ук игътибар иткәннәр. Иң беренче фонетик закончалыкларны төрки тел белемендә К. Фой билгели [Кайдаров, 1958, 21]. К. Фой күрсәткән закончалыкларның күбесе төрки телләрдә, шул җөмләдән татар телендә дә сакланмый [Рамазанов, 1984, 2].

Парлы сүзләр ясалышында фонетик закончалыкларны ике төргә бүлергә мөмкин. ***1) Парлы сүзләр ясалышына караган гомуми фонетик закончалыклар***. Бу очракта парлы сүзләргә хас

рифма, ритм, аллитерация турында сүз бара. ***2) Сүз һәм аның фонетик варианты моделендәге парлы композитларның икенче компонентының фонетик үзгәрүенә бәйле закончалыклар.*** Әлеге төр үзе ике төркемчәгә бүленә. **а)** Парлы сүзнең икенче компонент башындагы **тартык авазларның үзгәреше**. **б)** парлы сүзнең икенче компонентының **сузык авазлары үзгәрүе**.

Парлы сүзләр ясалышында гомуми фонетик закончалыклар дигәндә, иң беренче чиратта, парлы сүз компонентларының **рифмалашуы** күз алдында тотыла. А. Нажимов фикеренчә дә: “парлы сүзләр ясалышында фонетик моментлар әһәмияткә ия, ягъни компонентларының охшаш яңгырашлы, әйтелеше уңай булу мөһим” [Нажимов, 1971, 12].

Рифмалашу ике төрле булырга мөмкин**: 1) тамыр сүзләр рифмалаша**. Ул үзе ике төргә бүленә: а) тамырдан гына торган парлы сүзләр рифмалаша; б) тамыр һәм грамматик кушымча структурасына ия парлы сүзләр рифмалаша; **2) ясалма сүзләрдә бертөрле сүз ясагыч кушымчалар рифмалаша.**

Тулы рифма сүз һәм аның фонетик варианты тибындагы парлы сүзләрдә саклана. Иң беренче чиратта, аларда авазлар саны тулы килә. Икенчедән, бу төр парлы сүзләрдә тулы рифма саклана. Бу аңлашыла да. Чөнки парлы сүзләр ясалган вакытта ук беренче компонентка нигезләнеп төзелеп, аның фонетик варианты гына булып тора. Компонентлар арасындагы аермы бер яки ике авазда гына була. Үзгәрешләр дә беренче, икенче авазларда гына саклана. Мисалга, *заң-зоң, ярык-йорык, сак-сок, чаж-чож, чарт-чорт, кабыл-кобыл, калтый-колтый, каптыр-коптыр, капыл-копыл, карчык-корчык, каты-коты, катыр-котыр (чәйнәү), лагыр-логыр, шырдый-бырдый, тыз-быз, кылдый-былдый* һ. б.

Рифмалашу ягыннан икенче урынны фигыль сүз төркеме алып тора. Закончалыклы рәвештә татар теленлдә парлы фигыльләрдә беренче компонент нинди формада булса, икенче компонент та нәкъ шул ук кушымчага ия була. Бу аңлашыла да, чөнки парлы фигыльдә компонентлар төрле заманда килми, төрле зат-сан кушымчалары алмый һәм төрле фигыль төркемчәләренә карамый. Бу очракта парлы сүз мәгънәсез сүзгә әйләнеп калыр һәм парлы сүз буларак яшәүдән туктар иде. Парлы фигыль

барлыкка килсен өчен, компонентларның икесе дә бер үк формада килергә тиеш. Мисал өчен, *еларга-чәбәләнергә, елмаерга-көләргә, җайлап-юмалап, җимереп-ватып, җылыту-яктырту, зурлап-олылап, зыңлап-чыңлап, иелә-бөгелә, иелеп-бөкрәеп, изелеп-сытылып, иләнеп-чиләнеп, имләп-камлап.* Без карап киткән парлы фигыльләр арасында берничә генә компонентлары төрле формада булган сүзләр очрады. Мисалга, *күз ачып-йомганчы, килде-киpәкмәгән (кеше), очрашып-күрешү, төяп-бушатмыйлар, уйлашып-киңәшкәннән соң, уйнап-көлгәне юк иде, урып-җыю.* Болар арасыннан *килде-кирәкмәгән* сүзе парлы сүз. Чөнки биредә ул формаль яктан фигыльгә караса да, семантик яктан ул аергыч функциясендә килеп, сыйфат сүз төркеменә якынайган. Ягъни кеше сүзенә атрибутив мөнәсәбәттә тора. Сыйфатлар өчен рифмалашу чит булмаса да, фигыль сүз төркемендәге кебек мәҗбүри закончалык түгел. *Очрашып күрешү, уйлашып киңәшү, уйнап көлү* кебек сүзләрне парлы фигыльләргә кертеп карау бәхәсле. Әгәр дә аларның ике компоненты да бер үк формада килсә, аларны сызыкча аша язу дөрес: *очрашу-күрешү, уйный-көлә, уйлашу-киңәшү.* Рифмалашмаган мисаллар арасында шулай ук ике компоненты да хәзерге заман хикәя фигыль формасында килеп, төрле кушымча алган парлы фигыльләр бар. Бер компонентка -ый, -и; икенчесенә -а, -ә хәзерге заман формасы ялганган. Ләкин әлеге мисаллар күп түгел һәм закончалыкка каршы килерлек күренеш булып тормый. Мисаллар: *ярсый-сикерә, уйный-оча, уйный-чаба, уйный-шаяра, уйный-көлә, өзгәли-әрнетә, актара-карый.*

Сыйфат сүз төркеме өчен рифмалашу мәҗбүри түгел. Без тикшергән 500 ләп сыйфатның яртысы өчен рифмалашу хас, калган яртысы рифмалашмый. Һәм моның ачык кына кагыйдәләрен аерып чыгару да мөмкин түгел. Сыйфатларда рифмалашу башлыча **-лы, -ле/-сыз, -сез** кушымчасы ялганган очракта гына саклана. Рифмалашкан сыйфатларның иң күп өлеше (75 %ы) нәкъ шул юл белән ясалган. Мәсәлән, *челтәрле-телле, чиле-пешле, эсселе-суыклы, аңсыз-җансыз, тозлы-борычлы, туйлы-кунаклы, телсез-өнсез, сырсыз-бизәксез (бина).* Тамыр сыйфалар исә рифмалашмый. Мисал өчен, *сылу-чибәр, сау-шат, сау-имин, сәер-мөлаем, салкын-җитди, җитди-җылы, гади-мөлаем, озын-йомшак, куе-җиңел* һ. б. Рифмалашмаган парлы

сыйфатлар арасында берсе — ясалма икенчесе тамыр булган төрләре дә бар. Мисалга, *сокланулы-сәер, серле-тирән, ризасыз-караңгы, назлы-йомшак, моңлы-матур, ипле-тыныч, җитди-сынаулы, гайрәтле-калын.* Шулай ук бер компоненты -лы/-ле, -сыз/-сез, икенче компоненты да әлеге кушымчаларның берсе булган парлы сыйфатлар да очрый. Мәсәлән, *гамьсез-куанычлы, аңлаешсыз-ачулы, аңлы-аңсыз, ямьсез-шомлы.* Тик парлы сыйфатларның мондый төрләре аз. Сыйфат ясагыч -лы, -ле/-сыз, -сез кушымчалы парлы сыйфатлар гадәттә рифмалашып кулланылалар.

Төсне белдерүче сыйфатлар рифмалашмый диярлек, чөнки алар төрле төсне белдерүче сыйфатлар ярдәмендә ясала. Төсләрне белдергән сүзләр үзара рифмалашмаганлыктан, төсне белдергән парлы сыйфатлар да үзара рифмалашмавы аңлашыла. Бары тик сүз ясагыч -лы/-ле кушымчасы ярдәмендә барлыкка килгән сыйфатлар гына рифмалаша. Алар күп түгел. Мисал өчен, *аклы-күкле, аклы-кызыллы, ал(лы)-гөлле, зәңгәрле-кызыллы, кызыллы-зәңгәрле, зәңгәрле-яшелле, күкле-яшелле, кызыллы-каралы, кызыллы-сарылы кызыллы-яшелле, яшелле-зәңгәрле, яшелле-күкле.* Бу төр парлы сыйфатларның парлашуы закончалык буларак кабул ителә ала. Үз чиратында ике тамыр яки ясалма төсне белдерүче парлы сыйфатлар рифмалашуы очраклы рәвештә рифмалашу гына була ала, ә закончалык түгел. Мисалга, *күксел-яшел, якты-соры, ала-кола.*

Исем сүз төркемендә рифмалашу шулай ук бөтен тулылыгында чагылмый. Бу үз чиратында кушымча ялгану-ялганмау үзенчәлегенә бәйле. Без туплаган 1500 исем сүз төркеменә караган парлы сүзнең 360ы рифмалаша. Рифмалашу күренешен түбәндәгечә бүлеп булыр иде: **1) форма ясагыч кушымчалар рифмалашу; 2) сүз ясагыч кушымчалар рифмалашу; 3) тамыр исемнәр рифмалашу.** Соңгысы иң аз очраган мисаллар рәтенә керә.

Беренче төрне (форма ясагыч кушымчалар рифмалашу) үзен беничә төркемчәгә бүлеп карарга мөмкин: **а) парлы исемнең ике компоненты да тартым кушымчасын ала.** Тартым кушымчалары арасыннан иң активы булып III зат берлек сан тартым кушымчасы тора. Бу очракка караган мисаллар тартым кушымчалы парлы исемнәрнең 70%ын тәшкил итә. Барлыгы 89

тартым кушымчалы фигыльнең 61е әлеге мисалга карый. Мәсәлән, *исе-әсәре, исеме-чабы, көне-сәгате, очы-башы, тәне-сөяге, теше-тырнагы, урысы-татары* һ. б. Аннан соң икенче урында III зат күплектәге тартым кушымчасы тора (11 мисал). Мәсәлән, *апалары-агайлары, ботлары-чатлары, гүрләре-оҗмахлары, куллары-аяклары, куллары-бармаклары, куллары-киемнәре, күзләре-мыеклары, кырлары-болыннары.* **б) Ике компонентка да килеш кушымчасы ялгана.** Парлы исемнәрнең ике компоненты да килеш кушымчасы алган очракка мисаллар күп түгел. Бу мөгаен килеш кушымчаларының күбрәк соңгы компонентка ялгануына бәйледер. Бөтен исемнәр арасында бары **19** парлы сүзнең ике компоненты килеш кушымчасын алган. Мисал өчен*, балда-майда, алны-артны, алны-ялны, игә-чөйгә, ипкә-сапка, искә-санга, истә-күздә, истә-оста, истә-төштә, иткә-биткә, көнне-төнне, күзгә-башка, кырга-яланга, сөелүгә-назга, телгә-төшкә, төскә-башка, тузанга-майга, уйда-истә, эчкә-җанга.*

Шунысы игътибарга лаек: ике компоненты да килеш кушымчасы алган парлы сүзләрнең күбесе телдә катып калган формасында кулланыла. Икенче компоненты гына кушымча алган парлы исемнәр өч мәртәбә күбрәк. Бу исә тагын бер кат, Ф. Сафиуллина [Сафиуллина, 2004, 203], Ф. Тагированың [Тагирова, 2002, 27] кушымчалар парлы сүзләрнең ешрак икенче компонентына ялгана дигән фикерен раслый. **в) Парлы исемнең һәр ике компоненты да тартым+килеш кушымчасы ала.** Барлыгы **40** мисал тупланды. Иң күп очрак **III зат берлек сан, төшем килеше** формасына карый. Мәсәлән, *авызын-мыегын, акылын-җанын, акылын-фигылен, аркылысын-буен, ачысын-төчесен, башын-чәчен, битен-күкрәген, битен-муенын, җаен-форсатын һ.б.* (31 мисал). г) **Парлы исемнең һәр компоненты да күплек кушымчасына ия була**. Мондый төрдәге парлы исемнәр күп түгел. Телдә кабатланулардан качырга тырышу бар. Бу телдә аһәңлелек, матур яңгыраш белән бәйле. Ике компоненты да күплек кушымчасы алган парлы исемнәр күплек, бик күп, озакка сузылганлык мәгънәсен белдерә. Мисалга, *айлар-еллар, атналар-айлар, гөлләр-чәчәкләр, исәпләр-уйлар, картлар-карчыклар, кирпечләр-ярчыклар, малайлар-егетләр, уллар-оныклар, чатлар-аермалар, чикләр-бикләр, шәһәрләр-кальгалар.*

2. Рифмалашкан парлы исемнәр арасында **бер үк төрле сүз ясагыч кушычалардан ясалганнары** да күп очрады (**53** мисал). Алар арасыннан иң активы булып, **-ыш/-еш/-ш, -лык/-лек** кушымчалары ярдәмендә ясалган парлы исемнәр тора. **19** парлы исем **-ыш/-еш/-ш** кушымчасы ярдәмендә ясалган. Мисалга, *алыш-биреш, ачыш-табыш, багыш-күреш, барыш-кереш, елаш-кычкырыш, елаш-сыкраш, җыелыш-утырыш, йөгереш-кычкырыш, йөреш-торыш, кыланыш-торыш һ. б.*

17 мисалда парлы сүзнең һәр ике компоненты да сүз ясагыч **-лык/-лек** кушымчасы ярдәмендә ясалган. Мисаллар, *ачлык-ялангачлык, барлык-юклык, зулрык-хурлык, иминлек-тынычлык, исәнлек-иминлек, исәнлек-саулык, калынлык-юкалык, корылык-ачлык, тазалык-байлык, тазалык-саулык.* Соңгы мисалда рифмалашу ике төр сүз ясагыч кушымчасын алу рәвешендә бирелә. Рифмлашкан парлы исемнәр арасында компонентларның икесе дә **-ым, -ем, -м** сүз ясагыч кушымчасын алган очракны күрсәтергә мөмкин. Шундый **9** парлы исем очрады. Мәсәлән, *керем-чыгым, кием-салым, кием-тотым, килем-китем, туым-килем, үлем-бетем, үлем-китем, үлем-җитем, явым-төшем.* Шулай ук **-чы-че** кушымчалы исемнәр дә парлашып килергә мөмкин. Мәсәлән*, камчы-сихерче, кыйнаучы-җәзачы, орышучы-сугышучы, өшкерүче-сихерче, төзүче- коручы, юраучы-фалчы.*

Парлы исемнәрдән тамыр төзелешләре дә рифмалаша. Ләкин алар арасында тулы рифмага мисаллар бик аз. Күп кенә парлы сүзләрдә рифмалашу шартлы рәвештә генә күрсәтергә мөмкин. Аларда бары тик я бер аваз, я ике аваз гына туры килә. Рифмалашу я сүз ахырындагы бер хәрефтә, яки парлы сүз эчендәге сузык авазларның туры килүендә генә булырга мөмкин. Тулы рифмага мисаллар китерик: *аң-таң, ямь-тәм, яу-дау, ым-ырым, чара-бичара, күрше-күрпе, хәл-әхвәл, фигыль-шөгыль, Тәкыя-Нәкыя (игезәк кызларның исемнәре), сулагай-булмагай, ата-ана, пәрәмәч-күмәч, ачу-кычу, моң-чың, аяк-таяк, кыек-китек, көрәк-сәнәк, әбәк-чәбәк, коры-сары, әйлән-бәйлән, колан-болан, колхоз-совхоз, кирәк-ярак, киңәш-уңаш, карлыгач-сандугач, калдык-постык һ. б.*

Сүз ахырындагы бер тартык авазның туры килүен дә без өлешчә рифмалашуга кертеп карадык. Мисаллар, *яңгыр-кар, яз-көз, эш-омтылыш, утын-печән, ук-садак, тән-буын, түшәк-*

ястык, кашык-аяк, ләм-мим, ит-сөт, көрәш-сугыш, ирек-азатлык, ил-юл. Парлы сүз эчендәге яки ахырындагы бертөрле яки ясалышы буенча якын булган сузык авазларның кабатлануы **(а-ә, у-ү, ы-е(э), о-ө)** да өлешчә рифмалашу тудыра. Мисалга, *арба-чана, ата-баба, ачу-ярсу, яла-ифтира, шифа-дәва, чыбыркы-камчы, чишмә-елга, чәч-баш, чәч-каш, әйләнә-тирә, бәла-каза.* **Чәч-баш, чәч-каш, шифа-дәва** сүзләрендәге тартык авазлар да ясалышы буенчы бер-берсенә якын. Аерым алганда, **ч-ш, ф-в** тартыклары.

Рифмалашкан тамыр парлы исемнәр арасында сүзнең берничә тартык һәм сузык авазы туры килгәннәре дә бар. Авазлар компонентларның бер үк урыннарында кабатланмый, бәлки сүзнең төрле урыннарында бер үк тартык авазар килүе дә охшаш яңгырашка китерә. Мәсәлән, *азык-төлек, яфрак-сабак, ара-тирә, шигырь-җыр, шәрык-гареп, ант-шарт, чүлмәк-чынаяк, чирәм-үлән, челтәр-сурәт, чебен-кигәвен, хыял-идеал, хәбәр-хәтер, үлән-бәйләм, төтен-бетон, тән-җан, кыз-кымыз, арка-җилкә һ. б.* Мисал өчен, **шигырь-җыр** парлы сүзендә **ш-ж, ы, р** авазлары охшаш яңгыраш тудыра. **Челтәр-сурәт** сүзендә **т** һәм **р** тартыгы сүзнең төрле урыннарында урнашса да, (**т-р**, **р-т** рәвешендә), бертөрле авазлар булуы рифма тудыра.

Кушымча алган алмашлыклар өчен рифмалашу — мәҗбүри күренеш. Гадәттә, сорау алмашлыклары парлашып килгәндә үзара рифмалашмый. Бу аңлашыла да, чөнки сорау алмашлыклары төрләнми, кушымча алмый. Мисалга, *ни-нәрсә, кем-нәрсә, кайда-ничек.* Шулай ук тамыр алмашлыклар рифмалашмый. Мәсәлән, *ул-бу, теге-бу.* Әгәр парлы алмашлыкларның бер компоненты кушымча алып нинди дә булса формада килә икән, закончалыклы рәвештә икенче компонент та шул ук формага ия була. Мисал өчен, *алай-болай, анда-монда, андый-мондый, аннан-моннан, ан(ы)сы-мон(ы)сы, аны-моны, аңа-моңа, синнән-миннән, тегеләй-болай, тегене-моны, тегендә-монда, тегенди-мондый, тегеннән-моннан, тегеңә-моңа, тегесе-монысы.*

Рәвеш сүз төркеме өчен дә рифмалашу хас. Ләкин бөтен рәвешләр дә рифмалашмый. Без туплаган 82 рәвешнең 20 се генә рифмалашмаган. Ягъни 80% тирәсе рәвеш рифмалашкан. Мисалга, *бүлен-ярын, аңкы-миңке, астан-түбәннән, артыгы-*

киме, ачалак-йомалак һ. б. Рифмалашмаган рәвешләр арасында төрле кушымча алаган парлы рәвешләр белән беррәттән, тамыр рәвешләр дә бар. Беренче очракка мисаллар: *агай-энеләрчә, астын-өскә (китерү), иртәдән-кичкәчә.* Рифмалашмаган тамыр рәвешләргә мисаллар: *бута-болама (китерү), бүген-иртәгә, ду-чат (килү), зар-интизар, иртә-көндез, иртәдән-кичкәчә, исән-сау, ким-хур, кич-иртә, кичә-бүген, кичен-көндез, мәңге-бакый, хуш-мәмнүн, шау-гөр.*

Шулай итеп, рифмалашу парлы сүзләр өчен хас төп фонетик үзенчәлекләрнең берсе. Рифмалашу парлы сүзнең кайсы сүз төркеменә каравына бәйле. Рифмалашу бөтен тулылыгында "сүз-кайтаваз" тибындагы һәм фигыль сүз төркеменә караган парлы сүзләрдә чагыла. Рәвеш һәм алмашлык рифмалашу ягыннан икенче урында. Исем, сыйфат сүз төркеменә караган парлы сүзләр өчен дә рифмалашу чит күренеш түгел.

Әдәбият

1. Кайдаров А. Парные слова в современном уйгурском языке / А. Кайдаров. – Алма-Ата: изд-во АН казахской ССР, 1958. – 168 стр.

2. Нажимов Айман. Способы образования парных и парно-повторных слов в каракалпакском языке. Автореферат дис. канд. филол. наук / А. Нажимов. – Нукус: полиграфкомбинат им. 50-летия Правды РК, 1971. – 30 стр.

3. Рамазанов К. Т. Семантические принципы порядка компонентов парных слов в тюркских языках юго-западной группы. Автореферат доктора филол. наук / К. Т. Рамазанов. – Баку: АН Азерб. ССР, 1984. – 39 стр.

4. Сафиуллина Ф. С. Татар телендә парлы сүзләр һәм синтаксик мөнәсәбәтләр / Ф. С. Сафиуллина. – // Фәнни язмалар. – 2003. – Казань: РИЦ "Школа", 2004 – Б. 201-207.

5. Тагирова Ф. И. Лексикографирование и орфографирование сложных слов татарского языка / Ф. И. Тагирова. – Казань: "Печатный двор", 2002. – 128 стр.

Миннегулов Х.Ю.

Еще раз о турецко-татарских взаимосвязях

Когда речь идет о взаимоотношениях народов, решающим фактором считаются пространственно-географические расстояния. Да, в целом, это так. Близкое соседство, как правило, объективно наталкивают на общение, на сотрудничество. Но в жизни бывают и отклонения от общих закономерностей, от привычных правил. Ярким примером такого парадоксального явления считаются турецко-татарские взаимосвязи. Как известно, турки проживают, в основном, в Малой Азии, за Черным морем, а татары – в Поволжье и Приуралье, т.е. в Идель-юрте.. Османская и Российская империи в течение многих веков враждовали, воевали. Русские цари неоднократно пытались осуществить памятное «завещание» Петра Первого – завоевать Константинополь, водрузить российское знамя на храм Айа-София. Между СССР и Турцией, хотя и не было войн, взаимоотношения оставляли желать лучшего. Татары же, находящиеся под колониальным гнетом Москвы и Петербурга, не имели права самостоятельно определять свою судьбу, их часто вынуждали участвовать в антитурецких кампаниях, обвиняли в «пантюркизме». Отголоски такой политики продолжаются и по сей день. Например, стремление татар принять латиницу воспринималось официальными властями России как происки турецких разведывательных служб.

Но несмотря на различные объективные и субъективные трудности, преграды, связи между Идель-юртом и Малой Азией, обмен духовными ценностями не прерывались. Каждое поколение в той или иной степени внесло свою лепту в это благородное дело – сотрудничество.

Многовековые турецко-татарские взаимоотношения обусловлены реальными факторами, логикой исторического развития и характеризуются богатством и разнообразием диалогов, контактов. Оба народа имеют общие генетические корни. Алтай, Сибирь, Центральная Азия – это прародина почти всех тюрков. Но и дальнейшие судьбы наших предков, несмотря на миграционные изменения, переселения, часто соприкасались

друг с другом. Тюркские, уйгурский, хазарский каганаты, сельджукский, кимакский, караханидский, кипчакские политические союзы – все они взаимосвязанные звенья развития тюркской государственности. Рунические памятники, сокровища Махмуда Кашгари, величайшее творение Юсуфа Баласагуни, тончайшая лирика Ахмеда Ясави, страстные стихи Сулеймана Бакыргани и другие сочинения древности и раннего Средневековья считаются общим достоянием всех тюркских народов, фундаментом национальных литератур уйгур, узбеков, турков, татар, азербайджанцев и других.

XIV век – начало XV столетия – могущественный период развития тюркского мира. В руках Тимура, Туктамыша, Баязида была судьба не только тюркских народов, но и всей Европы и Азии. К сожалению, эти талантливые, великие правители, поддавшись личным страстям, политическим амбициям, пошли не по пути объединения, совместной заботы о благополучии и расцвете тюрков, а наоборот, к разъединению их, к разрушительным войнам, к истощению духовных сил наших предков, в результате чего распались империя Тимура, Золотая Орда; постепенно ослабло и через столетие сошло с политической сцены Мамлюкское государство. Османская империя, хотя в течение ряда веков была мировой державой, ее правители не очень заботились о сохранении и развитии других тюркских народов и государств. Например, когда руководители Казанского и Астраханского ханств перед вторжением Ивана Грозного обратились за помощью к османскому султану, могущественный Сулейман Кануни ничего не предпринял в защиту татар Поволжья. Вследствие чего эти татарские ханства были уничтожены. Предки современных татар оказались под колониальным гнетом; Россия встала на путь своего имперского развития и постепенно вытеснила свою соперницу – Османскую империю – с ее азовско-причерноморских и балканских территорий. Следует отметить, что Турция после Первой мировой войны, в основном, перестала быть империей, а Россия даже в XXI веке остается все еще ею.

Как известно, многие тюркские народы в течение ряда столетий держали свои государства, были хозяевами своей судьбы. Но к началу XX века таковым остались, в основном,

только турки. И их государство было уже слабым, не очень способным влиять на события в мире, на судьбу других тюркских народов. С распадом СССР сложилась совершенно иная ситуация: возник ряд новых, самостоятельных тюркских государств (Казахстан, Узбекистан, Азербайджан, Туркменистан, Киргизия). Они вместе с Турцией сейчас занимают значительные территории Центральной и юго-западной Азии, частично и Европы, где имеются богатые людские и природные ресурсы, удобные транспортные узлы, многовековой опыт ведения хозяйственной и культурной жизни. В настоящее время в тюркских (можно сказать – в тюрко-мусульманских) государствах проживает около 120 миллионов человек. Рождаемость у них очень высокая. Поэтому население в этих государствах быстро возрастет. Кроме того, рядом с Казахстаном, Азербайджаном проживают башкиры, татары и некоторые другие тюркские народы. Таким образом, XXI век открывает широкий простор и невиданные до сих пор возможности экономического, духовно-интеллектуального развития огромного тюркского мира, способствует взаимовлиянию и взаимообогащению культур населяющих его народов.

В связи с этим, хочется высказать еще одно предположение. Судьба почти всех тюркских народов, кроме турков, в той или иной степени связана с Россией (в широком смысле слова – с царской, в более узком – с Федеративной). В отличие от других тюрков, татары самый распространенный народ в России. И поэтому их язык, начиная с Средневековья и почти до 30-х годов прошлого столетия, выполнял определенные функции межнационального общения между тюркскими народами, с одной стороны, с другой – между официальными властями России и восточными мусульманскими странами. В связи с новой геополитической ситуацией в Евразии, с потребностями сотрудничества между тюркским миром и Россией, татарский язык может быть востребованным в качестве межнационального и международного языка и в XXI веке.

***

После некоторых размышлений глобального характера снова вернемся к турецко-татарским взаимосвязям, прежде всего – к литературным, интеллектуальным.

Многовековые, эффективные взаимоотношения между Малой Азией и Идель-юртом в духовной сфере были обусловлены прежде всего единством религии, генетическим родством, общей основой древнего словесного искусства, близостью языков, верований. Ислам как бы духовно сплотил различные этнические общности, способствовал созданию относительно единых интеллектуальных и эстетических ценностей, гуманистических идеалов и критериев морально-нравственных оценок. Следует отметить, что в средние века так называемый Мусульманский Восток стал центром мировой цивилизации, в котором доминирующую роль играли арабы, персы и тюрки. Кроме религии, их объединяла еще и единая графика. Арабский язык употреблялся как международный, как язык науки и религии. В связи с расцветом персидско-таджикской литературы, в X-XV веках очень возрастает роль фарси в мусульманском мире.

Арабский и персидский языки, литературы, частично их синтез оказали большое влияние и на татар, и на турков. В языках и словесности этих тюркских народов очень много арабо-персидских заимствований, сходных понятий, терминов, жанров, образов, сюжетов. Наличие общего источника в лице арабо-персидской письменной культуры создавало благоприятные условия для сближения и диалога татарской и турецкой литератур.

Интеллектуально-духовный уровень каждого народа во многом зависит от реальных жизненных обстоятельств, от социально-политических и общественно-нравственных факторов. В этом отношении в тюркском мире наблюдаются интересные явления. В караханидском, или по-другому – тюрко-уйгурском государстве в XI – XII веках бурно развиваются литература, наука, искусство. Гениальное произведение Юсуфа Баласагуни «Кутадгу билик» («Благодатное знание») (1069/1070) и по сей день считается кладезем мудрости, образцом поэтического слога. В XIV веке интеллектуально-культурным центром тюркского и даже всего мусульманского мира становится Золотая Орда. По словам Ибн Арабшаха (1388-1450), «город Сарай (столица этого государства. – Х.М.) сделался средоточием науки и рудником благодатей. За короткое время в нем собралась добрая и здоровая

доля ученых и знаменитостей, словесников и искусников, да всяких людей заслуженных, какой подобная не наблюдалась ни в многолюдных частях Египта, ни в деревнях его… Это был один из величайших городов по положению (своему) и населеннейший по количеству народа» (В.Тизенгаузен. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. Часть 1. – СПб, 1884. – С.463). По утверждению ученых, тюрки-татары Джучиева Улуса оказали значительное влияние на развитие литературы Средней Азии, Мамлюкского и Османского государств, в частности на творчество Ахмеди, Лутфи, Дурбека и др. XV столетие – это период расцвета тюрко-узбекской литературы, это – век Навои. Его творчество в известной степени определяло дальнейшую судьбу всей тюркоязычной словесности. В этот же период, опираясь на творческий опыт Шайяда Хамзы, Юнуса Эмре, Ашика Паши, Султана Веледа, Ахмеди и используя эстетические достижения других тюркоязычных, а также персоязычных авторов, османская литература добилась значительных успехов и вскоре стала доминирующей в тюркском мире. Татары же, вследствие потери государственности, жестокого колониального гнета, в течение ряда веков не могли нормально развивать свою культуру, словесное искусство и поэтому для удовлетворения духовных потребностей часто обращались к творениям других народов, в первую очередь – к произведениям мусульманских авторов. Они читались как в оригинале, так и в различных переводах, шерхах-комментариях.

Особую популярность среди татар получили научные, художественные, педагогические сочинения османских авторов. Необходимо подчеркнуть, что старотурецкий и старотатарский письменные языки были очень близки друг к другу и поэтому тексты, в основном, не нуждались в переводах. Кроме того, в XVII – XIX столетиях и даже в начале XX века в татарский письменный язык проникало много османских слов, выражений и грамматических форм. Это особенно бросается в глаза в произведениях Исмагила Бикмухаммедова (XVIII в.), Мусы Акъегетзаде (1864-1923), Фатиха Карими (1870-1937), которые в течение ряда лет жили, учились в Малой Азии. Даже в начальном периоде творчества Тукая, который ни разу не был в Турции, очень заметно влияние османского языка. Но постепенно, в связи

с общей тенденцией сближения письменного языка с разговорными, с развитием национального литературного языка, начинают появляться переводы османских сочинений на татарском. Среди них можно отметить такие знаменитые сборники «1001 ночь», «Тутинаме», книги К.Насыйри и других. Но до Октябрьской революции среди татар в целом доминировало чтение османских книг на языке оригинала.

Татарская публика в течение многих столетий особенно предпочитала «Гарибнаме» («Книга скитальца») Ашика Пашы (1271-1332), «Искандернаме» Ахмеди (Гирмияни. – 1329-1412), «Мухаммадия» Челеби (Языджоглу Мехмед) (1358-1451), «Рождение пророка» («Мәүледен-нәби») Сулеймана Челеби (умер в 1422 году), «Светоч влюбленных» / «Әнвәрел-гашыйкыйн») Ахмеда Бижана (XV в.) и др. Как видно, основная часть этих произведений религиозно-суфийского характера. Востребованность таких сочинений прежде всего объясняется обстоятельствами татарской действительности и духовными потребностями читателей и слушателей.

Имеется множество рукописей османоязычных произведений, составленных татарскими переписчиками. С XIX века широкое распространение получают печатные издания, выпущенные в Стамбуле и Казани. Так, например, «Мухаммадия» Челеби, начиная с 1845 года, издается в Казани более 20 раз и становится наравне с «Кыйссаи Юсуф» Кул Гали и «Рисалаи Газиза» Ялчыгола самой популярной книгой в татарском мире. Она оказала существенное влияние на творчество ряда татарских поэтов. В частности, сатирическая поэма Г.Тукая «Ысулы кадимче» написана способом назиры на одну из глав «Мухаммадии». Великий татарский поэт и в других произведениях использует мотивы, образы, рифмы, поэтические размеры сочинения Мухаммеда Челеби. Велика роль «Мухаммадии» в исторической судьбе татарских мунаджатов, которые и в наши дни звучат со сцен, по радио и телевидению. К знаменитому сочинению турецкого автора часто обращались Г.Кандалый, М.Гафури, Ф.Карими и другие татарские писатели. Г.Ибрагимов называет «Мухаммадию» «гениальным творением» и подчеркивает, что это произведение, как синтез «поэзии, песни

и музыки, в течение веков было духовной пищей» для татарского народа.

«Искандернаме» Ахмеди, кроме чтения широкой публикой, использовалось как учебное пособие по тюрки в некоторых учебных заведениях России, а также в Казанском университете. Отрывки из него опубликованы и в «Татарской хрестоматии» С.Кукляшева (1859).

В 30-70 гг. XIX столетия в Османской империи были проведены реформы, вошедшие в историю этого государства под названием Танзимат. Реформаторы брали пример с Западной Европы, в первую очередь – с Франции, проводили определенные изменения в системе образования, культуры, науки и в структуре управления. Изучение французского языка стало своего рода модой в Стамбуле.

Результаты Танзимата особенно выпукло проявились в османском словесном искусстве. На турецкий язык было переведено множество произведений западноевропейских авторов. Эти трансплантированные сочинения часто адаптировались к османской действительности, мусульманизировались. Турецкие писатели стали создавать свои произведения по образцу западноевропейского словесного искусства. Среди таких особенно выделялись Ибрахим Шенаси (1826-1871, его часто называли «отцом новой литературы»), автор известных драм Намык Кемаль (1840-1888), энциклопедист Ахмед Мидхад (1844-1913) и др. В результате творческого усвоения западноевропейских художественно-эстетических ценностей турецкая литература претерпела значительные изменения, поднялась на новый этап своего развития.

Во второй половине XIX столетия – в начале XX века обмен печатной продукцией между Малой Азией и Идель-юртом получил особый размах. Татарская интеллигенция была в курсе литературно-духовной жизни Османской империи. Кроме того, в эти десятилетия количество обучающихся в Стамбуле татарских студентов резко возрастает. Среди них были и писатели: Муса Акъегетзаде (1864-1923), Фатих Карими (1870-1937), Габдрахман Саади (1889-1956) и др. Они активно внедряли опыт «новой турецкой литературы» в татарское словесное искусство. Представители новой волны османской словесности Тевфик

Фикрет (1867-1915), Мехмет Тевфик (1843-1898), Шемседдин Сами (1850-1904), Халид Зия Ушаклыгиль (1866-1945) и др. были хорошо известны среди татарской творческой интеллигенции, их произведения читались в оригинале, некоторые переводились и на татарский язык.

Ахмед Мидхад – генератор духовной жизни османского общества второй половины XIX века-начала XX столетия – был своего рода наставником, кумиром татарской молодежи этого периода. Он неоднократно встречался, переписывался с татарами. Великий просветитель Ризаэддин Фахреддин (1859-1936) высоко ценил многогранную деятельность Ахмеда Мидхада, в своих трудах [«Воспитанное дитя» («Тәрбияле бала») и др.] использовал и пропагандировал его идеи. В 1913 году он выпустил замечательную книгу, посвященную этому великому сыну турецкого народа, которая и по сей день считается надежным источником при изучении жизни и творчества не только Ахмеда Мидхада, но и в исследовании татаро-турецких взаимоотношений.

В целом, Танзимат дал хорошие результаты, обильные плоды в османской литературе. Ими пользовались не только сами турки, но и некоторые тюркские народы, в первую очередь – азербайджанцы и татары.

Золотым периодом татарской литературы считается начало XX века. Это – время расцвета творчества Г.Исхаки, Г.Тукая, Г.Ибрагимова, М.Гафури, Дердеменда, С.Рамиева, Ф.Амирхана, Г.Камала, Ш.Бабича и многих других корифеев татарского словесного искусства. Литература этого периода характеризуется идейно-эстетическим богатством, разнообразием жанров, совершенством формы и стиля. Такое ускоренное развитие татарской литературы было обусловлено многими факторами: богатыми традициями и многовековым эстетическим опытом словесного искусства татар; тесной связью с классикой мусульманского Востока; общественно-политической ситуацией и борьбой за демократию в России; ростом национального самосознания народа; возникновением многочисленных газет и журналов на татарском языке, а также профессиональных театров; наличием широкой сети образовательных учреждений и др. Среди таких факторов значительную роль играли

традиционные взаимосвязи со османским словесным искусством. Во-первых, турецкая литература является одной из богатых, развитых литератур в тюркском мире. Во-вторых, многие произведения, достижения арабо-персидской классики входили в татарскую духовную жизнь через османский язык. Таковыми являются сборники «1001 ночь», «Тутинаме»; сочинения, переведенные на татарский язык К.Насыйри «Кабуснаме», «Гульрух и Камарджан», «Абугалисина» и многие другие. В третьих, османская литература сыграла роль посредника и в освоении татарами художественно-эстетического опыта Западной Европы. Несмотря на то, что мы издавна являемся соседями русских, но почти до конца XIX века не ощущается заметное влияние великой русской литературы на словесное искусство татар. Усвоение достижений русской литературы и через нее западноевропейской активизируется лишь в начале XX столетия. А до этого в межлитературных связях доминирующую роль сыграл Стамбул. Следует отметить, что в турецко-русских литературных контактах определенную роль играли и татары. В частности Муса Акъегетзаде, Габдулла Баттал-Таймас, Гаяз Исхаки, Фатих Карими, Закир Кадири, Садри Максуди и некоторые другие наши соплеменники, которые жили в Турции, переводили отдельные сочинения русских авторов на турецкий язык.

Вследствие колониальной политики царизма, различных революций, войн значительная часть татар была вынуждена оставлять свои родные края, эмигрировать в другие страны. Одним из таких притягивающих регионов мира для наших соплеменников была Малая Азия. Общность религии, графики, близость языка и духовных ценностей, генетическое родство, традиционные связи в определенной степени облегчали тяжелую участь эмигрантов. Население и властные структуры Османской империи – Турции в целом положительно относились к приезжим татарам, не препятствовали их адаптированию к турецкой жизни.

Татары, эмигрировавшие в Малую Азию, появились уже в средние века. Например, поэт Умми Камал (Исмагил. – Конец XIV века – 1475) вначале жил в Поволжье и в Крыму, а последние годы своей жизни провел в Османском государстве. Он считается общим поэтом и татар, и турков. После падения

Казанского, Астраханского, Крымского ханств количество переселившихся в Малую Азию татар, наверно, достигло нескольких сот тысяч. К ним прибавилась волна мухаджиров конца XIX и начала XX столетия. В Османской империи образовались отдельные деревни, кварталы эмигрантов – татар. В советское время Турция стала основным пристанищем для многих национальных деятеле, таких как Садри Максуди, Юсуф Акчура, Гаяз Исхаки, Заки Валиди, Рашид Рахмати (Арат), Акдас Нигмат Курат, Габдулла Баттал (Таймас), Закир Кадири, Фуат Туктаров, Гумер Терегулов, Ахмед Тимер, Сагадат Чыгатай, Сания Гиффат, Исфандияр Ишгай, Наиля Бинарк и многие другие, которые вложили много труда в развитие науки, литературы, культуры, просвещения, а также экономики Турции.

Муса Акъегетзаде известен татарским читателям как автор нового, реалистичного романа «Хисамеддин менла» (1886). Когда он переехал в Османскую империю, учился в престижном высшем учебном заведении в Стамбуле, написал ряд трудов по экономике. По мнению турецких ученых, его сочинения сыграли большую роль в реформировании экономики Турции. Оренбургский татарин Кемал Лукман (1899-1976) вначале учился в России, затем в Стамбуле, Гренобле, Страсбурге; кроме татарского и русского, хорошо владел турецким, английским, французским, арабским и другими языками. С 1929 года он работает в Турции председателем государственной нефтянной компании, министром энергетики и природных ресурсов Турции и др. Ахмед Вали Менгер (1891-1978) обосновал в Турции совместную немецко-турецкую фирму по производству автомобилей «Мерседес-Бенц». Ибрагим Вали, выходец из Троицка, учился в медресе, в Челябинской гимназии. Затем был студентом медицинского факультета Томского и Берлинского университетов. С 1937 года – в Турции . В течение ряда лет работал деканом медицинского факультета в Анкарском университете. Автор многочисленных монографий, учебников по медицине. Юсуф Акчура (1876-1935) был советником президента Ататюрка по вопросам политики и культуры. Садри Максуди (1878-1957) в течение почти 10 лет являлся депутатом парламента Турции. Таких примеров можно привести много. Примечательно то, что эмигрировавшие в Турцию татары не

забывали свои корни, национальную культуру, искусство: проводили вечера, издавали газеты и журналы («Kazan», «Тукай бюллетене» и др.), выпускали книги. В частности, Габдулла Баттал-Таймас написал сочинения о Ризаэддине Фахреддине (1958), Мусе Бигиеве (1958), Баруди (1958), о братьях Максудовых (1959) и др. Исфандияр Ишгай, Лебиб Каран издавали свои поэтические сборники на татарском языке.

***

С конца 80-х годов прошлого столетия, особенно после распада СССР в татарско-турецких взаимоотношениях начинается новый этап, характеризующийся интенсивностью диалога, сотрудничества. Между Казанью и Стамбулом почти ежедневно летали самолеты. Кроме того, пользовались и другими видами транспорта. Турция широко распахнула двери в свои учебные заведения. Наверно, в вузах этой страны обучалось несколько сот татарской молодежи. Поток туристов устремлялся в музеи Стамбула, Анкары, Измира, Коньи других городов. Курорты Анталии, Алании стали любимыми местами отдыхающих из Татарстана. Поездки в Турцию дали возможность глубже вникнуть в историю, культуру тюркских народов, ознакомиться с доселе недоступными для нас трудами, материалами, касающимся непосредственно татар. Так, например, мы узнали сочинение Шарифи «Зафарнамаи вилаяти Казан» (1550), труды Дауда Сулеймана Саксини (XII в.), познакомилиь с богатым литературным и научным наследием Г.Исхаки, С.Максуди, Г.Баттала-Таймаса и других эмигрантов-татар, а также с трудами нашего соплеменника – профессора Надира Давлета. Наши ученые совместно с турецкими, узбекскими, казахскими коллегами принимали участие в создании 33 томной истории литературы тюркских народов, энциклопедии. На турецком языке были опубликованы антология татарской поэзии, «Идегей», «Кыйссаи Юсуф», произведения современных татарских писателей. Например, в переводе Фатиха Кутлу на турецком языке изданы сборник татарских рассказов и повесть А.Гилязова «Три аршина земли». Фатма Озкян написала монографию о Тукае, издала его стихотворения на турецком и татарском языках. В Турции и Татарстане неоднократно проводились совместные научные конференции, симпозиумы,

посвященные актуальным проблемам тюркологии, межнациональным отношениям.

Сотрудничество Турции и России (где татары по количеству занимают второе место) в конце XX столетия – в начале XXI века получило невиданный размах. Россияне благодарны турецким строителям за возведенные жилые дома, административные и учебные здания. Построенная турками мечеть Кул Шариф стала уже одним из символов города Казани. Особенно велика роль турков в нашей системе образования. В Казанском государственном университете уже около 20 лет готовятся специалисты по туркологии с участием преподавателей из Турции.

Открытые в 90-е годы прошлого столетия турецко-татарские лицеи стали подлинными очагами образования, воспитания и культуры. Работа в них ведется с учетом и использованием современных мировых достижений, инновационных технологий. Выпускники лицеев хорошо владеют татарским, русским, английским и турецким языками. Совместная педагогическая деятельность турецких, и татарских учителей дает отличные результаты. Учащиеся лицеев постоянно занимают призовые места на различных соревнованиях, выступают победителями на республиканских, региональных, общероссийских олимпиадах, особенно по естественно-математическим циклам. Почти все выпускники лицеев поступают в вузы, техникумы и успешно продолжают учебу. В Казанском госуниверситете, где я работаю профессором, они учатся на различных факультетах. Наши коллеги очень хорошо отзываются об их учебе, воспитанности. Из числа выпускников лицеев уже выросли известные ученые, деятели литературы и культуры. Короче, татарско-турецкие лицеи уже на практике отлично зарекомендовали себя; сама жизнь требует сохранения и приумножения этого положительного опыта.

Когда речь идет о турецко-татарских взаимоотношениях, необходимо вспомнить еще один интересный аспект. Это – отображение жизни этих народов в их литературе. По имеющимся у меня сведениям, в туркоязычном словесном искусстве есть ряд произведений, посвященных татарской тематике. В частности, в центр романа Илгаз Вахаба Наурузхана

поставлена Казанская царица Сюмбике. Это произведение издано и на татарском языке (Сөембикә. – Чаллы, 1992. – 128 б.)

Татарские авторы издавна обращаются к жизни Турции. Например, в хаджнамах Исмагила Бикмухамедова, Мухаммеда Амина, Гали Чукрыя, в саяхатнаме Фатиха Карими имеются интересные картины, сведения об османской действительности. Гаяз Исхаки в рассказе «Покаявшаяся женщина» трогательно изображает сложную судьбу турчанки. У современных татарских поэтов Чулпан Зариф-Четин, Рустема Сульти, Файрузы Муслимовой и др. есть специальные циклы стихотворений, написанные на турецкую тематику.

***

Даже беглый экскурс в историю показывает, насколько глубокими и разносторонними были турецко-татарские взаимоотношения. Они охватывают более чем тысячелетний период, многие области духовной и материальной жизни. Этот богатый опыт диалога двух народов послужит надежным подспорьем и для дальнейшего плодотворного сотрудничества не только для турков и татар, но и для других народов и стран.

Минегулова А.Р.

Әсәрнең беренче сигез мәрҗәнендә автор милли сәясәт, милләт проблемаларын калку итеп куюга ирешә. Шул ук Әсир Мөхәммәтҗан мисалында ул рус империясенең кече халыкларга баскыннарча мөнәсәбәте, әлеге халык вәкилләренең тоткыннарча гомер кичерүе, күбесенең урыслаштырылуы турында уйланырга мәҗбүр итә. Кавказ халыкларының курку белмәс баһадиры Шамил улының урыс мохитендә тәрбияләнеп, Мөхәммәтләргә кимсетеп каравына, “бөек” милләт холык-фигылен алуына автор ризасызлык белдерә. Шул ук вакытта К.Тинчурин үз милләте турында да ачынып яза. Әсәрне уку дәвамында татарлар арасындагы бердәмсезлек, көнчелек, бер катламның икенчесеннән өстенлеге, юк нәрсә өчен дә тарткалаш-сугыш – болар бар да татар милләтенә хас күренешләр. Әйтерсең, әдип санаган тискәре күренешләр аркасында гына милләт шул дәрәҗәгә төште дип белдерергә тели. Бердәмлек, татулык шәкертләр арасында да юк; әсәрнең бөтен дәвамында үзәк урын объекты булып торган Печән базарында да һәрчак талаш, бер-береңнән көлү, сугыш һәм үтереш; бай “милләтпарвәрләр”нең “кечкенә” кешеләргә мөнәсәбәте дә явызларча; инкыйлаб, гражданнар сугышы чорындагы милләтнең үз эчендәге тарткалашлар, фикер төрлелеге дә күп очракта фаҗигагә алып килә.

“Сакал” дип аталган тәүге мәрҗәндә үк, Тинчурин милләткә сыйфатлама бирә. Шәрәфи исемле байның кибетеннән килеп чыккан күсе артыннан ярлысы, бае, чалбарлысы, чалбарсызы йөгерә башлыйлар. “Күсене урам уртасында тотып, плен алып, койрыгыннан күтәреп, зур тантана белән мәчет алдына ... фонарь баганасына башы белән аска таба асып куялар”. Шуннан китә кадимчеләр белән җәдитчеләр арасында талаш, бер-береңнән көлү. Күсе куу вакыйгасында авторның сатира остасы булуы искә төшә. Милләткә хезмәт итү, аның мәнфәгатьләрен кайгырту урынына күсе куу белән мавыгып, юк-бар эш белән

шөгыльләнеп, вакытларын буш сүз уйнатуга кайтарып калдыруларына Тинчурин, әлбәттә, ризасызлыгын белдерә.

“Мәрҗәннәр” өчен уртак герой, барлык хикәя-новеллаларны берләштереп торучы каһарман – Сөләйман образы. Хронологик яктан әсәр Сөләйманның авылыннан, әнисе яныннан китеп, Казанга килгән вакытыннан алып, гражданнар сугышы дәверенә кадәр корылган. Төп герой шактый тулы ачылган. Ә.Кәримуллин, Р.Ишморатлар Сөләйман образының прототибы итеп Тинчуринның үзе алынган дип саныйлар. Чыннан да, әсәрнең һәр мәрҗәне, һәр бүлеге зур танып белү көченә ия. Башкалар кебек, Кәрим Тинчурин да мәдрәсә тормышын, нигездә, тискәре яклары, кимчелекләре белән нисбәттә сурәтли. Автор үзе дә алты ел Казанның “Мөхәммәдия” мәдрәсәсендә белем алып, демократия җилләре исә башлагач, шәкертләр хәрәкәтенә кушылып, уку йортын ташлап чыгуын истә тотсак, биредә биографик моментлар, реаль яшәеш тасвирлануына шик тумый кебек. “Мәрҗәннәр” татар тормышында башланган уяну хәрәкәтен, мәгърифәткә һәм азатлыкка омтылган яшьләрнең үз чорыннан, байлардан, уку-укытудан канәгать булмавын әдәби сүзгә төреп бирү ягыннан да зур әһәмияткә ия. Ә менә “Утыз өч көн” дип аталган соңгы мәрҗәндәге Сөләйманның автор үзе булуына Б.Гыйззәт шик белдерә һәм моның өчен төп герой белән шул чордагы Тинчурин тормышын чагыштырып карарга тәкъдим итә. “Аклар Казанны басып алган чакта Сөләйман озак кына ике арада буталып йөри, аптыраштa кала һәм шактый күпне күргәннән соң гына дөрес юлга төшә... К.Тинчурин исә Октябрьне каршылаганда да, гражданнар сугышы чорында да һичбер икеләнмичә халык ягында була”, - дип яза ул [2, 505].

Биобиблиограф Рәис Даутов мәгълүматларына караганда, 1971 елгы Февраль инкыйлабыннан соң, Керенский хөкүмәте элек хәрби хезмәттән азат ителгәннәрне дә мобилизацияләү турында игълан итә. Шул вакытта заманында К.Тинчуринны үз труппасына алган Габдулла Кариев аңа янә булышырга алына һәм Мәскүдә яшәүче Г.Исхакыйга мөрәҗәгать итә. “Исхакый, ярдәм кулы сузып, К.Тинчуринны үз мөхәррирлегендә чыгып килгән “Ил” газетасы редакциясенә әдәби хезмәткәр итеп эшкә ала” [3, 33]. Әлбәттә, Исхакый кадәр Исхакыйның йогынтысы, тәэсире Тинчуринга тими калмагандыр. Мәгълүм ки, инкыйлаб

булгач та, иске тәртипләргә каршы чыккан, яңалык тарафдарлары буларак чыгыш ясаган күп кенә татар зыялысы каушап кала, кайсы якка кушылырга аптырап, төрле юл сайлый, язмышлары да төрлечә корыла.

“Утыз өч көн” бүлегендә вакыйгалар 1918 елның җәендә бара. Биредә гражданнар сугышы чоры, чехлар Казанны алгач, татар байларының алар ягына авышулары, советларга каршы көрәшүләре, татар зыяласы, журналист һәм яшь язучы Сөләйманның, ике арада калып, аптырап йөрүе, тирән кичерешләрдән соң кызылларга килеп кушылуы гәүдәләнә. Бу бүлектә автор психологизм остасы буларак ачыла: Сөләйман акылы белән яңа хакимият ягында, ләкин ул билгеле бер киртәне һаман узып чыга алмый, үз-үзе белән тарткалаша, инде кызылларга кушылдым дигәндә генә, янә фикереннән кайта, нидер комачаулый, тагын үз эчендә көрәш башлана. Язучы тагын күсе образына мөрәҗәгать итә: Сөләйман аптырап йөргән чагында, бик матур төш күреп ята, ләкин бер күсе аның бармагын тешләп уята. Биредә күсе вакыйгасы, беренчедән, төп геройның куркаклыгын, икенчедән, көчсезлеген күрсәтә (янәсе, хәтта күсе дә тешли ала).

Язганнарның күбесен Тинчурин үзе күргән, ишетеп белгән, шуларның тере шаһиты булган. Әсәр кысаларында Г.Камал, Х.Ямашев, Й.Акчура һәм башка тарихи шәхесләрнең исемнәре аталуы да “Мәрҗәннәр”нең реаль җирлеккә корылуын дәлилли. Документаль төгәллек һәм югары сәнгатьлелек белән язылганлыктан, әсәр татар укучысында зур кызыкыну уятырга сәләтле. Ф.Мусин язганча, “Тарихилык принцибы язучы иҗатында автор хыялы белән документализмның үзара тыгыз бәйләнештә булуларын, бер-берсенә булышуларын таләп итә. Шунлыктан иҗат процессында һич тә аларның берсенә генә өстенлек бирергә ярамый” [6, 9]). Геройларның язмышы да автор теләге белән генә түгел, тормыш кануннары белән хәл ителә. Гомумән, 1920-30 елларда әдипләр, телиләрме-юкмы, чишеләсе проблемаларны партиялелек, сыйнфыйлык принципларыннан чыгып яктыртырга мәҗбүр булалар. Ниһаять, Сөләйман да озак тарткалашудан соң совет иленә хезмәт итә башлый, “Эш” газетасында үз урынын таба. “Көннәр, атналар үткән саен Сөләйманның редакциядәге һәм матур әдәбият өлкәсендәге

уңышлары арта бардылар. Көннәр, атналар үткән саен аның язу өстәлендә Карл Маркс, Ленин китаплары күбәйгәннән-күбәя барды" - әсәр шул сүзләр белән романтик сурәттә тәмамлана.

Әдәбият

1. Бәшәр Ф. Контрастлар художнигы / Ф.Бәшәр // Сөйлә, каләм! – Казан: Татар.кит.нәшр., 2001. – Б.66-71.
2. Гыйззәт Б. Кәрим Тинчурин хикәяләре / Б.Гыйззәт // Тинчурин К. Сайланма әсәрләр. 3 томда, т.3. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1987. – Б.500-505.
3. Даутов Р. Драматург һәм артист / Р.Даутов // Мирас. – 2002. - №9. – Б.33-35.
4. Ишморат Р. Мәрҗәннәр турында берничә сүз / Р.Ишморат // Тинчурин К. Мәрҗәннәр. – Б.3-4.
5. Кәримуллин Ә. Кәрим Тинчурин хикәяләре / Ә.Кәримуллин // Тинчурин К. Сайланма хикәяләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1967. – Б.3-5.
6. Мусин Ф. Чор белән аваздаш / Ф.Мусин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1983. – 256 б.

Садыкова Л.Р.

Глагольное словообразование в трудах Шигапа Рамазанова

Рамазанов Шигап Галимович – ученый–лингвист начала XX века, внесший весомый вклад в развитие татарского языкознания. Научные изыскания его относятся в такие области как: татарская лексикология, фразеология, история татарского литературного языка, терминология, методика преподавания и др.

В статьях, посвященных научному наследию Ш.Рамазанова, изданных после великой октябрьской революции, отмечается, что им было создано более 60 его работ. Но, к сожалению, только часть его трудов изданы на сегодняшний день. Более доступным на сегодняшний день является монографический труд Ш.Рамазанова «Татар теле буенча очерклар» («Очерки по татарскому языку»),

В данной нашей статье объектом внимания является его статья "Татар телендә фигыль ясалышы", научное значение которой трудно переоценить и с точки зрения сегодняшней лингвистической науки. Одной из областей языкознания, в которой Ш.Рамазанова можно назвать первооткрывателем, является словообразование, особенно глагольное словообразование.

В грамматике Г.Алпарова, к примеру, дано 15 видов глаголообразующих аффиксов от других частей речи. Это такие как: ***–ла/-лә*** (эшлә, уйла), ***-та/-тә, -да/-дә, -за/-зә, -да/-дә*** (шыкырда), ***-лда/-лдә*** (безелдә), (данный аффикс также произносится в виде ***–алла/-əллə*** - *Г.А.*: шакылла, кимеллә)), ***-ыра/-ерә*** (шалтыра), ***-дыра/-дерә*** (кылтыра), ***-ай/-әй*** (күбәй, саргай), ***-ә/-а*** (кана, аша, яшә), ***-ар/әр*** (күгәр, кызар, кыскар), ***-к/-ķ*** (ялык, тарак), ***-ы*** (ныгы, байы).**[1, С.12]** Однако здесь, как видно, рассматриваются только продуктивные и самые живые формы глаголообразующих аффиксов.

Ш.Рамазанов впервые в татарском языкознании подробно исследовал словообразование глаголов не только в современном их состоянии и на «мертвые формы».

Данная статья Ш.Рамазанова сама состоит из нескольких подразделов. Сначала автор обращается к истории изучения словообразования, и в подразделе "Степень изучения глаголообразования" он описывает когда, кем и какие научные труды, касающиеся данной темы, были изданы.

В следующем подразделе "Корневые и производные глаголы" Ш.Рамазанов выделяет 3 типа глагольных основ. Здесь же, приступая к анализу словообразования глаголов, ученый обращает внимание на то, что в языке наряду с производными глаголами с прозрачной структурой, где четко выделяется основа и словообразующий аффикс: *уйла, җайла, йокла,* представлены не в малом количестве глаголы, возникшие путем опрощения корней типа *өйрән, тырыш, йөгер,* где в историческом плане также присутствуют словообразующие аффиксы, и указывает, что в методическом аспекте их также нужно изучить. Далее в подразделе "Глаголообразующие аффиксы" рассматриваются более продуктивные аффиксы: ***-ла/-лә, -лаш/-ләш, -лан/-лән, -ылда/-елдә*** и др.

Как особые подразделы выделяются также: производные основы, возникшие на основе залоговых форм, типы фонетических изменений и типы фонетических изменений и фонетических вариантов аффиксов. Вкратце описывается также структура составных глаголов, образованных при помощи вспомогательных глаголов *ит, кыл* и др.

Ученый считает, что преобладающим среди односложных корней-основ являются глаголы типа *бел (знай), тор (стой), йөр (ходи)* и др, т.е. основы типа согласный-гласный-согласный (СГС). Они составляют 70-75% корневых глаголов. Что касается основ типа согласный-гласный (СГ), таких глаголов, как *ти (трогай), ки (одевай)*, ученый совершенно справедливо отмечает, что они восходят к древним видам СГС: *кег – кей - ки, тег - тей - ти, киг - ки, тиг- ти, эй, ыв.*

При исследовании древних корней Ш.Рамазанов обращает внимание и на синкретичные корни, где отмечает, что многие слова, как имена и глаголы, произошли от единого корня. В виде примеров он приводит такие слова, как: *күз-күр* (глаз-видеть), *куз* (утлы күмер–горящий уголь) – *кыз-кызу* (нагревайся-горячий), *сүз-сөй(лә)* (слово-говори), *үгез-үгер* (бык-мычи), *симез-симер* (толстый-потолстей), *кач-кич-күч* (прячься-пройди-перемещайся) и др.**[3,С.149]** По словам автора, сходство их произношений и значений между собой, бессомнения, доказывает об их происхождении от одного корня.

В тоже время, основное внимание обращено подробному описанию аффиксального образования глаголов, здесь приводится богатый набор глаголообразующих аффиксов. Автор, и живые, и архаические вместе, насчитывает их 120. Вспомним, что у Г.Алпарова их насчитывается всего 15.

Далее автором на основе богатого фактического материала подробно исследованы такие глаголообразующие аффиксы, как: ***ла-лә*** *(сула-дыши, тизлә-ускорь),* ***лаш-ләш*** *(иялəш-приспосабливайся, берләш-объединяйся),* ***лан-лән*** *(өйлән-женись, коралланн-вооружайся),* ***ай-әй (гай)*** *(зурай-увеличься, азай-уменьшиться),* ***ар-әр*** *(күгәр-поржавей, яшәр-помолодей),* ***а-ә*** *(сана-считай, уйна-играй),* ***ы-е*** *(ныгы-крепни, бае-разбоготей),* ***сын-сен*** *(кызыксын-интересуйся, кимсен-унижайся),* ***кар-кәр, гар-гәр*** *(башкар-исполни, коткар-спаси, искәр-устарей),* ***ра-рә***

(ыра-ерә) *(очра-встреться, күкрә-греми, чәчрә-брызьни, ялтыра-светись, шалтыра-греми),* ***ылда-елдә(*** *уфылда-вздыхай, чыңылда-звени, дерелдә-дрожи),* ***шы–ше****: кыршы, шыңшы, җепше),* ***чы-че*** *(тончы, манчы).,* ***кын-кен*** *(ашкын, очкын)*, ***шын-шен*** (*кипшен, тыкшын),* ***кын-кен*** *(ашкын, очкын)* и др.

Отсюда можно сделать вывод, что данное исследование Ш.Рамазанова внесло огромный вклад в дальнейшее изучение словообразования в татарском языке и произвел большой скачок в данной области татарского языкознания.

Литература

1. *Алпаров Г.* Шәкли нигездә татар грамматикасы/ *Г.Алпаров.* Казан, 1926. 196 б.
2. *Рамазанов Ш.Г.* Каюм Насыйри – татар әдәби теленә нигез салучы/*Ш.Рамазанов*//Татар теле буенча очерклар. Казан: Таткнигоиздат:, 1954. 200б.
3. *Рамазанов Ш.Г.* Татар телендә фигыль ясалышы/*Ш.Рамазанов*//Татар теле буенча очерклар. Казан: Таткнигоиздат:, 1954. 200б.
4. *Рамазанов Ш.Г.* Тукай һәм хәзерге татар әдәби теленең үсеше /*Ш.Рамазанов*//Татар теле буенча очерклар. Казан: Таткнигоиздат:, 1954. 200б.
5. *Фахрутдинова В.Р.* Словообразование татарского глагола в Историческом плане: дис. ... канд. филол. наук / *В.Р. Фахрутдинова*. К., 2007. 194 с.

Сайхунов М.Р.

Ритмическая структура татарской разговорной речи

Речь представляет квазинепрерывный процесс. Паузами различной длительности обозначаются границы предложений, фраз и речевых тактов. Речевые такты в литературе часто называют ритмическими группами. Ритмическая группа представляет интонационное и смысловое целое. В языках, где словесное ударение не выполняет смыслоразличительную, делимитативную и кульминативную функции ритмическая группа выполняет основную ритмообразующую роль.

В работе проводилось исследование просодической структуры ритмических групп и интонационной организации предложения. В произношении шести дикторов мужского пола более пятидесяти повествовательных предложений были введены в компьютер. С помощью программ акустического анализа речи были установлены границы ритмических групп, а также распределение длительности, основного тона и интенсивности в слогах, входящих в различные типы ритмических групп. По занимаемой позиции в предложении были выделены начальные, серединные и конечные ритмические группы.



Рис. 1(Длительность)



Рис. 2(Частота основного тона)

На рисунках 1 и 2 приведено распределение длительности, основного тона в ритмических группах повествовательного

предложения. Вертикальными линиями обозначены границы ритмических групп.

Как следует из рисунков, длительность последнего слога ритмической группы заметно возрастает. Мелодический контур повествовательного предложения является нисходящим. Вместе с тем в конце первой и второй ритмических групп основной тон несколько повышается, что в сочетании с увеличением длительности слогов на границах ритмических групп говорит о падении ритмического ударения на последний слог.

В настоящее время на основе экспериментальных данных создается компьютерная модель интонации повествовательного предложения татарской речи, которая проходит апробацию в «Синтезаторе татарской речи» (разрабатывается в СНИЛ ПИИ АН РТ и КГУ под руководством Т.И.Ибрагимова).

Сафиуллина Ф. С.

Татар телендә парлы сүзләр

Төрле телләрнең, шул исәптән татар теленең сүз ясалышында зур урынны парлы сүзләр алып тора. Алар күп гасырлар буе ясалып килгәннәр, ясау ысуллары да билгеле бер калыпларга салынганнар. Бу сүзләрнең ясалышында урынны түбәндәге калыплар билгелиләр: 1) ике компоненты бер үк яки якын мәгънәләрне белдерә: бала-чага, хатын-кыз; 2) икенче калып антонимик мөнәсәбәтләрдән гыйбәрәт булган компонентлардан оеша: кереп-чыгып йөрү, килделе киттеле, кичәле-бүгенле; 3) икенче компоненттагы сүз беренче компонентның кайтавазы буларак киләб ләштер-лөштер // лыштыр-лоштыр, лакыр-локыр, лагыр-логыр, ларт-лорт; 4) мәгънәсе инде югалган компонент икенче компонентта өлешчә кабатлана: ыбыр-чыбыр, шырдый-бырдый, шытыр-шатыр (килү), сыздый-боздый; 5) икенче компонент **ни** алмашлыгы килә. Монда ул сорау алмашлыгы мәгънәсендә түгел: суга-нигә (төшмәсен).

Еш кына **мазар** сүзе икенче компонентта килә һәм ниндидер билгесезрәк төшенчәне белдерә: грипп-мазар, гөнаһ-мазар, гаеп-мазар.

Нисез сүзе дә икенче компонентта шактый актив: акчасыз-нисез (чыгу), китапсыз-нисез (килү), эшсез-нисез (йөрү).

Ни тамырыннан булган сүзләр икенче компонентта киләләр: песи-ни, сөйләде ни – сөйләмәде ни һ. б.

Беренче компонентта **ике** тамыры да шактый актив. Ул төрле формаларда килергә мөмкин: икәүдә-икәү (калу), икегә-өчкә (яру), икедән-өчтән (тору), икеләтә-өчләтә (арттыру), икешәр-өчәр (китап бүләк итү) һ. б.

Өс компоненты беренче урында гаять актив: өс-аяк (киемнәре), өс-башы, өсләрен-аякларын (чишенү), өстән-аяктан, өстән-баштан, өстән-өстәнлек, өсте-башы (бай), өсте-өстенә (бирү), өстә-биектә, өсте-өстенә (бирү, алу), өстән-өстән (уку).

Беренче компоненты рус-европа телләреннән алынган парлы сүзләр дә шактый актив күзәтелә: палатка-кибет, партия-хөкүмәт (чаралары), партия-хуҗалык (активы), патриот-шагыйрь, патша-корольләр, пегас-айгыр, педагог-галим, пергамент-күн, пехота-фәлән, печән-бүрәнә, пионист-башкаручы, план-йөкләмәләр, пожар-фәлән, коммерция-нәшрият (комплексы), поп-җырчы, порт-шәһәрләр, похот-сугыш, поэзия-шигърият, поэма-шигырьләр, предприятие-оешма, проект-эзләү (эшләре), пролетар-сыйнфый, пробег-чыгыш.

Б хәрефенә башланган сүзләр арасында парлашып рус алынмалары сирәгрәк күренә: бульвар-скверлар, бизнес-план, биф-томат, блиц-турнир, биология-экология, вице-адмирал, вице-губернатор, вице-президент, вольт-ампер, вагон-ресторан, вальс-танго, герой-шагыйрь, герой-хикәяләүче, геолог-галим, герой-ана, генерал-лейтенант, генерал-полковник, Гитлер-югенд һ. б.

Икенче компонент булып татарча сүз килә: вагон-арба, врач-ришвәтче, виноград-йөзем, витамин-дарулар һ. б.

Л авазына башланган сүзләр татар телендә күп түгел. Күпчелек өлешен рус-европа алынмалары алып тора: либераль-демократик (партия); лейб-гвардия; лейб-медик; ленд-лиз; лирик-драматик (поэма); лекальче-слесарь; лирик-фәлсәфи; люкс-вагон, лозунг-плакатлар һ. б.

Совет чорында киң таралган рус-европа алынмалары парлы сүзләр составында да күп күзәтеләләр. Күбесенчә бу алынмалар турыдан-туры калькалаштыру нигезендә телебезгә килеп

керәләр: спорт-сәламәтләндерү лагеры-спортивно-оздоровительный лагер, спорт-савыктыру төрләре-спортивно-оздоровительные виды, саквояж-сумка, сихер-магия, костюм-күлмәк, кулъязма-папкалар, Ленино-Кокушкино, Ленинград-Москва, ленин-Сталин (юлы, партиясе), лингвистик-чагыштырма, материал-документлар, лирик-фәлсәфи, лирик-эмоциональ, лирик-эпик, лозунг-плакатлар һ. б.

Ике компоненты да рус-европа сүзләреннән гыйбәрәт була: костюм-галстук, либерал-документлар, лирик-фәлсәфи, лирик-эмоциональ, лирик-эпик, лозунг-плакатлар... Бу төрдә рус сыйфаты лирический - лирик формасына, лирик-эмоциональ сүзендәге ике компонент та лирик-эмоциональнең формаларыннан үзгәрә.

Парлы сүзләрнең икесе дә гарәп-фарсы сүзләреннән булырга мөмкин: әхлак-холык, әхлакый-вәгазьче, гомер-бакый, гореф-гадәт, гомум-иҗтимагый (эш), госел-гамь һ. б.

Гарәп-фарсы сүзләре синонимнар булып киләләр: гашыйк-мәгъшүк, галим-голәмә, гадәт-йола, гасыр-дәверләр, гаеп-гөнаһлар.

Икенче компонент сүзләр составында **мазар** компоненты килә: гаеп-мазар, гөнаһ-мазар, грипп-мазар, эш-мазар, яңгыр-мазар.

Д хәрефенә башланган **дус** сүзе (тамыры) беренче компонент буларак гаять актив: дус-иш, дус-дошман, дус-иптәш, дус-кардәш, дус-кордаш, дуслар-ахирәтләр, дуслар-танышлар, дуслык-иптәшлек, дуслык-татулык, дус-тату.

Г хәрефеннән башланган гарәп-фарсы сүзләре гаять күп күзәтеләләр: гомер-бакый, гомер-гомергә, гореф-гадәтләр, голәмә-шәкерт, гомум-иҗтимагый (эш), горур-һавалы, госел-гамь, икәүдә-икәү (калу), икегә-өчкә (яру), икедән-өчтән (тору), икеләтә-өчләтә (арттыру), икешәр-өчәр (китап бүләк итү) һ. б.

Телебездә **д** хәрефе сүз башында актив түгел икән. Бу сүзләргә дер-дер (килү), де-факто, де-юре, сүзләрен әйтергә мөмкин. Парлы сүзләрнең беренче компоненты **дус** сүзе гаять актив икәнлеге ачыкланды: дус-дошман, дус-иптәш, дус-иш, дус-кардәш, дус-кордаш, дуслар-ахирәтләр, дуслар-танышлар, дуслык-иптәшлек, дуслык-татулык, дус-тату.

Еш кына **тирә** сүзе кулланыла. Шунысы кызык: бу сүз беренче булып та, икенче булып та килә ала: тирә-күрше // күрше-тирә, әйләнә-тирә // тирә-әйләнә, ызгыш-талаш // талаш-ызгыш һ. б. Күптәннән бирле **хатын-кыз** парлы сүзе **кыз-хатын** рәвешендә дә кулланылышта йөри.

Өмет-ышаныч // ышаныч-өмет, шат-бәхетле // бәхетле-шат, акыллы-матур // матур-акыллы, бүген-иртәгә // иртәгә-бүген, таныш-белеш // белеш-таныш, кичәле-бүгенле // бүгенле-кичәле.

Рус телендә соединительный авазлар белән бәйләнешкә кергән ике сүз татар телендәпарлы сүз барлыкка китерә: спорт-сәламәтләндерү лагеры-спортивно-оздоровительный лагер, спорт-савыктыру төрләре-спортивно-оздоровительные виды, лирико-эпический-лирик-эпик һ. б.

Парлы сүзләр **мазар, фәлән, нитми** компонентлары белән шактый күп кулланылалар: бүре-мазар, бүре-фәлән, борчу-фәлән, бумази-мазар, бишмәт-мазар, бирми-нитми, борчылганда-ниткәндә, банк-фәлән, бармалей-фәлән, банкет-фәлән һ. б.

Беренче компонент төрле формадагы **бала** сүзе белән килә: балалар-оныклар, бала-чага, бала-чагалы, бала-чагасыз, бала-чукча, балалар-өлкәннәр, балам-бәгърем.

Баш сүзе дә беренче компонентта зур активлык күрсәтә: баш-аягы (сау), баш-аяк (яту), баш-баштан, баш-башы (башлары), башын-күзен (әйләндерү, тондыру), баш-күз (әйләнү; тону), башы-актыгы, башы-ахыры (күренми), башы-аягы белән йолкып алу, кашын-күзен (җимерү) һ. б.

Ил сүзенең парлы сүзләрдә актив булуы гаҗәп түгел. Бу сүз төрле формаларда һәм беренче позициядә килә: ил-ана, ил-анакай, ил-базар, ил-ватан, ил-дәүләт, ил-җирләр, ил-көн, ил-республика, ил-күз, ил-көндәге, илләр-җилләр, ил-өй, ил-халыклар, илләр-халыклар, илле-җирлеләр, илсез-җирсез, ил-халык, ил-шәһәрләр, ил-ыру, илдән-илгә, ил-дәүләт, ил-җыр, ил-йорт, ил-капка, ил-корт.

Еш кына парлы сүзләрнең беренче компоненты булып **Идел** сүзе килә: Идел-дәрья, Идел-Дон (арасы), Идел-Дунай (арасы), Идел-елга, Идел-йорт, Идел-Кама, Идел-Урал (җирләре), Идел-Урал (халкы), Идел-Чулман (төбәге), Идел-яр.

Парлы сүзләр үрнәгендә сирәк кенә 3 компонентлы сүзләр дә ясала, мәсәлән: бозлы-яңгырлы-карлы (көн).

Сәлахова Э.К.

Хәйрияче Хәкимовлар

Татар җәмгыяте XIX йөз ахыры-XX йөз башында әлегә кадәр күрелмәгән зур үсеш кичерә. Бу яңарыш, алгарышны һәрбер өлкәдә күрергә мөмкин. Әлбәттә инде, бу күтәрелешнең матди нигезен тәэмин иткән татар хәйриячеләренең эшчәнлеге билгеләми мөмкин түгел. Алар бу чорда, бәхеткә каршы, аз булмыйлар. Аларның шактые турында матбугатта тәфсилле генә мәкаләләр дә дөнья күрде, ләкин кайберләренең игътибарга лаеклы эшчәнлеге бераз читтәрәк кала бирә. Шундый хөрмәткә лаеклы затлардан, һичшиксез, Хәкимовларны атау кирәк.

Нәсел шәҗәрәсе данлыклы Түнтәр авылын (Балтач районы) нигезләүчеләр – Янгол бабаның алты баласының берсе Үркәчегә барып тоташкан Габделхәким абзый нәселе вәкилләре татарның хәйриячелек тарихында тирән эз калдыралар. [Әхмәтҗанов М. Татар шәҗәрәләре. –Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 109-110.] Бөгелмә шәһәренең символы, хәзерге вакытта милли-мәдәни үзәк бинаның хуҗасы Шакир Хәкимов аны 1905 елда төзетә. Габделшакир Габделлатыйф улы Хәкимов элеккеге Вятка губернасы Малмыж өязе Түнтәр авылында 1869 елның 19 ноябрендә дөньяга килә. [ТР МА. 4 ф., 9 өст.тасв., 60 сакл. бер., 62 кгз.] Санкт-Петербургтагы Көнчыгышны өйрәнү институты архивында сакланучы Янгол шәҗәрәсе Габделшакир Хәкимовның әтисе Габделлатыйф Габделхәким улына кадәр булган Түнтәр авылы кешеләрне үз эченә ала. Габделхәкимнең әтисе Габделхак, аның әтисе Габделҗәлил, аның әтисе Габдесәлам, аның әтисе Колми, Колминың әтисе Үркәче, ә Үркәче исә Янгол баба улы.

Габделхәким абзыйның тугыз баласы туа, шуларның икесе – ир бала. Бу ике ир бала да шул заманың татар җәмгыятенә билгеле шәхесләр булып җитешәләр. Габделлатыйф Хәкимов –

Уфаның атаклы сәүдәгәре. Бу чор сәүдәгәрләре сату-алу гамәлләре белән генә чикләнеп калмыйча, кәсебләреннән килгән табышның бер өлешеннән мохтаҗларга да өлеш чыгарганнар, мәчет-мәдрәсә дә төзеткәннәр, гомумән, татар дөньясында барган бернәрсәгә битараф калмаганнар. Габделлатыйф әфәнде дә Уфа шәһәренең өченче мәчетен төзү эшенә үзеннән акчалата зур ярдәм күрсәтә, Уфа имамы Мөхәммәдсабир Хәсәневның "Вакыт" гәзитендәге 1906 елгы мәкаләсендә, шул чорның атаклы сәүдәгәрләре, эшкуарлары һәм гап-гади кешеләрнең мәчет төзелешенә матди ярдәм итүләре языла. Габделлатыйф Хәкимов мәчет түбәсе ябар өчен 600 сум акча һәм эш өчен кирәкле агач бирә, мичен чыгару өчен тотылган 100 сум чыгымны каплый, әле моңа да өстәп, 1000 сумлык ярдәм дә күрсәтә. Мәкаләдә китерелгән саннарга игътибар итсәк, бу мәчет төзелешенә иң зур хәйриялек күрсәткән кеше – сәүдәгәр Габделлатыйф әфәнде дип әйтә алабыз. [Имам Мөхәммәдсабир Хәсәнев. Уфа шәһәрендә 3 нче мәчет хакында // Вакыт. – 1906. – 7 октяб.] "Вакыт" гәзитенең 1906 ел, 7 октябрь санында Уфа шәһәрендә Хәкимов тарафыннан ният ителгән 5 нче мәчеткә 22 сентябрьдә иртәнге 9 да нигез ташы салынуы хәбәр ителә, бу тарихи вакыйгада казыйлар, ахундлар, мөдәррисләр һәм, хәтта, мөфти үзе дә катнаша. Мәчет салуга рөхсәт кәгазе алу бик авырлык белән бирелсә дә, уйлаган уйлар тормышка ашуына канәгатьлелек белдерелә. Бу хәерле эшкә фатиха биреп, Коръән укыла. Изге эшне башкаручы исеме белән Казандагы кебек "Фәләнев мәчете" дип аталырлык мәшһүр бер җәмигъ мәчетебез булачактыр, дип өмет баглана. Мәчет каршында мәктәп һәм мәдрәсә булдыру да күзалдында тотыла. [Уфадан // Вакыт. – 1906. – октяб.] Гаяз Исхакый Мәскәүдә чыккан "Сүз" гәзитендә түбәндәгеләрне яза: "Казан газеталары фәүкыльгадә [гадәттән тыш] бер зур милли хәбәр китерделәр. Уфаның һиммәтле байларыннан Габделлатыйф хаҗи Хәкимов Казандагы Харитонов матбагасын йөз меңгә сатып алып, шул матбаганы "Өмид" белән берләштереп, дини китаплар нәшер итәр өчен ширкәт мәйданга китергән. Габделлатыйф хаҗи Уфа җәмгыяте хәйриясенә күптән түгел генә йөз мең сум иганә иткән

заттыр. Габделлатыйф хаҗи Уфадагы үз мәхәлләсенең мәсҗеден, мәдрәсәсен бина иткән, бүгенге көндә үз хәрәҗаты [чыгымнары] берлән тәрбия итә торган заттыр". [Гаяз. Яшь күңелләрнең бурычы // Сүз. – 1916. – 14 авг.] Гаяз Исхакый Габделлатыйф Хәкимовның хәйриячелек эшен зурлап, олы яшьтәге хаҗиның эш-гамәлләрен яшь буынга үрнәк итеп, "Сүз" гәзитендә күләмле мәкалә белән чыгыш ясый. Ул Габделлатыйф хаҗиның милләт үсеше, аның киләчәге өчен беркайчан да акчасын кызганмавын, ә киресенчә, мулдан тотуын яза, шушы карт хаҗи акчасын начар гамәлдә кулланырга тырышучылар булуына рәнҗи. 1914 елда Габделлатыйф Хәкимов туган авылы Түнтәрдә икенче мәхәллә мәчете салдыра, аңа имам итеп Ишмөхәммәд бине Динмөхәммәд бине Мәхмүд әс-Сөневинең олы улы Мөхәммәднәкыйб билгеләнә. Бу мәчет бинасы 1944 елда Чепья район үзәгенә башкарма комитет бинасы итеп күчерелгән.

Түнтәр авылы тирә-якта үзенең сәүдәгәрләре белән генә түгел, ә традицион карашлы, җәдидчә укытуга каршы булган атаклы имамы Динмөхәммәд Ишмөхәммәд улы белән дә таныла. Шул чорда халык аны Ишми ишан, яисә камчылы ишан буларак белгән, аның образы Г.Тукай иҗатында да чагылыш тапкан. Габделлатыйф Хәкимов Ишми ишан белән яхшы мөнәсәбәттә торган, аның мәдрәсәсе өчен кирпеч бина да төзеткән. Ул авылның җәдидчә карашлы мулласы Мөхәммәтнәҗип бине Шәмсетдин бине Рәхмәтулла бине Мәхмүд бине Сөбханкол бине Рәхмәнкол Түнтәри үз язмасында болай дип яза: "Мулла булуым бик низагълы булып, бу эшкә Ишмөхәммәд мулла бар көче белән каршы торып, Габделлатыйф Хәкимов һәм авылның башка таза тормышлы вак сатучыларны үзенә ияртеп, безнең яктагы ярлылар белән хилаф бер оешма төзеп, ике елга якын низаг прошенияләре белән эше сузылып, инде эш булмый дип торганда, бәдбәхет указ дигән афәт килеп, зур мосыйбәт булды". [Мөхәммәднәҗиб хәзрәт язмасы // Эхо веков=Гасырлар авазы. – 2001. - № ½. – Б. 58.]

Татарның йөзек кашы булырлык асыл заты – Габделлатыйф әфәнде гаиләсе язмышында XX йөзнең 30 еллар караңгылыгы хәлиткеч роль уйный. Әлегә кадәр кулыбызда булган

документлар аның ачы язмышын ачыкларга мөмкинлек бирми. Алдагы тикшеренүләр нәтиҗәләр ачыклык кертер дигән өметтә калабыз.

Габделхәким абзыйның икенче улы Мөхәммәдгали туган авылы Түнтәрдә сәүдә эше, хәйриячелек белән шөгыльләнә. Ул, хәтта, беренче гильдияле сәүдәгәр булып җитешә.

Габделлатыйф Хәкимовның Мөхәммәдгариф, Бибигазизәбану, Шәрифәбану, Мөхәммәдзариф, Мөхәммәднәҗиб, Бибиәсма исемле балалары була. Мөхәммәдгариф, Мөхәммәдзариф, Бибиәсма балачакта ук фанидан бакыйга күчә. Әтисенең эшен ике улы – Мөхәммәдшакир белән Мөхәммәднәҗиб дәвам итәләр. 1868 елның 27 гыйнварында туган Мөхәммәднәҗиб Малмыжда сәүдә итә, ул да хәйриячелек эше белән шөгыльләнгән, әтисе салдырткан Уфа мәчетенә матди ярдәм күрсәтүе шул мәчет имамы Мөхәммәдсабир Хәсәневнең 1917 елны "Вакыт" гәзитендә чыккан мәкаләсендә әйтелә. Мөхәммәдшакир исә, эшен Бөгелмә шәһәрендә җәелдереп җибәрә. Мөхәммәдшакир исеме Бөгелмә төбәгендә хәзер дә билгеле, Бөгелмәдә "Хәкимов урманы", "Хәкимов күле" дигән урыннарның булуы ук халык аның исемен мәңгеләштергәнлеге хакында сөйли. Ул салдырган бинаны Бөгелмәлеләрнең милли-мәдәни үзәк итүләре бары тик хөрмәткә лаек. Безнең көннәргә кадәр сакланып калган документлардан Мөхәммәдшакир әфәнденең өч баласы хакында белә алабыз. Алар: 1901 елны туган Габдулла, 1905 елгы Фәйзерахман, 1912 елны дөньяга килгән кызы Асия, ләкин олы улы Габдулла 11 яшенә җитеп 1911 елда чахотка авыруыннан дөнья куя. [ТР МА. 4 ф., 177 тасв., 802 сакл. бер., 4 ф., 177 тасв., 936 сакл. бер., 26 кгз., 4 ф., 177 тасв., 1203 сакл. бер., 13 б кгз.]

Мөхәммәдшакир да, әтисе кебек үк, үзенең сәүдә кәсебеннән кергән мал исәбеннән мохтаҗларга ярдәм кулы сузган, Түнтәрдә мәдрәсә өчен мәйданы 140 кв. метр булган таш бина төзеткән.

[Мөхәммәднәҗиб хәзрәт язмасы // Гасырлар авазы=Эхо веков. – 2001. - № ½. – Б. 58.]

Мөхәммәдшакир Хәкимов XX йөз башында Россиядә барган вакыйгалар эчендә дә кайный, ул сәясәткә дә, татар милләтенең киләчәгенә дә битараф калмый, ә киресенчә, татарларны Россиянең югары идарә катламнарында да күрергә тели ул. 1906 елны Оренбургта чыгучы “Вакыт” гәзитендә Бөгелмәдән Дәүләт Думасына мөселман кешесе сайлана алмавына борчылу белдереп, киләчәктә, Думага сайлана алу өчен ниләр эшләргә икәнен киңәш итеп язган мәкаләсе басыла. “Мөселман халыкларына хәбәр биреп, сайлауларга катнашуларын вә файдалы кандидатларга тавыш бирүләрен үтенүне үземнең бурычым дия беләмен. Бәгъзе шәһәрләрдә, мәсәлән, Бөгелмә шәһәрендә мөселманнар бик аз торалар, ләкин моның өязендә мөселман бик күп. Бөтен халыкның файдасы өчен правосы булган җөмлә мөселманнар праволары илә файдаланырга вә сайлауларга катнашыр өчен шәһәргә килергә тиештер”, [Ш.Хәкимов. Бөгелмә өязе мөселманнарына // Вакыт. – 1906. – 21 нояб.], дип Дәүләт Думасына мөселманнарның да кереп, үз язмышларын хәл иткәндә үзләренең дә катнашулары мөһим икәнлеген билгели.

Татар дөньясының тоткасы булган асыл затларның язмышлары Россиядә 1917 елгы хәлләрдән соң төрлечә хәл ителә, әлбәттә инде, кызганыч вакыйгалар күзәтелә. Хәзергә кадәр кулыбызда булган мәгълүматлар Хәкимовлар язмышын теләгән кадәр үк төгәл ачыклау мөмкинлеге бирми, ләкин эзләнүләр дәвам итә.

Сәлимҗанова Ф.С.

Татарстан республикасының антропотопонимик системасы.

Татарстан республикасы антропотопонимнары дигәндә без, нигездә, республикабызның атамалары кеше исемнәренә, кушаматлар, отчество һәм фамилияләргә нигезләнеп ясалган торак пунктларны күздә тотабыз.

“Татарстан республикасы торак пунктлары” (Татар энциклопедиясе институты, Татарстан республикасы фәннәр академиясе, 1997) дигән белешмә мәгълүматларына таянып исәпләгәндә, республикабызда барлыгы 3206 торак пункт бар. (Искәрмә: әлеге белешмәнең 1966 елгы басмасында 3942 торак

пункт исәпләнә, димәк, 736 авыл 31ел эчендә юкка чыккан дигән сүз). Шуларның 1696сы антропонимик берәмлекләр белән бәйле, ягъни республикабыздагы торак пункт исемнәренең 50% ын антропотопонимнар тәшкил итә.

Галимнәр билгеләп үтүенчә, гомумән, төрки халыкларның топонимиясе антропотопонимнарның зур урын алуы белән характерлана. Торак пунктлар кеше көче, хезмәт җимеше буларак, бер урында яшәү өчен йортлар, төрле корылмалар салу нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр.

Аларның байтагына атама итеп, элек-электән, башлап нигез салучы кешенең исеме, шәхси яки нәсел кушаматы бирелгән. Менә шуңа, республикабыздагы күп кенә торак пунктларның исемнәрен тикшерү, аларның этимологиясен, төзелеш-ясалыш үзенчәлекләрен һәм тарихларын ачыклау өчен, беренче чиратта, татар антропонимиясенә хас булган закончалыкларны җентекләп өйрәнү зарури. Моннан тыш, антропотопонимнар хәзерге антропонимиядәге кулланылмый торган борынгы кеше исемнәрен, кушаматларны һәм фамилияләрне эзләп табарга, аларны реконструкцияләргә ярдәм итәләр.

Татарстан топонимиясенең хәзерге әдәби телебездә кулланылышта йөри торган кеше исемнәре белән мөнәсәбәтле булганнарын таный һәм аера белү кыен түгел. Мәсәлән, Айдар, Әмир, Колсәет, Тукай, Сулпан һ.б. кебек авыл атамаларының кеше исемнәреннән ясалган булуы һәркемгә мәгълүм. Әмма байтак кына авыл атамаларын кеше исемнәренә яки кушаматларга нигезләнеп ясалган булуын ачыклау һәм раслау өчен, тарихи-лингвистик яссылыкта аларны махсус анализлау таләп ителә. Бу төр атамаларны:

1) хәзерге татар телендә кулланылышта йөрми торган борынгы төрки-татар кеше исемнәреннән;
2) фонетик яки фонетик-морфологик үзгәрешләр кичергән исем вариантларыннан;
3) архаизмнарга, лексик диалектизмнарга һәм башка тел сүзләренә нисбәтле кушаматлардан яки кушамат исемнәрдән ясалган антропотопонимнарга аерып классификацияләргә мөмкин.

Әлеге мәкаләдә без фигыль нигезле борынгы төрки-татар кеше исемнәреннән ясалган кайбер антропотопонимнарга күзәтү ясарбыз.

Фигыль нигезле борынгы төрки кеше исемнәре үзләре ниндидер субъекттан, илаһи көчтән, алладан туачак яки әле яңа туган балага карата ата-ананың, аның кардәш-туганнарының төрле теләкләрен үтәвен, тормышка ашыруын сорауга яки бала тууны, аның төсен, килеш-килбәтен, холкын, ясаган хәрәкәтләрен һ.б. хәбәр итүгә, процессны белдерүгә мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгәннәр.

Бу төр авыл атамаларын, үз чиратында, берничә төркемгә аерып тикшерергә мөмкин.

Боерык-теләк тәгъбирлегендәге фигыльләргә нигезләнеп ясалган борынгы төрки-татар кеше исемнәре белән мөнәсәбәтле антропотопонимнарга күзәтү ясап китик.

Борынгы заманнарда төрки халыкларда гаиләдә озак вакыт бала булмый торса, тәңредән бала сорау йоласы булган. Бу йола "Бала келәве" дип аталган. Бала келәве келәү ("Теләү") йоласының бер төрен тәшкил иткән. Татар теле диалектларында, бигрәк тә көнбатыш диалект сөйләшендә, К~Т тартыклары тәңгәллеге хәзер дә чагылыш таба. Урта диалектта: теләү, теләнү, теләнче. Көнбатыш диалектта: келә, келәү, келәнү, келәнче һ.б.

Сөйләүченең бала тууга нисбәтле уй-теләкләрен чагылдырып, баланың исән, бәхетле, бай, матур һ.б. булуын теләү, үлемне туктатырга боеру кебек субъектив мөнәсәбәтләре боеру һәм теләк тәгъбирлегендәге фигыльләр ярдәмендә белдерелгән. Шушы җирлектә борынгы төрки телдә боеру һәм теләк тәгъбирлегендәге фигыль формаларына нигезләнеп кеше исемнәре барлыкка килгәннәр. Мәсәлән, Ишбул, Батырбул, Торсын, Иштуг, Салтуг һ.б.

Республикабызда боеру-теләк тәгъбирлегендәге фигыль формаларына нигезләнеп ясалган кеше исеме белән мөнәсәбәтле рәвештә берничә авыл атамасы бар.

Мәсәлән, Апас районындагы Янсурино авылы. Авыл халкы әлеге авыл атамасы Ян һәм Сурин дигән кешеләр исеменнән килеп чыккан диләр. Әмма бу авыл атамасы ике кеше исеменнән түгел, бәлки Янсорыйм дигән бер кеше исеменә генә нигезләнеп барлыкка килгән. Борын авазлары М белән Н ның чиратлашуы

һәм, О сузыгының У га күчүе нәтиҗәсендә, бу исем тора-бара Янсурин әйтелеше алган.

Республикабызның Кама Тамагы районында Олы Салтык һәм Кече Салтык, Кукмара районында Салтык-Ерыклы исемле татар авыллары бар. Салтык исеме сал+тык композитларыннан тора. Бу исемнең сал композиты борынгы төрки-сүзлектә бирелгән sal I сүзе белән мөнәсәбәтле дип саныйбыз. Анда бу сүзнең "плот из бурдюков" мәгънәсен белдерүе күрсәтелгән (Древнетюркский словарь, Л., 1969, 482 бит). Тире капчыкларга һава өреп тутырып ясалган саллар борынгы бабаларыбызга сулар, елгалар аша кичү өчен хезмәт иткәннәр. Мондый саллар бик таза һәм нык булганнар. Шушы сыйфатларга нигезләнеп, борынгы телдән сал сүзенең тазалык, ныклык төшенчәсен белдергән күчерелмә мәгънәсе барлыкка килгән.

Салтык исеменең икенче композиты тык борынгы төрки телдә "ту, барлыкка кил" мәгънәсен белдергән. Тоу (Древнетюркский словарь, 482) боерык фигыль белән мөнәсәбәтле. Димәк, Салтык атамасы "таза, нык булып ту" дигән мәгънәгә ия кеше исеме белән бәйле.

Безнең республикада, сирәк булса да, хәзерге заман хикәя фигыль формалы борынгы кеше исемнәре белән мөнәсәбәтле антропотопонимнар да очрый.

Мәсәлән, Яшел Үзән районындагы Югары һәм Түбән Урысбага авыллары атамасы.

Профессор Золотницкий Урысбага исемнең этимологиясен: "Ураз /чагтай, казан татарлары телендә - "бәхет", "язмыш" + "бакты" – "карады": Урызбакты "счастье взглянуло", - дип аңлата. (Н.И. Золотницкий. Приложения к корневому чувашско-русскому словарю, Казань, 1875, 248 бит).

Республикабызның Мамадыш районында Уразбакты исемле татар авылы бар. Алда карап үткән авыл атамасы "исем + хәзерге заман хикәя фигыль" моделена ия булса, соңгысы "исем + үткән заман хикәя фигыль" моделена төзеп, "бәхет карады" дигән мәгънә аңлата.

"Исем + III зат категорик үткән заман хикәя фигыль" моделендәге атамалар безнең республикада бик күп: Алабирде (Алла+бирде), Ямбакты (Җан+бакты) – Тәтеш районы; Янгелде

(Җан+килде) – Апас районы, Зур Тәрбит (Тәңре+бирде) – Кайбыч районы авыллары шундыйлардан.

Орым Тәрбите, Зур Тәрбит атамаларындагы тәрбит комонимы нигезендә Тәңребирде борынгы төрти-татар кеше исеменең халык телендә кулланылышка кертелгән, җайлаштырылган варианты ята дип әйтә алабыз. Әлеге фикерне Орым Тәрбите авылы янындагы иске зиратта язулы кабер ташлары сакланган булуы һәм шуларның берсе Тугаш улы Тәңребирде исеме һәм ташның 1550 елда язылган булуы турындагы мәгълүматалар да раслый. Әлеге авыл атамасының русча варианты (Тябердино) татарча вариантка караганда тулырак саклап калган.

“Исем + нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыль” төзелешенә ия авыл исемнәре дә очрый. Буа районы Янтуган авылы атамасында әлеге төзелеш ачык чагылыш тапкан.

Республикабызда теге яки бу фигыль формасына нигезләнеп ясалган атамаларның саны 100гә якын. Аларда чагылыш тапкан борынгы исемнәребез, әлбәттә, хәзер кулланнылмыйлар диярлек. Әмма аларның байтагы катлаулы фонетик үзгәрешләр кичергән хәлдә, авыл атамаларында, фамилияләрдә сакланып калганнар. Бу антропонимик берәмлекләрнең нигезен телә (келә), кара, бак, кил, тук/туг, ту, сора, сөй, үтә, сат, бир фигыльләре тәшкил итә. Шулар арасында иң еш кулланылышта кил/гил, туг/ту фигыльләре.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: кеше исемнәре белән бәйле авыл атамаларын тарихи-лингвистик яссылыкта өйрәнү бәхәсле һәм авыр эш, әмма гаять кызыклы һәм мавыктыргыч шөгыль. Алар туган як тарихы белән кызыксынучыларга, татар теле укытучыларына кызыклы өстәмә мәгълүмат чыганагы булып хезмәт итәләр.

Сибгаева Ф.Р.

Хәзерге татар әдәби телендә поэтик фразеологик антонимнарны өйрәнү мәсьәләсе

Фразеологик антонимия, башка лингвистик күренешләр кебек үк, мөһим тел күренешләренең берсе булып санала. Ул - чынбарлыкта яшәп килгән реаль каршылыкларны чагылдырган

мәгънәләр капма-каршылыгы. Фразеологиядә, аерым предметларны, табигать күренешләрен, әйләнә-тирәдәге чынбарлыкны аңлаткан, билгеле бер урын атамаларын, ялгызлык исемнәрне, термин характерындагы һәм төрле белем, производство тармакларын атаган фразеологик берәмлекләрнең антоним парлары була алмый. Әлеге фразеологизмнарның мәгънәләре икенче бер тотрыклы әйтелмәләр белән капма-каршы мөнәсәбәттә тора алмый. Ике фразеологик берәмлек арасында бер үк вакытта аермалык та, уртак билгеләр дә булса гына антонимия барлыкка килә ала. Димәк, бер үк грамматик төркемгә караган, лексик составы ягыннан өлешчә тәңгәл килгән яки тулысынча туры килмәгән, поляр мәгънәләр күзәтелгәндә һәм стилистик яктан аерыла яки туры килә торган уртак семантик компонентларга ия булган тотрыклы сүзтезмәләр фразеологик антонимнар дип атала [4: 5].

Г.Х.Ахунҗанов исә фразеологик антонимнарга түбәндәге билгеләмәне тәкъдим итә: «Мәгълүм булганча, антонимнар дип мәгънәләре ягыннан капма-каршы сүзләрне атыйлар. Лексикология белән идиоматика арасындагы аналогияне күздә тотып, мәгънәләре капма-каршы булган идиомаларны да антонимнар дип атый алабыз» [1: 76]. Кайбер рус теле дәреслекләрендә фразеологик антонимнарның ике үзенчәлекле билгесе генә күрсәтелә һәм мондый билгеләмә бирелә: «Фразеологик антонимнар -мәгънәләре ягыннан капма-каршы һәм төп семантик билгеләре ягыннан туры килгән фразеологизмнар ул» [8: 337]. Ә А.И. Молотковның «Рус теленең фразеологизмнары һәм аларның лексикографик тасвирламасының прнципларына» исемле мәкаләсендә төп өч үзенчәлек карала: «Капма-каршы лексик мәгънәгә, бертөсле компонентлы составка (бер компоненттан кала), бер үк лексик-грамматик характеристикага ия булган фразеологизмнар антонимнар дип атала» [6: 361].

Югарыда әйтелгәнчә, фразеологик антонимнар бер үк сүз төркеменә керергә тиеш. Ләкин бу мәсьәләгә икенче күзлектән карасак, әлеге шарт һәрвакытта да үтәлми. Мәсәлән, Е.Н. Миллер антонимияне ике зур төркемгә: бер сүз төркеменә кергән антонимия һәм төрле сүз төркемнәренә караган антонимиягә бүлә [5: 60].

Шулай итеп, фразеологик антонимнарга түбәндәге универсаль билгеләмәне биреп була: фразеологик антонимнар дип, бер үк логик тәртипкә нигезләнгән күренешләрне белдерә торган, мәгънә ягыннан капма-каршы фразологик әйтелмәләрне атыйлар [5: 201].

Күпчелек филологлар хезмәтләрендә фразеологик антонимнарның антонимлык критерийларын билгеләп үтәләр. Бу критерийлар хакында фикер-карашлар төрлелеге күзәтелми, монда принципиаль аермалыклар да юк. Тел белемендә биш төрле антонимлык критерий бар: семантик; стилистик; ярашу (яки туры килү); структур; контексто логик [4: 7-8].

Әлеге критерийлар фразеологик антонимнарның төп сыйфатларын аерганда да чагылыш таба. С.Г. Васильеваның «Фразеологик антонимия эчендә татар-рус параллельләре» исемле хезмәтендә татар һәм рус телләре өчен уртак билгеләр карала [2: 8-10]. Е.Н. Миллер исә фразеологик антонимнарның үзенчәлекләрен лексик антонимнар белән чагыштырып өйрәнә [5: 132-137].

«Хәзерге рус теле» китабында әлеге төркемләү белән бергә башка төрле классификация дә күрсәтелә:

1) антонимнар арасында уртак бер нейтраль сүз яки кисәк куеп булса, алар контрар антонимнар санала;

2) нейтраль сүз куеп булмаса - контрадиктор (капма-каршы килә торган, яки комплементар) антонимнар;

3) капма-каршы, төрле яклы эш-хәлләр яки билгеләр белдерелсә, конверсив (векторлы) антонимнар [7: 71].

Е.Н. Миллер фразеологик антонимнарның берничә классификациясен күрсәтә. Галим аларны, беренчедән, ике төргә бүлә [5: 97-100]:

1) абсолют каршылыкны белдерә торган фразеологик антонимнар (алар үз чиратларында икегә аерыла: абсолют константа һәм абсолют динамикалы);

2) мөнәсәбәтле каршылыкны белдерә торган фразеологик антонимнар.

Шулай ук Е.Н. Миллер лексик составлары ягыннан фразеологик антонимнарны өч төргә бүлә: үзгә структуралы, уртак структуралы, үзгә-уртак структуралы [5: 102].

А.И. Алехина антонимлыкның белдерелүе ягыннан аларны ике төркемгә аера:

а) лексик үзгә структуралы фразеологик антонимнар;

ә) лексик уртак структуралы фразеологик антонимнар.

Лексик үзгә структуралы фразеологик антонимнарны тагын икегә бүлә: 1) лексик составында уртак компонентлар булган һәм 2) лексик составында уртак компонент табылмаган антонимнар [4: 93].

Татар телендә фразеологик антонимнарны өйрәнүгә һәм төркемләүгә иң беренчеләрдән Г.Х. Ахунҗанов нигез сала. «Лексик антонимнардан аермалы буларак, идиоматик антонимнар ике структур төргә аерылалар» [1: 76-77], - дип яза галим. Ул бу лингвистик күренешне икегә бүлә:

1) үзгә структуралы антонимнар;

2) уртак структуралы антонимнар.

Үзгә структуралы антонимнарның эчке формалары, образ структуралары үзгә, ә мәгънәләре капма-каршы була; мәсәлән: җилгә каршы бару - агым уңаена йөзү, таң ату - кояш баю, уртак тел табу - борчак пешмәү һ.б.

Уртак структуралы антонимнарның эчке формасы, образ структурасы уртак булып, алар лексик яки грамматик яисә лексик һәм грамматик составлары ягыннан гына өлешчә үзгә булалар, мәсәлән, җеп очын югалту - җеп очын табу, сөйкемле сөяк - сөйкемсез сөяк, җил каршы исү - җил уңай исү һ.б [1: 76-77].

Г.Б. Мәрдәнова Л.П. Зимина тәкъдим иткән классификацияне куллана. Ул югарыда бирелгән уртак структуралы (бер типтагы) һәм үзгә структуралы (төрле типтагы) фразеологик антонимнарга бүлә. Галимә күрсәтелгән төрләрнең бер-берсеннән аермалы якларын тикшерә [4: 11-15]. Беренче аермалы як - ул уртак структуралы фразеологик антонимнарның билгеле бер формаль күрсәткечләре ягыннан тышкы капма-каршылыкта булуы. Антонимлыкның формаль күрсәткечләре булып, лексик антонимнар да хезмәт итә:

а) фигыльләр: эздән чыгу - эзгә керү, тик яту - тик ятмау;

ә) сыйфатлар: салкын канлы - кызу канлы, туры юл - кыек юл, җанлы мал-җансыз мал;

б) исемнәр: йөз аклыгы - йөз каралыгы, гомернең көзе - гоернең язы;

в) рәвешләр: төтене кыек чыгу - төтене туры чыгу, җиңелгә килү – авырга килү;

г) саннар: беренче кулдан - икенче кулдан, бер яктан - икенче яктан, беренче скрипка уйнау - икенче скрипка уйнау.

Лексик антонимнар бер тамырлы (тәмле телле - тәмсез телле, тик яту - тик ятмау) һәм төрле тамырлы (күңелне тырнау - күңелне басу) сүзләр белән белдерелергә мөмкин.

Лексик антонимнардан кала антонимлыкның формаль күрсәткечләре булып -сыз/-сез, -лы/-ле сүз ясагыч кушымчалары тора ала: җанлы мал - җансыз мал, сөйкемле сөяк - сөйкемсез сөяк.

Нигез + «булу» фигыле моделе буенча төзелгән фразеологик берәмлекләр эш-хәлнең, хәрәкәтнең барлыкка килүен һәм юкка чыгуын аңлата: бар булу - юк булу, риза булу - каршы булу.

Татар теленең фигыльләрендәге -у/-ү, -мау/-мәү кушымчалары эшнең яки хәлнең барлыгын яки юклыгын белдерәләр. Әлеге кушымчалар бер үк фигыльнең нигезенә кушылып антонимик мәгънәләр барлыкка китерәләр: тын тарту - тын тартмау, тик яту - тик ятмау.

Күчемле һәм күчемсез фигыльләр дә төшем, кайтым, уртаклык һәм йөкләтү юнәлешләре белән капма-каршы мөнәсәбәткә керәләр. Шулай итеп, фразеологик берәмлек составында торган бу фигыльләр фразеологик антонимнарны барлыкка китерәләр, мәсәлән: сафура бураны кубу - сафура бураны куптару, утка басу - утка бастыру.

Уртак структуралы фразеологик антонимнарның икенче аермалы үзенчәлеге - ул аларның структур-грамматик һәм семантик-стилистик караш нокталары ягыннан бер типлы булуы.

Шулай итеп, уртак структуралы фразеологик антонимнар - ул капма-каршы мәгънәләргә, бер типтагы структур-грамматик һәм семантик-стилистик формага, үзләренең составларында антонимлыкның формаль күрсәткечләренә ия булган нигезләрендә бер үк образлар яктан ике фразеологик берәмлек.

Уртак структуралы фразеологик антонимнардан аермалы буларак, үзгә структуралылар ул - структурасы, компонентларның саны һәм составы ягыннан төрле булган һәм нигезендә төрле образлар яткан фразеологик әйтелмәләр, мәсәлән, күңел түзмәү - сабыр канаты булу.

Үзгә структуралы фразеологик антонимнар эчендә ике төркем аерыла. Беренчесенең лексик составында уртак компонентлар бар: йөрәккә ял булу - йөрәгенә түзә (чыдый) алмау. Икенче төркемгә лексик составында уртак компонент табылмаган, төрле лексик составка һәм төрле грамматик структурага ия булган, нигезендә төрле образлар яткан фразеологик антонимнар керә: майда йөзү - суган суы суыру.

Шулай итеп, үзгә структуралы фразеологик антонимнар дип капма-каршы мәгънәләреннән башка төрле типтагы структур-грамматик һәм семантик-стилистик формаларга ия фразеологик берәмлекләр атала.

З.С. Каримова мәгънә үзенчәлекләре һәм ясалышы буенча фразеологик антонимнарны түбәндәге төрләргә бүлә:

1) мәгънәләре капма-каршы булган төрле чыгышлы берәмлекләр;

2) фразеологик берәмлек составындагы сүзләрнең капма-каршы мәгънәдәге булулары аркасында ясалган антонимнар;

3) юклык аффикслары һәм юклыкны белдергән сүзләр ярдәмендә ясалган антонимнар [3: 287].

Әлеге мәкаләдә фразеологик антонимнарга билгеләмә бирү һәм аларны төркемләү мәсьәләсе карап үтелде. Түбәндә китерелгән классификация татар тел белемендә поэтик фразеологик антонимнарны төркемләү өчен иң кулае булыр дигән өметтә тәкъдим ителә:

1. Үзгә структуралы фразеологик антонимнар.
2. Уртак структуралы фразеологик антонимнар:

1) фразеологик берәмлек составындагы сүзләрнең капма-каршы мәгънәдә булулары белән бәйле барлыкка килгән антонимнар;

2) юклык аффикслары һәм юклыкны белдергән сүзләр ярдәмендә ясалган антонимнар;

3) фразеологик антонимнар составында фигыльләрнең төп һәм калган дүрт юнәлешләрнең берсе булган фразеологик антонимнар;

4) гади уртак структуралы фразеологик антонимнар югарыдагы төрләрнең берсенә дә кермәгән антонимнар.

Фразеологик антонимия хәзерге поэзиядә стилистик-сурәтләү чаралары арасында мөһим урын алып тора. Аларда югары дәрәҗәдәге эмоциональлек, экспрессивлык, стилистик бизәкләр һәм образлылык бик көчле. Фразеологик антонимнар вакыйга, күренешләрне контраст яки антонимик формада куеп сурәтләргә ярдәм итәләр һәм киләчәктә тирәнтен өйрәнүне таләп итәләр.

Әдәбият

1. Ахунҗанов Г.Х. Татар теленең идиомалары / Г.Х. Ахунҗанов. - Казан: Татар. кит. нэшр., 1972. - 119 б.
2. Васильева С.Г. Татарско-русские параллели в фразеологической антонимии: автореф. дис. ... канд. фил. наук /С.Г. Васильева. - Казань, 1987. – 18 с.
3. Каримова З.С. Аяз Гыйләҗев иҗатында фразеологик әйтелмәләрнең лексик-семантик үзенчәлеге / З.С.Каримова // Татар теле һәм әдәбиятының актуаль проблемалары. – Стәрлетамак, 2004. – Б. 282-288.
4. Марданова Г.Б. Сопоставительный анализ фразеологических антонимов в английском и татарском языках: дис. ... канд. фил. наук / Г.Б. Марданова. - Казань, 1998. - 228 с.
5. Миллер Е.Н. Природа лексической и фразеологической антонимии/- Саратов: Изд-во Саратовского ун-та, 1990. – 221 с.
6. Молотков А.И. Фразеологизмы русского языка и принципы их лексикографического описания//Современный русский язык: Лексикология. Фразеология. Лексикография: Хрестоматия и учебные задания /Сост. Л.А. Ивашко, И.СЛутовинова, Д.М. Поцепня, М.А. Тарасова, М.Ю. Жукова, Е.И. Зиновьева, М.А. Шахматова; отв. Ред. Д.М, Поцепня. - 2-е изд., перераб. И доп. - СПб.: Филологический факультет СПбГУ, 2002. - 361 с.
7. Современный русский язык: Учеб. для студ. вузов, обучающихся по спец. «Филология» / П.А. Лекант, Е.И. Диброва, Л.Л. Касаткин и др., 3-е изд-е. – Москва: Дрофа, 2002. – 375 с.

8. Фомина М.И. Современный русский язык. Лексикология. - Москва: Высш. шк., 1990. - 415 с.

Усманова Г.С.

А. Троянский сүзлегендә сүзләрнең кулланылыш сферасы ягыннан тасвирлануы

XIX гасырның беренче яртысында дөнья күргән татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр арасында А.Троянский сүзлеге зур урын алып тора. Әлеге сүзлек аның күпьеллык фәнни-педагогик эшчәнлеге нәтиҗәсе. Хезмәт – “Словарь татарского языка и некоторых употребительных в нем речений арабских и персидских, собранных трудами и тщанием учителя татарского языка в Казанской семинарии священника Александра Троянского и напечатанный с дозволения комиссии духовных училищ” дип атала. 1829 елның 31 декабрендә сүзлекне бастырырга рөхсәт бирелә. Беренче биттә мондый сүзләр бар: “По журналу Комиссии Духовных училищ 31 декабря 1829 года состоявшемуся, печатать дозволяется для употребления в подведомственных оной Комиссии учебных заведениях Казанской семинарии ректор, Архимандрит и кавалер Феофан”. А.Троянский хезмәтендә төрки халыкларның лексик байлыгы тупланган, сүзләрнең кулланылыш сферасы, диалекталь үзенчәлекләре мисаллар ярдәмендә яктыртылган.

Диалекталь лексика әдәби телебезнең баю чыганакларының берсе булып тора. Күп кенә диалектизмнар телебезнең бик борынгы чорын чагылдыралар һәм килеп чыгышы ягыннан теге яки бу төбәкләрдә генә сакланып калган гомумхалык теле сүзләре булып торалар [3, 91 б.].

Чәрәчә – крыльцо (т. 1, 463 б.), хәзерге телдә юк, ул бары урта диалектның минзәлә сөйләше Әгерҗе урынчылыгында гына сакланып калган һәм мунча өй алдын белдерә, диалектологик сүзлекләрдә теркәлмәгән. Бу бик борынгы сүз Мәхмүт Кашгарый сүзлегендә үк булган һәм өй алды мәгънәсен белдергән. Бу хакта М. Ногман болай дип яза: “Элек лампа урынына чыра яндырганнар. Алдан әзерләп куелган чыралар өй алдында сакланган. Шуннан өй алды – чырача дип аталган булырга

тиеш”. Диалекталь сүзләргә *күнә суы – ртуть* [т. 2, 188 б.], казан арты, тау ягы сөйләшләрендә тере көмеш [ТТДС, 285 б.]; *ләвәш – сладкий пирог* [т. 2, 202 б.], казан арты, каргалы сөйләшләрендә пирог [ТТДС, 293б.]; *бармакча – перчатки* [т. 1, 182 б.], *аран – едва* [т. 1, 20 б.], *жир алмасы – картофель* [т. 2, 291 б.], сергач, тау ягы керәшеннәре сөйләше [ТТДС, 8 б.]; *туна – драть, сдирать* [т. 2, 25 б.] – златоус сөйләше [ТТДС, 307 б.] кирә.

Югарыда китерелгән мисаллар татар теленең төрле диалектларында, сөйләшләрендә хәзер дә актив кулланыла. Мәсәлән, *ярка* – гәй татарлары, минзәлә сөйләшләрендә ярган агач [ТТДС, 167 б.], *күнә суы* – казан арты, тау ягы сөйләшләрендә терекөмеш [ТТДС, 285 б.], *максыма* – казан арты-лаеш, тау ягы сөйләшләрендә өйдә кайнатылган сыра [ТТДС, 298 б.] мәгънәсен белдерә.

Халык тормышындагы үзгәрешләр иң беренче чиратта телнең сүзлек составында чагылалар. Бер әйбер яки күренеш искереп юкка чыга икән, аларны белдергән сүзләр дә төшеп кала, аерым очракларда, әйбер яки күренеш үзе калса да, аны атаган сүз янына яңасы барлыкка килә [3.102 б.]. А.Троянский сүзлегендә хәзерге чорда телебездән төшеп калган, сакланмаган, югалган сүзләр дә бар. *Букча* – дәфтәр, китап һ.б. нәрсәләрне салып йөртә торган киндер яки күн сумка [т. 1, 221 б.], *ту* – знамя [т. 2, 379 б.], *багбан* – виноградарь [т. 1, 214 б.], *брадәр* – братъ [т. 1, 185 б.], *михманханә* – гостиница [т. 1, 240 б.], *боламык* - кисель из сваренной муки [т. 1, 233 б.], *яс* - траур [т. 2, 295 б.] *симәләк* – овчарка [т. 1, 586 б.], *ышык балык* - треска [т. 1, 42 б.], *урынсыз* - тайна, секрет [т. 1,103 б.], *тастымал* - салфетка [т. 2, 314 б.]. Соңгысы фарсыда дәсткул төшенчәсен белдерә. *Дастмал* - кульъяулык, кул сөрткече дигән сүз. Дастмалдан *тастымал* сүзе үзгәреп килеп чыккан. Боларның икесе дә 17 -18 гасырларда телдә параллель кулланылган, соңыннан тастымал сүзе активлашып, дастмалны кысрыклап чыгарган һәм А. Троянский сүзлегендә урын алган [4, 82 б.]. *Бикәч – невеста* [т. 1, 225 б.] сүзе буйга җиткән кызларны хөрмәтләп әйтелгән исем булган. Соңыннан инде яңа гына кияүгә чыккан кызны бикәч дип атый башлаганнар. XIX йөздә бикәч сүзе телдән төшә һәм аның урынына кәләш сүзе кулланыла башлый.

Аралашу процессында тел берәмлеге төрле үзгәрешләр кичерә. Сүзләрнең мәгънәсе киңәя, яки тарая, хәтта гомумән, үзгәрергә, икенче бер атамага күчәргә мөмкин.

Сүзлектәге кайбер сүзләрнең мәгънәләре үзгәргән. *Конфет* [т. 1, 243 б.] сүзе сүзлектә *хәлвә* дип бирелә. Хәзерге телдә хәлвә аерым бер ризык төрен генә белдерә, әлеге мәгънәдә бу сүз XIX гасырда чыккан башка сүзлекләрдә һәм үзөйрәткечләрдә дә очрый. *Күчән* [т. 2, 179 б.] сүзе сүзлектә *дверная петля* , хәзерге телдә *күчән* – кәбестә сабагын белдерә [ТТАС, т. 2, 317 б.], *чара* - нинди дә булса максатка ирешү өчен кулланыла торган эш, хәрәкәт [ТТАС, т. 3, 409 б.], А. Троянский сүзлегендә , *чара - воля, свобода* [т. 1, 460 б.], *юрга* - юргалап чаба торган ат мәгънәсендә йөри [ТТАС, т. 3, 614 б.], автор *юрга* сүзен иноходец дип бирә [т. 2, 291 б.], *чәберчек – синица* [т. 1, 426 б.] сүзендә дә мәгънә үзгәрү күзәтелә. Хәзерге татар телендә чәберчек “кош басып утырганда бала чыкмыйча бозылган йомырка” дигән мәгънәне белдерә [ТТАС, т. 3, 465 б.].

Сүзнең мәгънәсе киңәйгән, я булмаса чикләнә төшкән сүзләр: *Идел*- зур елга, река [т. 1, 146 б.] дип бирелгән, хәзерге көндә Идел Көнчыгыш Европада Каспий диңгезенә коя һәм Татарстан территориясе аркылы үтә торган зур елга исеме [ТТАС, т. 1, 362 б.], *шулпа* - ашның сыек өлеше, ит һ.б. белән пешкән сыеклык [ТТАС, т. 3, 521 б.], автор *шулпа* сүзен - суп уха, росоль мәгънәсендә бирә [т. 1, 598 б.]. Фарсыда *фута* – мунча кергәндә билгә бәйли торган материя. А.Троянский сүзлегендә *пута* – кушак [т. 1, 260 б.] сүзе теркәлгән. Фута сүзе безгә пута булып, башлангыч мәгънәсен үзгәртеп керә. Ул инде фарсыдагыча, мунчада гына билгә бәйли торган материалны түгел, гомумән, билбау төшенчәсен белдерә.

А. Троянский сүзлегендә пассив кулланыштагы сүзләр теркәлгән. *Кара тавык* – дрозд [т. 2, 77 б.], хәзерге көндә миләш чыпчыгы атамасы кулланыла [РТС, 143 б.], *каракош* – орел [т. 2, 77 б.], бу сүзнең кулланышы пассивлаша, хәзер исә бөркет дип бирелә [РТС, 354 б.].

Димәк, телнең кулланыш сферасына төрле факторлар тәэсир итә, иҗтимагый һәм телнең үз законнары әлеге җирлектә мөһим роль уйный. Әгәр халыклар арасында милләт,

сәясәт, икътисад һәм тел яссылыгында алмашыну дәвам итсә, телнең кулланыш даирәсе, һичшиксез, камилләшә барачак.

Әдәбият

1. Ногман М. XVII - XVIII йөзләрдәге русча-татарча сүзлекләр. - Казан: Казан университеты, 1969. - 208 б.
2. Сафиуллина Ф. С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология (югары уку йортлары студенлары өчен) - Казан: Хәтер нәшрияты, 1999. - 288 б.
3. Саттаров Г. Ф. Татар топонимиясе. - Казан: Казан университеты нәшрияты, - 1998. - 420 б.
4. Хаков В. У. Татар әдәби теле тарихы. - Казан: Казан университеты нәшрияты, 1993. - 322 б.
5. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. - Казан: Татарстан китап нәшрияты,1977 - 1981.
6.Кононов А. Н. Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов. - Москва: издательство «Наука», 1974. - 339 с.
7. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. 2 томда. - Казан: «Иман нәшрияты», 1993.
8. Татар теленең диалекталь сүзлеге/ төзүчеләр Ф. С. Баязитова, Д. Б. Рамазанова, З. Р. Садыйкова, Т. Х. Хәйретдинова. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1993. - 459 б.
9. Будагов Л. Сравнительный словарь турецко-татарских наречий, со включением употребительных слов арабских и персидских и с переводом на русский язык. СПб.: Тип. АН, 1869. Т.1. 810 с.; СПб.: Тип. АН, 1871. Т2. 415 с.

Фазуллина Л. Х.

Язучы-прозаик буларак Газиз Гобәйдуллин

ХХ йөз башы иҗтимагый, икътисади үзгәрешләр, социаль тетрәнүләр, мәдәни алгарыш дәвере буларак бәяләнә. Татар халкы уяну, кузгалу чорын кичерә. Беренче рус инкыйлабы кабызган милли азатлык идеалы татар милләтенең аңын били, эш-гамәлләренең максатын билгели, изелгән милләтләрнең рус

һәм дөнья мәдәнияте белән бәйләнешләре көчәюенә зур тарихи йогынты ясый. Шушы шартларда татар әдәбияты әлегәчә күрелмәгән темплар белән үсеп китә, үзенең алтын дәверен кичерә, Аурупа әдәбияты ирешкән казанышларны яулый.

Гасыр башы әдәбиятында метод, юнәлеш, агым һәм стиль үсеше катлаулы төс ала. Реакция елларында тәнкыйди реализм әдәбияты формалаша. Язучылар кешеләрдәге аерым кимчелекләрне тәнкыйтьләү белән генә чикләнмичә, изүгә корылган җәмгыятьнең асылын фаш итәләр. Әйтергә кирәк, татар реалистик прозасы зур тарихи юл уза. XIX гасырда барлыкка килгән прозаик жанрлар Беренче рус инкыйлабы чорында З.Хади, Ш.Мөхәммәтов, Ф.Әмирхан, Ш.Камал, Г.Ибраһимов иҗатларында тагы да камилләшә: шәхес җәмгыять, иҗтимагый тирәлек белән тыгыз бәйләнештә тасвирлана. Яңа революция күтәрелеше вакытында әдәбиятка М.Гали, Ф.Вәлиев, Ш.Әхмәдиев, С.Рахманколый, С.Җәләл, Г.Харис, Г.Сөнгати кебек яшь иҗат әһелләре килә. Алар арасында Газиз Гобәйдуллин (Г.Газиз) үзенчәлекле урын алып тора.

Галим, педагог, язучы, публицист Г.Газизнең тууына (1887—1938) 2004 елның 27 июнендә 120 ел тула. Әдип татар милләтенең фән һәм мәдәният үсешенә гаять бай фәнни өлеш кертә, кызыклы әдәби мирас калдыра. Аның 120 фәнни хезмәте, 40 тан артык әдәби әсәре булуы мәгълүм. Иҗат эшчәнлегенең эчтәлеге һәм сыйфат ягыннан иң уңдырышлы вакыты 1907—1933 елларга туры килә. Халкыбызның милли үзаңын күтәрүгә багышланган тарихи, сәяси, әдәби хезмәтләре галимнәр тарафыннан шактый өйрәнелгән булса да, җитди һәм юмористик хикәяләр авторы буларак Г.Газиз иҗаты тикшерелмәгән диярлек.

Язучы әдәбият мәйданында новелла һәм кыска хикәяләр остасы буларак танныла. Аның әсәрләре күләм ягыннан артык күп булмаса да, әдәбият үсешенә керткән өлеше, яктырткан проблемалары шул чор яшәеш-мохитендә актуальлеген югалтмый.

Г.Газиз тәнкыйди реализм кысаларында иҗат итә. Балачактан ул А.П.Чехов әсәрләре тәэсирендә, аларны укып укып үсә. Шуңар да, атаклы рус язучысының иҗаты аңа зур йогынты ясый: ул иҗатында чынбарлыкны, кешеләрне табигать күренешләрен, тормышны бизәмичә, җитешсезлекләренә күз йоммыйча, ничек

бар шулай чагылдырырга, кыска, гади һәм төгәл сурәтләргә омтыла.

Мирасының зур өлешен көлкеле “Хәкимә әби” (1915), “Вәсвәсә” (1915), “Форточкалы кәләпүш” (1917), “Әхмәт бай тәһарәте”(1922) һәм сатирик “Хатыным җәдит булды” (1913), “Чалбар” (1915), “Күмгән иде” (1921) новеллалары тәшкил итә. Шул чор татар прозасын өйрәнүче Ф.К.Бәширов фикеренчә, Г.Газиз әсәрләренә нечкә юмор, кызгану белән өретелгән көлке хас. Язучы төп сурәтләү объекты итеп “кечкенә кешеләрне” — вак мәшәкатьләре, ыгы-зыгылары белән үзләрен зур, җитди мәсьәләләрне хәл итүчеләр итеп фикерләүче типларны ала”[1;25].

Дөньяда рухи кыйммәтләрнең җуела баруы, кеше җанының матурлыгы, яхшылык белән явызлык, мәңгелек һәм фани дөнья турындагы уйланулары исә фәлсәфи рух белән язылган “Бер хыял” (1913), “Әкиятләрдән берсе” (1914), “Юлдаш эзләгәндә” (1916) әсәрләрендә чагылыш таба.

Реалистик иҗат методында язылган “Олугъ ләгънәт” (1917) хикәясендә автор XX йөз башы татар әдәбиятына хас шымчы-провокатор образын психологик төгәллек белән сурәтли.

Г.Газиз әсәрләренә, әзерлекле укучыны истә тотып язылган, нечкә юмор, үткен сатира, тирән психологизм хас. Чор сәясәтенә көрәшкә ул үзенең әсәрләре белән коралланган хәлдә чыга. Кызганычка каршы, тоталитар режим тегермәненә эләккән бу олы шәхес турында мәгълүмат безгә, демократия җилләре исеп, илдә үткәндә ирешелгән мирасны барлау мөмкинлеге тугач, 1957 еллардан соң гына килеп җитә.

Бүгенге көндә тарих һәм әдәбият галимнәре Г.Газиз калдырган бай хәзинәне татар халкына, киң җәмәгатьчелеккә җиткерү өстендә эшли. Аның хезмәтләре гарәп шрифтыннан кириллицага күчерелә, анализлана. Сезнең игътибарыгызга язучының беренче иҗат җимешен — “Чын төш” (“Марс уян!”) хикәясен тәкъдим итәбез.

“Чын төш” хикәясе 1907 елның 6 апрелендә “Казан мөхбире” газетасында дөнья күргән әсәренең безнең чорда басылганы юк иде. Рашат Гайнанов искәрткәнчә, әсәрдә “борынгы Рим мифларына аваздашлык бар һәм латин телендә “Mars viqilla!" гыйбарәсе кулланылган. Күрәсең, шул гыйбарә Г.Гобәйдуллин хәтерендә калган һәм ул Гали Рәхимгә язган бер хатында беренче

хикәясенең исемен “Марс уян!” дип күрсәткән. Әлеге ялгышлык Г.Газиз иҗатына багышланган хезмәтләрдә дә шулай кабатланып килә” [2;227].

“Чын төш” хикәясе символизм алымнарына таянып язылган. Әсәрнең үзәк каһарманнары автор үзе һәм Марс (тексттан аңлашылганча — сугышны гәүдәләндерүче мифик образ). Яшь егет газетадан солых турында язылган мәкаләне укыган хәлендә йокыга китә һәм төш күрә. Имеш, аның янына Марс килә. Ул егетнең күзләрен “ачмакчы” була: “Солых булмаячак, бу үзсүзле хөкүмәтләр, бу милләтләрне аеручы вә дошманлык салучы галимнәр, бер хөкүмәтне икенчесе илә котыртып сугыштыра торган мөхәррирләр бетмәенчә солых мөмкинме?”— ди. Әйе, чыннан да Марсның сүзләрендә ачы хакыйкать чагыла.

Язучы империалистик дәүләтләренең чын йөзен фаш итә. Бер яктан, алар 1907 елда Нидерландтагы Гаага шәһәрендә үткәрелгән конференциядә сугыш коралларын кыскарту “мәңгелек тынычлык” урнаштыру турында борчылгандай сөйлиләр, ә икенчедән, шунда ук, халыкка сиздермәскә тырышып, сугышка әзерләнәләр. Язучы сатира ярдәмендә дәүләт башлыкларыннан ачы итеп көлә, икейөзле фарисейларны көчле тәнкыйть сүзләре белән камчылый. Сугыш җир шарында гасырлар дәвамында дәвам итә. Кан кою, халыкларны юкка чыгару, вәхшилек, ерткычлык, кеше талау аша дәүләт казнасына, үз кесәләренә күпләп акча эшләү — ил ияләре тарафыннан башкарыла торган явыз сәясәт. Чыннан да, әсәрдә күтәрелгән проблема бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмаган. Әлбәттә, хәзерге күзлектән караганда, әдипнең камил әсәрләре белән чагыштырганда, гарәп-фарсы алынмаларын мул кулланган бу хикәянең өйрәнчек әсәр булуы сизелеп тора. Публицистик хөкем өстенлек итә. Шулай да биредә авторның эрудициясе, олы фикерне кыска мәйданга сыйдырырга омтылуы һәм вакыйга-хәлләргә үз шәхси бәясе сизелеп тора.

Чын төш

Караңгы март кичәсендә кәнәфидә гәзитә укып ята идем. Гәзитәдә бик дәртле вә шагыйранә язылган бер мәкалә бар иде. Мәкалә исә солых гомуми тугрысыныда булып, солых бәгъдәндә булачак көннәрне язган иде. Мин дә шуны укып, тирән, тәмле йокыга талдым.

Бер вакыт битемә төшкән гәзитәмнең җил илә хәрәкәтенә уянып киттем. Ни күз илә күрим: каршымда рума легионлары кыяфәтендә, кулында озын сөңге вә артында галәмәт буры белән “Марс” мәгъбүд һәйкәле тора. Йөрәгем чыга язып тибә башлады... Әмма һәйкәл бик һибәтел вә куркыныч иде! Күзләре миңа таба карыйлар иде. Берничә минут бер-беремезгә карашып торгач, бәгъдә күзләре тере инсанныкы кеби елтырый вә авызлары хәрәкәткә килә башлады. Кыскасы, һәйкәл терелде.

Минем йөрәгем тибүе үземә ишетелә иде... Ниһаять, Марс бер адәм миңа таба алга атлап, әмәранә: “Мә укы әле, шул гәзитәдәге шагыйранә язылган мәкаләне!”— диде.

Мин исә карышмый укырга тотындым. Мәхарбәнең зарарларын вә начарлыкларын бәян кылган җирләренә җитә идем... Ниһаять, “Марс мәгъбүд нә моннан ары ихтыяҗымыз төшмәячәк, бетсен мәхарбә!”— дип туктаган җиренә җитеп туктадым. Марс, сөңгесенә таянып, сүзгә башлады: “Әй, хыялый адәм угланнары! Мәхарбә вә хамиси Марсны сүгәсез, әмма үзеңезне аңламыйсыз! Янә дә солых гомуми конференцияләре җыярга юрыйсыз!

Әмма сез белмисез ки: мондый тормышта солых гомуми булмаячак. Бу үзсүзле хөкүмәтләр, бу милләтләрне аеручы вә дошманлык салучы галимнәр, вә бу үзләренең мәнфәгать хирыс короналы хөкүмәтләрне дума сугыш ачарга котырта торган байлар, вә бу сатылып бер хөкүмәтне икенчесенә илә котыртып сугыштыра торган мөхәррирләр бетмәенчә солых гомуми мөмкинме? Бу сәбәпләрдән тулае угылларым Румул белә Рим сугыштылар. Ниһаять, катил изелделәр.

Мин исә Марсның бу кадәр инсанлар әхвәленнән хәбәрдар булуына вә һич илә солых гомумигә бик ышанганыма, вә бик хушым киткәненә ачуым килеп хәлемне игътиразга тотындым: “Син алай дисең, әмма бит бүген, иртәгә конференция булачак?”— дидем дә, ачуымнан туктадым.

— Белдем, белдем, адәм угланнары шулай ышанган нәрсәләрен бер адәм гакесына исбат кылса, ачуланалар. Син дә шулай. Әмма мин ул, җингүар инсаннардан вәхши инсаннан мәркәб булган җәмгыятьләрдән ул эш булмас дим. Чөнки Ярин сугышырга хәзерләнгәннәр, вә сугыш аркасында нам-шөһрәт казанырга хәзерләнгәннәр. Ничек ихтимал бар миңа сөекле

фигыльләрен туктатсыннар, шуңа күрә дә хәзер янә бер гасырларга кадәр булсын сезгә хуҗа булган инсаннар миңа янә “Mars viqilla!”, диячәкләр. “Вә яшәсен сугыш!” Янә мин дөньяда бераз химая кылачакмын!..— дип бүлмә төтенләр илә тулып мәгъбүд гаеб булды. Мәгәр сөңге башында кунаклаган галәмәти ябалакның гына шомлы кычкыруы ишетелеп калды.

Иртәгесен ватылган һәм арыган килеш йокыдан уяндым. Төнлә илә булган вакыйга бар да төш икән!

мәгъбүд — гыйбадәт кылынган зат, табынила торган зат

бәгъдә — бәйлек, соң, соңра, аннан соң, аннары

рум — грек, византияле

мәхарбә — сугыш

хамиси — һәммәсе

катил — үтерелгән, һәлак ителгән

игътираз — бер фикер яки карарга каршы төшү, каршы сөйләү, кире кагу

гакес — капма-каршылык, киресе, кире як

мәркәб — өстенә атлатыла торган хайван, гомумән атланып яки утырып йөри торган нәрсә

Әдәбият

1. Бәширов Ф.К. XX йөз башы татар прозасы // Ф.К.Бәширов— Казан: Фикер, 2002.— 25 б.
2. Гайнанов Р. Хикәяче Г.Газиз һәм аның иҗаты // Р.Гайнанов Газиз Гобәйдуллин: Фәнни-биографик җыентык.— Казан: Рухият, 2002.— 227 б.

Фәтхуллова К.С.

Телара аралашу ысулы буларак тәрҗемә.

Галимнәр әйтүенчә, дөньяда 2500-5000 гә якын тел исәпләнә, чөнки кайбер телләр һәм диалектлар арасында аерма шартлы һәм шуңа күрә төгәл санны беркем дә билгели алмый. Алар арасында иң таралган телләр булып кытай, инглиз, һинд, урду, испан, рус, гарәп, япон, немец, француз телләре санала. Аларны *дөнья телләре* дип тә атыйлар. Халыкара оешмаларның, шул исәптән Берләшкән милләтләр оешмасының рәсми һәм эш телләре

буларак инглиз, кытай, гарәп, рус, испан һәм француз телләре кабул ителгән. Барлык утырышлар шушы телләрдә алып барыла, барлык рәсми кәгазьләр шушы телләргә тәрҗемә ителә.

Билгеле булганча, гасырлар дәверендә аерым бер телләр халыкара аралашу теле вазифасын үтәгән. Борынгы чорларда беренче шундый тел буларак грек теле кулланылган, ә урта гасырларда латин теле халыкара фән һәм дипломатия теленә әверелә. Гомумән, грек һәм латин телләре башка телләрнең үсешенә, шул исәптән тәрҗемәчелек эшчәнлегенә нык тәэсир итә. XVII гасырдан башлап француз теле киң кулланылышта була... Ә инде XX гасырның икенче яртысында инглиз теле төп аралашу чарасына әйләнә һәм бүгенге көндә әһәмияткә ия булган бөтен мәгълүмат инглиз теленә тәрҗемә ителә. Хәтта төрле халыклар да ана теленнән башка инглиз телен гамәли үзләштерүгә омтылалар, чөнки бу телне белү кешенең һөнәри мөмкинлекләрен бермә-бер арттыра [1].

Бүгенге көндә халыклар үзара тыгыз бәйләнештә яшиләр, бер-берсе белән хезмәттәшлек итәләр. Галимнәр фикеренчә, дөнья зур бер фәнни-икътисади комплексны хәтерләтә. Ел саен дистәләгән халыкара форумнар, симпозиумнар, фәнни-гамәли конференцияләр, дәүләтара очрашулар үткәрелә һәм аларда төрле милләт вәкилләре катнаша. Барлык чыгыш ясаучыларны бер үк мөһим мәсьәләләр борчыса да, алар үз фикерләрен бер-берсенә турыдан-туры җиткерә алмыйлар, чөнки төрле телләрдә сөйләшәләр. Шуңа күрә әлеге чараларны уңышлы оештыруга тәрҗемәчеләр дә зур өлеш кертә. Димәк, күптеллелек тәрҗемә мәсьәләләренә игътибарны тагын да арттыра.

Моннан тыш аерым бер илләрдә берничә дәүләт теле кабул ителгән. Мәсәлән, Канадада – инглиз һәм француз телләре, Бельгиядә - француз һәм нидерланд телләре, Перуда – испан һәм кечуа телләре, ә менә Швейцариядә исә 4 тел - немец, француз, итальян һәм ретороман телләре тигез хлкуклы дәүләт телләре буларак игълан ителгән. Мондый дәүләтләрдә тәрҗемә эшләренә һәм тәрҗемәчеләр әзерләүгә аерым игътибар бирелә. Республикабызда татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кую нәтиҗәсендә тәрҗемәгә бәйле мәсьәләләр тагын да актуальләште, чөнки ике дәүләт теле дә төрле өлкәләрдә кулланыла: идарә итү

һәм икътисад, техника һәм сәнәгать, хокук, сәнгать һәм әдәбият, туризм һәм күңел ачу һ.б.

Санап чыккан мисаллардан күренгәнчә, тәрҗемә - кеше эшчәнлегенең катлаулы һәм күпкырлы төре. Тәрҗемәдә төрле чорлар, мәдәният, әдәбият, гореф-гадәтләр һәм шәхесләр бәрелешә. Шуңа күрә тел белемендә әлеге күренешкә төрле билгеләмәләр бирелә. Тәрҗемә төшенчәсе ике мәгънәгә ия: *1) интеллектуаль эшчәнлек, ягъни процесс; 2) шушы процессның нәтиҗәсе, ягъни текст* [2]. Телара аралашу ысулы буларак тәрҗемә процессны да, аның нәтиҗәсен дә өйрәнә. Моннан тыш галимнәр, тәрҗемәгә билгеләмә биргәндә, төрле телләрдә сөйләшүче кешеләрнең аралашу үзенчәлекләрен, лингвистик һәм экстралингвистик факторларны да исәпкә алалар. Танылган тәрҗемә белгечләре тарафыннан тәкъдим ителгән кайбер билгеләмәләргә тукталып үтик.

1) **А.В.Федоров** әйтүенчә, “тәрҗемә - бер телдә әйтелгән фикерне икенче тел чаралары ярдәмендә төгәл һәм дөрес итеп белдерү”;

2) **А.Д.Швейцер** фикеренчә, “тәрҗемә - телара һәм мәдәниятара аралашу процессы, аның нәтиҗәсендә беренче телдәге текст анализлана һәм икенче телдәге текст (метатекст) төзелә”;

3) **Я.И.Рецкер** үз фикерен түбәндәгечә белдерә: “тәрҗемәченең бурычы – икенче тел чаралары ярдәмендә оригиналның эчтәлеген тулы һәм төгәл итеп бирә белү һәм шул ук вакытта аның стилистик һәм экспрессив үзенчәлекләрен саклап кала алу”;

4) **Л.С.Бархударов** тәрҗемәне телара трансформациянең билгеле бер төре дип атый.

5) **Р.К.Миньяр-Белоручев** раславынча: “тәрҗемә сөйләм эшчәнлегенең иң катлаулы тәрләренең берсе булып тора, чөнки ул аралашу компонентларын икегә арттыра. Ике чыганак, ике ситуация, ике сөйләм әсәре барлыкка килә. Бу яклары белән тәрҗемә сөйләм эшчәнлегенең башка төрләреннән аерылып тора.”

Китерелгән билгеләмәләргә нигезләнеп, тәрҗемәгә хас булган төп сыйфатларны аерып чыгарырга мөмкин: тәрҗемә - бер телдәге мәгълүматны икенче тел чаралары ярдәмендә белдерү;

телара һәм мәдәниятара аралашу процессы; ике телне кулланып аралашу; телара трансформация төре; сүз сәнгате төре [3] һ.б.

Тәрҗемә төрле шартларда башкарыла, тәрҗемәчеләр жанр һәм тема ягыннан төрле текстлар белән эш итәләр. Шулардан чыгып, тәрҗемә төрләренең ике төп классификациясе билгеләнә: *1) тәрҗемә ителә торган текстларның жанрлары белән бәйле төр; 2) тәрҗемә процессында тәрҗемәченең хәрәкәтләре һәм эш шартлары белән бәйле төр.*

Тәрҗемә төрләренең гомуми классификациясе түбәндәгечә аңлатыла.

1) Телара аралашу төрләре: гомуми тәрҗемә, машина тәрҗемәсе;

2) Телара аралашу формалары: язма тәрҗемә; телдән тәрҗемә (синхрон тәрҗемә, эзлекле тәрҗемә);

3) Телара аралашу жанрлары: иҗтимагый-публицистик әдәбият тәрҗемәсе; рәсми документлар һәм эш кәгазьләре тәрҗемәсе; фәнни-техник әдәбият тәрҗемәсе; матур әдәбият тәрҗемәсе (проза, шигърият, драматургия, фольклор).

Бүленештән күренгәнчә, тәрҗемә төрлөре, формалары һәм жанрлары бер-берсе белән тыгыз бәйләшештә тора, ләкин шул ук вакытта аларның һәрберсенә билгеле бер үзенчәлекләр хас. Кайбер галимнәр әлеге бүленешкә телдән тәрҗемәнең тагын ике формасын кертәләр: **берьяклы тәрҗемә һәм икеяклы тәрҗемә.** Аерым бер фәнни хезмәтләрдә исә әлеге классификация гомумиләштереп бирелә. Мәсәлән, Р.К.Миньяр–Белоручев тарафыннан тәкъдим ителгән классификацияне карап үтик.

1) тәрҗемә механизмына бәйле рәвештә: машина тәрҗемәсе, кеше тарафыннан башкарылган тәрҗемә;

2) тәрҗемә шартларына бәйле рәвештә: язма тәрҗемә, телдән тәрҗемә;

3) текстларның жарларына бәйле рәвештә: әдәби тәрҗемә, махсус тәрҗемә [4].

Болардан тыш Л.С.Бархударов язма һәм телдән тәрҗемәнең тагын берничә төркемчәсен аерып чыгара: **язма-язма тәрҗемә; телдән-телдән тәрҗемә; язма-телдән тәрҗемә; телдән-язма тәрҗемә**.

Язма һәм телдән тәрҗемә арасындагы төп аермалар түбәндәгечә билгелиләр:

1) Язма тәрҗемә барышында тәрҗемәченең вакыты чикләнмәгән, ул тәрҗемә ителгән өзеккә кире әйләнеп кайта ала. Телдән тәрҗемә барышында тәрҗемәченең хәрәкәтләре оратор сөйләменә бәйле, тәрҗемә сөйләм белән параллель рәвештә алып барыла.

2) Язма тәрҗемә барышында тәрҗемәче тулы текст белән эш итә, ә телдән тәрҗемә иткәндә, ул бөтен текстның эчтәлеген анализлый алмый, бары тик аерым җөмләләрне яки абзацларны гына бер-бер артлы тәрҗемә итеп бара.

3) Тәрҗемәнең әлеге ике төре телара аралашуда катнашучыларның үзара бәйләнеше ягыннан да аерылып тора. Язма тәрҗемә барышында тәрҗемәче оригиналның авторы белән аралашмый. Телдән тәрҗемә барышында тәрҗемәче аралашуда катнашучылар белән турыдан-туры элемтәдә тора һәм алар белән кире бәйләнеш булдыра.

4) Язма тәрҗемә вакытында тәрҗемә берьяклы гына була, ә телдән тәрҗемә берьяклы да, икеяклы да булырга мөмкин [2].

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: кеше эшчәнлегенең бер төре булган тәрҗемә өлкәсендә эзләнүләр, тикшеренүләр алып бару, телара аралашу ысулы буларак тәрҗемә төрләрен һәм аларның үзенчәлекләрен өйрәнү зур әһәмияткә ия. Терҗемә процессы ничек оештырылырга тиеш? Яхшы тәрҗемәче булу өчен, нинди белем һәм күнекмәләргә ия булырга кирәк? Тәрҗемәчелек компетенциясе нидән гыйбарәт? Әлеге сорауларга җавап бирү максатыннан, һәр галим үз фикерләрен дәлилләп белдерә һәм моңа бәйле рәвештә тәрҗемә теориясе һәм өйрәтү методикасы тагын да камилләшә, тагын да үсеш ала.

Хәзерге чорда тәрҗемәгә өйрәтүнең **төп** максаты – ике телдәге лингвистик аермаларны билгеләү белән чикләнмичә, тәрҗемәчедә кирәкле күнекмәләр булдыру һәм аның һөнәри осталыгын арттыру мәсьәләләрен яктырту. Әлеге максатка ирешү өчен, түбәндәге **бурычларны** хәл итү сорала: тәрҗемәне лингвометодик тикшеренү объекты буларак билгеләү; тәрҗемәчелек эшчәнлеге төрләренең классификациясен булдыру; тәрҗемәчелек эшчәнлегенең нигезен тәшкил иткән закончылыкларны һәм үзенчәлекләрне аерып күрсәтү; "тәрҗемә нормасы" дигән төшенчәне төгәл билгеләү һәм тәрҗемә

сыйфатын бәяләү принципларын ачыклау. Димәк, тәрҗемә теориясе һәм практикасы өлкәсендә хәл ителәсе мәсьәләләр шактый күп әле.

Әдәбият

1. Гарбовский Н.К. Теория перевода: Учебник / Н.К.Гарбовский. – М.: Изд.МГУ, 2004.
2. Комиссаров В.Н. Современное переводоведение: Курс лекций /В.Н.Комиссаров. – М.: ЭТС, 2002.
3. Латышев Л.К. Перевод: проблемы теории, практики и методики преподавания./Л.К.Латышев. –М.: Просвещение, 1988.
4. Миньяр–Белоручев Р.К. Последовательный перевод. Теория и методика обучения. / Р.К. Миьняр –Белоручев. – М.: Воениздат, 1969.

Хаков В.Х.

Татар әдәби теле тарихында хәл ителәсе кайбер мәсьәләләр

Татар тел белеменең мөстәкыйль бер тармагы буларак, татар әдәби теле тарихы фәне XX гасырның икенче яртысында формалашып җитә. Ул лингвистик һәм социологик юнәлештә әдәби телнең барлыкка килү кануннарын, төзелешен һәм андагы үзгәрешләрне тарихи үсештә өйрәнә. Бу фәндә норма һәм стиль (өслүб) дигән ике зур төшенчә төп урынны тота. Борынгы чорлардан башлап, хәзерге көнгә кадәр, тел нормаларының һәм стильләрнең барлыкка килү, үсү һәм үзгәрү юлларын тикшерү әдәби тел тарихы фәненең төп эчтәлеген тәшкил итә. Әдәби тел кануннары нигездә язу барлыкка килгән чор белән тыгыз бәйләнештә карала. Монда, әлбәттә, халык сөйләү телендәге әдәби нормаларның үсеше дә инкарь ителми. Татар халкының әдәби теле һәм язма мәдәнияте күптәннән үсеп килә. Ул үзенең традицион-дәвамчан, эшкәртелгән, төрле яссылыктагы нормаларга ия булуы, таралу тирәлеге белән аерылып тора, үзенең тарихы һәм эчтәлеге ягыннан әдәби тел ерак гасырларга барып тоташа. Милләт теленең төп байлыгын эченә алып, әдәби

тел бөтен халык өчен уртак дәрәҗәгә китерелгән, киң җирлеккә таралган нормалар нигезендә барлыкка килә. Гасырлар буенча үсү һәм камилләшү барышында анда төрле үзгәрешләр күзәтелә. Әдәби тел гомумхалык сөйләме һәм халык авыз иҗаты әсәрләре теле нигезендә борынгы заманнардан бирле үсеп, бер телдә сөйләшүче халыкның барысы өчен дә уртак дәрәҗәгә китерелгән, төрле сөйләм стильләрен (өслүбләрен) эченә алган, гасырлар дәвамында эшкәртелеп, шомартылып килгән тел ул. Тарихи категория буларак, әдәби телнең үсешендә өч чыганакны искә алу әһәмиятле. Беренчедән, анда элек-электән билгеле бер җирлектә - халык тупланган урыннарда, соңга таба шәһәрләрдә үсеп чыккан гомумхалык теле (койне) зур урын тота. Икенчедән, әдәби телне үстерүдә диалектларның (шивәләрнең) да роле зур. Өченчедән, халык тарафыннан иҗат ителеп, төрле жанрларда буыннан-буынга күчеп килгән фольклор әсәрләре дә әдәби тел нормаларын үстерүдә мөһим чыганаклардан санала.

Төрки халыкларның тарихы ерак үткәннәргә - элекке дәверләргә барып тоташа. Аларда язу да бик күптәннән барлыкка килгән. Борынгы һәм урта гасырларда төрки телнең үсешен, аның хәзерге төрки телләргә мөнәсәбәтен билгеләгәндә тарихи-чагыштырма ысулны куллану аеруча зур әһәмияткә ия. Бу очракта әдәби телнең төп ике формасына игътибар ителә: беренчедән, сөйләмә телнең, икенчедән, язма телнең барлыкка килү һәм үсеш закончалыклары тикшерелә. Алар арасында еш кына ныклы чикләр дә куеп булмый, аларны бер-берсеннән аерып карау да кыен, чөнки язу барлыкка килү белән язма һәм сөйләмә нормалар үзара бик тыгыз кушылып китәләр, әмма һәр тарихи чорда аларга хас аерымлыкларны да күзәтергә мөмкин. Моны лексик, фонетик, грамматик яссылыкта да, сөйләм төзелешендә дә күрергә мөмкин.

Хәзер тюркология фәне алдында, шул исәптән татар тел белемендә борынгы төрки язма ядкарьләрнең телен бөтен тулылыгы белән өйрәнү бурычы тора. Бу – татар теленең үсешен күз алдына китерү өчен генә түгел, бәлки тагын ике зур проблеманы – телнең татар халкы этногенезында тоткан тарихи урынын билгеләү һәм хәзерге шартларда элекке традицияләр җирлегендә татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү мәсьәләсен хәл итү белән бәйләнгән.

Хәзерге чорда төрки телләрнең үзләренә хас тарихи үзенчәлекләрен ачыграк күз алдына китерү, аларның гомуми һәм хосусый билгеләрен дөрес итеп аеру, телләр арасындагы чикләрне тагы да төгәлрәк билгеләү максатыннан чыгып, тел тарихының һәр ике бүлеген (тарихи грамматика һәм әдәби тел тарихы) өйрәнү һәм тикшерү фәнни методологик принципларга нигезләнергә тиеш.

Борынгы телнең төзелеше сакланган хәлдә, әдәби тел гасырлар буенча камилләшә килә, төрле үзгәрешләргә тартыла, туктаусыз яңара һәм анда яңа сыйфатлар үсеп чыга. Үзгәрешләр әдәби телнең элек-электән килгән системасын җимерү рәвешендә түгел, бәлки аны тагын да баету, тулыландыру юнәлешендә бара. Әдәби телнең үсеше җәмгыятьтәге иҗтимагый-тарихи вакыйгалар белән аерылгысыз мөнәсәбәттә тора, һәм ул халык сөйләменә якынаюы белән үлчәнә. Әдәби тел үсешендә нормаларның бердәмлеге, гомумилеге, элекке тар кысаларның җимерелә, функциональ күренешләрнең киңәя баруы күзәтелә. Гомуми юнәлештә караганда, әдәби телдәге үзгәрешләр телнең төп яшәеш төрләре белән бәйләнгән. Аларга әдәби тел үзе, диалектлар, гади җанлы сөйләм һ.б. керә. Боларның үз эчендә дә тармаклану була ала. Тел чараларын гамәлгә ашыру һәм сөйләм төзү процессында әдәби тел киң тирәлектә хәрәкәт итә, нәтиҗәдә бу иҗтимагый тормышның төрле өлкәләрендә ачык чагылыш таба. Соңгы елларда тел гыйлемендә шивәләрдән өстен торган тел күренешләренең барлыкка килү юллары да һәм аларның кулланылу үзенчәлекләре дә шактый киң өйрәнелде. Монда аеруча төрле телләрдәге язма һәм сөйләмә төрләргә генә түгел, бәлки билгеле бер өлкә яки шәһәр белән бәйләнешле тел үзенчәлекләренә дә игътибар ителә. Бу - әдәби телне төрле яссылыктагы күренешләр – шивәләр, гади сөйләм, тарихи җирлектә барлыкка килгән гомумхалык теле нормалары белән тыгыз мөнәсәбәттә карауны таләп итә. Телнең функциональъ стратификациясе нәкъ әдәби телнең, сөйләү теленең төрле тирәлектә кулланылышын күздә тота. Шулай ук монда аралашу максатында әдәби телнең функциональ-стилистик яктан үсеш-үзгәреш һәм киң җирлектә таралышы да

искә алына. Мәсәлән, матур әдәбиятның аерым жанрларына, публицистикага, фәнгә, идарә, уку-укыту эшенә караган сөйләм үзенчәлекләре һ.б.

Татар халкының да язма әдәбияты, гомуми мәдәнияты иҗтимагый һәм икътисади тормышы борынгы бай төрки традицияләргә нигезләнеп үсә. Соңгы берничә гасыр дәвамында, үзенең дәүләтчелеген югалтып, буйсынып яшәүгә дучар ителсә дә, татар халкы элекке гореф-гадәтләрен , үз яшәешлелеген югалтмады, XX гасырга шактый бөтен рәвештә керде, үзенең зур укымышлыларын, язучыларын, тарихчыларын – гыйлем ияләрен бирде. Милли күтәрелеш һәм уяну заманы төрки халыкларның бердәмлеген торгызуга киң юл ачты. Ул заманның мәгърифәтче-галимнәре төрки халыкларны, аларның телен саклап калу өчен зур көрәш алып бардылар.

XIX гасырның икенче яртысында күтәрелгән гомумтөрки әдәби тел төшенчәсен һәр төрки халыкның үз милли теленә каршы кую дөрес булмас иде. Уртак төрки әдәби тел мәсьәләсе бердәмлеккә, мөстәкыйльлеккә ирешү һәм милли-азатлык мәсьәләләрен хәл итү белән дә бәйләнгән. Шул ук вакытта бу – төрки халыкларны, аларның телен саклап калуга да юнәлтелгән. Тел бердәмлеге өчен көрәш кайбер чорларда аеруча кискен төс ала. XX гасырның башында һәм ахырында бу мәсьәләне хәл итү өчен аеруча уңай шартлар туды дияргә мөмкин. Әмма аны тормышка ашыру бик авырлык белән бара, төрле киртәләргә очрый.

Төрки халыкларны бер-берсеннән аерырга, алар арасындагы тарихи бәйләнешләрне өзәргә тырышу нәтиҗәсендә, элекке язма мираска, мәдәнияткә дөрес булмаган карашның урнашуын да әйтмичә үтеп булмый. Мәсәлән, XI гасырда иҗат ителгән “Котадгу билиг” әсәре, Мәхмүд Кашгарый хезмәте үзбәкләргә якынайтылды. Күп кенә тюркологик әдәбиятта XIV гасырда Алтын Урда чорында язылган әсәрләр дә иске үзбәк әдәби теле үрнәкләре итеп карала. Тагы бер мисал. 1989 елда XI-XIV гасырдагы төрки телләрне тикшерүгә багышланган хезмәттә дә мондый караш сизелә (Наджип Э.Н. Исследования по истории тюркских языков XI- XIV вв. – М.: Наука, 1989). Анда XI-XIII

гасыр төрки язма әсәрләре – Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф”ы (XIII гасыр), XIV гасыр язма истәлекләре (“Гөлстан бит-төрки”, “Хөсрәү вә Ширин”, “Нәһҗел-фәрадис” һ.б.) - барысы да Урта Азия ядкарьләре итеп алыналар, ә “Кыйссаи Йосыф” угыз телләренә нисбәт ителә. Гомумән, әле төрки язма әсәрләргә карата бердәм фикер урнашмаган. Киләчәктә бу өлкәдә ачыклыйсы мәсьәләләр шактый күп.

Төрки телләр арасында татар әдәби теленең тоткан урыны турында тюркологиядәге карашларны да ачыклыйсы бар. Төрки телләрне иске һәм яңа телләргә бүлеп карау да тарихны бозуга китерә. Шуны да искә алырга кирәк: бүгенге исемнән, этнонимнан чыгып кына теге яки бу халыкның тарихын, барлыкка килүен ачыклап бетереп булмый. Әлбәттә, һәр тарихи этнонимның нигезе бар. “Татар” дигән этноним белән дә эш шулай тора. Дәүләтчелек язма әдәбиятның үсешенә зур йогынты ясый, халыкларның иҗтимагый һәм мәдәни тормышында яңа эра ача, әдәби телнең тотрыклы нормалары үсүгә, төрле сөйләм стильләре белән баюына нык этәргеч бирә. Идел буе төрки әдәби теленә Болгар дәүләте чорында нигез салына. Болгар дәүләтендә XII-XIV гасырларда гомумтөрки традицияләр һәм җирле кабилә телләре нигезендә гомумтөрки язма әдәби теле үсеп чыга, аралашу процессында тел чараларын билгеле бер максаттан файдалану нәтиҗәсендә, аның аерым стильләре формалаша башлый. Бу – берничә гасырга сузылган эволюцион процесс. Безнең эраның VIII гасырында рун язмаларында һәм аннан да алда искә алынган татар кабиләләре, аларның теле турындагы төшенчәләрне дә ачыклап үтү зарурый. Идел буенда яшәгән безнең борынгы бабаларыбызның теленә карата “Идел буе төркиләре”, “Казан төркиләре теле”, “төрки тел” дигән атамалар кулланылган. Бу атамалар бүгенге татар халкы, татар әдәби теле төшенчәсенә туры киләләр. Моны искә алмау халкыбызның этногенезын һәм телнең үсешен тикшергәндә зур буталчыклар китереп чыгара, дөрес булмаган нәтиҗәләргә дә этәрә. Бу - кайбер хезмәтләрдә татар халкының әдәби теле XVIII-XIX гасырларда гына үсеп һәм формалашып җиткән, аңа чаклы Идел буенда гомумтөрки тел генә булган дигән фикерләргә юл калдыра. Кызгынычка

каршы, халык тарихын, әдәби тел тарихын болай бозып яктырту, мондый берьяклы фикерләр аерым фәнни хезмәтләрдә дә урын ала. Бу - XVIII-XIX гасырларга кадәр Идел буенда төрле стильләрдә иҗат ителгән бай әдәби, фәнни, дипломатик мирасны, тарихи чыганакларны белмәүдән генә түгел, бәлки татар халкының меңъеллык язма хәзинәсен кабул итәргә теләмәүдән, аны юкка чыгарырга тырышудан килә. Хәзерге чорда тарих һәм тел тарихы фәне бик авырлык белән булса да, мондый суъектив карашлардан арына бара.

Әдәби тел тарихында үзара тыгыз бәйләнештә бер-берсеннән шактый аерылып торган сөйләм төрләрен күзәтергә була. Язма сөйләмгә үрнәк итеп, матур әдәбият әсәрләренең телен (”Кыйссаи Йосыф”, “Кисекбаш китабы” һ.б.), үгет-нәсихәт стилен (”Бәдәвам китабы”, “Тәкый гаҗәп”, “Нәсыйхәттес-салихин” һ.б.), эпитафик язмаларны, сөйләмә формалардан исә халык авыз иҗаты әсәрләрендәге (“Туйбикә кыйссасы”, “Кыйссаи нәүрүз”, “Кыйссаи ике былбыл”, “Сак-Сок бәете” һ.б.) тел үзенчәлекләрен аерып күрсәтергә мөмкин. Бу әсәрләрдәге язма һәм сөйләмә формаларның тыгыз үрелеп баруы, төрле стильләрнең үсеше нәтиҗәсендә Болгар дәүләте чорында ук Идел буе төрки теле барлыкка килә. Алтын Урда дәүләтендә дә шул традицияләр дәвам итә. Болгар-кыпчак телләреннән тыш, Идел буе язма әдәби телендә VI-IX гасырларга караган төрки әдәби телнең – рун язмаларының, X-XI гасырларда иҗат итлегән “Алтын балкыш”, “Котадгу билик”, М. Кашгарыйның “Диване лөгат-ет төрк”, XII гасыр Әхмәт Йугнәкинең “Һибәтел-хакаикъ”, Хуҗа Әхмәт Йәсәви хикмәтләрендәге, Сөләйман Бакыргани әсәрләрендәге тел үзенчәлекләре дә бар. Бу гомуми уртак сыйфатлар борынгы төрки телдән үк килгән традицияләрне күрсәтә. Татар теле белән Идел болгарлары дәүләтендәге төрки телләр арасында тыгыз бәйләнеш бар. Элекке чордагы төрки язма истәлекләрдә телнең эчке мөмкинлекләреннән киң файдаланыла, күчерелмә мәгънәдәге сүзләргә, төрле сурәтләү алынмалары, фразеологик әйтелмәләргә зур урын бирелә. Борынгы чорда һәм Урта гасырларда иҗат ителгән язма әсәрләрнең телен өйрәнү хәзерге татар әдәби теле һәм аның тарихына караган төп мәсьәләләрне

чишәргә мөмкинлек бирә. Идел һәм Урал буйларында яшәгән төрки халыкларның таралышы, аларның телләре турындагы мәсьәлә тикшерүчеләрнең игътибарын күптәннән үзенә җәлеп итә. Аларның яши башлавын монда болгарлар килгән чордан башлап караучылар да, Европага һуннар килү һәм аңа кадәрге чор белән бәйле рәвештә тикшерүчеләр дә бар.

Җәмгыяттәге үзгәрешләр язма телгә генә түгел, сөйләү теленә дә үзенең тәэсирен ясамый калмаган. Элек-электән сөйләү теле һәм язма сөйләм бер-берсе белән кушылып барган. Анда төрле кабилә телләре катнашкан. Хәзерге тарар теленең диалекталь төрлелеге дә шуны ачык күрсәтә. Шулай итеп, XII-XIII гасырларда һәм соңга таба Идел буе төрки теленең үз нормалары тотрыклылана, үсә, ныгый барган. Моны ачыклау өчен ул вакытта иҗат ителгән әсәрләр, төрле сүзлекләр ярдәмгә килә. Ул язма истәлеләрдә төрки кабилә телләре җирлегендә үсеп чыккан бай һәм камилләшкән тел чагыла. Гомумән, болгар-кыпчак теле озак дәверләр зур үзгәрешләргә тартылмыйча сакланып килә. Ул Алтын Урда дәүләте, Казан ханлыгы чорында һәм аннан соң да дәвам итә. Казан ханлыгы дәверендә дә татар халкының бер дәүләт булып оешуы сөйләү теленең үсүенә зур йогынты ясый. Һичшиксез, татар халкы сөйләү теленең нигезе Болгар дәүләтендә салына. Төрки кабиләләрнең бер-берсе белән аралашып яшәве, шул нигездә гомумуртак тел нормаларының барлыкка килү нәтиҗәсендә, борынгы язма төрки тел һәм сөйләү теле йогынтысында XIII-XIV йөзләрдә Идел буе төрки әдәби теленең лексик, фонетик һәм грамматик нормалары һәм стильләре формалаша һәм шактый ныгый. Ул борынгы һәм иске татар язма әдәби теленең нигезе булып санала.

Җыеп әйткәндә, борынгы чорларда һәм урта гасырларда иҗат ителгән әсәрләрнең телен өйрәнү хәзерге татар әдәби теле һәм аның тарихына караган төп мәсьәләләрне чишәргә мөмкинлек бирә. Идел-Урал буйларында яшәгән төрки халыкларның таралышы, аларның телләре турындагы мәсьәлә тикшерүчеләрнең игътибар үзәгендә тора. Бүгенге көндә төрки телләрнең язма чыганакларын өйрәнүдә яңа методлар һәм

алымнар кулланып эш итү, тикшерүләрне фәнни методологиягә кору зарурияте төп бурычларның берсе булып кала бирә.

Харрасова Р.Ф.

Текстта җөмләара бәйләнешләрне тикшерү

Гамәли дәресләрдә даими рәвештә текст өстендә төрле югарлыктагы логик бәйләнешләрне өйрәнми торып, студентларны камил иҗат итәргә, үзара культуралы аралашырга күнектерү мөмкин түгел. Сөйләм логикасына игътибарлылык булачак укытучылар, һәм инде журналистлар, тәнкыйтьчеләр, әдәби редакторлар өчен бигрәк тә кирәк. Аларның язма продукциясе бөтен илне тел әдәбенә өйрәтә. Камил калыплаштырылмаган текстлар исә, киресенчә, укучылар аудиториясен дә сөйләмдәге җитешсезлекләргә битараф итәчәк, хәтта ки тора-бара алар бу хаталарны тоймый да башлаячак яисә билгеле бер нормалар дип санаячак.

Еллар дәвамында вакытлы матбугатны өйрәнү төрле тип хаталардан азат булган текстларның бөтенләй очрамавын күрсәтте. Аерым бер авторлар, бигрәк тә танылган шагыйрь һәм прозаиклар язган әсәрләр генә идеалда эшләнергә тиеш текстларга якын тора. Бүгенге көн каләм ияләреннән телгә соң дәрәҗәдә сак килүгә омтылыш Марсель Галиевтә күзәтелә. Күрәсең, талант һәм таләпчәнлек, тел язмышы өчен борчылу янәшә йөри. Флүс Латыйфи, Мәгъсум Хуҗин, Миргазыян Юныс һәм башка кайбер авторлар тудырган әдәби мирас та тел матурлыгы, аны калыплаштыру камиллеге белән шактый аерылып тора. Әлеге әдипләрнең вакытлы матбугатта бастырган язмалары да әнә шундый.

Газета-журналда чыккан материал язучыныкы я булмаса иҗатчы укучыныкы гына түгел, чөнки редактор кулы аша да уза һәм, кызганычка каршы, еш кына ялгыш куелган тыныш билгеләре, орфографик хаталар белән дә «баетыла». Актив иҗат итүче авторлар моның белән килешерләр дип уйлыйм.

Каләмдәшләр белән әңгәмәләр аларның бигрәк тә текстны кыскартып бастырулары өчен борчылуларын күрсәтте, чөнки бу

барлык очракта да сөйләм логикасын, уздырырга теләгән фикерне теге яки бу дәрәҗәдә бозуга китерә икән. Ә бит әле текстта автор тарафыннан калдырылган һәм редактор тотып алмаган хаталар да була.

Текстны төрле яссылыкта өйрәнергә, бәяләргә мөмкин. Бу хезмәттә аны җөмләара бәйләнешләр ноктасыннан камилләштерү турында сүз алып барырбыз. Сөйләм логикасындагы җитешсезлекләр юкка чыгарылганда, үзеннән-үзе башка төр хаталар да кими, һәм шуның киресе дә күзәтелә. Әйтик, җөмлә төзелешендәге хаталардан арыну сөйләм эзлеклелеген көчәйтә.

Укучыларның басма сүзне кабул итүе психологик үзенчәлекләренә, профессиясенә бик бәйле. Яшь бала, үсмер зур текстның гомуми логикасындагы хатаны тота алмаска мөмкин. Кемдер җөмләара бәйләнешләрне гомумән күрми, китапны ябып куйгач кына, аның үтәли фикер сөрешендәге чатаклыклар турында уйлана. Берәүләр, бигрәк тә әдәби мөхәррир булып эшләүчеләр, хатага бик игътибарлы була, аларның күплеге аркасында, сәнгать әсәреннән ләззәт тә ала алмый. Икенчеләр, башта тулы текст белән таныша, аңаербөтен сыйфатында якын килә һәм шул бөтенлеккә зыян китергән якларны күрә, аннан соң җөмлә, абзац, аерым өлешләр эчендәге хаталарны табып ала. Бар төр җитешсезлекләрне истә тотучылар һәм текстны берьюлы бөтен планда да камилләштерә алучылар да бар. Әлеге гамәлнең юллары шулай ук төрле. Әйтик, аерым җөмләне төзәткән саен, кечерәк күләмдәге текстны тулаем укып, янәшә рәвештә башка төр хаталарны киметергә мөмкин. Ике җөмләне бәйләнештә карау гына да үзеннән-үзе җөмләләр, абзацлар бөтенлеген, логикасын көчәйтәчәк. Шул ук вакытта тулы текст та камилрәк калыплашачак.

Студентлар, аларның яшьтәшләре, каләмдәш дуслары язган әсәрләрне тикшерү дәресне җанлы, кызыклы итә. Семестр дәвамында бер үк укучыларның иҗади эшләрен өйрәнү аларга үзләренә хас типик хаталардан арынырга булыша. Әлбәттә, бер текстны тулаем анализлап чыкканнан соң да, аерым кеше, тирәлек, һөнәр иясе сөйләменә хас, яшь үзенчәлегенә бәйле даими очраган җитешсезлекләрне тотып алырга мөмкин.

Махсус сайланган төркемнәрдә иҗатка бәйле фәннәр өченче курста һәм «Әдәби тәнкыйть» курсыннан башлана. Бу вакытка студентларның иҗади тәҗрибәсе зур түгел, әмма университетта инде тел фәннәрен өйрәнгәннәр, гадәттә, бик яхшы билгеләренә имтихан да тапшырганнар. Теоретик белемнәргә ия булуларына карамастан, хәтта язучылык эше белән балачактан шөгыльләнгән студентларда да, кызганыч ки, камил сөйләм күнекмәләре, хәтта ки тыныш билгесен дөрес кую күнекмәләре очрамый. Еллар дәвамында әлеге предмет буенча алып барылган гамәли дәресләр әнә шуны сөйли. Студентлар, күрәсең, кагыйдәне өйрәнәләр дә оныталар, шунлыктан һәр җөмлә өстендә эш сүз язылышына, пунктуациягә караган кагыйдәләрне искә төшерүдән башлана.

Н.Гыйматдинованың «Манара» хикәясенә гамәли дәресләрнең берсендә рецензия язган идек. Текстны укучы башкарган вариантта тулаем китерәбез:

«Н.Гыйматдинованың «Манара» хикәясенә рецензия

Алдымда Н.Гыйматдинованың чираттагы әсәре – «Манара» хикәясе. Мин аны зур кызыксыну белән укып чыктым. Хикәя миңа совет чорында дингә булган карашларның нинди булуын, кеше күңелен, икейөзле кешенең әхлагы, намусы ни дәрәҗәдә булуын аңларга ярдәм итте. Нәбирә апа – минем иң яраткан язучыларымның берсе. Шуңа да мин аның әсәрләрен җиңел укыйм. Манара хикәясе 1989 нчы елда язылган. Әсәрнең сюжеты аңлаешлы. Хикәянең исеме «Манара» дип куелган. Әсәрдә күбрәк Нурулла, аның эшләгән кара эшләре турында сөйләнелә. Ә аның кылган начарлыгы нәкъ менә манара белән бәйле.

Нурулланың дәрәҗәсе социаль яктан югары булса да, авыл халкы арасында зур казаныш яулый алмый. Ә бит барысы да аның үз кулында иде. Нурулланың мөхтәрәм ил карты буласы килә, ләкин аны беркая да чакыручы, эндәшүче юк. Очраганда да күрмәмешкә салынып китәләр. Аның бар дөньясы ишекалды белән генә чикләнә Бу тормышка ул үзе гаепле. Үзенең никадәр генә күңеле сызласа да, айны кире урынына кую турында уйламый да. Ә боларның барсын да ул үзенең ялагайлыгы, куркуы, икейөзлелеге белән эшли. Якын дусты Зарифулла ясатып куйган айны, район секретаренә

ярыйм дип, юкка чыгара. Үзенең иң якын дустын сата. Манараны торгызганын әләкләп төрмәгә озаттыра. Авыл халкыннан ягымлы караш күрә алмаган Нурулла йодрыгын эшкә җигә. Зарифулланы үз иткән авыл Нурулланы күрә алмый. Бары тик аның «йодрыгыннан» гына шүрләп яши. Нурулланы авыл халкының күрә алмавы гына түгел ә ае урланган манараның көн саен төшенә кереп йөдәтүе дә шомландыра, һәрвакыт өстенә авар кебек тоела. Нурулла соң булса да картлыгында җир йөзеннән керле килеш китәсе килмгәнлектән, айны урынына кую өчен төнлә манарага менеп китә. Һәм такталар ычкынып, манара белән бергә җиргә ава.

Әлеге сюжеттан без Нурулланың никадәр кансыз киәнлеген күрәбез. Аның эшләгән начарлыгының ни дәрәҗәдә булуын белү өчен, безгә тамак өчен теләсә нинди эш эшләргә риза булган зимагур Шакирҗанның әйткән сүзләрен искә төшерү дә җитә. Нурулла аңа мәчетне яндырырга кушкач, Шакирҗан ризалашса да, вакыты җиткәч, бу эшне эшләми. Ә Нурулла бит аңа «ипигә коендырам» дигән иде. Ә аңа каршы зимагур «аен урлаган имансызга әйт, ай тиклем айны урлагач, бусын да булдырыр. Мәчет манарасын яндырганчы, ачлыктан үләм мин, абзый…» дип җавап бирә.

Автор әсәрдә безне ике герой белән таныштыра: Зарифулла һәм Нурулла. Ул аларны төрле яктан ачып бирергә тырышкан.

Әсәрдә автор шул чорның дингә карашын, яхшы кешеләрен дә чор колы булуын йчагылдыра. Кешенең дәрәҗәсе үсү белән әхлагы югалуын күрсәтә. Аллаһ йорты булган мәчетнең аен урлауның, гомумән, мәчеткә кул тидерүнең нәтиҗәләрен ачып күрсәтә. Әсәрнең буеннан-буена без укучыларга гыйбрәт, сабак булырдай фикерләр күренә.

Әсәрне укыгач, үзең генә түгел, сине авыл председателе итеп куйганнар икән – авыл халкы мәнфәгатьләрен дә кайгыртып яшәргә, намуслы булырга, ата-баба миарсын сакларга (Зарифулла бу матурлыкны югалтсак, оныклар гафу итмәс»,– ди.) дигән уй-фикерләр туа.

Әсәр бар яктан да камил эшләнелгән. Җөмләләр гади һәм аңлаешлы, җиңел укыла. Кыска гына китеп әйткәндә – бер

тында укып чыгарлык. Укучыга тәэсир итә, уйландыра торган гыйбрәтле әсәр.»

Түбәндә, хөрмәтле укучым, әлеге текстта җөмләара бәйләнешләрне камилләштерү юлларының берсен күрсәтербез. Моның өчен берничә җөмләне аерып алып карарбыз. Аның да төрле юллары бар. Әйтик, без беренче абзацтан кабатланган сүзле янәшә җөмләләрне аерып чыгардык, һәм бу җитешсезлекне ассызык белән билгеләдек.

«Алдымда Н.Гыйматдинованың чираттагы әсәре – «Манара» хикәясе. Мин аны зур кызыксыну белән укып чыктым. Хикәя миңа совет чорында дингә булган карашларның нинди булуын, кеше күңелен, икейөзле кешенең әхлагы, намусы ни дәрәҗәдә булуын аңларга ярдәм итте.» Автор «булганның нинди булуын аңлау» турында яза. Болай да билгеле икән, аны нигә ачыкларга, дигән сорау туа. Шул ук вакытта совет чорында дингә мөнәсәбәтнең нindilеге ачылмый кала, текст узган тарихыбыздан хәбәрдар укучы өчен генә язылган булып чыга. Рецензент намуслылыкны математик дәрәҗәдә төгәл бәяләргә омтыла шикелле, шуның аркасында сөйләм табигый кабул ителми. Беренчедән, герой хакында үзе үк икейөзле, намусы юк дип язып куя, шуннан соң яңадан әхлагы турында уйлана булып чыга, ягъни сөйләмдә нәтиҗәнең урыны дөрес сайланмаган.

Укып чыкмый торып, әсәр хакында фикер йөртеп булмый. Аны асызыклауның кирәге юк. «**Әсәрне кызыксынып уку**» хакындагы фразалар рецензияләрдә еш очрый, шунлыктан алар кергән җөмлә турында, дежур сөйләм һәм текстны сузу өчен генә язылган дип уйлыйсың.

Аерым җөмләләр хакында әнә шул рәвешле фикер йөрткәннән соң, мөмкин булган уннарча камил вариантлардан берсен тәкъдим итә барырбыз. Алар һәрвакыт кыскалыкта осталык икәнлеген исбатлап торучы җөмләләр булыр.

«Хикәя мине совет чорында хөкем сөргән карашлар, кеше күңеле, намус, әхлак турында уйланырга мәҗбүр итте.»

«Нәбирә апа – минем иң яраткан язучыларымның берсе.» Минем алмашлыгы артык, ул инде язучыларым сүзе ярдәмендә белдерелгән. Конструкция алдагы абзацныкына охшаган. **Иң**

дигәч, бер генә язучы була ала, һәм **берсе** сүзенең кирәге бетә. Дөресе: **«Нәбирә апа – иң яраткан язучым».** Инде алда төзәтелгән җөмләне янәшәдәгесе белән кушыйк: **«Нәбирә апа – иң яраткан язучым. Шуңа да мин аның әсәрләрен җиңел укыйм.»** Китерелгән җөмләләрдә сөйләм логикасының дүртенче кануны бозылган: дәлилләү җитми. Минемчә, яраткан авторың авыр телле әсәр язган икән, аны җиңел укыту өчен, мәхәббәт ярдәмгә килә алмас. Бәлки, автор фикернең нәкъ капма-каршысын әйтергә теләгәндер? Әйтик: **«Әсәрләренең теле җиңел булганга, ул – иң яраткан язучым»** дияргә кирәктер?

Алга таба автор: « **«Манара» хикәясе 1989 <u>нчы</u> елда язылган»**,– лыкны әйтә. Аның алдагы җөмлә белән бәйләнеше юк. Димәк, ул үзгә тема алып килә, һәм төзәтүнең иң җиңел юлы – яңа абзац башлау.

Әгәр без текстны **«Аның 1989 елда язылган «Манара» хикәясе дә табигый тел агышы белән үзенә алып кереп китә»,** дип үзгәртсәк, икенче җөмлә аңа уңышлы ялганырмы? Бәлки, әлеге дә баягы логиканың дүртенче канунын кулланырга һәм, әсәр теленә хас сыйфатлар хакында язып, абзац оештырыргадыр?

Алга таба укыйк: **«Әсәрнең сюжеты аңлаешлы».** Хәзер сүз, һичшиксез, шушы сюжетны ачу юнәлешендә барырга тиеш, югыйсә җөмлә бушка атылган таш булып кала. Икенче яктан, газета – кече күләмле орган, анда битне, рубриканы күп материал белән тыгызларга тырышалар, димәк, текстыгыздагы бу җөмләне кыскартачаклар.

Алга таба укыйк: **«Хикәянең исеме «Манара» дип куелган.»** Сөйләм бәйләнеше юк. Артык җөмлә: исеме билгеле бит инде. Синтаксик конструкция буларак дөрес түгел. Ул: **«Хикәягә «Манара» исеме куелган»,–** рәвешендә калыплашырга тиеш иде.

Әгәр исемгә яңадан игътибар юнәлтергә телибез икән, аның максаты булырга тиеш. Мәсәлән: идея эчтәлегенә, озынлык-кыскалыгына, яңгырашына һәм башка нәрсәләргә игътибар иттеү теләге. Бер формасы: **«Хикәя гади генә бер сүз белән – «Манара» дип аталган».** Алга таба кулланылган җөмләләр, бу исемнең отышлы яисә отышсыз булуын ачсалар яхшы. Исеме гади генә, хикәянең идея эчтәлеге тирәнлеген исбатларга мөмкин.

Бу очракта тәүге җөмләдән **«Манара» хикәясе** дигән гыйбарәне алып атарга кирәк була.

Автор алга таба: **«Әсәрдә күбрәк Нурулла, аның эшләгән кара эшләре турында сөйләнелә. Ә аның кылган начарлыгы нәкъ менә манара белән бәйле»**,– дип яза. Димәк: **«Манара образы әсәрнең композицион үзәге булып тора»**–, дип ассызыклау аның өчен мөһим булган.

Язарга өйрәнүнең башлангыч этабында, текстның бер-ике җөмләсен генә күз уңында тота алганда, аларга керткән үзгәрешләр, башка җөмләләр белән бәйләнешләргә, гомуми композициягә, җөмлә төзелешенә зыян салырга, шунлыктан хезмәтеңне яңадан иҗат итә башлыйсың.

Уку тизлеге йөгерек, текстны күз белән иңләү күләме зур, шунлыктан битләрне тулы күреп укый алган кеше берничә җөмләне кушып күрә, шулай булгач, бер җөмләне төзәткәндә, икенчеләре арасындагы бәйләнешләрне дә күздә тота ала. Студентлар исә төрле күнекмәләргә ия, шунлыктан, бергәләп текстның кече өлешләре өстендә генә эшләп була һәм, ике җөмләне укыганнан соң, алдагысына кире әйләнеп кайтасың, инде яңадан ясаган хаталарыңны төзәтәсең.

Бу очракта да, чыннан да, манара исеме мөһим икән һәм тәкъдим иткән җөмләбез бу урына отышлы булып чыкты, алга таба рецензияне: **«Атама исеме буларак сайланган гади генә сүзгә бик тирән мәгънә салынган, ул төп герой Нурулла гамәлләре аша ачыла»,–** дип тә дәвам итә алам. Ул, авторныкыча калганда да, бик матур яңгыраш ала, бу урында язучылык интуициям зур эш башкарган булып чыга.

Кыскасы, абзацны яңадан бер кат карап чыгабыз. Аның авторныкына шактый якын бер вариантын түбәндә китереп узыйк:

«Нәбирә Гыйматдинова – иң яраткан язучым. Алдымда – аның 1989 елда язылган «Манара»хикәясе. Әсәрнең теле җиңел, сюжеты аңлаешлы. Хикәя мине совет чорында хөкем сөргән карашлар, кеше күңеле, намус, әхлак турында уйланырга мәҗбүр итте.

Манара образы әсәрнең композицион үзәге булып тора. Хикәядә үзәк герой Нурулланың кара эшләре турында сөйләнелә. Ә алар, беренче чиратта, нәкъ менә манара белән бәйле.»

Текстны алга таба укыйбыз: **«Нурулланың дәрәҗәсе социаль яктан югары булса да, авыл халкы арасында зур казаныш яулый алмый».** Иярченле кушма җөмләдә ия-хәбәр бәйләнешләре дөрес түгел. Беренче җөмләдә сүз дәрәҗә турында бара, икенчесенең иясе төшеп калган, шунлыктан, геройның социаль дәрәҗәсе авыл халкы арасында казаныш артыннан куган булып чыга, ә сөйләм үзе аерымланган хәлле киң җөмлә сыйфатында кабул ителә. Дөрес төзелмәгән әлеге җөмләдә тыныш билгеләре түбәндәгечә урнашырга тиеш булыр иде: «Нурулланың дәрәҗәсе, социаль яктан югары булса да, авыл халкы арасында зур казаныш яулый алмый». Болай эшләгәч исә, җөмлә көлке хисе уята. Аны, урынсыз кулланылган **ның** кушымчасын алып аткач кына, пунктацион ноктадан камилләштерергә кирәк: **“Нурулла, социаль чыгышы буенча дәрәҗәле булса да, авыл халкы...”** Сүз куллану, гыйбарәләр төзүдәге хаталар текстны бизәми. Социаль дәрәҗәсе югары, дип әйтәбез, әмма, дәрәҗә социаль яктан югары, дип сөйләшмибез.

«Ә бит барысы да аның үз кулында иде.» Автор тискәре герой булып кайгыра түгелме? Ягъни: фикерләүче тупас рәвештә бер абзац эчендә алмашына. Автор бәяләмәләр урынына, тойгылы сорау җөмләләр язарга керешә. Текстның аһәңе үзгәрә, рецензия шуның аркасында инша төсен ала башлый.

«Нурулланың мөхтәрәм ил карты буласы килә, ләкин аны беркая да чакыручы, эндәшүче юк.» Бу җөмләдә автор фикерен ачып бетерми. Ул **«Нурулланың ил картларына күрсәтелә торган хөрмәткә ия буласы килә, әмма аны төрле мәҗлесләргә, авылда уздырылган чараларга олылыклап чакырмыйлар»,–** дип әйтергә тели. Шулай эшләгәндә, чираттагы җөмлә алдагысындагы фикернең эзлекле үстерелеше сыйфатында кабул ителер иде: «Очраганда да күрмәмешкә салынып китәләр». өзектә , җитми.

Алга таба автор: «**Аның бар дөньясы ишекалды белән генә чикләнә. Бу тормышка ул үзе гаепле. Манара башыннан ай урлаган өчен шулай ялгызлыкта герой»,–** дип яза. Бу очракта татар сөйләменә хас конструкцияләр кулланмау да

логиканың бозылуына китерә. Герой ай урлаган өчен түгел, я шуның аркасында ялгыз яисә – шул сәбәп аркасында авылдашлары аннан йөз чөергәнгә. Бу җөмләдә инверсия алымын куллану да – отышсыз.

« **<u>Үзенең</u> никадәр генә күңеле сызласа да, айны кире урынына кую турында уйламый да.»** Икенче җөмләдә эш-хәлнең иясен атамаганлыктан, җөмлә төзелешеннән чыгып фикер йөртсәк, күңеле уйламый булып чыга. **«Ә боларның барсын да ул <u>үзенең</u> ялагайлыгы, куркуы, икейөзлелеге белән эшли. Якын дусты Зарифулла ясатып куйган айны, район секретаренә ярыйм дип, юкка чыгара.»** Икенче җөмләдә кулланылырга тиешле ия онытылган, шунлыктан Зарифулла иягә әйләнә, ягъни айны юкка чыгаручы булып чыга. Димәк, соңгысына **ул** ны өстәргә кирәк.

Даими рәвештә тулы булмаган җөмләләр куллану фәнни текстта үзен акламый. Алга таба да шул ук күренеш дәвам итә: « **<u>Үзенең</u> иң якын дустын сата. Манараны торгызганын әләкләп төрмәгә озаттыра».** Кемгә кем әләкли– билгесез. «**Авыл халкыннан ягымлы караш күрә алмаган Нурулла йодрыгын эшкә җигә.»** Тәнкыйть мәкаләсе юмор-сатира әсәренә әйләнә башлый, төп герой исә кыйнап яраттыручы этигә охшап кала.

«Зарифулланы үз иткән авыл Нурулланы күрә алмый.» Каршы куеп тасвирлау юк иде бит әлегәчә. Җитмәсә, берсен үз иткәнгә генә, кешеләр икенчесен яратмый кебек фикер дә аңлашыла. **«Бары тик аның «йодрыгыннан» гына шүрләп яши.»** Алдагы җөмлә белән кушабыз. Моннан тыш, текстны укыганда, шүрләсәләр, ягымлы булып кыланырлар иде, дип каршы төшү теләге тууын да әйтеп узыйк.

«Нурулланы авыл халкының күрә алмавы гына түгел, ә ае урланган манараның көн саен төшенә кереп йөдәтүе дә шомландыра, һәрвакыт өстенә авар кебе тоела.» Бу җөмләдә дә алда күрсәтелгән хата күзәтелә. Икенче җөмләдә ия аталмаганлыктан, **төшкә керү** – ия, **авар** – хәбәр булып чыга.

«Нурулла соң булса да картлыгында, җир йөзеннән керле килеш китәсе килмәгәнлектән, айны урынына кую өчен, төнлә манарага менеп китә.» Җөмләдә кайбер урында өтерләр юк, урын-вакыт килешләре күп, алар җөмлә эчендә

отышлы урыннар алмаган. **«Һәм такталар ычкынып, манара белән бергә җиргә ава.»** Ни өчен яңа җөмлә? Алдагысына кушарга я иясен табарга кирәк. Югыйсә, **төнлә менгәнгә, такталар ычкына** кебек килеп чыга. **Такталар ава** дип тә аңларга мөмкин.

Текстны абзацларга бүләргә, түбәндәгечә үзгәртергә кирәк:

Нурулла авыл халкы арасында зур казаныш яуларга, мөхтәрәм ил карты булырга тели, әмма башкача килеп чыга: авылдашлары аны, олылыклап, беркая да чакырмыйлар, очраганда, күрмәмешкә салынып үтәләр. Ул ишекалдыннан чыкмыйча диярлек яши.

Кешеләрнең бу рәвешчә мөнәсәбәтенә үзе сәбәпчесе булса да, моның өчен күңеле никадәр сызласа да, төп герой хатасын төзәтми: айны кире урынына кую турында уйламый да.

Ялагай, куркак, икейөзлеле Нурулла иң якын дусты Зарифулла ясатып куйган айны, район секретаренә ярыйм дип, юкка чыгара. Алай гына да түгел, манараны торгызганын әләкләп, аны төрмәгә үк озаттыра. Димәк, ул иң якын дустын сатудан да тайчынмый.

Кылган гамәлләре аркасында, ягымлы караш күрә алмаган, халык хөрмәтен казанган Зәрифуллага үчле Нурулла авылдашларын куркыту эшенә керешә. Тора-бара аны, кешеләрнең үзен күрә алмавы гына түгел ә ае урланган мәчетнең көн саен төшенә кереп йөдәтүе дә шомландыра башлый. Манара көннәрдән бер көнне аның өстенә авып төшәр кебек тоела. Җир йөзеннән керле килеш китәсе килми башлаган Нурулла, ниһаять, айны урынына кую өчен, бер төндә манарага менә, шул вакыт, аяк астындагы такталар ычкынып, манара белән бергә җиргә ава.

Бу текстта, автор текстыннан ерак китмичә, синонимы булмаган манара сүзеннән котылу шактый авыр, аны ассызыклап бару яңгырашка зур зыян салмас дип уйлыйм.

«Әлеге сюжеттан без Нурулланың никадәр кансыз киәнлеген күрәбез.» Хикәя сюжетыннан дип әйтеп була, **әлеге** дип ассызыклар өчен нигез – берничә сюжет юк. Икенче яктан, җөмләләр янәшәлегеннән чыгып фикер йөртсәң, автор төп геройны, йодрык белән үзен хөрмәт иттергәнгә, кансыз дип атый

шикелле. Дөресе: **Нурулла кылган гамәлләрдән аның никадәр кансыз икәнлеге аңлашыла.**

«Аның эшләгән начарлыгының ни дәрәҗәдә булуын белү өчен, безгә тамак өчен теләсә нинди эш эшләргә риза булган зимагур Шакирҗанның әйткән сүзләрен искә төшерү дә җитә.» Һич тә җитми! Хикәяне укып чыгарга кирәк! Шуны аңлаганга, автор үзе дә укыган лабасаҺ Җитмәсә, текстта Шакирҗан сүзләре урын алмаган. Хикәя белән таныш түгел укучыга аның эчтәлеге хакында фаразларга гына кала.

«Нурулла аңа мәчетне яндырырга кушкач, Шакирҗан ризалашса да, вакыты җиткәч, бу эшне эшләми.» Беренчедән, үтә дә талымсыз җөмлә. Икенчедән, автор интонациясе Шакирҗанны гаепләүне тоемлата. Алага таба аңа үкенеч хисе кушыла Моның сәбәпчесе – җөмлә башында «ә бит»не куллану : « **Ә Нурулла бит аңа «ипигә коендырам» дигән иде.»** Җөмлә төзелешенә бәйле рәвештә, автор төзегән сөйләмдә өндәү дә соралып тора. «**Ә аңа каршы зимагур «аен урлаган имансызга әйт, ай тиклем айны урлагач, бусын да булдырыр. Мәчет манарасын яндырганчы, ачлыктан үләм мин, абзый…» дип җавап бирә.»** Нурулла хакындагы җөмлә узган заманга карый, болары исә – хәзерге заманга. Моны, ике герой арасында диалог тудыру өчен, һичшиксез, төзәтергә кирәк.

Автор әсәрдә безне ике герой белән таныштыра: Зарифулла һәм Нурулла. Бу җөмлә текст башы өчен генә отышлы, әлеге мәгълүматларны әллә кайчан белүебез исәпкә алынмый. Артта килгәне дөрес җөмләгә әйләнсен өчен, **капма-каршы характерлы** гыйбарәсен өстәргә кирәк, чөнки ул аларны төрле яктан ачып бирергә тырышкан.

«Әсәрдә автор шул чорның дингә карашын, яхшы кешеләрен дә чор колы булуын чагылдыра.» Бер генә чорда да дингә караш берлек санында гына була алмый, **чор идеологииясе** яисә **шул чорда җәмгыятьтә өстенлек иткән карашлар** гыйбарәләрен кулланабыз. **«Яхшы кешеләрнең дә идеология колы булын чагылдыра.»** Әсәрдә сүзе артык. Алда да шушы ук конструкцияле җөмлә икәнлек исәпкә алынмаган. **«Кешенең дәрәҗәсе үсү белән әхлагы югалуын күрсәтә.»** Тыныш билгеләре куелму логикага зыян сала.

«Аллаһ йорты булган мәчетнең аен урлауның, гомумән, мәчеткә кул тидерүнең нәтиҗәләрен ачып күрсәтә.» Ия юк. Күрсәтә сүзе җитә. Әсәрнең буеннан-буена без укучыларга гыйбрәт, сабак булырдай фикерләр күренә. Текстны кабатлаулардан да арындырырга кирәк. Алар һаман да сызыклар белән билгеләнеп барылды.

«Әсәрне укыгач, үзең генә түгел, сине авыл председателе итеп куйганнар икән – авыл халкы мәнфәгатьләрен дә кайгыртып яшәргә, намуслы булырга, ата-баба мирасын сакларга (Зарифулла бу матурлыкны югалтсак, оныклар гафу итмәс»,– ди.) дигән уй-фикерләр туа.» Текст авторның үзе турында сөйләнүе кебек төзелгән, укучы колхоз рәисенә әйләнгәндәй тоела. Фикерне төп геройга юнәлтергә кирәк, гомуми нәтиҗәдә, колхоз рәисе булсаң гына, намуслы яшәргә кирәклекне раслау дөрес булмас. Җәя эче артык, урынсыз, башка абзац сыйфатында киңәйтеп бирергә мөмкин.
«Әсәр бар яктан да камил эшләнелгән.» Фигыльнең бу формасы бармый. Тәгаенлек тойгысы кими төшә, ихтыярсызлыктан башкарылгандыр кебек, укучының битарафлыгы да тоемлана. **Камил эшләнгән** дибез. **«Җөмләләр гади һәм аңлаешлы, җиңел укыла.»** Ә бит талантлы кеше катлаулы җөмләләрне дә аңлаешлы язарга тиеш. **«Кыска гына китеп әйткәндә – бер тында укып чыгарлык. Укучыга тәэсир итә, уйландыра торган гыйбрәтле әсәр.»** Җиңел уку турында алда әйтелде инде.

Кыскасы, беренче карашка кызыклы һәм камил текстның да, җентекләп укый башласаң, редакцияләнеп бетмәгәнлеге ачыклана. Югарыда студент рецензиясен җөмләара бәйләнешләр, шул бәйләнешләрне тудыруда аерым сүзнең, җөмлә кисәкләренең, тыныш билгеләренең роле ноктасыннан карап уздык. Текстны аерым кабатлаулардан арындырдык.

Сөйләмнең логик сыйфатларын анализлау – бигрәк тә булачак мөхәррирләр эшендә мөһим бер гамәл. Тикшерелгән текст, фикерләү логикасы бозылганда, ясалган нәтиҗәләрнең уңышсызлыгы, ышандыру көченә ия булмавы хакында сөйли. Дөрес, китерелгән үрнәктә сөйләм логикасының төп кануннары, бигрәк тә тәңгәллек, капма-каршылык, өченчене танымау кануннары бозылмаган. Сүз-гыйбарәләрне дөрес, урынлы

кулланмау һәм ия-хәбәр мөнәсәбәтләрен, янәшәлекләрен исәпкә алмау гына да текст бөтенлегенә, логикасына зур зыян салган. Әлеге текстны һөнәри дәрәҗәдә дөресләү татар теленең гамәли стилистикасын ныклап өйрәнүне таләп итә.

Хәбибуллина Л.Р.

XX йөз башы татар поэмаларында мифологиянең урыны

XIX-XX гасыр чикләрендә татар әдәбияты үсеш юлында яңа сукмаклар сала башлый. Бу фикер, бердән, сүз сәнгатендә модернистик эзләнүләргә, шартлы алымнарга, икенчедән, милли-мәдәни традицияләргә игътибарның артуы белән дә дәлилләнә. Бу алгарыш үз чиратында мифологик образлар, сюжет-мотивлар, мифопоэтик шәхесләр, архетипик образлар белән кызыксыну көчәюгә алып килә. Шуның нәтиҗәсе буларак, милли поэзиядә мифологик образларны гәүдәләндергән бер төркем лирик һәм лиро-эпик әсәрләр мәйданга килә.

Дөнья әдәбиятларын бербөтенгә бәйләп торучы, төрле халыкларның сүз сәнгатен бер юнәлешкә туплаучы уртак закончалыклар, кануннар, образлар системасы, фәлсәфә барлыгы билгеле. Төрле халыкларның әдәби мирасы традицион күзаллаулар, мифологик сюжетлар, мотивлар белән баетылган хәлдә үсә. Гомумән, һәр сүз сәнгате мифлардан үсеш алган экиятләр, аннан героик эпос, классик эпоска кадәрге стадияләрен үтә [6; 45].

Мифология һәм әдәбият бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә яши [3; 4]. Гомумән, галимнәр тарафыннан әдәбият мифологиядән үсеп чыккан, дигән фикер әйтелә, чөнки миф атамасының килеп чыгышы борынгы грек теле белән бәйләнгән. Анда mifos сүзе риваять, дастан сөйләү дигәнне аңлата. Димәк, мифларга беренчел билгеләмә, исем биргәндә үк, аларның нигезендә әдәби әсәр булуына басым ясала [9;102]. Бу бәйләнеш генетик яктан гына чагылып калмый, миф һәм әдәбият өчен чынбарлыкны чагылдыру тибы да бердәй, ягъни икесе дә образлылыкка корыла [4; 877]. Шуңа күрә сүз сәнгатенең, килеп чыгышы турында онытылганнан соң да, мифологиягә мөрәҗәгать итүе гаҗәп түгел.

Миф борынгы кешеләрнең дөнья турында күзаллауларын чагылдыра, төрле күренешләрне аңлатырга омтылу нәтиҗәсендә, анда уйдырма төп урынны алып тора. Ләкин мифның ни дәрәҗәдә фантастик характерлы булуына карамастан, андагы уйдырма, хәтта күренеп торган ялган да дөреслек, кире кагылгысыз факт буларак кабул ителә. Миф раслануы мәҗбүри булмаган закон рәвешендә карала ала [8;60-61]. А.Ф.Лосев тарафыннан да шушы ук фикер үстерелә. Галим билгеләвенчә, мифик аң-фикерләү ноктасыннан чыгып караганда, миф һич кенә дә фикция яки фантазия дип кабул ителә алмый. Анда очраклы, кирәксез, ирекле яки уйлап табылган, фантастик берни дә юк. Ул – чын һәм максималь конкрет реальлек [5; 24].

Әдәбиятның һәр төре, һәр жанрында миф һәрчак кулланылып килгән. XIX - XX гасыр чикләрендә дә сәнгати образның киңәюе, нигездә, дөнья мифологиясенең (антик, христиан, көнчыгыш һ.б.) бай чыганакларыннан киң файдалануга бәйле төстә бара [1; 22].

XIX-XX гасыр чикләрендә дә сәнгати образның үсүе, нигездә, антик, христиан, ислам һ.б. мифологиясенә мөрәҗәгать итү, аларны яңача, заман күзлегеннән чыгып куллану белән бәйле төстә бара. Гомумбилгеле мифлар һәм легендалар яңа мәдәни-тарихи контекстта заманлаштыруга дучар ителә һәм халыкның милли психологиясе таләпләренә яраклаштырыла. Әлеге процесс миф хронотобы белән укучы чоры арасындагы чикләр җуелуга китерә. Нәкъ менә шушы үзенчәлек мифопоэтик структурага корылган әсәрләрдә ышандыру көченең, заман белән бәйләнешнең, актуальлекнең көчле булуына китерә.

XIX-XX гасыр чиге иҗтимагый-сәяси, фәлсәфи фикердә сыйфат үзгәрешләре чоры буларак билгеле. Бу яңарыш сүз сәнгатенә дә үз чалымнарын биреп, үзгә сыйфатларга җирлек әзерли. Шуның бер чагылышы буларак, XIX-XX гасыр чикләрендә мифологик образлар, сюжет-мотивлар, мифопоэтик шәхесләр, архетипик образлар белән кызыксыну көчәя.

Шушы дәвердә борынгы ышануларга, ислам мифологиясенә мөрәҗәгать итеп язылган поэмалар үзләре бер катламны тәшкил итә. Мондый әсәрләр, нигездә, 1914-1916 еллар аралыгында күпләп языла. Күпчелегендә үзәк образ буларак ислам

мифологиясенә бәйле Җен, Иблис, Хозер, шулай ук төрки-татар ышануларына бәйле Су анасы, Убыр, Өрәк кебек мифологик образлар алынган Ш.Бабичның "Газазил", М.Гафуриның "Адәм вә Иблис", Һ.Такташның "Газраилләр", Г.Сөнгатинең "Хозер", Г.Харисның "Өрәк" кебек әсәрләре дөнья әдәбиятындагы "антижанр" функцияләрен яңарта. Антижанр иске форманың яңа функциядә кулланылуы буларак карала. Ул, башлангыч формасыннан аермалы буларак, капма-каршы эчтәлектә укучыга тәкъдим ителә. Әдәбят белемендә аның ике төре аерып чыгарыла: көлке, сатира, пародиягә корылган һәм җитди антижанр.[2; 60-63]. Мәсәлән, Ш.Бабичның "Газазил", М.Гафуриның "Адәм вә Иблис" кебек поэмалары пародиягә корылган антижанрга, ә Г.Сөнгатинең "Хозер", Г.Харисның "Өрәк" әсәрләре җитди антижанрга мисал була ала. Бу да гасыр башы сүз сәнгатенең баюын, поэма жанрының төрлеләнүен исбатлаучы бер күренеш буларак бәяләнүгә лаек.

XX йөз башы татар поэзиясендә күп кулланылган ислам мифологиясенә бәйле образлар булып Адәм, Иблис, Газазил, Фәрештә, Хозер кебекләр тора. XX йөз башы шигърияте аларны татар укучысына символ югарылыгына күтәреп тәкъдим итә. Дини-мифологик образлар әдәбиятта тормыштагы авырлыкларга, ямьсезлеккә мөнәсәбәт белдерү яки юаныч эзләү чарасына әйләнә.

Мәсәлән, Ш.Бабич "Газазил" поэмасында берничә катлам фәлсәфә аша явызлыкның вакытка бәйсез категория булуын кабатлый. Поэмада явызлык күктән, Алла катыннан төшә. Алла һәм Газазил арасындагы беренче каршылык ук яшәешкә кагылышлы яхшылык-явызлык мәсьәләсенең чишелеш-нәтиҗәсен бирә: яхшылык та, явызлык та мәңгелек, беренчел категорияләр дип белдерелә.

М.Гафуриның "Адәм вә Иблис" поэмасында да мифологик образлар аркылы кеше күңеленең ямьсезлеге хакында сүз әйтелә. Поэма берничә катламның синтезы төсендә уйланылган. Фәлсәфи катлам явызлык, аның чыганагы турындагы уйланулар төсендә чагылыш тапкан. Явызлык күктән, Алла катыннан төшми, ә, бәлки, кешенең табигатеннән үк килә торган көч буларак тәкъдим ителә. Шуңа нисбәтле, Иблис кешенең ләззәткә омтылышы кебек кабул ителә. Явызлык кеше фәлсәфәсе дәрәҗәсендә дә бирелә.

Шагыйрьраславынча, кеше – җир йөзендәге бар начарлыкның чыганагы. Явызлык кешенең табигатенә салынган. Аның аерылгысыз үзенчәлеге булган нәфес – гөнаһка китерүче начар сыйфат. Бу фикерне җиткерү функциясе символ дәрәҗәсенә күтәрелгән мифологик образларга йөкләнгән. Поэмадагы Адәм образы җирдәге явызлык билгесен аңлатса, Иблис исә кешелекнең начарлыкка омтылышы булып төгәлләшә. Әлеге фикерләр җәмгыятькә бәя биргән тәнкыйди катламның асылын тәшкил итә.

Әсәр экзистенциаль рухта тәмамлана. Шагыйрь фикеренчә, җир тормышында яхшылыкка урын юк. Җир үзе үк гөнаһлы булып яратылган. Гөнаһ кылу, нәфес, үтереш кебек төшенчәләр кешенең табигатенә салынган. Бозыклык, явызлык, гөнаһның һаман арта баруы, туктаусыз сугышлар кешелекнең юкка чыгуына китерәчәк. Алланың үзенең дә бу инсаннарны барлыкка китерүенә үкенүе ассызыклана. Тәүбәгә килү, Аллаһка сыену, рухи чистарыну, изгелекне яшәү кыйбласы итү генә бетүдән саклап калачак. Автор үткәргән төп идея шуннан гыйбарәт.

Г.Сөнгатинең “Хозер” поэмасы исә карт архетибын яңартуы белән үзенчәлекле. Әсәр берничә катламның синтезы рәвешендә иҗат ителгән. Мифологик катламда лирик герой, юлда туктап, чанасына утырткан картның язмышы тасвирлана. Картның Хозер пәйгамбәр икәнлеге ачыклана. Хозер карт архетибы булып аңлашыла. Ул адашкан лирик геройга юл күрсәтә, аңа ярдәм кулын суза. Ягъни бу әсәр мисалында әлеге образ үзенә хас сакраль функцияне үти: коткара һәм ярдәм итә, дөрес юлга чыгара.

Икенче катлам романтик сурәтләрне бирү белән бәйле. Биредә дә Хозер образы үзәк урынны алып тора. Ул автор тарафыннан яшәешкә бәя бирү өчен кертелә. Карт туган гарәп илен сурәтләү аша, ул кешелекнең кол хәлендә яшәве, бозыклыгы, бер-берсен үтерүгә кадәр барып җитүе һәм талау белән шөгыльләнүен җәмгыятьне юкка чыгаруга китерүче төп шартлар икәнлекне ассызыклый. Димәк, автор фикеренчә, явызлыкның чыганагы – кешеләрнең үзләрендә.

Картның чикмәне тетелеп беткән, бүреге кырык җирдән ямалган, чабатасы иске. Бу сурәтләр аша автор әсәренең төп

идеясен җиткерә. Кешелектә аклыкка омтылыш юк, ул яхшылыкны явызлык белән алыштыра. Бездә хаос хөкем сөрә, ил сәясәте, бетмәс сугышлар изгелекнең, рухи чисталык, сафлык, олы җанлылык кебек сыйфатларның җир йөзеннән юкка чыгуына китерәчәк. Әсәрнең экзистенциаль асылы шуннан гыйбарәт.

Б.Мирзановның “Җен туе” поэмасы җеннәр тормышы аркылы идеаль яшәеш моделен тергезүе ягыннан кызыклы. Әсәрдәге реалистик башлангыч чынбарлыкны сурәтләүгә, яшәеш тәртипләрен ачып бирүгә багышлана. Биредә хронотоп буларак билгеләгән көз сурәте яшәешкә символ булып килә. Көз җитү илдәге гаделсезлекләр, сугыш китергән афәтләрне аңлата. Әсәрнең башыннан ахырына кадәр кабатланган җил тавышы образы исә чорның шыксызлыгын, куркынычлыгын көчәйтү вазифасын башкара. Кара буран, котырган кар, көчле җил кешелекнең яшәешенә метафора булып килә. Җәмгыятьтә шулай тәртипсезлек, хаос хөкем сөрә, алга бара торган юл билгесезлек томаны белән капланган.

Җен туен күрү вакыйгасы мифологик катламның эчтәлеген тәшкил итә. Ислам мифологиясе буенча, җеннәр явыз көчләрне гәүдәләндерә. Алар кешеләргә авыру, зәхмәт китерү, юлдан яздыру белән шөгыльләнәләр, шулай ук христиан динендә дә алар тискәре мәгънәдә атап йөртеләләр [7; 92]. Әмма бу әсәрдә җен образына үзгә мәгънә салына. Җен туе биредә символ дәрәҗәсенә күтәрелеп, чынбарлыкка каршы куела, кешеләрнең якты киләчәк, матур тормыш турындагы хыял-өметләрен гәүдәләндерә. Шул рәвешле автор яшәп килгән мифны кире кага, “үзгәртеп кора”. Б.Мирзанов, җеннәрнең яшәешен ямьсез, кырыс чынбарлыкка каршы куеп, кешене якты киләчәккә өмет кенә дөнья ямьсезлекләреннән коткарып кала ала дигән фикер үткәрә.

Ислам мифологиясенә йөз тоткан әсәрләр, нигездә, демифологизация – яшәп килүче мифны кире кагу, юкка чыгару юлы белән иҗат ителгән. Бу күренеш авторларга кешелек яшәешендәге явызлыкны илаһи югарылыкта хәл итәргә һәм аның дәрәҗәсен көчәйтергә ярдәм итә.

XX йөз башы поэзиясендә төрки-татар ышануларына бәйле мифологик образлар да яратып кулланыла, ләкин алар күпчелекне тәшкил итми. Мәсәлән, Г.Сөнгатинең “Су анасы”,

И.Шаммаси “Убыр”, Г.Харисның “Өрәк” кебек поэма-балладаларында төрки-татар ышануларына бәйле Су анасы, Убыр, Өрәк кебек мифологик образлар яңартыла. Алар да символик яки аллегорик яссылыкта кешелек яшәешенә, кеше күңеленә бәя бирүне максат итә һәм экзистенциаль фәлсәфәне үткәрә. Мифологик образлар үзләре дә күп очракта явызлык, авырлык, ямьсезлек символлары булып тәгәлләшә. Бу образлар үзләренең борынгы мәгънәви калыбын саклый, шуңа бәйле төстә мифологизация күренеше алга чыга.

Мәсәлән, “Су анасы” поэмасында мифологик образ кешеләрнең, тормыш авырлыгыннан, ямьсезлектән юану табу өчен, саф мәхәббәт турында хыяллануын гәүдәләндерә. Ул матур, әмма салкын. Әйтерсең лә, автор бу яшәештә матурлыкка, мәхәббәткә урын юк дигән фикер үткәрә. Ямьсез көз, залим төн метафорик образлары да яшәешкә бәя бирү өчен кулланыла. Шул рәвешле автор тормышның авырлыгына, караңгылыгына, залимлегенә ишарә итә. Һәр кешенең артыннан канга туймас Иблис күзе – сәясәтнең, яшәүнең явызлыгы шымчылык итүе – ямьсез чынбарлыкка хәсрәтләнү хисенең дәрәҗәсен тагын да арттыра.

Габдулла Харисның “Өрәк” поэмасы (1915) – реалистик, мифологик һәм символик катламнарның синтезы төсендә иҗат ителгән романтик әсәр. Бу әсәрдә өрәк образы көчләп юк ителгән ирек, хөр тормыш, хакыйкать кебек аңлашыла.

Ә Имаметдин Шаммасиның “Убыр” лиро-эпик әсәре (1914) болардан берникадәр үзгәрәк характерда булуы аерылып тора. Мифологик катламда бер егеткә Убыр иялəшүе, төнлә янына килеп, таңга кадәр торуы турында сөйләнә. Имаметдин Шаммаси, Убырның сатирик сурәтен тудырып, демифологизация күренешенә мөрәҗәгать итә. Ул биредә символ булып тәгәлләшә. Әлеге образ – кеше күңелендәге явызлык, ямьсезлек символы. Шул чор яшәешенең төп үзенчәлекләре дә – явызлык, ямьсезлек, хәерчелек. Кеше тормышның тышкы матурлыгына, алдавыч вәгъдәләренә ышанып яши бирә. Ә чынлыкта кеше күңелендә икейөзлелек патшалык итә. И.Шаммаси әнә шулай кеше рухының моделен торгыза.

Шул рәвешле, ике гасыр чигендә поэзиянең яңадан-яңа мифологик образларны шигъри мәйданга кертүе, булганнарын да заманча фәлсәфәгә төреп тәкъдим итүе сүз сәнгатенең яңарышын, дөнья әдәбиятына йөз тотуын тагын бер кат дәлилли.

Чыганаклар

1. Гудкова С.П. Миф и способы поэтического освоения в художественной системе А.А.Фета / С.П.Гудкова // Литература: миф и реальность. – Казань: Издательство КГУ, 2004.

2. Давыдова Т. Теория литературы: Учебное пособие / Т.Давыдова, В.Пронин. – М.: Логос, 2003.

3. Ибрагимов М.И. Миф в татарской литературе XX века: проблемы поэтики / М.И.Ибрагимов. – Казань: Gumanitaria, 2003.

4. Краткая Литратурная Энциклопедия. – Т.4. – М.: Советская литература, 1967. – 877 с.

5. Лосев А.Ф. Философия. Мифология. Культура / А.Ф.Лосев. – М.: Политиздат, 1991. – 525 с.

6. Мелетинский Е.М. От мифа к литературе. Курс лекций “Теория мифа и историческая поэтика” / Е.М.Мелетинский. – Москва: РГДУ, 2001.

7. Мифология. Энциклопедия / Гл. ред. Е.М.Мелетинский. – М.: Болҗшая Российская Энциклопедия, 2003. – 736 с.

8. Тахо-Гади А.А. Миф у Платона как действительное и воображаемое / А.А.Тахо-Гади // Платон и его эпоха. – М.: Наука, 1979.

9. Урманче Фатих. Татар мифологиясе / Ф.Урманче // Фәнни эзләнүләр юлында. – Казан: Фикер, 2000. – 102-134 б.

Хәкимов Б.Э.

Русча-татарча икетеллелек шартларында профессиональ телдән тәрҗемә һәм аңа өйрәтүнең кайбер мәсьәләләре

Бүгенге көндә татар теле тирән үзгәрешләр чорын кичерә. Төрле объектив һәм субъектив кыенлыкларга карамастан, аның дәүләт теле буларак гамәлгә керү процессы дәвам итә. Шушы шартларда татар лингвистикасы алдында телебезнең потенциаль мөмкинлекләрен тормышка ашыру бурычы куела. Хәзерге

вакытта, иң беренче чиратта, татар теленең функциональ үсеше, ягъни аны иҗтимагый тормышның барлык өлкәләрендә дә кулланышка кертү мәсьәләләре алгы планга чыга.

Хәзерге русча-татарча икетеллелек шартларында татар теленең функциональ үсеше өчен тәрҗемә эшчәнлегенең әһәмияте аеруча арта, бу эшчәнлек югары профессиональ дәрәҗәдә оештырылырга тиеш була. Шуңа бәйле рәвештә, тәрҗемәче белгечлегенә өйрәтүнең аерым мәсьәләләренә тукталып үтәбез.

Мәгълүм булганча, тәрҗемәнең ике төп формасы бар: язмача һәм телдән тәрҗемә. Аларның һәрберсенең дә тел үсеше өчен үз әһәмиятләре бар, шулай ук һәр ике төр дә даими үзенчәлекләргә ия [1]. Шул сәбәпле, укыту процессында язмача һәм телдән тәрҗемә өчен кирәк булган махсус белем һәм күнекмәләргә аерым игътибар бирелә, һәм, гадәттә, телдән тәрҗемә махсус фән буларак укытыла.

Язмача һәм телдән тәрҗемәнең мәгълүм темпораль (башкарылу вакыты һәм рәвеше ягыннан), лингвистик, коммуникатив һәм башка даими үзенчәлекләренә кагылмыйча, аларның хәзерге татар җәмгыятендә тоткан урынына һәм, шуннан чыгып, иҗтимагый актуальлегенә игътибар итик. Бүгенге көндә белем бирү системасы җәмгыять таләпләренә, базар икътисады шартларына җавап бирергә тиеш, шуңа күрә югарыда әйтелгән мәсьәләләр тәрҗемәчелек эшенә өйрәтүнең эчтәлеген билгеләүдә турыдан-туры катнаша.

Русчадан татарчага яки татарчадан русчага телдән тәрҗемә эшчәнлегенең хәзерге хәленә килсәк, аның бик нык чикләнгән булуын танырга мәҗбүр булабыз. Бу табигый дә: язмача тәрҗемә тәмамланган һәм “статик” халәттә булган текстлар белән эш итсә, телдән тәрҗемә реаль җанлы аралашу белән аерылгысыз бәйләнгән. Татарстанда исә, иҗтимагый, рәсми, профессиональ һ. б. һәртөрле коммуникация вакытында русча-татарча икетеллелек берьяклы рәвештә генә яши, ягъни барлык коммуникантлар да рус телендә аралаша алалар.

Татарчадан русчага һәм русчадан татарчага телдән тәрҗемә эшчәнлеге түбәндәге очракларда чагыштырмача даими кулланыла:

1) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында (барлык утырышлар да синхрон тәрҗемә белән тәэмин ителә);
2) Халыкара дәрәҗәгә ия аерым рәсми чараларда (Бөтендөнья татарлар конгрессы корылтайларында һ.б.). Бу очракта телдән тәрҗемәнең эзлекле һәм синхрон төрләре кулланылырга мөмкин;
3) Мәхкәмә процессларында (эзлекле тәрҗемә);
4) Кайбер башка очракларда да эпизодик рәвештә кулланылырга мөмкин.

Димәк, татар тәрҗемәчеләрен укытканда төп игътибар язмача тәрҗемә бирелергә тиеш дигән нәтиҗә ясалып, телдән тәрҗемәнең иҗтимагый яктан әһәмиятле булмавы турында фикер туарга мөмкин.

Чыннан да, бүгенге көндә телдән тәрҗемә өлкәсендәге эшләрнең күләме зур түгел, шуңа күрә күп тәрҗемәче кирәк тә түгел. Татарстанда әлеге эш белән шөгыльләнүче практикларның тар гына даирәсе бар һәм алар иҗтимагый мәнфәгатьләрне әлегә канәгатьләндерә.

Шуңа да карамастан, киләчәктә мондый эшләргә ихтыяҗ артыр дип фараз иткәндә һәм тәрҗемәче белгечлеге буенча укучы студентларның һәрьяклап белем алырга тиешлеген исәпкә алганда, телдән тәрҗемәгә кагылышлы белем һәм күнекмәләр тәрҗемәгә өйрәтү эчтәлегендә, һичшиксез, үз урынын алырга тиеш.

Шул ук вакытта, телдән тәрҗемәгә өйрәтүнең хәзерге вакыттагы объектив кыенлыкларын да әйтеп үтәргә кирәк. Иң беренче чиратта, татар теле өчен телдән тәрҗемәнең хосусый теориясе әлегә эшләнмәгән.

Шуннан чыгып, татар телендә телдән тәрҗемәнең хосусый теориясе һәм методикасы өчен актуаль булган лингвистик эзләнү юнәлешләре түбәндәгечә билгеләнә:

1) Татар теле өчен төрле типтагы текстларда уртача “мәгълүмати артыклык” (“избыточность”) күрсәткечләрен ачыклау. Әлеге термин белән тел берәмлекләренең бер-берсе турында мәгълүмат бирә алу үзенчәлеге атала. Тел системасының бу фундаменталь сыйфаты телдән тәрҗемәнең һәм эзлекле, һәм синхрон төрләрендә дә хәлиткеч роль уйный [2, 4];

2) Ике телдәге лексик берәмлекләрнең семантик бәйләнешләрен өйрәнү;
3) Бүгенге көндә телдән ясалган төрле чыгышларны төрле яклап анализлау, ике телдәге сөйләм текстлары арасында лексик, грамматик, стилистик, структур һ. б. даими эквивалентлыкларны билгеләү;
4) Телдән тәрҗемә процессында кулланыла торган махсус язу системасын булдыру. Махсус язу системасы эзлекле тәрҗемә эшчәнлегенең мөһим коралы булып тора [2]. Татар теленең үзенчәлекләренә туры килгән язу системасын булдыру профессиональ телдән тәрҗемә эшен гамәлгә кую өчен әһәмияткә ия;
5) Махсус тематик лексика һәм актив сөйләм гыйбарәләре сүзлекләрен төзү.

Әдәбият:

1. Комиссаров В.Н. Современное переводоведение: Курс лекций / В.Н.Комиссаров. — М.: ЭТС, 2002. – 424 с.
2. Миньяр - Белоручев Р.К. Последовательный перевод: Теория и методы обучения / Р.К.Миньяр-Белоручев. — М.: Воениздат, 1969. – 288 с.
3. Юсупов Р.А. Соотношение разноструктурных языков и вопросы перевода / Р.А.Юсупов. – Казань, 2005. - 225 с.
4. Чернов Г.В. Теория и практика синхронного перевода / Г.В.Чернов. – М.: Международные отношения, 1978. – 208 с.

Хәкимуллина Х.Р.

“Баласы бар кошның күңеле ояда була” (Р.Мингалимнең “Өченче бүлмәдә эт яши” (1980) драмасы буенча)

Драматургның яшьлек, мәхәббәт, гаилә һәм бала бәхете, шәхси тормышта чын кеше булу мөһимлеген алга куйган “Өченче бүлмәдә эт яши” исемле ике бүлекле драмасы 1980 нче елда Мәскәү каласында язылa.

Пьесаның сюжет – композициясе катлаулы түгел. Драмада яшь гаилә тормышы сурәтләнә. Райман белән Гөлия, аларның кызлары һәм гаилә башлыгының әти - әнисе бергәләшеп

тату гына, иркен өч бүлмәле фатирда яшәп яталар. Ләкин башта - этиләре, аннан соң – яраткан бердәнбер кызлары, ахырдан - әниләре вафат булгач, тормыш матурлыгы югала. Өйләренә килгән хәсрәт ир белән хатынны кайгыга батыра, бер- берсеннән читләштерә. Гөлия юанычны үзенең беренче мәхәббәте сыйныфташы Фирдүстә таба. Райман да гаилә җылысын Наридә исемле хатын янында эзли. Ә бит нәкъ шушы чакта аларга бер – берсенең ярдәме, таянычы кирәк була. Мондый фаҗигагә нәрсә китерә соң? Матур итеп торган гаиләне нәрсә җимерә? Икенче төрле әйткәндә, драмада конфликт нинди җирлектә туа? Моны ачыклау өчен персонажларга, аерым детальләргә тукталып китү кирәк.

Гөлия иренең хыянәт иткәнен сизенеп, җитмәгән мәхәббәтне читтән эзли башлый. Беренче мәхәббәте Фирдүснең шәһәргә күченеп килгәнен белүгә, очраша башлыйлар. Ләкин аталучы герой Фирдүснең дәрәҗәле эше (ул – хәрби), гаиләсе бар. Гөлия аның өчен яшьлек хатирәсен яңарту, бер мавыгу гына. Ире Райман хатынының хаталануын күреп тора, ләкин ярдәм итәргә ашыкмый. Үзе дә бит чит хатын кочагында юана. Гөлия ялгышын аңлап, Райманнан гафу үтенә. Ир хатынын кичерми, шулай да үзенең ирлек горурлыгын тынычландыру өчен, бөтен дөньясына ачу белән карый башлый. Райман үз хатынына гына түгел, очраткан, өйләренә шалтыраткан кешеләрдән ачуын ала, үзен агрессив тота. Ләкин үзе генә калган очракларда, кызын сагынып өзгәләнгәндә, без аның күңел йомшаклыгын, йөрәк әрнүләрен күрәбез. Стенада эленеп торган кызының портретына карап, Райман еш кына аның белән сөйләшә, кызын исән кебек хис итә, киңәш сорый.

Моннан Райманның үз гаиләсенең язмышына битараф булмаганлыгы күренә. Димәк, әле өмет бар. Гаиләнең җимерелә баруы, ләкин аны саклап калыра мөмкин булуы көзге детале аша бирелә. Райман белән Гөлия кычкырышканда идәнгә түгәрәк көзге төшеп ватыла. Көзге өчкә ярылган: бу – Райман, Гөлия һәм кызлары. Ләкин таралмаган, тирәсе тотып калган. Бәлки нindидер көч гаиләне саклап калыр.

Кызлары исән чакта гел эт баласы алып кайтуны сораган. Ләкин Райман моңа каршы килә. Кызлары вафат булгач, гаилә башлыгы кызы алырга теләгән көчеккә охшаган эт алып кайта.

Аны бала урынына карыйлар, тәрбиялиләр. Әсәргә килеп кергән эт образы кыз образын дәвам итүче, күпмедер күләмдә аны алмаштыручы булып та килә. Элек өченче бүлмәдә әти - әнисе белән кызлары торган, хәзер исә “Сынок” кушаматлы эт яши. Этләре өйдә булу аркасында гына гына икесе дә өйгә кайтырга мәҗбүр. Этне кызларыннан да ким күрмиләр. Эт – Райман белән Гөлияне бәйләүче, татулыкка, тугрылыкка өндәүче образ булып тора. Гомумән, эт – татулык, тугрылык, дуслык билгесе.

Шулай да кызыклы сорау туа. Гаилә җылысы өйдә асраган җанвар белән генә ныклы була аламы икән? Драмада ретроспекция алымы бык уңышлы кулланылган. Райманның әтисе белән әнисе, ярдәмче геройлар буларак, яшьләргә киңәш бирүче кешеләр. Күпне күргән ана тагын бала алып кайтуны сорый, “ике бала – бер бала, бер бала – юк бала” дип халык мәкальләре белән дәлилләр китерә. Ахырдан “Баласы бар кошның күңеле ояда була. Оясында шатлыгы була” дип өстәп тә куя. Ләкин ир белән хатын төрле сәбәпләр табып, бу мәсьәләне кузгатмаска тырышалар. Һәм нәтиҗәдә кызлары вафат булгач, гаиләнең җимерелү алдында торганын абайламый да калалар. Автор гаилә бәхете бала белән генә тулы була дигән нәтиҗәгә этәрә.

Шулай да укучы зур кызыксыну белән ир белән хатын мөнәсәбәте ничек тәмамланыр икән дип күзәтә. Райман беренче булып тормыш иптәшенә аерылышу турында тәкъдим ясый. Фатир бүлешү, этнең кем белән каласы да билгеләнеп куела. Гөлия язмышка буйсынып, иренең карары белән килешә. Драманың кульминациясе булып, Ризван исемле таксистың Гөлия белән танышуы тора. Таксист аларның гаилә хәлләренән, хәтта сөяркә тотуларыннан да хәбәрдар булып чыга. Чөнки ул Ризван һәм Гөлияне сөяркәләре белән үзенең машинасында еш кына күргән, сөйләшүләренә колак салган, бу гаиләнең тормышы белән кызыксына башлаган. Шулай итеп, Ризван бу ике кешенең гаиләсенә килеп керә, гаиләдәге атмосфераны көйләүче рольдә килә. Аның кызыклы күзәтүләре, тормыш фәлсәфәсе дә бар: “Гаилә дигән нәрсә ул шулай сәер дөнья икән. Аның үз гомере, үз төне була икән... үз күгендә – үз ае, үз йолдызлары яна. Әгәр анда “әти”, “әни”, “улым”, “кызым” дигән төшенчәләр асыл сыйфатларын югалтса, ир, хатын, малай, кыз дигән затлар гына калса – бетте дигән сүз... алар арасында мәрхәмәт җитмәс. Алар

дөньясы – каты, җайсыз булыр. Тирә - юньгә дә салкынлык биреп, ул дөнья таркалыр” [Мингалим, 1990, 181]

Автор Ризван ярдәмендә фәлсәфи фикерләр уздыра, гомумкешелек кыйммәтләрен беренче планга чыгарып карый. Егетнең ниятләре изге. Ул кешеләрне бер-берсенә мәрхәмәтле булырга, хөрмәт итәргә өнди. Шундый ният белән ул Райманнарга килә һәм үз хәлен, йөрәк белән акыл тартышуының сәбәбен күрсәтмәкче була. Ирләр белән хатыннар арасындагы төрле мөнәсәбәт, хыянәт итүләр егетнең гаиләгә булган карашын үзгәртәләр. Гаилә кору, балалар үстерү ниятенә ышаныч югалтуга китерәләр.

Ризванны бик күп сораулар борчый. Өйләнешкәннәргә ни җитми? Ни өчен матур яши алмыйлар? Таксист үзенең шәхси тормышын җайланмавында да Ризван белән Гөлия кебекләрне гаепли. Гаилә нигезе бер-береңә ышануга, тугрылыкка корыла дип фикерли егет. Эпизодик герой Лу (Луара) белән мөнәсәбәтләре дә шушы җирлектә ачыла. Ирдән аерылган хатын Лу “хатын-кыз барын да сөйләмәскә тиеш” дигән позициядә тора, ир дигән затка ышанып бетми. Нәтиҗәдә Ризван белән Лу барыбер бергә калмыйлар, хатын кире элекеге иренә кияүгә чыга.

Шулай итеп, драмада конфликт аңлашылмаучылыкка корылган. Ул гаилә эчендә генә калмый, аның җиле башка кешеләргә дә кагыла. Хәтта кешеләрнең язмышларына да тәэсир итә. Гаиләдә туган аңлашылмаучанлык, ышанычсызлык, шәхси проблемалар үз кысаларында гына чишелергә тиеш. Бер-береңне аңларга тырышу, проблемаларны вакытында хәл итргә омтылу күп кенә бәлалардан азат итәр иде.

Гомумән, әхлакый савыгу проблемасы Р.Мингалим иҗатында киң мәйдан ала. Әхлаксыз Райман белән Гөлиягә капма-каршы итеп әхлаклы, инсафлы кеше – Ризван куелган. Әхлак кануннарының көче шунда, алар кешенең аңында яши, туымыштан килә. Ризван – авылда туып-үскән саф, пакъ күңелле кеше. Бер-береңә шәфкатьле булу, хөрмәт күрсәтү аның канына сеңән.

Драматург бу герое аша үзенең фикерләрен укучы-тамашачыга җиткерә. Ризван тәэсирендә ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләр көйләнә.

Драманың чишелеше булып Гөлия белән Райманның уллары туу һәм бәхетле ата белән таксист Ризванның аны алып кайтырга җыенулары тора. Райман кызларының дәвамчысы булган “Сынок”ны күз алдыннан югалтырга, Гөлиянең күңелен яраламас өчен, башка җиргә урнаштырмакчы була. Монда да таксист ярдәмгә килә, этне авылга кайтарырга килешә.

Автор укучыга матур бетем тәкъдим итә. Райман белән Гөлия гаиләне торгызуның соңгы өмете бала тудыруда, тәрбияләүдә икәнне аңлыйлар. Баласыз дөнья – буш дөнья. Бала ул – гаиләнең шатлыгы-сөенече, күңел җимеше, ата-ананың бәгырь парәсе, әби-бабасының юанычы.

Татар драматургиясе әхлак темасына язылган әсәрләргә бай. Р.Мингалим дә әхлакый савыгу мәсьәләсенә яңача, үзгә итеп, югарырак баскычка менеп, фәлсәфи күзлектән караган. Без моны таксист Ризван образында күрәбез. Пьесаның исеме дә “Өченче бүлмәдә эт яши” шартлы рәвештә алынган. Яктыртылган проблема әсәр исеменә үк метафора итеп чыгарыла. “Өйнең яме бала белән” дигән борынгылар. Авторның бу темага игътибар бирүе хуплауга лаек. Халыкның традицион әхлак нигезләрен яклау пьесаны тамашачы күңеленә якынайта.

Әдәбият

1.Татар әдәбияты: Теория. Тарих/ Д.Ф.Заһидуллина, Ә.М.Закирҗанов, Т.Ш.Гыйләҗев, Н.М.Йосыпова. – Тулыл. 2 нче басма/ Д.Ф.Заһидуллина. – Казан:Мәгариф. – 2006. – 319 б.

2.Мингалим Р. Тау астында илле бүре: Пьесалар/ Р.Мингалим. –Казан: Тат.кит.нәшр. – 1990. – 312 б.

Хәмидуллина Г.Н.

Тел белемендә реклама феномены

Реклама сүзенең тамыры латинча reclamare сүзеннән алынган, француз телендә réclame “кычкырып әйтәм” мәгънәсендә кулланыла. [1 : 1008.]

“Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә рекламаның түбәндәге мәгънәләре урын алган: реклама – 1) файдаланучыларны,

кулланучыларны, сатып алучыларны, тамашачыларны һәм башкаларны тарту, аларның игътибарын җәлеп итү максаты белән үткәрелгән чара. Берәр кеше яисә берәр нәрсә турында популярлык, шөһрәт тудыру максаты белән мәгълүмат тарату; 2) кемнең дә булса да дикъкате өчен берәр кеше яисә берәр нәрсә турында хәбәр-мәгълүмат бирә, игълан итә торган белдерү, плакат, афиша, вывеска һәм башкалар. [11 : 588]

Бүгенгеге көндә татар рекламасына игътибар арта барганлыктан аны төрле юнәлешләрдә: тарихи яктан үсеш-үзгәрешен, лингвистик аспектта реклама текстларының телен, психологик аспектта кешегә тәэсир итү көчен һәм башка үзенчәлекләрен фәнни нигездә өйрәнү ихтыяҗы туа.

Көнбатыш галимнәре тарфыннан реклама журналистиканың бер төре, яисә бер өлеше буларак түгел, ә икътисадый фәннәр рәтенә кертеп өйрәнелә. Реклама күренешен өйрәнгән Г.Сэмпсон, Б.Элиот, Ф.Пресбери, Ф.Джефкинс, Ч. Сэндидж, Г. Фрайбургер, К.Ротцолл кебек көнбатыш галимнәрнең хезмәтләре моның дәлиле булып тора. Базар мөнәсәбәтләре алга киткән илләрдә реклама исәп-хисапка нигезләнгән кампания буларак кабул ителә, ул билгеле бер үрнәктәге формулалар, сораштыру, рейтинг һәм мониторингка таянып оештырыла. Россиядә исә реклама гуманитар фәннәр кысасында карала. Кинематография, драматургия, матур әдәбият кебек үк реклама текстларында да төп игътибар сүз һәм психологизмга юнәлдерелгән. Халыккүләм масса чараларын өйрәнүче галимнәр тыңлаучы яисә укучы аңын визуальләштерү турында сүз куертсалар да, рекламаны өйрәнгәндә алгы планга аның тексты куела.

Соңгы вакытларда реклама лингвистик тикшеренүләр игътибары үзәгендә тора. Күп кенә телчеләр һәм журналистлар фикеренчә, рекламаның әле дә бердәм билгеләмәсе юк, ә бу исә реклама феноменының катлаулылыгы турында сөйли. Шуңа да карамастан, галимнәр тарафыннан бирелгән билгеләмәләргә нигезләнеп, рекламага хас булган ике төп функция турында сүз йөртә алабыз, алар – хәбәр итү һәм тәэсир ясау функцияләре.

Реклама текстларын өйрәнүче рус галимнәре Н.Н. Кохтев һәм Д.Э. Розентальның “Язык рекламных текстов” хезмәтендә рекламаның хәбәр итү яисә мәгълүмат бирү функциясе

түбәндәгечә билгеләнә: “Реклама игълан формасында тормышка ашырыла, ул безгә товарның үзенчәлекләре, аны куллану ысуллары, сыйфаты һәм сату урыны турында күбрәк мәгълүмат тупларга ярдәм итә”.[10 : 7] Тәэсир итү функциясе 80 нче елларда өстенлек иткән идеологиягә нигезләнгән: “Социалистик рекламаның төп бурычы - кешеләрдә кызыксыну уяту, аларның ихтыяҗын канәгатьләндерү”.[10 : 8] Элеге рекламага бирелгән характеристика башка телчеләр хезмәтендә дә күзәтелә, әйтик, Г.К. Воронов, К.А. Павлов, В.В. Глазунов, Д.В. Беклешов һ.б.

Югарыда атап үтелгән функцияләрнең бердәмлеген һәм шул ук вакытта мөстәкыйльлеген исәпкә алып, кайбер авторлар реклама текстларын мәгълүмати (таныштыру) һәм тәэсир итү максатыннан төзелгән төрләргә аерып карыйлар. Хәзерге вакытта реклама текстларын өйрәнүче галим В.В. Тулупов, мәсәлән, рекламаны стильләргә бүлеп өйрәнүне кулай күрә, ул мәгълүмати, тасвирлы һәм мәгълүмати-тасвирлы реклама стильләрен аерып чыга.[12 : 45]

Рекламадагы мәгълүмат аның төп үзенчәлекләрен билгеләргә мөмкинлек бирә. Әлеге мәгълүмат ике төп структур компоненттан гыйбарәт. Беренчесе – сигматик яисә тулы информация. Әлеге мәгълүматны тапшыруның төп ысулы – авербаль ысул, чөнки вербаль билгеләр кулланган очракта сигматик информациянең бер өлеше югалырга мөмкин. Бу, үз чиратында, реклама текстларын төзүчедән тапкырлык, уйлап табу сәләте һәм сүзне дөрес итеп һәм урынлы куллануны таләп итә, бары шул очракта гына эмоциональ йогынты ясауга ирешеп була. Бу яктан игълан текстлары матур әдәбият текстларына охшаш, реклама матур әдәбият стиленә якын тора. Шулай итеп, мактау һәм күтәренке рухта иҗат ителгән мәдхияләрне дә реклама буларак кабул итеп була.

Икенче структур компонент – прагматик (гамәли яктан мөһим булган) информация. Әлге төр мәгълүмат беренче чиратта сүз ярдәмендә (вербаль ысул) җиткерелә, шулай ук математик символлар, диаграмма һәм сызымнар да кулланыла. Бу очракта вербаль билгеләр төгәл, кыска һәм аңлаешлы, бер мәгънәгә ия булырга тиеш, ә бу, үз чиратында, рекламаны рәсми стильгә

якынлаштыра. Әйтик, гади рецепт яисә техник күрсәтмәләр дә реклама буларак каралырга мөмкин.

Шулай итеп, реклама ул сигматик һәм прагматик мәгълүматның бердәмлеге. Бары тик әлеге үзенчәлекләрне исәпкә алганда гына, рекламага хас булган тел үзенчәлекләре турында әйтеп була. Аңлашыла ки, рекламага хас булган сыйфатлар теләсә кайсы текстта да күзәтелергә мөмкин, бигрәк тә публицистика һәм вакытлы матбугат стилендә. Элеге стильләр кысасында рекламадан гыйбарәт мәкалә, репортаж, интервью, каталог кебек жанрларны да билгеләп узарга кирәк.

Күпчелек галимнәр фикеренчә, реклама стиле – ул мөстәкыйль күренеш һәм аның тел үзенчәлекләре типик реклама мисалларында каралырга тиеш, шул ук вакытта аның нигезен тәшкил иткән психо- һәм социолингвистик концепцияләрне дә исәпкә алырга кирәк.

Әгәр дә гади сатучы яисә сатып алучы өчен реклама бары тик сәүдәне алга этәрүче чара булса, тел белгече өчен ул, иң беренче чиратта, текст, һәм әлеге текстның төп бурычы потенциаль тамашачы, укучы яисә тыңлаучыга (реципиентка) таләпчән мөрәҗәгать. Оптималь оешкан очракта әлеге текст тулысы белән мәгълүматны тапшыру һәм кабул итүгә нигезләнгән психологик кануннар белән билгеләнә, ә алар, үз чиратында, телнең үз принциплары, психология, риторика, семантика ярдәмендә тормышка ашырыла.

Реклама текстларын тикшерү нәтиҗәләренә таянып, күп кенә галимнәр әлеге текстларга хас булган типик сыйфатларны күрсәтәләр. Алар түбәндәгеләр:

- реклама тектслары күләм ягыннан кыска, аңлаешлы һәм төп максатка – сатып алучыны җәлеп итүгә хезмәт итәргә тиеш;
- реклама текстларының уңышлылыгы белдерүнең тулысынча яисә кайбер өлшәләренең даими кабатланып килүендә;
- кыска сүзләр, җыйнак фразалар һәм абзацлар белдерүнең күрсәмтәлелеген арттырырга ярдәм итәләр, ә бу исә, аның тиз укылуына һәм үзләштерелүенә этәргеч;
- реклама текстларында сатып алучыга мөрәҗәгать, аның белән диалог төзү шулай ук мөһим фактор, бигрәк тә бу

чара тойгылы һәм иператив конструкцияләр ярдәмендә тормышка ашырыла;

Реклама тексты укучыга, тыңлаучыга өч яссылыкта: эмоциональ-хисси, мантыйкый (логик) һәм эстетик тәэсир ясый. Башта хис-тойгы тудыру чаралары тәэсир итә, аннары аерым логик дәлилләр белән беркетелә, эмоциональ һәм мантыйкый чараларның һәр аерым шәхескә үзенчә йогынты ясарга кирәклеген истә тоту сорала. Чөнки һәр укучы, тыңлаучы рекламаны төрле хисси халәттә кабул итә: шатланып куя, кызыксынып китә, аптырап-гаҗәпләнеп ала, күңеле күтәрелеп, очынып-канатланып китә.

Шул ук вакытта мантыйкый процесс белән бәйле хис тәэсирләре дә чагыла: кисәтү, өндәү, үтенү, төшендерү, ышану.

Зиһенгә алу асылда өч төрле була: 1) бу мәгълүматны адресатның кабул итәсе килә, ул аны көткән, игълан ителүен теләгән. Ул шундук төшенә, хәтеренә алып куя, зиһенендә тота; 2) бу мәгълүматка очраклы юлыга; 3) бу мәгълүмат бу кешегә шушы мәлдә кирәк түгел, укучы, тыңлаучы аңа бөтенләй игътибар итми.[10 : 16]

Реклама текстларында урын алган милли һәм массакүләм мәдәният элементлары дискурс ноктасыннан караганда, билгеле бер стереотипларга бәйләнгән. Бу очракта дискурс эчтәлегенә хәбәрләмәнең адресатына тәэсир итү төшенчәсе салынган.[2 : 114] Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, монда реклама тексты бары тик тел аспекты ягыннан тикшерелә. Телдән тыш чаралар (сурәт, төсләр, музыка һ.б.) белән тәэсир итү арткы планга чыга.

Реклама текстларындагы милли мәдәният элементларын куллану гомуми архетипларга нигезләнгән стереотипларның активлыгына китерә. Бу архетипларда, үз чиратында, нәселдән-нәселгә күчүче үткән буынның тәҗрибәсе гәүдәләнә.[9 : 17] Гамәлдә яисә реклама текстларында милли мәдәният элементларыннан файдалану милли геройлар исемен кулланудa, милләт тарихында урын тоткан мөһим вакыйгаларга мөрәҗәгать итүдә чагыла. Реклама текстлары кыссасына әкияти яисә фольклор образлар һәм мотивлар кертү шулай ук милли мәдәният элементларының бер төре.

Соңгы вакытларда милли мәдәният элементлары татар рекламаларында да кулланыла башлады. Мәсәлән, 2006 нчы ел Татарстан Республикасында әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан ителгәнлектән, “Татарстан – Яңа гасыр” телеканлында, урам щитларында халкыбызның мәшһүр шәхесләре һәм татар мәдәниятендәге мөһим вакыйгалар турында социаль типтагы рекламалар еш күренә башлады. Мәсәлән, татар әдәбиятының үсешенә зур өлеш керткән шагыйрьләребез Габдулла Тукайның тууына 120 ел, Муса Җәлилнең тууына 100 ел булуы турындагы мәгълүматлар, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры 100 нче сезонын билгеләп үткәнлеге хакында игъланнар шундыйларга керә.

Милли массакүләм элементлары исә аралашу процессында альтернатив мәгълүмати чыганаклардан алынган тәҗрибәгә нигезләнә. Милли мәдәният элементларыннан аермалы буларак массакүләм мәдәният элементларына хас стереотиплар турыдан-туры аңга тәэсир итәләр. Массакүләм мәдәният гомуми кулланылышка юнәлдерелгән мәдәни кыйммәтләр булдыруны белдерә.[6 : 71] Реклама текстларында массакүләм мәдәният чаралары реклама кысасында товар яисә хезмәтне популярлаштырган танылган артистлар, спортсменнар һәм башка чыганаклардан файдалануда, төрле яшьтәге кешеләргә, профессияләргә хас сленглар куллануда чагыла.

Әйтик, бүгенге көндә татар массакүләм мәгълүмат чаралары татар телен пропагандалау, туган телеңә хөрмәт уяту максатыннан акцияләр үткәрелә. Бу чараларның үткәрелү вакыты һәм урыны, ә иң мөһиме максаты матбугат, телевидение һәм радио аша хәбәр ителә. Әйтик, “Татарстан – Яңа гасыр”, “Татар радиосы”, “Курай” радиосындагы рекламаларны еш кына танылган театр артистлары, сүз осталары укый. Кайберләре популяр җырчылар тарафыннан башкарыла.

Нәтиҗә буларак шуны әйтергә кирәк, реклама ул социаль-психологик күренеш, теләсә кайсы мәгълүмат шәхеснең һәм социаль төркемнең танып белү, эмоциональ аспектына йогынты ясый. Проблема шунда ки, көнчыгыш илләреннән аермалы буларак татарларда әлегә татар халкының милли гореф-гадәтләрен, яшәү рәвешен, мәдәни хәзинәләрен исәпкә алган

милли реклама индустриясе барлыкка килмәгән. Татар рекламасының уңышы халыкның психологиясен, аның этнопсихологик үзенчәлекләрен, зәвыгын өйрәнүдән дә тора. Татар рекламасын иҗат иткәндә, аны өйрәнгәндә дә халыкның менталитетын, гореф-гадәтләрен, шулай ук җенес һәм яшь үзенчәлекләрен дә исәпкә алырга кирәк.

Әдәбият

1. Большой энциклопедический словарь. 2-е изд. Переработанное и дополненное. – М.: Большая Российская Энциклопедия, СПб: Норинт, 1999. – 2590 с.
2. Головко Б.Н. Деловые издания: Информационный менеджмент массовой коммуникации. / Б.Н.Головко. – СПб.: Изд-во Михайлова В.А., 2005. – 247 с.
3. Джефкинс Ф. Реклама: Учебное пособие для вузов / Перевод с англ. под ред. Б.Л. Еремина. – М.: ЮНИТИ-ДАНА, 2002. – 543 с.
4. Каримова Л.И. Этнокультурные особенности восприятия рекламы // Вопросы психологии: Научный журнал. – 2003. – № 6. – С. 52–55.
5. Корнилова Е.Е., Гордеев Ю.А. Слово и изображение в рекламе / Е.Е. Корнилова, Ю.А. Гордеев. – Воронеж: Издательство «Кварта», 2001. – 224 с.
6. Красова Е.Ю. Социология рекламной деятельности. / Е.Ю. Красова. // Акценты. Новое в массовой коммуникации. Альманах. Выпуск 7-8 (50-51). – Воронеж, 2004. – 95 с.
7. Мурашов А.А. О некоторых особенностях языка рекламы // Русский язык в школе. – 2004. – № 4. – С. 82–86.
8. Низамов. И.М. Татар рекламы һәм матбугат. / И.М.Низамов. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1997. –110 б.
9. Практическая психология для менеджеров. – М.: Филинъ, 1997. – 250 с.
10. Розенталь Д.Э. Кохтев Н.Н. Язык рекламных текстов. / Д.Э. Розенталь, Н.Н. Кохтев. – М.: Высшая школа, 1981. – 125 с.
11. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. II том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – Б. 588.

12. Тулупов В.В. Российская пресса: дизайн, реклама, типология / В.В. Тулупов. – Воронеж, 1996.

Хәсәнова А.М.

Әдәбият белемендә жанрлар төрлелеге мәсьәләсе.

Әдәбият төрле чорда төрле әдипләр тарафыннан иҗат ителгән әсәрләрдән гыйбарәт. Әсәрләр бер-берсеннән куелган проблематикасы, идеясе, сюжет-композицисе, формалары белән аерылып торсалар да, барлык әдәби әсәрләрне берләштерүче үзенчәлекләр дә бар. Әлеге сыйфатлардан чыгып, әдәби әсәрләрне төрләргә аерлалар.

Әдәби әсәрләрне диференцияләү мәсьәләсе борынгыдан алып бүгенге көнгә кадәр яшәп килә. Әдәби эзләнү процессының һәрбер этабында яңа чишелеш юллары, яңа приоритетлар табыла, эмма Платон һәм Аристотель (б.э.к. V-IV г.) заманыннан башлап әдәби әсәрләрне өч төргә бүлү принцибы – эпос, лирика, драма - үзгәрешсез булып кала. Эпик төр язучының тышкы тирә-якны әдәби тасвирлауга нигезләнә. Лирик - шагыйрьнең теге яисә бу тормыш күренешләренә карата хис-тойгыларын белдерү ярдәмендә барлыкка килә. Драматик ысул үзендә эпик һәм лирик төрләрнең мөмкинлекләрен берләштерә – катнашучыларның уйнау вакытында чагылдырган төрле характерлар пьесада лирик гәүдәләндерү рәвешендә күрсәтеләләр [2. 213].

Әдәби төрләр үзләре генә әдәби әсәрләрнең формалары була алмый, алар бары тик тасвирлауның гомум принципларын чагылдыруга сәләтле. Әлеге принциплар эпик, лирик һәм драматик формаларның әдәби үсү процессында барлыкка килгән һәм үскән күптөрлелегендә тормышка ашалар. Эпик сурәтләү эпопеяда, хикәя, повесть, роман, очерк төрләрендә гәүдәләндерелә. Лирик ысул кулланылышын элегия, һөҗү, багышлауда тапкан булса, драма төренең гомум принциплары трагедия, комедия, драмада тормышка аша. Болардан тыш, әдәби төр формаларының кайберләре аерым төркемчәләргә бүленә. Мисал өчен, романны социаль-психологик, фәлсәфи, тарихи, маҗаралы төрләрен беләбез.

Әлеге фактлардан чыгып, әдәбият белемендә өч төшенчәне аерып чыгару күздә тотыла: рус телендәге теоретик хезмәтләрнең күпчелегендә алар род, вид һәм жанр дип аталса, татар тел белемендә әлеге төшенчәләрне төр, жанр һәм жанр формалары дип билгеләү кулланышка кергән [1. 219].

Иң даими, фундаметаль - гомүм төшенчә булып “төр” саналса, жанрлар һәм жанр формалары ниндидер үзгәрешсез, мәңгелек төшенчәләр була алмый. Алар әдәби фикер эволюциясенә бәйле рәвештә барлыкка киләләр, теоретик аңлашылалар, үсәләр һәм үзгәрәләр. Әдәби әсәрләрне жанрларга бүлүнең бердәм принцибын аерып чыгару җиңел түгел. Бүгенге көнгә кадәр жанр теориясен булдыру әдәбият белеменең проблематик сорауларының берсе булып санала. Әдәби әсәрләр барыннан да элек, меңләгән язучыларның күп гасырлык иҗат тәҗрибәсе һәм шул ук вакытта даими үсә барган укучы ихтыяҗларына бәйле туалар. Икенче төрле әйткәндә, жанрлар төрлелеге дә әдипләрнең теләк – омтылышлары, иҗат манералары, әйтергә теләгән фикерләре белән укучыларның идея-танып белү ихтыяҗларына ярашлы барлыкка киләләр, гасырлар буе камилләшәләр. Ләкин еш кына язучылар авторитеты жанр билгеләү эшен кыенлаштыра. Әдипләрнең үзләре иҗат иткән әсәрләренә жанр атамасын бирүе төгәллексезләргә китерегә мөмкин. Мәсәлән, Гоголь үзенең “Мертвые души” әсәрен поэма дип атый.

Жанрларны квалификацияләү мәсьәләсендә тагын бер кыенлык булып аларның атамалары галимнәрнең эзләнү процессында түгел, ә бәлки стихияле рәвештә гасырлар дәвамында, төрле шәһәрләрдә, төрле

телләрдә, әдәби әсәрләрне тудыручылар, укучылар, тыңлаучылар даирәсендә барлыка килүләре тора. Тегe яисә бу шәһәрдә барлыкка килгән жанр атамаларының кайберләре башка шәһәрләргә “күчеп китеп”, башка төрле мәгънәдә кулланыла башлый. Шуның сәбәпле еш кына бер ук атама белән төрле жанрдагы әсәрләр белдерелә һәм, киресенчә, бер үк жанр төрле илләрдә төрле атамага ия була башлый [4. 231]. Шул ук вакытта әдәбият составында бер жанр белән дә бәйләнеше булмаган әсәрләрнең барлыкка килүе дә күзәтелә, мәсәлән, күп кенә драматик әсәрләр нейтраль “пьеса” атамасы астында иҗат

ителәләр, бернинди жанр класификациясенә кермәгән күпсанлы лирик шигырьләр барлыкка килә.

Әдәбият белеменең иң башлангыч этапларында жанрларны аеру максатыннан беренче планга формаль аспект чыгарыла. Һәрбер жанр үзенең махсус әдәби чараларга ия була башлый. Сурәтләү предметы, төзелешенә караган катгый таләпләр барлыкка килә, жанрлар арасындагы ачык һәм аңлаешлы чикләр булдырыла, индивидуаль авторлык инициативасы исә игътибардан читтә кала. Әлбәттә, Гораций, Ю.Ц. Скалигера, И.Н. Буало кебек галимнәр тарафыннан жанр төрлелеген катгый кыссаларга кертү теләге вакыт сынавы узмый, гасыр узу белән каноник таләпләр юкка чыга. Жанрлар бер - берсеннән изоляцияләнгән күренешләр түгел, ә бәлки билгеле бер сыйфатлар җыелмасына ия булган әсәрләр группасы буларак карала башлый.

Жанрлар “специфик сыйфатлар, форма һәм эчтәлек берлегендә әдәби әсәр төре” дип билгеләнә дидек. Иң гомуми планда элеге билгеләмә дөрес һәм классификацион максатларда файдалы да булып тора. Ю.В. Шатин “Жанр теориясенең өч аспекты” мәкаләсендә формалашкан жанр системасында бер берсе белән бәйләнгән өч аспектны аерып карарга тәкъдим итә [5. 6]. Бүленешнең бер аспекты буларак **норматив** аспектны аерып чыгара. Жанрларны төрләргә аеру эшендә иң четрекле мәсьәләләрнең берсе булып, әлеге әдәби әсәрләрнең эчтәлек һәм форма күп төрлелегендә жанрларга хас булган сыйфат һәм билгеләрен аерып чыгару тора. Бер жанрга караган, ләкин төрле вакытта, төрле әдипләр тарафыннан иҗат ителгән әсәрләр кабатлана торган сыйфатларга ия. Роман, комедия, элегия форма, төрле язучы иҗатында үзләренең конкрет төзелешләре буенча аерылып торсалар да, үзләренең кабатлана торган үзенчәлекләре белән роман, комедия һәи элегия булып калачаклар.

Норматив аспект күзлегеннән, жанр магълүм бер сыйфатларның җыелмасы булып тора. Элеге сыйфатлар әдәби структураның төрле якларын (тематик, сюжет-композицион, сөйләм) үз эченә ала. Ю.В. Шатин фикеренчә, аерым алынган әдәби әсәр бар жанрга хас сыйфатларны кулланмый, ә бәлки аның бер өлешенә генә ия була. Шулай да нәкъ менә әлеге “өлеш” ярдәмендә без романны хикәядән, багышлауны

элегиядән, комедияне мелодрамадан аерабыз. Шул ук вакытта жанр әсәрдәге билгеле бер сыйфатларның булуы белән генә түгел, ә башка сыйфаталар җыелмасының юклыгы белән дә билгеләнә ала. Мәсәлән, драманың бер жанр төре булган трагедиянең сюжет нигезе капма-каршы көчләрнең килешүе мөмкин булмаган көчле конфликтка корылган сәхнә әсәре буларак билгеле, әлеге әсәрләрдә ирония элементлары трагедия жанрның дифференциаль билгесе булып тора.

Шулай да, теге яисә бу жанрларга хас булган үзенчәлекләрне әдәби әсәрләрнең форма үзенчәлегендә генә эзләргә ярамый. Әсәр формаларының белдергән идея - эчтәлекләре һәм конкрет үзенчәлекләре белән даими үзгәреп торуын истә тотарга кирәк. Димәк, жанр билгеләүнең тагын өстәмә аспектын аерып чыгару кирәклеге бар.

Жанрны билгеләүнең тагын бер аспекты буларак Ю.В. Шатин **генетик** аспектны тәкъдим итә. Галим фикеренчә, норматив аспект үткән һәм хәзерге көндәге жанрлар системалары арасында бәйләнешне урнаштыра алмый. Моның өчен генетик аспектны аерып чыгару зарур. Әлеге аспект М.М Бахтин тарафыннан киң өйрәнелгән. Жанр гомум әдәбият структурасында даими кабатланган сыйфатларны чагылдыра торган билгеләр белән характерлана. М.М Бахтин жанрны "сәнгать хәтере” дип атый, “жанрларда гасырлар дәвамында доньяның билгеле якларын күззалау һәм аңлау формалары тупланып килә”, дип билгели [III. 332]. Әдәби әсәр үзендә бар үткән мәдәни тәҗрибәләрне чагылдыра. Язучы әлеге тәҗрибәне интуитив рәвештә куллана, ягъни чагылдыру надиндивидуаль характерга ия. Бүгенге әдәбият үткәндәге әдәбият тәҗрибәсен үзләштерә, әмма әлеге үзләштерү жанрның генетик билгеләре ярдәмендә тормышка аша. Әдәбиятның һәр яңа үсеш этабында һәм билгеле бер жанрга караган яңа әсәр туганда элеге жанр яңара, көчләнә бара.

Норматив һәм генетик аспект белән беррәттән жанрлар теориясендә мөһим урынны **конвенциональ** аспект алып тора. Ю.В. Шатин жанр конвенциясе астында язучылар һәм укучылар аңында барлыкка килгән күрсәтмәләр системасын, әдәби әсәрләрне теге яисә бу жанр яссылыгында кабул итәргә ярдәм күрсәткән алдан әйтелгән килешмәләрне күздә тота. Галим жанр

конвенциясе төшенчәсе аерым бер әдәби чорга синхрон булырга тиеш дип билгели [5. 6]. Вакыт узу белән, тормыш таләпләренә җавап рәвешендә яңа жанрлар туарга, искеләре төшеп калырга мөмкин. Һәрбер тарихи дәвердә жанрлар үзара төрлечә мөнәсәбәткә керәләр, шул сәбәпле, аерым жанрны аерым чорга нисбәтле түгел, ә бәлки һәрбер чорның жанрлар системасын өйрәнү зарур.

Жанрлар теориясенең әлеге өч аспекты жанрларны аеруда өч төрле карашны чагылдыра. Беренчесе структур аспектларның үзгәрүе белән
(морфология) бәйләнгән, икенчесе - генетик структураларның барлыкка килүенә (этимология), өченчесе жанрларны теге яисә бу чорга нисбәтле карауга (семанитика) нигезләнгән.

Жанрлар хәрәкәтендәге үзгәрешләр, әлбәттә, иҗтимагый тормыштагы үзгәрешләр белән бәйләнгән. Яңа чор әдәбият алдында яңа бурычлар куя, шул бурычларны үтәү ихтыяҗы жанрларның үзгәрүенә, яңа жанрларның тууына, кайберләрнең юкка чыгуына, ягъни бер чорда – билгеле бер жанрларның, икенче чорда исә икенче бер жанрларның активлашуына китерә.

Жанр мәсьәләсе – чынбарлык күренешнең әдәби әсәр эчтәлегенә һәм формасына күчеше. Әдәбияттагы жанр төрлелеге, барыннан да элек, чынбарлыкны сәнгатьчә танып белү ихтыяҗына бәйле барлыкка килә. Күп жанрлылыкның чыганагы булып чынбарлыкның үзе торса, жанрны аңлау һәм өйрәнү мәсьәләсенә карашалар төрлеге, һәрбер галимнең үз тикшерү ноктасы булуы белән аңлатыла. Шулай да барысы да диярлек әлеге категориянең үзәк һәм универсаль булуын ассызыклыйлар. Жанрларда төрле әдәби методларның, мәктәпләрнең, әдәби юнәлешләрнең алымнары чагыла, жанр законнарын тирәнтен өйрәнми торып, әсәрнең тирәнлеген, язучының индивидуаль оссталыгын профессиоанль бәяләргә мөмкин түгел. Әлеге мәсьәлә бүгенге көндә дә үз актуальлеген югалтмый.

Әдәбият:

1. Әдәбият теориясенә кереш: Урта мәктәпләрдә тел-әдәбият укыту өчен кулланма. – Казан: Татар китап нәшр., 1987.- 219 б.

2. Абрамович Г.Л. Введение в литературоведение: Учебник для студентов пед. ин-тов по специальности №2101 “Рус.яз. и лит.”/ Г.Л. Абрамович –М.: Просвещение, 1979. - 352 с.
3. Бахтин М.М.Эстетика словесного творчества/ М.М.Бахтин. - М., 1979. - 435 с.
4. Поспелов Г.Н. Теория литературы: Учебник для ун-тов/ Г.Н Поспелов - М.: высшая школа, 1978.- 351 с.
5. Проблемы литературных жанров/Под ред.Н.Н.Киселева, Ф.З.Кануновой, А.С. Янушкевича. – Томск: Изд-во ТГУ, 1990. – 235 с.

Хисамова Л.А.

Хәзерге татар вакытлы матбугатында варваризмнар

Бер генә халык та изоляцияләнеп яши алмый. Әүәл башка кабиләләр белән, соңга таба төрле халыклар, дәүләтләр белән аралашу нәтиҗәсендә татар теленә теге яки бу телдән алынмалар килеп кергән. Алар телнең төп сүзлек фондын тәшкил иткәннәр, шуларга нигезләнеп, телнең сүзлек составы үсә, үзгәрә, камилләшә, байый барган [2, 58б.]

Төп проблеманы ачыклау алдыннан алынма төшенчәсен ачыклап китик:

Алынма – ул башка телнең элементы булып торган (сүз, морфема, синтаксик төзелмә) һәм бер телдән икенчесенә тел бәйләнеше ярдәмендә күчкән сүз, күп очракларда синтаксик һәм фразеологик әйләнешләр [3, 158б.] Алынмалар телгә яраклашалар һәм хәтта ниндидер вакыт узгач, алынма булып саналудан туктыйлар.

Инглиз алынмалары ягъни англицизмнар безнең телдә күп түгел. Алар күбрәк спорт (*айсинг, нокаут, офсайд* һ.б.), техника (*автокор, стартер, экскаватор* һ.б.), көнкүреш (*бар, бунгало*, *слайд* һ.б.), диңгез эшенә бәйле (*бриг, хачбот, пирс* һ.б.), икътисад (*бизнес, бум, демпинг* һ.б.), күңел ачу (*скетч, твист*, *буги-вуги* һ.б.) һ.б өлкәләргә карыйлар. Ләкин аларны латин, грек, француз алынмалары белән бутап була. Мисал өчен хәзерге көндә шактый популяр булган сүз мобильный (mobile) латин алынмасы , ә штат (state) сүзе алман теленнән

алынганнар. Әлбәттә, алар инглиз сүзлек составына күп еллар элек кертелгәннәр һәм аларның этимологиясе дә онытылып бара. Мисал өчен француз алынмалары: *авангард, идеал, романтизм, туризм* һ.б.

Яки итальян теле аша кергән алынмалар: *арлекин, соната, галерея* һ.б.

Билгеле булганча, бу мисаллар инглиз, рус телләрендә һәм рус теле аша татар телендә актив кулланалар.

Дьков фикеренчә, алынмаларны көнбатыш чыебарлыгын яки текстның стилистик маркировкасын күрсәтү өчен кулланыла, ә рус эквивалентлары рус дөреслеген күрсәтү өчен кулланалар. Мәсәлән: “Караңгылык князе” чип-чиста хоррор, “Вий” – беренче рус куркыныч фильм һ.б [12, 35 б.].

1. Стилистик (эмфатик) эффект булдыру. Мисал итеп Брейтер Мира Пола Андерсенның китабына чыккан рецензия “Аптека. Street. Фонарь” дип аталган иде. Исеме шулай ук интертекстка (Блокның “Төн. Урам. Фонарь. Аптека”... әсәреннән өзеген истә тота) бәйле, дип яза галим. Татар телендә исә эмфатик эффектны күбрәк вакытлы матбугатта кулланалар (бигрәк тә “Татарстан яшьләре” газетасында): Кайбер урыннарны Европа илләрендәге кебек *таун хауслар*, виллалар бизиячәк. (“Татарстан яшьләре”, №52, 2005)

“Таун хаус” (town house) сүзен-сүзгә шәһәр йорты дип тәрҗемә ителә.

2. Позитив һәм негатив коннотацияләр белдерү. Автор фикеренчә, Россиядә яшәүче халыклар арасында, чит ил технологияләре прогрессиврак, чит ил банклары, товарлары яхшырак, ышанычлырак дигән фикер яши. Брейтер уйлавынча, бу фикерләрне беренче чиратта реклама нык куллана. Рекламада алынмалыр позитив коннотацияләрне актуалләштерер өчен кулланалар, ди галим. Мисал өчен: auto-rental фирмалары “машиналар прокатка” урынына, паб сыраханә урынына һ.б. Татар каналларында инглиз алынмаларын кулланган рекламалар соңгы вакытта шактый еш ишетелә. Күбесенчә ул кафе, рестораннар, матурлык салоннарының исемнәре, яки яңа ачылган *маркетлар.* Мәсәлән: *Bodyline Lux*, *Prestige House, Ocean of life, Fit Life, RED FOX, Beeглога* һ.б.

Бигрәк тә 90 еллар ахырында инглиз алынмалары бик нык популярлаша. Вакытлы матбугатта ешрак варваризмнар очрый башлый. Крысин фикеренчә, варваризмнарның соңгы елларда күбәюе иҗтимагый-психологик факторлар белән бәйле. Коллектив фикеренчә, алынмалар абруйлырак, яңгырауда матуррак, дип санала.

Билгеле булганча, соңгы дүрт-биш елда Россия һәм Көнбатыш арасында тыгыз мөнәсәбәтләр урнаша. Бу хәл Россия халыкларының менталитетын үзгәртә башлый, дип күрсәтә Дьяков үзенең мәкаләсендә [12, 40].

Чыннан да, Көнбатышның йогынтысы бик зур. Инглиз сүзләрен сәхнәдә радио-телевидиниеларда бик актив кулланалар: Рус эстрадасында малайлар төркеме модада: “Чай в двоем”, “Smash”, “Примьер министр”. (“Татарстан яшьләре”, №18, февраль, 2005)

Көнбатышта чыга торган журналлар соңгы ун елда Россиядә бик популярлашты. Мәсәлән: “Cosmopolitan”, “Ell”, “Glamour” һ.б. Яки:

“Economist” журналы яшәү өчен иң уңайлы илләрне ачыклау буенча сораштыру үткәргән. (“Татарстан яшьләре”, №39, март 2005).

Көнбатыш белән тыгыз контактлар нәтиҗәсендә, Россиядә 90 еллар башында Америкада һәм Европада яратып ашый торган фаст-фудлар (ягъни, сүзен - сүзгә тәрҗәмә иткәндә, тиз вакытта әзер була торган ашамлык) популярлашты. MacDonalds, Burger King кафе-рестораннары ачылды (Көнбатыш илләрендә аларны күбрәк рестораннар дип атыйлар). Ә соңрак Казанда ачылган яңа күңел ачу урыннарының кайберләре инглизчә атала башлады: Right Bull (Уң Болак урамында урнашкан клуб, right – уң як, ә bull Болакның абривиатурасы), Coffe inn һәм безнең горурлыгыбыз Баскет холл: “Баскет холл” да үтәчәк билбау спорт бәйрәменә Мәскәүдән А.Карелин, Ш.Хисаметдинов кебек атаклы көрәшчеләрнең килүе көтелә. (“Татарстан яшьләре”, №39, сентябрь, 2005).

Сүзен-сүзгә тәрҗемә иткәндә, basket – ул корзин, ә holl – зал, коридор. Баскетхолл дигәндә баскетбол сүзенең мәгънәсеистә тотылып, ball компоненты урынына holl кую күздә тотыла. Ball сүзе аерым кулланмый.

Варваризмнарны ике төркечәгә бүлеп була. Беренчесенең, без алдарак карап кителгәннәрең, русча эквивалентын табып була, яки башка, алай ук колакка бәрелми торган алынмалар белән алыштырып була. Ә икенчесе – фирмаларның, компанияләрнең, чит илдә булган конкурсларның атамалары. Мисал өчен: Американың NASA космос агентлыгында эшләүче ике галим сенсацион белдерү ясадылар. (Татарстан яшьләре", №29, 2005).

NASA бөтен дөньяга билгеле компания һәм әлбәттә аның рус яки татар телендә эквивалентын табып булмый. Яки: Без яратып сибенеп йөргән хушбуйлар составында агулы матдәләр табылган. Бу хакта "гринпис" экологик оешмасы игълан итте. ("Татарстан яшьләре", №21, февраль, 2005).

Гринпис (green - яшел , peas – тынычлык) - бөтендөнья экологиясе турында кайгыртучы компания. Аның филиаллары җир шарының барлык илләрендә бар диярлек һәм аның исемен үзгәртеп була алмый.

Варваризмнар татар теленә соңгы биш-алты ел өчендә шактый керәләр һәм, алдарак китерелгән мисаллар нәтиҗәсендә еш кулланалар дигән нәтиҗәгә килеп була. Хәзерге көндә алар кеше тормышында шактый мөһим урын тоталар. Кичке клубларны хәзер *night club,* клубның каравылчыларын *security*, ә ишек алдындагы тикшерерүне *фейс контроль* дип атыйлар. Соңгы елларда кеше бу яңалыкларга шундый күнеккән һәм хәтта башка атаманы күзгә дә китерә алмый.

Соңгы бер-ике ел өчендә администрация сүзе *ресепшен* сүзенә алыштырыла бара һәм клубларның күбесендә хәзер администрация сүзе кулланылмый яки *ресепшенга* үзгәрә.

Димәк, алдагы мисалларга таянып, варваризмнарның арта бара дигән нәтиҗәгә килеп була.

Әдәбият

1. Ахунзянов Э.М. Русские заимствования в татарском языке / Э.М. Ахунзянов – Казань: Издательство казанского университета, 57 стр., 1968.

1. 8. Бельчиков Ю.А. Интернациональная терминология в русском языке. / Ю.А. Бельчиков Ю.А. – Москва: Просвещение, 1959. – 80 стр.

2. Дьяков А.И. Причины интенсивного заимствования англицизмов в современном русском языке / А.И. Дьяков // Язык и культура. – Новосибирск, 2003. – С. 35-43.
3. Заимствования Русского языка в историко-функциональном аспекте. Под ред. Юналеева Р.А. – Казань: Издательство казанского университета, 1991. – 192стр.
4. Иноязычные слова в современном русском языке. – Москва: Просвещение, 1968. – 330 стр.
5. Сафиуллина Ф.С. Тел дигән дәрья бар / Ф.С. Сафиуллина– Казан: Тат.книго.издат., 1979. – 136 б.
6. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология / Сафиуллина Ф.С. – Казан: "Хәтер", 1999. – 288 б.
7. Хайруллин М.Б. Проблемы развития лексической системы татарского литературного языка / М.Б. Хайруллин – Казань – 2000. – 204 стр.
8. Хайруллин М. Лексикабыздагы чит тел сүзләре. / М. Хайруллин // Мәгариф. – 1998. - №9 – Б. 82 – 84.

Сүзлекләр

1. Англо-русский словарь. Мюллер В.К. – Москва: Русский язык, 1992. – 845стр.
2. Лингвистический энциклопедический словарь. Глав.ред. Ярцева В.Н. – Москва: Советская энциклопедия, 1990. – 685 стр.
3. Новейший словарь иностранных слов и выражений. – Москва: Современная литература, 2003. – 976 стр.
4. Русско-татарский словарь. Под ред. Ганиева Ф.А. – Москва: «Русский язык», 1991. – 736стр.
5. Словарь иностранных слов. – 15-е издание, исправления. – Москва: Русский язык, 1988. – 608 стр.
6. Татарча-русча уку-укыту сүзлеге. Ганиев Ф.Ә. ред. – Мәскәү: Рус теле, 1992. – 416

Хөрмәтуллина Р.Ш.

Гамил Афзал әсәрләрендә эндәш сүзләрнең роле.

Шигырьнең эмоция көчен арттыра, аны укучы зиһененә якынлаштыра торган әһәмиятле алымнарның берсе – шагыйрьнең

җансыз нәрсәләргә мөрәҗәгать итеп, шигъри сөйләмне бизәкләр белән баетуы; аерым геройларга, кайчакта укучыга кат-кат басым ясап мөрәҗәгать итүе; риторик сорау куеп, шул сорауның үзе белән үк теге яки бу төшенчәне раславы.

Халык шагыйре Гамил Афзал поэзиясендә бу алым шактый еш кулланыла. Аның лирик героеның мөрәҗәгать итү объектлары бик киң һәм күптөрле. Бу алымны кулланып, автор шигырьләрен эмоциональ баета, аларның эстетик көчен арттыра. Мәсәлән, “Төркиләр моңы” циклына кергән шигырьләрендә без аның Дәште Кыпчакка мөрәҗәгать итеп язган “Дәште Кыпчак” шигыре белән таныша алабыз:

Яшисең син, риваятьләр җыеп,
Моңлы җырлар җыеп кочак-кочак,
Идел, Урал сахрасына сыеп,
Дәште Кыпчак.

“Болгар ташлары” шигырендә дә өндәүләр һәм риторик сораулар күп кулланылган. Мәсәлән:

Чәчелгәнсең, сибелгәнсең, татар,
Явыз язмыш шулай кушкандыр,
Хәзер безнең баш калкытыр чаклар,
Тере икәнеңә ышандыр!
……………………………………..
Кара пулат ап-ак булып торсын,
Ак кирпечләр тезик, оланнар.
…………………………………….
Болгар мәчетенең диварына,
Милләттәшләр, кирпеч салыгыз!

Яисә, риторик сорау:

Дөнья тулы явызлык һәм мәкер,
Кайсы юллар белән барасы?

Шунысы кызык, бу “кайсы юллар белән барасы?” соравы шагыйрь иҗатында әледән-әле яңгырап китә. Менә тагын:

Пәйгамбәрсез калган өммәт кебек
Дәвер белән дәвер арасы.
Менә минем изге кыйблам диеп,
Кайсы юллар белән барасы?
(“Пәйгамбәрсез калган өммәт...”)

Һәм инде халык җырларына тартым “Ул заман да, бу заман” шигырендә:

Ул заман да, бу заман,
Җир белән күк арасы.
Күзләрем күрми, балам,
Кайсы юлдан барасы?

Үзе яшәгән беренче каттагы бүлмәсеннән яшь-җилкенчәкнең теләсә-ничек тәртипсезләнеп, трай тибеп йөрүен күреп торган шагыйрь, аларга “газиз балам” дип мөрәҗәгать итеп, мондый шигырь яза:

Бу төркемгә карап уйга талам;
Бәхет, шатлык өчен тугансыз,
Ничек яшәрсез сез, газиз балам,
Әхлаксыз, намуссыз, имансыз?
Сулар ага, олан, еллар ага,
Типсә, тимер өзәр егет сез,
Ничек яшәрсез сез бу дөньяда,
Намуссыз, имансыз, өметсез?

(“Ничек яшәрсез сез?”)

Яисә:

Изге иман иңгән көннәрдә
Кем рухына дога кылыйм икән,
Сәҗдә кылыйм икән кемнәргә?

(“Әллә кырау, әллә томан төшә...”)

Аңлашылганча, шагыйрь бу сорауларына җавап ала алмаячак. Ул аны көтми дә. Болар – риторик сораулар. Аларда заман таләпләренә кагылышлы мөһим мәсьәләләргә игътибар ителә.

Шагыйрь иҗатында күңелендә мәңге җуелмас тәэсирләр калдырган Актанышның гүзәл бер почмагы – Такталачык авылы образы кызыл җеп булып сузылып бара. Гомумән, татар авылын, татар халкын сурәтләгән шигырьләрендә ул авылга еш мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, “Әй, авыл” шигыре:

Әй авылым, туган телнең
Матурлыгы сүнми торган,
Мең яшәрлек мәкальләрең,
Бәетләрең синдә туган.

Лирик геройның кичерешләре авыл белән генә түгел, фани дөнья белән дә бәйләнешле. “Туган авыл белән саубуллашу” шигырендә

Сау бул инде, михнәт чиккән дөнья,
Суык җилле, юеш, караңгы көз,
Бәке тишеп кер чайкаган елга,
Күченәбез, – дип,

авылдан чыгып киткәндәге кичерешләрен сурәтләсә, “Авылга кайткач” шигырендә туган халкына эндәшеп мондый сорау бирә:

Ничек яшәдең син, чыдам халык,
Яхшы заман көткән мең елда?
Дулкыннарын зәңгәр моңга манып,
Ни турында сөйли бу елга?

Шагыйрьнең илаһи көчләргә мөрәҗәгать итүе дә күзәтелә:

Яшь язучыларга киңәш бирәм
Яз шулай, дим, энем, яз болай.
Үз өемдә ачы яшьләр түгәм,
Ничек языйм, димен, и Ходай!
(“...Яшь язучыларга”)

Йа, Илаһым, бу тынгысыз җанны.
Халык арасына сыендыр.
(“Иман яңарту”)

Яки тагын:

Беркемне дә алдамыйча китәм,
Әүлияләр, дога кылыгыз!
(“Алга барганда” циклыннан).

Туган халкына һәм илаһи көчкә ышанычын ул киләчәк буынга да васыять сыман әйтеп калдыра:

Әллә кай заманда әйткән бер ишан:
-Патшага ышанма, аллага ышан!
Мин уйлап торам да улыма кушам:
-Түрәгә ышанма, халыкка ышан!
(“Мәңгелек гамь”)

Г.Афзалның “Чәчәкләр бирегез” шигырендә кешегә игътибарлы булуны, кеше кадерен ул исән чакта белдерүгә теләкне чагылдырган бик матур риторик өндәү мисаллары бар:

Таралсын күгелҗем болытлар,

Якты көн карасын кешегә!
………………………………
Ике кат яшәмәс берәү дә,
Чәчәкләр бирегез кешегә!

Әдип абстракт төшенчәләр белән дә гәп кора, шул рәвешле шигырьләренең җанлылыгына, тәэсир көченең артуына ирешә.

И матур, туган аһәңнәр,
Бабайлар тоткан йола,
Ташландык авыл читендә
Күзге җил булып ела.
И телем, таныш мәкальләр,
Әбиләр кылган дога,
Ташландык мәктәп түрендә
Күзге җил булып ела!

(“И матур, туган аһәңнәр”)

Сау бул инде, егерменче гасыр,
Бик күп даһиларны күмгән заман
Гади кеше айга менгән заман!

Шагыйрь яза торган җырына, поэзиягә дә мөрәҗәгать итә:

Поэзия,
Сиңа багышладым
Изге минутларын гомернең .

(“Поэзия”)

Сүнгән йолдыз нуры кебек
Йолдызлар арасында,
Моң булып яшә син, җырым,
Йөрәкләр ярасында,
Күзләрнең карасында!

(“Сүнгән йолдыз...”)

Җырга, шигырьгә мөрәҗәгать итү, гомумән, поэзиядә киң таралган. Муса Җәлилнең һәркемгә мәгълүм “Җырларым” шигыре – шуның матур үрнәге. Бу нисбәттән Гамил Афзалның “Шигырь” әсәре игътибарга лаек:

Күңелдән очып тор, шигырь,
Дөньяны кочып тор, шигырь,
Кеше аңына кадалып,
Намусын борчып тор, шигырь,
Һәр җанда посып тор, шигырь.

Ул хәтта шагыйрьнең үзен дә матур иҗатка өнди:

И шагыйрь, шундый җыр җырла син,
Төннәрне балкытып таң атсын,
Пушкиннар аһ итеп тыңласын,
Тукайлар сокланып кул чапсын.

“Гомер мизгелләре” циклында шагыйрьгә “каләмдәш” дип эндәшеп, болай яза:

Җил-давыллы яшь гомерләр үткәч,
Чал сакаллар үскәч, каләмдәш,
Биек-биек тауга менеп җиткәч,
Пәйгамбәрең белән сәламләш!

Әдипнең аерым шәхесләргә мөрәҗәгать итеп язылган шигырьләре дә байтак. Шундыйлардан исемсез бер шигыре:

“Коммунизм кыры күренә”, –дидең,
Күренмәде әле, Һади Такташ
Ничек итеп ул күренер икән.
Капитализмга кайткач?

Шәхескә мөрәҗәгать итү матур әдәбият стилендә элек-электән киң таралган. Гамил Афзалда лирик эндәшләр, мөрәҗәгатьләр “туганнар”, “оланнар”, “кардәш”, “улым”, “балам”, “энем”, “үскәнем”, “аппагым”, “җаным” һ.б. сүзләр белән бирелгән. “Бүз бала” эндәше дә очрый хәтта. Ә шулай да шагыйрь телендә иң еш очраган ике эндәш сүз – “дускаем” һәм “иркәм”. Шунысы кызыклы, яратып, үз итеп, тәмләп әйтелергә тиеш “иркәм” сүзен шагыйрь күбрәк фәлсәфи шигырьләрендә куллана. Берничәсен карап үтик:

Өрлектәй дә ирләр өректе, иркәм,
Өченче сорт булгач бу халык.
(“Күсе елы борчылулары” циклыннан)

Шагыйрьнең төп дошманы – битарафлык, икейөзлелек, рухи зәгыйфьлек:

Халык ихтыяҗы, дисең, иркәм,
Власть тирәсенә елышканда.
(“Алдап эшләтү”)

Ә чынлыкта, ул сәясәт, иркәм,
Сине көчләү өчен кирәк икән... (“Сәясәт”)

Яки тагын:

Ярты халык – дебильныйлар, иркәм,
Ниләр үсми уртак бакчада!

(“Үткән еллар моңы” циклыннан)

Патшаның да хәле авыр икән,
Бөтен халык хокук сорый, иркәм.

(“Патшаның да хәле...”)

Мисаллардан күренгәнчә, лирик эндәшләр, мөрәҗәгатьләр ярдәмендә шагыйрь укучы белән ихлас әңгәмә алып бара, тормыш, кешеләр турында борчыла, уй-хисләре, өмет-хыяллары белән уртаклаша. Тирән уй, фәлсәфи фикер Г. Афзал лирикасының төп асылын билгели.

Сатира жанрындагы эндәш сүзләр турында сөйләшү – үзе зур бер хезмәт булыр иде. Бер сүз белән әйткәндә, риторик эндәшләр, һичшиксез, Гамил Афзал сатирасын сатира иткән иң мөһим күрсәткечләрнең берсе.

Фәлсәфи һәм лирик шигырьләрендә кулланылган риторик сорау һәм өндәүләр турында сөйләшүне төгәлләгәнче, тагын бер-ике генә мисал китереп үтәсе килә. Беренчедән, “Ачы язмышлар” шигырендә риторик сорау белән җавапның янәшә килүен:

Кем гаепле – без гаепле инде,
Күзе тонган кара сарык булдык.

Икенчедән, иҗатының буеннан-буена куелып барылган “ничек яшәргә?”, “кем гаепле?”, “кайсы юллар белән барасы?”, “кемгә табынырга?” кебек сорауларына җавап рәвешендә шагыйрьнең усал елмаеп, мондый дүртьюллык язуын:

Уйлар тала, куллар тала, күзләр тала
Бу заманда кемгә барып баш иясе?
Яңа заман философы сөрән сала:
- Берләшегез, бөтендөнья мафиясе!

Ирексездән, Г.Афзал поэзиясенә Нил Юзиев биргән бәяләмә искә төшә: “Гамил Афзал поэзиясе сорау поэзиясе түгел, нокта һәм өндәү поэзиясе. Уйлану, фәлсәфә аңарда сорау белән түгел, нокта һәм өндәү белән тәмамлана. Шагыйрьнең аһәңле һәм мәгънәле дөньяны кабул итүенең бер үзенчәлеге, минемчә, әнә шунда”.

Әдәбият
1. Афзал Г. Өф-өф итеп: Сатира-юмор шигырьләре /Г.Афзал. – Казан:
Таткитнәшр., 1968. – 187 б.
2. Афзал Г.Ышаныгыз: Сайланма шигырьләр /Г.Афзал. – Казан:
Таткитнәшр., 1971. – 288 б.
3. Афзал Г. Гомер кичүләре /Г. Афзал. – Казан: Рухият, 2000, – 559 б.
4. Афзал Г. Айлы кичләр: Шигырьләр. [Н.Юзиев кереш сүзе белән]
/Г.Афзал. – Казан: Таткитнәшр., 1977. – 333 б.

Хузина Э.С.

Понятие «гендер» в языкознании

Относительно недавно в российском языкознании стало формироваться новое направление исследований, получившее название гендерных исследований. В основе их концепции лежит представление о гендере как о социальном поле.

Современная социальная наука различает понятия «пол» и «гендер». Пол обозначает физические, физиологические, биологические различия между мужчинами и женщинами. Термин гендер употребляется для обозначения пола как социального понятия и явления. В энциклопедическом словаре о гендере написано нижеследующее: «Гендер (англ. gender – род, чаще всего грамматический) – понятие, используемое в социальных науках для отображения социокультурного аспекта половой принадлежности человека. Гендер – социальная организация половых различий; культурологическая характеристика поведения, которое соответствует полу данном обществе в данное время…». (7: 209) Из этого следует, что не пол, а гендер обусловливает способности, психологические качества, виды занятий мужчин и женщин через воспитание, традиции, правовые и этические нормы.

По мнению Дж. Батлера, Д. Зиммермана, каждый индивид самостоятельно создает свою гендерную идентичность, и каждое общество располагает набором ресурсов для создания гендера – к ним относятся физические характеристики социального

окружения, стандартные социальные ситуации, практики формирования супружеских пар. Авторы так же отмечают, что категория принадлежности по полу и гендер являются управляемыми свойствами поведения.

Отсюда и понятие «гендерный стереотип», которое культурно обусловлен и оказывает влияние на поведение, в том числе и речевое, на процессы языковой социализации личности.

Речь и пол человека взаимосвязаны. Поведении человека, которое обусловливается его полом, проявляется на всех уровнях языка. (5: 26) Таким образом, язык и речь могут быть проанализированы с точки зрения отражения в них гендерных отношений.

Дифференциация форм выражения одного и того же содержания в зависимости от пола и возраста выступает у всех народов как следствие социальных и биологических различий. Мужчины говорят таким языком, который они рассматривают как типичный мужчинам, а женщины – в манере, которую они рассматривают как соответствующую женщинам. (4: 90) Отсюда и понятие «гендерлекты» - «мужской» и «женский» языки – дифференциация речи по половому признаку. (8: 280)

Для исследователей главное место занимает проблема методологии. Нельзя опираться только на чисто лингвистические методы. Поэтому они используют междисциплинарный подход к изучению человека и общества и опираются на методы различных гуманитарных дисциплин (социологии, психологии, истории, философии, лингвистики и др.).

Важнейшей дискуссионной проблемой гендерных исследований сегодня является соотношение биологических и культурных факторов, влияющих на гендерные различия в языке и речи. Есть два мнения по этому поводу: социодетерминисты (А.В. Кирилина, Е.М. Бакушева, И.И. Халеева и др.) считают, что человеку большое воздействие оказывают культура и общество; биодетерминисты (Э. Гольберг, Л.Д. Коста и др.) считают, что врожденные биологические различия мужчин и женщин обусловливают их социальное поведение.

Мы считаем, что основная причина существования отличительных особенностей мужской и женской речи в

статусно-ролевых характеристиках мужчины и женщины в обществе и в семейно-родственных отношений. Сюда же мы включаем и национально-культурные и психологические особенности речевого поведения.

Таким образом, гендерные исследования являются новой и перспективной областью знаний российской гуманитарной науки. Изучение каждого языка в гендерном плане позволит точнее описать особенности концептуализации мужественности и женственности в разных языках.

Литература

1. Бакушева Е.М. Социолингвистика и анализ речевого поведения мужчины и женщины в современном обществе/ Е.М. Бакушева. – Рязань, 1992.- 167 с.
2. Горошко Е.И. Особенности мужского и женского стиля письма/ Е.И. Горошко// Гендерный фактор в языке и коммуникации/ Под ред. И.И. Халеевой. – Иваново, 1999. – С. 28-41.
3. Дадова З.И. Гендер: лингвокультурологический аспект/ З.И. Дадова// проблемы развития языков и литератур народов Северного Кавказа. Материалы региональной научной конференции (23-24 октября 2004 г.). –Нальчик: каб.-Балк. Ун-т, 2004. – С. 120-124.
4. Земская Е.А. Особенности мужской и женской/ Е.А. Земская, М.А. Китайгородская, И.И. Розанова// Русский язык в его функционировании. Под ред. Е.А. Земской и Д.И. Шмелева. - М.: Наука, 1993. – 224 с.
5. Кирилина А.В. Гендер: лингвистические аспекты/ А.В. Кирилина. – М.: Ин-т Социологии РАН, 1999. – 189 с.
6. Кирилина А.В. Категория gender в языкознании/ А.В. Кирилина// Женщина в российском обществе. – 1997. - №2. – С. 15-20.
7. Социология: Энциклопедия/ Сост. А.А. Грицанов, В.Л. Абушенко, Г.М. Евелькин и др. – М.: Книжный Дом, 2003. - 1312 с.
8. Теория языка: Учебное пособие/ А.Т. Хропенко, В.Д. Бондалетов. – М.: Наука, 2004. – 512 с.

Хурматуллин А.К.

Понятие «дискурс» в современной лингвистике

Постановка вопроса о динамичности термина «дискурс» в аспекте его семантического варьирования вполне правомерна, так как в последние десятилетия это – наиболее распространённый в лингвистике термин. И не исключено, что этому способствовало отсутствие чёткого и общепризнанного определения «дискурса», охватывающего все случаи его употребления. Современный научный подход рассматривает дискурс как важнейшую форму повседневной жизненной практики человека и определяет его как сложное коммуникативное явление, включающее, кроме текста, и экстралингвистические факторы (знание о мире, мнения, установки, цели адресата), необходимые для понимания текста.

Определение понятия "дискурс" представляет значительные сложности в силу того, что оно оказалось на стыке целого ряда научных дисциплин, таких как лингвистика, антропология, литературоведение, этнография, социология, социолингвистика, философия, психолингвистика, когнитивная психология и многих других. И вполне естественно, что многозначность термина «дискурс» и его использование в различных областях гуманитарного знания порождают разные подходы к трактовке значения и сущности данного понятия. Тем не менее, можно говорить о том, что благодаря усилиям ученых различных областей теория дискурса оформляется в настоящее время как самостоятельная междисциплинарная область, отражающая общую тенденцию к интеграции в развитии современной науки.

Ещё до появления современной теории дискурса, которая начала складываться в самостоятельную область лишь в середине 60-х годов XX века, существовали попытки дать определение этому термину. Наиболее «старым» значением «discours» обладает во французском языке и означает диалогическую речь. А уже в 19 веке этот термин был полисемичен: в Словаре немецкого языка Якоба Вильгельма Грима «Deutsches Woerterbuch» 1860 года указаны следующие семантические параметры термина «дискурс»: 1) диалог, беседа; 2) речь, лекция. Такой подход был характерен в период становления теории дискурса в рамках многочисленных исследований, получивших

название лингвистки текста. Это был период, когда лингвистика вышла за рамки исследования изолированного высказывания (предложения) и перешла к анализу синтагматической цепи высказываний, образующих текст, конституирующими свойствами которого являются завершенность, целостность, связность и др. Интерес к изучению текста был обусловлен стремлением объяснить язык как цельное средство коммуникации, глубже изучить связи языка с различными сторонами человеческой деятельности, реализуемыми через текст. Интенсивное развитие лингвистики текста как науки о сущности, предпосылках и условиях человеческой коммуникации наметило поворот от лингвистики языка к лингвистике речи, усиление внимания к акту коммуникации.

С самого начала в рамках исследований, изучающих организацию текста связной речи, шла полемика, связанная с терминологическим определением объекта исследования, а также самой области лингвистики, изучающей текст. Первоначально возникший термин "лингвистика текста" многим ученым представляется не совсем удачным, и в некоторых лингвистических работах текст связной речи называют дискурсом. Полисемичность термина «дискурс» зафиксирована в «Кратком словаре терминов лингвистики текста» Т.М. Николаевой: «Дискурс – многозначный термин лингвистики текста, употребляемый рядом авторов в значениях, почти омонимичных. Важнейшие из них: 1) связный текст; 2) устно-разговорная форма текста; 3) диалог; 4) группа высказываний, связанных между собой по смыслу; 5) речевое произведение как данность - письменная или устная [Николаева:1978; с.467].

Возникновение теории дискурса ознаменовало качественный скачок в развитии науки о языке и выдвинуло сложнейшую задачу – задачу лингвистического описания дискурса. Возникнув в рамках лингвистики текста, теория дискурса никогда не утрачивала своей изначальной связи с ней, но последовательно шла к дифференциации предмета своего исследования, к разграничению понятий "текст" и "дискурс". К примеру, по определению В.Г. Борботько, дискурс есть текст, но такой, который состоит из коммуникативных единиц языка – предложений и их объединений в более крупные единства,

находящиеся в непрерывной смысловой связи, что позволяет воспринимать его как цельное образование [Борьботько:1981; с.8]. Борботько подчеркивает тот факт, что текст как языковой материал не всегда представляет собой связную речь, то есть дискурс. Текст – более общее понятие, чем дискурс. Дискурс всегда является текстом, но обратное неверно. Не всякий текст является дискурсом. Дискурс – частный случай текста.

В современной лингвистике дискурс трактуется неоднозначно. Можно выделить несколько подходов к определению дискурса:

1.Коммуникативный (функциональный) подход: дискурс как вербальное общение (речь, употребление, функционирование языка), либо как диалог, либо как беседа, т.е. тип диалогического высказывания, либо как речь с позиции говорящего в противоположность повествованию, которое не учитывает такой позиции. В рамках коммуникативного подхода термин «дискурс» трактуется как «некая знаковая структура, которую делают дискурсом её субъект, объект, место, время, обстоятельства создания (производства).

2. Структурно-синтаксический подход: дискурс как фрагмент текста, т.е. образование выше уровня предложения (сверхфразовое единство, сложное синтаксическое целое, абзац). Под дискурсом понимаются два или несколько предложений, находящихся друг с другом в смысловой связи, при этом связность рассматривается как один из основных признаков дискурса.

3. Структурно-стилистический подход: дискурс как нетекстовая организация разговорной речи, характеризующаяся нечётким делением на части, господством ассоциативных связей, спонтанностью, ситуативностью, высокой контекстностью, стилистической спецификой.

4. Социально-прагматический подход: дискурс как текст, погружённый в ситуацию общения, в жизнь, либо как социальный или идеологически ограниченный тип высказываний, либо как «язык в языке», но представленный в виде особой социальной данности, имеющий свои тексты.

Данная классификация позволяет понять, что природа дискурса тройственна: одна его сторона обращена к прагматике,

к типовым ситуациям общения, другая к процессам, происходящим в сознании участников общения, и к характеристикам этих сознаний, третья — к собственно тексту.

Выделенные подходы отчасти противоречивы. Понятие «дискурс» осмысливается с понятиями речь и текст. Дискурс как коммуникативное явление – это промежуточное звено между речью как вербальным общением, как деятельностью, с одной стороны, и конкретным текстом, зафиксированным в ходе общения, с другой. В более простом противопоставлении дискурс следует понимать как когнитивный процесс, связанный с реальным речепроизводством, со знанием речевого произведения, а текст – как конечный результат процесса речевой деятельности, выливающийся в определённую законченную форму. Такое противопоставление реального говорения его результату приводит к осознанию того, что текст может трактоваться как дискурс только тогда, когда он реально воспринимается и попадает в текущее сознание воспринимающего его индивида. Г. Видоусен предпринял попытку дифференцировать понятия «текст» и «дискурс» с помощью включения в данную пару категории «ситуация». Так дискурс им рассматривается как «текст»+»ситуация».

Понятие дискурс было введено из-за назревшей в науке потребности учитывать не только характеристики «текста как такового», исходя из его внутренней специфики, но и текста как «послания», адресованного кому-либо и выражающего какие-то потребности адресата и автора. Французский учёный Э. Бенвенист говорит о дискурсе как о «речи, присваиваемой говорящим»: «дискурс не является простой суммой фраз, при его рождении происходит разрыв с грамматическим строем языка. Дискурс - это такой эмпирический объект, с которым сталкивается лингвист, когда он открывает следы субъекта акта высказывания, формальные элементы, указывающие на присвоение языка говорящим" [Гийому, Мальдидье:1999; с.124]. По его мнению, существенной чертой дискурса, понимаемого им в широком смысле, является соотнесение дискурса с конкретными участниками акта, то есть говорящим и слушающим, а также с коммуникативным намерением говорящего каким-либо образом воздействовать на слушателя.

Структуру разговорного дискурса составляет ряд этапов (вступление в речевой контакт, выдвижение инициальной темы разговора и ее ратификация, смена ролей в ходе коммуникативного акта, смена темы разговора, выход из коммуникативного акта), каждый из которых обусловлен комплексом внешних и внутренних факторов.

Лингво-коммуникативный аспект дискурса прослеживается в определении Г.А. Орлова, который рассматривает дискурс как категорию (естественной) речи, материализуемой в виде устного или письменного речевого произведения, относительно завершённого в смысловом и структурном отношении, длина которого потенциально вариативна: от синтагматической цепи свыше отдельного высказывания (предложения) до содержательно цельного произведения (рассказа, беседы, описания, инструкции, лекции и т. п.) [Орлов:1991; с.14]. Понятие «дискурс» характеризуется параметрами завершенности, цельности, связности и др. (то есть всеми свойствами текста), оно рассматривается одновременно и как процесс (с учетом воздействия социокультурных, экстралингвистических и коммуникативно-ситуативных факторов), и как результат в виде фиксированного текста.

Как видим, определение «дискурса» как термина постепенно вышло за пределы текста и стало включать в себя перечисление условий, в которых этот текст актуализируется. Здесь уместным будет привести дефиницию дискурса, предложенную В.В. Петровым и Ю.Н. Карауловым. Эта дефиниция аккумулирует воззрения на «дискурс» нидерландского учёного Т.А. Ван Дейка, которому в современном языкознании принадлежит приоритет в описании дискурса: «…дискурс – это сложное коммуникативное явление, включающее кроме текста, ещё и экстралингвистические факторы (знания о мире, установки, цели адресанта), необходимые для понимания текста». [Петров, Караулов:1989; с.7]. Нужно отметить, что это лаконичное определение было в качестве отправного момента положено в основу многих лингвистических исследований текста современного периода.

В.З.Демьянков, основываясь на новых работах по зарубежному языкознанию, дал определение дискурса, которое

отражает функциональную природу дискурса и в значительной степени углубляет предыдущие дефиниции: «Discours – дискурс, произвольный фрагмент текста, состоящий более чем из одного предложения или независимой части предложения. Часто, но не всегда, концентрируется вокруг некоторого опорного концепта; создаёт общий контекст, описывающий действующие лица, объекты, обстоятельства, времена, поступки и т.п., определяясь не столько последовательностью предложений, сколько тем общим для создающего дискурс и его интерпретатора миром, который «строится» по ходу развёртывания дискурса. Исходная структура для дискурса имеет вид последовательности элементарных пропозиций, связанных между собой логическими отношениями конъюнкции, дизъюнкции и т.п. Элементы дискурса: излагаемые события, их участники, перформативная информация и «не-события», т.е. а) обстоятельства, сопровождающие события; б) фон, поясняющий события; в) оценка участников события; г) информация, соотносящая дискурс с событиями». [Демьянков:1982; с.7]. Ядром этой дефиниции можно считать положение о том, что дискурс определяется не как величина, адекватная тексту, или даже, как ясно из приведённых выше определений, синонимичная ему, а значительно шире.

При социально-прагматическом подходе в центре внимания исследователей находится речевое действие, участниками которого являются некоторые типы языковых личностей, оказавшиеся в рамках определённых обстоятельств и условий общения.

Понимание дискурса как социального явления восходит к французским структуралистам и постструктуралистам, прежде всего М.Фуко. Также в исследовании и обосновании этого термина важную роль сыграли А.Греймас, Ж.Деррида, Ю.Кристева. В работах этих учёных просматривается стремление к уточнению традиционных понятий стиля (в том самом максимально широком значении, которое имеют в виду, говоря «стиль – это человек») и индивидуального языка (ср. традиционные выражения *стиль Достоевского*, *язык Пушкина* или *язык большевизма* с такими более современно звучащими выражениями, как *современный русский политический дискурс*

или *дискурс Рональда Рейгана*). Понимаемый таким образом термин «дискурс» (а также производный и часто заменяющий его термин «дискурсивные практики», также использовавшийся Фуко) описывает способ говорения и обязательно имеет определение – какой или чей дискурс, ибо исследователей интересует не дискурс вообще, а его конкретные разновидности, задаваемые широким набором параметров: чисто языковыми отличительными чертами (в той мере, в какой они могут быть отчетливо идентифицированы), стилистической спецификой (во многом определяемой количественными тенденциями в использовании языковых средств), а также спецификой тематики, систем убеждений, способов рассуждения и т.д. Более того, предполагается, что способ говорения во многом предопределяет и создает саму предметную сферу дискурса, а также соответствующие ей социальные институты. Тем самым, для французской школы дискурс – прежде всего определённый тип высказывания, присущий определённой социально-политической группе или эпохе.

У Т.А. Ван Дейка также есть определение, трактующее дискурс как социальное явление: «дискурс – это речевой поток, язык в его постоянном движении, вбирающий в себя всё многообразие исторической эпохи, индивидуальных и социальных особенностей как коммуниканта так и коммуникативной ситуации, в которой происходит общение. В дискурсе отражается менталитет и культура как национальная, всеобщая, так и индивидуальная, частная» [Петрова:1989; с.47].

Термин дискурс широко использовал в своих работах известный немецкий философ Ю. Хабермас. В его работах дискурс – вид речевой коммуникации, обусловленный критическим рассмотрением ценностей и норм социальной жизни [Habermas:1989; с.571-606].

Интересна точка зрения Ю.С.Степанова, связывающего дискурс с понятиями альтернативного мира, факта и причинности. Степанов также дает широкую лингво-философскую трактовку дискурса как “языка в языке”, представленного в виде особой социальной данности. При этом дискурс не может быть сведен к стилю, грамматике или лексикону как просто язык. Он «существует, прежде всего, и

главным образом в текстах, но таких, за которыми встает особая грамматика, особый лексикон, особые правила словоупотребления и синтаксиса, особая семантика, – в конечном счете – особый мир» [Степанов:1995; с.45]. Хотя Степанов также говорит о существовании дискурса в текстах, его видение дискурса как особого, возможного мира выводит дискурс далеко за рамки текста.

Таким образом, резюмируя вышеприведённые определения к понятию «дискурс», можно утверждать, что данный термин, как он понимается в современной лингвистике, близок по смыслу к понятию «текст», однако подчеркивает динамический, разворачивающийся во времени характер языкового общения; в противоположность этому, текст мыслится преимущественно как статический объект, результат языковой деятельности. Иногда «дискурс» понимается как включающий одновременно два компонента: и динамический процесс языковой деятельности, вписанной в ее социальный контекст, и ее результат (т.е. текст); именно такое понимание является предпочтительным.

Литература

1. Борботько В. Г. Элементы теории дискурса/ В.Г. Борботько. – Г., 1981.
2. Николаева Т.М. Краткий словарь терминов лингвистики текста//Лингвистика текста/Новое в зарубежной лингвистике/ Т.М. Николаева. – М.: Прогресс, 1978.
3. Гийому Ж. О новых приёмах интерпретации, или проблема смысла с точки зрения анализа дискурса // Квадратура смысла./ Ж. Гийому, Д. М. Мальдидье. – М.:1999, с. 124-136.
4. Орлов Г.А. Современная английская речь/ Г.А. Орлов. – М.: Высшая школа, 1991.
5. Дейк Т.А. ван. Язык. Познание. Коммуникация. Коммуникация: Пер. с англ./Сост. В.В. Петрова; под ред. В.И. Герасимова; Вступ. ст. Ю.Н. Караулова и В.В. Петрова/ Т.А. ван Дейк. – М.: Прогресс, 1989.
6. Демьянков В.З. Доминирующие лингвистические теории в конце XX века//Язык и наука конца XX века/ В.З. Демьянков. – М.: Ин-т языкозн., Рос. гуманит. ун-т, 1995.

7. Habermas, J. Erlaeuterungen zum Begriff des kommunikativen Handelns//Vorstudien und Ergaenzungen zur Theorie des kommunikativen Handelns.- 3. Aufl/ J. Habermas. – Frankfurt a.M.: Suhrkamp Verl., 1989.
8. Степанов Ю.С. Альтернативный мир, Дискурс, Факт и принцип Причинности//Язык и наука конца 20 века/Сб. статей/Степанов Ю.С. – М.: Ин-т языкознания РАН, Рос. гумантит. ун-т, 1995.

ЭЛЕКТРОННЫЕ РЕСУРСЫ
http://www.krugosvet.ru/articles/82/1008254/print.htm
http://discourse-pm.ur.ru/avtor6/mironova.php
http://www.edu-zone.net/show/71104.html
http://infolex.ru/DOMINAT.html#_Toc32481686

Шакирова Г.М.

Гаяз Исхакыйның проза әсәрләрендә портрет бирелеше

Әсәрдәге һәр герой тышкы кыяфәте яисә эш-хәрәкәте белән укучы күңеленә үзенчә юл сала, истә кала. Бу сыйфат турыдан-туры язучының осталыгына бәйле, дисәк, ялгышмабыз. Чөнки еллар узгач та, яратып укылган әсәребезнең исемен ишетүгә, геройлары күз алдына килеп баса, әдипнең сүз байлыгы аша тасвирланган портретлар пәйда була.

Язучының персонажларны сурәтләгәндә кулланган төрле тел чараларын өйрәнү әлеге ысулларның текст төзү процессындагы ролен ачыклап кына калмый, ә язучының тел осталыгын да күрсәтә. Шушы максаттан чыгып, әлеге мәкаләдә XX йөз башы өлгергән татар прозасында тирән эз калдырган Гаяз Исхакыйның чәчмә әсәрләрендә портрет бирелешендәге үзенчәлекләрне карап узарбыз. Чагыштырып күзаллау һәм нәтиҗәләребез тагын да дәлиллерәк булсын өчен язучының башлангыч чор иҗатына караган иң беренче әсәре “Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер” (1897) һәм мөһаҗирлектә язылган “Көз” (1923) повестен алдык.

Тикшеренүләрдән күренгәнчә, Гаяз Исхакый иң беренче әсәрендә персонажларының портретларын сурәтләүне арткы планга калдыра, хәтта аларның тышкы кыяфәтләрен бирүне

кирәк тапмый да диярлек, әдипкә хәрәкәт, вакыйгалар үстерелеше кирәк. Бу – шул чор өчен табигый күренеш. Чөнки, мәгърифәтче язучылар өчен, геройның тышкы кыяфәтенә караганда, аның аң-белем өлкәсендә гамәлләре мөһимрәк. “Тәгаллемдә сәгадәт...” әсәренең төп герое Хәлимнең дә портреты бирелмәгән. Әмма укучы, әсәр белән танышу барышында, Исхакыйның сихри тел осталыгына бирелеп, геройны тулысынча күз алдына китерә. Язучы героеның эш-гамәлләре, социаль хәле, башка персонажлар һәм табигатькә мөнәсәбәте аша аның портретын сурәтли, характер билгесен ачыклый. Әлеге күренеш тел гыйлемендә имплицит (яшертен) лексик чара дип йөртелә.

“Тәгаллемдә сәгадәт...” әсәрендә төп герой Хәлимне әнисе Фатыйма мәдрәсәгә укырга алып килә. Хәлимнең укуга теләге бик зур. Әнисе Фатыйма улының бәхете өчен барысына әзер, аны гыйлемле, белемле зур кеше итеп күрә. Урамнан узучы шәкертләрне күргәч, *Фатыйма: Карасана, Рәхимә абыстай, ниндәен әдәпле баралар, берсенә берсе дә карамый, безнең Хәлим дә шулай әдәпле булыр микән? (Әсәрләр, 15 томда. 1 том, 41 б.)* дип сорый. Безнең күз алдына бик әдәпле, матур кыяфәтле шәкертләр килеп баса, Хәлим дә алар арасында булачак. *Рәхимә: Менә монда Сәгъди хәзрәт шәкертләре бар. Алар да шул мәчеткә баралар, күрерсең, әллә ни кылынып бетәләр, берсе берсе берлә көлешкән булып, ялтыр-йолтыр күзләрен тәрәзәгә әйләндерәләр, әйтерсең, аларны монда көтеп торалар. (1 том, 41 б.)* Болары инде, әдәпсез шәкертләр. Язучы, урамдагы шушы күренешләр аша, гыйлемле кешенең, бу очракта Хәлимнең, һәр эштә дә әдәпле булырга тиешлеген ассызыклый. *Икенче елны унтугыз яшендә бер мөгаллим булып, дәхи сәнаигы нәфисә мәктәбендә бер шәкерт булып, мәктәптә үзенә билгеләнгән бер өйдә тора башлады. (1 том, 45 б.)* Язучы Хәлимнең портретын күзаллау өчен ярдәм итәрлек бердән-бер билге – 19 яшь икәнен әйтеп үтә. *Кызның төсен, йөрешен, укымышын бик мактыйлар, эшкә дә оста диләр. (1 том, 45 б.); Фәхри: Мин сиңа бер кыз исәпләп торам, атасы-анасы бирсәләр, кызда эш соң калмаган, матурлыккамы дисең, куштанлыккамы дисең, ул укымыш инде, мәнзумә китапларны шатырдатып укый, бирсәләр, яхшы булыр. (1 том, 47 б.)* Әсәрдә укымышлы, әдәпле Хәлимгә туры килә

торган кыз да эзләнә. Булачак кәләшләрне сурәтләү аша Хәлимнең бәясе тагы да күтәрелә.

Укучы язучының шушы беренче әсәрендә портретка бәйле геройның характерын ачучы мисаллар белән башка очрашмый. Әсәрнең эчтәлеге аша Хәлимгә гомуми сурәт бирелә: ул – тырыш, укымышлы, эти-әнисенә рәхмәтле, әдәпле, үзенә бар яклап туры килүче кәләше булган үрнәк герой. Бу – аның характер билгеләре, ә портретын сурәтләүче бердән-бер сыйфат – аңа 19 яшь.

Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектә иҗат иткән “Көз” әсәрендә исә, портрет бирелеше башка яклап ачыла. Язучы бу вакытта инде үз стилен булдырган, язу кыйбласын тапкан, геройларын да гомуми билгеләр аша гына түгел, ә аерым сыйфатларга йөгәнли, үзенчәлекле шәхси тамгалар белән сурәтли, укучы күңеленә оныттырмаслык ачкыч ясый.

Әсәрдә ике хатын – бәхетле Нәфисә һәм бәхетсез Гөлсемнең тормыш юллары тасвирлана. Героиняларының бүгенге язмышын автор алар тәрбияләнгән социаль катлау, гореф-гадәтләр тәэсиренә бәйләп аңлата. Урта хәлле сәүдәгәр кызы Нәфисә милли традицияләрне үзләштереп үсә, дингә еш таяна, русча да өйрәнә. Үз бәхете өчен көрәшерлек көчле рухлы, милли җанлы кыз булып җитешә. Мирза кызы Гөлсем исә бик иртә әнисез кала, этисенең сеңелесе тәрбиясендә, рус мохитендә үсә. Петербургта татар студенты белән танышса да, үз бәхете өчен көрәшергә көч тапмый. Ахырдан бер эчкече офицерга кияүгә чыга һәм бәхетсез язмышка дучар була. Ә аның яшьлек дусты – студент егет бәхетле Нәфисәнең тормыш юлдашы булуы әсәр ахырында ачыклана.

Әсәр башында Гөлсем ике баласын ияртеп Нәфисәләр урнашкан полубага килеп керә: *Нәфисә киемнәре юешләнеп тәннәренә сыланган, ябык куллары чөгендер кебек кызарган, нечкә ирене күгәргән, бите ак киндер булган шул хатынны, артында дер-дер килә торган боек балаларны күреп кызганды (5 том, 244 б). Нәфисәдә бу ябык хатынга, бу зәгыйфь балаларга кызгану хисе уянганга, ул аларның хәлләрен сорашырга кереште (5 том, 245 б.). Тәрәзәдән төшә торган фонарь яктысы аның болай да ак йөзенә саргылт бер төс кушты, ул мумия кебек катып Нәфисәне, үзеннән, үзенең бәхетеннән разый Нәфисәне*

сөзде (5 том, 272 б.). Аның йөзе үләргә хәзерләнгән кебек ап-ак, иреннәре зәңгәр, күзе курку, өметсезлеккә баткан итеп тапканга, Нәфисәнең көлүе яртысында ябылды (5 том, 296 б.). Доктор, бу карчыкны кайда күрдем соң, дип озак уйлап торганның соңында, җимерелгән, кипкән карчыкта ул 18-19 яшьлек, күбәләк кебек оча торган Гөлсемнең, үзе бер вакытларны бөтен хәятын фидә итәргә йөргән Гөлсемнең шәүләсен күрде (5 том, 296 б.). Гөлсем - ябык, күгәргән иренле, үләргә хәзерләнгән кебек ап-ак йөзле, күзләре өметсез, куркулы, кыскасы "җимерелгән, кипкән карчык". Автор бәхетсез Гөлсемнең тышкы кыяфәтен чагыштырулар ярдәмендә вак детальләр аша үтемле итеп тасвирлап бирә. Ә бит кайчандыр ул, 18-19 яшьлек чагында, күбәләк кебек оча торган Гөлсем булган! Гаяз Исхакый әлеге урында шушы контекстка гына хас индивидуаль чагыштыруны урынлы куллана: җимерелгән карчык һәм очып йөри торган күбәләк. Гөлсемнең бөтен кыяфәте укучы күңелендә онытылмаслык эз калдыра.

Әсәр ахырында Гөлсем яшьлек мәхәббәте белән күрешә. Әлбәттә, тормыштагы бу мөһим вакыйга тышкы кыяфәттә дә чагылырга тиеш. Әйтерсең, язучы героен ямьсез сурәтләвенә ояла һәм ахырдан булса да бер җөмлә өстәп куя: *Гөлсемнең йөзендәге җыерчыклар качты, аның йөзенә бер кызару йөгерде, битенә елмаю килде (5 том, 304 б.)*

Бәхетле Нәфисә исә әсәрдә ачылган гөлгә тиңләнә. Аның бәхеттән күзләре елмая, йөзе нурлы, тавышы йомшак: *Аның күзе елмайды, йөзе нурланды, тавышына әллә нинди йомшак бер аһәң катышты. Яңа хатын Нәфисәнең ачылган гөл кебек нурланып киткән йөзенә карап, моның бәхете минеке кебек түгелдер шул, дип, ике колагын тыңларга хәзерләде. (5 том, 247 б.)* Нәфисәнен һәр эшеннән, сүзеннән бәхет бөркелә, язучы аның нәкъ менә тышкы кыяфәтен тагын да арттырып сурәтләүне артык күрә кебек, башка портрет билгеләрен тасвирламый.

Героиняларның капма-каршы бирелгән портрет билгеләре аша Гаяз Исхакый өчен хатын-кызда йөз нурлылыгы һәм елмаюлы күзнең мөһимлеген сиземлибез. *Иртәнге яктыда Гөлсемнең яшьли картайган битен бик күп җыерчыклар каплады. Эчкә җыя алмый күзләрдән ташып чыккан бәхет*

елмаюы, Нәфисәнең йөзенә яшеннән дә артык яшьлек буявы сөртте (5 том, 294 б.).

Әсәрдәге башка персонажларнын да портрет билгеләренә тукталып үтик: *Хәзер дә бөтен кыяфәтләре күз алдымда... карасу бер костюм, бер зәңгәррәк, бер карарак булып китә торган муен бавы, ап-пак якалар, тирән генә уйлы күзләр (5 том, 248 б.).* Бу – Гөлсемнең яшьлек мәхәббәте, Нәфисәнең тормыш юлдашы Хәлил.

Кызгылт кофта кигән, чәчләрен бөдрәләтеп тараган тутакай килеп керде. Аның берлә бергә әллә нинди исле май, пудра исләре бүлмәне тутырды. Мин аның йөзенә куркынган кеше кебек карадым ул миңа шул вакытта, зур шәһәрләрдә кызлар тотучы юан симез яһүд хатыны кебек күренде (5 том, 289 б.); Тагы борылып кечерәеп калган әтине, кызарынган-бүртенгән тутакайны, пәҗегән шалкан кебек булган коданы, нишләргә белми аптырап калган яшь әфисәрне сөздем (5 том, 290 б.); Йорт караучы да, су ташучы да, ат башында йөрүче дә булып тора торган, бер кулы чулак, аягы чатан Зарифны ат башына утыртып чыгып киттем (5 том, 258 б.); Тутакай картайган, изрәгән, ләпшердәгән иде. Әти төссезләнгән, күңелсезләнгән иде (5 том, 291 б.); Сүзләргә җавап булыр булмас теге исерек, бер эполеты бөтенләй төшкән, берсе иңсәсенә аткырыйлы итеп эленгән, гаскәри шинельдәге исерек докторны килеп төртте (5 том, 296 б.). Мисалларда Гөлсемнең әтисе, тутасы, исерек ире һәм башка персонажларның портрет билгеләре китерелде. Игътибар итсәк, авторның һәр геройга мөнәсәбәте ачык сизелеп тора. Һәр сүз үз урынын һәм тәмен белеп кулланылган. Җәенке эпитетлар, индивидуаль чагыштырулар язучының ослыгын күрсәтеп тора. Әлеге ярдәмче геройларны тасвирлаганда әдип аларның психологик халәтенә керми, җиңелчә, әмма кабатланмас билгеләре аша тышкы кием һәм йөз чалымнарын сурәтли.

Яшьлегенең иң матур, иң пакъ бер битенең көтелмәгәндә болай бердән кырт киселүе, йөрәкнең иң тирән почмагында сакланган соңгы өметнең көзге сары яфраклар берлә каплануы, томалануы Гөлсемне тагы басты, тагы изде. Тормыш йөге астында изелгән аның билене тагы бөкте. Нәфисә берлә үткән тулы мәгънәле тормыш эчендә күптән онытылган яшьлек

хатирәләре, көтмәгәндә килгән шәйтан туе кебек, Хәлилнең тыныч күңелен болгатты, дулкынлатты. Бәхетле гаилә тормышының калын өресе астында, үзенең эсселеген, кайнарлыгын яшергән, саклаган аның йөрәк уты шул көзге җилнең искәртмәстән исүе берлә пәрдәсез, калкансыз калды. Аның уты тышка чыкты. Аның ялкыны дөньяга күренде. Ул йөрәкнең көйгән исе Нәфисәнең йөзенә бәрелде. Хәлил үзенең бәхетле тормышының остасы, зур күңелле шул саф хатынының алдында оялды. Аның олуглыгы астында муен иде. Башын бөкте. Нәфисә дә, бөтен гомерен кешеләргә ышануга, кешеләрнең яхшылыгына корган Нәфисә дә, ун ел эчендә баштанаяк иренә ышануга, инануга баткан, чумган Нәфисә дә, шул ара-тирә кызыл миләшләр, баланнар берлә генә бизәкләнгән сары яфрактан, сары кәфен киенгән көзге урман эчендәге шул юешле, суыклы көзге җил, аның күңелендә иренә каршы беренче мәртәбә шөбһә уятты. Иренең тугрылыгына каршы, кешеләрнең яхшылыга каршы йөрәгенә шик салды. Ул шөбһәне тиздән бетерә алмаганга, шуны кирәкмәгән чүп кебек читкә төртеп ташлый алмаганга, тормышның кәкереле-бөкереле тыкрыклары, почмаклары эчендә ул адашкан кебек булды, ул да көләчлегене югалтты, күңеленә әллә нинди бер исемсез эчпошыргыч (нәрсә) җирләште, әллә нинди күрелмәгән бер көя аның тынычлыгын ашый башлады (5 том, 307 б.). Әлеге мисалда төп геройлар – Нәфисә, Хәлил һәм Гөлсемнең портрет билгеләре белән янәшә психологик халәтләре дә үстерелә. Автор тиңдәш кисәкләр, тиңдәш җөмләләр, кабатлаулар, индивидуаль чагыштырулар аша геройларының эчке халәтләрен һәм портрет билгеләрен кабатланмас итеп ачып сала.

Димәк, башлангыч чор иҗатында әдип персонажларының тышкы портретларын кискен-кискен детальләр белән аз гына сурәтләп куя да, аларга басым ясамый. Аңа хәрәкәт, вакыйганың үстерелеше, динамизм кирәк. Геройлар гомуми характерда гына ачыла. Ә алга таба әсәрләрдә кабатланмас, онытылмас персонажлар гәүдәләнә. Аларның портрет билгеләрен сурәтләгәндә язучы кабатлаулар, тиңдәш кисәкләр, тиңдәш җөмләләр, индивидуаль һәм контекстуаль чагыштыруларга мөрәҗәгать итә. Гаяз Исхакыйга көләч йөзле, тулы битле, төп-төз

гәүдәле, нык кешеләр ошый. Автор геройларының портрет билгеләре белән бергә психологик халәтләрен дә сурәтли. Бар яклап әдипнең язучы буларак осталыгы ачыла.

Чыннан да портрет билгеләре белән укучы күңелендә онытылмаслык уелып калган геройлар Исхакый иҗатында җитәрлек: "Остазбикә"дә Сәгыйдә, яше югалган кебек исеме дә югалган, үзенең өе аша сурәтләнүче Сөннәтче бабай...

Әдәбият

1. Гальперин И.Р. Текст как объект лингвистического исследования. М., "Наука", 1981. – 139 с.
2. Исхакый Г. Сайланма әсәрләр, 15 томда. 1 том. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1998, 399 б.
3. Исхакый Г. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татарстан Республикасы "Хәтер" нәшрияты (ТаРИХ), 2002. – 480 б.
4. Сафиуллина Ф.С. текст төзелеше: Югары уку йортлары өчен дәреслек- кулланма. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993. – 263 б.

Шәйдуллина Р.Р.

Бертуган Хөсәеневләрнең татар мәгърифәте өлкәсендәге эшчәнлекләре (XIX йөз ахыры-XX йөз башы)

Татар буржуазиясенең XIX йөз ахыры-XX йөз башы иҗтимагый-мәдәни үзгәрешләрдәге төп роле ачык билгеле. Мәгариф өлкәсендәге җәдиди реформаларны, милли матбагачылык, татар газета-журналларын булдыруны, милли әдәбият һәм сәнгать үсешен нәкъ менә татар сәүдәгәр-сәнәгатькәрләре финанс тәэмин иткәннәр.

Татар милләтенең рухи яңарышында катнашкан бик күп әдипләр арасында төп урыннарның берсен, әлбәттә, чыгышлары белән Оренбург якларыннан 4 миллионлы мирасияләре бертуган Әхмәт (1837-1906), Гани (1839-1902) һәм Мәхмүт (1839-1910) Хөсәеневләр алып торалар. Аларның әлеге гаять зур капиталлары – тырышлык, салкын акыл белән эш итү, кайвакыт хәтта эчке

сиземләүгә (*интуициягә*) таяну нәтиҗәсе. Чөнки грамота белмәгән килеш тә, Хөсәеневләр озак еллар дәвамында, югалтуларга, авырлыкларга бирешмичә, төгәл максатлар куеп эшләгәннәр һәм әлеге зур мирас туплауга ирешкәннәр.

Ләкин мал туплау белән бергә алар аның аерым бер өлешен милләт ихтияҗларын канәгатьләндерүгә сарыф иткәннәр. Агай-эне Хөсәеневләр, дин белән милләтнең тәне булып акча торса, аларның рухы (җаны) булып гыйлем белән мәгърифәттер дигән караштa торганнар, ә иң зур булганлыкны байлык һәм абруйлык аркасында башкаларга файда кылуда күргәннәр. Әлбәттә, аларның һәрберсе әлеге эшләрне үз күзлегеннән чыгып башкарган, һәрберсе төрле дәрәҗәдә күңеллен биргәннәр.

Әхмәт бай милләтнең киләчәген укымышлы белгечләр әзерләүдә күргән. Мәктәп-мәдрәсәләрне яңа тәртипләргә нигезләп үзгәртеп кору мәҗлесләрендә ул үзе дә болай дип әйткән: «Мин биш сумнан дүрт миллионлык мирас җыйдым. Шуңа күрә берегез дә минем турында надан, ялкау, зирәк түгел дип әйтә алмый. Ләкин әлеге сыйфатларга ия булсам да, мин дүрт кыш дәвамында укырга һәм үз исемемне язарга өйрәнә алмадым. Моның төп сәбәбе – безнең мәктәп-мәдрәсәләребездә тәртип булмау» [1].

Әхмәт бай татар халкын һөнәрле итәргә тырышкан, аны сәнәгать-сәүдәгә тарту кирәклеген аңлаган. Ә инде моның өчен рус һәм татар телләрен белү, дөньяви фәннәрне үзләштерү, заман таләпләреннән хәбәрдар булу зарурияте килеп баскан. Шуңа да милләтнең алга таба чәчәк атуы, иң беренче чиратта, татар-мөселман мәгариф системасын үзгәртеп кору, җәдиди мәктәп-мәдрәсәләр ачу белән бәйләнгән. Кадими мәдрәсәләр тәртипләрен Әхмәт бай бик яхшы белгән. Шуңа аларның биналарын яңарту, шәкертләрне укыту шартларын яхшырту, гигиена һәм сәламәтлекне саклау кагыйдәләренә туры китерерлек итеп оештыруга материаль ярдәм итеп торырга омтылган.

Шулай итеп, Казанда яшәү дәверендә аның акчаларына һәрберсе 3000 сумга төшкән 20 мәчет һәм мәдрәсә салынган, 40 укытучыга хезмәт хакы түләнгән, 200 уку йорты дәреслекләр белән тәэмин ителгән [2].

Шулай ук халык мәгариф системасын үзгәртү юлында зур бер казаныш буларак, 1889 елда Оренбургта атаклы җәдиди «Хөсәения» мәдрәсәсе ачылган. Әлеге уку йортын шулай ук Әхмәт байның хәйрия эшчәнлегенең нәтиҗәсе итеп карарга кирәк. Мәдрәсәдә нигездә дөньяви фәннәргә өстенлек бирелгән. Аеруча математика көчле укытылган. Әхмәт бай «Хөсәения»не теория һәм практиканы уңышлы берләштерүче белгечләр әзерли торган уку йорты буларак күргән. Шул максатлардан Каһирә һәм Истамбулдан укытучылар чакырылган, дөньяви фәннәр - төрек телендә, ә дин нигезләре гарәп телендәге дәреслекләр буенча укытылган. Әлеге мәдрәсә укытучылары татар телендә тарих, география һәм башка фәннәрдән яңа дәреслекләр эшләп чыгарганнар. «Хөсәения»дә Р.Фәхретдин, С.Рәмиев, С.Сөнчәләй, Ш.Камал, Ф.Кәрими һ.б. кебек мәшһүр затлар дәрес биргәннәр.

Ә инде 1906 елда «Хөсәения» мәдрәсәсенең өч катлы яңа бинасы төзелеп беткән. Шуңа бәйле эшчәнлекне тагын да киңрәк җәелдерү мөмкинлекләре арткан.

Әхмәт бай Ә инде үзенең вафатыннан соң, ул ярты миллионга якын сумманы хәйрия эшләренә сарыф итәргә васыять итеп калдырган. Әхмәт бай бик төгәл рәвештә әлеге акчаларның нәрсәгә һәм ничек итеп сарыф ителәчәген белгерткән. Варисларына аларны «эшләтү» һәм алга таба татар милләтенә хезмәт итәчәк табыш алу өчен җентекле план төзеп калдырган.

Әлеге васыятьнамәнең түбәндәге өлешләре турыдан-туры татар мәгариф системасының үсешен тәэмин итүгә багышланган:

1) Фидиясенә *(ягъни аның гөнаһысын коткару өчен бирелгән мал буларак*) һәр елга 250 сумнан хисап итеп җыелган суммадан (13.751 сум) Оренбургта Хөсәенев мәдрәсәсендә укучылардан тәрбиячесе юк 50 ятимнең һәркайсысына 10нар сумнан 6 елгача (3000 сум) бирергә, авылларда тәртип илә укытучы 60 мөгаллим, 40 мөгаллимәгә һәркайсысына 10нар сумнан 5 елгача (5000 сум) бирергә.

2) Оренбургтагы «Мәдрәсәи Хөсәения» бинасына һәм аңа варидәт *(керемнәр*) өчен Мәкәрҗәдәге Хөсәенев подворьесын *(сәүдә йортын)* вәкыф итеп *(җәмәгать ихтыяҗларына калдырылган милек)* даимә дин белүче вә өйрәтүчеләр җитештерер өчен булган шул мәдрәсәнең мәктәбенә ярдәмгә.

3) Шул мәдрәсәнең идарә хәяты тасрифында улмак *(тасриф - сарыф итү, үзгәртү)* шарты илә 200 000 сум калдырып, варидәтене *(керемнәрне)* Оренбургтагы 7нче мәчеткә һәм башка мәгариф юлына сарыф итәргә.

4) 120 000 сум вәкыф итеп, төрле килгән файдасы белән һәр ел (500 сум) китап бастырырга, һәр ел саен 12шәр баланы һөнәр мәкәпләрендә укытырга, Казандагы русча дарелмөгаллиминдә *(ир-атлардан укытучылар әзерли торган институт)* 2шәр шәкерт тәрбия итәргә, тиҗарәт (*сәүдә)* мәктәбендә 4әр бала, гимназиядә 2шәр, реальный училищеда 2шәр, Русиянең гали *(югары)* мәктәбендә 4әр, Гарәбстанда 2шәр шәкерт укытырга һәм 60 мәктәпнең мөгаллимнәренә хезмәт хакы түләп торырга.

5) Мәкәрҗәдәге Канлы буендагы 4000 сум чамасы варидәт *(керем)* китерә торган йортын Казандагы «Мәдрәсәи Мөхәммәдиягә» вә шул мәхәлләнең мәсҗеденә вакыф итәргә [3].

Гани бай Хөсәенев исә, татар-мөселманнарны башлангыч белемле итү идеясе белән билгеле. Шуңа бәйле Гани байның йорты еш кына ысулы җәдиднең штабына әверелгән, ул җәдидчелек тарафдарлары белән даими багланышларда торган, аларны бик теләп кунак иткән, татар халкының киләчәге турында фикер алышкан. Алар арасында И.Гаспралы, Р.Фәхретдин, Ф.Кәрими, Г.Баруди кебек татар дөньясының билгеле зыялы, мәгърифәтче шәхесләрне атарга мөмкин.

Гани байның халыкны агарту өлкәсендә интенсив эшчәнлеге 1896 елда башланып киткән. Әйтергә кирәк, Гани бай яңа мәдрәсәләр ачу эшендә материаль ярдәм күрсәтеп кенә калмаган, еш кына әлеге процесста үзе дә актив катнашкан. Аңа еш кына уку-укыту процессында туып торган бик күп фәнни-практик оештыру мәсьәләләрен – мәктәп режимы, уку планы, уку программалары, дәреслекләр, педагогика һәм дидактика мәсьәләләрен хәл үзенә итәргә туры килгән. Ул, аларның һәрберсенә бик җитди карап, җентекләп өйрәнгәннән соң гына билгеле бер карар чыгарган, һәр эшен уйлап эшләгән, аның нәтиҗәләрен дә алдан күздә тотып башкарган.

Мәсәлән, 1901 елда Уфа шәһәрендә узган җәдидчелекнең әдәби-педагогия эшлекләләре җыелышында яңа ысулы җәдидкә нигезләнгән мәктәпләр өчен бердәм программа төзү мәсьәләсе

тикшерелгән. Әлеге мәҗлестә Гани бай Хөсәенев та катнашкан, урын алган бәхәсләрне, фикер алышуларны зур игътибар белән күзәтеп барган.

Гани бай ысулы җәдид белән балалар укутуны нәтиҗәле итү эшендә һичшиксез хәл ителергә тиеш проблема итеп яхшы мөгаллим һәм мөгаллимәләр эзерләү, аларны мәдрәсәләргә урнаштыру һәм хезмәт хакын түләүне күргән.

Шуңа, мәсәлән, 1896-1901 елларда Гани бай һәр елда мөгаллимнәр әзерләү, мәктәпләр ачу, укытучыларга эш хакын түләү өчен үз хисабыннан 35-45 мең сум акча тоткан [4].

Ә 1898 елның җәендә Сәгыйть бистәсендә яңа җәдиди мәктәп-мәдрәсәләргә укытучылар әзерләү өчен кыскы вакытлы курслар оештырган [5]. Әлеге күренешнең татар тормышында әле яңа булуына карамастан, алар халык арасында бик тә популяр булганнар, бөтен Россиядән шәкертләрне үзләренә туплаганнар. Ләкин тиз арада патша хөкүмәтенең игътибарын үзләренә юнәлтеп ябылганнар.

Гани бай шулай ук хатын-кызларны укытуга аеруча игътибар биргән. Чөнки нәкъ менә кызлар булачак милләт аналары итеп күзалланганнар, аларны белемле итү иң беренче максатлардан саналган. Шуңа күрә Гани бай тарафыннан 1897 елда мөгаллимәләр хәзерләү курслары оештырылган. Ул курсларга килгән барлык мөгаллимәләрнең юл чыгымнарын түләгән, уку дәверенә ашау-эчү чыгымнарын үз өстенә алган, аларны китаплар һәм башка уку-язу әсбаплары белән тәэмин иткән. Алга таба әлеге мөгаллимнәр үз эшләренең барышы турында Гани байга хат язып торырга тиеш булганнар [6]. Бер үк вакытта Гани бай әлеге укытучылар киткән районнарның күренекле мөдәррисләре, хәзрәтләре, байлары белән дә хат язышкан һәм ысулы җәдидне кертү өчен бик күп халыкны хәрәкәткә китергән [7].

Әйтергә кирәк, Гани байның да үзеннән соң татар милләтенә хәйрия буларак мирасының аерым өлешен калдыру теләге булуы билгеле. Ләкин ул кинәт кенә вафат булып, васыятьнамәсен тиешле рәвештә рәсмиләштерергә өлгермәгән.

Ләкин бу факт аның куйган хезмәтен бер дә юкка чыгармый. Шуңа бүгенге көндә аның бертуган агасы Әхмәт бай үзенең

вакыфы белән билгеле булса, Гани бай — укыткан шәкертләре һәм әзерләгән мөгаллимнәре белән билгеле шәхес.

Мәхмүт бай һәм аның эшчәнлеге хакында исә мәгълүматлар бик үк күп булмаса да, гадәттә, аның исемен нигездә туганнары Әхмәт һәм Гани белән бергә искә алалар. Мәсәлән, 1910 елда дөнья күргән «Йолдыз» газетасында түбәндәге фикерләр әйтелгән: «Дин вә милләт юлында иткән хезмәтләре һәм калдырган вакыфлары сәясендә (*өлкәсендә*) Әхмәт вә Гани байлар бөтен галәме исламга мәшһүр кешеләр иделәр. Мәхмүт бай да агалары шикелле үзенең хәйратләре илә зур шөһрәт тапты» [8].

Мәхмүт бай үзенең туганнарына һәрвакыт теләктәшлек кылган, аларның эшләрендә, теләк-омтылышларында иң беренче ярдәмче булып торган.

Мәхмүт бай туганнары белән бергә җәдиди мәктәп-мәдрәсәләр ачу, белем-мәгърифәт тарату, мөселман ятимнәре һәм гарипләренә ярдәм итү һ.б. шундый изге эшләрдә бик теләп катнашкан һәм үз өлешен керткән.

Мәсәлән, ул үзенең Тәфтиләү утарын Оренбург һәм Каргалы мәктәп-мәдрәсләре файдасына вәкыф иткән. Шуны әйтергә кирәк, 2100 дисәтинә җирдән гыйбарәт булган Тәфтиләү утарының бәясе 400 мең сумга якын булган [9].

Хәтта вафатыннан соң да ул, агасы Әхмәт бай кебек үк, мирасының аерым бер өлешен хәйрия эшләренә васыять итеп калдырган. Аны җирләгән көнне 40лап муллага 100әр сум, 100ләп мөәзин һәм хәлфәләргә 50шәр сум, 200ләп кешегә 10нар сум, 300гә кадәр кешегә 3әр сум, калганнарына көмеш тәңкәләр таратылган. Ә фидиясенә *(ягъни аның гөнаһысын коткару өчен бирелгән мал буларак)* 13 мең сум калдырылган. Моннан башка Мәхмүт бай үзенең якыннарына һәм Каргалы вә тирә-юнендәге кыя һәмкүперләргә 25 мең сум, хаҗга җибәрергә 10 мең сум һәм башка урыннарга 50 мең сумнан артыграк васыять иткән.

Әлбәттә, Мәхмүт бай эшчәнлегенең киңлеге Әхмәт бай белән чагыштырганда бераз сүлпәнәеп һәм кечерәеп кала, ләкин эш нигездә сумаларның зурлыгында да түгел. Төп игътибар әлеге шәхесне татар милләтен, туган халкын кайгырту һәм аның үсешен тәэмин итүнең ихлас теләгендә. Нәкъ менә әлеге ихласлык, эчкерсезлек, башкаларны кайгырту Мәхмүт байны

атаклы Хөсәеневләрнең аерым бер вәкиле итә һәм аңа карата соклану һәм ихтирам хисләрен уята.

Шулай итеп, агай-эне Хөсәеневләрнең һәрберсе, әлбәттә төрлесе төрле дәрәҗәдә һәм төрле рәвештә, иң беренче чиратта, татар мәгариф системасын камилләштерү ярдәмендә милләткә хезмәт итү юлында зур эшләр башкарганнар. Нәкъ менә мәгърифәт тарату өлкәсендәге эшчәнлекләре - аларның татар халкы рухи үсешенә керткән иң зур иганәләренең берсе.

Әдәбият

1.Фәхретдин Р. Әхмәт бай // Р.Фәхретдин. – Оренбург. – 1911. – Б.15-16.

2. Фәхретдин Р. Әхмәт бай // Р.Фәхретдин. – Оренбург. – 1911. – Б.28-30.

3.Әхмәт бай васыяте // Йолдыз. – 1906. – 17 декабрҗ. – Б.3.

4.Гайнетдинов М. Гани бай // Мәңге тонықланмас көзгебез. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2006. – Б.342.

5.Валиди Дж. Очерки образованности и литературы волжских татар / Дж. Валиди. – М., 1923. – С.61.

6. Гайнетдинов М. Гани бай // Мәңге тонықланмас көзгебез. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2006. – Б.335.

7. Гани бай / Төз. Б.Шәрәф. – Оренбург, 1913. – Б.18-22.

8. Мәрхүм Мәхмүт бай // Йолдыз. – 1910. – 17 август. – Б.3.

9. Мәрхүм Мәхмүт бай // Йолдыз. – 1910. – 17 август. – Б.3.

Шәкүрова М.М., Шәехов М.Р.

Г. Гыйльмановның “Фронтовик” парчасына лингвистик анализ ясау үрнәге

Татар һәм рус мәктәпләрендә татар теленнән белем бирүнең нәтиҗәлелеген, сыйфатын арттыру укучыдан, теоретик материалны аңлатканда, тирән белем бирү белән беррәттән, аларда телгә карата кызыксыну уятуны һәм иң мөһиме — аны аңлап, дөрес итеп сөйләшергә, укырга һәм язарга, логик фикерләргә өйрәтүне, заманча технологияләрне файдаланып, телнең психолингвистик үзенчәлекләренә дә, әдәби әсәргә лингвистик анализ ясауга да игътибар бирүне таләп итә. Соңгы

елларда сүзләрнең килеп чыгышын билгеләүдә, бирелгән җөмләләрдә ассызыкланган сүзләрнең мәгънәләрен аңлатуда, укучыларның язма эшләрендә бик күп төгәлсезлекләр китә. Мәктәп программасында сүзлекләр белән эшләүгә бик аз вакыт бирелә. Шуңа күрә татар теле дәресләрендә синонимнар, антонимнар, омонимнар, аңлатмалы, фразеологик һ.б. сүзлекләр белән һәр дәрестә диярлек эшләү зарури. Шуны исәпкә алып, татар теле дәресләрендә сүзлекләр белән бәйле булган төрле күнегүләр (лексик-фонетик, лексик-орфографик, лексик-семантик, лексик-морфологик, лексик-синтаксик күнегүләр) эшләтү дә үзен аклый. Чөнки укучыларның сүз байлыгын арттыру, лексик минимумны ачыклау, сүзләрнең кулланылышын, төрләнешен, мәгънә төсмерләрен җөмләләр һәм текст эчендә карау, дөрес әйтелешен, язылышын өйрәтү - татар теленең мөһим мәсьәләләреннән санала. Текстлар аша телнең гаять киң мөмкинлекләрен, функциональ үзенчәлекләрен күрсәтергә дә җай туа: абзацара бәйләнешне ачыклау, текснының семантик кырын билгеләү, сүзлек составын барлау, синонимнар, антонимнар һәм омонимнарның кулланылышы, тел-сурәтләү чаралары, морфологик, синтаксик һәм пунктуацион үзенчәлекләрне күрсәтү һ.б. Болар барысы да татар теле программаларында күрсәтелгән коммуникатив, лингвистик, этнокультура өлкәсенә караган компетенцияләрне тормышка ашырырга ярдәм итә. Лингвистик анализ ясау өчен, Г. Гыйльмановның “Фронтовик” исемле парчасын сайладык: «Бүген, көтмәгәндә, күп юудан агарып беткән» дип башлана, «… рухи ныклык, ихтыяр көче биреп киткән иде...» дип бетә. Хәзер шуңа җентеклэбрәк тукталып үтәбез.

I. Гомуми күзәтү

Лингвистик анализның төп объекты итеп Г. Гыйльмановның “Фронтовик” исемле парчасын сайладык. Нәкъ менә шушы текстка тукталуыбызның берничә сәбәбе дә бар:

1) текст ике гасыр чигендә язылган, ә аның авторы – әле дә иҗат итүче әдип, шуңа күрә бу әсәр үрнәгендә хәзерге татар әдәбиятының торышы турында билгеле бер күзаллау тудырырга була;

2) парча тәмамланган, автор әйтәсе килгән фикер тулысынча белдерелгән, ягъни текст бердәмлеге бозылмаган;
3) текстның теле төзек һәм тәэсирле;
4) укучыны беренче укыдан ук хисләндерә, дулкынландыра торган тормышчан вакыйганың сурәтләнүе һ. б.

Жанры буенча текст автор тарафыннан парча дип билгеләнә. Парча – ул фәлсәфи эчтәлекле, хискә корылган, югары осталык белән язылган кечкенә күләмле лирик әсәр. Гадәттә парчада хикмәтле тормышчан вакыйганы сурәтләү алгы планга чыга, укучыга тәэсир итү, аны уйландыру максат итеп куела. Шуңа күрә бу текстта да һәм тасвирлау, һәм хәрәкәтне күрсәтү киң кулланыла.

Гомумән алганда, бу парчада ике төрле стиль аерылып тора: сорау бирүче автор-хикәяләүче сөйләме һәм хатирәләрен бәян итүче фронтовик картның сөйләме. Бу ягы белән текст интервью жанрына якын тора, ягъни сорау бирүче һәм җавап кайтаручы затларның сөйләме үзенчәлекле чагыла. Бу текстта әлеге аермалар фигыльнең заман формаларында, алмашлыкларны куллануда, җөмләнең катлаулыгында һ. б. күренеп тора.

Интервьюга якын торганга күрә, текстның теле гади сөйләм үзенчәлекләре белән баетылган. Кисәкчәләр, тормыш-көнкүреш сүзләре һәм әйләнмәләре, үзенчәлекле җөмлә конструкцияләре – барысы да үзгә бер стиль тудырырга ярдәм итә. Ләкин автор, бу чараларны чама белән кулланып, югары әдәби стильне саклап кала, әдәби әсәргә хас югары зәвыкълылыкны бозмый.

Текстның мәгънәви-семантик кырын билгеләүче сүзләргә тукталып китү уңышлы булыр. Парчада иң еш кулланылган сүз – *малай*, ул әсәрдә җиде тапкыр кулланыла һәм теманы ачарга, бу образның хәлиткеч көчкә ия икәнен ассызыкларга ярдәм итә. Шулай ук төп темага мөнәсәбәттә *фронт* һәм *сугыш* тамырларыннан ясалган сүзләр бишәр тапкыр очрый (мәсәлән, сугыш – сугышчы – сугышчан, фронт – фронтовик һ. б.). Моннан ары, *мин* һәм аның юнәлеш килеш формасы бергә 9 тапкыр, *ап-ак* сыйфаты 5 тапкыр кулланыла.

Текстта 12 абзац, 453 сүз, 2621 сүз бар. Абзацлар үзара бик тыгыз бәйләнгәннәр һәм уңышлы итеп бүленгәннәр. Аларның

өчесе генә диалог рәвешендә башланган, ләкин 7 – 11 абзацлар бер үк кешенең туры сөйләмен – фронтовикның хатирәләрен чагылдыра.

Абзацларны башлап җибәрүдә бертөрлелек күзәтелми, автор төрле чаралардан мул куллана. Аерым алганда, абзацара бәйләнешне булдыруда түбәндәге сүз төркемнәрен куллана:

- исем: Әңгәмәдәшем...; Малай...;
- сыйфат: Ап-ак чәчле!...;
- сан: Кырык беренче елның...;
- алмашлык: Без...; Мин...; Кая ул...;
- рәвеш: Бүген...;
- теркәгеч: Ә мин...; Әллә нинди...;
- кисәкчә: Инде мин...; Бик авыр...

Бу чараларны сайлау очраклы түгел, чөнки алар һәрберсе билгеле бер мәгънәви әһәмияткә ия. Мәсәлән, рәвеш һәм сан сүз төркемнәре текстның темасына кертеп җибәрергә булыша, кисәкчәләр сөйләм үзенчәлекләрен бирергә ярдәм итә, алмашлыклар исә абзацларны бердәм тотып тора һ. б.

II. Текстның лексик составы

1. Сүзләрнең килеп чыгышы ягыннан.

Бу парча алынмаларга бик бай – барлыгы 43 сүз. Аларны ике төркемгә бүлеп карарга була: **гарәп-фарсы** һәм **рус-Европа** телләреннән кергән сүзләр.

Текстта 25 гарәп-фарсы алынмасы табылды, шуларның дүртесе фарсы теленән кергән: дан, һәрвакыт, һәвәс, әзмәвер. Калган 21 алынма – төрле өлкәләргә карый торган гарәп алынмалары: вакыт, хатирә, гаҗәп, гомер, рухи, газаплы һ. б.

Икенче төркемгә 18 мисал табылды. Монда 6 рус (*Мәскәү, часть, полуторка, орудие, снаряд, окоп*), 6 латин (*фронт, фронтовик, орден, минут, ветеран, граната*), 3 немец (*лафет* – артиллерия тубы торган җайланма; *солдат, фашист*), 2 грек (*гимнастерка* – совет армиясендә хәрби кием булып хезмәт иткән тыгыз тукымалы һәм туры якалы күлмәк; *эпопея*) һәм 1 француз (*каска*) сүзе кулланылган. Игътибар белән караганда әлеге төркем сүзләренең барысы да диярлек хәрби лексикага караганы, сугыш белән бәйле булганы ачык күренә. Бу сүзләрне, терминнарны автор, махсус кулланып, билгеле бер эмоциональ фон, сугыш

атмосферасын тудыра. Моннан ары, бу алынмалар ярдәмендә автор сөйләм үзенчәлекләрен дә ассызыклый. Мәсәлән, *полуторка* – сугыш вакытында кулланылган 1,5 тонна күтәрешле Газ-АА йөк машинасы. Ләкин автор аны үз атамасы белән калдыра, мәсәлән, *йөк машинасы* дип үзгәртми, чөнки сугышны башыннан ахырына кадәр үткән фронтовик аңында ул шул исем белән яши.

2. Синонимнар кулланылышы.

Автор синонимнарны да киң һәм уңышлы куллана. Текстта **саф** синонимнарга карый (хәлсезләнү – бетешү, моңсулану – уйчанлану) **контекстуаль** синонимнар күбрәк очрый. Мәсәлән: җиңел – күңелле – якты (минутлар), моңсулану – уйчанлану – басылу, төпсез – тонык (күз карашы). Шулай ук **синтаксик** синонимнар да бар: рухи ныклык – ихтыяр көче, үзе дә сизмәстән – очраклы рәвештә.

Язучы барлык төр синонимнарны билгеле бер сурәт тудыру, градация ярдәмендә тәэсирне арттыру өчен куллана. Аларны еш кына бер-бер артлы китерү дә әсәрнең әдәби яктан көчен арттыра.

3. Антонимнар кулланылышы.

Парча, гомумән алганда, антитезага корылган: сугыш белән тынычлык, сугышчылар һәм фронтовик белән кечкенә малай, фронтовик карт белән бала һ. б. каршы куела. Шул сәбәпле текстта антонимнар еш очрый һәм әсәрдәге антиподларны ассызыклап тора. Моңа саф антонимнар да (җиңел – авыр, кап-кара – ап-ак), киңрәк кулланылган контекстуаль антонимнар да (күңелле – газаплы, тумыштан – сугыш сөременнән, үлгән – яшәү гаме бар һ. б.) ярдәм итә.

4. Фразеологизмнар кулланылышы.

Әйткәнебезчә, парчаның теле матур һәм тәэсирле. Моны фразеологик гыйбарәләрнең күплеге белән дә аңлатып буладыр. Мәсәлән: *томам да арттан калмый озатып йөрү, күз алдына килү, хатирәләрдән бушану, хатирәләргә кагылмау, хәлләрне күздән кичерү, мактануның әсәре дә булмау, эһ тә итмәү* һ. б.

5. *Сурәтләү чаралары*ннан түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин:

Эпитетлар: иң җиңел, күңелле, якты минутлар; көзге томан; чын солдат; җансыз гәүдә һ. б.

Метафоралар: төпсез, тонык күз карашы, яшәү гаме, полуторка (синеекдоха), фронт эпопеясы, күңел төпкесе һ. б.

Кабатлаулар: 1) Малай... Ап-ак чәчле малай...; 2) Ап-ак чәчле! Беләсеңме, ап-ак...; 3) Әйе шул, бик тә гаҗәп тоелган иде безгә бу күренеш. Әмма иң гаҗәбе алда иде әле.

Антитеза: фронтовик/сугышчы – малай/бала, кыска вакыт – фронт эпопеясы, юудан агарып беткән гимнастерка – өч Дан ордены, истәлекле хатирә – мәзәк хәл һ. б.

III. Морфологик үзенчәлекләр

Текстның морфологиясе, фикерне җиткерү өчен сайланылган сүзләре дә игътибарга лаеклы. Парчада кулланылган сүзләрне тикшереп, без түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

1. **Исем** белән **фигыль** сүз төркемнәре бер үк санда диярлек кулланылганнар: исем – 118, фигыль– 126 (шуның 23 е – ярдәмче фигыль).
2. **Исем**нең бөтен килешләре дә бер дәрәҗәдә актив кулланылган.
3. **Фигыль**нең кушма формасы бик актив. Мәсәлән, булышып тору, тартып килү, сөйләп китү, булышып калу һ. б.
4. Автор-хикәяләүче сөйләмендә фигыльнең билгеле һәм тәмамланмаган үткән **заман**нары өстенлек итә, ә фронтовик сөйләмендә аларга хәзерге заман формасы да өстәлә һәм хатирәләрне күз алдына китереп бастырырга ярдәм итә. Шулай ук билгесез һәм күптән үткән заманнар да кулланыла.
5. **Сыйфат** һәм **рәвешләр** дә шактый еш күзәтеләләр һәм сурәт тудыру, тәэсирле образлар ясау өчен хезмәт итәләр.
6. **Алмашлыклар**ның күп төркемчәләре бирелгән: <u>зат</u> – мин, без, ул, син; <u>сорау</u> – кая, ничек, нинди; <u>күрсәтү</u> – менә, шушы, бу, әнә; <u>билгеләү</u> – үз һ. б.
7. Тексттагы **кисәкчәләр** үзенчәлекле функция үтәп киләләр: алар ярдәмендә автор әсәргә гади сөйләм элементларын кертә, хикәяләүне җанландыра. Мәсәлән, *иң, кап-, ап-, бик* кебек арттыру кисәкчәләре кирәкле сыйфатларны аерып күрсәтә; *инде, гына, да/дә, үк* һ. б. кисәкчәләр текстка экспрессивлык өсти. Иң әһәмиятлесе – язучы кисәкчә һәм бәйлекләрне кулланганда чаманы белеп эш итә.

IV. Синтаксик үзенчәлекләр

Һәр язучының аңа гына хас стиль үзенчәлекләрен һәм сурәтләү алымнарын билгеләүдә текстның синтаксисы, ягъни сөйләм төзелеше зур урынны тота. Парчада әлеге үзенчәлекләр җөмләләрнең төзелешендә ачык чагыла. Язучы, текстны артык катлауландырмау, җиңел аңларлык итү һәм сөйләм теленә якынайту максатыннан чыгып, күбрәк кыска, гади җөмләләрне куллана. Шуның сәбәпле парчада бары тик бер тезмә, 7 иярченле кушма җөмлә (иярчен аергыч, тәмамлык, рәвеш, шарт җөмләләр), бер катнаш (унынчы абзацның өченче җөмләсе) һәм күп иярченле катлаулы кушма җөмлә (унынчы абзацның икенче җөмләсе) табылды.

Гади җөмләләрнең дә кулланылышы игътибарга лаек. Автор бер составлы һәм ким җөмләләрне яратып файдалана: барлыгы 9 бер составлы җөмлә (алтысы – атау, өчесе – фигыль) һәм 12 ким җөмлә очрый. Болар ярдәмендә әдип сөйләмне тизләтә, активлаштыра. Шул ук вакытта, кушма җөмләләрне дә кертеп, кирәк урында темпны акрынайта, салмакландыра (мәсәлән, җиденче абзац).

Парчадагы җөмләләрнең күбесе аерымланган хәл яки тиңдәш кисәкләр белән катлауландырылганнар. Барлыгы 5 аерымланган хәл табылды, шуларның берсе өтерләр белән аерылмаган. Бу пунктацион хатаны болай төзәтергә була: Үрелебрәк карасак, орудие лафетында**, канга буялып, **бер бала ята.

Текстта кулланылган 13 тиңдәш кисәк тә форма ягыннан аерыла. Мәсәлән: Әңгәмәдәшем шунда ук *уйчанланып*, *басылып* калды. (тиңдәш хәлләр, гади); Яралылар төшәлгән *ат-арбалар* да, *полуторкалар* да үтеп-сүтеп йөри... (тиңдәш ияләр, гади); ... Бу абзый миңа... *рухи ныклык*, *ихтыяр көче* биреп киткән иде... (тиңдәш тәмамлыклар, җәенке) һ. б.

V. Пунктуацион үзенчәлекләр

Сәләтле язучылар әсәрдәге тыныш билгеләрне фикерне төгәл җиткерү һәм укучыга көчлерәк тәэсир итү өчен оста куллана беләләр. Г. Гыйльманов та бу канунны яхшы үзләштергән. Парча жанры көчле хисләргә һәм тирән фикергә корыла, шуңа күрә текстның пунктациясе дә үзенчәлекле:

1. Текстта барлыгы 14 тапкыр **күпнокталар** кулланылган. Алар, әсәрдәге тирән фәлсәфи фикерләрне аңлау өчен, паузалар

хасил итә һәм сөйләмнең салмаклылыгын белгертә. Күп нокталар аеруча фронтовик хатирәләрендә мул кулланыла һәм персонаж сөйләменең үзенчәлекләрен күрсәтә. Автор-хикәяләүченең сөйләме исә башта тиз һәм активрак булса да, соңгы абзацта кискен үзгәрә: фронтовикның сүзләре аны уйландыра, рухи яктан баета. Моны сиздерү өчен, автор махсус рәвештә унберенче абзацны күп нокталар белән бетереп, соңгысын янә күп нокталар белән башлый.

2. Тиңдәш кисәкләр һәм аерымланган хәлләр еш кулланылу сәбәпле, **өтерләр** саны да текстта 41гә җиткән. Шуларга тагын аерымланган хәлнең янында куелырга тиешле өтерне дә өстәргә кирәк.

3. Текстның тәэсирен сиздерү өчен, автор **?**; **!**; **?!**; **?..** катнаш билгеләрен дә еш куллана һәм персонажларның төрле хисләрен, эмоциональ халәтен төгәлрәк бирүгә ирешә.

Гомумән алганда, әсәрдәге тыныш билгеләр (югарыда искә алган бер хатаны искә алмаганда) дөрес һәм урынлы кулланылганнар, әсәрнең стилен бирүгә дә хезмәт итәләр.

VI. Йомгак

Бу төр тикшеренүләр текстны яхшырак үзләштерергә, язучы стиленең үзенчәлекләрен табарга, татар теленең байлыгын аңларга ярдәм итә. Г. Гыйльмановның “Фронтовик” парчасын өйрәнү безне түбәндәге нәтиҗәләргә китерде:

1. Текст парчага хас тәэсирле сурәтләү чараларына, үзенчәлекле стилистик алымнарга бай, шуңа күрә укучыга тиешле дәрәҗәдә тәэсир итә, аның тирән хисләрен кузгата.

2. Лексик, морфологик һәм синтаксик яктан текст дөрес һәм төзек итеп, билгеләнгән максатларга яраклы рәвештә корылган. Бары тик басма хатасы дип санарлык бер-ике очрак кына бар (“сиңа” урынына “сине” дип язу – унынчы абзац; аерымланган хәлләр янында тыныш билгеләрен төшереп калдыру – җиденче абзац һ.б.).

3. Тел ярусларының барысын да карап чыккач, текст уңышлы төзелгән, барлык тел чаралары да урынлы кулланылган дигән фикергә килдек. Шуңа күрә әсәр укучыга аңлаешлы һәм якын, җиңел кабул ителә.

Әдәбият
1. Минералов Ю.И. Теория художественной словесности (поэтика и индивидуальность): Учеб. для студ. филол. фак. высш. учеб. заведений / Ю.И.Минералов. – М.: Владос,1999. – 360 с.
2. Николина Н.А. Филологический анализ текста: Учеб. пособие для студ. высш. пед. учеб. заведений / Н.А.Николина. – М.: Издательский центр «Академия», 2003. – 256 с.

Шәмсетдинова Р.Р.

Фәнни-техник әдәбиятны тәрҗемә итүгә кагылышлы кайбер мәсьәләләр

Тәрҗемә эшчәнлеген функциональ һәм коммуникатив юнәлешләре ягыннан өч төргә бүлеп карау кабул ителгән: әдәби, иҗтимагый-сәяси һәм махсус. Махсус тәрҗемәне профессиональ юнәлешле тәрҗемә дип тә, профессиональ аралашу (коммуникация) өлкәсе тәрҗемәсе дип тә атау кабул ителгән. Махсус тәрҗемә өлкәсенә хәрби тәрҗемә, юридик тәрҗемә, икътисадый тәрҗемә, фәнни-техник тәрҗемә, медицина өлкәсенә караган һ.б. тәрҗемәләр керә. Ягъни махсус тәрҗемә объекты булып кеше танып-белүенең һәм гамәли эшчәнлегенең, фән һәм техниканың төрле өлкәләренә караган материаллар тора. Бу материалларны башкалардан беренче чиратта фикерне төгәл белдерү аерып тора. Бу исә, үз чиратында, мондый әдәбиятта терминнарның киң кулланылышы аша ирешелә.

Фәнни техник әдәбиятның тәрҗемәсе тәрҗемә ителә торган тел нормаларына туры килергә тиеш. Дөрес тәрҗемә итү өчен контекстта сүз нәрсә турында баруын белү әһәмиятле. Яңа чит тел терминын контекстта төгәл аңлау, аңа логик-лингвистик анализ ясау аша аның тәрҗемә ителә торган телдәге төгәл, бер мәгънәле тәрҗемәсен табу әһәмиятле. Әгәр дә чит тел терминына туган телдә туры килә торган сүз булса һәм шулай ук алынма сүз дә йөрсә, аларның уңышлырак вариантын сайлау мөһим. Тәрҗемәнең бу жанры чыганак тексттагы материалны аз гына үзгәртүгә дә юл куймый. Тәрҗемә итү барышында фразаларны төзегәндә, фикерне төгәл бирү максаты куела, шуңа күрә тәрҗемә итү барышында катлаулы җөмләләрне кечерәк өлешләргә бүлеп тәрҗемә итү төп текстның эчтәлегенә кире тәэсир итми.

Югарыда әйтеп кителгәнчә, фәнни-техник әдәбиятта терминнарның киң кулланылышы күзәтелә. Шуңа күрә фәнни-техник тәрҗемә эшчәнлегендә төп авырлык терминнарны тәрҗемә итүгә бәйле килеп туа. Шуны да истә тотырга кирәк, кагыйдә буларак, тәрҗемә текстындагы термин икенче телдәге тәңгәл килгән термин белән тәрҗемә ителә. Шуңа күрә аналогын табу, синонимы белән алыштыру, аңлатма аша тәрҗемә итү, чыганак телдәге терминның тәрҗемә телдә тәңгәл килгән термины булмаганда гына кулланыла. Махсус әдәбияттагы терминнарны анализлау аларның мәгънә күләмнәре ягыннан бер генә төрле булмавын күрсәтә. Бер мәгънәгә генә ия терминнар белән беррәттән күп мәгънәле терминнар да яшәп килә. Күпмәгънәлелек, хәтта бер компонентлы гына булса да терминны дөрес аңлауны һәм тәрҗемә итүне авырайта. Аңлау һәм аңлап тәрҗемә итү ягыннан чыгып караганда, терминнарны өч төркемгә бүлергә мөмкин: 1). Чит ил чынбарлыгы белән бәйле реалийларны чагылдыручы терминнар. Бу төркем терминнарны аңлау түбәндәге очракларда шактый гади, әгәр дә а) эквивалент буларак, формасы интернациональ характерда булган термин белән бәйле татар телендә кулланылышка кереп киткән термин кулланыса; б) эквивалент буларак, терминның интернациональ формасы белән бөтенләй бәйләнеше булмаган татар теленең үз термины файдаланылса; в) берничә сүздән торган күпкомпонентлы терминның мәгънәсе татар телендәге шундый ук компонентлар белән тәңгәл килсә; г) күпкомпонентлы рус терминының гомуми мәгънәсе шундый ук татар терминының мәгънәсе белән тәңгәл килсә, ләкин терминның аерым компонентлары татар телендәге эквивалентының компонентларыннан аерылып тора. 2). Чит ил чынбарлыгын чагылдыручы, ләкин татар телендә гомумкабул ителгән терминологик элементлары булган терминнар. 3). Чит ил чынбарлыгын чагылдыручы һәм татар телендә эквивалентлары булмаган терминнар. Мондый характердагы терминнарны тәрҗемә итү түбәндәге ысуллар аша ирешелә: а) рус телендәге терминны тасвирлау юлы белән; б) сүзен-сүзгә тәрҗемә итү аша; в) өлешчә яки тулы транслитерация, ягъни бер алфавиттагы терминны икенче алфавит чаралары белән тапшыру; г) транслитерация һәм сүзен сүзгә тәрҗемә; д) транскрипцияләү; е)

транскрипциялəү һəм тəрҗемə. Мондый төр терминнарны тəрҗемə иткəндə, тəрҗемəчелəрнең интернациональ терминга татар телендə тəңгəл килə торган сүз табарга тырышулары, аларның төп хаталары булып тора. Терминнарны тəрҗемə итүгə мондый мөнəсəбəт бик үк дөрес саналмый, чөнки, беренчедəн, чит тел чынбарлыгы белəн бəйле төшенчəлəрнең үзенчəлеге тоныклана, юкка чыгарыла, яки ул реалиялəрне чагылдыруга сəлəтле булмый. Шулай ук тəрҗемəченең мондый характердагы терминны сүзен-сүзгə тəрҗемə итергə омтылышы да хата ысул булып тора. Тəрҗемə иткəндə, терминның шул контексттагы реаль мəгънəсен исəпкə алу мөһим.

Фəнни-техник əдəбиятны тəрҗемə иткəндə, беренче планга тəрҗемə ителə торган текстның предметын яхшы аңлау чыгарыла. Шуның белəн бергə, фəн һəм техниканың карала торган өлкəсендə кулланыла торган татар терминнарын белү дə бик əһəмиятле. Тəрҗемə процессында кабул ителгəн стандарт терминологиягə нигезлəнергə киңəш ителə. Тасвирлама тəрҗемə татар телендə термин булмаган очракта гына тəкъдим ителə. Тəрҗемə эшчəнлегенə керешкəнче, шул белгечлек буенча материалларны аңлауга этəргеч булган төп моментларга тукталырга, əдəбият белəн танышырга кирəк.

Терминның хəрефкə-хəреф тəрҗемəсе буларак сайланган сүз белəн бу терминның асыл мəгънəсе арасында каршылык тумаска тиеш. Əгəр дə каршылык туа икəн, термин дөрес тəрҗемə ителгəн буса да уңышсыз була һəм телдə урнашып китми.

Түбəндə соңгы елларда чыккан терминологик сүзлеклəрдəн алынган мисаллар китерелə: *озакка сузылган каршылык, дугалы металл, эретеп-ябыштыру, җөй ясагыч машина, күптапкыр киңəйтүче пар машинасы, күпцилиндрлы пар машинасы, сеңдерүче аппаратның көче* һ.б. Бу терминнар төгəл терминологик мəгънəне бозып бирүлəре белəн аерылып торалар, мəсəлəн: сеңдерүче аппаратның көче дигəндə сила түгел, бəлки кысылган вакытта аппарат тарафыннан сеңдерелə торган кенетик энергия турында сүз бара, шуңа күрə көч дип түгел, я егəрлек дип тəрҗемə итү яки энергия дип калдыру дөресрəк булыр иде. Җөй ясагыч машина термины да төгəл терминологик мəгънəгə ия түгел, бары тик эретеп төшенчəсен өстəгəч кенə терминологик мəгънə конкретлаша.

Тәрҗемә терминнар арасында күпсүзлелеккә нигезләнгән, мәгънәгә ирешә алмаган терминнар да очырый, мәсәлән, *пардан файдаланучы пар машинасы, ике яклы эшчәнлеккә нигезләнгән пар машинасы, катнаш горелка* һ.б.

Сүзен-сүзгә тәрҗемә итеп термин ясау иң җиңел һәм шул ук вакытта тайгак ысулларның берсе булып тора. Шуңа күрә, беренче чиратта телнең үзендә яшәүче табигый формаларга, сүзләргә нигезләнеп термин ясарга тырышырга кирәк, тулы калька характерындагы телебезгә ятышсыз тәрҗемә терминнар телне дә баетмый, шул ук вакытта фәнни текстны кабул итүгә дә киртә булып тора.

Шулай итеп, тәрҗемә фикерне төгәл тапшыру һәм кабул ителгән терминологиядән файдалану белән генә чикләнмичә, кыскалык, аңлаешлылык белән дә аерылып торырга тиеш. Машина, җиһаз, инструмент яки җитештерү процессларын тасвирлау тәрҗемәдә күрсәтмә характерда булырга тиеш. Мондый төр терминнарны тәрҗемә иткәндә, телебез өчен шактый ятышсыз, ләкин шул ук вакытта котылгысыз булып торган гибрид терминнар килеп керә, мәсәлән: *җыючы-клепкалаучы, станок-сиртмә, җыйгыч-пресс, слесарь-җыючы, мастер-көйләүче* һ.б.

Мәгълүм булганча, фәнни ачышлар кайсы телдә ясалса, атамалар да шул телдә бирелә. Шуңа күрә терминнарны тәрҗемә итү эшчәнлеге интернациональ термин ясагыч элементларга карата аеруча игътибарлы булуны таләп итә. Интернациональ терминны тәрҗемә итә башлаганчы, аның составына кергән сүзләрнең составын, мәгънәсен анализларга, термин элементларга таркатырга кирәк. Башта һәр элементны аерым, аннан соң аның термин эчендәге мәгънәләрен анализларга, шуннан соң тәрҗемә ителә торган телдә эквивалентын табарга кирәк. Татар телендә мондый терминнарны тәрҗемә итүнең бер ысулы күзәтелә: тәрҗемә итеп булмый торган термин ясагыч элемент татар теленең үз сүзе белән бәйләнештә бирелә, мәсәлән: *автоягулык, автосабан, авточана, академшәһәрчек, трансмилли, авиатөзүче, дискоүзәк* һ.б.

Фәнни–техник текстның тәрҗемәсе оригинал текстның мәгънәсен оригинал текст формасына якын торган формада тапшырырга тиеш.

Тәрҗемә хәрефен-хәрефкә тәрҗемә характерында да оригиналның эчтәлеген ирекле сөйләп чыгу характерында да булырга тиеш түгел, гәрчә тәрҗемәдә ике ысул да чагылыш таба: әгәр дә нинди дә булса фразаны сүзгә-сүз тәрҗемә итү аның мәгънәсен төгәл тапшыра һәм татарча яңгырый икән, бу очракта әлеге ысулны куллану тулысынча үзен аклый һәм аны үзгәртү өчен нигез юк, ә аерым очракларда билгеле бер өлешнең эчтәлеген үз сүзләрең белән сөйләп чыгудан башка чара калмаска да мөмкин. Иң мөһиме - булган информацияне, мәгълүматны төшереп калдырмау яки оригиналда булмаганны өстәү күзәтелмәскә тиеш.

Фәнни тәрҗемәнең дөреслеген, төгәллеген тәрҗемәченең оригинал текст телен һәм предметын ни дәрәҗәдә яхшы белүе, аңлавы билгели. Шул ук вакытта дөрес, төгәл мәгънә ачык һәм үтемле бирелергә тиеш.

Текстның ачыклыгы дигәндә, аның бер мәгънәлелеге күз алдында тотыла. Тәрҗемә текстларын төрлечә аңларлык итеп тәрҗемә ителүнең төп сәбәбе булып, беренче чиратта, стилистик төгәлсезлекләр, җитешсезлекләр тора. Без алар рәтенә түбәндәгеләрне кертәбез:

1.Төрлечә аңларга мөмкин булган җөмләләр. Мондый төр җөмләләр арасында булырга тиешле ачыклаучы сүзе төшереп калдырып тәрҗемә ителгән мисаллар тора. Мәсәлән, мәктәпләргә анатомия-физиология фәнен укыту өчен тәкъдим ителгән тәрҗемә дәреслектә “ ... *фермент субстратны тарката*” дигән җөмлә бирелә һәм, әлеге җөмләне укыгач, әллә никадәрле сорау туа. Фермент(ягъни матдәләр алмашуда катнашучы аксым катализатор) ничек итеп субстратны (ягъни нигез матдәне) тарката? Нәтиҗәдә, укучы дәреслектә бирелгән әлеге җөмләне аңламый, аның өчен фикер ачык түгел. Белешмәләрдән чыгып, без субстратны түгел, бәлки субстрат молекуласын таркатуын ачыкладык. Шул ук дәреслектә “*гипофиз гармоннары башка бизләрне активлаштыралар*” диелгән. Сорау туа, ә бизне ничек активлаштырырга мөмкин икән? Дөресе - бизне түгел, ә бизнең эшчәнлеген активлаштыралар икән.

2. Җөмләдә бәйләүче чараларны дөрес, урынлы куллану, кулланмау да мәгълүматны кабул итүгә комачаулый. Мисал өчен түбәндәге җөмләләргә тукталыйк: “... бу *матдә фермент белән*

таркатыла", ягъни организмда булмаган ферментны организмга махсус кертәләр килеп чыга, чынлакта исә ул фермент организмда эшләнә, ул бар, шуңа күрә матдәнең ферментлар тарафыннан таркатлуы турындагы информация җиткерелергә тиеш иде тәрҗемә текстында.

Тәрҗемә ителә торган текстта күрсәтү алмашлыкларын читләштерү дә фәнни текстларны ике төрле аңлауга китерәләр. Мәсәлән, шул ук дәреслектә: " *...очмый торган термитлар*" диелә термитларның оча ала торганнары да оча алмый торганнары да булганын аңламаучы җөмләне ничек аңларга тиеш : термитлар барысы да оча алмый дипме, әллә аерым оча алмый торган төре дипме? Бу очракта җөмлә "*Термитларның мондый оча алмый торган төрләре*"дип тәрҗемә ителергә тиеш иде.

Яки: "*Бөҗәкләр белән тукланучы ярканатлар ...*", ягъни барлык ярканатлар да бөҗәкләр белән ткулануы турында информация ала укучы, ә табигатьтә бит әле үсемлек, җиләк-җимеш белән туклана торган ярканатлар да бар, шуңа күрә "ярканатларның бөҗәкләр белән туклана торган мондый төрләре, әлеге төрләре" һ.б.

3. Тәрҗемә ителә торган текстта кирәксезгә сүз куллану да тексттагы мәгълүматны кабул итүгә комачаулык ясый. Мәсәлән: *"... билгеле бер төр хайваннарда*", төгәлрәк булыр иде – кайбер хайваннарда; "*тукыма культуралар өстендә башкарылган экспериментлар*" – тукыма культураларда үткәрелгән экспериментлар; *"күптөрлелек белән характерланалар"* – күптөрлеләр; "*югарырак тизлекләр белән яңаралар*" – тизрәк яңаралар; *"бу күзәнәкләрне үзәк һәм периферик төрләргә классифицияләргә мөмкин"* – аларны үзәк һәм периферик күзәнәкләргә бүлергә мөмкин;

Мисаллардан күренгәнчә, тәрҗемә характердагы фәнни-популяр әдәбият үзенә игътибарны, кабат карап чыгуны таләп итә. Фәндә кулланыла торган теләсә нинди термин мәгънәсе ягыннан да нигезле, аңлаешлы, төгәл булмау, әлеге фәннең үсешенә дә, аны популярлаштыруга да комачаулык ясаучы төп факторларның берсе булып тора.

Юсупов А.Ф.

Верования в тюрко-монгольском мире до образования Золотой Орды

Как уже известно, начиная со средневековья, христианские и исламские богословы разделили все верования на два вида: язычества и религию. Религия ставить своей целью заставить человека общаться с богом как создателем всего сущего и объяснить отношение человека к богу. Следовательно, если в концепции нет единого божества, то не может быть и связи, и такие системы религиями называть нельзя. Например, в языческих верованиях нет единобожье, следовательно, это не религии, а собрания суеверий. [Безертинов, 2004, 5]

Однако в древнерусском церковно-славянском языке слово «народ» обозначает «язык, языки». Следовательно, язычество означало – народная религия [ПСРЛ, 1692, 91]. «В исторической науке, термином «язычество» следует обозначать – древнейшие, первобытные, многообразные верования и культы, исполняющиеся в интересах человека, семьи популяции, лингвистической и этнической группы, рода или племени. Таким образом, язычество - это религия народа, которая сохранила следы первоначального единобожия. Однако в конечном итоге получилось так, что язычество стало ложной религией, искаженной с помощью религиозных чувств людей. Поэтому, язычество не начало истории религии и не первоначальный ее вид, а уклонение от истинной религией, отпадение человеческого духа от божеств в мир природы» [Малов, Малышев, Ракушин, 1998, 45-47].

Языческий характер религиозных верований кочевников, предполагает существование различных форм культов, составляющих определенную религиозную систему – тюрко-монгольский шаманизм [Малов, Малышев, Ракушин, 1998, 50]. Таким образом, авторы книги «Религия в Золотой Орде» Н.М.Малов, А.Б. Малышев и А.И.Ракушин ставят знак равенство между язычеством и шаманизмом. Для А.Ю.Якубовского так же язычество и шаманизм, которые были распространены в тюрко-монгольском мире, одно и тоже верование [Греков, Якубовский,

1950, 166], но шаманизм более сформулированном виде по сравнению язычеством [Греков, Якубовский, 1950, 161].

Многие исследователи за основу принимают суждения средневековых богословов и признают религиями только иудаизм, христианство и ислам. Российский историк Г.С.Саблуков, исследуя религиозные верования монголов, обращает внимание на шаманизм и верование в одного единого Бога. Однако для историка шаманизм и язычество не отдельные религии, а просто сбор традиционных обычаев. «Шаманство не есть отдельная религия, а суеверия в буддизме» [Саблуков, 1895, 46]. Таким образом, автор делает вывод, что слова Плано Карпини насчет того, что «монголы веруют в Бога, Творца Вселенной», есть намек на Будду [Саблуков, 1895, 43].

В статье «О религии татар по русским летописям» Н.И.Веселовского, которое напечатано в журнале «Журнал министерства народного просвещения» исследован религия монголов, опираясь на русских источников. Цель историка – уяснение верование татар, чтобы понять из каких побуждений вытекали отношения ханов к покоренным народам и в частности к русским князям и к русскому населению [Веселовский, 1916, 82].

Историк, также как и Г.С.Саблуков, считает, что первоначальная религия татар была одинакова с монголами, но не буддизм как утверждает второй автор, а шаманизм. По его мнению, шаманизм это отдельная религия, а не собрание суеверий. «Ни у какого народа шаманская верования не достигла такой резкой и грубой формы, как у монголов и у татар. Боязнь колдовство и всяких чар, суеверия, гадания, проведение людей через двух огней, наказание за преступление против религии и т.д. вот и суть их веровании [Веселовский, 1916, 81-82]. Однако автор прав в том, что «культ огня настолько силен, что ни буддизм, ни ислам не могли уничтожить это языческое верование. Поэтому буддизм не пытался бороться с нею и принял ее сразу в число своих обрядов» [Веселовский, 1916, 90].

Заслуживает особого внимание тезис историка насчет сохранения шаманских обрядов после принятия монголами ислама. Эту явлению связывает автора с расширением до максимума шаманских обрядов, и якобы, поэтому ислам не смог

вытиснить их из повседневной жизни, но мало – по-малому они утрачивали свой смысл и переходили просто в традицию, которую и сами монголы не могли объяснить [Веселовский, 1916, 83, 90].

Однако тюрко-монгольский шаманизм или тэнгрианство обладают всеми качествами религиозных доктрин, но в них исключено признание единого бога. В тоже время они не подразумевают безбожия, как обычно утверждаются [ПСРЛ, 1962, 91]. Тюрко-монгольский шаманизм и тэнгрианство связаны с почитанием духов предков, духов Неба, Земли, гор, воды и т.д. [Безертинов, 2004, 5-6].

Тюрко-монгольский шаманизм, по мнению современных историков, это особая система религиозных верований, характеризующая делением Вселенной на три мира - верхний, средний и Нижний [Малов, Малышев, Ракушин, 1998, 51-52].

В тоже время советский историк Г.А.Федоров-Давыдов тюрко-могольский шаманизм рассматривает как исконная вера предков монголов, и относятся шаманизму нейтрально. Историк в термине «шаманизм» объединяет и языческие обряды, и религиозные верования [Федоров-Давыдов, 1998, 28-31]. На такой же позиции стоит и профессор М.А.Усманов. Автор пишет что, процесс образования монголами-шаманистами своего государства сопровождался соприкосновением с различными религиозными учениями, но в тоже время они не пытались навязывать покоренным народам навязывать свое верование – шаманизм [Усманов, 1985, 177]. Таким образом, историк в лице шаманизма видеть традиционную обычаю монголов и их религиозную веру.

Татарский историк Г.М.Давлетшин, кроме тюрко-монгольского шаманизма и язычество, по мнению ряда ученых, в тюрко-могольском мире существовали и другие религий. Один из чиновников, пользовавшийся большим доверием у Чингисхана, возглавивший затем при его сыне Угедэе (1229-1241) правительство империи и совершивши ряд реформ, был киданьский буддист Елюй Чу-Цай [Давлетшин, 2004, 168-184]. Хулагу-хан, покровительствуя христианам в Иране, также почитал и буддизм [Гумилев, 1970, 209], распространившийся здесь при монгольской династии [Греков, Якубовский, 1950, 164].

Л.Н.Гумилев, основываясь на археологические находки, доказывает распространение буддизма среди монгольской знати. «Рядом с городищем Хир-Хира, прообразом монгольского города XIII-XIV вв., в Читинской области были открыты богатые курганы монгольской аристократии – родов Джочи-Кайсана и Исункэ с предметами буддистского культа» [Гумилев, 1970, 209]. А также, по мнению историка несторианство распространилось до такой степени что, его исповедовали государственные чиновники, министры, военачальники и царской фамилии [Гумилев, 1970, 175].

Необходимо отметить, с христианством моголо-татары тоже были знакомы, по мнению некоторых историков, еще до того, как они появились на пространствах Восточно-Европейских степей. Также как и основное ее кочевое кипчакское население [Малов, Малышев, Ракушин, 1998, 75].

Таким образом, отношение историков шаманизму разносторонне. Если одни авторы считают тюрко-монгольского шаманизма сбором суеверий, и доказывают с этим, что среди монголов религия не было. С другой стороны другие авторы наоборот тюрко-монгольского шаманизма относят к числу религией, но это религия своеобразной форме. В тоже время третье видят в шаманизме синтез суеверий и религиозной верования.

Литература

1. Безертинов Р.Н. Тэнгрианство – религия тюрков и монголов / Р.Н.Безертинов. – Н.Челны: Аяз, 2000, Казань: Слово, – 2004. – 448 с.

2. Веселевский Н. О религии татар по русским летописям / Н.Веселовский // Журнал министерства народного просвещения. Ч. 64. – 1916. – июль. – С. 81-101.

3. Греков Б. Золотая Орда и ее падение / Б.Греков, А.Якубовский. – М.,Л.: Изд-во АНСССР, 1950. – 480 с.

4. Гумилев Л.Н. Поиски вымышленного царства / Л.Н.Гумилев. – М.: 1970.

5. Давлетшин Г.М. Очерки по истории духовной культуры предков татарского народа / Г.М.Давлетшин. – Казань: Татар. кн. издат., 2004. – 431 с.
6. Полное собрание русских летописей Т.1. 1962. Стб. 91.
7. Саблуков Г.С. Очерки внутренннго состояния кипчакского царства / Г.С.Саблуков. – Казань: Типо-литография императорского университета, 1985. – 60 с.
8. Усманов М.А. Этапы исламизации Джучиева Улуса и мусульманского духовенства в татарских ханствах XIII-XVI вв. // Духовенство и политическая жизнь на Ближнем и среднем Востоке в период феодализма. – М.: Наука, 1985. – С. 177-186.
9. Федоров-Давыдов Г.А. Религия и верования в городах Золотой Орды / Г.А.Федоров-Давыдов // Историчесая археология. Традиции и переспективы. – М.: 1998. – С.28-39.

Юсупов Ф.Ю., Хәмидова Ф.Ф.

Минзәлә сөйләшенең формалашу һәм өйрәнелү тарихы

Сөйләшүчеләрнең саны, шулай ук таралыш территориясенең зурлыгы ягыннан минзәлә сөйләше татар теленең иң зур сөйләшләреннән санала. Ул Татарстан Республикасының көнчыгыш (Әгерже, Зәй, Тукай, Минзәлә, Сарман, Мөслим, Актаныш, Әлмәт, Азнакай, Баулы, Бөгелмә), Башкортстан Республикасының көньяк-көнбатыш (Илеш, Дүртиле, Кушнаренко, Чакмагыш, Благовар, Бүздәк, Чишмә, Бакалы, Шаран, Туймазы, Янаул, Калтасы, Краснокама, Ауыргазы, Әлшәй, Бәләбәй, Бишбүләк, Кармаскалы, Мәләүез) районнарында таралган. Бу сөйләш, Татарстанның көнчыгыш, Башкортстанның көньяк-көнбатыш районнарын эченә алып, тоташ территория хасыйл итә.

Сөйләшнең үзенчәлеген тәшкил итә торган билгеләр сөйләш таралган барлык территорияләр өчен дә бер үк дәрәҗәдә хас түгел. Алар нигездә Татарстан Һәм Башкортстан Республикаларына чиктәш булган, Агыйдел, Ык, Сөн елгаларының бассейнларында таралган урынчылыкларда күзәтелә. Галимнәрнең фикеренә караганда, Татарстаннан көнчыгыш тарафка киткән саен, бу билгеләрнең саны сизелерлек

арта, кайбер үзенчәлекләр исә бөтенләй юкка чыга (Махмутова, 1962, 57; Рамазанова, 1984, 6). Бу, үз чиратында, минзәлә сөйләшенең формалашу үзенчәлеге белән аңлатыла. Билгеле булганча, 1552 елда, Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, Казан тирәсендә яшәгән татарларның күпчелеге кама аръягындагы, аеруча Агыйдел, Ык, Сөн елгалары буендагы ул вакытта чагыштырмача халык аз яшәгән җирләргә агыла. Казан ягыннан килгән татарларның саны бу төбәктә гомер сөрүче төрки-татар кабиләләренең санынннан дистәләрчә артып китә. Шул рәвешчә, казан татарларының сөйләше бередә төп аралашу чарасына әйләнә. Казан татарларының сан ягыннан һәм иҗтимагый тормыштагы өстенлеге соңгы гасырларга кадәр дәвам итә. Башкортстанның көньяк-көнбатыш төбәкләрендә, киресенчә, казан татарларының саны ул кадәр үк зур булмый. Татар халкының мәдәни үзәгеннән ераклашкан саен, биредә бик борынгы заманнанрдан бирле яшәп килгән җирле татар-төрки халыкларының теле, рухи һәм материаль культурасы үзен сиздерә башлый. Шуның нәтиҗәсендә, вакыт узу белән, биредә яңа формалашып килгән татар сөйләшләренә, шул исәптән минзәлә сөйләшенә һәм халык мәдәниятенең төрле тармакларына, җирле үзенчәлекләр үтеп керә башлый, тора-бара татар сөйләшләре таралган төбәкләрнең көнчыгыш чикләрендә башкорт, казах телләре һәм себер татарлары сөйләшләре белән уртак булган билгеләр барлыкка килә. Бу билгеләрнең кайберләре Татарстанның көнчыгыш, Башкортстанның көнбатыш өлешләрендә таралган сөйләшләрне борынгы, шулай ук хәзерге көнчыгыш төрки телләр белән якынайта. Чөнки, тарихчыларның әйтүләренә караганда, Урал итәкләре бик борынгы заманнардан бирле кешелек цивилизациясе үзәкләренең берсе булып исәпләнгән. Бу төбәкләрне борынгы хуннар, VIII гасырда кыпчак кабиләләре үз иткәннәр. Соңрак, кыпчакларның күп өлеше Идел болгарлары яши торган Урта Идел һәм Түбән Кама бассейнына күчеп китсәләр дә, аларның шактый зур өлеше биредә яшәп калган. Бу яклар Идел болгарларының көнчыгыш биләмәләре булып саналган. Себер ханлыкларының көнбатыш чикләре Кама һәм Агыйдел буйларына кадәр дәвам иткән (Дмитриев, 1900). Р.Г. Кузеев та Башкортстанның көнбатыш өлеше бик борынгыдан ук болгарлар тарафыннан үзләштерелгән булган, дип исәпли

(Кузеев, 1957, 23). Кайбер галимнәр исә Идел Болгарстанының көнчыгыш чикләре Агыйдел һәм Җаек елгаларына кадәр үк барып җиткәннәр, дип күрсәтәләр (Шпилевский, 1877, 159). Н.А Мәҗитов һәм Ә.Н Солтановалар да Көнбатыш Башкортстанның шактый өлеше Болгар дәүләте составында булган, дип санныйлар (Мәҗитов, Солтанова, 246-247). Хәзерге башкорт тарихчылары да, Болгар дәүләте, монголлар тарафыннан җимерелгәч, болгарларның бер өлеше Башкортстанның көнбатыш һәм төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш өлешләренә күчеп утырганнар, дип күрсәтәләр (Очерки..., 1959, 32-33). Галимнәр Урал алды территориясендә борын-борыннан болгар-татар дәүләтләре халкына генетик яктан бик якын торган этник төркемнәр яшәгәннәр дигән нәтиҗә ясыйлар (Рамазанова, 1984, 14; Сибәгатов, 2002, 18). Бу территорияләрдә, күп кенә тарихчыларның әйтүенчә, VIII гасырга кадәр үк болгар кабиләләре берлегенә кергән яки аларның тәэсирен кичергән халыклар яшәгәннәр (Р.Г. Кузеев. Башкирский шежере. –Уфа, 1960; Кузеев, 1974, 421). Моннан тыш болгарлар, төрле гасырларда зур булмаган төркемнәр хәлендә, Урал һәм Урал артындагы җирләргә дә үтеп кергәннәр. Минзәлә сөйләше вәкилләренең бердәм этнографик төркем буларак оеша башлавы болгар чоры заманында ук башланган дигән фикер дөреслеккә туры килә. Шуның нәтиҗәсендә, Идел буе һәм Урал итәкләрендә яшәүче төрки кабиләләрнең берничә гасыр үзара тәэсир итешү дәвамында, материаль һәм рухи культурада уртак билгеләр барлыкка килгән. Шушы чорда ук бу якта яшәүчеләрнең казан татарлары теленә нигезләнгән җирле сөйләше формалаша башлый Идел ягыннан килгән болгарлар һәм аларга якын кабиләләр телдә, рухи культураның башка тармакларында болгар-татар традицияләрен дәвам итсә, биредә борынгыдан яшәп килгән төрки кабиләләр әлеге сөйләшнең күрше һәм Урта Азия төркиләре белән уртак күренешләрне саклап калуга ярдәм иткән.

Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларында да Көнбатыш Башкортстан территориясе әлеге дәүләтләрнең сәяси, икътисадый, мәдәни йогынтысы астында кала бирә. Башкортстан гына түгел, Себер ханлыгының Урал төбәгендәге җирләре дә XX

гасыр башына кадәр татар икътисади мәнфәгатенең әһәмиятле үзәкләренең берсе булуын дәвам итә.

Минзәлә сәйләшенең формалашуында, шулай ук Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, казан татарларының бу якларга күпләп күчеп килүе җирле халыкның материаль, рухи культурасының нигезен барлыкка китерүдә хәлиткеч роль уйнаган, дип әйтергә тулы нигез бар. Шуның нәтиҗәсендә булса кирәк, казан арты сөйләшләре өчен хас булган төп билгеләр яңа оеша башлаган минзәлә сөйләшенең дә нигезен тәшкил итә торган үзенчәлекләр системасы буларак формалаша башлый. Шуңа да игътибар итәргә кирәк, казан арты һәм минзәлә сөйләшләре белән уртак булган кайбер үзенчәлекләр соңгы елларда, әдәби телнең көчле йогынтысына да карамастан, бүгенге көнгә кадәр актив кулланылуын дәвам итә (мәсәлән, теш-ара [d] тартыгын куллану һ.б.).

Югарыда карап узган тарихи һәм социаль шартлар биредә яшәүчеләрнең сөйләшләре формалашуга да тәэсир иткән: минзәлә сөйләше, берничә гасыр үзгә шартларда үсүенә карамастан, Казан ханлыгы чорында нигез сөйләш булып формалашкан казан арты сөйләшләренең төп билгеләрен саклап кала алган. Моңа, безнең фикеребезчә, биредә яшүче төрле төрки төркемнәр арасында казан татарларының сан ягыннан күп булуы гына түгел, бәлки аларның икътисади, материаль һәм рухи культура ягыннан да өстен булуы ярдәм иткән, дип уйларга кирәк. Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, Урал итәкләренә күчеп килгән татарларның биредәге башкортлар белән биш гасырга якын аралашып яшәүләренә карамастан, минзәлә сөйләшендә башкорт теле өчен генә хас булган үзенчәлекле билгеләр үтеп керә алмаган. Беренче чиратта, борынгы һәм гомуми төрки телдәге саңгырау, тел очы, өрелмәле [с] тартыгын фарингаль [h] авазы белән алмаштыру (минзәлә сөйләшендә: сарыҡ – башк. һарык, сөт-һөт, сап - һап, сары – һары һ.б.; борынгы һәм гомуми төрки телдәге аффриката (татар әдәби теле һәм урта диалектның күпчелек сөйләшләрендә - беркатлы, өрелмәле [ч] тартыгының тел очы өрелмәле [с] авазы белән тәңгәлләштерү (минзәлә сөйләшендә: чибәр – башк. сибәр, чебен – себен, чалғы – салғы, чалбар – салбар һ.б.), шулай ук тартык

авазлар өчен башкорт теленә хас булган ассимиляция һәм диссимиляция күренешләре дә минзәлә сәйләше өчен хас түгел (минзәлә сөйләшендә: ҡошлар – башк. коштар, ташлар – таштар, ҡойашны – кояшты, ҡартны – картты, ҡызлар – кыddар, айны – айзdы, баладан – баланнан, арбадан - арбанан һ.б.

XVI-XX гасырларда тарихи әдәбиятта һәм архив материалларында “башкорт җирләре” дип аталып йөртелгән территорияга күчеп килгән татарларны типтәрләр, йомышлы татарлар, ясаклы татарлар дип атап йөрткәннәр. Без бу мәкаләбездә нигездә шушы төркемнәр турында сүз алып барачакбыз.

Башкорт җирләренә үзәк өлкәләрдән күчеп утырган халыкның иң зур төркемен типтәрләр тәшкил иткән. Типтәрләрнең килеп чыгышы турында тарихи әдәбиятта бик күп фикеләр яшәп килә. Бер төркем тарихчылар типтәрләрне Идел буйларыннан күчеп килгән татарларның җирле башкортлар белән кушылуыннан килеп чыккан этник төркем, дип исәпли (Кеппен, 1861; Әхмәров, 1907). Соңрак бу терминның этнос атамасы түгел, бәлки башкорт җирләрендәге авыл халкының социаль катламын аңлатуы ачыклана (Рахматуллин, 1975). Соңгы хезмәтләрдә типтәрләр этник үзенчәлекләргә ия булган социаль катлам дип карала (Исхаков, 1993, 44-50). Архив һәм тарихи материалларда типтәр катламына татарлардан тыш мари, удмурт, чувашларның да кертелгәнлеге күренә. Типтәрләрне өйрәнүче галимнәр аларның тормыш-көнкүреш ягыннанн казан татарларыннан аерылмаулары һәм сөйләшләре татар теленә бик якын булулары турында әйтәләр (Бессонов, 1881; Катанов, 1900, 1903). 1939, 1959, 1970, 1979 елгы халык санын алу вакытында бу төбәкләрдә яшәгән типтәрләр үзләрен татарлар дип күрсәткәннәр (Исхаков, 1990, 8).

Типтәр тарихы белән шөгелләнүче галимнәр бу социаль-этник төркемнең, XVI гасырдан башлап, Башкортстан территориясенә күчеп килгән төркемнәрдән оешкан, дип исәпли, Башкортстан, Рус дәүләтенә кушылганнан соң, андагы җирләр дәүләт карамагына күчә. Дәүләт бу җирләрне, башка кешеләргә сатмау һәм, аннан кулланган өчен ясак түләү шарты белән, җирле башкорт кабиләләренә, шулай ук моңа кадәр үк бу

җирләргә килеп төпләнеп, бу төбәкнең үз халкы булып өлгергән башка төркемнәргә дә рәсми рәвештә теркәп куя. Шулай да **“вотчина”** дип аталган бу җирләрне читтән күчеп килгән җирсез халыкка арендага бирергә рөхсәт итә. Рәсми документларда, Урал төбәкләренә күчеп килеп, типтәр атамасы астында йөргән татарларның башкорт җирләренә төрле характердагы антлашмалар нигезендә, гадәттә җир хуҗаларының рус хакимиятенә булган ясакларын түләп тору шарты белән, урнашулары күренә. С.М. Васильев башкорт җирләренә антлашма нигезендә утырган һәркем типтәр исеме белән аталган, дип аңлата (Васильев, 1950). Әлеге антлашмалар телдән генә дә, язма рәвештә дә төзелгәннәр. Башкорт җирләренә төрле антлашмалар нигезендә утыру бигрәк тә көнбатыш төбәкләр өчен хас булган. Башкортстандагы җирле һәм килгән халыклар белән мондый мөнәсәбәтләр XX гасыр башларына кадәр дәвам иткән. Бу якларның җирле халкы белән күп гасырлар дәвамында аралашып яшәү нәтиҗәсендә, татар сөйләшләрендә башкорт теле белән кайбер уртак үзенчәлекләр дә барлыкка килгән.

Йомышлы татарлар. Татарларның, XVI гасырдан башлап, Башкортстан һәм Урал төбәкләренә күчеп утырулары һәр очракта да стихияле рәвештә генә дәвам итмәгән. Бу процессны туктату чарасын таба алмаган патша хөкүмәте, бу хәрәкәткә икенче бер юнәлеш биреп, аны колониаль сәясәтенә туры китереп, рәсми рәвештә алып барырга ниятли. Билгеле булганча, Казан ханлыгы Рус дәүләтенә кушылгач, империянең көнчыгыш чикләрен башкорт һәм кыргыз-кайсак һөҗүмнәреннән саклау ихтыяҗы туа. Шул сәбәп белән 1578 елда Минзәлә, Бирск, Уфа шәһәрләре төзелә башлый. Рус хөкүмәте бу шәһәрләргә һәм алар тирәсенә руслардан тыш хәлиткеч заманнарда үзләренә тугрылыклы булып калган йомышлы татарларны урнаштыра. Аларның бер өлешенә шушы крепостьлар тирәсендәге буш җирләр дә бүлеп бирелә. Шулай итеп, элекке Казан ханлыгы һәм кагазьдә генә рус дәүләтенә «ирекле» кушылган башкорт җирләре арасында беренче ныгытылган чик буе линияләре барлыкка килә. Соңыннан Башкортстанда булып торган төрле восстанияләр бу линияләрнең колониаль рус дәүләте өчен ни дәрәҗәдә вакытлы һәм кирәкле булуларын ничәмә-ничә кат исбат иттеләр. Вакыт

узу белән бу линияләр, әкренләп, Башкортстанның үзәк өлешләренә, хәтта XVIII гасыр азакларында хәзерге Чиләбе һәм Курган өлкәләре белән чиктәш булган казах далаларына кадәр барып җитә.

Йомышлы татарларының күпчелеге рус дәүләте химаясында (протектаратында) берничә гасыр яшәгән мишәрләрдән торганлыктан, шул заманга караган документларда аларны **мишәр, мишәрәк** атамалары белән аталып йөртелүләре архив материалларында һәм күп санлы экспедицияләр вакытында, язып алынган легендаларда чагылыш таба.

Татар-мишәрләр турында сүз барганда, тагын бер әһәмиятле фактка игътибар итәргә кирәк. Билгеле булганча, элек рус армиясендә татарлардан мишәрләр генә хезмәт иткән. Соңга таба бу эшкә Оренбург губернасындагы Себергә һәм Казахстанга якын булган чик буйларында яшәүче бүтән татарлар да тартыла башлый. Тора-бара көнчыгыш өлкәләрдә яшәүче хәрби сословиегә кертелгән күп кенә башка татарларны да мишәрләр дип атау гадәткә кереп китә.

П.И.Кеппен дә, шушы чор халыкларының тарихы турында сүз барганда, йомышлы татарларны мишәрләр дип атау кабул ителгәнлеген әйтә. Ул шушы уңай белән бер указдан өзек китерә: «В Уфимском уезде обитают служилые татары, называемые мещеряками» (Кеппен, 1861, 363; Материалы по истории Башкирской АССР, т. III, 1936, 492). Йомышлы татар-мишәрләр башкортларның вотчина дип аталган (дәүләт гомерлеккә файдаланырга биргән) җирләрендә яшәгәннәр, аннан файдаланган өчен аларга оброк түләгәннәр. Ләкин, 1736 елның 11 январь указы нигезендә, 1735 елгы башкорт восстанияләрен бастыруда актив катнашулары өчен, алар оброктан, ә 1754 елда барлык түләүләрдән дә азат ителәләр. 1797 елда бу җирләрдәге мишәрләр Оренбург хәрби идарә карамагына кертеләләр һәм башкорт авыллары белән бергә кантоннорга бүленәләр. Шушы хәлләрдән башлап, йомышлы мишәрләрнең административ һәм социаль шартлары башкортлар белән тиңләштереләләр. Шулай да башкортларның электән килгән “җир хуҗалары” дигән мактаулы атлары башкорт булмаган халыкларны үзенә тартып торган. Шунлыктан, җае чыгу белән, һәр этник төркем башкорт булып язылырга омтылган. Рус хөкүмәте, мишәрләрне социаль

хокуклары белән башкортлар белән тиңләштерүгә карамастан, мишәрләр арасында да башкорт сословиесенә күчергә теләүчеләр шактый күп булган. Шушы сәбәпләр нәтиҗәсендә, хәзерге Татарстан Республикасының көнбатыш, Башкортстанның көнчыгыш төбәкләрендә яшәгән йомышлы мишәрләрнең күпчелеге рәсми кәгазьләрдә башкорт булып күрсәтелә башлыйлар.

Бу яклардагы йомышлы мишәрләрнең төгәл саны беркайчан да билгеле булмаган, чөнки ул ел саен Идел ягынна килгән йомышлы татарлар һәм бу социаль катламга үз теләге белән күчкән ясаклы татарлар хисабына арта барган (ЦГА БР. Ф. 138, оп. 2, ед. хр. 22, 87, 97. ЦГАДА. Ф. 45, оп. 2, ед. хр. 74, 16).

1797 елдан башлап, йомышлы мишәрләр, Оренбург хәрби идарәсе карамагына кертелеп, төрле кантоннарга бүленәләр һәм аларның төп хокуклары башкортлар белән тигезләнә.

Оренбург губернасы төзелә башлау белән, бу якларга татарларга күчеп утырырга рөхсәт бирүче кайбер документлар кабул ителә. 1736 елгы указ нигезендә башкорт восстанияләре вакытында рус хөкүмәтенә тугрылык күрсәткән йомышлы татарларның, типтәрләр һәм бобыльләрнең башкортлардан алып торган җирләре гомерлеккә үзләренә бирелә. Моннан тыш аларга баш күтәргән башкортларның җирләрен сатып алырга рөхсәт тә ителә.

1840 елгы “О военном управлении Башкирско-Мещерякским войском” дигән положение буенча, бу территориядә яшәүче халыкларның барлык эшләре белән җитәкчелек итү шушы гаскәр идәрәсенә тапшырыла. 1855 елда Башкорт-Мишәр гаскәренә Уфа һәм Оренбург губерналарында яшәгән барлык типтәрләр, бобыльләр кабул ителә һәм бу административ берәмлек Башкорт гаскәре дип аталып йөртелә башлый. Бу авыллардагы татарлар, типтәрләр, ясаклы татарлар рәсми кәгазьләрдә башкорт дип күрсәтелә башлый. Элеккеге ыруглык, этник билгеләр нигезендә төзелгән административ бүленеш бозыла. Бер үк кантон һәм волостьларга башкорт, мишәр, типтәрләр, ясаклы татарлар да кертелә. Электән үк башкортларга бирелгән кайбер өстенлеккә өмет иткән татарлар һәм типтәрләр үзләрен башкорт дип язуга каршылык күрсәтми.

Административ системадагы үзгәрешләр XIX гасыр урталарында башкорт восстаниеләрен булдырмауны күздә тоткан кантоннарны бетерү белән тәмамлана. Икенчедән, рус дәүләтенә кушылганнан соң, Уфа провинциясе һәм Оренбург губернасы территорияләре чик буе өлкәләре булудан туктый. Шулай итеп, хәзерге вакытта минзәлә сөйләше вәкилләре яшәгән Уфа провинциясенең көнбатыш һәм үзәк өлкәләрдә мишәр кантоннары тотуда ихтыяҗ бетә. Шунлыктан кайбер мишәр һәм башкорт кантоннары, казак сословиясеннән чыгарылып, ясакка кертеләләр.

Югарыда сөйләгәннәрдән күренгәнчә, мишәр термины, хәзерге этнография фәнендә кабул ителгәнчә, этник төркемне генә белдереп калмаган, бәлки хәрби хезмәт (казак хезмәте) алып баручы татарларга карата да кулланылган булуы аңлашыла.

Хәзерге көндә минзәлә сөйләше вәкилләре яши торган территориядә яшәүче миллион ярымнан артык кеше үзенең ана телен татар теле итеп саный. Үткән гасырның алтмышынчы елларына кадәр бу төбәктә уку-укыту, административ идарә итү эшләре, кагыйдә буларак, татар телендә алып барылды. Халык санын алу вакытында халык туган телен татар теле дип санап килде.

Иске административ бүленеш буенча биредә яшәгән татарлар, төрле чорларда Казан, Уфа (провинциясе), өлешчә Оренбург губерналары составында булып, Минзәлә, Бәләбәй, Өфе өязләренә караганнар. 1920 елда оештырылган Башкорт автономияле социалистик революция төзелү белән, бу җирләрдә борынгыдан ук яшәп килгән татарлар ике дәүләт чикләре арасында бүленеп калдылар. Күп гасырлар Казан губернасы чикләрендә бердәм икътисад, тел, рухи культура уртаклыгында яшәгән халыкның берлегенә зур зыян килде. Шушы көннән башлап, Урта Идел, Түбән Кама, Урал итәкләрендә күп гасырлар буе уртак язмыш кичергән халык ясалма тудырылган шартлар эчендә яши башлады. Татар халкының иҗтимагый тормышына көчләп башкорт теле кертелә. XX гасырның урталарыннан башлап, мәктәпләрдән, мәктәпкәчә балалар, культура учреждениеләреннән татар теле кысырыклап чыгарыла, аның урынына көчләп башкорт теле укытыла башлый. Татар

әдәбиятының, мәдәниятенең тәэсире бик нык кими башлый. Шулай булуга да карамастан, татар халкы үз телен саклап калу һәм аны киләчәк буыннарга тапшыру юлында каһарманнарча көрәш юлына баса.

Минзәлә сөйләше татар теленең иң күп өйрәнелгән сөйләшләреннән санала. Төрле гасырларда иҗат иткән галимнәр бертавыштан сөйләшнең фонетик, грамматик төзелеше, төп лексик байлыгы ягыннан татар әдәби теленә бик якын торган, аны тагын да баетуга зур өлеш керткән сөйләш итеп саныйлар (Бессонов, 1881, 232; Катанов, 1900; Җәләй, 1947; Залялетдинов, 1954; Юлдашев, 1950, 1959, 1968; Махмутова, 1962, 57; Афлетунов, 1961; Әфләтүнов, 1960; Алмаз, 1959;. Рамазанова, 1984; Баязитова, 1989 һ.б.). Минзәлә сөйләшенең хәзерге татар әдәби теленә нигез булып торган урта диалект сөйләшләренә якынлыгы турында аеруча басым ясап әйтергә кирәк. Казан ханлыгы территориясеннән бу якларга күчеп килгән татарлар татар сөйләшләренә хас булган төп билгеләрне саклап калганнар. Урал төбәкләрендә XVI гасырдан соң барлыкка килгән башка татар сөйләшләре дә бу уртак хәзинәгә тугърылыклы булып калалар. Яңа шартларда барлыкка килгән үзенчәлекләрнең күбесе бу тәбәктә таралган барлык татар сөйләшләре өчен уртак күренешләр итеп каралалар. Чөнки алар уртак тарихи, социаль, икътисади шартларда барлыкка килгәннәр.

Урал итәкләрендә таралган татар сөйләшләре турында беренче фәнни мәгълүматларны татар диалектологиясе фәненә нигез салган рус галиме А.Г. Бессонов калдыра. Ул үзенең 1881 елда Санкт-Петербургта басылып чыккан “О говорах казанского татарского наречия и об отношении его к ближайшим к нему наречиям и языкам” дигән хезмәтендә Урал төбәкләрендә таралган типтәрләр сөйләшен казан татарлары шивәсенә иң якын торган сөйләше, дип исәпли. Бу Башкортстан территориясендәге татар сөйләшләренең казан татарлары теленә якынлыгын фәнни дәлилләгән беренче хезмәт була. Ул ислам динендәге типтәрләр сөйләшен күпмедер дәрәҗәдә башкорт һәм мишәр сөйләшләренең йогынтысына бирелгән татар сөйләше, дип исәпли. Галимнең бу фикерләре безнең һәм башка тикшеренүчеләрнең материаллары белән дә раслана. А.Г. Бесссонов бу сөйләшләргә башкорт теленең йогынтысын конкрет

дәлилләр китереп исбатламый. Алай гына да түгел, бу төбәктәге татар сөйләшләрен башкорт сөйләшләре итеп карарга тырышкан башкорт телчеләреннән аермалы буларак, тел очы йомык (кайбер галимнәрнең күзәтүенчә, теш-ара) [d] тартыгының кулланылуына да игътибар итми. Ул бу авазны бик хаклы рәвештә йомык [д] тартыгы белән тиңли. Дөрестән дә, әлеге аваз үзенең ясалу хосусияте ягыннан башкорт телендәге теш-ара "сакау" [з] тартыгыннан аерылып тора. Соңарак А.Г. Бессоновның бу фикере башка галимнәр тарафыннан да раслана (Җәләй, 1954, 431; Әфләтүнов, 1958, 124; Рамазанова, 1968, 338; Юсупов, 2006, 28).

А.Г. Бессоновның бу төбәкләрдә таралган типтәр сөйләшләренең казан татарлары шивәсенә (хәзерге терминология буенча, татар теленең урта диалектына) якын торуын [а] сузыгының нык иренләштереп әйтелүе белән дә раслый. Моннан тыш галим мишәр сөйләшләренең дә, беренче чиратта, казан татарлары шивәсенә якын торуы турында әйтә. А.Г. Бессоновның Урал итәкләрендә яшәүче татарларның, аерым алганда минзәлә сөйләше турында әйткән фикерләре, үзенең фәнни әһәмиятен бүгенгә кадәр дә югалтмаганнар. Иң әһәмиятлесе – бу яклардагы сөйләшләрнең татар теленә бик якын булуы соңгы елларда да бик күп галимнәр тарафыннан тагын бер кабат расланды.

Урал итәкләрендә таралган татар сөйләшләренең казан татарлары теленә якын торуын төрки телләр белгече мәшһүр Н.Ф. Катанов тарафыннан да әйтелә. Ул 1898 елда, Бәләбәй өязенең мишәр, башкорт, типтәр, керәшен татарлары яшәгән авылларда булып, аларның тел үзенчәлекләрен өйрәнә. Бу авылларда яшәүчеләрнең теле керәшен татарлары, ягъни казан татарлары теленә якын торуы турында әйтә. Н.Ф. Катанов та, А.Г. Бессонов кебек үк, бу сөйләшләрдә башкорт теле өчен хас булган теш-ара "сакау" [з] тартыгы булуы турында бер сүз әйтми. Димәк, галим бу авазны йомык [д] тартыгыннан аермый. Башкорт автономияле социалистик республикасы корылганнан соң, башкорт телен булдыру, аның нигез сөйләшләрен барлау максатында үткәрелгән күп санлы лингвистик экспедицияләр дә Башкортстанның көнъяк-көнбатыш өлешендә яшәүчеләрнең теле татар теленә бик якын тора дигән нәтиҗәләр ясый.

Урал итәкләренең Татарстан респуликасына кергән өлешендә яшәүчеләрнең сөйләшен, татар диалектологларыннан беренче булып, күренекле тел галиме Латыйф ага Җәләй (Җәләлетдинов) өйрәнә башлады. 1947 елда басылып чыккан “Татар диалектологиясе” дигән югары уку йортлары өчен язылган дәреслегендә бу сөйләш **“минзәлә сөйләше”** дигән исем астында карала. Татар диалектологиясенең беренче адымнары гына булуга карамастан, автор бу сөйләшне татар теленең иң зур сөйләше, дип атый. Ул минзәлә сөйләшенең казан арты сөйләшләре белән булган уртаклыгына да игътибар итә. Бу, беренче чиратта, әлеге сөйләшләрдә тел очы, йомык [d] тартыгының булуы, д< d тәңгәллегенә карый. Бу күренешнең таралышын галим ни өчендер көнчыгыштан (Минзәлә ягыннан) көнбатыш юнәлештә күзәтә. Әлеге тел үзенчәлекләренең татарларның көнчыгышка таба миграция процессында барлыкка килгәнен аңлау өчен ул вакытта тел, тарихи һәм архив материаллары җитәрлек булмаган, күрәсең, сөйләшнең фонетик, грамматик, лексик билгеләрен анализлап, автор аның урта диалект составында мөстәкыйль сөйләш булырга хаклы икәнен дәлилли. Минзәлә сөйләшенә хас булган үзенчәлекләр галимнең 1954 елда “Татар теленең урта диалекты” дигән темага якланган докторлык диссертациясендә дә шактый тәфсилле итеп тикшерелә. Ләкин, бу якта яшүчеләрнең сөйләше ул вакытта җитәрлек өйрәнелмәгәнгә күрә, ул минзәлә сөйләшенең таралыш чикләрен билгели алмаган. Л.Җәләйнең фикеренчә, минзәлә сәйләше Минзәлә һәм аңа күрше булган районнарда гына таралган, дип карала.

XX гасырның икенче яртысыннан башлап, минзәлә сөйләшенең Башкортстан республикасы территориясендә таралган өлешләре дә өйрәнелә башлый. Бу эшкә, беренче булып, күренекле тел галиме, атаклы башкорт теле белгече Әхнәф Әхмәт улы Юлдашев тотына. Ул үзенең 1950 елда якланган “Типтәр сөйләшләре (“Язык типтярей”) дигән кандидатлык диссертациясендә Башкортстанның көнбатыш районнарында таралган татар сөйләшләрен анализлауга да шактый урын бирә. Биредә ул Учалы районында таралган типтәр сөйләшен Бәләбәй, Бүздәк, Туймазы, Бакалы, Шаран районнарында яшәүче

татарларның тел үзенчәлекләре белән чагыштырып өйрәнә (Юлдашев, 1950).

Ә.Ә. Юлдашев, тел материалларын анализлаганда, тарихи чыганакларны да оста куллана. Авторның фикеренчә, күпчелек очракта типтәрләр дип башкорт җирләренә күчеп килгән, үз җирләре булмаган казан татарларын атап йөрткәннәр. Ул типтәрләрнең башкорт җирләрендә кайчан һәм нинди сәбәпләр белән барлыкка килүен, бу сөйләшләрнең, беренче чиратта, башкорт теле белән чагыштырганда, татар әдәби теле һәм татар сөйләшләренә якын торуын ышанычлы дәлилләр белән исбатлап күрсәтә. Ул, башкорт галимнәреннән аермалы буларак, типтәр атамасының этник билгедән бигрәк, сыйнфый катламны белдергән, дип аңлата. Типтәрләрнең бердәм этник берлек, телләренең бердәм сөйләш була алмавының төп сәбәбе итеп, Ә.Ә. Юлдашев Идел буе өлкәләреннән чыккан татарларның берничә гасыр буенча Башкортстандагы татарлар составына агылып торуын атый (Юлдашев, 1950, 246). Авторның Башкортстанда таралган татар (типтәр) сөйләшләренең нигездә бер-берләренә якын булулары турындагы фикерелләре дә зур әһәмияткә ия. Бу татар диалектологларының узган гасырның 60-80 елларда уздырылган тикшеренүләре белән дә расланды.

Башкортстандагы татар сөйләшләрен өйрәнүдә күренекле татар диалектологы Л.Т. Мәхмүтованың роле зур булды. Ул 1954-1957 елларда Башкортстанның көнбатыш районнарына оештырылган диалектологик экспедицияләр белән җитәкчелек итте. Шушы материаллар нигезендә ул минзәлә һәм бөре сөйләшләре турында фәнни мәкаләләр язып бастырды (Махмутова, 1962, 57-86). Ул, татар телчеләреннән беренчеләрдән булып, тарихи Башкортстан җирләренә мөнәсәбәттә кулланылган башкорт, типтәр, мишәр терминнарының этник мәгънә белдерүдән бигрәк, социаль терминнар буларак кулланылуына игътибар итте. Башкорстанның көнбатыш районнарында яшәгән татарларның сөйләшләрен өйрәнгәндә, галимәнең бу фикерләре дөрес фәнни нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирде. Башкортстандагы татар сөйләшләрен өйрәнү буенча Л.Т. Мәхмүтова тарафыннан башлап җибәрелгән эшне аның укучылары дәвам итте.

Башкортстанда татар сөйләшләрен, аерым алганда минзәлә сөйләшен өйрәнүгә Казан дәүләт университеты галимнәре дә өлеш керттеләр. Студентларның диалектологик практикасына җитәкчелек итү барышында, 1956 елда Җ. Алмаз, Илеш һәм Дүртиле районнарында яшәүчеләрнең тел үзенчәлекләрен өйрәнеп, "Башкортстанның Дүртиле һәм Илеш районнары татарларының сөйләшенә карата" дигән мәкаләсен бастырды (Алмаз,1954). Галим бу төбәктә яшүчеләрнең сөйләше буенча кызыклы гына күзәтүләр ясый, бай лингвистик материал китерә. Ул да, халык арасында сакланып калган күп кенә легендаларга таянып, башкорт һәм типтәр терминнарының, беренче чиратта, җиргә мөнәсәбәтле булган социаль катламны белдерүен әйтә.

1954-1956 елларда әлеге территориядә яшәүчеләрнең тел үзенчәлеге Казан дәүләт угиверситеты укытучысы Ә.Ш. Әфләтүнов тарафыннан да өйрәнелә. Ул, бу якта яшәүчеләрнең тел үзенчәлекләрен татар теленең башка сөйлшләре белән чагыштырып, кандидатлык диссертациясе яклый. Галим Башкортстанның көнбатышында яшәүчеләрнең телен татар әдәби теленә һәм күрше татар сөйләшләренә бик якын тора, дип исәпли. Ә.Ш. Әфләтүнов фикеренчә дә, биредәге татарларны кайбер язмаларда һәм халык санын алу кенәгәләрендә башкорт, типтәр дип әйтү аларның сыйнфый билгеләреннән чыгып бирелгән, дип исәпли.

XX гасырның 60 елларыннан башлап, СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы галимнәре Татарстанның көнчыгыш, Башкортстанның көнбатыш районнарында яшәүче татарларның тел үзенчәлекләре, татар теленең Диалектологик атласын төзү максатында, махсус программа нигезендә өйрәнелде. Шушы эш барышында, Ф.Ю. Юсупов, Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова әлеге географик зонада яшәүче татарларның сөйләшләре, татар авылларының тарихы, халык авыз иҗаты буенча бай фактик материал тупладылар (Юсупов, 2002,64).

Ф.С. Баязитова. "Татар теленең Түбән Кама тирәсендә таралган сөйләшләре, Д.Б. Рамазанованың "Урта Кама тирәсендә таралган сөйләшләре"("Говоры татар Среднего Прикамья" Рамазанова, 1973) дигән темаларга якланган кандидатлык диссертацияләре минзәлә сөйләшенең аерым урынчылыкларын

яктыртуга багышланды. 1984 елда басылып чыккан “Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии” хезмәтендә Д. Б. Рамазанова минзәлә сөйләшенең аерым урынчылыкларын җентекләп өйрәнә.

Ф.С. Баязитова, Татарстанның Алабуга Чаллы, Актаныш, Сарман, Минзәлә, Әлмәт, Бөгелмә, Мөслим районнары, Башкортстанның Бакалы, Чакмагыш, Илеш, Шаран районнарындагы татар авылларының сөйләш үзенчәлекләрен өйрәнеп, ” Татар теленең минзәлә сөйләше” дигән мәкаләсен бастырып чыгарды. Урал итәкләренең киң территориясендә таралган татар сөйләшләре буенча махсус сораулык буенча тупланган бай материал нигезендә, ул минзәлә сөйләшенең көнбатыш һәм көнчыгыш чикләрен билгели һәм, аннан алдагы тикшеренүчеләрнең фикерен раслап, бу сөйләшнең барлык территориядә дә нигездә бер төрле икәнлеген әйтә. Мәкалә авторы белдергәнчә, минзәлә сөйләше көнбатыш чикләрендә урта диалектның мамадыш, көнчыгышта бөре сөйләшләренең кайбер үзенчәлекләре белән баетыла.

Ю.Ю. Юсупов 1967, 1968, 1969, 1970 елларда Татарстанның Актаныш, Зәй, Минзәлә, Башкортстан Республикасының Илеш, Дүртиле, Чакмагыш, Блогавар, Бүздәк районнарыда яшәүчеләрнең тел үзенчәлекләре, татар авылларының тарихы, халык авыз иҗаты буенча бай материал туплады, аларны үзенең күп санлы хезмәтләрендә бу татарларның тарихы, сөйләшләренең формалашу этапларын яктыртканда файдаланды

Күп еллар буенча алып барылган эзләнүләр нәтиҗәсендә, әлеге төбәктә яшәүче татар һәм типтәр сөйләшләре татар теленең аерылгысыз бер сөйләше – күп гасырлар дәвамында төрле сәяси – икътисадый шартларда, төрле этник төркемнәрнең үзара мөнәсәбәтләре нәтиҗәсендә формалашкан мөстәкыйль татар сөйләше икәне исбат ителде.

Юсупова А.Ш.

Отражение субъективных факторов в татарско-русских и русско-татарских словарях XIX века

В XIX веке с целью обучения татар русскому, а русских – татарскому языку были составлены и изданы словари «Слова коренные, нужнейшие к сведению для обучения татарскому языку, собранные в Тобольской главной школе, учителем татарского языка Софийского собора, священником Иосифом Гигановым и муллами юртовскими свидетельствованный» И.Гиганова (СПб., 1801), «Словарь российско-татарский, собранный в Тобольском главном народном училище учителем татарскго языка И.Гигановым и муллами юртовскими» И.Гиганова (СПб., 1804), «Словарь татарского языка и некоторыхъ употребительныхъ въ немъ реченій арабскихъ и персидскихъ, собранный трудами и тщаніемъ учителя татарского языка въ Казанской семинаріи священника Александра Троянского и напечатанный съ дозволенія комиссіи духовныхъ училищъ» А.Троянского (Казань, 1833, 1835), «Словарь к татарской хрестоматии» С.Кукляшева (Казань, 1859), «Сравнительный словарь турецко-татарских наречий, со включением употребительнейших слов арабских и персидских и с переводом на русский язык» Л. Будагова (СПб., 1869,1871), «Татарско-русский словарь» К.Насыри (Казань, 1878), «Первый опыт словаря народно-татарского языка по выговору крещёных татар Казанской губернии» Н.Остроумова (Казань, 1876), «Краткий татарско-русский словарь с прибавлением некоторых славянских слов с татарским переводом» Миссионерского общества (Казань, 1880, 1882, 1886, 1888, 1891), «Татарско-русский словарь» Н.Остроумова (Казань, 1892), «Перевод с татарского на русский язык или словарь» Ш.Габдельгазиза, «Русско-татарский словарь» А.Воскресенского (Казань, 1894), «Татарско-русский словарь наиболее употребительных слов и выражений» М.Юнусова (Казань, 1900) и др. В татарско-русские и русско-татарские словари XIX века были включены лексические единицы, которые широко употреблялись в этот период, в том числе и слова разговорной речи. В них можно встретить и лексические диалектизмы, и фонетические

варианты, характерные для того или иного диалекта, и сложные арабско-персидские заимствования, а также русско-европейскую лексику, которая постепенно замещала арабско-персидские заимствования.

В каждом татарско-русском и русско-татарском словаре XIX века нашли свое отражение не только объективные обстоятельства, но и личностное отношение их составителей и издателей, их знания, положение, и занимаемое ими в обществе.

На те или иные особенности соответствующего словаря могли повлиять и место жительства автора, и условия его жизни, деятельности, круг общения. А.Троянский, К.Насыри жили и работали в Казани; А.Воскресенский − в Казани и Астрахани; И.Гиганов – в Сибири; Л.Будагов – в Санкт-Петербурге; С.Кукляшев – в Оренбурге; Н.Остроумов – в Казани, Ташкенте, Туркестане; Ш.Габдельгазиз проживал в деревне Чукри Алемово (ныне деревня Чукри Аланово Кайбицкого района Республики Татарстан); М.Юнусов избрал местом проживания Чистополь [Кононов, 1974, с.272, с.224, с.141, с.146, с.130, с.201, с.229, с.246, с.293].

Безусловно, важным фактором являлся уровень образованности авторов-составителей словарей. Л.Будагов, С.Кукляшев обучались в классических университетах. Л.Будагов окончил отделение восточных языков Санкт-Петербургского университета [Кононов, 1974, с.130], С.Кукляшев – факультет филологии Казанского Императорского университета [Кононов, 1974, с.201].

К. Насыри, Ш. Габдельгазиз получили образование в медресе. К.Насыри учился в известном казанском медресе «Касыймия» [ТЭС, 1999, с.388], был вольнослушателем Казанского университета; Ш.Габдельгазиз закончил Апанаевское медресе в Казани [ТЭС, 1999, с.465].

А.Троянский, Н.Остроумов, А.Воскресенский – выпускники Казанской духовной академии, обучались на богословском и миссионерском противомусульманском отделениях [Кононов, 1974, с.272, с. 229, с.141].

Словари, составленные И.Гигановым и М. Юнусовым, также свидетельствуют об уровне их филологических знаний.

Отдельные особенности словарей обусловлены профессией их составителей. Многие из них были преподавателями: И.Гиганов преподавал в Тобольском народном училище, А.Троянский − в Казанской духовной академии, Л.Будагов − в Санкт-Петербургском университете, С.Кукляшев – в Неплюевском кадетском корпусе (Оренбург), М.Юнусов – в городском медресе Чистополя, К.Насыри − в Казанской татарской учительской школе. Они обучали татарскому языку русскоязычных слушателей и русскому языку − татар.

Н.Остроумов и А.Воскресенский были активными членами Миссионерского общества святителя Гурия. Н.Остроумов преподавал в Казанской духовной академии и учительской семинарии, работал инспектором Туркестанского народного училища, выполнял обязанности директора мужской гимназии в Ташкенте, был редактором газеты. А.Воскресенский обучал богословию в Казанской крещёно-татарской школе, был инспектором в казахских школ Астрахансклй губернии, работал директором Казанской и Преславской учительских семинарий [Кононов, 1974, с.229]. Татарско-русские и русско-татарские словари были необходимым в их повседневной деятельности.

Специфические черты словарей были обусловлены и религиозными верованиями их составителей. Большинство авторов рассмотренных словарей − представители христианской религии. Работа по составлению словарей была тесно связана с их миссионерской деятельностью.

Следует обратить внимание на принципы составления словарей, раскрывающие уровень филологических знаний их авторов. Так, словарю «Сравнительный словарь турецко-татарскихъ наречій, съ включеніемъ употребительнейшихъ словъ арабскихъ и персидскихъ и съ переводомъ на русскій языкъ...» Л. Будагова (1869, 1871) присуще продуманное расположение слов и их толкование, в нем указаны источники и их происхождения, сферы употребления, приводятся однокоренные слова и даётся их сравнение с вариантами из других тюркских языков. В словарь включены также наиболее

употребительные арабские и персидские слова, что свидетельствует о глубине филологических знаний автора.

В словарях, выпущенных Миссионерским обществом святителя Гурия [1880, 1882, 1886, 1888, 1891], даётся лишь перевод слов и отсутствует какая-либо информация филологического характера.

В татарско-русские и русско-татарские словари XIX века включались лексические единицы, находившиеся в активном употреблении, а также варианты разговорной речи. К тому же в них фиксировались и диалектизмы, и сложные арабско-персидские заимствования, и религиозные термины.

В заключении отметим, что формирование в XIX веке корпуса двуязычных словарей являелось результатом комплекса объективных и субъективных факторов, обусловленных изменениями в общественно-политической жизни России. В определённой степени сам факт их (словарей) создания свидетельствовал о росте национального самосознания татар и усилении роли татарского языка и культуры в общественно-политической и экономической жизни Российской империи. В ещё большей степени расширение корпуса татарско-русских и русско-татарских словарей, повышение их качественных характеристик указывали на существенное усиление процессов многопланового встраивания татарского народа во все важнейшие сферы жизни России сближения татарского народа и русскоязычного населения.

Литература

1.Кононов А.Н. Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов [дооктябрьский период] / А.Н. Кононов. − М.: Наука, 1974. – 340 с.

2.Татарский энциклопедический словарь. − Казань: институт татарской энциклопедии АН РТ, 1999. − с.703

Юсупова А.Ш., Ситдыкова А.Ф.

Тематические группы «Посуда» в татарско-русских и русско-татарских словарях XIX века

В материальной культуре любого народа важное место занимают домашняя посуда и утварь. Изобретая орудия труда, человек дает им соответствующие названия.

Наименования, обозначающие предметы, составляют древний пласт лексики. Изучение названий предметов домашней утвари, их научно-теоретическое освещение – одна из важнейших проблем современного языкознания.

Татарская кухонная утварь, посуда отличается большим разнообразием. Поэтому данная тематическая группа включает в себя большое количество наименований.

Следует отметить, что слова этой тематической группы не изучены в татарском языкознании. В научных исследованиях изредка встречаются этимологические толкования некоторых лексем этой тематики. Например, в монографии Т.Х.Хайрутдиновой «Бытовая лексика татарского языка» (2000) наряду с названиями предметов быта рассматриваются названия посуды и указывается, что часть их зафиксирована в двуязычных словарях XIX века.

В нашей статье комплексному анализу впервые подвергаются названия посуды тюрко-татарского происхождения, зафиксированные в татарско-русских и русско-татарских словарях XIX века. В этих словарях закреплено очень много слов, обозначающих посуду, кухонную утварь.

Зафиксированные в двуязычных словарях слова дошли до нас без каких-либо изменений. Например, **чиниак** – чашка [Г., 1804, с.490; Т., 1833, с.490], **аякъ** – чаша [К., 1859, с. 20; Г., 1801, с.9], **бардак** - кувшин, манерка [Т., 1833, с.183], **кашык** – ложка [Б., 1871, с. 15.; К., 1859, с.76; Т., 1835, с.101; О., 1876, с. 87; Г., 1801, с. 9], **чүмеч** – ковшикъ [Т., 1833, с. 497], **чумичка** – уполовник [Б., 1869, с.500.], **чүмеч, тустаган** - ковшъ [ковшикъ] [Н., 1878, с.55], **комган** – кукшин - кувшин [Н., 1892, с. 55], **чүмяк** – горшокъ [Н., 1892, с.32], **чюмеч** – чумыч, ковшъ [О., 1892, с.232], **чынаяк** – чашка чайная, фарфоровая чашка[О.,

1892, с. 223], **чургат** – медный сосуд для пива [О., 892, с. 230; Ю., 1900, с. 101], **казан** – котел [Б., 1871, с.14., Г., 1801, с. 10; О., 1876, с. 82; Кр., 1888, с.19; Т., 1835, с. 94], **кәс** – чаша, стаканъ [К., 1859, с. 79], **кан – кын** – горшки, кастрюли, котлы, чашки [Б., 1871, с.1], **шәрап кыны** – сосуд для вина [Б., 1871, с.1], **аяк** – чашка, чаша, чарка для вина [Б., 1869, с.174; К., 1859, с. 20], **аяк аш** – деревянная чашка изъ которой едят, миска [Б., 1869, с. 174.], **савыт** – посуда [Б., 1869, с. 693.], **чулпы** – ковшъ плетенный, ситечко [Б., 1869, с.499.], **чаучак** – деревянная чаша [Б., 1869, с.465.], **чаргата** - ковшикъ [Б., 1869, с.465.], **жяйляў** – чайное блюдечко[О., 1892, с.88], **тырыс** – тырысчык буракъ, ведро изъ берёзовой коры [О., 1892, с.208], блюдо – **табак, жяйлян** [большое деревянное блюдо] [В., 1894,с.10; Г., 1804, с. 19; Т., 1835, с. 3; Кр, 1888, с. 19; Г., 1801, с. 9], кубышка – **чюлмяк** [В., 1894, с.115], **чанчки** – вилка [Г., 1801, с. 9, Кр, 1888, с. 19, Т., 1833, с. 490], **пчакъ** – ножикъ [Г., 1801, с. 9], **чулмякъ** – горшокъ [Кр, 1888, с. 19; Г., 1801, с.10], **чуюнъ** – чугунъ [Кр., 1888, с. 19], **кисьмякъ** – кадка [Кр, 1888, с. 19], **тоз сауты** – солонка [Г., 1801, с. 9; Кр, 1888, с. 19; Т., 1833, с. 308], **кабкачъ** – крышка [Г., 1801, с.10], **таба** – сковорода [Т., 1835, с. 3; Кр., 1888, с.19; О. 1876, с. 118], **илякъ** – сито [Г., 1801, с. 10; Кр., 1888, с. 19], **чилякъ** – ведро [Г., 1801, с. 9; Кр. 1888, с. 19], **чын табак** – чайное блюдечко [Т., 1833, с. 490], **калак** – лопатка [О., 1876, с. 83], **созгеч** – ситечко [Т., 1833, с. 577], **кыргыцъ** – терка [Г., 1804, с. 601], **кисмәк** – кадка, кадушка, **кебгир** – ситечко чайное, **куш** – пара наполненных вином чашек [Б., 1871, с.82], **ләгүн** – кадка с двумя днами, **казан** – котел [Б., 1871, с.14], **кулама** – лоток с ручками [Б., 1871, с.89] и т.д.

Само понятие «посуда» в татарском литературном языке выражается словом **савыт - саба.** В таком же варианте оно зафиксировано в словаре А.Троянского [Т., 1833, с. 616]. В работах И.Гиганова, Н.Остроумова это понятие педается словом «сауыт» – посуда [Г., 1801, с. 9; О., 1876, с. 112]. Употребляясь с определяющими словами, **савыт** выражает новые понятия: **шикяр сауты** – сахарница [Кр., 1888, с. 19], **тоз сауты** – солонка [Г., 1801, с. 9; Кр., 1888, с. 19; Т., 1833, с. 308], **ком сауты** – песочница [Т., 1835, с. 120].

Слово **аякъ** [Г., 1801, с.9, К., 1859, с.20] – весьма древняя тюрко–татарская лексическая единица. В письменных памятниках татарского языка лексема **айак** отмечена в значении «чаша, пиала, полоскательница»: «Башыннан балны кояек, Идегәй андый ир икән, Берәр **аяк** куяек» [Идегэй, 1988, с.719]. В произведении «Нахдж ал-Фарадис» **айак** даётся в значении «бокал, кубок», а в памятниках деловой письменности обозначает посуду [Нуриева, 1999, с.77; Хисамова, 1981, б.48; Хайрутдинова, 2000, с.50–51]. Этот же компонент входит в составе слов **чынаяк**: **чин аяк - chin ajq** – китайская посуда или чашка, **җам аяк** – бадьян, чаша, **аяк аш -** деревянная чашка, изъ которой едят, миска [Б., 1869, с. 174.]. Для обозначения понятия «кухонная и столовая посуда» в словаре Н.Остроумова зафиксировано слово **кашаяк** (кашык + аяк) – кухонная посуда [О., 1876, с. 87]. В XIX веке активно употреблялось состоящее из двух корней таш+аяк слово **ташаяк** – каменная посуда. В XV–XVI веках в Казани, на правом берегу реки Булак, проводилась ярмарка «Ташаяк ярминкәсе» («Ярмарка Ташаяк»). Кроме татар и русских, здесь торговали купцы из стран Средней Азии, Кавказа. Товары – кожа, пушнина, ткани, металлические изделия и др. Об этом свидетельствует сохранившая небольшая улица «Ташаяк » [ТЭС, 1999, с.569].

Среди кухонной утвари, необходимой для приготовления пищи, у татар в основном преобладала деревянная посуда. Из дерева делали лотки, кадки для хранения муки, зерна и других продуктов, ковши, скалки и другие предметы. Деревянные изделия, применяемые в быту, были разнообразны и по своим названиям. Большинство наименований посуды и утвари сейчас считаются архаизмами. Обусловлена историческими и социальными изменениями в жизни народа. С исчезновением старой посуды пропадают и связанные с ней наименования. Память о них хранится лишь в словарях: **чаучак** − деревянная чаша [Б., 1869, с.465], **аяк аш** − деревянная чашка, изъ которой едят, миска [Б., 1869, с. 174.], **бадьян** – большая деревянная чашка, въ которой подаютъ пиво для угошения пришедшихъ [О., 1876, с. 55].

Слово **иляк** – сито зафиксировано во многих словарях [Г., 1804, с.512; Г., 1801, с. 10; Кр., 1888, с. 19]. В зависимости от

материала было распространено название **кыл иляк**, которое отмечено нами в словаре И.Гиганова [Г., 1801, с.10]. В современном татарском языке данное словосочетание употребляется в составе фразеологизма *кыл иләктән иләү* (пропускать через сито). В словаре Н.Остроумова зафиксировано слова **он иляге** – мучное решето, **жармя иляге** – крупяное решето [О., 1892, с.94].

Забытыми, устаревшими считаются: **кэс** – чаша, стаканъ [К.,1859, с. 79], **кын** – горшки, кастрюли, котлы, чашки [Б., 1871, с.1], **шәрап кыны** –сосуд для вина [Б., 1871, с1], **халва табак** – тарелка [Г., 1801, с.9; 1804, с. 598], **кадяхъ** – чаша [Г., 1804, с. 650], **чара** – чаша большая [Т., 1833, с. 460] и т.д. Здесь же необходимо рассмотреть слово **чулпы** – ковшъ плетенный, ситечко [Б., 1869, с.499]. Эта лексема в различных фонетических вариантах широко распространена в тюркских языках.

Из диалектной лексики, отражающий названия посуды, отметим слова: **ашлавъ** – корыто [Г., 1801, с. 9], **капкир** – половник [Г., 1801, с .7], شبالا **шабаля** – ложка [Г., 1801, с. 9] и т.д. При этом слово *шабала*, изменив своё значение, функционирует в значении «щипцы для угля» в говоре сафакульских татар [Юсупов, 2006, б. 179].

Бадьян (деревянная чаша) употребляется в значении «посуда, изготовленная из дерева» [О., 1876, с.55; О., 1892, с.32]. На сегодняшний день оно сохранилось лишь в диалектах татарского языка. Например, в заказанском и атнинском говорах *бадьян* обозначает деревянную посуду и употребляется именно в этом значении. В тамбовском же говоре бадьяном называют деревянное ведро [ТТДС, 1993, б.42].

Тигяня (начевки) – желобообразная ёмкость, изготовленная из цельного куска дерева путём выковыривания из него сердцевины; посуда; употребляется в значении «корыто» [О., 1876, с.171; О., 1892, с.195]. В современном литературном языке слово *тигәнә* употребляется реже, тем не менее в диалектах оно встречается довольно часто. Например, в карсунском, кряшенском и мишарском говорах Ульяновской области существуют такие варианты слова, как *тигәнә* (тигәнәк) и *тегәнә* [ТТДС, 1993, б.297], которые обозначают «жёлоб, посуду,

сделанную путём выдалбливания» [ТТАС, т.III, б.12]. В говорах сафакульских татар лексема *тигәнә* употребляется в значении «корыто», «колода для скота» [Юсупов, 2006, б. 179].

Лагун – маленькая кадка [О., 1876, с. 100; О., 1892, с. 145]. Это слово встречается чаще в говорах, чем в современном татарском литературном языке. Например, в стерлитамакском и хвалынском говорах используется его варианты – *лагун* (лахун) лоханка; в говорах крещёных татар функционирует лишь вариант *лагун*, который также обозначает маленькую деревянную бочку [ТТДС, 1993, б.210].

Слово **лянгыз** (маленькое ведёрко) [О., 1892, с.146] в современном литературном языке уже не употребляется, но в определённых говорах некоторых областей (чистопольский, дрожжановский, кряшенский) оно находится в активном употреблении и так же обозначает «маленькое ведро, предназначенное для переноса воды или другой жидкости» [ТТДС, 1969, б.294].

Улак (колода) – углублённое и удлинённое приспособление для очищения воды, жидкообразных веществ от частиц, примесей и осадков, которое делали из дерева, камня, металла и других плотных материалов [О., 1876, с.129; О., 1892, с.216]. Встречается в мелекесском, хвалынском и дрожжановском говорах мишарского диалекта и мензелинском говоре среднего диалекта [ТТДС, 1969, с.454], раскрывая при этом то же самое значение [ТТАС, т.III, с.306].

К этой же группе можно отнести слова **каплама, табак кашыгы, саблаяк, бакрач, җәйләү, җилпуч.** Слово **каплама** [Ю., 1900, с.83] в мензелинском говоре среднего диалекта используется в значении «закрывающаяся деревянная посуда, предназначенная для мёда, масла и сахара» [ТТДС, 1993, б.129]. В словарях XIX века зафиксировано несколько вариантов слова **аш чүмече** – половник. Н.Остроумов предложил вариант **табак кашыгы** [О., 1878, с.185], И.Гиганов –**капкир** [Г, 1801, с.7], а К.Насыри – **бакрач** [Н., 1878, с.14]. Перечисленные выше слова по сей день продолжают своё существование в различных говорах. В заказанском говоре употребляется слово *табак*

кашыгы [ТТДС, 1993, с.134], в карсунском – *саплаяк* [ТТДС, 1993, с.263], в каргалинском, стерлитамакском, мензелинском а также в заказанском и чистопольском говорах – *бакрач* [ТТДС, 1969, б.65; ТТДС, 1993, с.43].

К словам, обозначающим посуду, можно отнести такие лексические единицы, как **җилпуч** – лоток [Ю., 1900, с.19], **кәрнәшә** – кузовок [О., 1892, с.111], **җәйләү** – чайное блюдечко [О., 1892, с. 88], توستغان **тустаган** [Н., 1878, с. 66], **чапчак** – кадка [Ю., 1900, с. 101], كه ندي **кандәй** – чашка [Б., 1871, с.14], **кулаш**а – лоток [О., 1876, с.131; Ю., 1900, с.77]. Они употребляются в разных диалектах и находят своё отражение в диалектологических словарях татарского языка, в том числе в составе имен собственных. Например, слово *чапчак* сохранилось в топониме Кызыл Чапчак [Населенные пункты..., с.205].

Таким образом, представленные здесь названия посуды и кухонной утвари весьма разнообразны и имеют довольно большое количество синонимов. Большинство из них тюркского происхождения и широко распространены во многих тюркских языках.

Источники

Б. Будагов Л. Сравнительный словарь турецко-татарских наречий, со включением употребительнейших слов арабских и персидских и с переводом на русский язык: в 2 т. / Л. Будагов. – СПб.: Тип. АН, 1869. – Т.1. – 810 с.; – СПб.: Тип. АН, 1871. – Т. 2. – 415 с.

Г. Гиганов И. Слова коренные, нужнейшие к сведению для обучения татарскому языку, собранные в Тобольской главной школе учителем татарского языка, Софийского собора священником Иосифом Гигановым и юртовскими муллами свидетельствованные / И. Гиганов. – СПб., 1801. – 75 с.

Г. Гиганов И. Словарь российско-татарский, собранный в Тобольском главном народном училище учителем татарского языка И.Гигановым и муллами юртовскими / И. Гиганов. – СПб.: Имп. АН, 1804. – 627 с.

В. Воскресенский А. Русско-татарский словарь с предисловием о произношении и этимологических

изменениях татарских слов А.Воскресенского / А.Воскресенский. – Казань, 1894. – 374 с.

Кр. Краткий татарско-русский словарь с прибавлением некоторых славянских слов с татарским переводом. – Казань, 1880. – 55 с.; 1882. – 55 с.; 1886. – 96 с.; 1888. – 96 с.; 1891. – 96 с.

К. Кукляшев С. Словарь къ татарской хрестоматии / С.Кукляшев. – Казань, 1859. – 106 с.

Н. Насыри К. Татарско-русский словарь / К. Насыри. – Казань, 1878. – 120 с.

Н. Насыри К. Полный русско-татарский словарь с дополнением из иностранных слов, употребляемых в русском языке как научные термины / К. Насыри. – Казань, 1892. – 263 с.

О. Остроумов Н.П. Первый опыт словаря народно-татарского языка по выговору крещеных татар Казанской губернии / Н. Остроумов. – Казань, 1876. –145 с.

О. Остроумов Н.П. Татарско-русский словарь / Н. Остроумов. – Казань, 1892. – 246 с.

Т. Троянский А. Словарь татарского языка и некоторыхъ употребительныхъ въ немъ реченій арабскихъ и персидскихъ, собранный трудами и тщаніемъ учителя татарского языка въ Казанской семинаріи священника Александра Троянского и напечатанный съ дозволенія комиссіи духовныхъ училищъ, в 2 т. / А. Троянский. – Казань, 1833. – Т. 1. – 629 с.; – Казань, 1835. – Т. 2. – 340 с.

Ш. Габделгазиз Шигабутдин. Перевод съ татарскаго на русский языкъ или словарь / Ш.Габделгазиз. – Казань, 1893. − 72с.

Ю.Юнусов М. Татарско-русский словарь наиболее употребительных слов и выражений / М. Юнусов. – Казань, 1900. – 115 с.

Литература

Идегәй: Татар халык дастаны. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2006 – 535 б.

Нуриева Ф.Ш. Нахдж ал –Фарадис Махмуда ал –Булгари / Ф.Ш.Нуриева. – Казань: Фән, 1999. – 208 с.

Хайрутдинова Т.Х. Бытовая лексика татарского языка / Т.Х. Хайрутдинова. – Казань: Фикер, 2000. – 124 с.

Хисамова Ф.М. XVШ йөздәге татарча эш кәгазе язмаларынын тел үзенчәлекләре / Ф. М. Хисамова. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1981. – 162 б.

Юсупов Ф.Ю. Сафакүл татарлары: тарих, тел, халык иҗаты / Ф.Ю.Юсупов. – Казан: Татполиграф, 2006. – 607 б.

Юсупова А.Ш. Самоучители татарского языка XIX века. Лексика / А.Ш.Юсупова. – Казань: РИЦ «Школа», 2002. – 140 с.

Янсаева Л. А.

Татар теле диалекталь синтаксисында җөмлә кисәкләренә кагылышлы аермалыклар.

Соңгы елларда татар халкы, бигрәк тә яшь буын, акрынлап булса да, әдәби телдә сөйләшүгә күчеп бара. Ә бит татар теленең төрле диалектлары бар. Аларда телебез тарихын өйрәнү өчен гаять әһәмиятле булган күренешләр сакланып ята. Сөйләшләрне өйрәнү гомумтатар культурасын үстерүгә зур өлеш кертә.

Синтаксис - телнең иң тотрыклы өлкәләренең берсе. Телнең нигезе, мөстәкыйльлеге, үзенчәлеге аның грамматик төзелешенә, аеруча, синтаксиска бәйле. Телнең лексикасы, фонетикасыннан башка, телләрнең тәэсире көчле булганда да синтаксиста бу тәэсир күзгә бәрелеп тормый. Әмма борынгы язма әдәбият үрнәкләрен хәзерге көн әдәби теле белән чагыштырып караганда, без синтаксиста да аермалыкларны күрәбез. Мәкаләдә без диалектларда кулланылган җөмлә кисәкләре арасында булган аермалыкларга игътибар итәрбез.

Халыкның сөйләм теле тизәйткечләр формасында тиз генә әйтелә. Шул сәбәпле сүзләр җөмләдә бер-берсенә кушылып та киләләр. Бу бигрәктә хәбәрләр арасында еш очрый. Мәсәлән: *Суwырткыч **суwыртадырыйык** балага*(ТТДС, 1969: 374, к.-арт., лш.,). *Аруга өзелмибез без бер дә, узган йыл бодай күп **алганыйык***(к.-арт. блт).

Хәбәрне тикшергәндә иң беренче очракта элипсис күренешенә тукталып үтәргә кирәк. Диалектларда һәм сөйләшләрдә кушма хәбәр күп очракта кушылып килә. Әдәби

телдә мондый күренешне галимнәр сөйләм телендәге экономия принцибы белән аңлаталар. Сөйләшләрдә төп экономияләү чарасы – төшереп калдыру. Бу экономияләү принцибының тышкы факторы. Ташкент галиме М. Ш. Турапова фикеренчә, диалекталь синтаксиста экономияләү принцибы гомуми төшенчәне өлешчә бирүдә чагыла[8:56]. Ягъни, диалекталь сөйләмдә кыска җөмләләр белән сөйләү хас. Әмма, бу, сөйләшләр тулысынча гади җөмләләрдән генә тора дигән сүз түгел. Диалекталь сөйләмгә игътибар итсәк тезмә кушма, иярчен кушма җөмләләрне дә күрә алабыз. Кайчакта диалекталь сөйләмдә катлаулы җөмлә төрләрен дә очратабыз. Мондый җөмләләр сөйләм теленә эмоциональ төсмер, образлылык өсти һәм әдәби телдә стилистик максаттан чыгып кулланылалар.

Шулай да бәхәскә илтүче сораулар барлыкка килә. Сүзләрнең бер-берсенә яраклашып килүен фонетика өйрәнә. Л. Җәләй шул исәптән, мондый үзенчәлекне, фонетик үзенчәлек буларак карый. Әмма шунысы ачык: аерым очракларда синтаксик үзенчәлек булып фонетик һәм морфологик үзенчәлекләр дә була ала. Мәсәлән, ассимиляция вакытында кушма хәбәр **(алып килә)** гади хәбәргә әйләнә **(апкилә).** Ә хәбәр төрләрен синтаксис өйрәнә. Мәсәлән: *Тегене **ватыбыргытты** да сывка ташлады*(злт.). *Суwырткыч **суwыртадырыйык** балага*(ТТДС, 1969: 374, к.-арт., лш.,). *Өй агартларга **йөрткәнийем** пумаламны*(Юсупов, 2004: 191). Тикшеренүләрдән күренгәнчә, мишәр диалектында **-дер** кушымчасы белән тәмамланган фигыльләргә ярдәмлек фигыле күпләп ялгана. Әлеге сөйләш вәкилендә **30**га якын кушма хәбәрләрдән ясалган гади хәбәрләр очрады. Аларның арасында **фигыль+иде** конструкциясендә килгән **27** хәбәр табылды. **Иде** фигыле татар теленең бик күп сөйләшләрендә үзеннән алда килгән сүзнең авазлар составына буйсына: *Пылау пешерәләр вет шолай/ кашыкларны кадап чыгара тырганнар ыйы/ шул тәртке **булайды***(Садыкова, 1986: 219). *Аннан килен булып тешкәч элек заманда су йулы күрсәтергә **барайды*** (Садыкова, 1986: 220). Урта диалектта *алып килде, алып китте* кебек конструкцияләр гади хәбәргә әйләнәләр. Моны фонетика бүлегендә яшәп килгән закончалыклар белән аңлатып була. Боерык җөмләнең хәбәре шарт фигыль нигезендә килгән кушма төрен Каюм Насыйри **“сыйгаи тәмәнни”[**6: 55] дип атый. Монда без карап үткән

алсиде, **дисиде** кебек кушма фигыль хәбәрләрдән гади хәбәрләр мисалын китерә.

Мондый кушмаларның күбесе телебезнең башка диалект сөйләшләрендә дә шактый күпләп саклана. Л. Җәләй “Бу алым бер сүз буларак кушылган тамырларда гына түгел, бәлки бөтен бер синтагма, яки тулы җөмлә төзү уңаенда үзара мөнәсәбәткә кергән сүзләрне әйтүдә дә ачык сизелә [3: 15] -ди. Мәсәлән: **апар - алып бар, әпкил – алып кил һ. б.** Бу кыскартылмалар җөмләдә аерым синтагма булып киләләр. **Мәйтәм – мин әйтәм** дигәндә исә тулы җөмләнең логик пауза белән аерылып әйтелергә тиеш кисәкләре бер-берсенә керешәләр. Билгеле, мондый кыскартулар тел өчен файдалы түгел.

Көнбатыш һәм көнчыгыш диалектларында кире күренешләр күзәтелә. Ягъни, әдәби телдә гади фигыль хәбәрләр, әлеге диалектларда кушма фигыль хәбәр буларак киләләр. Мәсәлән: *Шал китапны миңа* ***пиреп пакцы****. – Шул китапны миңа* ***бирче****. Көтмәгәндә* ***килеп йеварте****. – Көтмәгәндә* ***килде****. Иртәгәсен урамга цыгып паксам, ап-ак кар* ***йауып йататы****. – Иртән урамга чыксам, ап-ак кар* ***ява***(Әхәтов, 1963: 178). *Тчиткә* ***китә булганнар*** *актча эшләргә*(Арсланов, 1966: 124). - *Тчиткә* ***киткәннәр****, актча эшләргә.* Мишәр диалектында **фигыль+булган** конструкциясе килеп, гади хәбәрдән кушма фигыль хәбәр барлыкка китерә. Әлеге диалектта мондый күренешләр бик күп таралганнар. Төрки телләрдән әзәрбайҗан сөйләшләрендә[1: 31] дә очрый.

Әдәби телдә ия белән хәбәр зат-санда яраша. Мондый күренеш татар теленең диалектларында һәм сөйләшләрендә дә күзәтелә. Әмма чараларның нинди формада бирелүләренә карап, бер диалект, икенче диалекттан аерыла. Ф. С. Сафиуллина мондый күренеш **“аномалия хәленә дә житә”[7**: 167], ди. Ягъни, әдәби телдә чагылыш тапмаган чаралар диалектларда урын ала.

Әдәби телдә үткән заман хикәя фигыльләр белән бирелгән хәбәрләр, ия белән затта һәм санда ярашмаска мөмкин. Диалектларда һәм сөйләшләрдә мондый күренешләр еш очрый. Себер татарлары диалектының күп сөйләшләрендә үткән һәм хәзерге заман фигыль зат кушымчасыз килергә мөмкин: *Мин сөйләй белмәймен,* ***оныткан***(СДМ, 2001: 31, тмн с.,). *Мин аны гөмөрөмтә бер генә мәртәбә* ***ишеткән***(СДМ, 2001: 41, тмн с.,).

Күп очракларда хәбәрнең зат кушымчасыннан башка кулланылганда, ия алмашлык белән чагыла. Шулай да күп вакытта алмашлык төшеп калырга мөмкин. Бу очракта сөйләм ситуациясеннән генә затны билгеләргә кала. Мондый ук күренеш мишәр диалектының чистай сөйләшендә дә күзәтелә[6: 12].

Әдәби телдә I**(-мын/-мен; -сың/-сең)**, II**(-м; -ң)** группа зат кушымчалары килсә, диалектларда әлеге группалар бер-берсе белән буталчыкта яшиләр. Себер татарлары диалектының Омск өлкәсенең Тевриз, Тарск районнарында, Төмән өлкәсенең Вагай районнарында I группа урынына II группа кулланылып килә: *мин парганын, укыганын. – барганмын, укыганмын.* Мәсәлән: ***Мин* *сиңа бер имә әйтәнен***(СДМ, 2001: 62, тмн с.,). Башкорт теленә якын урнашкан сөйләшләрдә II зат берлек санда хәзерге заманда кыскартылган **–ң** кушымчасы белән төрләндерү киң таралган. Моны башкорт теленең йогынтысы белән аңлатырга мөмкин. Мәсәлән: *Салгы алып кайа **бараң**?*(Юсупов, 2003: 63). *Мәкәрҗә сыргасын колагыңа **кигезәң***(ТТДС, 1969: 382, к.-арт. крш. с.,). *Ниҹә казан **кайнатаң**/ кайнаткаҹ шуны **суытаң** түгәрәккә салып*(МТД, 1983: 148, эчк. с.,). Бу үзенчәлек себер татарлары диалектында да очрый. Татар теленең I зат кушымчасының тулы варианты мишәр диалекты өчен генә хас дигән фикер яши. Әмма Урта диалект сөйләшләрендә бу үзенчәлек әдәби тел йогынтысында кулланыла. Иң беренче чиратта касыйм, пермь, минзәлә, нагайбәк, красноуфим, сафакүл һәм эчкен сөйләшләре өчен хас. Бу изаглоссаның үзәге булып себер татарларының диалекты санала[9: 123]. Мондый күренеш хәзерге вакытта да әлеге диалектта күзәтелә. Төрки телләрдән Алтай һәм Урта Азия территорияләрендә таралган телләрдә очрый[2: 158]. Әдәби телдәге II зат кушымчалары урынына мишәр диалектында борынгы сакланып калган **–сын/-сен(-цен/-цын)** формасы яшәп килә: *Син цәй **эцәцен**?*. Бу үзенчәлек урта диалектның красноуфим сөйләшендә дә күзәтелә.

Урта диалектның нократ-глазов сөйләшендә нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыльне белдерү өчен **–ып/-еп** формалы фигыльгә зат кушымчалары ялганып ясалган фигыль формалары актив кулланыла: *Йыклап **китепмен** ич, бабач киткәнне сизмәпмен*(ТТДС, 1969: 62). Мондый ук күренеш мишәр һәм себер диалектында да чагыла: *Сигез йыл солдатта **йерепсең**,*

башын йатмаган әтәм(ТТДС, 1969: 73, срг. с.,). *Каз балаларны кулың белән **үтерепсең, карамапсың** ди бийеменә(*ТТДС, 1969: 85). Соңгы җөмләдә *үтерепсең, карамапсың* сүзләре тиңдәш кисәкләр, ике сүзнең арасында ияртүле бәйләнеш бар. Бу очракта хәбәргә ялганып килгән кушымчалар II зат кушымчасы булып тора.

Әдәби телдә ия белән хәбәр санда да ярашып килә. III зат күплек санда ярашу әдәби телдә ике төрле булырга мөмкин: **1) ия дә, хәбәр дә күплек санда; 2) ия күплектә, хәбәр берлек санда**. Ярашуның беренче төре типтәрләр сөйләшендә, синтаксик реликт буларак, киң таралыш тота. Шул сәбәпле әдәби телдә бөтенләй кулланылмый торган җөмлә конструкцияләре килеп чыга: ***Эштәләр** быгай **үзләре**, белмәйем. Монау Сәгыйдә җиңгинең кызлары, **икәүләр алар***. Диалектларда сан белән бирелгән ия, грамматик яктан берлек санда килсә, хәбәр күплек санда килергә мөмкин. Мондый җөмләләр әдәби телдә сирәк очрый. Диалектларда һәм сөйләшләрдә "һәр адым саен" күрә алабыз: *Йәшен атып өч кеше **үлделәр***(ТТДС, 1969: 54, чст. с.,). *Малайның әтәсе кыd әтәсенә **бирәләр***(мнз с.,). *Айакларым җөрмәгәч, **бигрәкләр** дә кыйын*(Илеш районы БАССР, урта д.,). Мишәр диалектының Тамбов өлкәсендә урнашкан күршә авылы сөйләшендә хәбәргә зат кушымчасы белән бергә сан кушымчалары кушылганда тавтологик күренеш күзәтелә: *Авызландыр**дар** кызымны чаршау астында, ике кеше авызландыра (*ТТДС, 1993: 17). Моны да телдә булган экономиялек принцибы белән аңлатырга мөмкин. Мондый күренеш төрки телләрдән әзәрбайҗан теленең шарур диалектында[4: 8] очрый.

Ия булмаганда, хәбәр күплек сан кушымчасын үзенә ала. Диалектларда һәм сөйләшләрдә башка күренеш күзәтелә. Әдәби кануннардан тайпылышны халык авыз иҗатында да күрә алабыз.

Йомгаклап әйткәндә, әдәби телгә хас булмаган үзенчәлекләр диалектларда һәм сөйләшләрдә урын ала. Шулай да тел дигән дәрья иксез-чиксез, аның төбенә төшеп җитү, анда күмелеп яткан энҗеләрнең бөтенесен дә чүпләп бетерү һич мөмкин түгел. Бу эшне әле әби-бабаларыбыз исән вакытта ук башларга кирәк булган. Заманында моңа Н. Исәнбәт тә, игътибар итеп, болай дип язган: "Бигрәк тә безнең шикелле телебезнең культурасын

өйрәнергә соң тотынган халык...”[8: 223]. Ләкин “соң булса да уң булсын” дигәннәр бит.

Әдәбият

1. Джафарзаде М. М. Синтаксис диалектов и говоров азербайджанского языка: автореф. дисс......док. филол. наук / М. М. Джафарзаде. –Баку, 1981. – С. 31

2. Дмитриев Н. К. Башкорт теленең грамматикаhы / Н. К. Дмитриев. – Өфө: Башкорт. кит. нәшр., 1950. – Б. 158

3. Җәләй Л. Татар диалектологиясе / Л. Җ. Җәләй - Казан:Татиздат, 1947. – Б. 15

4. Имамкулиев К. Г. Шарурские говоры азербайҗанского языка: автореф.....канд. фил. наук / К. Г. Имамкулиев. – Баку, 1991. –С. 8

5. Мингулова Р. Р. Особенности чистопольского говора татарского языка: автореф.......канд. фил. наук./ Р. Р. Мингулова. – Казань, 1963. –С. 12

6. Насыйри К. Әнмүзәҗ / К. Насыйри – Казан. – 1895. – С. 55-56

7. Сафиуллина Ф. С. Синтаксис татарской разговорной речи / Ф. С. Сафиуллина. – Казань: КУ, 1978. – С. 167

8. Турапова М. Ш. Информация, компенсация, избыточность и экономия в диалектном синтаксисе / М. Ш. Турапова // Языкознание. Тезисы докладов и сообщении 10-12 сентября 1980 г. – Ташкент: Из-во “Фан”, 1980. – С. 121-124

9. Юсупов Ф. Ю. Татар теленең диалектлары: Урал сөйләшләре / Ф. Ю. Юсупов. – Казан: Мәгариф, 2003. – Б. 12

Чыганаклар

1. Материалы по татарской диалектологии. – Вып. 5. – Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 1983. – 168 с.

2. Рамазанова Д. Б. Себер диалектларыннан материаллар/ Д. Б. Рамазанова; ТФА, ТӘСИ; Җав. Ред. М. З. Зәкиев. – Казан: Фикер, 2001. – 141 б.

3. Татар теленең диалектологик сүзлеге / Д. Б. Рамазанова, Ф. С. Баязитова, З. Р. Садыкова, Т. Х. Хәйретдинова. – Казан: ТКН, 1993. –458 б.

4. Татар теленең диалектологик сүзлеге / Л. Т. Махмутова. – Казан: ТКН., 1969. – 642 с.